# Казан утлары

6.1985



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

6

1985

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП


М. Ш. ШӘЙМИЕВ. Икмәк һәм су . . . . . . 3


ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ


Г. К. ГЫЙМАТДИНОВ. Тиңнәребез арасында . . 9


ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ


Я. УХСАЙ. Иванов урманы. *Шигырьләр* . . . 13
М. СЕНИЭЛЬ. Фестиваль. *Шигырьләр* . . . . 14
Р. СӘРБИ. Нарат. *Шигырьләр* . . . . . . . 15
Х. УЯР. Котлау хаты. *Хикәя* . . . . . . . . 16
В. САДАЙ. Томан исе. *Хикәя* . . . . . . . . 20

Т. МИҢНУЛЛИН. Әниләр һәм бәбиләр. *Драматик хикәя* . . . . . . . . . . . . . . . 23

Х. КАМАЛОВ. Безне өйдә көтәләр. *Роман* . . . 43

Ә. БАЯНОВ. Тынлык эше. *Шигырьләр* . . . . 107
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Ак кыялар турында хыял. *Повесть* . . . . . . . . . . . . 113

М. ӘГЪЛӘМОВ. Синең кулда каләм. *Шигырьләр* . 169


М. ВАХИТОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА


Р. НӘФИКОВ. Ленинның көрәштәше . . . . . 174


ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА


Т. ХАҖИӘХМӘТОВ. Уральскида Тукай урыннары . . . . . . . . . . . . . . 178
Ә. РӘШИТОВ. Тукай клубы . . . . . . . 179


ЮБИЛЕЙЛАР


Н. ЮЗИЕВ. Әдәбиятка олы мәхәббәт . . . . . 181

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**

**ӘХӘТ ГАФФАР**

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**

**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**

**ФӘҮН МУСИН**

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*

**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**

**НУРИХАН ФӘТТАХ**

**СИБГАТ ХӘКИМ**

**РИЗВАН ХӘМИД**

**НИЛ ЮЗИЕВ**

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

**Безнең адрес:** 420066, Казань, ул. Декабристов, 2

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

**ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ**

М. ХӘСӘНОВ. Икмәк — тормыш ул . . . . . 185

**БИБЛИОГРАФИЯ**

В. Скоробогатов. Каһарманнар елгасы . . . . 188
Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

В рубрике «Навстречу XXVII съезду КПСС» статья секретаря Татарского ОК КПСС М. Ш. ШАЙМИЕВА «Хлеб и вода».
Новая рубрика: «Татарстан — родной мой край». Рассказ об Октябрьском районе. Публицистическое выступление М. ХАСАНОВА «Хлеб — это жизнь».
Роман Х. КАМАЛОВА «Нас ждут дома» (окончание). Повесть Р. МУХАМАДИЕВА «Мечта о белых скалах».
Драматическая повесть Т. МИННУЛЛИНА «Колыбельная».
Стихи А. БАЯНОВА, М. АГЛЯМОВА.
«Дружба народов — дружба литератур». Стихи и рассказы чувашских писателей.
К 100-летию Габдуллы Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА из серии «Тукаевские места в Уральске». А. РАШИТОВ. «Клуб имени Тукая».
К 100-летию М. Вахитова: статья Р. НАФИКОВА «Соратник Ленина».
В номере отмечается юбилей Г. Халита.
В разделе «Библиография» рецензируется книга «Днепр — река героев».
Дневник культуры.
На наших обложках: творчество художника Л. Фаттахова.

Техник редактор Р. Сөләйманова. Корректорлар Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова.

Производствога бирелде 30.04.1985 ел. Басарга кул куелды 27.05.1985 ел. ПФ 02116. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70 × 108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64049. Заказ Ф-153. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1985 ел.

**М. Ш. Шәймиев,**

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре

# ИКМӘК ҺӘМ СУ

Кеше гасырлар буе иген игү тәҗрибәсе туплаган һәм табигатьнең иң зур могҗизасы булган ашлыктан тотрыклы уңыш алу турында хыялланган. Әмма җирне кара тир белән сугарса да, аның якты өметләре еш кына челпәрәмә килә барган. Әйе, икмәк кешегә һичкайчан да ансат кына бирелмәгән. Урта Идел буйларында яшәүчеләр исә аны борын-борыннан аеруча зур көч куеп, тир түгеп җитештергәннәр. Безнең якларда еш кабатланып торган аяусыз корылыклар игенче алдына сынау артыннан сынау куйган. Чал тарих битләрендә, тирән яра эзе сыман, өнне алып, шомлы-афәтле еллар да очраштыргалый.

Бәлки шуңадыр, һәр буын кешеләре игенчегә мәдхия укыганнар, аның ифрат авыр хезмәтен олылаганнар. Мәсәлән, рус халкының бөек шагыйре Н. А. Некрасов болай дигән: «Игенче — бөек кеше, дөнья аның турында беркайчан да — шатлык килгәндә дә, кайгы килгәндә дә онытмады, беркайчан да онытмас. Икмәк телеме ат башы кадәр алтыннан да кыйммәтрәк».

Билгеле булганча, безнең республика игенчеләре дә авыл хуҗалыгы эшләрен катлаулы табигый шартларда алып баралар. Соңгы елларны гына күз алдына китерик. 1970 елдан санасак, шуларның нибары биш елы гына авыл хуҗалыгы өчен азмы-күпме уңай булды. Соңгы 50 елга күз салсаң, монда тагын да кырысрак күренеш: шул чорның 32 елында корылык интектерде.

Инде башка төрле саннарга мөрәҗәгать итик. Мәсәлән, бер тонна уҗым ашлыгы алу өчен 700—750 тонна су кирәк. Сабан культуралары суны тагын да күбрәк сорыйлар: бер тонна бөртек алу өчен 800—900 тонна су тотыла. Яшелчәләргә дымның аеруча мул кирәклеге һәркемгә мәгълүм. Мәсәлән, кәбестәнең бер гектарыннан 500 центнер алу өчен генә дә 4000 тонна өстәмә су кирәк. Мондый мисалларны бик күпләп китерергә мөмкин булыр иде.

Шуңа күрә дә җирне тиешенчә сугару крестьянның борын-борыннан килгән хыялы булган. Тик бу максатка ирешү өчен аның көче дә, мөмкинлеге дә җитмәгән. Бары тик совет власте гына крестьянның өметләренә яктылык сирпеде. Совет властеның беренче көннәреннән үк сугару системаларын җайга салу кирәклеге көн тәртибенә куелды. В. И. Ленинның мелиорацияне җир эшкәртүдә инженер-техник алым итеп кенә түгел, ә властьны үз кулына алган пролетариатның стратегик һәм тактик чарасы итеп тануы һәркемгә билгеле. 1921 елның 29 апрелендә кабул ителгән «Корылыкка каршы көрәш» дигән тарихи карар — моның ачык мисалы. Анда, корылык белән көрәш — партия һәм хөкүмәтебезнең авыл хуҗалыгын күтәрүдә иң әһәмиятле, беренче чираттагы чарасы дип, басым ясап, ассызыклап әйтелә.

Безнең республикада мелиорация эшләренә егерменче елның башларында ук керешелде. Бу әһәмиятле эш белән җитәкчелек итү өчен аерым идарә дә оештырылды. Дөрес, ул вакытта әле җир, тулысынча диярлек, кулдан яки бик гади җайланмалар ярдәмендә генә эшкәртелә иде. Куакларны кисү, кәс турау,

сугару каналлары казу — барысы да көрәк, балта, тимерчелектә генә ясалган кораллар ярдәмендә башкарылды. Хәтта шул чаралар да тиз арада бөртекле, кузаклы культураларның, чәчелгән үләннәрнең, яшелчәләрнең уңышын сизелерлек күтәрү мөмкинлеген бирде. Мәсәлән, Кама Тамагы районындагы Чернышевский мелиорация-тәҗрибә хуҗалыгында 1927 елны чөгендердән — 336, бәрәңгедән — 135, үләннән 62 центнер уңыш алынды. Ә инде 1934—1940 елларда, республикабызның Куйбышев районында тәҗрибә басулары булдырылды. Икенче бишьеллыкта инде сугарыла торган җирләрнең мәйданы 9610 гектарга җиткерелде. Бу, әлбәттә, ул чор өчен зур җиңү иде. Татарстан беренче тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән еллар иде бу.

Бөек Ватан сугышыннан соң җирне сугаруга, корылыкка каршы торучан урман теземнәре утыртуга аеруча зур әһәмият бирелә башлады, чөнки бу чаралар үзенең тормышчанлыгын, тотрыклы уңыш чыганагы булуын исбат итеп өлгергәннәр иде инде. Тагын саннарга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Мәсәлән, 1946 елда мелиорация өчен 1,3 миллион сум акча тотылса, 1948 елда ул 2,6 миллион сумга җитте, 1950 елда инде бу чыгым 5,6 миллион сум тәшкил итә иде.

Җирләрне сугаруның өченче этабы итеп, әлбәттә, КПСС Үзәк Комитетының 1965 елгы март һәм 1966 елгы май Пленумнарыннан соңгы чорны санарга кирәктер. Совет халкы бу карарларны программ документ итеп каршылады. Авыл хуҗалыгында аерым төстә мелиорация тармагы барлыкка килде. Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыклары, специальләштерелгән оешмалар булдырылды.

Бүгенге көндә Татарстанда 25 механикалаштырылган күчмә колоннаны (ПМК) берләштергән «Татмелиоводстрой» һәм «Татсельхозводстрой» трестлары эшли. Ә «Татгипроводхоз» институты һәр елны сугару системалары һәм гидротехник корылмалар өчен 2 миллион сумлык проектлар төзи. Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгының тимер-бетон корылмалар ясый торган үз заводы, ремонт-техника заводлары, өч автохуҗалыгы, производство-техник комплектация һәм төзелешне механикалаштыру идарәләре бар.

КПССның Татарстан өлкә комитеты партия съездлары һәм КПСС Үзәк Комитеты Пленумнары карарлары яктылыгында җирләребезне мелиорацияләүне яхшырту буенча максатлы эш алып бара. Моңа материаль һәм финанс ресурслары бирү дә елдан-ел арта. Сигезенче бишьеллыкта бу өлкәдә 73 миллион сум акча тотылган иде, тугызынчы бишьеллыкта бу чыгым ике тапкырга артты. Агымдагы бишьеллыкның дүрт елында гына да ул 148 миллионга җиткерелде.

Инде шул чыгымнар бәрабәренә ирешелгән нәтиҗәне карыйк. Соңгы вакытта бу эшнең техник ягы сизелерлек яхшырды, сугарыла торган объектларны проектлаштыруның һәм төзүнең сыйфаты әйбәтләнде, су белән тәэмин итү хуҗалыкларының материаль-техник мөмкинлеге ныгыды.

Хәзерге көнгә Татарстандагы сугарулы җирләр 235,4 мең гектар тәшкил итә. Әлеге бишьеллыкта гына да 38 мең гектар җир сугарыла башлады. Бу мәйданнарның 73 проценты киң алдырып яңгыр яудыра торган машиналарга көйләнгән, ә 30 процент чамасы электрлаштырылган насос станцияләренә беркетелгән.

Җирләрне сугару масштабларының һаман киңрәк колач алуы, бу шөгыльнең ышанычлы техникага нигезләнә баруы кадрлар әзерләүгә, аларның квалификациясен үстерүгә карата яңадан-яңа таләпләр куя.

Бүгенге көндә Татарстан Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгының төрле тармакларында 7 меңнән артык эшче, инженер-техник хезмәткәр эшли. Аларның 350 се югары һәм урта-техник белемле. Күп кенә алдынгы коллективларыбыз Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия социалистик ярышында, төрле конкурсларда җиңеп чыктылар. Шундыйлар рәтендә, беренче чиратта, «Татмелиоводстрой», «Татсельхозводстрой» трестларын, Карамалыдагы 5 нче механикалаштырылган күчмә колонна коллективын, Брежнев шәһәрендәге

9 нчы механикалаштырылган күчмә колоннаны һәм тимер-бетон әйберләр ясау заводын, «Татгипроводхоз» институтын, Казан механикалаштырылган ремонт-төзелеш күчмә колоннасы коллективларын атыйсы килә. ТАССР Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгының 50 дән артык эшчесе, инженер-техник работнигы СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде, 9 кешегә «РСФСРның атказанган мелиораторы», 40 кешегә «Татарстан АССРның атказанган мелиораторы» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Соңгы елларда, эзлекле рәвештә эшләп, сизелерлек нәтиҗәләргә ирешкән коллективлардан Брежневның 9 нчы механикалаштырылган күчмә колоннасын күрсәтәсе килә. Планны вакытында һәм җиренә җиткереп үтәүдә Насыйбуллин Р. С. һәм Комиссаров Г. Г. бригадаларының тырышлыгы аерым игътибарга лаек. Бу ике бригада, социалистик ярышта җиңеп чыгып, Ю. Гагарин исемендәге «Йолдызлы әләм» белән бүләкләнделәр.

Октябрь районы мелиораторларыннан Грачев В. Н., Матросов В. И., Буадан Буланов А. М., Кретов Г. П. һәм Чистайдан Мөхәммәтҗанов С. М. бригадаларының эшенә дә тел-теш тидерерлек түгел.

Җирне ел тәүлеге буена кадерләүче тагын бер коллектив уңганнарына да җылы сүз әйтми булмый. Бу — «Татсельхозстрой» трестының төзелешне механикалаштыру идарәсе комплексы хезмәткәрләре. Осетрин П. И., Карманов С. И. һәм Люкин Н. Т. иптәшләр җитәкли торган бригадаларның 20—30 градуслы салкыннарда да, җәйге чилләләрдә дә тәүлекләр буе фидакарьләрчә эшләүләренә сокланмый мөмкин түгел.

Республика мелиораторлары арасында менә дигән осталар үсеп чыкты. Мәсәлән, Саба районының 12 нче механикалаштырылган күчмә колоннасында эшләүче Сабитовлар гаиләсе һәрчак макталып телгә алына. Гаилә башлыгы Миңләхмәт Хәмитович Сабитов мелиорация эшенә иң авыр чорда, 1967 елда килде. Ул җитәкчелек иткән коллектив һәр елны иң югары күрсәткечләргә иреште. Татарстан мелиораторлары арасында Миңләхмәт Хәмитович, иң беренчеләрдән булып, РСФСРның атказанган мелиораторы исеменә лаек булды. Узган елда аны зурлап пенсиягә озаттылар. Үзе китсә дә, коллективта өч улы калды аның. Өлкән улы Наил — ун ел инде экскаватор машинисты, Шамиле — бульдозерда, кече улы Камил прораб булып эшли. Уллары да берсеннән-берсе тырышлар, әтиләренә охшаганнар.

Мелиораторларның социалистик ярышы авангардында Азнакай районындагы төзү-монтаж эшләрен хуҗалык исәбенә башкаручы участок бара. Бу бердәм коллективны Татарстанның атказанган мелиораторы Рәис Шәрифуллин җитәкли. Әлеге подразделение коллективы узган елның беренче һәм өченче квартал йомгаклары буенча Бөтенсоюз социалистик ярышта җиңеп чыкты. СССР Су хуҗалыгы министрлыгы һәм профсоюзлар Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагына лаек булды. Коллектив соңгы дүрт ел эчендә генә дә биш миллион сумлык эш башкарды, гидротехник корылмалар ясады, нәтиҗәдә районның сугарыла торган басулары тагын 2495 гектарга артты. Бу мелиораторларның эше һәрчак югары сыйфатлы булуы белән аерылып тора. Коллективта җитештерүчән хезмәт өчен шартлар да бар: механика мастерскойлары, гаражлар, бетон изгеч, тимерчелек — барысы да гөрләп тора. Мелиораторлар колхоз-совхоз җитәкчеләре һәм белгечләре белән һәрчак тыгыз элемтәдә. Кыенрак мәсьәләләрне гел бергәләп хәл итәләр.

Республиканың партия, совет һәм хуҗалык органнары сугарулы җирләрнең эффектлылыгын арттыру мәсьәләсенә зур җаваплылык белән карыйлар. Моны җир эшкәртүдә иң отышлы алым итеп, терлек азыгы җитештерү проблемасын чишүдә иң ышанычлы юл дип таныйлар. Хәзер сугарулы чәчүлекләрдә басу әйләнеше тәртипкә салына, югары уңыш бирүчән үләннәр чәчү алга сөрелә, яхшы орлыклар булдырыла. Сугарулы җирләрнең 95 процентлабы коллектив подряды белән эшләүче звенолар карамагына тапшырылган. Нәтиҗәдә Балтач, Сарман, Чүпрәле, Тукай һәм башка районнарда сугарулы басуларның һәр гектарыннан 55-60 ар центнер азык бирәмлегә ала башладылар. Алдынгы хуҗалыклар арасында бу күрсәткечне 80-100 әр

центнерга җиткерүчеләр дә бар. Чәчүлек җирләренең алты процент чамасын алып торучы сугарулы басулар хәзер республикада җитештерелүче үсемлек продукциясенең — унөч процентын, печән белән сенажның өчтән бер өлешен һәм барлык тамыразык белән яшелчәне бирә. Сугарулы гектарның продуктлылыгын арттыру терлекчелектә яңа уңышларга ирешүнең яңа юлын ачты.

Үткән елның ноябрь аенда партиянең өлкә комитеты пленумы, КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1984) Пленумы карары яктылыгында, мелиорация эшләрен тагын да җанландыру мәсьәләләрен карады. РСФСР Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы белән бергәләп җирләрне мелиорацияләү буенча программа булдырылды. Анда билгеләнгәнчә, 1990 елда безнең республиканың ясалма яңгыр яудырыла торган басулары —290 мең, 2000 елда исә 400 мең гектарга җиткереләчәк. Сугарулы җирнең җитештерүчән көчен арттыруга да әһәмият бирелә, аның һәр гектарыннан 70-80 центнер азык берәмлеге алу күздә тотыла. 1990 елга бу төр чәчүлекләрдән тулаем 1,5 миллион тонна, ә 2000 елга 2 миллион тонна чамасы азык берәмлеге җыярга планлаштырыла.

Алдынгы хуҗалыкларның моңарчы ирешкән уңышлары — бу бурычларның тормышчанлыгына ачык дәлил.

Җирләрне мелиорацияләү, сугару эшләрен оештыру, ясалма яңгыр яудырылган җирләрдән тотрыклы, югары уңыш алу буенча республикабызда шактый тәҗрибә тупланды инде. Балтач, Чирмешән, Тукай һәм башка районнарда сугарылган гектарның потенциаль мөмкинлекләреннән аеруча оста файдаланалар. Берничә хуҗалыкка конкретрак туктыйсы килә. Мисалга Тукай районының «Гигант» совхозын алып карыйк. Бу хуҗалыкны 12 ел инде Социалистик Хезмәт Герое Нәҗип Зыятдинов җитәкли. Монда сугару системалары кору эшенә 1973 елда керешкәннәр иде. Хәзерге көндә совхозга беркетелгән 5300 гектар сөрү җирләренең 2880 гектары сугарыла. Бу эш җайга салынганнан бирле мелиорацияләнгән җирләрдән авыл хуҗалыгы продукциясе алу өч тапкырга артты. Әгәр дә совхоз буенча тугызынчы бишьеллыкта һәр гектардан уртача 15 центнер ашлык алынган булса, унынчы бишьеллыкта ул 34 центнерга җитте, агымдагы бишьеллыкның дүрт елында уңыш 44 центнер тәшкил итә. Күпьеллык үләннәрнең уңышы 100 центнердан 500 центнерга кадәр күтәрелде. Совхозда бөртекле культуралар чәчү мәйданының 50 процентка якыны сугарыла. Шул мәйданнардан соңгы дүрт ел эчендә гектар саен уртача 50 центнердан артык уңыш алынды. Узган елда, табигать шартларының шактый ук кырыс килүенә карамастан, сугарулы җирләрнең һәр гектарыннан 53,3 центнер уңыш чыкты. Бу — ясалма яңгыр яудыру осталары Х. Галәвиев, Х. Рамазанов, А. Муллахмәтов, Н. Яппаров һәм башкаларның тырыш хезмәте нәтиҗәсе.

Совхозда мелиорация системасы җайга салынганнан бирле, терлек азыгының нык базасы булдырылды. Азыкның муллыгы аркасында терлекләрнең баш саны өч тапкырга артты. Бүгенге көндә монда 4300 баш мөгезле эре терлек бар, шуларның ике меңе савым сыеры. Совхоз һәркөнне КамАЗчыларга 200 центнердан да артыграк сөт бирә.

Тукай районының «Коммунизм» колхозы ирешкән уңышлар да башка хуҗалыкларга үрнәк. Мондагы мелиораторларның 6 кешелек звеносын 1971 елдан бирле Мәгъсүмҗан Миңлебаев җитәкли. Алар күпьеллык үлән үстерәләр. Звено бу эштә үз технологиясен булдырды. Шушы сугарулы мәйданнан 660 центнер сусыл үлән, 50 центнер әйбәт печән җыеп алынды. Звено членнары СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең бронза медальләренә лаек булдылар. Звено җитәкчесе М. Миңлебаев Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнде.

Сүз уңаенда Балтач районының «Якты юл», «Яңа тормыш», «ВЛКСМның 50 еллыгы», «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге; Кама Тамагы районының «Кама», Минзәлә районының «Гигант»; Кукмара районының «Правда»; Мөслим районының «Урожай»; Лениногорск районының «Спартак»; Алабуга районының «Волна революции»; Актаныш районының

«Игенче»; Саба районының «1-Май»; Биектау районының «Алга» һәм «Бөреле»; Октябрь районының Хафизов исемендәге; Югары Ослан районының «Рассвет»; Арча районының Ленин исемендәге; Лаеш районының «Новый»; Түбән Кама районының «Түбән Кама» хуҗалыкларында да, җирне кадерләп сугарганда, нинди могҗизалар тудырырга мөмкин икәнлеге бик ачык расланды.

Азык-төлек программасында авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне арттыруда мелиорациянең роле дә бик ачык дәлилләнде. Анда мелиорация системаларыннан файдалану һәм аларга техник хезмәт күрсәтүнең яңа оешты-ру формаларын кертү, сугаруның югары нәтиҗәле ысулларын куллануны киңәйтү, автоматика һәм телевизион идарә системаларыннан файдалану, мелиорация төзелешендә полимер материалларны киң куллану бурычлары да куелды. Максатка ирешү ечен югары җитештерүчән сугару техникасы, машиналар һәм механизмнар өлгертүне тәэмин итү буенча да конкрет чаралар билгеләнде.

Алга куелган олы бурычларны үтәүдә авыл хуҗалыгына республикадагы промышленность предприятиеләре зур ярдәм күрсәтәләр. 1984 елда кырыклап предприятие тырышлыгы белән терлек азыгы җыя торган КПКУ –75 маркалы комбайн ясалды. Үткән ел ук инде шундый 200 машина әзер иде, быел тагын 500 машина өлгерә. 1985 елны СССР Суднолар төзү, РСФСР Мелиорация һәм Су хуҗалыгы министрлыклары киң алдырып яңгыр яудыручы «Фрегат» машиналары чыгаруны җайга салды. «Нармонский» совхозында үзебез ясаган бу җайланма көйләп тә куелды инде. Ел азагына кадәр без аларның санын 50 гә җиткерәчәкбез, киләчәктә исә ел саен 200 данә чыгарачакбыз. Бу яңа чаралар уникенче бишьеллыкта 50 мең гектар җирне сугарырга, 30 мең гектардагы элекке җайланмаларны яңартып төзергә мөмкинлек бирәчәк. Нәтиҗәдә сугарулы басулардан 1,5 миллион тонна азык бирәмлеге җыеп алыначак.

Октябрь Пленумында нәкъ менә шул турыда әйтелде, мелиорация эшендә колхоз-совхозларның үз инициативасын күтәрүгә аерым игътибар юнәлтелде. Хуҗалыклар кемнәрнеңдер килеп ярдәм итүен көтеп тормасыннар, эчке мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышсыннар, су хуҗалыгы органнары белән берлектә үз җирләрен мелиорацияләү эшләрен башкаруда үз көчләренә ныграк таянсыннар иде.

Сугарулы мәйданнар киңәю белән, көн тәртибенә су проблемасы килеп басты. Дөрес, беренче карашка, Иделе, Камасы, Агыйделе, Вяткасы булган Татарстан өчен бу мәсьәлә әллә ни кыенлык тудырмас кебек. Чынлыкта исә авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү шактый авыр. Бу фикерне исбат итү өчен бер генә мисал китерәсе килә. Бүгенге көндә бездә төрледән-төрле 3,5 мең насос станциясе эшли. Алар берьюлы суыртсалар, бер тәүлек эчендә генә дә, берничә миллион тонна су кирәк булыр иде. Соңгы елларда исә сугарулы мәйданнар арта бара.

Язгы ташу вакытында елгаларыбызның 75 процент суы агып китүне исәпкә алып, без бу байлыкны буаларда һәм сусаклагычларда тотып калырга, аннары алардан басуларны сугару өчен файдаланырга уйлыйбыз. Республикабызда 1200 буа һәм сусаклагыч булдырылачак. Шуларның 375 е төзелеп файдалануга тапшырылды. Һәр елны, планда бирелгәнчә, 25-30 буа ясала.

Чирмешән, Кукмара, Буа, Азнакай районнарында унар-уникешәр буа файда күрсәтә башлады инде.

Хәзер безнең республикада даими сугару белән бергә су сиптергеч күчмә җайланмалар да киң кулланыла. Соңгы елларда мондый мәйданнар 3,5 мәртәбәгә артты һәм 40 мең гектарга җитте. Кукмара, Балтач районнарында бу ысул белән 2200-3700 гектарлап җиргә су сибелә. Эштә коллектив, гаилә подряды алымнары алга сөрелә. 1984 елны мондый басуларның гектарыннан 800 центнер һәм аннан да артыграк тамыразык җыелды. Гомумән алганда, республикабызның сугарулы басуларыннан 1200 мең тонна тамыразык җыелды, уртача һәр гектардан —450 центнер.

Яшелчәчелек һәм бәрәңге үстерү белән шөгыльләнүче хуҗалыклар җирне сугарудан бигрәк тә зур файда күрәләр. Бу төр азыклар исә безгә ел саен күбрәк кирәк була бара. Хәзер республикадагы яшелчә һәм бәрәңге бакчаларының 20 мең гектар чамасы сугаруга көйләнгән. Без яшелчә үстерүне «Татплодоовощхоз» берләшмәсенә үзәкләштердек. Аның совхозлары Зеленодольск, Биектау, Бөгелмә, Лаеш һәм Тукай районнарына урнашканнар.

«Нармонский», «Ворошиловский» совхозларында яшелчәчелек ныклы нигездә алып барыла. Бу хуҗалыклар Казан, Брежнев, Түбән Кама шәһәрләрен яшелчә белән тәэмин итәләр.

Әле күптән түгел КПСС өлкә комитеты бюросы КПССның Казан шәһәр комитеты, халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты һәм КПССның Брежнев шәһәр комитеты тарафыннан бәрәңге белән яшелчә җитештерүне арттыру, аларның сыйфатын яхшырту буенча алга куелган чараларны хуплады. Бу чаралар шәһәр янындагы авыл хуҗалыгы зоналарында, шәһәрләрдә бәрәңге һәм яшелчәләрне җыйганнан соң эшкәртү, саклау пунктлары, махсус контейнерлар, консервлау цехлары булдыруны күздә тота. Яңа кибетләр, саклау урыннары ачу, искеләрен яхшылап төзәтү кебек бурычлар да алга куела. Аларны тормышка ашыруда Казан, Брежнев шәһәрләрендәге төзелеш оешмалары, промышленность предприятиеләре дә актив катнашачак.

КПСС Үзәк Комитетының октябрь (1984) Пленумында күрсәтелгәнчә, илне азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл кылу өчен иң әүвәл бөртеклеләр җитештерүне арттырырга кирәк. Бу бурычны үтәү хәзерге чорда һәр колхоз-совхозның, агропромышленность комплексларының, партия оешмаларының, кыскасы, республиканың игенчелеккә бәйле һәр кешесенең төп максаты. Моңа ирешү юлы бер генә — иген үстерүне интенсив үсү юлыннан алып барырга кирәк. Быел ук инде уҗым культураларының 350 мең гектары, бодайның 200 мең гектары интенсив технологиягә нигезләп эшкәртеләчәк.

Республикабыз мелиораторлары 1985 елның үзенчәлекле, җаваплы ел булуын яхшы беләләр. Бу — бишьеллыкны тәгәлләү елы, сайлаулар үткәрү, В. И. Ленинның тууына 115 ел тулу, Бөек Җиңүнең 40 еллыгы, бу — стахановчылык хәрәкәтенең 50 еллыгын каршылау, партиянең XXVII съездына әзерләнү елы. Шуныктан мелиораторларыбыз 1985 елга күтәренке йөкләмәләр кабул иттеләр. Хәзер һәрбер коллективта югары оешканлык, тәртипле иҗади хезмәт хөкем сөрә. Мелиораторларның күп кенә звенолары, бригадалары һәм комплекслары, быелгы кебек кырыс кышкы көннәрдә дә икешәр сменага бүленеп, ә кайбер урыннарда хәтта тәүлекләр буена кызу эш алып бардылар. Комплексларга техник ярдәм күрсәтү өчен махсус бригадалар билгеләнде. Һәрбер объектта диярлек җылытылган махсус вагоннар булдырылды, эшчеләрне кайнар аш белән тәэмин итү чаралары күрелде. Хезмәтне шулай оештыру механизмнарны рациональ файдалануга, директив нормаларны арттырып үтәүгә мөмкинлек бирде. Мелиораторлар яхшы беләләр: артык алынган һәр тонна ашлык, ит, сөт — халкыбызның тормыш хәлен яхшырту гына түгел, ул — тыныч тормышның өстәмә таянычы, Ватаныбызның оборона сәләтен ныгытуга безнең конкрет өлешебез.

Хәзер республикабыз мелиораторлары басуларда планда каралган уңыш үстерү өчен көрәш җәелдерделәр. Колхоз-совхозлар агропромышленность комплекслары белән яңартылган җирләрдән отышлы рәвештә файдалануга юнәлтелгән килешүләр төзиләр. Сугару җайланмалары көйләнә, кадрлар өйрәтелә, ашламалар һәм үләннәрнең яхшы орлыклары әзерләнә.

Республикабыз мелиораторлары 1985 елны яңа уңышлар белән билгеләп үтү, дәүләт планнарын һәм алынган йөкләмәләрне үтәү өчен көчләрен кызганмаслар, дип зур ышаныч белән әйтергә була.

## *Татарстан — туган төбәгем*



*Республикабыз Татарстан турындагы мәгълүматыбыз тулымы икән безнең? Аның аерым төбәкләрендә нинди тарихи вакыйгалар булган, бүгенге көннәргә юл ничек узган? Хәзер нинләр белән горурлана алабыз, алдагы максатларыбыз нинди һәм киләчәгебез ни вәгъдә итә — боларның барын да беләбезме?*

*Бик күпләребез дөньякүләм әһәмиятле хәлләр белән таныш, ерак илләргә сәяхәтләргә дә йөри; илебез тарихын һәм бүгенгесен яхшы белә, ә менә Татарстан, хәтта үзе туып-үскән район турында да, кызганычка каршы, бик аз мәгълүматлы.*

*Дөньяны, кешеләрне, Ватанны ярату, аларга соклану һәм аларны тагын да матуррак, бәхетлерәк итәргә тырышу нәкъ үз туган төбәгеңне өйрәнүдән, аңа карата ихтирамлы булудан башланырга тиеш ләбаса!*

*Шул хакыйкатьне күздә тотып, журналның бу саныннан Татарстан районнарына багышланган яңа сәхифә ачып җибәрәбез. Анда ай саен район җитәкчеләренә сүз биреләчәк.*

**Г. К. Гыйматдинов,**
КПССның Октябрь район комитеты беренче секретаре,
Социалистик Хезмәт Герое

# ТИҢНӘРЕБЕЗ АРАСЫНДА

Билгеле булганча, безнең республикада утыз сигез район бар. Үткәндә кичергәннәре, бүгенге көнкүрешләре һәм киләчәккә омтылышлары, күп яктан, бер-берсенә охшаса да, аларның үзләренә генә хас аерымлыклары да шактый.

Безнең Октябрь районы Татарстанның иң көньягына урнашкан. Аны Куйбышев өлкәсеннән аерып Кондырча суы ага. Мәйданыбызның көньяк өлеше буйлап 26 километрлы тимер юл уза. Җиребезне көньяк, төньяк өлешләргә бүлүче Чирмешән һәм аның белән кисешеп агучы Сөлчә елгаларыбыз бар. Климат, башлыча, коры һавалы, чөнки көнбатыштан исүче җилләр, дымнарын Идел буендагы биеклекләргә сеңдереп, безнең тирәгә коргаксып кына килеп җитәләр. Басуларыбыз кара туфраклы. Чирмешән елгасы һәм аның кушылдыгы арасын шактый калын, төрле җәнлекләр һәм үсемлекләр дөньясына бай булган урманнар били.

Бу яклардагы тормышның тарихы Рус дәүләте белән Казан ханлыгының кушылу чорларына барып тоташа. Патша властьлары, җирне тизрәк үзләштерү өчен, бу төбәккә үзәк Россиядә яшәгән кешеләрне дә күпләп-күпләп күчереп утырталар. Элек буш торган киңлекләргә Кондырча, Чирмешән, Чишмә крепостьлары салына. Җирле халык яңа күчеп килүчеләр белән аралашып яши башлый. XVII гасырда, гади күченүчеләрдән соң озак көттермичә, патша чиновниклары, сәүдәгәрләр һәм крепостник алпавытлар да килеп-килеп урнашалар. Алпавытларның тирә-юньне дер селкетеп торучыларыннан Зубов, Аристов кебек графларны күрсәтергә мөмкин. Алар байлыкларының исәпсез булуы белән генә түгел, крестьяннарны ерткычларча изүләре белән дә халыкның котын алып яшәгәннәр. Рус, татар, чуваш, мордва крестьяннарының, авырлыкларга түзә алмыйча, Урал якларына китеп, Пугачев хәрәкәтенә кушылулары турында да мәгълүматлар бар.

1941 елны тимер юл салынып, Норлат станциясе ачыла. Безнең тирәне, шул еллардан башлап, «Норлат ягы» дип тә йөртәләр.

1917 елгы февраль революциясеннән соң империалистик сугыш фронтларыннан кайтучылар патшаның бәреп төшерелүе хакында хәбәр тараталар. Ул да түгел, моңарчы сөргендә җәфа чиккән Аксенов Ф. М., Благоразумов Н. В. кебек җирле большевиклар да Норлатка кайтып төшә. Алар халыкны совет власте өчен көрәшкә туплыйлар. Шул җәйне үк Егоркино крестьяннары үзләренең волость съездында Оболенский фамилияле князьнең урманын һәм бөтен байлыгын үзара бүлешергә карар чыгаралар. Алпавыт Рожнов, Ситдиков, Кәримов, Садриев, Нигъмәтуллин кебек кулакларның мөлкәте дә шул ук язмышка дучар ителә.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүе крестьяннарны яңа адымга этәрә. Норлаттагы Аксенов, Благоразумов, Горшков кебек большевикларга ярдәмгә Чистай большевиклары да кушылалар. 1918 елның январенда ук волостьларда крестьян депутатларының Советлары оештырыла.

Гражданнар сугышы чорында Норлат ягы яңа афәтләр кичерә. Монда ак чехлар да, колчакчылар да булып китә. Алар совет власте өчен җан аямыйча көрәшүче революционерларны ерткычларча җәзалыйлар. 1918 елның октябрендә, ниһаять, Норлат станциясе совет иле дошманнарыннан азат ителә. Кан коюлы сугышларда һәлак булган каһарманнарга һәйкәл куела.

1919 елның мартында волостьларда РКП(б) ячейкалары оештырыла башлый. Шушы елда ук кайбер урыннарда аерым хуҗалыкларны берләштерергә дә тотыналар: авыл хуҗалыгы артельләре, коммуналар барлыкка килә. Крестьян хуҗалыкларын күмәкләштерү төп бурыч итеп билгеләнгәч, сыйнфый көрәш кабаттан да кискенләшеп ала.

1930 елны рәсми төстә Октябрь районы төзелә. Ул үзенә Егоркино, Чулпан, Иске Чаллы волостьларын берләштерә, Норлат станциясе районның үзәге итеп билгеләнә. Районның төрле авылларында партия ячейкалары, авыл советлары, комсомол оешмаларын төзү һәм хуҗалыкларны күмәкләштерү кан коюлы кискен көрәшләр аша алып барыла. Кайбер җирләрдә авыл советы председательләрен, комсомол секретарьларын, коммунистларны, күмәк хуҗалык җитәкчеләрен җәзалап үтерү очраклары да була.

Әмма гасырлар буе изелүдә яшәгән халыкның матур яңалыкка ышанычы шулкадәр көчәя ки, аны алга омтылышыннан һичнинди корбаннар да туктата алмый. Татарстанда беренче буларак, районның үз машина-трактор станциясе дә төзелгәч, крестьяннарның киләчәккә ышанычы аеруча ныгый.

Октябрь районы, оештырылуының беренче елларыннан ук, Татарстанда алдынгылар сафына баса. 1932 елда районның игенчеләрен «Правда» газетасында мактап чыгалар. 1933 елның 20 маенда район «ТАССРның алдынгы районына» дигән күчмә Кызыл байрак белән бүләкләнә. Район бу абруен бүгенгәчә саклап килә.

Бөек Ватан сугышы елларында районның 12 мең 500 улы һәм кызы фронтка китә. Аларның яртысы гына әйләнеп кайта, башкалары яу кырында ятып кала. Бүген без Советлар Союзы Герое исемен алган А. И. Кузнецов, Н. К. Синдряков, И. А. Козлов, М. Е. Сергеев, Дан орденының өч дәрәҗәсенә дә лаек булган П. Е. Михеев, М. М. Мәсгутов һәм башка каһарманнарыбыз белән ихластан горурланабыз.

Районның хезмәт ияләре «Татарстан колхозчысы», «Октябрь колхозчысы» исемле танк колонналары, самолетлар төзү өчен 6 миллион 161 мең 800 сум акча җыялар. Кызыл Армиягә һәм завод эшчеләренә дип 20 966 пот икмәк тапшыралар. Шушындый игелекләре өчен безнең район кешеләре Башкомандующий И. В. Сталинның рәхмәт телеграммаларында өч тапкыр телгә алына.

Сугыштан соңгы чор да безнең кешеләрнең гаҗәеп фидакарьлеге белән аерылып тора. Район тиз арада нык җирлеккә баса һәм яңа үсеш юлына керә. 1958 елда районда Татарстанның беренче шикәр заводы эшли башлый. 1964 елны коммуналь хуҗалыкларга җиһазлар җитештерә торган машина төзү заводы сафка кертелә. 1979—1980 елларда Идел буендагы иң эреләрдән санал-

ган меңнәрчә тонна ашлык сыйдырышлы элеватор өлгерә. Май, ит, сөт комбинатлары һәм башка төр промышленность предприятиеләре барлыкка килә. Аларның житештерүчәнлек куәте ел саен арта бара. 1983 елны гына да алар 75 миллион сумлык эш башкарды. Бу, унынчы бишьеллыкның бер елындагыга караганда, 1,5 тапкырга артыграк.

Илленче еллар уртасында Норлат җирендә нефть эзләү башланган иде. Хәзерге көндә бездә 120 ләп нефть чыганагы ачылды. «Норлатнефть» коллективы 1979 елдан бирле илгә 4 миллион 270 мең тонна сыек ягулык бирде.

Безнең төп байлыгыбыз, әлбәттә — нык алга киткән, күп тармаклы авыл хуҗалыгы: унсигез колхозыбыз, дүрт совхозыбыз бар. Алар, башлыча, терлекчелек, игенчелек һәм шикәр чөгендере үстерү белән шөгыльләнәләр. Ел саен дәүләткә 450 мең центнер ашлык, 63 мең центнер ит, 230 мең центнер сөт, 830 центнер йон һәм 100 мең тонна шикәр чөгендере саталар. Мондый зур хуҗалыкларны җитәкләп, күп тармаклары механикалаштырылган эшләрне башкару өчен хәзерлекле, белемле, тәҗрибәле кадрлар кирәк. Бездәге биш йөздән артык белгечнең югары һәм махсус урта белеме бар.

Соңгы елларда зур-зур төзелешләр башлап җибәрдек. Ниятебез — авылларны төзекләндерү, яшәр өчен уңайлы итү, матурлау. Хәзер колхоз һәм совхозлар карамагындагы 447 торак йортта 746 гаилә яши. Бу саннар көн саен үзгәрә, арта тора, чөнки төзелешләр бер генә сәгатькә дә туктамый. Моның кадрларны туплауда, яңа белгечләрне тартуда бик мөһим чара икәнлеген яхшы аңлыйбыз. Бу җәһәттән Синдряков исемендәге колхозны аерым телгә алып үтәргә кирәк табам. Әле кайчан гына бу хуҗалык эшче куллар җитмәүдән интегә иде. Хәлне төзәтү өчен колхоз җитәкчелеге авылның социаль ягын үзгәртергә, бигрәк тә колхозчыларның көнкүрешен, торак мәсьәләләрен яхшыртуга йөз тота башлады. Хәзер колхозның сиксәннән артык үз торак йорты бар. Аларда механизаторлар, терлекчеләр, игенчеләр һәм интеллигенция вәкилләре яши. Яңа йортлар ел саен салына. Идарә яшь гаиләләргә бигрәк тә теләп ярдәм итә. Йорт салырга ашкынып торалар икән, андыйларга бурычка акча бирелә. Колхозның ләм белән дәваланырга да җайланган үз больницасы, урта мәктәбе, элемтә бүлеге, ашханәсе, балалар бакчасы бар.

Тулаем алып караганда да, район кешеләренең көнкүрешендә, культура дәрәҗәсе үсешендә алга китеш әллә кайдан сизелеп тора. Һәм бу уңышларның барысының да нигезендә бер нәрсә — кешеләребезнең уңганлыгы, фидакарьлеге, тырышлыгы ята.

Безнең кешеләр район оештырылуның беренче көннәреннән үк үзләренең илгә, халыкка, партиягә тугрылыкларын каннары белән раслап күрсәттеләр. Шуңа күрә дә без аларны районның иң зур байлыгыннан саныйбыз. Норлат ягы элек-электән талантларга да бай булган. Татар театрына нигез салучыларның берсе, атаклы артист һәм режиссер Габдулла Кариев — безнең Күлбай Мораса авылы егете. Бу авылның культура сарае аның исемен йөртә. Татар шигъриятен илаһилыкка табынудан арындырып, җир кызларына, җирдәге тормышка мәдхия җырлаган шагыйрь Габделҗаббар Кандалый, безнең Кизләү мәдрәсәсендә укып, заманасына күрә белемне алып киткән. Татарстанның атказанган артисткасы Зәкия Туишева, популяр көйләр авторы Марс Макаров та — безнең якташлар. Илебезнең күренекле галимнәре арасында безнең Абляскино авылы егете, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Дәүләт премиясе лауреаты, техник фәннәр докторы, профессор Александр Изотов; Кизләү егете, Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясе профессоры Хәбибулла Әсәров бар. Норлатта үскән Рифкат Богданов — Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының өлкән фәнни хезмәткәре. Галим якташларыбыздан тагын тарих фәннәре кандидаты Сәлам Алишевны, медицина фәннәре кандидаты Әфкат Галиуллинны, филология фәннәре докторы, Алабуга дәүләт педагогия институты ректоры Тәлгать Галиуллинны һәм башкаларны күрсәтергә була.

Октябрь районы Совет Армиясенә Николай Яковлев кебек генерал-лейтенантны, Ибраһим Сафин, Евгений Соловьев кебек генерал-майорларны бирде.

Спорт дөньясында да безнең якташлар бар: футбол буенча атказанган спорт мастеры Галимҗан Хөсәенов районның Яңа Иглай авылында туып үскән; марафон дистанциясенә йөгерүдә дөнья чемпионы, халыкара спорт мастеры Михаил Горелов — безнең Чияле авылы егете.

Районның бүгенгесен, аның мәшәкатьләрен хезмәт батырларыбыз үз иңнәрендә тоталар: Социалистик Хезмәт Геройлары бораулаучы Тимерҗанов З. Т., Н. К. Синдряков исемендәге колхоз председателе урынбасары Захаров Н. И., «Тернәс» совхозының элекке зоотехнигы Ефимов В. В. Андыйларның осталыгын яшьләрне тәрбияләүдә дә файдаланырга тырышабыз без. «Дружба» колхозында озак еллар буе председательлек иткән Социалистик Хезмәт Герое Хафизов Ш. дөньядан кичкәч, бу мөхтәрәм шәхеснең истәлеген мәңгеләштерү өчен, колхозга Хафизов исемен бирдек. Колхозчылар аның урынына Хафизов үзе тәрбияләп үстергән япь-яшь белгеч Хәлил Морадыймовны председатель итеп сайладылар.

Халык хөрмәтен казанган уңганнарыбыздан СССР Верховный Советы депутаты, Күлбай Мораса авыл советы председателе Гөлсирин Садретдинованы, бораулаучылар идарәсе начальнигы, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнгән Ю. Мөхәрмәтовны, «Заветы Ильича» колхозының ферма мөдире, «Халыклар дуслыгы» ордены кавалеры Е. С. Пининаны, «Тернәс» совхозы савымчысы, «Почет билгесе» ордены алган А. В. Рыбинаны да мактыйсы килә.

Хезмәтчәннәребезнең егермеләбе — Ленин ордены, ике йөздән артыгракы башка орден һәм медальләр белән бүләкләнде. Районыбыз үзара туганнардай дус, тату яшәүче дистәләрчә милләт вәкилләрен берләштерә. Алар барысы да бер үк максат — иртәгәге көнне тагын да матуррак, муллрак итү өчен тырышалар. Көрәшнең алгы сафында — коммунистлар. Райондагы 72 башлангыч партия оешмасы барлык хезмәт ияләрен иҗади җиңүләргә рухландырып тора. Комсомоллар исә — партия оешмаларына һәрчак ярдәм итәргә ныклы таяныч.

Бу көннәрдә районыбыз хезмәт ияләре КПССның XXVII съездын, эштә яңа уңышлар яулап, лаеклы төстә каршыларга көчләрен аямыйлар.

## Яков Ухсай,

Чувашстан халык шагыйре.

### Иванов урманы

*Атабыз — меңьяшәр имән...*

Чуваш халык җыры.

Шагыйрь — күккә тигән имән.
Иелмәгән җәбер-җилдән.
Һәр сүзе күпме күңелне
Күтәргән түбән дәвердән.

Халкым, кайда сөйгән улың?
Гүрдәме ул? Күңелдәдер: —
Бөек имән бертуктаусыз
Безнең җанда шаулый хәзер.

Аның чикләвекләреннән
Күтәрелде урман, ашты...
Үзе дә ул шул урманда,
Йолдызларда — ябалдашы.

Тынмый шагыйрь сүзе, урман
Күтәрепләр ала аны.
Шаула, чуваш шигърияте —
Ивановның яшь урманы!

### Идел турында җыр

Агыл, җырым, агыл, агыл,
Идел өсләренә кагыл.
Иделемә мәдхия син,
Илдән-илгә кит син агып.

Риваятьләр белән бергә
Бүгенгә килгән Иделем! —
Һәр дулкының таныш миңа:
Синдә — илем, синдә — телем.

Без коенган суларыңда
Таң шәүләсе янып торды.
Шуңадырмы балаларың
Батырларның да батыры!

Күзләрдә дә, күңелдә дә
Бар сафлыгы суларыңның.
Синең белән кан-кардәшлек —
Горурлыгы улларыңның.

Җиңәм диеп килде дошман.
Җанның силгә иш мәлләре.
Болгатырга мөмкинме соң
Безнең бәхет чишмәләрен?!

Чакырылмаган кунакларны
Куып киттек изге җирдән.
Идел атларын Одерда
Су эчердек без чөңгердәп.

Риваятьләр белән бергә
Киләчәккә җит, Иделем,
Һәм мәңгегә иркле бул:
Синдә — илем, синдә — телем.

Ләис ЗӨЛКАРНӘЕВ тәрҗемәләре.

## Михаил Сениэль,

чуваш шагыйре.

### Фестиваль

Биш таҗлы ромашкадай,
Якты, көләч җир шары.
Көләчлектән курыкса тик
Куркыр сугыш чукмары.

Барыбер, җир шарының, күр,
Таҗлары ачыла бара.
Әнә, сугыш яклыларның
Йөзләре нинди кара...

Балкый, балкый ромашканың
Биш чатлы йолдызлары...
(Бәйрәмне бизәр чувашның
Егетләре-кызлары!)

Шулай берләштер яшьләрне,
Бөтендөнья бәйрәме! —
Чәчәк кебек гүзәл җирем,
Бары шатлык гамьнәре

Бал корты кебек сарсыннар
Таҗларның яфрагын, —
Биш кыйтганы — биш йолдызны
Берләштергән җир шарым!

### Чувашстаныма

Булды еллар — хәтерләү дә авыр! —
Син хокуксыз һәм хәерче идең...
«Исән калдың — мәңге яшәрсең», — дип,
Горурланып әйтәм, туган җирем.

Хәзер бездә гөрли башка тормыш, —
Елмаюдан балкый инде күңелең,
Чувашстан, туган ягым минем,
Чуваш халкы, горур халкым минем.

Тормышыбыз — соңгы очыш түгел:
Бу дөньяда дуслар күп булганда,
Яшәгәндә тату гаиләдә,
Ватан киңлегендә — кем югала?!

Чувашстан, таң чыгыдай якты
Матурлыкка кушыла гади җырым.
Туган җирем, улларыңа ышан:
Сине данлап яши һәрбер улың.

Синең яктың барда күңелләрдә
Омтылмабыз җырда без ят якка...
Миннән башка да гел яшәрсең син,
Яши аламмы мин синнән башка?!

## Рәисә Сәрби,

чуваш шагыйрәсе.

### Нарат

Кигән яшел гимнастерка,
Кыңгыр төшкән пилоткасы:
Мәгъруур басып тора нарат,
Әйтерсең лә чик сакчысы.

Кошлар сайрый, ниндидер өн
Килә июль кырларыннан.
Уяу монда бар табигать,—
Нәкъ ил чигендәге сыман.

Ә мин ятам засадада —
Тын бакчада, кырда түгел.
Постта торган абыемны
Һаман сагына минем күңел.

Ул да шулай пилоткадан,
Яшел гимнастерка киеп,
Сакта тора ил чигендә,
Сакта тора — нарат кебек.

Ул еракта, бик еракта...
Карыйм мин яшел наратка —
Икәү илне саклыйбыз күк,
Ул да — сакта, мин дә — сакта.

●

Чегән кызы күк үзе,
Кара тут көләч йөзе.

Чәчләре куе, бөдрә,
Тарагы ничек керә?..

Алтындай улы исә
Ак тәнле булып үсә.—

Тумыштан шундый булган,
Бодай башагы сыман.

Көләләр:
—Кемгә тарткан?
...Көнбагыш чәчәк аткан!

Кемнеке диим аны?—
Ул бит кояш туганы!..

ХӘЙДӘР тәрҗемәләре.

**Хведер Уяр**

# КОТЛАУ ХАТЫ

хикәя



Каравылчы өендә ике карт һәм бер карчык: тегерманче Эрхип, колхоз умартачысы Лаврась һәм Кулинә апа. Чал сакаллы Эрхип җитмеш биш яшьләрендә, Лаврась та шул тирәдә. Кулинә апа иллене узып килә. Җыйнак, пөхтә һәм килешле итеп киенгәнгәме, ул яшь күренә. Тегермәндә үз чиратын көтүче Кулинә черем итү нияте белән мич янындагы сәкегә урнашкан. Әмма ничек кенә дә йокыга китә алмый, бер яктан икенче якка әйләнә. Җитмәсә кырыс Лаврась аның кәефен бозды.

Каравылчы өендә эссе. Мич бертуктаусыз яна. Җылыдан әлсерәгән картлар тышта җил сызгыруын тыңлыйлар. Кайчандыр икона бизәгән түр башында радио эленеп тора, аның тәлинкәсеннән ниндидер салмак көй агыла. Умартачы карт Лаврась музыка көенә бармаклары белән утын пүләненә чиртеп ала. Эрхип бабай, тәрәзәгә каршы ян сәкегә утырып, тын гына челем пыскыта.

Кулындагы утын пүләнен мичкә ташлагач, Эрхипка карап, Лаврась болай дип мыгырданды:

— Юк, кешене санга сукмау бу...

Эрхип карт, җавапсыз гына, үз урынында утыра бирә. Ә ачулы Лаврась үзенекен сукалый:

— Кешеләргә карата мәрхәмәтсезлек күрсәтү бу, Эрхип. Я, әйт син миңа, кайчан килгән идем тегерманга?

— Төштән соң,— диде Эрхип, тыныч кына.

— Дөрес!— диде Лаврась, аның сүзен раслап.— Әйе, төштән соң килгән идем. Ә егерме кадак арыш тарттыра алмыйм... Бүген башкарасы эшләрне калдырып килдем бит мин. Хатын югалткандыр инде. Түшәмгә төкереп ятар чак түгел хәзер, Эрхип. Сугыш бара...

— Ә мин нәрсә эшли алам? Җил гаепле! Әнә бит ничек котырына. Тегермән канатларын кайсы якка борырга да белмим... Җил — кыйблаcыз, юнәлешен үзгәртә дә тора.

Эрхип картның сүзләре дөрес икәнлеген Лаврась үзе дә аңлый, ләкин санаулы вакыт бушка узганга ачуы килә, шуңа, хискә бирелмәскә тырышып, үзенекен сукалавын дәвам итә:

— Юк, Эрхип, кешене санга сукмау бу. Мин тегерманга килгәндә якты көн иде, ә хәзер караңгы төн. Мәйтәм, эшне тиз генә башкарырмын да өйгә кайтып китәрмен. Барып чыкмады, корт чаккыры!.. Адәм хурлыгы бит, эшсез өч аршынлы өндә утырам. Ике аю да бер өнгә сыймый, ә без өчәү. Үз өемә кайткач, хатынга Кулинәкәйдән аерыласым килмәде дип әйтерменме?..

Эрхип сүзсез генә челемен суыра.

Тегермәнченең тынычлыгы умартачыны чыгырыннан чыгара, аның Эрхип картка каты итеп әйтәсе килә.

— Хикмәт шунда: тәртип юк тегермәндә. Син җаен минем хуҗалыкта — умарталыкта булып кара. Анда һәр бал корты эшли — хәрәкәттә. Берсе генә дә тик йөрми.

— Биредә бал кортларының нинди катнашы бар?— диде Эрхип, сабырлыгын югалтмаска тырышып.

Умартачы Лаврась, бал кортлары турында сөйләргә кирәкмәгәнлеген аңласа да, сүз көрәштерүен дәвам иттерде:

— Беләсеңме, минем бал кортлары синең белән нәрсә эшләрләр иде?.. Качып та котыла алмассың, ачуларын китерсәң.

Гадел булмаган сүзләр Эрхипка җитә кала һәм ул, авызыннан челемен алып, болай ди:

— Юкны сөйләмә, һава начар икән, бал кортлары да бернәрсә эшли алмыйлар. Барысы да һавадан килә.

— Һава, имеш!.. Алар һәрвакыт хәрәкәттә. Ә хәрәкәттә бәрәкәт. Моны бал кортлары синең белән миннән яхшырак аңлыйлар.

— Аңлыйлар микән?

— Аңлыйлар... Алар хәтта кем исерек, кем аек икәнлекне дә беләләр. Менә син алар янында исерек килеш булып кара. Кая керергә тишек тапмассың!

— Лаврась дөресен сөйли,— дип, сәкедә ятучы Кулинә сүзгә кушыла.

— Эшсез кешеләрне алар бер дә яратмыйлар, бигрәк тә авызларына челем кабып йөрүчеләрне...

Умартачының үҗәтлеген белгәнгә, Эрхип сүзне икенчегә бора:

— Син менә мине колхозчылар җыелышында яманладың. Я, әйт, ни өчен?

— Дөрес түгел идемени?— ди Лаврась, утын пүләннәрен бер-бер артлы утлы мич эченә ташлап.— Җыелышта әйткәнемне мин хәзер дә раслыйм. Мәйтәм, эшлекле, уңган кешеләр фронтка киттеләр. Ә безнең ише картлар акыл сатарга яраталар, ә тегермәнгә электр уты кертә алмыйлар. Мәйтәм, күрше авыл тегермәнендә ут гөлт итеп яна, ә безнекендә Эрхип карт төн карчыгасыдай караңгыда утыра. Шуннан соң, үзең беләсең, сине, Эрхип, «буксир»га алдылар. Тегермәнгә ут та керттеләр. Юк, мин сине яманламадым, тәнкыйтьләдем генә, кыскасы, дөресен әйттем.

— Ә нәрсә ул «буксир?»— дип, Кулинә башын күтәрә.

Лаврась үзе Эрхипка карый, үзе аңлата:

— Артта калучыларны, койрыкта сөйрәлүчеләрне тарту — менә нәрсә ул «буксир»!

Үзенең уңайсыз хәлгә калуын сизгән Эрхип, тәрәзә янына килеп, төнге буранга күз төшерә.

— Әйе, җил — кеше түгел, аңа боерып булмый,— ди тегермәнче үзалдына сөйләнеп.— Синең егерме кадак арышыңны тарттыру пустәк ул. Ләкин бит миннән тормый, күзләрең күрә, колакларың ишетә, җил һаман котырына.

Кышкы буран, карт сүзен раслагандай, көчәйгәннән-көчәя бара, каравылчы өе, диңгез уртасында калган көймәдәй, җил-давылда селкенә.

Умартачы Лаврась, үз гаебен аңлап, кинәт тынып кала, мич янында авызына су капкандай утыра.

Радиодан сагышлы моң ишетелә. Умартачы Лаврась мондый көйне тыңларга күнекмәгән, шуңа ул яңадан үзенекен башлый:

— Аңла син, Эрхип, мин тынгысыз кеше. Үзең беләсең, хуҗалыгым, умарталарым бар... Ә син музыка тыңлатасың...

Шул вакыт радио кинәт тынып кала, музыка өзелә. Репродукторда башта нидер чытырдый, ә аннары дикторның көчле тавышы яңгырый:

«...СССР Верховный Советы Президиумы Указы... Киевтан көньяктарак Днепр елгасын кичкәндә батырлык һәм кыюлык күрсәткәне өчен лейтенант Иван Максимилианович Сироткинга Советлар Союзы Герое исемен бирергә...»

Тынлык урнашты. Эрхип картның челеме кулыннан идәнгә төште. Кулинә яткан урыныннан сикереп торды.

— И хода,— диде ул, нишләргә белмичә.— Безнең Ваня-Ванюша ич бу!.. Эрхип бабай, Лаврась, ишеттегезме?

Эрхип карт, идәннән челемен бөгелеп алды да, сабыр гына әйтте:

— Әйе, указ безнең авылдаш Иван турында. Әтисе Максимилиан: «Улым армиядә лейтенант булып хезмәт итә»,— дигән иде шул. Дөрес әйткән икән.

Умартачы Лаврась сөйләргә ашыкмады. Мич яныннан өстәл артына килеп утырды, аннары бер Эрхипка, бер Кулинэга карап алды.

— Шулай итеп безнең Ваня Сироткин герой пулган икән!— диде Кулинэ кутәренке тавыш белән.

— Пулган,— диде Лаврась, кесәсеннән кәгазь кисәкләре чыгарып.— Фронтка киткәнче дә менә дигән итеп эшләде ул, үзенең нинди егет икәнлеген күрсәтте. Эшсез утырмады дип әйтүем...

Батыр турында һәммәсенең дә мактау сүзләре әйтәсе килде. Шуңа алар, бер-берсенең сүзен бүлә-бүлә, сөйли башладылар:

— Ваня-Ванюша яхшы егет. Ә бит гади чуваш авылыннан. Малай чакта да бик үткен иде шул. Әтисе дә шәп кеше. Әйе, чаптар атның колыны да менә дигән була. Советлар Союзы Герое! Нинди зур исем. Безнең Ваня Сироткинны бүгеннән бөтен ил белә...

Ниһаять, алар тынып калдылар. Уйга талган умартачы Лаврась болай диде:

— Ваня Сироткин Мәскәүгә «Алтын Йолдыз» алырга килгәч, «Син, Иван Максимилианович, кайсы авылдан, Морзаялдан түгелме?» — дип сорарлар микән?

— Безнең авыл белән бик мактана алмассың,— диде Эрхип карт, челемен көйрәтеп.

— Корт чаккыры!.. Нигә алай дисең? Бүгенгә мактанырлык эшләр күренмәсә, иртәгә күренер. Ходайга шөкер, һаман эшсез түгелләр. Бүген төн генә менә...

Радиодан ишетелгән хәбәр шатлыгы Эрхипның йөзенә чыккан иде.

— Иван Сироткинны котлап телеграмма сугарга кирәк... Кәгазь алып киләм, хәзер...

— Телеграммада әйтеп бетереп булмый, котлау хаты язарга кирәк,— диде Лаврась.— Әйдәгез, утырыгыз, хатны бергәләп язабыз...

Кулына карандаш тоткан Лаврась хат язарга кереште: беренче җөмләсе аның котлау сүзе булды. Батыр егетне ул үз исеменнән, Эрхип белән Кулинэ һәм Морзаялда яшәүче барлык колхозчылар исеменнән тәбрикләде. Аннары, сүзләрне кабатлый-кабатлый, авыл яңалыкларын тәфсилләргә кереште: «...Теге син белгән Петрша доктор булды. Хилип уллары өчесе дә, үзләре теләп, фронтка китте... Роман хатынының сыеры икене бозаулады... Колхоз ярдәмендә авылда яңа мәктәп салынды. Электр станциясен берничек тә игә китерә алмыйбыз. Колхозда атлар саны кимеде...»

Сүз артыннан сүз чыкты, хатка яңалыклар өстәлә торды.

— Безнең гаилә турында да язарга кирәк иде,— диде Кулинэ.— Урын бармы?

— Урын җитәрлек,— диде Лаврась, карандаш очын иреннәре белән ялап.— Болай дип язам. «Касьян белән Кулинэ гаиләсендә яңалык, ул бер кешегә кимеде. Элек МТСта эшләгән Аннушка, ниндидер очучы белән танышканнан соң, аның аэропланына утырып, фронтка очты...»

— Шулай, шулай,— диде Кулинэ, язганны раслап.— Хәзерге көндә Аннушка сугышта шәфкать туташы, яралы сугышчыларны үләмнән коткара.

Каш җыерып хат язучы Лаврась та өстәде: «Аннушканың таныш булмаган очучыга ияреп китүен хуплап бетермибез. Үзебезнең авылда егетләр беткәнмени? Хәер, алар фронтта, әмма көтәргә генә кирәк. Мәсәлән, Филипп Григорьевны кызларга ни дип көтмәскә? Ул сугышта

ун фашистны дөмектергән, ике медале бар. Мактап фронт газетасында язганнар. Тегерманче улы Васлейны алыйк. Инвалид булуына карамастан, бер ел эчендә алты йөз эш көне эшләде. Ударник булып Мәскәүгә дә барды. Калининның үзе белән сөйләшкән...»

— Әйе, сөйләшкән,— дип раслады Эрхип карт.

Лаврась җитдиләнә төште: «...Аннушканың таныш булмаган очучыга иярә китүен яхшы дип тапмыйбыз. Безнең авылдан чыккан очучылар да бар, менә дигән егетләр. Мәсәлән, Танилның ике улы да аэропланда оча. Тагын Микулай да, Якку да очучылар икән...»

— Үз авылыбызның егетләре мактап бетермәслек,— диде Эрхип.

— Аннушкага китмә дип әйттем, тыңламады,— диде Кулинә.

Мич сүнгән иде инде, ләкин моңа игътибар итмәделәр, хатны язуларын белделәр: «...Колхоздагы эшләр турында берничә сүз. Февраль аенда колхозчылар җыелышы булды. Кызыл Армиягә бүләкләр тапшыру турында авылдашлар кумәкләшеп сөйләштеләр. «Армия һәмтыл — бер йодрык, фронтка ярдәм итәргә кирәк»,— дигән колхоз председателе Кондрат Ефимыч. Бу хакта миңа җыелышта катнашучы хатыным кайтып сөйләде. Ә мин үзем, кызганычка каршы, анда катнаша алмадым. Мич башында авырып яттым. Авыл фельдшеры суык тигән, грипп, диде. Өйгә килеп бүләк сорамадылар, мине бөтенләйгә онытканнар. Җыелыш узганның икенче көнендә үк, мич башыннан төштем дә, колхоз идарәсенә киттем. «Авыру кеше нишләп йөри?»— дигән була Кондрат Ефимыч. Менә минем Кызыл Армиягә дигән бүләкләрем, мәйтәм, үз кулларым белән тапшырам... Эрхип та бүләкләр биргән. Шәп карт ул, гел эшли. Кыскасы, тиктормас кеше!..»

Таң атып килә. Җил дә басыла төште. Ә бер карчык һәм ике карт һаман да котлау хаты белән мәшгульләр.

— Күпкә китте бугай?— диде Эрхип.

— Озынрак булды ахры?— диде хат язучы үзе дә.

— Сәлам хаты түгел, тастымал бит бу!— диде Кулинә.— Фронтовик Иван мондый хатны ничек укып бетерсен? Аңа мимецларга атарга кирәк. Озын да, мәгънәсез дә бу хат.

— Авыл хәбәре хатка сыймаса, нишләргә?— диде Лаврась.

— Алайса сүз белән түгел, сан белән яз. Конторада эшләүче акыллы башлар гел шулай язалар.

— Бик дөрес,— диде Кулинә.— Мин җыештыручы булып эшләгән канцелярда ай саен райүзәккә төрле мәгълүматлар бирәләр. Һәр сүз, һәр сан үз урынында, бер генә артыгы да юк.

Буран тынып калгач, Эрхип, Кулинәны ияртеп, тегермәнгә кереп китте. Лаврась, сөйләнә-сөйләнә, хат күчерә калды: «...Антон Арлановның 1942 елда 420, ә 1943 елда 489 хезмәт көне бар. Бу бер (1). Икенчедән (2), аның ике (2) улы да фронтта. Кызы фермада эшли... Өченче хәбәр (3): көтүче Саврасьның 1942 елда 427, 1943 елда 503 хезмәт көне бар. Ә карчыгы фермада сыер сава...»

Ишектә тегерманче Эрхип күренде.

— Я, ничек?— диде ул.— Күчерергә күп калдымы?

— Бетерермен шикелле. Син әйткәнчә, кирәклеләрен генә күчерәм. Ни, Эрхип тус, Иван Сироткинның адресын төгәл пелмибез бит әле? Конвертка ничек дип язарга инде? «Хәрәкәттәге Армия, Советлар Союзы Герое И. М. Сироткинга» дисәм, хат барып җитәр микән?

— Җитмини! Безнең Иванны хәзер бөтен фронт белә...

Эрхип тәрәзәгә күз төшерде:

— Лаврась, синең карчык килә түгелме?

— Улдыр, кем булсын, миннән дә тынгысызрак. Дөньяда өйдәге эшләрдән дә әһәмиятлерәкләре барлыгын аңлап бетерми ул. Итәгенә тагылып йөргәнне ярата. Барып чыкмас, корт чаккыры!..

**Владимир Садай**

# ТОМАН ИСЕ

ХИКӘЯ



Менә чирек гасырга якын инде Алексей Петрович җәмәгате белән ерак Себердә гомер кичерә, ә туган җире, туган Атыл-Иделе — гел күз алдында. Кичә генә чыгып киткән кебек ул туган авылыннан.

Себер якларына килгәч, Алексей Петрович үзе урман хуҗалыгында эшләде, ә хатыны мәктәптә балалар укытты. Үзләренең балалары юк иде аларның. Баштарак Алексей Петрович моны авыр кичерсә дә, аннары күнекте, ходай биргән язмыш белән ризалашты. Җәмәгате Мая Федоровна балалар йортыннан берәр ятим калган сабыйны тәрбиягә алу турында сүз кузгатканда, Алексей Петрович гел баш тарта килде. Аннары, көннәрдән беркөнне, һич көтмәгәндә үзе: «Әйдә, хатын, синеңчә булсын!»— диде. Һәм алар ике яшьлек Сергейны үзләренеке иттеләр. Каратут йөзле, түгәрәкләнеп торган ияге, зәңгәр чәчәкне хәтерләткән күзләре белән малай Мая Федоровнага охшаган иде. Ә кайберәүләр аны Алексей Петровичка охшаттылар, үз улы дип уйладылар. Әйе, Алексей Петрович белән аның тәрбиягә алган улында, төсләрендә генә түгел, холыкларында, хәтта йөрешләрендә дә ниндидер охшашлык бар иде. Шуңа күрә Сергейны аның улы түгел дип берәү дә кырт кисеп әйтә алмас иде. Өч кашыктан торган гаилә бик тә тату яшәде, барысы да үзен бәхетле хис итте. Һәм менә көтмәгәндә бәла килде: Мая Федоровна аяктан егылды. Каһәр суккан грипптыр, бернichә тәүлек урында ятар да терелер диделәр, ләкин алай булып чыкмады, чир чигенмәде, әҗәл килде: Мая Федоровна вафат булды. Сергей бик өзгәләнсә дә, егет буларак, сынатмаска тырышты. Ә менә Алексей Петрович хатынын җирләгәннән соң тәмам кызганыч хәлдә калды, тормышның ямен-тәмен югалтты, күңеле сүнде. Эштә ул әле үзен бераз җиңелрәк хис итсә дә, өйгә кайтты исә сагыш-уйга батты.

Чыдар хәле калмагач, Алексей Петрович урамга чыгып китә, таныш шәһәр буйлап атлый иде. Әмма монда да һәр тыкрык, урам чаты Мая белән бәйле. Бу нәни шәһәрдә алар очрашмаган тыкрык, урам чаты юктыр. Алексей Петрович сөеклесен мәктәпкә озата килә, каршы ала иде. Ә кичләрен алар икәүләшеп клубка йөрделәр...

Хәсрәт-кайгысын, күңел сагышын бастыру нияте белән Алексей Петрович, үз хисабына ял алып, Идел буена урнашкан туган авылына кайтырга карар кылды. Туган як ниндидер күренмәс җеп белән аны үзенә тартты. «Сергейны да алып кайтырга кирәк, туган авыл, аның табигате, кешеләре белән танышыр»,— дип уйлады Алексей Петрович.

Таулар исемле авыл Иделнең уң як ярында урнашкан иде, аннан төрле якка гаҗәеп матур күренешләр ачыла. Бер якта бөдрә урман. Икенчесендә сөзәк яр, Иделгә челтерәп аккан нәни елга да шуннан башлана. Ә авыл артында гына бакчалар. «Бер кайда юк андый бакчалар»,— дип таулылар тикмәгә генә җырламыйлардыр.

Таулар авылы урнашкан урында Идел киң, агышы тыныч. Иртәнге тыныч суда йортлар, агачлар чагылып күренә. Әйтерсең урман өстендә үсә. Биредә һәммә нәрсә дә җанлы, серле...

Алексей Петрович район үзәгеннән авылга җәяү генә атларга булды: балачак хатирәләре белән бәйле иде кайтыр сукмаклар, яңгыравыклы чикерткә тавышлары.

— Менә бу җиләкле урында базардан кайтучы әтиләрне көтә идек,— диде Алексей Петрович Сергейга, урман аланына килеп җиткәч.— Алар кыңгыраулы атларда җырлый-җырлый кайталар... Ә без олауларга менеп утырабыз да клиндер кимерәбез...

Туган ягында озак еллар булмаган кешегә түмгәк тә җанлы булып күренә. Әнә, имәнлек шаулый, арыш басуы дулкынлана, тугай-болыннарда чуарланып чәчәкләр үсеп утыра. Ә еракка, әллә кайларга сузылган сукмак бормалы елганы хәтерләтә, яланаяклы балачакны күз алдына китерә. Сукмактагы балачак эзләре мәңге дә җуелмас шикелле!..

Алексей Петрович белән Сергей авылга якынлашканда кич җитеп килә иде инде. Басу капкасына килеп җиткәч, алар хәтфәдәй яшел үләнгә утырдылар. Күңелләре күтәренке, шат. Алексей Петровичның җырлыйсы да, елыйсы да килә. Чирәмлектә яланаяклы малай-шалайлар уйнап йөри. Алексей Петрович дикъкать белән озак күзәтте балалар уенын: «Бәхетле балачак!» Капка янында гына, койрыгын болгый-болгый, бер бозау йөри, ул да үзен бәхетле итеп сизәдер кебек.

Әнә, калкулыкта Алексей Петровичның туган йорты. Аның тәрәзәләре Иделгә, кояш чыккан якка карый. Хәер, Алексей Петровичның маякчы булып эшләүче әтисе анда кышкы көннәрен генә уздырды. Җәйләрен исә ул гаиләсе белән маякчы өчен салынган такта өйдә яшәде. Ерактан караганда сыерчык оясын хәтерләткән өйне, яз килеп җиткәч, яшел буяуга буяды. Аның тирәсендә төрле-төрле чәчәкләр утыртты. Ярата иде әтисе хуш исле чәчәкләрне...

Туган җир!.. Бу сүзләрне әйтү белән йөрәк әрни-сызлана, күңел сыкрана-өзелә. Өй морҗаларыннан чыккан төтенгә кадәр ширбәтле, шифалы тоела, учак ягып көлдә бәрәңге тәгәрәтәсе, чирәм өстенә ятып ауныйсы, саф һавасын сулаган саен сулыйсы килә...

Туган йортының капкасын ачып кергәч, Алексей Петровичның борынына печән исе килеп бәрелде. Берәүләр өчен печән, бәлки, киптерелгән үлән генәдер?.. Ә менә Алексей Петрович өчен печән — җәйге чиллә, юмарт кояш, яшел кузгалаклар, ромашкалар. Алай гынамы соң?! Печәнлектән балачак исе килде. Җәйләрен печән өстендә йокларга Алексей Петровичның бабасы да, әтисе дә бик ярата иде. Анда йоклауны төнлә соңгарып, аулак урыннардан кайтучы Алексей да хуш күрде. Инде менә, Алексей Петрович белән янәшәдә генә, печән өстендә улы Сергей ята. Әлегә улы аулак урыннарга йөрми, килер вакыт — ул да таң әтәчләре белән дуслашыр, үзе дә белми калыр, яшьлекнең үз кануны... Әнә, кунакчада әтәч кычкырды. Аның яңгыравыклы тавышына аръяк урамнардагы әтәчләр кушылды.

— Йокы качты,— диде Сергей әтисенә.— Коенып кайтыйм әле...

Түше белән шуышып, Сергей печән өстеннән аска тәгәрәде. «Яшьлек — үзенекен итә, китте!»— диде Алексей Петрович һәм уйлана-уйлана кабат татлы йокыга талды. Ул уянганда кояш күтәрелеп килә иде инде. Печәнлеккә күз төшерде: «Сергей ич, кайчан кайткан, белми дә калганмын?..» Улын тәмле йокыдан уятасы килмәгән Алексей Петрович, саклык белән генә печәнлектән төште дә, сиртмәле коедан су алып юынды. Аннары ян капкадан бакчага керде. Әтисе исән чакта алма агачы дүртәү генә иде, ә хәзер аларның саны унга җиткән. Койма янында гына ике миләш һәм берничә каен ябалдашлары югарыга күтәрелгән. Ә менә тагын бер таныш сукмак, ул да елгага төшә. Алексей Петрович шул тар сукмактан елгага килеп чыкты да, Иделгә озак карап торды. Тамак төбенә ачы төер утыргандай тоела, сагыш-моң баса. Тирә-якта нәрсәдер җитми, үз урынында түгел кебек. Маякчы өе юк икән, теге зәңгәргә буялган, җәй көннәрендә әтисе белән бергә яшәгән такта өй. Тәмәке кабызып,

Алексей Петрович әлеге сукмактан өй нигезе янына килде: аны үлем баскан, анда-санда кирпеч ватыклары аунап ята. Алексей Петрович, тезләнеп, кулындагы таяк белән актарынырга кереште, иске көл арасыннан ул черегән бау һәм яньчелеп беткән бакыр кашык тапты: «Әтием кашыгымы әллә?.. Юк, аныкы түгел, маякчы карт агач кашык белән ашарга ярата иде». Ком белән чистартканнан соң, бакыр кашыкны кулына тотып, озак уйланып торды. Иделдә, якында гына моторлы көймә узганын ишетте, аның артыннан бер-бер артлы дулкыннар ярга бәрелде. Бер мизгелгә бөтен җиһан, Идел-йорт чайкалып, селкенеп, аваз биргәндәй булды. Шул аһәңгә су өстендәге акчарлаклар тавышы кушылды... Алексей Петрович, кулындагы кашыкны Иделгә ташлап, ташка утырды. Алексей Петровичка чал таш таныш иде. Элек ул күркәмрәк күренсә, хәзер агарып, шадраланып, мүкләнеп беткән. Чатнаган урыннары да бар, бер ягы бөтенләйгә ярылган. Су өстендә үтә күренмәле сыек томан тарала. Идел өсте, аның аръягындагы урман, бөтен тирә-як акка төренгән. Алексей Петрович уйга калды: аның бөтен яшьлеге, күңелендә мәңге сеңеп калган онытылмаслык хатирәләр Атыл-Идел һәм шушы урыннар белән бәйләнгән. Алексей аяк басмаган урын юктыр биредә, сөеклесе Мая белән дә Идел буенда танышты ул, аңа беренче мәхәббәт сүзләрен әйтте. Хатирәләр, хатирәләр... Алар Алексей Петровичны яшьлеккә алып кайталар, йөрәген көчлерәк тибәргә мәҗбүр итәләр, күзләренә шатлыклы яшьләр китерәләр, сагыш уяталар. Ул хатирәләр күңелдәге яраларны кузгаталар. Гомер уза, яшьлек хыял гына булып кала. Ә хыял — һич кенә дә чынлык түгел! Шул үзәкне өзә, күңелне телгәли. Яшьлекнең бер генә мизгеле дә яңадан кабатланмаячак, шул бетерә-үтерә!.. Әнә, карт тал. Ул, күптәнге танышының кайтуына сөенгәндәй, шаулап куя. Аның ботакларына кунган кошлар да, Алексей Петровичка сәлам биргәндәй, чыр-чыр киләләр. Карт тал белән янәшәдә генә яшь өянкеләр үсә. «Әйе, шулай булырга тиеш тә,— ди Алексей Петрович.— Картлыкка алмашка яшьлек килә. Кешелек белән табигатьнең законы-кануны шундый».

Якында гына, карт тал артында, күңелле бер тавыш ишетелде. Алексей Петрович сукмакка күз салды: анда улы Сергей белән Кирилл кызы Маринка килә иде. Кыз алданрак бара, ә Сергей аның артыннан атлый. «Мая белән мин, икәүләшеп, Иделгә коенырга шушы сукмактан төшә идек,— диде Алексей Петрович.— Мая боландай җитез иде. Әлеге кыз да йөреше белән Маяның яшь чагын хәтерләтә». Яшьләргә комачауламыйм дип, Алексей Петрович өянкеләр арасына кереп, аларны күзәтә башлады: Сергейның яр кырыена килеп җитүе булды, тиз-тиз генә чишенде дә, суга сикерде.

— Маринка, нәрсә уйланасың, кер әйдә суга,— диде Сергей.— Су түгел, яңа сауган сөт!.. Томан исе килә...

— Оялам мин, Сережа.

— Кемнән?

— Кемнән булсын, синнән...

Дулкынланудан Алексей Петровичның йөрәге сикерә башлады: сөеклесе Мая авазын ишеткәндәй булды, Иделдә коенганда ул да шулай: «Оялам мин»,— дигән иде. Шуннан соң күпме сулар акты!.. Әле дә хәтерендә, җәйге көн ул чакта нәкъ бүгенгедәй иде, судан томан, өянкеләр исе килде. Улы Сергей дөрес әйтте...

Су коенып чыккач, Сергей белән Маринка өянкеләр арасына кереп яшеренмәгәйләре, комачауларммын дип, Алексей Петрович сукмак буйлап ашыкмый гына авылга таба атлады.

Чувашчадан Кави **ЛАТЫЙПОВ** тәрҗемәләре.

## Туфан Миңнуллин

# ӘНИЛӘР ҺӘМ БӘБИЛӘР

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМАТИК ХИКӘЯ

*Ана —*
*Бөек исем.*
*Нәрсә җитә ана булуга...*

Һади Такташ

**Катнашалар:**

**Гөлфинә** — 45 яшьтә.
**Валентина** — 30 яшьтә.
**Алтынчәч** — 32 яшьтә.
**Дилемма** — 20 яшендә.
**Баш врач** — өлкән яшьтәге ханым.
**Айзарә Әхәтовна** — палата врачы, 50 яшьләрендә.
**Нина** — сестра, 19 яшьтә.
**Исемсез хатын** — 30 тирәләрендә.
**Вазыйфа** — Дилемманың кайнанасы } Икесе дә 50 яшьләр тирәсендә.
**Римма** — Дилемманың әнисе

Вакыйга безнең заманда шәһәрдәге бала тудыру йортларының берсендә бара.

### Беренче пәрдә

Бала табу йорты палатасы. Коридорның да бер өлеше һәм врач кабинеты күренә. Якты дөньяга гөнаһсыз нарасыйлар килгән урын. Кеше туган җир. Сәхнәнең ике ягында ике бишек эленгән. Ак төс фонында алар төрле төсләргә буялган, бизәкле булулары белән игътибарны җәлеп итеп торалар. Ике бишек янында ике Ана утыра. Вакыйгада катнашучылардан аермалы буларак, аларның киемнәре бишекләр шикелле үк бизәкле, чәчәкле. Пәрдә ачылганда бишекләр янындагы ике Ана, бишек җырын җырлап, бишекләрне тирбәтәләр.

Әлли-бәлли, бәллием,
Йокла, балам, нәнием.
Тәмләп йокла, бәбием,
Сакта тора әниең.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

**Беренче Ана.** Йокла, улым, батырым,
**Икенче Ана.** Йокла, кызым, матурым.

Икәү бергә. Иокла, минем бергенәм,
Чәчәккенәм, гөлгенәм.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.
Йөрәгемнең парасы,
Ике күзем карасы,
Мәхәббәтем чаткысы,
Күңелемнең яктысы.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

**Җырны ике Ана сүзсез генә дәвам итәләр. Шул җыр белән бала тапкан аналар палатасы яктыра. Вакыт иртә. Аналар йокыдан уянып, юынып, ясанып балаларын имезергә китергәнне көтәләр. Алтынчәч белән Валентина караватларында утырып торалар. Дилемма ятkан. Гөлфинә аяк өстендә.**

Гөлфинә *(Дилемма караваты янына килеп).* Тор әйдә, кызым, тор. Синең яшьтә озак яту килешми. *(Дилемма борылып яткач.)* Бигрәк иркә семьяда үскәнсең, ахрысы, авыр булыр яшәве. *(Алтынчәч янына килә.)* Нихәл соң, Алтынчәч?

Алтынчәч. Яхшы.

Гөлфинә. Исемең бигрәк матур инде.

Алтынчәч. Үзем ямьсез, әйеме?

Гөлфинә. Ямьсез дип инде... Бер дә ул хәтле ямьсез түгел. Матурлык ул туйда гына кирәк. Үзеңә ишең табылган бит әле. Балагыз бар. Ямь шул була инде, Алтынчәч айналаем.

Алтынчәч. Безнеңчә каян беләсез?

Гөлфинә. Казахчамы? Белмим, Чимкентка кунакка барган идек тә шунда бер казах апасыннан ишеттем. Бигрәк матур сүз — айналаем. Матур сүзләрне яратам мин, Алтынчәч... Бер киңәш биримме, Алтынчәч? Син һәрвакыт елмаеп йөр, елмайганда син бик чибәрләнәсең. Ямьсез дип әйткәннәренә ышанма, бик ямьле, бик матур син, айналаем.

Алтынчәч *(елмаеп).* Рәхмәт.

Гөлфинә *(караватында мышык-мышык елап утыручы Валентина янына килә).* Ни булды, Валентина, нигә җылыйсың?

Валентина. Куркам.

Гөлфинә. Нидән?

Валентина. Әгәр дә минем сөтем җитмәсә? Ул ачтан үлсә? Юк, ул үлсә, мин дә яшәмәячәкмен. Ул минем соңгы өметем.

Гөлфинә *(көлеп).* Тукта, тиле. Тапкансың җылар нәрсә. Җиңел котылганыңа сөенеп кенә йөрергә кирәк сиңа. Җылап бала үстереп булмый ул, җаным. Көлеп йөр, балаң да синнән көлергә өйрәнсен.

Валентина. Карагыз әле минем күкрәкләргә. Бик бәләкәйләр бит. Ничек аның сөте җитсен.

Гөлфинә. Алай димә, Валентина. Тфү, тфү, күз тимәсен, болардан әле колын имезергә була. Беренчемне тапканда бөтенләй юк иде әле минем. Эзләре генә бар иде. Әле дә хәтеремдә, өйләнешеп беренче йоклаган төнне Зарифулла, минем ирем инде, кагылмакчы була, кулы шуа да китә тегенең, шуа да китә. Менә шул күкрәкне, Валентина җаным, унбер бала имеп үстеләр. Уникенчесе монда көтеп тора. Улларым Газинур Гафиятуллин кебек, кызларым Галиябанудан ким түгел СССР илләрендә. Әле район больницасында табып шундыйлар. Казан больницасында тапсам, нинди булмаслар иде. Менә шуңарга күрә, уникенчесе тагын да шәбрәк булсын дип, Казан роддомына килдем. Зарифулла әйтә, алмыйлар сине, син анда учетта түгел, ди. Ашыкма, мин әйтәм. Табар чагым җиткәнне чамаладым да сеңелләремә килдем. Тулгак тота башлагач, скорый помощька шылтыраттылар да... алмый нишләсеннәр. Туам дигән баланы туктатып булмый ич...

Дилемма. Туктап торыгыз әле әзрәк кенә.

Гөлфинә. Ни диде, сеңлем?

Дилемма. Бик күп сөйлисез!

Гөлфинә *(Дилемма янына килеп).* Балтун инде мин шулай, тел бистәсе. Зарифулла да шуның өчен әрли үземне. Нишлисең, синең сыман бер беребезгә сырт куеп ятсак та, күңелле булмас иде. *(Алтынчәчкә.)* Шулай бит, айналаем?

Алтынчәч. Шулай.

Гөлфинә *(Алтынчәч янына килеп).* Син үзең Казанда торасыңмы соң, Алтынчәч?

Алтынчәч. Юк, Ульбада.

Гөлфинә. Ульба? Кайда соң ул?

Алтынчәч. Казахстанда.

Гөлфинә. И-и-и! Монда ничек килеп эләктең?

Алтынчәч. Шулай туры килде инде. Мәскәүгә бара идем, апаларга.

Гөлфинә. Ирең беләме соң монда тапканыңны?

Алтынчәч. Юк.

Гөлфинә. Хәбәр иттер, ятмасын дөньясын онытып. Туганнарың бармы соң Казанда?

Алтынчәч. Юк.

Гөлфинә. Пәрәмәч! Ничәнче балаң?

Алтынчәч. Беренче.

Гөлфинә. Ничә яшь соң үзеңә?

Алтынчәч. Утыз ике.

Гөлфинә. Кияүгә соң чыктыңмыни?

Алтынчәч. Әйе, соң. Ямьсез бит мин — алучы булмады.

Гөлфинә. Алай димә. Әйтмә алай дип. Бала тапкан хатын ямьсез булмый. Юкны сөйләмә икенче тапкыр, Алтынчәч, риза-бәхил түгел.

Алтынчәч. Кызым да ямьсез булыр микән? Малай булуын теләгән идем.

Гөлфинә. Хәзер малайның, кызның аермасы юк. Хәзер барысы да үз бәхетләре белән туалар. Әнә, минекеләр тупырдап торалар. Уникe булдылар бит, малай җаным, уникe. Бик күп инде, әйеме?

Валентина. Күп түгел, Гуля апа. Мин егермене табар идем.

Гөлфинә. Егермегә хатын-кызның чыдамы җитсә дә, гомере җитмидер ул.

Валентина. Без җиде ел көттек. Ой, белсәгез... Саша, мин, Сашаның әтиләре, минекеләр — барыбыз да көттек. Бармаган больница, күренмәгән доктор калмады. Җиде ел! Саша белән икәүләп сүзләрнең ниндиләрен генә ишетмәдек. Ой-ой!... Буйга узгач ничек сакладык без аны, Гуля апа!..

Гөлфинә. Шуңа күрә зур булып туган да инде ул.

Валентина. Өч кило да алты йөз илле грамм.

Гөлфинә. Артык зур булып туганны врачлар яратып бетерми шул.

Валентина. Яшәр микән? Ой, куркам... Белсәгез курыкканымны. Яшәр микән, Гуля апа?

Гөлфинә. Мондагылар җыелып туена барабыз әле малаеңның, чакырсаң.

Валентина. Чакырам, Гуля апа, барыгызны да чакырам. Шундый туй булыр!.. Ой, кызлар!.. Кызлар! Белмисез шатлыгымны, белмисез куанганымны! Аны бары тик җиде ел бала көткән хатын-кыз гына аңлый. Балам бар бит минем, улым бар! Исеме Саша булачак. Әтисе дә Саша, улым да Саша! Александр Александрович. Ой, ничек яратам мин аның әтисен, кызлар! Сез күз алдына да китерә алмыйсыз, ничек мин аны яратам.

Гөлфинә. Безнең дә иребез бар. Яратмасак, шул ирдән уникe бала тапмас идек.

**Ишек төбенә Исемсез хатын килеп, сөйләшкәнне посыбрак тыңлап тора.**

Валентина. Сез бәхетле, Гуля апа. Уникe балагыз бар.

Гөлфинә. Нәселебез шундый инде. Мин үзем Зарифулланың җиле тиеп китсә дә балага узам. Тик минә сеңелебез генә, Казанга китте дә ире белән икәүләп бер баланың күзенә карап торалар.

Валентина. Юк, юк! Мин!.. Минә күрерсез!..

Гөлфинә. Була, була... Бер юлы ачылгач, була инде ул, Валентина. Бигрәк матур исем инде Валентина. Марҗа булган булсам, мин үземә Валентина куштырган булыр идем. Син, Валентина, миңа Гуля димә инде, ярыймы. Үз исемем белән әйт, ярыймы.

Валентина. Әйтүе читен бит.

Гөлфинә. Бер дә кыен түгел. Гөл-финә. Гөл, гөл, гөл... цветок, цветок... Беләсеңме цветокны? Менә шул инде. Финәсен үзем дә белмим. Гөлфинә.

Валентина. Гульфина. Гульфина апа.

Гөлфинә. Менә. Менә бит, менә. Оныт-ма гына инде хәзер. Гөлфинә нәрсә ул, менә авыр исемнәр була ул. Әйткәндә телең сынарлык. Сугыш вакытында безнең авылга эвакуирынныйлар килгән иде. Безгә дә бер семья урнашкан. Мин аларны бик аз гына хәтерлим. Әни сөйли: бик тиз бер-беребезгә ияләштек, ди. Сөйләшергә дә өйрәндем, ди. Тик менә бабайларның гына исемен әйтә алмый изаландым, ди. Үзебезчә Самат бабай дип әйткән идем дә, пажалысты үз исемем белән әйтегез инде, дип әйтә ди бабай. Язып алып ике ай ятладым, ди, әни әйтә, көчкә өйрәндем, ди. Миңа әйткән иде, мин дә әйтә алмадым. Әкрен генә иҗекләп кенә әйтеп була, бергә җыеп тиз генә әйтеп булмый. Яле, син әйтә алырсың микән, Валентина? Са-му-ил Со-ло-мо-но-вич.

Валентина. Самуил Соломонович.

Гөлфинә. Синең телең килешеп тора шул андый исемнәргә. Һәр халыкның үз теле шул. Шуңа күрә әйбәт тә. Бетенесе дә матур Валентина, милый мой дорогой. Кара нинди матур сүзләр. Валентина җаным, дисәң дә рәхәт бит.

Дилемма. Ой! Перестаньте, ради бога.

Гөлфинә. Дәшмим, дәшмим, сеңелем, ачуланма, зинһар... Ә синең исемең ничек, сеңелем?.. *(Дилемма эндәшмәгәч.)* Казан роддомының шул инде аның, районда булса... Өченче баламны тапканда Малаевка авылының бер хатыны белән бер караватта яттык. Рәхәтләндек кенә сөйләшеп. *(Ишек төбендәге Исемсез хатынны күреп, янына килә.)* Карап-карап торам да, ни кермисез, ни китмисез. Я, кереп утырыгыз, я...

Хатын. Миңа анда керергә ярамый.

Гөлфинә. Нишләп ярамасын ди! Монда барыбыз да бертигез.

Хатын. Мин бүтән отделениедан.

Гөлфинә. Булсагыз ни. Бездә йогышлы авырулар ятмый. Сезнең палатагыз кайда соң?

Хатын. Аста.

Гөлфинә. Анда ниндиләр ята?

Хатын. Минем кебекләр.

Гөлфинә. Сез нинди соң?

Хатын. Баласыз хатын.

Гөлфинә. Балагыз булмыймыни? Әйтәм аны... Ә сез бер дә кайгырмагыз. Балалардан кем рәхәт күргән. Интегеп, азапланып үстерәсең, үстерәсең дә... Әнә безнең күрше Хәдичә апа малайлары, кайсы кая таралышып бетте, адреслары да билгесез.

Коридордан Айзарә Әхәтовна килә.

Айзарә *(исемсез хатынга)*. Сез тагын биредә? Соңгы тапкыр кисәтәм, әгәр тагын бу отделениега керсәгез..

Хатын. Китәм, китәм... *(Югала.)*

Айзарә *(Гөлфинәгә)*. Ә сез монда нишләп торасыз? Керегез палатагызга.

Гөлфинә. Балам булмый, ди.

Айзарә. Булмаса, сез табып бирмәкче буласызмы?

Гөлфинә. Юатырга кирәк бит кешене.

Айзарә. Юатырга... Ятыгыз урыныгызга. *(Палатага керә).*

Гөлфинә *(аңа иярә)*. Сез врач кеше, алай дип әйтү сезгә килешми.

Айзарә. Аларга монда кереп йөрергә рөхсәт ителми, аңлыйсызмы? Сезгә дә теләсә кайда йөрергә ярамый.

Гөлфинә. Харап икән. Тегеләй ярамый, болай ярамый. Кешенең авыр хәсрәте бар. Җаны үрсәләнәдер, аңа сөйләшеп җиңеләергә кирәк.

Айзарә. Биредән чыккач иркенләп сөйләшерсез.

Гөлфинә. Аны кайчан күрәм мин.

Айзарә. Я, я, булды, тынычланыгыз. Ул хатынга сез дә, без дә ярдәм итә алмыйбыз. Моннан ун ел элек баласын төшерткән ул. Беренче баласын. Шуннан бүтән балага узмаган. Ул вакытта врачларны тыңламаган. Хәзер йөри. Без нишли алабыз, я? Бирегез әле кулыгызны. *(Гөлфинәнең пульсын тыңлаганнан соң.)* Яхшы. Тик шулай да бик күп йөрмәгез. *(Валентина янына килеп.)* Я, сезнең хәлләр ничек?

Гөлфинә. Курка ул.

Айзарә *(Валентинага)*. Нидән?

Валентина. Сөтем җитә микән?

Айзарә. Җитмәсә, әйтерләр. Борчылмагыз. Барысы да яхшы булыр. *(Дилемма янына килеп.)* Бүген тордыгызмы әле?

Дилемма. Юк.

Айзарә. Бераз йөрергә кирәк.

Дилемма. Йөрергә ярамый миңа.

Айзарә. Нигә?

Дилемма. Шулай. Сез врач — сез белергә тиеш. Олы корсаклы булып каласым килми.

Айзарә. Ай-яй, күп беләсез! *(Гөлфинәне күрсәтеп.)* Әнә бу апага карагыз, унике бала анасы — тал чыбыгы кебек зифа.

Гөлфинә. Безнең бит май җыеп ятарга вакыт юк.

Дилемма. Гомумән, әйтегез аларга. Миңа дәваланырга, ял итәргә кирәк, ә биредә базар.

Айзарә *(хатыннарга)*. Нигә шул чаклы тавышланасыз?

Валентина. Кем тавышлана? Безме? Без сөйләшәбез генә, Айзарә Әхәтовна.

Айзарә. Әкренрәк сөйләшергә кирәк.

Гөлфинә *(Валентинага әкрен генә)* Чебен тимәс чер итәрләр командасыннан икән теге.

Айзарә *(Алтынчәч янына килеп)*. Ә сез ничек?

Алтынчәч. Яхшы.

Айзарә. Молодец. Йөрергә ашыкмагыз, сезгә иртәрәк әле.

Алтынчәч. Әйтегез әле, кызлар әтиләренә охшыйлармы, әниләренәме?

Айзарә. Ә сез кемгә охшавын телер идегез?

Алтынчәч. Миңа түгел. Күреп торасыз. Ямьсез бит мин

Айзарә. Кем әйтте аны сезгә?

Алтынчәч. Минем яныма бер егет тә якын килмәде.

Айзарә. Димәк, җүләрләр.

Гөлфинә. Мин дә шулай дидем. Нәрсәгә сиңа егетләр, ирең булгач...

Айзарә *(Гөлфинәгә)*. Утырыгыз урыныгызга. Бөтен җиргә өлгерәсез, бөтенесен күрәсез, бөтенесен ишетәсез сез.

Гөлфинә. И күңелсез сезнең Казаныгызда, район больницасында рәхәтләнеп йөри идем.

Тышта ирләр тавышы ишетелә.

Валентина *(тәрәзә төбенә менеп баса да форточкадан кычкыра)*. Саша!.. Сашенька!.. Мин бу! Бу мин! Танымыйсыңмы мине?! Ә?!. Яхшы! Борчылма, Сашенька!

Айзарә *(Валентина янына килеп)*. Төшегез хәзер үк.

Валентина. Доктор... Айзарә Әхәтовна... Зинһар өчен, пожалуйста... Саша килгән бит, Сашенька... Бер генә сүз әйтәм... *(Форточкага башын тыгып.)* Саша-а!.. Син мине яратасыңмы, Са-ша-а?

Айзарә. Әйткәнне аңлыйсызмы, юкмы?

Валентина *(тәрәзә төбеннән төшә-төшә)*. Аңлыйм, доктор, аңлыйм. *(Айзарә Әхәтовнаны кочаклап.)* Ой, белсәгез иде, доктор, белсәгез иде!.. Безнең бакчабыз бар, Айзарә Әхәтовна, чәчәкләр күп. Мин сезгә чәчәкләр китерәм әле. Барыгызга да, барыгызга да...

Айзарә. Яхшы, яхшы... Китерерсез. Тик тынычланыгыз. Тынычрак булырга кирәк, бала ашатасыгыз бар.

Валентина. Булды, булды, доктор. Ни әйтсәгез дә тыңлыйм. *(Караватына барып утыра.)*

Айзарә. Менә нәрсә кадерле әниләр, форточка ирләр белән сөйләшү өчен уелмаган. Әгәр дә тагын шулай кылансагыз, кадаклап куячакбыз. Өйләрегезгә кайткач сөйләшерсез. Аңлашыламы?

Валентина. Аңлашыла, доктор, аңлашыла.

Гөлфинә. Өйгә кайткач ирләр белән сөйләшергә вакыт буламыни ул... Кешенең ирләре ир төсле. Безнеке йөридер чабып.

Айзарә. Я, ярый... Тик, зинһар, әкренрәк... *(Чыгып китә.)*

**Балаларның елаганы ишетелә. Арбага шул елакларны төяп сестра Нина керә.**

Нина. Ягез әле, апалар, алыгыз әле җылакларыгызны. Тик сабыр, сабыр... Кабаланмыйча гына. *(Балаларның аналарына өләшә. Валентинага.)* Баланы алай кысып тотмыйлар, күрсәттем бит мин сезгә.

Валентина. Я төшеп китәр.

Нина. Китми. Әнә апага карагыз. *(Алтынчәчкә.)* Башта ашатыгыз, нәрсә эзлисез аның битендә? Алар әлегә барысы да бер төсле.

Валентина. Түгел... Минеке...

Нина. Сөйләшмәгез. *(Дилеммага.)* Ә сез нигә ашатмыйсыз?

Дилемма. Ашатырмын, борчылмагыз.

Нина. Мине борчылыр өчен укыттылар. *(Арбаны алып чыгып китә.)*

**Бала имезгәндә генә була торган илаһи тынлык урнаша. Ул тынлыкны балаларның дәррәү елап алуы гына бозгалый. Ут бишек тибрәтүче ике Ананы гына яктырта. Алар үз җырларын дәвам итәләр.**

Беренче Ана. Сайрар кошлар тынып калган,

Исәр җилләр ялга талган:
Изге тынлык бу дөньяда —
Бала имезә Ана,
Бала имезә Ана.
Ага сулар тып-тын гына,
Тып-тын урман тыңлап тора:
Изге мизгел бу дөньяда —
Бала имезә Ана,
Бала имезә Ана.

Бергә. Атмый торсын атар туплар —
Дөрләмәсен хәтәр утлар:
Тынлык кирәк бу дөньяга —
Бала имезә Ана,
Бала имезә Ана.

**Җырның соңгы юлларында сестра Нина тамаклары туеп, тынып калган балаларны төяп чыгып китә. Палата эче, коридор яктыра.**

Гөлфинә. Бик үзсүзле булыр, ахры...

Валентина. Каян беләсез аны, Гульфина апа?

Гөлфинә. Белмәскә... Мин аларның кайсы нинди буласын карынымда ятканда ук беләм. Нурисламым селкенеп тә карамады, хәзер дә йокы ярата. Әлфиям гел тибенеп торды, хәзер дә өстендә юрганын тотмый, Фәритем кыбырсына да кыбырсына иде, һаман утырган урынында тик кенә утыра алмый — боргалана...

Алтынчәч. Ә минем кызым үземә охшамаган. Аның сеңлесенә охшаган. Ә ул чибәр. Аңарга сокланмаган егет юк.

Валентина. Минеке нәкъ минем каенанам. *(Тавыш ишетеп кинәт тәрәзәгә ташлана.)* Ой, кызлар, килегез әле, килегез. Бер кәтү. Минекеләр. *(Тәрәзә төбенә менеп, форточкадан кычкыра.)* Әни-и!.. Исәнме, әнием. Исәнмесез, Антонина Сергеевна. *(Хатыннарга карап.)* Минем каенанам. *(Урамга.)* Борчылмагыз... Искиткеч!.. Алдым, барысын да алдым... Антонина Сергеевна, онытыгыз сезгә охшаган Честное слово. Ә?.. Юк, юк, нормально... Сашаны ач йөртмәгез. Саша, тәмле ашаталармы сине? Кара аны, ач йөрмә.

Гөлфинә. *(Валентинаның итәгеннән тартып).* Валентина, сора әле, безнеке күренми микән шунда. Зарифулла күренми микән?

Валентина. Хәзер, хәзер, Гуля апа... Әй, Саша, Зарифулла күренмиме анда. Ә?.. Гуля апаның ире.

Гөлфинә. Гөлфинә диген, Валентина, Гуля дигәнне аңламый бит инде ул Зарифулла.

Валентина. Әй, Саша! Гульфина апаның ире анда булса, әйт, Гульфина апа сине эзли диген. Ә?.. *(Гөлфинәгә.)* Ниндирәк соң ул, Гульфина апа?

Гөлфинә. Авыл кешесе әллә каян танылып тора инде. Кара чәчле булыр. Мыегы бар. Борынының сул канатында бәләкәй генә миңе дә бар. Уң кулын болгап йөрер. Керфекләре озын. Уртача буйлы. Өстенә ни кигәндер — белмим инде.

Валентина. Әй, Саша, әйбәтләп тыңла. Кара чәчле, борынында миңе бар. Озын керфекле, уртача буйлы, уң кулын болгап йөри. Аңладыңмы? Аңладыңмы, Сашенька? Тапсаң, шушы тәрәзәгә килсен. Әнә, әнә шул син басып торган җиргә килсен. *(Кинәт Гөлфинәгә таба борылып.)* Гульфина апа! Карале, теге түгелме?

Гөлфинә *(тәрәзәдән карап).* Шул үзе, алабай. *(Валентина янына менеп баса. Алар хәзер икәүләп бер-берсен бүлешә-бүлешә сөйләшәләр.)*

Валентина. Саша! Саша! Кирәкми. Әнә ул үзе.

Гөлфинә. Зариф, чукынчык, нишләп йөрисең?.. Ә?.. Авылда әллә эшең беткәнме монда йөрмәсәң. Ә?.. Ни булсын ди миңа. Ничек эзләп таптың?.. Передача алып килдеңме?.. Балалар ни хәлдә..

Валентина. Саша!.. Әни!.. Чәчәкләр алып килегез!.. Күп итеп чәчәкләр алып килегез. Ә?.. Озакламыйм... Әйтәм бит, барысы да нормально.

Гөлфинә. Зарифулла, мине ишетәсеңме? Гөлсинә сыерны сауганда үзең дә карап тор, сыерның гадәтен беләсең. Айраттан хат юкмы? Айдарны кара, су буена төшмәсен. Казларны алып кайтып ябарга онытмагыз.

Валентина. Саша, ак күлмәгең гардеробның антресолендә. Безне алырга килгәндә галстук тагып кил.

Гөлфинә. Зарифулла, Зарифулла... Бар кайт, монда болганып йөрмә, сүз әйтмәсеннәр. Уракка төшмәдегезме әле? Карап йөрт комбаенныңны. Былтыр да өч көн ремонтлап яттың.

Валентина. Саша, дүрт көннән чыгам. Килеп йөрмә, үзем кайтырмын.

Валентина. Әни!..

Гөлфинә. Зарифулла, чукынчык, тукта, кая чабасың?

Валентина. Әни!..

Гөлфинә. Зарифулла...

Сестра Нина керә.

Нина. Әй, сез, төшегез әле аннан тизрәк!

Гөлфинә. Ярый, бар инде бар, Зарифулла. *(Тәрәзә төбеннән төшеп, тәрәзәдән карап тора.)*

Нина. Кемгә әйтәләр. *(Валентинаның итәгеннән тарта.)*

Валентина. Саша!.. Әни!.. Антонина Сергеевна! Сау булыгыз *(Төшә.)*

Нина. Әгәр дә ачык форточка янында торып күкрәкләрегезгә салкын тидерсәгез... Бала-чага түгел бит инде сез, әйткәнне тыңларга кирәк. Врачка әйтәм.

Гөлфинә. Врач үзе дә белә инде. Миңа салкын тими ул, сеңелем.

Нина. Соңгы тапкыр кисәтәм.

Валентина. Зинһар, гафу итегез.

Нина *(Дилемма янына килеп).* Сез нигә балагызны ашатмадыгыз?

Дилемма. Каян беләсез?

Нина. Белмәсәм, мин биредә эшләмәс идем. Нигә ашатмадыгыз.

Дилемма. Нигә әле сез минем белән андый тонда сөйләшәсез?

Нина. Мин нормаль тонда сөйләшәм. Сез балагызны ашатмагансыз. Мин сәбәбен белергә тиеш.

Дилемма. Минем күкрәкләрем авырта.

Нина. Врач беләме бу турыда?.. Нигә эндәшмисез?.. Яхшы. Мин хәзер үк врачка әйтәм. *(Чыгып китә.)*

Гөлфинә. Син, сеңелем, алар белән матуррак сөйләш. Алар синең балаңны караучылар ич. Нәрсә, әллә имиләреңнең башы ярылганмы? Бала тапканчы белмисең шул ул нишләргә кирәген. Аны угалап, массаж ясап торырга кирәк. Әллә нинди әле син, сеңелем. Әллә бер зур начальникның баласымы? Безне санга сукмавыңмы?

Валентина. Без биредә барыбыз да аналар.

Гөлфинә. Дөрес әйтә Валентина, монда бөтенебез бертигез. Ачылып китеп сөйләшсәң, без дә каршыңда көлеп торыр идек. Алай ярамый.

Дилемма. Сөйләп бетердеңме?

Гөлфинә. Юк әле.

Айзарә Әхәтовна белән Нина керәләр.

Нина. Мин үлчәп карадым. Айзарә Әхәтовна, бала ашатылмаган.

Айзарә *(Дилеммага).* Күрсәтегез әле күкрәкләрегезне. *(Караватка иелеп Дилемманың күкрәкләрен карый.)* Икесе дә нормаль. Ничек авырталар? Имезгәндәме? Һәрвакытмы?

Дилемма. Һәрвакыт.

Айзарә. Ягез әле, карыйк тагын бер мәртәбә.

Дилемма. Карадыгыз — җитәр.

Айзарә. Гафу итегез, мин белергә тиеш.

Дилемма. Белегез алайса, авыртмыйлар.

Айзарә. Авыртмыйлар? Нигә, алай булгач?..

Дилемма. Кирәкми.

Айзарә. Ничек кирәкми?

Дилемма. Теләмим.

Айзарә. Ачыграк итеп әйтегез.

Дилемма. Теләмим имезергә.

Айзарә. Ни өчен?

Дилемма. Теләмим — бетте китте. Нигә бәйләнәсез?

Айзарә. Сабыррак, сабыррак, Әйдәгез, җайлап кына сөйләшик. Мин бит сезнең палатагызның врачы, шуңа күрә мин белергә тиеш. Тиешме? Ни өчен балагызны имезергә теләмисез?..

Пауза.

Дилемма. Миңа ул кирәкми.

*(Әлегә хәтле сөйләшкәнне дикъкать белән тыңлап утырган өч хатын — Гөлфинә, Валентина, Алтынчәч аягүрә басалар.)*

Айзарә *(хатыннарга).* Утырыгыз, ханымнар. Сабыр. *(Дилеммага.)* Сәбәбе җитдиме?

Дилемма. Җитди.

Айзарә. Ирегез бармы?

Дилемма *(паузадан соң).* Юк. Юк минем ирем.

*(Бишек тирбәтүче Аналар бишек җырын башлыйлар.)*

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Көйләр көйли әнкәсе,
Әнкәсенең янында
Бәбкәсенең әттәсе.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

Палата яктырганда Айзарә Әхәтовна да, Нина да юк. Алтынчәч караватында елап утыра. Аның ике ягына Гөлфинә белән Валентина утырганнар.

Гөлфинә. Алтынчәч, айналаем, бәгырь кисәгем, тукта. Я, нигә, нигә инде җылыйсың?

Валентина. Алтынчәч, милая, хорошая...

Гөлфинә. Ул бала безгә дә кызганыч. Нишләтик соң инде? Алданалар шул. Хатын-кыз алданыр өчен яратылгандыр инде.

Валентина. Җылама. Алтынчәч, күрерсең, барысы да яхшы булыр. Кызып китеп кенә ул. Тынычланыр, уйланыр, барысы да яхшы булыр. Җылама инде, югыйсә, мин дә җылый башлыйм. Бөтен кеше өчен дә җылап бетереп булмый ич инде. Без үзебез дә аның белән сөйләшербез.

Гөлфинә. *(Алтынчәч елаудан туктагач).* Менә шулай. Сабырлык сары алтын. Сездә дә шулай диләрме?

Алтынчәч. Әйе...

Валентина. Ә балаларга сездә ничек иркәләп дәшәләр, Алтынчәч?

Алтынчәч. Колынчагым... Чырагым... Балапаным... Кымбатым...

Гөлфинә. И-и-и, кара ничаклы матур сүзләр...

Алтынчәч. Күп алар.

Валентина. Ә бездә соколик ты мой, золотце мое, солнышко мое, сынуля, дочурка, лапочка, ненаглядный, ненаглядная...

Гөлфинә. Бигрәк тә күп инде матур сүзләр. Матур сүзләрне яратам шул мин. Бәгырь кисәгем, багалмам, йөрәк маем, матурым, тәтием, күземнең карасы, алтыным, көмешем, сандугачым, карлыгачым, гөлкәем... Шундый сүзләрне әйтергә тилмерүчеләр дә бар бит дөньяда. Әйтергә теләмәгәннәр дә бар.

Алтынчәч. Барыбер ул хаклы түгел. Хаклы түгел. Кемдер теләмәгән дип кенә ана үз баласыннан баш тартырга тиеш түгел. Бала өчен ата җаваплы түгел, ана җаваплы. Ананың хакы юк. *(Караватында яткан Дилеммага карап.)* Хакың юк. Кемнеңдер үчен баладан алырга хакың юк.

Гөлфинә. Алтынчәч..

Алтынчәч. Тыймагыз мине, юатмагыз. Мин барыбер аңа әйтәсемне әйтәм. Ул аңларга тиеш. *(Дилеммага.)* Хакың юк синең. Табигать сиңа олы бәхет биргән. Бала табу бәхетен биргән. Син рәхмәт әйтәсе урынга...

Гөлфинә. Я инде, я. Шаярта гына бит ул. *(Дилеммага.)* Юри генә бит син, сеңелем, әйеме?

*(Дилемма эндәшми. Дөресрәге, хатыннарның сүзләрен ишетми дә ул, ишетергә дә теләми...)*

Алтынчәч. Шаярмасын да. Бала шаяра торган нәрсә түгел. Уенчык түгел ул. Уенчыкны да ташлап калдырмыйлар юньле кеше балалары. Ире юк, имеш. Минем дә ирем юк. Ләкин баламның атасы бар. Егетләр карамады миңа, кулымнан тотып сөям дип әйткән кешем булмады. Кияүгә алырга да теләмәделәр. Картаеп барганымны аңлагач, берәвесенә үзем ялындым. Бала анасы ит мине, дидем. Бу дөньядан бала анасы булып китәсем килде. Көлде генә ул берәү миннән, ышанмады чынлап әйткән сүзләремә, бәлки курыккандыр да. Икенчесенә ялындым. Йөземә карарга курыксаң, төнлә кил, караңгыда йөземне күрмәссең, дидем. Бала табасым килә, дидем. Синең балаң икәнен берәүгә дә әйтмәм, дип ант иттем, җыладым. Көлмәде ул миннән, аңлады мине. Мең-мең рәхмәтләр яусын аңа, ул мине бәхетле итте. Мин — ана, минем балам бар. Миннән соң да минем каным аңарда калачак, җанымның бер өлеше аңарда булачак. Минем балам минем күкрәк сөтемне имгәндә миннән дә бәхетле кем бар дөньяда! Ничек син?.. Җаның ничек чыдый?..

Валентина *(елап җибәреп).* Юк, мин ышанмыйм моңа. Теләсәгез нишләтегез, мин ышанмыйм. Ышанырга да теләмим.

Гөлфинә. Ягез, булды. Дөнья күрмәгәнсез әле сез. Бер дә ишеткәнегез юк мәллә? Ятыгыз урыннарыгызга. Ятасыгыз килмәсә, коридорда йөрегез. Нәрсә икәүләп ташландыгыз кешегә? Кешене сүгү җиңел ул. *(Дилемма караваты янына утырып.)* Нәрсә, алдандыңмыни, сеңелем? Син бик бетеренмә. Нишләтәсең инде хәзер. Боларга ачуланма да. Алар сине якын итеп кенә... Я, торып утыр. Сеңелем тәмле күчтәначләр керткән, әйбәтләп сөйләшә-сөйләшә ашыйк. Җиңеләеп китәрсең. Сөйләш син, хәсрәтеңне эчеңә җыеп барма. Имез син балаңны. Алырсыңмы, алмассыңмы, башта имез. Аннан соң үзең дә тагын бер кат уйларсың. Иргә исең китмәсен. Ир-ат ир-ат инде ул — ишек алдындагы әтәч кебек. Балаңны күргәч, ул да әле икенчерәк уйлар. Нәрсә, өйләнгән нәрсә идемени? Әтиең-әниең бармы соң?

Дилемма. Китегез.

Гөлфинә. Кит дигәч... Китәрмен. Без монда гомер буе ятмыйбыз, күп булса атна-ун көн. Яныңа килгәннәрне куарга ашыкма. Юкса, килүче дә булмас. Ялгыз башың нишләрсең? Тор әйдә, тор, киреләнмә. Әдрисен әйт сине алдаган мәлгуньнең, без аңа хат язып салыйк... Яшь әле син, күп нәрсәне белмисең. Менә мин төннәрен уянып китәм дә, балаларымның барысының да башларыннан сыйпап чыгам. Ә сыйпарлык кешең булмаса...

Дилемма. Китегез, дидем.

Гөлфинә. Бәгырең каткан синең, җанкисәгем. Авыр булачак үзеңә дә бүтәннәргә дә. Бәгыре каткан кеше куркыныч бит ул, сеңелкәем. Изгелек тә эшли алмый ул, эшләгән изгелекнең дә кадерен белми. Балаңның рәнҗүеннән

курык ичмасам. Ананың рәнҗүе балага, баланың рәнҗүе анага төшә ул, дип әйтә минем әни. *(Айзарә Әхәтовнаның кергәнен күреп.)* Менә әле сөйләшәбез, иптәш врач, бик матур гына сөйләшәбез.

Айзарә *(Дилеммага).* Нигә алдашасыз, Менгличева? Ирегез бар бит сезнең... Нигә эндәшмисез?

Дилемма. Нигә сез миннән сорау аласыз?

Айзарә. Мин сезнең врачыгыз.

Дилемма. Врач булсагыз, үз эшегез белән шөгыльләнегез. Сорау алу сезнең эш түгел.

Айзарә. Сез, ирем юк, дидегез. Сезнең ирегез бар. Законлы ирегез бар... Нигә эндәшмисез? *(Кызыксынып тыңлап торган хатыннарга.)* Мөмкин булса, беразга гына чыгып торыгыз әле, ханымнар. *(Хатыннар чыгып киткәч.)* Сезнең законлы ирегез бар, Менгличева.

Дилемма. Әйе, бар. Шуннан?

Айзарә. Сез аның белән бергә торасыз.

Дилемма. Әйе, торабыз.

Айзарә. Нигә алдашырга?

Дилемма. Анысы минем эш.

Айзарә. Сезнең баланы алырга теләмәвегезне ирегез беләме?

Дилемма. Үзеннән сорагыз.

Айз Ул командировкада.

Дилемма. Ул студотрядта. Сезгә бездән ни кирәк?

Айзарә. Миңа сездән берни дә кирәкми, иптәш Менгличева. Мине сезнең балагызның язмышы борчый.

Дилемма. Нигә сез аңа борчыласыз?

Айзарә. Баланың әнисе борчылмый икән, кемдер борчылырга тиеш ич инде. Мин аңламыйм сезне, Менгличева.

Дилемма. Аңлашылмаслык ни бар? Баланы алмаячакмын. Һәм минем законлы ирем дә шул ук фикердә.

Айзарә. Ни өчен?

Дилемма. Әлегә безгә бала кирәкми. Ул безгә комачаулый.

Айзарә. Ничек?

Дилемма. Бала карарга безнең вакытыбыз юк. Безгә икебезгә дә укып бетерергә кирәк.

Айзарә. Әниләрегез бармы?

Дилемма. Без аларга бурычлы булырга теләмибез. Икебез дә.

Айзарә. Алайса нигә балага узарга иде?

Дилемма. Ул безнең ялгышыбыз.

Айзарә. Нигә абортка кермәдегез?

Дилемма. Беренче баланы төшерткәннән соң икенче балага узмавыгыз ихтимал, диделәр. Кем белә, бәлки безгә киләчәктә бала кирәк булыр.

Айзарә. Шундый тыныч сөйләшәсез!...

Дилемма. Ә нигә ахылдарга?.. Артык эмоция сәламәтлеккә зарарлы.

Айзарә. Сүз сезнең балагыз турында бара.

Дилемма. Аңлыйм. Беләм.

Айзарә. Аңлап бетермисез, сеңелем.

Дилемма. Сез нәрсә?.. Сеңелем дә сеңелем. Әйттеләр бит сезгә — бала безгә кирәкми. Кемгә кирәк — шул алсын. Минем... Безнең бернинди дә претензиябез юк һәм булмаячак та.

Айзарә. Ирегезне чакыртып кайтарырга туры килер.

Дилемма. Файдасы булмаячак. Без икебез дә принципиаль кешеләр.

Айзарә. Әниләрегез белән сөйләшәчәкбез...

Дилемма. Сөйләшегез. Телиләр икән — алсыннар. Тик безгә претензияләре булмасын.

Айзарә. Коточкыч! Мондый хәлне беренче тапкыр очратам.

Дилемма. Тагын очратырсыз да икенче булыр... Нигә карап торасыз? Оялтырга теләпме? Юкка тырышасыз.

Айзарә. Сез укыган институтка хәбәр итәчәкбез.

Дилемма. Без ул вариантны да уйладык.. Без җинаять эшләмибез. Аборт ясатып үтергәнгә хөкем итмиләр, ә моның өчен нигә хөкем итәргә тиешләр? Ни аермасы бар?

Айзарә *(кыза төшеп).* Кем карарга тиеш сезнең балагызны? Уйладыгызмы шул хакта? Кем карарга тиеш?

Дилемма. Кабатлап әйтәм: кемгә кирәк шул карар. Андыйларны карый торган махсус урыннар бар.

Айзарә. Дәүләт җилкәсенә?

Дилемма. Дәүләтнең җилкәсе юк. Дәүләт үзе кешеләр җилкәсендә утыра. Дәүләткә хезмәт итәргә кешеләр кирәк. Кирәк икән — үстерсен.

Айзарә. Иманыгыз бармы сезнең?

Дилемма. Мин ул сүзне аңламыйм.

Айзарә. Бишек җыры беләсезме сез?

Дилемма. Безгә аны өйрәтмәделәр.

Айзарә Сез бит ана!

Дилемма. Мин хатын-кыз гына. Ул миңа корсакта чакта ук ят иде.

Айзарә. Кеше исемен йөртәсез бит сез!

Дилемма. Кеше исемен йөртүчеләр миллиард белән исәпләнә. Барысы да сез күз алдына китергәнчә түгелдер. Сез тормышны үзегезчә күрәсез, мин үземчә. Мин бит, нигә минемчә уйламыйсыз, дип бәйләнмим, нигә сез үз рецептыгыз белән миңа бәйләнәсез?

Айзарә. Туктагыз әле, бәлки сез чынлап түгелдер, ә? Болай гынадыр, безне сынап карау өчен генәдер?

Дилемма. Ә нигә сезне сынарга? Ул минем вазифама керми. Шулай ук

мине сынау да сезнең эш түгел. Мин ничек телим, шулай яшим.

**Айзарә.** Әгәр мин үземтеләгәнчә булса сезне моннан типкәләп чыгарып идем.

**Дилемма.** Чыгарыгыз. Булдыра алсагыз.

**Айзарә.** Кызганычка каршы, гуманность дигән нәрсә бар дөньяда. Кешелеклелек бар.

**Дилемма.** Әйе. бар. Кызганычка каршы...

**Айзарә.** Ичмасам, имезә торыгыз. Чыкканда алмассыз.

**Дилемма.** Сез врачлар телендә сөйләшмисез, авыл апасы кебек сөйләшәсез. Нигә миңа аны имезергә? Ярамый миңа аны имезергә. Иләлшмәсен... Мин арыдым, миңа ял итәргә кирәк. Мәсьәлә ачык. Калганын үзегез хәл итәрсез.

**Айзарә.** Бәлки уйларсыз, ә, сеңелкәем, бәгырькәем. Карале күзләремә, карале. Күңелеңнең бер почмагында, бәлки миһырбан очкыны калгандыр? Карале күзләремә. *(Дилемма эндәшмәгәч, әкрен генә урыныннан тора да ишеккә юнәлә. Аны коридорда хатыннар каршы алалар.)*

**Валентина.** Доктор...

**Айзарә.** Барыгыз керегез. *(Кабинетына уза. Хәле бетеп урындыкка утыра. Сестра Нина керә.)*

**Нина.** Айзарә Әхәтовна... Сезгә ни булды. Айзарә Әхәтовна? Нигә шулай карап торасыз, Айзарә Әхәтовна?

**Айзарә.** Иоргән егетең бармы синең, Ниночка?

**Нина.** Нигә сорыйсыз, Айзарә Әхәтовна?... Бар.

**Айзарә.** Әйбәтме?

**Нина.** Кайсы мәгънәдә?

**Айзарә.** Ниночка, әйтмә шул кайсы мәгънәдә дигән мәгънәсез сүзне.

**Нина.** Гафу итегез, яратамы дип сорыйсызмы? Кем белә инде аны.

**Айзарә.** Ә кем белергә тиеш?

**Нина.** Мин, билгеле.

**Айзарә.** Ошыймы сиңа монда?

**Нина.** Кайсы мәгънәдә, Айзарә Әхәтовна?.. Гафу итегез. Айзарә Әхәтовна, ошамаса, эшләмәс идем. Ничаклы бала, бәхетле аналар.

**Айзарә.** Ә бәхетсезләре? Ә бәхетле булырга теләмәгәннәре?

**Нина.** Тормыш бит, Айзарә Әхәтовна. Төрлесе була... Бәхетлеләр күбрәк...

**Айзарә.** Бишенче палатадагы Менгличевага баласын кертмәгез.

**Нина.** Яхшы, Айзарә Әхәтовна.

**Айзарә.** Туктагыз әле, бәлки алып керергәдер, ә? Бәлки... Ничек уйлыйсыз, Ниночка?

**Нина.** Белмим.

**Айзарә.** Ә кем белергә тиеш?

**Нина.** Сез әллә нинди, Айзарә Әхәтовна.

**Айзарә.** Мин ул хатын белән сөйләштем...

**Нина.** Ә нигә аның белән сөйләшеп торырга.

**Айзарә.** Кеше ич ул.

**Нина.** Кеше? Кеше андый булмый, Айзарә Әхәтовна.

**Айзарә.** Нинди була?

**Нина.** Кеше төсле була.

**Айзарә.** Әнисен чакыртыгыз әле аның. Иренең әнисен дә.

**Нина.** Яхшы, Айзарә Әхәтовна.

**Айзарә.** Син бишек җыры беләсеңме, Ниночка?

**Нина.** Кайсы мәгънәдә?.. Гафу итегез...

**Айзарә.** Ярый, калдыр мине үземне генә. Әз генә ял итим. *(Чыгып китә. Ишектә Гөлфинә.)*

**Гөфин** Керергә ярыймы соң?

**Айзарә.** Ни бар?

**Гөлфинә.** Болай гына иде...

**Айзарә.** Керегез соң алайса, болай гына.

**Гөлфинә** *(кереп утырып).* Әчем пошып китте әле минә.

**Айзарә.** Нидән?

**Гөлфинә.** Нидән дип... Әллә ничек бит.

**Айзарә.** Нәрсә әллә ничек?

**Гөлфинә.** Бөтен җирдә дә шулай микән?

**Айзарә.** Ничек?

**Гөлфинә.** Беләсез ич инде.

**Айзарә.** Барыгыз, кереп ятыгыз. Сез һәрвакыт аяк өстендә. Өзлегеп китсәгез...

**Гөлфинә.** Өзлексә тагы. Кызык та түгел.

**Айзарә.** Биредә кәмит күрсәтмиләр бит.

**Гөлфинә.** Күрсәтәләр икән шул менә. Авылга кайтып сөйләсәм, ышанмыйлар инде.

**Айзарә.** Авылда бөтенесе әйбәтмени?

**Гөлфинә.** Төрлесе бар да, болай ук түгел инде барыбер. Ирләр кайда да азгын инде, хатын-кызның болай булганы юктыр.

**Айзарә.** Әйе, шулай булуына иләлшмәсәк иде. Ирсез бала үстерүгә инде иләлштек, күнектек. Ирсез бала тапканнарның балаларын алмавына иләлшеп барабыз. Ә монда... Ирле-хатынлы икесе дә салкын акыл белән... Моныснна да иләлшсәк, кем булабыз инде без, балаларыбыз кем була?..

**Гөлфинә.** Шулай шул.

**Айзарә.** Бишек җырларын онытып барабыз...

Гөлфинә. Шулай шул... Онытып барабыз икән шул... Авыр инде сезгә дә монда эшләве, әйеме? Үзегезнең балаларыгыз бармы соң?

Айзарә. Бар.

Гөлфинә. Берәү генәме?

Айзарә. Өчәү.

Гөлфинә. Анысы яхшы икән әле.

Айзарә. Кем белә инде. Улым, кызым дип башларыннан сыйпарга вакыт та юк. Чабабыз да чабабыз.

Гөлфинә. Баштан сыйпар өчен күп вакыт кирәкми анысы. Гел сыйпап торганны да яратмый бала-чага. Күңелең изгедә булса, тоя ул бала-чага әнисенең күңелен. Әтисен дә шулай.

Айзарә. Шулайдыр. Сезнең тәҗрибә зуррак.

Гөлфинә. Кеше булсыннар иде инде, ил алдында оятка калдырмасыннар иде. Үзең гең белсәң ул, авыр булса да түзәсең, менә ил сөйләсә балаңны хурлап, анысын күтәреп булмыйдыр. Олы малайга әтисе Зарифулла әйтә әле беркөн, кара аны, әгәр кешеләр алдында яманатың чыкса, сиңа бер сүз әйтмим, үзем басу капкасына чыгып асылынам, ди. Көлеп кенә йөрисе урынга, әллә нинди күңелсез нәрсәләр сөйләшеп утырабыз, әйеме?.. Карагыз әле, аны бездән чыгарсагыз яхшы булыр иде.

Айзарә. Кая чыгарыйк? Бөтен палаталарда да сезнең кебек кешеләр.

Гөлфинә. Шулаен шулай да. Мин үзем болай түзем халык та, икебез бик ни бит. Бала дигән нәрсә аларга бигрәк кадерле. Ул-бу булып куймагае дип куркам.

Валентина *(ашыгып килеп керә)*. Доктор!.. Әйдәгез тизрәк... Алтынчәч!.. Алтынчәч!.. *(Барысы да ашыгып палатага юнәләләр. Бишек җыры дәвам итә):*

Әлли-бәлли, бәбием,
Кая киткән әнием?
Мәми алырга киткән,
Әз генә көт, нәнием.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

**Палата эче яктырганда палатада Гөлфинә, Валентина, Алтынчәч һәм сестра Нина. Дилемма юк. Караватында яткан Алтынчәчкә Нина яңа гына укол кадаган.**

Нина *(Гөлфинә белән Валентинага)*. Әкренрәк йөрегез, йокласын.

Гөлфинә. Баласын үзем имезәм, сеңелем, сөтем җитәрлек минем.

Нина. Ятыгыз әле урыныгызга.

Гөлфинә. Ятам, сеңелем, ятам. *(Караватына барып ята. Нина чыгып киткәч.)* Менә, күрдеңме инде, Валентина. Бик артык нитәргә ярамый. Үз нервыңа үзең баш булырга кирәк.

Валентина. Алтынчәчнең баласы кызганыч.

Гөлфинә. Яле, син, юкны сөйләмә. Монда баланы ачтан үтерәләр димени. Үзе дә бик әйбәт булыр. Үтә, диде бит врач.

Валентина. Барысы да шул кабәхәт аркасында...

Гөлфинә. Булды дим, җитте. *(Пауза. Тышта ир-атның кычкырган тавышы ишетелә.)*

Валентина. Саша... *(Торып тәрәзә янына бара. Тавышланырга ярамый дигәнне кулы белән ишарәләп аңлата. Саша аңламагач, тәрәзә төбенә менеп, форточкадан башын тыгып аңлата.)* Сашуля! Бездә йоклыйлар... Бар, җаным, кайт. Яхшы. Бөтенесе дә яхшы. *(Тәрәзә төбеннән төшеп.)* Ачуланмагыз инде, Гульфина апа. Килгән бит.

Гөлфинә. Менә кызык, нигә ачуланыйм.

**Дилемма керә. Форточканы яба. Валентина урыныннан торып форточканы ача.**

Дилемма. Ябыгыз. Сквозняк.

Гөлфинә. Нинди сквозняк булсын. Алтынчәчкә һава кирәк.

Дилемма. Ябыгыз, диләр. *(Тора башлый.)*

Валентина. Килеп кенә кара. Хәзер форточкадан тотып ыргытам. Синең сулышыңны иснәп ятарга монда, поганая!

Дилемма. Замолчи!

Валентина. Вот я замолчу тебе, стерва.

Гөлфинә. Валентина, ярамый, нишлисең... *(Дилеммага.)* Әйтеп торалар бит сиңа. Күреп торасың Алтынчәчнең хәлен. *(Дилемма җаймәсенә бөркәнеп ята. Гөлфинә торып Валентина янына килә, караватының читенә утыра.)* Син сүгенмә, Валентина, ямьсез сүзләр әйтмә.

Валентина. Ул гына аз әле аңа...

Гөлфинә. Барыбер кирәкми. Кешене ямьсез сүз әйтеп төзәтеп булмый. Аннары синең ул сүзләреңне улың ишетеп ята... Әйе, әйе, ишетми димә, күңеле белән ишетә ул. Бала ул синең ни уйлаганыңа хәтле ишетеп ята. Тәмсез телле хатыннарның балалары да тәмсез телле була.

Валентина. Сезнең бер дә сүгенгәнегез юкмы?

Гөлфинә. Юк.

Валентина. Эштә дәме?

Гөлфинә. Барыбер инде ул. Эштә ни, өйдә ни.

Валентина. Әй, безнең эштә! Ике сүзнең берендә...

Гөлфинә. Бездә дә инде анысы. Сирәк саудым мин уникe ел. Сүгенәләр.

Хатын-кызлар сүгенә, Валентина җаным. Тик торганнан сүгенә. Сыерны да сүгә, сөт алырга килгән шоферны да сүгә. Өенә кайткач та сүгенә. Әллә нинди сүгенү сүзләре беләләр, матур сүз белмиләр. Әнә врач әйтеп торды: бишек җырларын онытып барабыз, ди. Шунда әчемнән генә оялып куйдым. Мин дә байтактан җырлаганым юк икән бишек җырын. Гел җырлап тормасак, онытыла шул ул. Син бишек җыры беләсеңме, Валентина?

Валентина. Бишек җыры?.. Бишек җыры... Белмим бит, Гульфина апа.

Алтынчәч. Ә мин беләм...

Гөлфинә. Менә уяттык та... *(Алтынчәч янына килеп.)* Син йокла, Алтынчәч айналаем, йокла... Телемне тыя алмыйм шул, телемне.

Алтынчәч. Мин йокламый идем. Сөйләшегез, мин сезне тыңлап ятыйм.

Гөлфинә. Юк инде, юк, сестра сөйләшмәскә кушты.

Алтынчәч. Минем сезне тыңлыйсым килә.

Валентина *(Алтынчәч янына килеп).* Куркыттың бит, Алтынчәч. Яхшымы инде хәзер?

Алтынчәч. Сөйләшегез.

Гөлфинә. Сөйләш дигәндә сүзен дә табып булмый бит ул. Менә әле хәлең яхшыргач, синнән бишек җырыгызны җырлатабыз. Авылга отып алып кайтам. Аптырасыннар әле балалар.

Валентина. Мин дә Сашага әйтәм, язып алып килсен. *(Дилемма урыныннан торып чыгып китә.)*

Гөлфинә. Түзмәде. Башына уй керә башлады ахрысы. Борсалана. Без әле бергәләп юри ул барында өчәүләп бишек җыры җырларбыз. Әйтте диярсең, үкереп җылаячак. Аннары, китерегез минем баламны, диячәк. Җырның шунысы яхшы — үзәккә барып кадала. Бервакыт безнең авылда мондый хәл булган. Бер кыз төбәлеп әнисенә карап тора икән. Нигә шулай карап торасың, кызым, дип сораган әнисе. Синнән туганыма хурланып карап торам, дигән кыз. Шул көнне авылга концерт килгән икән. Шунда бер җырчы бик моңлы итеп «Әнием, күз нурым» дигән җырны җырлаган. Шул җырны тыңлаганнан соң теге кыз клубта җылап җибәргән. Өйләренә кайткач, әнисен кочаклап, әнием — күз нурым, гафу ит мине, дип җылаган. Аннары соң, күрше авылда — Салтыкта болай булган. *(Гөлфинә сөйли, безгә аның ни сөйләгәне ишетелми. Коридорда исемсез хатын пәйда була. Палатада сөйләшкән сүзне тыңлап тора. Сестра Нина килгәнне күргәч, качмакчы була да, кире уйлап, Нинаның каршысына килә.)*

Нина. Тагын сез?! Бүген үк бездән чыгып китәсез. Кисәтеп арыдым.

Хатын. Зинһар, тавышланмагыз инде. Бер генә нәрсә сорыйм.

Нина. Сорамагыз да, тыңламыйм да. Хәзер үк чыгып китегез.

Хатын. Сестра...

Нина. Чыгып китегез. *(Коридордан килүче Айзарә Әхәтовнага.)* Айзарә Әхәтовна, мин берни эшли алмыйм. Милиция чакыра алмыйм бит инде.

Айзарә. Кем җибәрә соң аны монда?

Нина. Кем белә. Ничә тапкыр әйттем. Без белмибез, диләр.

Хатын. Иптәш врач... Зинһар өчен...

Айзарә. Әйткәнне аңлыйсызмы сез, юкмы?

Хатын. Аңлыйм. Зинһар өчен, тыңлагыз мине. Әз генә.

Айзарә. Я, тыңлыйм, тыңлыйм. *(Кабинетка уза. Исемсез хатын аңа ияреп керә.)* Я, тыңлыйм. Нинди кеше соң сез, әйтеп торалар лабаса. Я, сөйләгез.

Хатын. Гинекология бүлегеннән мин.

Айзарә. Беләм.

Хатын. Балам юк минем. Дәваланам.

Айзарә. Беләм.

Хатын. Мин белмәдем. Яшь идем әле. Аборт ясатырга куштылар. Шулай туры килде... Врачлар әйтте — тыңламадым. Ышанмадым. Яшь идем әле мин... Бүтән булмады... Балам юк минем...

Айзарә. Ә мин нишли алам?

Хатын. Бала кирәк миңа. Ярдәм итегез.

Айзарә. Ярдәм?.. Нинди ярдәм?

Хатын. Бала кирәк миңа.

Айзарә. Әйттегез.

Хатын. Аерылышабыз, ди. Ирем. Мин аны яратам. Мин ансыз тора алмыйм. Башта баланы төшертте, үзе кушты, хәзер, аерылышабыз, ди. Бала кирәк миңа, ди. Бала кирәк миңа.

Айзарә. Аңладым бит инде, җанкисәгем. Берни дә эшли алмыйм бит мин сезгә.

Хатын. Эшли аласыз. Мин ишеттем.

Айзарә. Нәрсә ишеттегез?

Хатын. Теләсәгез, эшли аласыз.

Айзарә. Әйтегез соң ничек эшли алам?

Хатын *(колагыннан алтын алкаларын, бармакларыннан йөзекләрен салып өстәлгә, Айзарә алдына куя).* Мәгез, алыгыз.

Айзарә. Нәрсә болар?

Хатын. Алыгыз, сезгә. Тик, зинһар, ярдәм итегез.

Айзарә. Җыеп алыгыз әле боларны. Һәм барыгыз чыгып китегез. Барыгыз!

Хатын. Туктагыз әле.

Айзарә *(урыныннан торып).* Мин сезгә әйттем.

Хатын *(алка, йөзекләрен алып).* Ярый, ярый, ачуланмагыз. Тик ярдәм генә итегез. *(Айзарәнең каршына тезләнеп.)* Ярдәм итегез миңа. Миңа әйттеләр. Өйрәттеләр. Роддомнан бала алып чыгып була, диделәр. Мин иремне алдадым. Балага уздым, дидем. Роддомга бала табарга керәм, дидем. Ул әлегә командировкада. Ул командировкада чакта кердем. Ярдәм итегез миңа!

Айзарә. Кызганычка каршы, мин сезгә берничек тә ярдәм и-тә ал-мыйм.

Хатын. Аласыз. Мин барысын да беләм. Баласын алмый диделәр. Бирегез миңа шул баланы.

Айзарә. Торыгыз. Яле, торыгыз, тор. Утырыгыз. Тынычланыгыз. Хәзер инде мине тыңлагыз. Тыңлый аласызмы мине?

Хатын. Тыңлыйм.

Айзарә. Алкаларыгызны, йөзекләрегезне киегез.

Хатын. Киям, киям...

Айзарә. Менә шулай. Инде менә болай: кем сезгә әйткәндер артык бала бар дип, белмим. Әмма булган очракта да болай гына җиңел генә эшләнми ул. Бала бит, адәм баласы! Монда итәк астыннан гына алыш-биреш итәргә — сорочи базары түгел.

Хатын. Әйттеләр, мөмкин, диделәр.

Айзарә. Кем әйткән, шул килеп безне өйрәтсен — ничек эшлиләр икән. Менә мин сезгә әйтәм: сезгә бала биргән очракта да сезнең бала түгеллеген иригез белергә тиеш.

Хатын. Ул белергә тиеш түгел. Ул риза булмаячак. Мин аңарга әйттем, бала алыйк, дидем, риза булмады.

Айзарә. Башкача мөмкин түгел. Закон бар.

Хатын. Ярдәм итегез.

Айзарә. Нинди кеше соң сез?... Мин сезгә әйтеп торам.

Хатын. Ярдәм итегез. *(Җан ачысы белән кычкырып.)* Бала кирәк миңа! Миңа бала кирәк!.. Бала кирәк!.. *(Ике ана бишек җырын дәвам итәләр):*

Йөрәгемнең пәрәсе,
Ике күзем карасы,
Мәхәббәтем чаткысы,
Күңелемнең яктысы.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү...

**Шушы көй белән беренче пәрдә тәмамлана.**

## Икенче пәрдә

**Беренче пәрдәдәге күренеш. Бишек тирбәтүче ике Ана бишек җырын дәвам итәләр:**

Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам-багалмам,
Үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры,
Күчәрсеңме син?
Бәхет гөлемнең чәчәге булып,
Былбыл кошкаем,
Яшәрсеңме син?
Әнием, диеп, кадерлем, диеп,
Сандугачкаем,
Дәшәрсеңме син?
Гомрең сукмагын зур юллар буйлап,
Өмет йолдызым,
Үтәрсеңме син?
Илеңнең данын Намус, Вөжданың,
Балам, әй, балам,
Итәрсеңме син?

**Коридор әкренләп яктыра. Сестра Нина тамаклары тук балаларны палатадан төяп алып чыга. Аңа Валентина иярә.**

Нина. Сез кая?

Валентина. Озатып куям.

Нина. Ни өчен?

Валентина. Ул-бу булмагае.

Нина. Ни булсын ди аларга? Мин алар өчен сездән күбрәк җавап бирәм.

Валентина. Сашенькага карап кына калыйм инде.

Нина. Имезгәндә карамадыгызмыни?

Валентина. Эх, Ниночка, аңа карап туеп буламыни! Сезнең әле балагыз юк... белмисез.

Нина. Бала уенчык түгел. *(Арбасын этеп китә.)*

Валентина *(палатага кереп).* Бигрәк кырыс бу Нина.

Гөлфинә. Шулай тиештер аңа. Роддомдагы бөтен хатыннар белән кочаклашып йөри алмый ич. Аңа эш эшләргә кирәк. Син, Валентина, аның кырыслыгын әйтмә, балаларны ничек итеп тотуын кара. Мин үз баламны да алай матур итеп тота алмыйм.

Алтынчәч. Рәхә-әт.

Валентина. Нәрсә рәхәт, Алтынчәч?

Алтынчәч. Сезгә дә шулаймы, бала имгәч, җанга рәхәт.

Валентина. Сиңа да шулай, да? Минем тәннәрем рәхәтләнеп, җиңеләеп китә. Менә хәзер мин җип-җиңел... Әйдәгез, кызлар, хәзер утырып ашыйбыз. Сезнең дә ашыйсыгыз киләме, ә минем һаман тамак туймый.

Алтынчәч. Минем ашыйсым килми.

Валентина. Алдашма, Алтынчәч. Син, беләм, юри генә. Нигә ояласың? Минем мондагы передачаны ашап бетерерлек түгел. Килегез, Гульфина апа. Графиня Гульфина, кушать подано.

Гөлфинә. Графиня ничек дип әйтә инде?

Валентина *(графиня булып)*. Мерси.

Гөлфинә *(графиня булып)*. Мирси. Алтынчәч, подходи.

Алтынчәч. Мин графиня түгелмени?

Валентина. Син княгиня, Алтынчәч.

Гөлфинә. Кайсысы зур соң аларның?

Валентина. Кем белә инде анысын. Эх, рәхәте, кызлар!.. Эшлисе юк, ашап кына ят, ә? Шулай да эшемне сагынам.

Алтынчәч. Кем булып эшлисең, Валентина?

Валентина. Штукатур-маляр.

Гөлфинә. Сагынырлык эш икән шул.

Валентина. Алай димәгез, Гульфина апа, һәр эшнең үз матурлыгы бар. Эшемнән дә бигрәк бригададагы иптәш кызларымны сагындым. Менә бусы алар күчтәнәче. Нигә туктадың, Алтынчәч? Оялма инде, аша.

Гөлфинә. Казахларда аша димиләр, җиең, җиең диләр.

Валентина. Җиең, җиең, Алтынчәч.

Алтынчәч. Миңа чыннан да җитте. Рәхмәт. *(Хатыннар үзенең караватында китап укып яткан Дилеммага карап-карап алалар. Гомумән, Дилеммага аларның берсе дә битараф түгел. Бу юлы Гөлфинә Дилемма ягына карый да Валентинага пышылдый.)*

Гөлфинә. Чакырмыйбызмы?

Валентина. Китабын укысын.

Гөлфинә. Аңламыйдыр ул, бу нидә укып була димени?

Валентина. Ничек кенә аңлый әле... Булды. Безнең бригадир Соня апа әйтмешли, алла акбар. Хәзер нишлибез? Ятып йоклыйбызмы?

Гөлфинә. Ашагач ук йокларга ярамый, диләр. Алтынчәчнең бишек җырын өйрәнәсебез бар. Таралыр вакыт җитә.

Валентина. Алтынчәч, давай.

Алтынчәч. Ярый микән соң монда?

Гөлфинә. Монда да бишек җыры җырларга ярамагач... Әйдә.

Алтынчәч *(казах халкының бишек җырларыннан берсен әкрен генә җырлый)*.

Күзимнең агы, карасы,
Җүригимниң парасы.
Дуние камды ойлатпас,
Көңилимниң данасы.
Әлди, балам, әлди.

Айналаен, шырагым,
Көлге биткен корагым,
Жагамдагы кондызым,
Әуедеги жолдызым.
Әлди, балам, әлди.

Айналаеын балам — ай,
Айналсын сенең анаң — ай,
Әлдилеп сени сүйгендә
Анаңның болар күңили җай.
Әлди, балам, әлди.

Гөлфинә. Үзәкләрне өзеп ала шул.

Валентина. Кем булып эшлисең син, Алтынчәч?

Алтынчәч. Балалар бакчасында тәрбияче идем.

Гөлфинә. Күренеп тора шул.

Валентина. Нигә идем дисең, Алтынчәч.

Алтынчәч. Хәзер эшләмим. Дүрт ай. Беленә башлагач, киттем.

Валентина. Беленсә ни...

Гөлфинә. Алай димә, Валентина. Кеше бит ул, беләсең... Бигрәк тә хатын-кыз, аны моны уйлап тормый, әйтә дә сала. Син берәүдән дә курыкма да, оялма да, Алтынчәч. Син бит аны зина кылып тапмаган.

Алтынчәч. Әни җылады.

Гөлфинә. Әниләр җылый инде ул, нишләтәсең. Аңлагач, җыламас әле. Син бит инде уналты-унҗиде яшьлек кыз түгел.

Валентина. Кызык бу тормыш дигәнең, әйеме? Ишетеп, тыңлап, күреп торасың... Безнең бригадада гел хатын-кызлар. Утырып сөйләшәбез дә кайвакыт, үзебез шаккатабыз. Барысына да ирләр гаепле!

Гөлфинә. Ничек ирләр гаепле?

Валентина. Ир кешеләр бетеп бара бит, Гульфина апа, «Мурзилка» журналына бесплатное приложение булып кына яшиләр. Кемне генә тыңласаң да, шуны әйтә. Безнең Соня апа да әйтә, ирләргә ышаныч юк, ди. Ертыгыма ямау булыр дип чыккан буласың киявгә, аннары гомер буе интегәсең исерек ир тәрбияләп, ди.

Гөлфинә. Кем соң инде ул Соня апа дигәнең?

Валентина. Безнең бригадир.

Гөлфинә. Шулай бик күп беләмени?

Валентина. Аның инде пенсиягә чыгарга вакыты җитә. Күргән инде дөньяны. Ире бик эчә.

Гөлфинә. Эчерткәч эчә инде.

Валентина. Әле җитмәсә балаларны ятим итеп ташлап чыгып китәләр, ди.

Гөлфинә. Чуртым да белми синең Соня апаң. Валентина милый мой, дорогой, әйбәт хатыннарны ире ташлап китми.

Валентина. Ничек кенә китә әле. Минем иптәш кызым бар иде, искиткеч иде. Аны ташлап, бер юньсезгә өйләнде ире.

Гөлфинә. Синең Сашаң сине ташламаган бит. Ничә ел балагыз булмаган, алай да ташлап китмәгән. Әчми дә дисең үзең.

Валентина. Саша кебекләр сирәк. Саша ул минем бәхетемә туры килгән.

Гөлфинә. Әй, Валентина, милый мой, дорогой! Син Саша бәхетенә туры килгәнсең. Синең иптәш кызың синең өчен искиткеч булгандыр да, ире өчен искиткеч булмагандыр. Ирләр алар, Валентина, хайван терлеге белән бер. Вакытында ашатып-эчертеп, тамак астын кашып торсаң, артыңнан ияреп йөри. Менә сыерны гына ал син, тпри-тпри-тпри дип сыйпап алдына печән салсаң, он болгатып җылы су эчерсәң, күзләрен мөлдерәтеп мөгрәп кенә тора. Җиленен җылы су белән юып, йомшак чиста сөлге белән сөртсәң, сауганда да тибенми, сөтен дә күп бирә. Әгәр дә инде, башың беткере, муенын астына килгере, дип чыбык белән кыйнасаң, көтүдән кайтып капкадан чабып керми инде ул. Куып кайтарырга туры килә. Эт булып эт тә, ашатмыйча, пшул, дип кычкырсаң, капка астыннан күршеләр ишегалдына кереп тавыкларга изгәнне ашап йөри.

Валентина *(рәхәтләнеп көлеп)*. Саша, Сашуля, тпри-тпри-тпри!

Алтынчәч. Ирләр матурларны эзлиләр, Гөлфинә апа.

Гөлфинә. Юк, айналаем Алтынчәч... Беләсең килсә, ирләр эзләми хатын-кызны, без эзлибез аларны.

Валентина. Дөрес түгел, Гульфина апа. Мин, мәсәлән, үзем эзләмәдем.

Гөлфинә. Шулай тоела гына ул. Мин дә менә, Зарифулла, Зарифулла дип кычкырып Зарифулланы эзләп йөрмәдем. Зарифуллага бер карагач, күңелем Зарифулланы эзләгәнен сизеп алдым да, өйләндердем дә куйдым Зарифулланың башын үземнең якка.

Валентина. Ничек, Гульфина апа, ничек?

Гөлфинә. Зарифулла Мөршидә исемле кыз артыннан йөри иде, миңа борылып та карамый. Ә Мөршидә бүтәнне эзли. Шуннан мин Зарифулланың йомшак ягын сизеп алдым да... Бии белми ул, җырлый да белми. Үзенең бисе дә килә, җырлыйсы да килә. Клубта — вечерларда Зарифулла бии башласа да, җырлый башласа да, кызлар моңардан көләләр. Мөршидә кушылып көлә. Шуннан мин Зарифулла үгез кебек үкереп җырлый башласа, аңа кушылам да китәм, Зарифулланың җырлый белмәгәне сизелми дә, минем тавыш матур да, көчле дә. Биергә дә Зарифулланы чакырам, ул аю кебек әйләнгәндә мин моның тирәсендә күбәләк шикелле бөтереләм. Менә без ничә ел инде Зарифулла белән авызга-авыз куеп яшибез, Мөршидә ирдән-иргә йөри.

Алтынчәч. Сез бит чибәр дә, Гөлфинә апа.

Гөлфинә. И, Алтынчәч. Нинди чибәр булыйм?! Кылыч борын, иләк авыз, акай күз — нинди чибәр булыйм. Менә син үзеңне үзең ким санап юкка йөрисең, хатын-кызның чибәрлеге йөзендә түгел, айналаем, хәйләсендә. Мин чибәр дип күзгегә карап тор син. Чибәр икәнлегеңә ышансаң, бүтәннәр дә ышана. Үзең ышанмагач, бүтәннәр ничек ышансын?! Менә мин авызымны бәләкәй итеп күрсәтер өчен бөреп йөрим. Күзләремне акайтып, авызны җырып елмаеп җибәрәм, Зарифулла авызга кереп китәрдәй булып сокланып карап тора.

Валентина. Ә минем Саша мороженое ярата. Яратканын сиздермәскә тырыша. Мин юри мороженое саткан җирдән үткәндә, Саша мороженое алыйк әле, дип ялынам. Миңа ала бу, үзенә алмый. Үзеңә дә ал, дип бәйләнәм, аңа да алдыртам. Мыекларын ялый-ялый кимерә Саша мороженоены. Ә мин мороженое яратмыйм, шулай да яраткан булып кыланам.

Гөлфинә. Менә, менә, менә... Хәйләкәр төлке. Саша мине ярата, дигән була. Ничек яратмасын мондый хатынны! Әйтәм бит, ирләр алар сабый бала белән бер. Без яхшы булсак, алар яхшы, без начар булсак, алар да начар. Дөньяның тоткасы — хатын-кызда. Патшалар да хатыннары сүзеннән чыкмаган. Хатыны әйткән икән мондый закон чыгар дип, икенче көнне үк патша шундый закон чыгарган. Без, дип ирләр түш кенә киереп йөри, эшләүчеләре без аның.

Валентина *(патша хатыны булып уйнап күрсәтә)*. Саша, Александр Борисович, шундый закон чыгар!...

Гөлфинә. Алай түгел, Валентина, кычкырып түгел, кычкырганны яратмый ир-ат. Җайлап кына, йокларга яткач, ул сине кочакларга үрелгәндә... *(Валентина, Алтынчәч көләләр.)*

Алтынчәч. Шундый итеп сөйлисез, Гөлфинә апа...

Гөлфинә. Ышанмыйсызмы? Әйт әле, синең кызыңның атасы өйләнгән кешеме? Әйт инде, әйт, нәрсәсе оят аның.

**Алтынчәч.** Юк.

**Валентина.** Алай булгач, нигә сиңа өйләнмәде?

**Алтынчәч.** Ничек инде өйләнсен, ул чибәр, яшь. Мин үзем дә аңа чыкмас идем.

**Гөлфинә.** Нишләп?

**Алтынчәч.** Монысы өчен дә рәхмәт.

**Гөлфинә.** Әй син, тиле, тиле... Бигрәк тәртипле шул сезнең халык. Давай, чык син аңа кияүгә!

**Алтынчәч.** Сез нәрсә?..

**Гөлфинә.** Валентина белән тотынсак, каршыңа килеп тезләнәчәк.

**Валентина.** Гульфина апа, чыннан да, әйдәле...

**Гөлфинә.** Эшлибез, Валентина, эшлибез. Безгә ул нипочем. Әйбәт кешеме үзе болай?

**Алтынчәч.** Ничек дип әйтергә...

**Гөлфинә.** Аракы эчәме?

**Алтынчәч.** Эчә бугай...

**Гөлфинә.** Күп эчәме?

**Алтынчәч.** Исерек чагын еш күрәм.

**Валентина.** Алайса, кирәкми... Син балага узганда исерек түгел идеме?

**Алтынчәч.** Юк. Анысын мин беләм. Миңа сәламәт бала кирәк.

**Гөлфинә.** Эчүен дә ташлатабыз без аның. Конфет суырып йөри торган итәбез. Ирләрне төзәтүе җиңел ул. Ирләрнең азгынын да төзәтеп була. Менә хатын-кыз азса — синең Соняң әйтмешли, Валентина, алла әкбәр, бетте дөнья, атом бомбасы да кирәкми. Ник дигәндә, ир кеше нишләгәнен белмичә аза, хатын-кыз белеп аза, акыл белән, усаллык белән. *(Дилемма ягына.)* Менә аның урынында ир кеше булсамы? Җил ягына салам кыстырыбрак сөйләшсәң, үз баласын гына түгел, бүтәннәрнекен дә җыеп алып чыгып китәчәк. Бу — юк.

**Валентина.** Ире белән сөйләшеп ич алар.

**Гөлфинә.** Ире белән бу сөйләшкән, бу котырткан.

**Дилемма** *(сикереп торып).* Туктыйсыңмы син, юкмы? *(Гөлфинә каршына килеп.)* Син!..

**Валентина** *(аның юлына аркылы төшеп).* Якын килмә.

**Дилемма** *(Валентина аша Гөлфинәгә).* Ты!.. Свинья!.. Рожай своих поросят и копайся в навозе, меня не трогай!

**Валентина** *(Дилемманы ишеккә таба кысрыклап).* Нәрсә дидең син аңа, ә, нәрсә әйттең?..

**Гөлфинә.** Валентина, кирәкми. Кирәкми, Валентина...

**Айзарә** *(кереп Валентина белән Дилемма арасына баса).* Нишлисез сез, туктагыз хәзер үк!

**Валентина.** Чыгарыгыз аны моннан. Соңгы тапкыр әйтәбез, чыгарыгыз. Югыйсә, үзегезгә начар булачак. Министрны чакыртабыз.

**Айзарә.** Тынычланыгыз.

**Валентина.** Юк, без тынычланмыйбыз. Һаман бер сүз — тынычланыгыз.

**Айзарә.** Сабыр. Зинһар өчен, сабыр булыгыз. *(Валентинаны култыклап караваты янына алып килеп утырта.)* Сез бит өлкән кешеләр. Аңлагыз безне дә. Без бит сезне аңларга тырышабыз.

**Валентина.** Юк, сез аңламыйсыз. Ул безнең барыбызны да неврастеник итеп бетерә.

**Айзарә.** Я, я, булды, булды. *(Гөлфинәгә ишарәләп.)* Менә бу апагыздан үрнәк алыгыз.

**Гөлфинә.** Минем аркада килеп чыкты ла. Ялгыш ычкынып китте.

**Валентина.** Гаепләмәгез үзегезне, Гульфина апа.

**Айзарә.** Булды, дидем. Валямы әле исемегез?

**Валентина.** Валя.

**Айзарә.** Сезнең бала имезәсегез бар, Валечка. *(Алтынчәч янына килеп.)* Я, сезнең хәлләр ничек?

**Алтынчәч.** Яхшы.

**Айзарә.** Молодец. Барысы да яхшы булыр.

**Дилемма** *(ишек төбеннән).* Выпишите меня. Мин — сәламәт.

**Айзарә.** Сез сәламәт, анысына шигем юк... Бүген баш врач кайтты — хәл итәр. *(Ике Ана бишек җырын дәвам итәләр.)*

Бәхет гөлемнең чәчәге булып,
Былбыл кошкаем,
Яшәрсеңме син?
Әнием диеп, кадерлем диеп,
Сандугачкаем, дәшәрсеңме син?

**(Врач кабинеты актыра. Анда баш врач Зәйтүнә Закировна һәм Айзарә Әхмәтовна).**

**Баш врач.** Сез беләсез, Айзарә Әхәтовна, без андый эшне эшли алмыйбыз.

**Айзарә.** Аңлыйм.

**Баш врач.** Аңлагач, шул. Бала үз анасы белән чыгарга тиеш. Яхшылап сөйләштегезме?

**Айзарә.** Сөйләшмәгән кая. Бераз гына да йомшамый.

**Баш врач.** Сәбәбе дә җитди түгел, югыйсә.

**Айзарә.** Бөтен куркынычы дә шунда шул. Иренә хәбәр иттергән идек, студотрядта ди, кайтып тормаган. Телеграмма җибәргән, Дилемма ничек тели, шулай булсын, дигән.

Баш врач. Исеме Дилеммамыни?

Айзарә. Әйе.

Баш врач. Һе. Тапканнар исемне дә. Баланың әби-бабалары ничек?

Айзарә. Сез кайтканны көттек, Зәйтүнә Закировна. Бүген чакырттык — килерләрме, юкмы...

Баш врач. Көтелмәгән хәлләр белән очраша башладык бит әле, Айзарә Әхәтовна... Бер балага урын табылыр. Табылып тора. Тәрбияләнер дә. Тик, ничек кенә тәрбияләнсә дә, ятимлек ятимлек инде. Ничек кенә булса да, ятим балада психологик деффект була. Чөнки тәрбиячеләр дә, бүтәннәр дә аларга ятим итеп кызганып карыйлар. Кеше шуңарга өйрәнә, гомер буе үзен кызганганнарын таләп итә. Янсә, киресенчә, кызганган кешеләрне күрә алмый, рәхимсез, миһырбансыз була. Ата-анасы үлгән ятимнәр бер хәл, бүгенге көндә күпме ата-аналы ятимнәр. Һәм без шулардан шәфкать көтәргә тиеш. Каян килеп чыкты бу кешеләрдә шундый җавапсызлык? Юк, нәрсәдер эшләргә кирәк. Ничек инде ул сау-сәламәт ир белән хатын балаларын алмыйлар? Ни өчен алмаска тиеш? Алмасалар, нигә закон алдында җавап бирмиләр?

Нина. Гафу итегез, Менгличеваның каенанасы килде.

Баш врач. Керсен. *(Нина чыгып китә, Вазыйфа керә.)*

Вазыйфа. Исәнмесез.

Баш врач. Исәнмесез. Утырыгыз... Сез Менгличева Дилемманың каенанасымы?

Вазыйфа. Шулайдыр.

Баш врач. Ничек шулайдыр?

Вазыйфа. Ну, кайнанасы.

Баш врач. Менгличевамы фамилиягез?

Вазыйфа. Юк, Садриева Вазыйфа. Фамилиясен үзгәртмәгән ул.

Баш врач. Киленегезме?

Вазыйфа. Килен түгел ул миңа. Мин аны признавать итмим.

Баш врач. Ничек итмисез? Улыгызны балагыз дип таныйсыздыр ич?

Вазыйфа. Анысын таныйм да...

Баш врач. Менгличева Дилемма сезнең улыгызның законлы хатыны.

Вазыйфа. Булмагае...

Баш врач. Алай икән... Ә соң сез киленегезнең бала тапканын беләсезме?

Вазыйфа. Ишеткән идем.

Баш врач. Нигә бергә яшәмисезмени?

Вазыйфа. Юк, квартирга чыктылар.

Баш врач. Ярый. Ә киленегезнең үз баласын алырга теләмәгәнен беләсезме?

Вазыйфа. Ничек инде алырга теләмәгәнен?

Баш врач. Шулай. Сезнең улыгызның хатыны үзенең һәм сезнең улыгызның баласын, ягъни сезнең оныгыгызны үзенә алырга теләми. Миңа бала кирәкми, ди.

Вазыйфа. Кирәк булмагач, нигә тапкан соң?

Баш врач. Анысы икенче мәсьәлә. Киленегез баласын имезми.

Вазыйфа. Ничек имезсен — змия ич ул.

Баш врач. Туктагыз әле... Ярый, киленегез «змея», ди, ә улыгыз? Ул да ризалык биргән бит.

Вазыйфа. Баланы алмаскамы?

Баш врач. Әйе.

Вазыйфа. Өйдә юк диделәр ич аны.

Баш врач. Элегрәк килешкәннәр, һәм улыгыз телеграмма да җибәргән.

Вазыйфа. Чүпрәк ич ул.

Баш врач. Улыгызмы? *(Вазыйфа эндәшмәгәч)* Инде нишлибез, Вазыйфа ханым?

Вазыйфа *(паузадан соң).* Мин нишлим? Бездә эшең юк, кысылма, диделәр, теләсәләр нишләсеннәр.

Баш врач. Ләкин бала бит сезнең оныгыгыз!

Вазыйфа. Булмагае...

Баш врач. Бәлки, сез баланы алырсыз?

Вазыйфа. Нишлим ди мин аның белән?

Баш врач. Ирегез бармы сезнең?

Вазыйфа. Булса ни. Ул җебегәннең ирлеге. Бала белән ул түгел бит, мин мучиться ителәсе.

Баш врач. Тагын балаларыгыз бармы сезнең?

Вазыйфа. Монысыннан да гарык.

Баш врач. Вазыйфа ханым, әгәр дә сезгә шушы хәлне сөйләсәләр, сез ышаныр идегезме?

Вазыйфа. Кайсы хәлне?

Баш врач. Бер ир хатынының үз баласын алырга теләмәвен, иренең шуңа ризалык бирүен, ир анасының шулай сөйләшеп утыруын...

Вазыйфа. Ә мин нәрсә сөйләшкән ул хәтле? Өйләнмә аңа, дидем.

Баш врач. Сез киленегезне күптән белә идегезмени?

Вазыйфа. Белмәскә! Энисе — ата спекулянт. Ирен куып чыгарып, типтереп яшәде.

Баш врач. Үзегез кайда эшлисез?

Вазыйфа. Нәрсәгә кирәк ул сезгә? Кайда эшләсәм дә эшлим.

Баш врач. Бала кызганыч бит, Вазыйфа ханым.

Вазыйфа. Алар кызганмаганны нигә мин кызганыйм.

**Баш врач.** Соңыннан үкенәчәксез бит.

**Вазыйфа.** Үкенәсен үкенгән инде. Бу бозауны тапканга да үкенеп бетә алмыйм.

**Баш врач.** Алар әле яшьләр, күп нәрсәне аңлап бетермиләр.

**Вазыйфа.** Аңламаслар... Үзләренә кирәкне бик аңлыйлар. Беләм мин ул юха җыланны, алмыйм дигән булып баланы юри безгә ыргытмакчылар. Без карап үстерсен, янәмәсе. Ыргытмый гына торсыннар әле. *(Кәҗә тоягы күрсәтеп.)* Менә аларга. Тапкан готовый нәнкә. Белә ул безнекенең җебеп төшәсен.

**Баш врач.** Кем инде ул сезнеке?

**Вазыйфа.** Кем булсын — ирем. Монда да ризык тәяп килмәкче. Җибәрдем ди! Ашамый гына торсын әле. Әнә спекулянт әнисе ашатсын.

**Баш врач.** Киленегезне күреп сөйләшергә теләмисезме?

**Вазыйфа.** Минме?... Анымы?.. Мин аны оҗмахта очратсам да, аңардан качып тамугка керәчәкмен.

**Айзарә.** Сезнең кайчан да булса жылаганыгыз бармы?

**Вазыйфа.** Ничек инде ул жылаганым бармы?

**Айзарә.** Кешеләрнең берәр кайгысын, фаҗигасен ишетеп, йөрәгегез әрнеп.

**Вазыйфа.** Кеше кайгысымыни монда! Үземнеке житәрлек. Малаем шуңа өйләнгәч, жылый-жылый күз яшьләрем кипте, күңелем катты.

**Баш врач.** Анысы бит аның фаҗига түгел, Вазыйфа ханым.

**Вазыйфа.** Сезгә әйтүе җиңел. Сезгә моннан тизрәк куып чыгарырга гына кирәк, котылырга гына кирәк.

**Баш врач.** Безнең урында сез нишләр идегез?

**Вазыйфа.** Милиция чакырып, сөйрәп чыгарып аттырыр идем.

**Баш врач.** Димәк, бала сезгә дә кирәкми?

**Вазыйфа.** Юк, кирәкми.

**Баш врач.** Бәлки, яхшылабрак уйларсыз?

**Вазыйфа.** Уйлыйсы-нитәсе юк. Ул бит мәче баласы түгел. Үлеп-нитеп китсә, булыр аннары. Юри үтергәннәр дип судтан судка йөртерләр. Әнисе алсын да карасын, акчасы күп.

**Айзарә.** Сезнең юкмы?

**Вазыйфа.** Ниемә дип сез миңа каныктыгыз әле? Юк дигәч, юк. Әйткән сүземнән кире кайтканым да юк, кайтмыйм да, кайтачак та түгел. Хет асыгыз, хет кисегез. Синсез яшибез, диделәр, минсез яшәсеннәр. *(Балалар елаган тавыш ишетелә.)*

**Баш врач.** Ишетәсезме?

**Вазыйфа.** Чукрак түгел.

**Баш врач.** Ашыйсы килгән нарасыйлар жылый. Аларны әниләре янына алып баралар. Тиздән алар тамаклары туеп тынып калырлар, рәхәтләнеп йокларлар. Ә сезнең оныгыгыз...

**Вазыйфа.** Нәрсә дип әле сез... *(Урыныннан тора.)*

**Баш врач.** Юк. Сез утырыгыз. Тыңлагыз әз генә. Тыңлагыз, тыңлагыз.

*(Вазыйфа утыра. Тыңларга мәҗбүр. Ике Ананың җыры.)*

Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам-багалмам,
Үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры,
Кучәрсеңме син?

**Палатада Валентина тәрәзә төбенә басып форточка аша Саша белән сөйләшә.**

**Валентина.** Саша!.. Такси белән килдеңме? Автобус белән?.. Молодчина. Хәзер жыена башлыйм. Ә?.. Алай тиз генә булмый әле ул. Кәт. Китмә. Нәрсә?.. Ничек икәнен астагы дежурныйдан сора. Ә?.. Әйтәм. Әйтәм. *(Борылып.)* Гульфина апа, Алтынчәч, Саша сәлам әйтә.

**Гөлфинә.** Сора әле, Зарифулла күренмиме?

**Валентина.** Зарифулла абый күренмиме? Ә?.. Ничек инде кайсы Зарифулла?! Белмисеңмени? Гульфина апаның ире? Юк?.. *(Борылып.)* Юк, ди, Гульфина апа.

**Гөлфинә.** Нишләп йөри икән инде, әйтеп жибәрдем ич сеңелгә. Күрсен дә торсын, килеп алмыйча чыкмыйм.

**Валентина.** Сашенька, яратасыңмы мине? Мин дә сине яратам, Сашенька. Ә?.. Юк, менә алмыйсың. Не дури, егылып төшәрсең. Бар, кит тизрәк, миңа жыеныргa кирәк. Кит дим... Ну, Саша, миленький... *(Сашага кул болгап, тәрәзә төбеннән төшә. Бишек җырын көйләп палата буенча йөри.)*

Баю-баюшки, баю.
Не ложися на краю.
Придет серенький волчок
И утащит за бочок...

*(Туктап караватка утыра да.)* Я, кызлар, утырышыгыз. Присядем, друзья, перед дальней дорогой, пусть легким окажется путь. Эчемдә шатлыгым да чиксез, сездән аерылганда жылыйсым да килә. Очрашырбыз микән без тагын?

**Гөлфинә.** Унөченчесен табарга килсәм генә инде...

**Валентина.** Килегез, Гульфина апа. Шушы палатада очрашабыз. *(Алтынчәчкә.)* Син... Син күңелсезләнмә, боекма, Алтынчәч, менә күрерсең, барысы да яхшы булыр. Минем адрес синдә бар. Хат язышыйк.

Айналаен балам-ай,
Айналсын синең анаң-ай...

Менә күрерсең!... Мин сиңа иң-иң изге теләкләр телим!

Алтынчәч. Сиңа да, Валентина. Рәхмәт сиңа!

Гөлфинә. Алтынчәчкә бер дога өйрәттем әле, Валентина. Шул доганы эчтән генә укып Оралбаена карап торса...

Алтынчәч. Гөлфинә апа...

Валентина. Яле, яле, Гульфина апа... Карале боларга, миннән качып дога өйрәнеп яталар. Хәзер үк миңа да өйрәтегез.

Гөлфинә. Синең каратасы егетең юк, Валентина, синеке мәңгелеккә караган.

Валентина. Тфү, тфү, тфү диегез, Гульфина апа,

Гөлфинә. Тфү, тфү...

Валентина. Әйтегез инде доганы.

Гөлфинә. Кузең төшкән егеткә карап торасың да эчеңнән генә болай дисең:

Талкыга салып талкырмын,
Кояшың булып балкырмын,
Килегә салып төярмен,
Сагышка салып сөярмен,

— дисең. Ябыша да кала егетең. Зарифуллага шулай әйттем мин... Килми әле чукынчык.

Нина *(ишектән карап)*. Васильевна, җыенагыз.

Валентина. Ой, кызлар, җылыйсым килә... Гульфина апа, милый мой, дорогой. Яратам мин сезне, Гульфина апа!

Гөлфинә. Я, ярый. Өчәүләп тезелешеп бераз гына утырыйк та... *(Тезелешеп тын гына утыралар. Ике Ананың җыры аларның тынлыгын саклый.)*

Ике кулын куеп алар тезләренә
Утырышып бер, ял итеп алалар да
Тагын эштә,
Тагын шөгыль, мең мәшәкать...
Исән-саулык телик әле аналарга,
Озын гомер телик без аларга.
Баласының йөргән юлы йөзләрендә,
Алар гаме яллар иткән арада да.
Һаман сагыш, һаман борчу, мең төрле уй...
Сабырлыклар телик әле аналарга,
Түземлекләр телик без аларга.

Җырның соңгы юлларында урыннарыннан торып палатадан чыгалар, коридордан үтәләр. Врач кабинеты актыра. Анда Дилемманың энисе Римма һәм Баш врач Зәйтүнә Закировна.

Баш врач. Рәхим итегез, утырыгыз.

Римма. Римма Әүхәдиевна мин.

Баш врач. Бик яхшы... Римма, Дилемма — кызыклы исемнәр.

Римма. Миңа әти кушкан, кызыма — үзем. Сез Зәйтүнә Закировна бит, әйеме?

Баш врач. Әйе.

Римма. Сезнең исем Казанда данлыклы, Зәйтүнә Закировна. Әле үзем киләм, үзем уйлыйм, андый зур кеше белән ничек сөйләшермен инде, дим. Ялгыш сүз ычкындырсам, ачуланмассыз инде, Зәйтүнә Закировна.

Баш врач. Ә сез ычкындырмаска тырышыгыз.

Римма. Шулаймы?.. Сез минем кызым Дилемма турындадыр инде, әйеме?

Баш врач. Әйе. Сез-нең кы-зы-гыз Дилемма турында.

Римма. Бәгырь кисәгем. *(Елап җибәрә.)*

Баш врач. Сез нигә җылыйсыз?

Римма. Ничек инде җыламаска, Зәйтүнә Закировна. Бердәнбер кызым бит ул минем. Ике яшеннән алып бер ялгызым үстердем.

Баш врач. Әтисе нишләде?

Римма. Юньсез булып чыкты кабәхәт. Куып чыгардым. Николай Павлович, Николай Павлович дип кенә тордым үзенә, барыбер кадеремне белмәде. Мин аңа Николай Павлович дидем, ул миңа химера диде. Түздем, түздем дә, әзең булмасын, сатана, дидем.

Баш врач. Кызыгызның бала тапканын белдегезме?

Римма. Ничек инде белмәскә, ничек инде белмәскә, Зәйтүнә Закировна...

Баш врач. Кызыгызның хәлен белергә килдегезме?

Римма. Бик килер идем дә, кертмиләр бит аның янына, Зәйтүнә Закировна.

Баш врач. Котлап язу да җибәрмәдегезме? Кучтәнәч тә китермәдегезме?

Римма. Монда ашатырга тиешләрдер ич.

Баш врач. Кызыгыз баласын алырга теләми, беләсезме? *(Римма тагын елап җибәргәч.)* Туктагыз. Беләсезме, дип сорыйм мин сездән.

Римма. Аның белән сөйләштем инде мин монда кергәнче үк. Тыңлыймыни алар безне. Үзсүзле ул. Башына бер уй керсә...

Баш врач. Тагын сөйләшеп карагыз... Нигә эндәшмисез?

Римма. Тагынмы?

Баш врач. Тагын.

Римма. Шушындамы? Чакырып китерәсезме?

Баш врач. Ерак түгел бит.

Римма. Тик үзегез чыгып китмәгез, ярыймы?

Баш врач. Нигә?

Римма *(паузадан соң)*. Куркам мин аңардан.

Баш врач *(ишек артына)*. Бишенче палатадан Менгличеваны чакырыгыз.

Римма. Сез миңа ничек сөйләшергә икәнен өйрәтеп куегыз, Зәйтүнә Закировна.

Баш врач. Кызыгыз белән сөйләшерлек тә сүзегез юкмыни?

Римма. Ул ике сүз әйтә дә, мин утырып җылыйм. Ә ул җылый да белми, көлә дә белми.

Баш врач. Нигә өйрәтмәдегез соң көләргә?

Римма. Көлеп тумаган баланы ничек өйрәтәсең.

Баш врач. Туганда җылагандыр ич, нигә оныткан?

Римма. Шундый бала инде.

Баш врач. Шундый бала булмый, андыйларны үстерәләр.

Римма. Мине гаеплисезмени? *(Дилемма кергәч, аның каршына барып.)* Дилемма, кызым...

Дилемма. Чего тебе?

Римма. Әнә Зәйтүнә Закировна сөйләшергә куша.

Дилемма. Ну и сөйләшегез.

Баш врач. Утырыгыз, Менгличева.

Дилемма. Нигә миңа утырырга. Минем аның белән сөйләшерлек сүзем юк.

Баш врач. Әниең бит...

Дилемма. Ну и что?

Римма. Менә шундый инде ул, Зәйтүнә Закировна.

Дилемма. Ничек шундый? А сама какая? *(Баш врачка.)* Выпишите меня. А то үзем китәм. *(Чыгарга борыла.)*

Баш врач. Ашыкмагыз, утырыгыз.

Дилемма. Мин әйттем.

Баш врач. Ни әйтим сезгә? Сеңелем диярґә телем бармый. Гражданка Менгличева, сезнең каршыгызда, сезне унсигез ел буе тәрбияләгән әниегез...

Дилемма. Тәрбияләгән?!

Баш врач. Ашатып, эчертеп, киендереп үстергән...

Дилемма. Ну и что?!

Баш врач *(паузадан соң).* Барыгыз, гражданка Менгличева. Бүген сезне чыгарырлар. *(Дилемма чыгып киткәч.)* Ана белән кыз. Шуның өчен, менә шуның өчен яшәдегезме инде сез? Күңелләме сезгә?

Римма. Әйттем бит мин.

Баш врач. Китәргә мөмкин сезгә, Римма Әүхәдиевна. *(Римма китмәгәч.)* Китәргә мөмкин, дидем.

Римма. Мине гаепләп каласызмы, Зәйтүнә Закировна?

Баш врач. Ә сез кемне гаепләр идегез? Китәргә мөмкин.

Римма. Баланы нишләтәсез инде?

Баш врач. Анысы сезнең кайгы түгел. Кызганычка каршы, сез дә, сезнең кызыгыз да безнең җәмгыятьнең члennары. Үз ялгышын җәмгыять үзе төзәтергә мәҗбүр.

Римма. Баланы миңа алырга ярыймы? Закон кушамы?

Баш врач. Закон рөхсәт итә. Ләкин без аны сезгә бирмибез.

Римма. Нигә?

Баш врач. Кешеләр арасына бер имгәк үстереп җибәргәнегез дә бик җиткән. *(Римма елый башлагач.)* Кыланмагыз, гражданка. Чынлап елаган аналарның күз яшьләрен пычратмагыз. Сугыш вакытында Ил, Ватан хакына башларын салган балалары өчен елаган аналар рухын рәнҗетмәгез. *(Римма, төзәтенеп, чыгып китә. Кертмәскә тырышкан Айзарә Әхәтовнаны этеп җибәреп, Исемсез хатын атылып керә.)*

Хатын. Мин риза. Риза мин. Ирем дә алырга риза. Бирегез безгә аны! *(Ике Ана җыры.)*

Гомрең сукмагын зур юллар буйлап,
Өмет йолдызым,
Үтәрсеңме син?
Илеңнең данын Намус, Вөҗданың,
Балам, әй, балам,
Итәрсеңме син?

*(Палатада Гөлфинә белән Алтынчәч. Гөлфинә тәрәзәдән карап тора.)*

Гөлфинә. Бу ниткән эш инде? Зарифулланың вакыты булмаса, сеңелем килергә тиеш ич инде. Врачлардан оят. Бүген киләм, дип язган иде ич сеңелем. Менә шулай инде ул, Алтынчәч айналаем, башны ташка орсаң да баш ярыла, ташны башка орсаң да баш ярыла. Кайтып кына җитим, күрсәтәм бу Зарифуллага. Тагын шул комбаенын ремонтлап ятадыр. Урак өсте җитсә, комбайн ремонтлаудан арынмый. Председателе дә бирми бит шуңа яңа комбайн. *(Айзарә Әхәтовна керә.)*

Айзарә. Я, ничек, матурларым?

Гөлфинә. Килмиләр, Айзарә җаным. Сеңелем килергә тиеш иде. Ишек төбендә күренмиме шунда?

Айзарә. Күренсә хәбәр итәр иде. Сез борчылмагыз. Килерләр.

Гөлфинә. Зарифулла килә алмый инде ул — эше тыгыз. Урак өсте бит. Сеңелем менә нишләп килми икән?

Айзарә *(Алтынчәч янына килеп).* Сез?..

Гөлфинә. Без аның белән сөйләштек, Айзарә Әхәтовна, бер дә борчылмагыз. Аларда бит тәртип хатын-кыз мәсьәләсендә бездәгедән катырак. Әнисенә хат та язып салган идек — җавап юк. Үпкәләве бетеп җитми торгандыр. Әлегә безгә кайтып торабыз. Колхозда какраз кеше җитешмәгән чак. Бездә ясле дә, бакча да бар. Эшли торыр. Өй иркен. Аннан, әнисеннән хат килгәчтенме, болаймы, баласы үсә төшкәч, үзе карар. Бала әйберләрен башта ук монда бирдем, ди. Торалардыр ич?

Айзарә. Кая китсеннәр, әлбәттә, тора.

Гөлфинә. Ну, бу сеңелне! Бала кадерен беләмени ул. Көлеп ятадыр әле, үзе дә чыгар, дип уйлыйдыр.

Айзарә. Борчылмагыз, зинһар, уынмагыз. Вакыт иртә.

Гөлфинә. Чыннан да, әйеме, Айзарә? Килерләр әле... Бу караватларга нигә кертмисез соң әле?

Айзарә. Сез чыкканны көтик инде.

Гөлфинә. Менә әйтәм бит. Ачуланмагыз инде, хәзер килеп җитәрләр... Менә шулай булсын иде ул, әйеме! Мин көтеп торыйм-торыйм иде дә, минекеләр килгәнче, Алтынчәчнең Оралбае килсен дә чыксын иде! Мин килде-ем, Алтынчәч, дип тәрәзәгә кычкырсын иде. Оралбай исемле Алтынчәч кызының әтисе. Бик әйбәт егет, ди Алтынчәч әйтә... Әкиятләр нигә чын булмый икән ул, Айзарә Әхәтовна?

Айзарә *(Алтынчәчнең башыннан сыйпап).* Кем белә, бәлки булган хәлләрне әкият итеп сөйлиләрдер кешеләр. *(Алтынчәчкә.)* Бер дә борчылмагыз, барысы да сез уйлаганча булыр.

Нина *(керә).* Калаубекова, сезгә килгәннәр. *(Алтынчәчкә язу бирә.)*

Гөлфинә. Әстагъфирулла дип әйтер иде, Валентина булса. Укы, укы тизрәк, Алтынчәч айналаем. *(Алтынчәч нишләргә белми язуны кулында тотып тик тора.)*

Айзарә. Сабыр, сабыр. Тынычланыгыз, Алтынчәч. Менә шулай, шулай.

Гөлфинә. Бир, Алтынчәч, үзем укыйм.

Алтынчәч. Үзем. *(Язуны сакланып кына ача, укый.)*

Гөлфинә. Оралбаймы, Алтынчәч бәгырь кисәгем?

Алтынчәч *(паузадан соң).* Апа белән җизни.

Гөлфинә. Җыен инде тизрәк. *(Айзарә Әхәтовна белән Нина.)* Җыештырыгыз инде аны, нәрсә карап торасыз.

Айзарә. Кабаланмагыз, диләр сезгә.

Гөлфинә. Кабаланмасам, унике баланы табып бетерергә ничек вакыт җиткерим ди мин. Күреп торасыз лабаса, Алтынчәч үзе бернишли алмый. Алтынчәч, борчылма. Борчылма, Алтынчәч.

Нина. Шактый ук үзәккә үттегез сез минем, апа. Бераз гына утырып торырга буладыр бит.

Гөлфинә. Сагынырсыз әле, Нина, сагынырсыз. Әнә теге караваттагы кебекләр күбрәк кергәләсә, сагынырсыз. Кил әле, кочаклыйм әле бер үзеңне. *(Нинаны кочаклап.)* Икенче малаема хатын булып киләсеңме безгә?

Нина. Берсекенгә кәтегез.

Гөлфинә *(көлеп Нинаның аркасыннан сөя дә тәрәзә янына килә).* Күренмиләр чукынчыклар. *(Кинәт кычкырып җибәрә.)* Киләләр!.. Киләләр!.. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау. Алтысы үземнеке. Җиденчесе үземнең Зарифулла, сигезенчесе сеңелем, тугызынчысы кияү. Барысының да кулында чәчәк. *(Айзарә Әхәтовна белән Нинага.)* Чәчәкләре сезгәдер инде ул. *(Караватка утыра да кинәт елап җибәрә.)*

Айзарә. Менә инде тагын! Көлеп йөрдегез, йөрдегез дә...

Алтынчәч. Гөлфинә апа...

Нина. Комедия...

Гөлфинә. Карагыз әле, китмәделәр микән?

Нина *(тәрәзәдән карап).* Торалар тезелешеп.

Гөлфинә. Кыр казлары кебекме?

Нина. Юк, солдатлар кебек.

Гөлфинә. Айзарә җаным, әйтим инде шуларга бер сүз.

Айзарә. Ярый, әйтегез.

Гөлфинә *(тәрәзә төбенә менеп, форточкадан кычкыра).* Зарифулла! Ишеккә барыгыз, ишеккә... *(Күз яшьләрен сөртә-сөртә тәрәзә төбеннән төшә.)* Айдарның борынын да сөртмәгәннәр.

Нина. Булдымы? Әйдәгез. *(Палатадан чыгалар. Коридордан үткәндә Баш врач очрый.)*

Баш врач. Киттегезме, гүзәлкәйләр? Хәерле юл!

Гөлфинә. Алтынчәч. Бик зур рәхмәт сезгә! *(Китәләр.)*

Баш врач. Айзарә Әхәтовна, килгәннәр бит.

Айзарә. Кемнәр, Зәйтүнә Закировна?

Баш врач. Менгличеваның кайнанасы, улы белән... *(Аларның сөйләшкәнен ашыйсылары килгән балаларның елау тавышы баса. Ике бишек яңадан аска төшә. Ике Ана аларны тирбәтеп бишек җырын дәвам итәләр.)*

Әлли-бәлли, бәллием.
Йокла, балам, нәнием.
Тәмләп йокла, бәбием,
Сакта тора әниең.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

Пәрдә.

## Хисам Камалов

# БЕЗНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР

РОМАН



Мостафинның кереп, сыйланып чыкканын сизде дә, Зангир иркенәеп китте һәм колбаса белән ак күмәчкә үрелде.

— Син әйт, сукин сын, минем хатын чибәрме?— диде Асоев, авызына папирос каба-каба. Асоев шулай бер дә көтелмәгән сораулар биреп, Зангирдан нәрсә булса да тагы беләсе килә, берәр яшерен сер ычкындырып куймасмы, дигән хәйләсе дә бар иде.

— Карасу ак йөзле, көрән чәчле, чикләвек төсле коңгырт күзле...

— Ә тагы, тагы?

— Аларына инде минем агач телем җитми...

— Шул шул. Ну башта ялындырды да соң үзе, йөрәгемдә шул җөй һаман сулкылдап куйгалый...

— Чибәрләргә эшең төшмәсен.

— Алай түгел. Без аның артыннан өч егет йөрдек. Ну, мин тегеләрнең кулыннан аны каерып алдым.

— Катя апа шуңа торырлык та.

— Ләкин мин аңа үземне ярәттырып өлгерә алмадым. Бары бер ай гына торып калдык. Мин аны беткәнче яраттым, ул мине яратырга житешә алмады, шуңа күрә бүтәннәргә дә каравы бар. — Асоевның тавышы калтыранды. — Әх, кайтып булмады! — Ул тәмәке төпчеген ниндидер ачу белән идәнгә ташлады да тынып калды. Зангир аның күзләре яшь элпәсе белән мөлдерәгәнен күреп алды, карашын читкә борды. Асоев тирән итеп бер көрсенде дә Зангирга төбәлде.

— Син ник карашыңны читкә борасың, ә? Әллә Катя апаң белән ниме... — дип мыгырданды. Зангир башта аны шаяра дип уйлады, ныклабрак караса, теге бик җитди йөзле, әмма шактый мәлҗерәгән.

— Валлаһи... ышанмыйсыңмы? — диде Зангир, күзләренең агы елтырап китте.

— Сиңа ышанам, Зангир! — дип, Асоев көләргә тотынды. — Мин үземә ышанмыйм, шуннан чыгып әйтәм. Ярар, минем анда күзәтчеләр бар, язарлар...

— Юк, андый булырга тиеш түгел, фәрештә кебек ул.

— Алып кайткан бүләкләргә исе китмәде дисең бит. Бу зерәгә түгел.

— Ул бит сине көткән, аңа син кирәк, әйбернең кадерен белеп тә житкермидер.

— Дөрес әйтәсең, сукин сын,— диде ул яратулы тавыш белән. Зангир, тышта ниндидер тавышлар ишетеп, өстәлдәге ризыкларны җыештырып алды. Асоев, җилкәләре салынып, берни күрми торган караш белән уйланып утыра бирде.

— Кәпәгә кайчан барабыз? — диде Зангир, аны авыр уйлардан арындырыр өчен генә.

---

Ахыры. Башы 4—5 саннарда.

— Иртәгә. — Асоевның тавышы сүлпән чыкты, йокламаудан кызарган күзләре дә, менә йомылам, менә йомылам, дигәндәй, тәмам арыганнар иде. Ул кузгалып, өйнең плащ-палатка белән бүленгән ягына атлады, әз генә ял итмичә берни дә эшли алмас кебек иде. Ләкин аңа караватына барып сузылырга ирек бирмәделәр, ашыгыч приказ белән ике сержант килеп керделәр.

## 6

Кешеләр карулашып, үз дигәннәрен итмәкче булалар, үз фикерләрен өстен чыгарырга тартышалар, читләшеп бетәләр. Ачу коралар, бер-берсенә яныйлар, һәрберсе үз кырыгын кырыклап, дәгъва куптара. Кайсы эш өчен чын күңелдән янып йөри, кайсы җәмагать эше эшләүче төсенә кереп, астыртын гына үзенең дан-дәрәҗәсен кайгырта. Бу нәрсә кешеләр булган һәр җирдә шулай булганга, алгы сызыкның икенче эшелонында торган тупчыларда да шулай иде. Әмма сугыш кешеләрнең ыгы-зыгы, тынгысыз яшәвенә үзенең кулын искәрмәстән китереп сала һәм аларның бар тырышлыкларын мәгънәсез бер эш итә дә калдыра. Кинәт бер төнне немец самоходкаларының оборонаны өзүе хакында приказ килде. «Барча тырышлыклар җилгә очты»,— дип кайгырды Идрисов, приказны алгач, «Егетләр харап булды»,—диде Тафтилов та башын тотып. Ләкин начарның бер яхшы ягы да була, диләр бит. Немец танкларының безнең тылга үтеп керүе көтмәгәндә хәлне бик нык кискенләштерде. Танкларга каршы куярлык тупчы расчетлар бик өтек иде. Шуңа күрә җанлы көч белән тулыландырып өлгертелмәгән батареяларга ярдәмгә комендант роталарындагы сугышчыларны алып бирделәр. Танкларга каршы бөтен өмет тупчыларда иде. Бу исә Ляшков һәм Каракүз өчен дә бәхетле очрак булды, аларны берсүзсез үз батареяларына кайтардылар.

Немецлар сентябрьдә безнекеләрне кысрыклап Ауце, Добэле шәһәрчекләрен алуга ирешкәннәр иде. Ә хәзерге ниятләре ачык күренеп тора: шул ике шәһәрне тоташтырган юлны тулысынча үзләренеке итмәкчеләр.

Ул таш юл тупчылар урнашкан җирдән ерак түгел иде, шуңа хуҗалык, штаблар үз урынында калып, пушкаларны гына күчерделәр. Дөм караңгы төн, туплар гөрселди, офыкта утлар елдырымы чагылып китә, ә җирнең калтырап куйганын аяк табаннары гына сизә. Идрисов пушкалар таккан машиналары белән тиешле урынга килеп җиткәндә, Мостафин разведчикларга обстановканы аңлатып тора иде инде. Ул тиз-тиз пушкаларны кая, ничек урнаштыру турында әйтте дә икенче батареяларга китеп барды. Алты батареядагы утызлап пушканы туры наводкадан танкларга атарлык итеп җайлы позициягә кую ансат эш түгел. Монда барча бәла ихтималын алдан исәпкә алырга туры килә иде.

Караңгыда пушкаларны кая каратып куярга белмәделәр. Идрисов, Мирхас һәм тагы бер-ике разведчик немец танклары килердәй юнәлешне эзләп йөрделәр. Тапкач, позицияне күзалларга мөмкин була башлады. Шуның өчен әзерләп куйган кебек, юлдан сигез йөз метрлар чамасында сузылып киткән чаука урман бар иде, пушкаларны яшерергә бик әйбәт булды. Анда җир туңы да юка гына иде. Бар сугышчылар үзләрен бик киеренке хис итә, сүзләр әз, булганы да кискен һәм ачулы чыга. Көрәкләрнең ташка тиеп киткәне, кайсының ютәлләгәне ишетелеп кала, еракта төнге самолетлар ташлаган бомбалар гөрселди.

Идрисов Ляшков пушкасына килде. Тегеннән кайткач, ул аның белән сөйләшергә өлгерә алмаган иде. Ни эшләде икән, үзенең гаебен таныймы, бераз басынкыланып, акылга утырып кайтканмы? Әмма Ляшков нәкъ элеккеге кебек шат күңелле, бер дә кикриге шиңгәнгә охшамый, кем беләндер әрепләшә-әрепләшә чокыр казый иде. Ул үзенең гаебе турында

сүз башлар, минем алда уңайсызланып калыр дип уйлаган иде Идрисов, ләкин теге комбатны шәйләмәгән дә кебек булып, снаряд әрҗәләре өчен чокыр казучы белән шаяра иде:

— Казы, казы, ник тәрәлдең?

— Сулыш алырга ирек бир, син бигрәк...

— Тылда тәмам симереп беткәнсең, артык май организмга зарарлы.

— Беләсең әбиеңнең келәсен. Син белгәнне мин турап элгән.

— Менә иртәгә немец танклары ми тартмаларыңны юдыртып алыр, бөтенләй яңадан тугандай булырсың.

— Мин алардан шүрләмим, өркетмә.

— Шүрлисең дип әйтмим, әмма миеңне чайкаштырып алганда әйбәт буласы, валлаһи.

— Үз башыңны кайгырт, кеше башы — чакма ташы.

— Ә синең баш — буты ташы, аңардан бер чаткы чыгарыйм димә!

Идрисов теге комендант ярдәмчесен тавышыннан танып алды, агачлар арасыннан аларга якынайды. Ярдәмче күкрәк тиңентен тар гына траншеяда иде, Идрисовны күргәч, зарланырга тотынды.

— Иптәш комбат, сержант мине шелтәләмәсен әле?

— Ничек бирегә эләктегез? — диде Идрисов бу хәлгә бераз аптыраган сыман. Әмма гаҗәпләнерлек берни дә юк икәнен шунда ук төшенеп алды.

— Замполит яңа пополнениедән миңа бирде аны,— диде Ляшков эре генә.

— Иптәш комбат,— дип башлады теге. — Минем гаебем юк, мин ярдәмче генә бит, әгәр үз кулымда булса... Нигә ул миңа кычкыра?

— Синең гаебең юк, ә аның приказы — сиңа закон.

— Иптәш комбат...

— Приказны үтәгез,— диде Идрисов кырыс тавыш белән, аннары Ляшковны читкәрәк алып китте дә, әрепләшү, үчләшүнең мәгънәсе юк, бетер, дип нык кына кисәтеп әйтте. Теге елмайды, җилкәләрен кыймылдатып, юк, мин бары шаярттым гына, дигәнне аңлатып, пушкасын урнаштырырга китте. Идрисов аңа ышанды, Ляшковның андый вакчыл егет түгел икәнен яхшы белә иде. Әмма кешене, бигрәк тә Ляшков ише эчендә көче ташыган, шул ташкын ирегенә бирелергә генә торган кешене белəм дип әйтүе кыен. Шулай уйлап атлаганда Ляшков аның артыннан куып җитте.

— Иптәш комбат, нигә мине ачуланмыйсыз? — диде сәер генә. Үзе елмая иде, ак тешләре ялтырап күренде. Идрисов йомшак тавыш белән:

— Син үзеңә-үзең җәза бирдең инде, Ляшков,— дип, аңа карады. Аның артык ачык сөйләшергә теләвенең серен аңламакчы булды.

— Беләм, соңыннан талкырсыз әле?

— Юк, телгә дә алмам.

— Нигә: «Яңадан тәртип бозмасаң», дип әйтмисез? — дип куйды Ляшков ничектер бик моңсу рәвештә. Идрисовның нечкәртеп торырга вакыты юк иде.

— Аңлаганга тукмак кирәкми,— диде, китә башлап. Ляшков нәрсәдер әйтәсе килгән шикелле итенде, әмма комбатның ашыгуын күреп, дәшмәде, өметен өзгәндәй, кулын селтәде дә калды. Ә күңелендә әллә нинди шиккә охшаш борчулы гамь туган иде. Нәрсәдән бу? Комбатның ачуланмавыннан ниндидер начар мәгънә табарга маташты ул. Юкка гына түгел бу, дип, яманга юрыйсы килде. Лейтенант дәрәҗәсен җуйганына тамчы да көенми. Урыныннан кузгатылып тузынган уйлары: тиргәмәде, миннән өмет өзгән, димәк, мине рәтле кешегә санамый, дигән нәтиҗә чыгарды һәм аның күңеле чын кимсенү кичерде. Аннары каршы дулкын рәвешендә: ярар, мин сезгә күрсәтермен әле, дигән горурлык хисе килде һәм уйларындагы каршылыклы авырлыкны бетергәндәй булды. Ә җир казу аны тәмам тынычландырды, берничә вакыттан соң ул тагы комендант ярдәмчесен юри шаяртып сөйләшә башлады.

Идрисов күзәтү пункты ясаучылар янына килде. Мирхас, Әнвәр һәм яңа килгәннәрдән икәү казый-казый янып пешкәннәр. Мирхас һаман ашыктыра, бер кат түшәмле тар гына блиндаж әмәлләгәннәр, аңа ялгап траншея сузалар. Кайбер командирлар түшәменә бер рәт кенә агач җәйгән блиндажга керергә дә теләмиләр, аларга кимендә өч кат накат булсын, солдатның көчен җәлләмиләр. Идрисов алай түгел, ул блиндаждан канәгать калды, тик күзәтү пункты дошман кételгән якка табарак, шактый алда эшләнгән, җайсыз булмас микән, дип шикләнеп куйды ул, әмма уен беркемгә дә белгертмәде. Әнвәргә элемтә сузарга, Мирхаска стереотрубаны җайларга кушып, Зарипов пушкасына барып кайтырга уйлады. Караңгыда кантарлы җирдән атлаганда элемтәче Мөслимовның тагы тылда калуына эче тырналды. Бик хәйләкәр нәрсә, судагы балык кебек кулдан шома гына ычкына. Бу юлы да теш сызлый, дип санбатка китеп, әллә нинди сылтаулар тапты...

Зарипов һәрвакыттагыча бөтенесен булдырган, пушка да чокырга җайлап утыртылган, блиндаж һәм траншея да казылган. Сугышчылар блиндажга кереп ятканнар, хәл җыялар. Зарипов үзе ишек төбенә тезләнеп утырган да тәмәке тарта, бөтен кыяфәте арыган солдатларны борчымауны үтенә сыман иде. Ул ничектер балаларының йокысын саклап торучы анага охшап калган. Аның үз карамагындагы кешеләр турында бик кайгыртучан булуын Идрисов күп мәртәбәләр шәйләде. Һәм ул солдатларын эшләтә дә белә иде. Аның пушкасы тирәсендәге пөхтәлек һәрчак сокланырлык була. Үзе күп сөйләшми, алга чыгып күренергә, үзен күрсәтергә тырышмый. Менә кемне лейтенант дәрәҗәсенә күтәрергә кирәк булган, дип уйлады Идрисов аның янына чүгәләп. Зарипов батареяга күптән килсә дә, ничектер күзгә-күз сөйләшергә вакыт тимәде. Бу операциядә үзен әйбәт кенә күрсәтсә, һичшиксез, дәрәҗә бирергә кирәк, дигән карарга килде ул. Немец танкларының йомшак җире кайда дип төпченеп сорашты. Бу төпченүе дә аның эшлекле булуыннан килә иде.

— Самовар—күмердән, кеше гомердән туймас, ди, шуның кебек... — дип, Зарипов сүзен әйтеп бетермичә көрсенеп куйды.

— Әллә син семьялы кешеме? — диде Идрисов, аның сәер генә сүзен үзенчә аңлап.

— Күзле-башлы идем, иптәш Идрисов, ләкин сугыш алдыннан гына бозылыштык.

— Болай үзең җайлы, күндәм күренәсең...

— Эш болай булды, яшерен-батырын түгел, иптәш Идрисов. (Ул «иптәш Идрисов»ны ничектер үзе белән бер коллективта эшләүче якын танышына әйткән кебек итеп әйтә иде.) Безнең беренче балабыз туды. Тупырдап торган малай. Әбиләр кунакка чакырып яздылар. Без Кукмарада яши идек. Беләсезме, Кукмара ни дигән сүз? Ике мари дигән сүз. Мин мәктәптә военрук, хатын — итек басу артилендә хисапчы. Шулай Сәрдеккә кунакка киттек. Хатын баланы бик нык юрганнарга төреп, чанага печән өстенә салды. Ә барып җиткәч алып карасак бәбәйне, ни күзебез белән күрик — үлгән. Йөзе күм-күк төскә кергән иде бичараның, тыны бетеп харап булган. Хатын, җубалгы нәрсә, аны төргәндә бөтенләй томалап куйган... Нишлисең? Шуннан сүтелдек без. Тырышып карадык, оешып булмады. Ул риза, тик минем бәгырь катты. Ышанасызмы, сугыш дуслаштырды безне. Мин Сталинград тәмугында булдым, ниндидер могҗиза белән әллә ничә тапкыр үлемнән калдым. Һи, андагы мәхшәрне күрсәгез! Шунда үземә сүз бирдем. Исән чыксам, Саура белән дуслашам. Галәмәт кырылыш иде анда. Хәзер нәрсә, һөҗүмгә барасың, немецның бер самолеты күренми, ул чагында кара болыт булып килә иде,һәр квадратметрның астын-өскә әйләндерә, ник бер җан иясе калсын!.. Шуннан бирле хат алышабыз. Тәмам акылга утырды кеше. Әле менә хатынга посылка салырга йөри идем, авырган, бераз дарулар да юнәттем. Әгәр мин тегеләй-болай булсам, шуны өйгә салдыртырсыз әле, ә?




*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

Зарипов комбатны бик якын итүдән генә шундый гозерен әйтә иде, әмма бу үтенеч Идрисовның кинәт ачуын кузгатты. Ни дип җавап бирергә белмичә торган хәлдә башында уйлар йөгереште. Акыллы гына күренгән бу кешедән шундый мәгънәсез сүз чыксын әле. Димәк, ул мине һичшиксез исән кала, дип исәпли икән. Ни өчен мине шулай кимсетә торган уйлар килә аңа? Мин блиндажда яшеренеп ятмыйм ич ут өермәсе вакытында. Нәрсә әйтәсең инде моңа? Кеше никадәр чыныккан рухлы булмасын, үлемгә бирешәсе килми шул.

— Алдан ук җир астына кермик әле,— диде салкын, коры тавыш белән Идрисов.

— Юк, төрлечә булуы ихтимал, дим...

— Төрле хәлнең миңа да булуы ихтимал түгелмени?

— Соң гозерне сезгә әйтми кемгә әйтәсең, иптәш Идрисов — Зарипов нинди дер моңсу гаҗиз тавыш белән әйтте. Идрисовның бөтен ачу-шикләре бетте дә куйды. Командирның исән калуын күпсенү аның уенда да булмаган, ахрысы. Идрисов, шуңа эчтән уңайсызланып, бүтән пушкаларны барларга ашыкты...

Дошман көтелгән тарафта урман кара стенадай тора иде, шул караңгылыктан ракета чөяләр, якында гына! Әллә танклар килеп тә җиткәннәр микән дигән шик җанны чеметеп ала иде. Бик ашыгыч нәрсәдер эшләргә кирәклекне бөтен барлыгың белән тоясың. Шуңа күрә Идрисов үзенең күзәтү пунктына йөгерде. Анда элемтә сузылган булырга тиеш иде.

Мостафин бик тыныч сөйләште, ракеталарны ул бая ук күреп алган икән. Аңа шундый ук фикер килгән, тик менә берни дә әйтә алмый әле. Командасыз ут ачмаска, дип трубканы куйды ул.

Таң беленеп килә, гади күз белән дә якын-тирәне күрергә була. Әнә алардан бер сигез йөз метр чамасында таш юл аксылланып сузылган, әз генә арырак күл булырга тиеш. Идрисов стереотрубадан карады. Әһә, әнә ул. Юл исә, күлне кочагына алырга теләгәндәй, аны дугайлап уза да каршыдагы ике тау арасындагы үзәнгә кереп китә шикелле. Күл каршында ярлар бик текә, танклар үрмәләрлек түгел икән, җете кызыл балчык төсе белән соры кырлардан нык аерылып тора. Менә шул ике тау арасындагы юлны миналап, танк үтмәслек итсәк, шәп булачак, билләһи дип Идрисов окулярдан күзен алды.

Шул чак аяк астындагы җир дерелди башлады. Стереотрубада Мирхас иде, ләкин берни дә күренми дигәнне аңлатып кулын селкеде.

— Урман буе бик шикле,— диде Идрисов, җир, дерелдәве көчәя баруын бар тәне белән тоеп. Юк бит, дип Мирхас стереотрубаның «мөгез»ләрен төрле якка боргалап маташты. Әмма шунда җир дерелдәвенә каяндыр астан килгән чиркандыргыч икенче гөрелдәү тавышы да кушылды. Ул гөрелдәү һаман якыная барды. Карасалар, ниндидер аксыл болыт каршыга килә сыман иде, әмма бераздан ул болытның танклар тәгәрмәченнән күтәрелгән тузан икәнен шәйләп алдылар. Танкларны юлдан килерләр дип көткәннәр иде, ләкин алар юлга нәкъ перпендикуляр рәвештә кырдан хәрәкәт итәләр. Пушкалар исә танклар юлдан килгәндә янтыкларына атарга исәпләп куелган. Күзәтү пункты да уң флангка, алга ук барып казылган иде. Хәзер болар барысы да файдасыз бер эш булып калды. Танкларның нәкъ тупларга капма-каршы, маңгай белән килүләре дә әйбәт нәрсә вәгъдә итми иде. Маңгайдан бәреп аларны җимереп булмый, алгы бронялары снаряд ала торган түгел...

Тузан болыты күлгә табарак авышып якыная бара. Анда Мостафин дүртенче, бишенче, алтынчы батарея тупчыларын урнаштырган булырга тиеш. Аның күзәтү пункты исә күлнең бу ягындагы чаука урманда булса кирәк. Ул төштән бөтен нәрсә уч төбендәге кебек күренә инде.

Кинәт тузан болыты бетте, танклар күренде, алар болынлыктан барганга, тузан күтәрелми иде. Ничә танк монда? Берәү, икәү, өчәү... Юк,

санап булырлык түгел, бер-берсен узышып күл буендагы юлга ыргылалар. Әһә, әнә бернечә самоходка күзгә чалынып китте, алар арттанрак киләләр икән. Менә шулары инде аның иң куркынычлары! Алдагы танклар юлга төшеп, күлне дугайлап үтә торган җиргә борылдылар. Нәкъ шул моментта тау буендагы безнең пушкалар дәррәү бер залп бирде.

Башланды!

Бар нәрсәне изеп таптап ташларга килгән котырган дулкын, нәрсәгәдер бәрелеп, капылт артка тибәрелгәндәй булды. Немецлар исләренә килеп өлгергәнче туплар өермәле ут аттылар. Ул арада бер танктан төтен күтәрелде. Шушы хәл немецларны аңга китерде булса кирәк, алар җимерелмәс самоходкаларын алга чыгарып ата башладылар. Ә җиңелрәк танклар флангларга ябырылды. Ничек тә ут божрасыннан ычкынырга телиләр иде.

Моны күзәтеп торган Идрисовның аркасын кайнар елдырым сызып үтте. Өерелеп килгән уйлары миен пешерде. Ул икеләнеп торганда, немец снарядлары алар позициясен теткәләргә тотынды. Бу әле прицелсыз ут иде. Шулай да элемтә өзелде. Идрисов бер минутлык каушавын җиңеп, танкларга каршы ут ачарга боерды. Шул боерыкны җиткерергә Мирхасны күзәтү пункты янындагы тупчыларга йөгертте, үзе иң куркыныч булган сул флангка чапты. Бераз киткәч тә иелә-бөгелә линияне ялгап йөгерүче Әнвәрне очратты. «Әгәр штабтан шалтыратсалар Мирхаска әйтерсең, ул миңа җиткерер»,— диде Идрисов ашыга-ашыга... Әнвәр ияк кагып, элемтә чыбыгын үзенә тартып карады һәм, снаряд шартлаганын җиргә ятып көтеп торды да, сирәк куаклык арасында юкка чыкты.

Идрисов ерактан ук күрде: Зарипов пушкасы торган җирне шартлаган снаряд төтене, актарылган балчык тузаны каплаган иде. Йөрәге сикереп-сикереп тибәргә тотынды: әллә һәлак булганнармы? Якынрак килеп, пушканы һәм бик тыныч кыяфәтле Зариповны күргәч, шундый шатланды. Өстәвенә Зарипов приказны көтеп тормас борын ук танкларга ут ачкан. «Нинди молодец, нинди молодец!» — дип сөйләнде ул, сөенечен эчендә генә калдыра алмыйча. Аңа рәхмәт белдерәсе килде аның, әмма Зарипов прицелдан карап, төзәп маташа иде, комбатны күрмәгән дә кыяфәт белән торды. Баш очыннан гына, йөрәк яргыч тавыш чыгарып, дошман снарядлары очалар да әз генә арттарак ярылалар. Зарипов төзәп бетергәч, биноклен алга төбәде, кул ымы белән рычагны тартырга кушты. Зарипов-ның кулы тагы кыймылдады, шул мәлдә яңа снаряд замокка кереп бикләнде. Тагы ату. Шулай бер минут эчендә дүрт тапкыр йөгерек ут яудырдылар.

Икенче минутта бинокльдән күзәткән Зарипов:

— Расчет, ышыкка!! — дип кычкырды. Шап-шоп килеп пушка кырыендагы тар траншеяларга сикереп төштеләр. Идрисов та шунда атылды. Нәкъ шул мәлдә биш-алты метрда гына снаряд төшеп шартлады, барысын да балчык кантары белән коендырып алды. Ярчыклар лафет, казенник тимерен сыдырып, буявын кубарганнар. Сызылып киткән ак эзләр канлы ерткыч тырмашкан җирне хәтерләтәләр иде. «Менә ичмаса чын командир»,— дип уйлады Идрисов, үзен күрмәвенә дә исе китмичә Зариповка сокланып. Расчетын саклый да белә, эшләтә дә белә!.. Зарипов эченнән нидер тәкърарлагандай, үз алдына караган, нәрсәгәдер тулысы белән йотылган иде. Эчтән нидер исәпли шикелле, иреннәре кыймылдый, саргылт йөзе катып калган сыман, ул дога укучыга ошап калган. Әллә минутларны саныймы? Идрисов аны бүлдерергә базмады. Менә Зарипов тагы кыска һәм үтемле итеп команда бирде:

— Расчет, атарга әзерлән!

Тагы йөгерек ут ачтылар. Идрисов траншеядан күтәрелеп, биноклен күзләренә куйды. Зарипов аткан танкны шәйләп алды. Танк атар өчен уңайлырак урын эзләп бер як тәгәрмәче белән әз генә калкуга килеп, менде генә, Зариповның ике снаряды бер-бер артлы шунда килеп тиде, трагын

эштән чыгарып ташлады. Әмма танкның башнясы исән, ул пулеметтан, пушкасыннан ата ала. Шуңа күрә Зарипов ул акылын җыйганчы аңа тагы өч подкалибрный снаряд тондырды... Аннары үзенең ниндидер эчке сиземләвенә буйсынып, ышыкка посарга команда бирде. Баягы кебек тагы немец снаряды бик якында гына шартлады. Әгәр яшеренмәгән булсалар, берсе дә исән каласы булмаганлыгы шунда ук ачык күренде. Бу Зариповның бер-бер хәйләсе бармы әллә, дигән уй килде Идрисовка. Әлбәттә, бернинди дә хәйлә юк иде, бары дошман техникасын, аның ату тизлеген, төзәргә, корырга күпме вакыт тотканлыгын яхшы белү генә бар. Моны һәркем дә булдыра алмый шул. Идрисов траншеяда вакытта Зарипов расчетындагы сугышчыларга күз төшерде. Әллә орудие командиры артык катымы, аңардан шүрләпме алар барысы да шулай тиз эшлиләр? Әмма төсләрендә бер дә андый нәрсә сизелми. Алар батареяга Зариповтан соңрак килгәннәр иде, ләкин яшь булулары һәм эш арасында шукланырга яратулары белән бик тиз танылып киттеләр. Монда үлем астында да өшәнеп калмаганнар. Һаман шаянлыкларын итәләр. Немец снаряды башка тиярлек булып бик хәтәр сызгырып үткәндә берсе каскасын салган да икенчесенең чалбар төбенә китереп тоткан, үзләре шырык-шырык көләләр. Битләре корымга, балчыкка буялып беткән, тик тешләре генә ялтырап китә.

Зарипов тагы ут ачарга әзерләнеп, команда биргәндә, Идрисов икенче пушкага ашыкты. Аның командиры һәм расчеты гел яңа килгәннәрдән генә тора иде. Аларның танктан куркалармы, юкмы икәнен Идрисов чамалый алмаган иде, кылларын тартырга вакыт тимәде. Курку бик хәтәр, хыянәтчел нәрсә. Иң кискен минутта ул кешенең тез астына суга.

Барса, ни күрсен: пушка тик тора, ә расчет үзенең командиры белән кечкенә блиндажга кереп поскан. Комбатны күргәч, үз гаепләрен тойгандай агарынып торып бастылар. Йөзләрендә таркаулык, үз-үзләреннән канәгать түгеллек, күзләре уңайсызланып читкә төбәлгән. Орудие командиры хәзер үк пушка янына чыгарга һәм дошман танкларына ата башларга тиеш иде. Ләкин ул нидер көтә сыман. Аңа приказ җиткерелгән, үтәргә көче җитмәгәнме? Әһә, аларга курку үзенең тырнакларын батырып өлгергән. Әнә бит берсе дә өскә, үлем уены шашынган җиргә чыгарга, пушкага тотынырга базмый тора. Мәхшәр эчендә калганда кайчак каушап төшү була ул, тик менә андый моментта акылын җуймаган, ихтыярын йомшартмаган, мәлҗерәп төшмәгән бер кеше булырга тиеш. Әгәр арада куркып калмаучы берәү табылса, шул җитә, аның курыкмавын күреп, бүтәннәр дә курыкмый һәм бөтен эш әйбәт бара...

— Сукин сыннар! Нәрсә көтәсез?! — дип кычкырып җибәрде Идрисов. Аның тавышы фаҗигале һәм кискен яңгырады. Шул сүз тегеләрне хәрәкәткә китерде һәм алар курку тырнагыннан ычкынып, умарта күче шикелле җан койгыч ярчыклар чыелдап торган җиргә чыктылар. Өчесе дә Идрисовтан өлкән, аларны картлар дияргә була. Әллә ничә яраланып, әллә ничә госпитальдә тернәкләнеп чыгып, өченчеме-дүртенчеме тапкыр алгы сызыкка килүләре булса кирәк. Әле утка кереп, әле уттан могҗиза белән котылып, тәмам каешланып беткәнгә охшыйлар. Боларның бернигә дә артык исләре китми шикелле. Курыксалар да шул үлемнән генә шүрлиләр булыр.

Идрисов бинокле белән алны күзәтеп, кычкырып прицелны әйтергә тотынды. Алда бер самоходка яны беләнрәк торган хәлдә уң флангка ата иде, аның дикъкатен ничек тә булса бирегә юнәлтергә, аны саташтырырга кирәк. Әмма орудие командиры, озынча битле тәбәнәгрәк сержант, әкрен кыймылдый, бүтәннәре дә шактый үшәннәр. Болай эшне төгәл эшлиләр, ләкин дәртләре сүнгән, ничектер күз аклары да кызганыч булып ялтырап киткәли, әмма аларны һич җәлләргә ярамый иде. Танк бирегә төбәлеп килсә — бетте баш, дип пошынды Идрисов.

Өченче снарядны самоходканың чылбырына тигерделәр. Ул янындагы чокырга чүмәлебрәк китте. Пушкасыннан ике-өч минут ата алмый торачак. Тигезләнергә кирәк әле аңа. Шул вакыт эчендә аңа тагы берничә снаряд җибәрергә була... Әһә, самоходканың уң як чылбыры өзелгән икән, моны бинокльдән Идрисов ачык күрде һәм расчетка кычкырды:

— Молодцы! Шулай кирәк!

Картларның да буыннары языла башлады шикелле, йөзләренә өн чыкты. Битләрендә өркүнең соры төсе бөтенләй калмаган иде. Үз көченә ышану, изге бурычны үтәүдән туган җан канәгатьлеге күзләрендә очкынлана иде. Орудие командиры үзен тәмам кулга алды, төгәл, мөстәкыйль боерыклар биреп, расчетын да кулында тота башлады. Ул алны күзәтеп, анда немец пехотасының күбәюен шәйләде, шул борчуын комбатка әйтте. Идрисов, баядан бирле бу нәрсәдән курыкканлыгын эчтән искәреп, осколочный снаряд белән атарга боерык бирде. Үзе уң флангка китте. Болар янына Тафтиловны җибәрергә булыр, дип ныклы карарга килеп атлады.

Көчле ут киртәсенә килеп бәрелгән немец танклары, читлеккә эләккән ерткычлардай, төрлесе-төрле якка ташланып, ычкыныр юл эзли башладылар. Ут йомшаграк булган төшне чамалыйлар иде. Кайбер калын бронялысы, үзенең җимерелмәслегенә ышанып, изеп ташлау нияте белән орудиеләргә таба хәрәкәт итте. Каракүз дә үзләренә төбәлеп килгән бер танкны күреп алды. Әйе, шик юк, аларга шуыша. Сержант бераз атуны туктатып торды, нәкъ шул минутта танктан аткан снаряд, башка тияртимәс дигәндәй, хәтәр ыжгырып узды да арттарак шартлады. Йә ул сине, йә син аны, менә хәлнең шулай торганлыгы ап-ачык иде. Каракүз, бар тәне кымырҗып, эссе-суыклы булып китте. Иптәшләренә борылып, танк туп-туры безне таптарга килә, дип кычкырды. Тегеләр эшне тиз-тиз эшләргә тотындылар. Каракүз башта танкның киртләчләнеп күренгән башнясына төзәп атты. Җимереп булмаслыгын белә торып шулай эшләде, чөнки бу прицел өчен кирәк иде. Бер тапкыр прицелны дөрес алгач, аны уңга, сулга, алга, артка күчерү кыен түгел. Ул өченче снарядны башняның киртләченә тигерде. Аннары тәгәрмәченә эләктерергә теләп, тагы өч подкалибрныйны җибәрде. Юк, авызын корт чаккыры, танк, гигант бер ерткычтай, сыртын калтыратып кына куя да алга таба шуыша иде. Үзе һаман ата, тик снарядлары арттарак ярыла, менә шуның аркасында гына Каракүз пушкасы исән кала. Юкса... Ул кабат тәгәрмәченә тигерергә теләп, өч снаряд тондырды, әйбәт кенә эләкте шикелле танкка, юк, һаман килә. Инде нишләргә? Ничек аны әз генә борылырга мәҗбүр итәргә? Аның ян бронялары юкарак булырга тиеш... Каракүзнең тәмам җен ачуы чыкты. Ул хәйләгә керешә. Танкның нәкъ алдына тиз-тиз өч фугасный снаряд атты һәм шактый тирән чокырлар ясап куйды. Хәшәрәт, хәзер борылмыйча гына үтә алмассың. Һәм шулай булды да. Танк бөтен гәүдәсе белән уңгарак борыла башлады, подкалибрный снаряд көпшәдә иде инде, Каракүз окулярда танк шәүләсе килеп кергәнне бар дикъкатен җигеп көтеп торды һәм рычаг бавын тартты. Ул снарядның танк янтыгына тигәнен шәйләде һәм: «Вәссәлам!» — дип кычкырып җибәрде. Төтен җәелеп беткәчрәк караса, ни күрсен, танк тураеп алга үрмәли. Тфү! — диде Каракүз, кан төкереп. Ул артык киеренкелектән телен тешләп канатканын да сизмәгән иде. Аның күзләре тиле кешенекедәй зур булып ачылды, сулышы сызгырып чыкты, бар тәне, мускуллары, үлем алды көче белән куәтләнде. Хәтәр кыҗрап танкның бара торган юлына өчдүрт фугасный белән тагын чокырлар тезеп куйды. Теге ихтыярсыздан әкрен генә авыр сынын борды, нәкъ шул минутта аның янтыгына тагын подкалибрный снаряд белән сылады ул. Шунда тәмам хәле киткәнен сизде сержант, бар тәне мунчала кебек йомшап каядыр ишелә иде. Танктан аткан снаряд, бер-ике метрда гына төшеп, шартлау дулкыны аны яндагы траншеяга алып ташлады. Башы каты бәрелгәнен сизде, торып

тезләнде, зиһенен җыеп торды, танкның мотор тавышын ишетмәде. Яраланган немецларның кычкырулары аны реаль хәлгә кайтарды, фрицлар тавышын шәп аера ул. Димәк, танк беткән, әмма торып карамыйча ышанмады. Үрмәләп пушкасы янына килде, алга карау белән өч йөз метрлар чамасында гына тынып калган танк калгып торганын күрде. Шунда ул тагы бер көче беткәнлеген сизде, иптәшләрен күзләре белән эзләде, тик бернинди җан иясе дә юк иде. Ул аларның үзләре казыган траншеяда күмелеп калуларын сизмәде, үз хәле бик авыр иде. Эчендә туган бушлыктан лафет тимеренә башын куйды да үксергә тотынды. Тыела алмыйча кычкырып-кычкырып елый иде. Күңеленә тулган ачу, үч кинәт барлыкка килгән тынлыкта шулай бушана сыман иде. Снарядлары дошман танкларын җимертә алмаганга да, үзенең чослыгы җитмәгәнгә дә хурланып елый иде. Гүя кемнәрдер аны бер нәрсәгә ышандырганнар, ә гамәлдә бүтәнчә килеп чыккан, шуңа алдануына гарьлегеннән тыела алмыйча ачыргалана иде.

Идрисов уң флангка барганда, тавыштан чамалап, ату бераз сүрелә төшкәнен белде, әмма автомат «чытырдау»ларының көчәюен ишетеп бик нык борчылды. Бу хәтәр нәрсә иде. Әмма үзең барып күрмичә берни белеп булмый хәзер, бар җир соры төтен, корым белән капланган. Шуңардан көн дә караңгыланган иде. Кинәт куе чаукалык арасындагы сукмактан Тафтилов килеп чыкты, ул өч сугышчы иярткән, тик үзенең төсе-өне беткән, шинеле, итекләре пычракка баткан. Пополнениегә яңа килгән сугышчыларны сафтан чыкканнар урынына орудие саен билгеләп йөри икән.

— Ляшковта коточкыч! — диде ул җиргә тезләнеп, сулышын көчкә ала-ала. — Икене аңа калдырдым.

— Һаман керәләрме?

— Бер самоходканың трагын җимергәннәр, әмма һаман атып ята. Мин Зәйнуллинны комулятив снаряд алырга җибәргән идем, җитешә алмас, ахры, әле генә безнең танклар һөҗүмгә киттеләр...

— Чынмы?! — дип, Идрисов сөенеченнән тезләнгән урынында тыпырчынып куйды. Як-ягына каранды. Дөрестән дә, урманда танк эзләре күп иде.

— Теге картлачларга барам,— диде Тафтилов җирдән торып. Идрисов хуп дигәнне белгертеп ияген какты да үз юлына ашыкты. Безнең танкларның һөҗүмгә керүе аны сизелерлек шатландырган иде. Ләкин аңа Ляшков янына барып җитәргә язмаган икән, бераз киткәч тә артында гына немец снаряды шартлады да көчле дулкын аны башы белән бер төпкә китереп бәрде... Ул әллә ни хәтле вакыттан соң гына аңына килде.

Идрисов сул флангта, Мирхас Ляшковка булышып маташкан бер арада, җәяүле немецлар, бронетранспортерга төялеп, шактый алда урнашкан күзәтү пунктына якынлаштылар. Траншеяда Әнвәр һәм тагы бер пулеметчы гына иде. Немецлар көтмәгән яктан гранаталар атып, үрмәләп килделәр. Өченче гранатадан тегесе пулеметы-ние белән траншеяга ишелеп төште, Әнвәр контузия алып исен җуйды. Әмма немецлар шунда ук чигенергә мәҗбүр булдылар, безнең танклар килә иде. Немецлар Әнвәрнең җаны барлыгын шәйләп, безнең траншеяга чаклы җиткәнлекләрен күрсәтү өчендерме, аны үзләре белән әләктереп киттеләр.

Ә соңгы минутта Ляшковның орудиесе җимерелде, бер як тәгәрмәче күчәреннән өзелеп әллә кая очкан иде. Үзе нинди дер могҗиза белән исәнимин калды. Эш шунда: ул нәкъ вакытында кырыйдагы траншеяга сикереп төшә белде. Моны аңы белән эшләмәде ул, ә ниндидер сизү инстинкты аны траншея төбенә алып аткан иде. Солдатта шул эчке сизем булмаса, бу мәхшәрдә, гомумән, бер кеше дә исән калмас иде.

Ляшков куллары белән өстендәге балчыкны шап-шоп кага-кага траншеядан күтәрелгәндә, кырыйга безнең танк килеп туктады. Башня ачылып, аннан яралыларны чыгара башладылар. Танкка снаряд тигән, ләкин зарарламаган, тик әчтән чуен кубып, шуның ярчыклары ике танкист-

ны яралаган икән. Аларны җиргә төшереп бәйләгәч, танкист механик Ляшковны күреп алды.

— Пушкадан ата беләсеңме? — диде әллә шаярып, әллә чынлап.

— Беләм шикелле,— дип, Ляшков танкка таба атлады. Бу бер карауда үзенә ышаныч уята торган ягымлы, киң битле егет белән сөйләшәсе килеп китте аның. Яралыларны озатырга куша ахры, дигән уй башында чагылып узды.

— Әйдә, утыр! Күрәсең пушкарьны. Монда шайтан да ярдәм итмәс... — Ул чыбык-чабыклар өстендә бер уфылдап, бер ыңгырашып ятучы яралыга ымлады. Ляшков тегене шаяра дип уйлап, туп-туры күзен текәп тора. Юк, теге шаярмый, чынлап әйтә икән. Моның формаль таләпләргә туры килмәвен белеп кыстый. Ул һөҗүмнең уңышлы баруы белән гаять дулкынланган, чигенүче дошман өстенә барырга атлыгып тора иде. Аның эчкерсез кутәренкелеге Ляшковка да тәэсир итте, ул да җиңү дәрте дулкынында иде, җаны омтылыш белән тулы. Ике уйларга яратмаган Ляшков танкистның тәкъдименә шунда ук риза булды һәм, болай эшләргә ярамаганлыгын аңының бер почмагы аңа эчтән искәртсә дә, үҗәтлеге үзенекен итте, танкка менеп утырды. Ә механик нииндидер ярсу белән газ бирде һәм алар алга ыргылдылар. Аның янында утыручы радист командиры белән элемтәгә керде, задание алдылар. Танк зур тизлеккә күчеп элдерде генә. Ляшков триплекстан карап алны күзәтеп барды, төзәү һәм ату приборларының үз орудиесеннән бик аз аерылуына сөенә-сөенә, кулын эшләтеп карады, башня механизмын да барлап чыкты. Ләкин чигенүче немецларның ничектер күренмәве барган саен күңеленә шик сала иде. Башта танкистлар үзләре беләләрдер дип, үзен юатты. Аннары ниндидер сөрмәгән, кантарлы җиргә килеп кергәч, радистка төртте.

— Без дөрес барабызмы?

— Элемтә югалды,— диде радист, наушнигын салып. Механик машинаны туктатты. Рациянең кечкенә лампочкасын яндырып карта-километровкага карадылар.

— Монда шайтан үзе белсен! — дип куйды механик үзләренең кайда булуларын тәгаенли алмыйча.

— Әнә алдагы урман лейтенант әйткән җир булырга тиеш,— диде радист ышанычлы тавыш белән. Ляшков һаман күзәтә иде. Шул урман буен тагы бер кат күздән кичергәндә моннан ерак та түгел уң кулдарак өч зениткаңың һавага төбәлгән көпшәләрен күреп алды. «Зениткалар!» — дип кычкырып җибәрде ул, тегеләр дә триплекска ябыштылар. Зениткалар янында йөгерешкән шәүләләр дә күзләренә чалынмый калмады. Танкны күреп алганлыклары ачык иде.

— Немец тылына килеп чыкканбыз, монда шайтан да ярдәм итә алмас; — дип, механик өч катлы итеп сүгенде. Ул арада немецлар ата да башлады. Киеренке момент килеп туды, нишләргә? Өчесе дә башларын нык эшләтә иде, йөзләре караңгыланып китте. Механик, исен җыеп, танкны уйсурак җиргә алып төште, моннан тәгәрмәченә тигерә алмыйлар, каршы атарга җайлы гына. Ляшков, башка чара юклыгын аңлап алып, зениткаларга бер-бер артлы ике снаряд җибәрде. Зениткалар кечерәк калибрлы булып, танк башнясы өчен әллә ни куркыныч түгел иде, шуңа күрә Ляшков бик иркенләп эш итте. Өченче снарядны кырыйдагы зениткаңың нәкъ өстенә төшерде.

— Молодчина! — дип кычкырды хуплаудан тыела алмаган механик. Ляшков чынлап та шәп ата иде. Иң элек икенче зениткаңың кырыена стена кебек өелгән кәсләрне туздырып ташлады, өченчеме-дүртенчеме снаряд белән тегене бөтенләй җимерде. Шушы уңыш механикны хәтәр кайнарлатып җибәрде, ул артык дәрәҗәдә дәртсенеп танкны зениткаларга таба алып китте. Ә артка чигәргә кирәк иде, ялгышларын бик соң аңладылар...

Танк атмый торган өченче зениткаНы борыны белән бәреп аударды һәм тәгәрмәчләрен издереп узды. Тегендәрәк немецларның үлгән гәүдәләре күренә, ә мотор тынган арада яралыларның кычкыруы колакны ярды.

— Давай артка киттек! — дип кычкырды Ляшков. Механик каршы килмәде, танкны килгән эзгә борып, алып бара башлады. Ләкин шул чакта танкка арттан атарга тотындылар. Бер снаряд тиеп тәгәрмәч чылбырын өзеп ташлады. Тегендәрәк тагы зениткалар булган икән. Механик астагы люктан чыгып карады һәм йөрәк ачысы белән сүгенде, аның тавышыннан хәлнең өметсез икәне аңлашылды. Радист аппаратын ходка җибәреп азапланды, юк, микрофонга кычкыра-кычкыра тәмам тавышы бетте, ул тоташ ысылдый гына иде.

— Ремонтларлык түгелме? — дип сорады Ляшков.

— Монда шайтан да берни эшли алмый,— диде механик, ачы үртәлү белән сүгенә-сүгенә. Ляшков якындарак бер җимерек блиндаж күреп алган иде, әллә шунда качып торыргамы, дип уйлады, чөнки танкны немецлар хәзер бик тиз яндырачаклар.

— Ну каптык! — дип ысылдады радист, наушнигын башыннан салып атып бәрде.

— Көйсезләнмә,— диде механик, тегенең йомшаклыгын шушы бер сүз белән кистергәндәй. Ул автоматын барлап, запас дискы алды. Ляшков кул пулеметын эләктерде. Сүзсез-нисез аңлашып, астагы люктан шуышып чыктылар. Ляшков алданрак үрмәләп, аларны үзе шәйләгән блиндаж җимереклегенә алып керде. Өчесе дә еш-еш сулый, эчтәге киеренкелек сөйләшергә дә ирек бирми, тыннарын кыса. Ляшков көчкә әйтте:

— Караңгы гына төшсен, аннары... — сүзләре өзелсә дә аңлашылды, тегеләрнең күзләрендә өмет ялтырады. Немец зениткасы һаман ата иде, ахырда танкның моторын яндырды. Аннан куе кара төтен бөркелә башлады. Шул сигнал булды, немецлар, нидер кычкыра-кычкыра, танкка якынайдылар. Танктан атучы булмагач, тагы да кыюланып, кырыена ук килделәр. Янәсе, янган танктан барыбер чыгачаклар. Шуны өмет итеп «рус капут», дип кычкырыналар иде. Чыгучы озак күренмәгәч, алар як-якларына карана башладылар. Ляшков сизеп алды, аларны табачаклар һәм шуңа күрә тиз генә пулеметын җайлап куеп, немецларга очередь бирде. Танкның берьягындагы фрицлар, чалгы белән киселгән үләндәй, кыелып төштеләр. Буталыш, кычкырыш китте. Күз бәйләнеп килә иде инде. Шушы уңайдан файдаланырга теләп, механик автоматыннан ата-ата күтәрелде, алга йөгереп үтмәк булды. Аның артыннан Ляшков белән радист та чыктылар. Ләкин танкистлар бер нәрсәне исәпләп бетермәделәр: танкның икенче ягында фрицлар исән калганнар икән. Автомат уты механикның нәкъ күкрәгеннән тишкәләп үтте, ул өч-дүрт адым киткәч тә җиргә барып төште, бүтән кымшанмады. Ляшков та яраланып ауды, радистка да каты эләккән иде, ул әкрен генә тезләнде, бер якка янтаеп җиргә ятты, гүя йокыга әзерләнә диярсең. Ляшков шуышып артка чигенгәндә аның үлем белән тартышып гырылдаганын ишетеп калды. Кан агуын да тоймыйча, Ляшков әле байтак вакыт немецларга атып маташты. Бер мәл аның чокырына гранаталар оча башлады. Менә кинәт янәгына кемдер нәрсә беләндер бик каты суккан кебек булды, күзеннән утлар күренде, шуннан соң аңын караңгылык каплады...

Ике көн узгач, бу төшләрдән немецларны чигендерделәр. Болар яңа частьлар иде. Кыр уртасында аунап яткан гәүдәләрнең кемнәр, кайдан икәнен күпме белергә тырышсалар да булмады. Фрицлар аларның барча кәгазьләрен, хәтта погоннарын да йолкып алып киткәннәр иде. Шул билгесез-атсыз көе күмделәр.

Ә батарея алга күчмәде, үз позициясендә калды. Ул шактый нык өтелгән иде, күп кенә сугышчылар сафтан чыккан, пушкаларга да зыян килгән. Теге картлар расчетының имгәтелгән тубы гына янтаеп ята, ә кешеләре юк. Гәүдәләре дә күренми. Кечкенә генә блиндажларын авыр снаряд актарып ташлаган. Кырыенда гына тагы зур снаряд чокыры. Шулардан һәлак булып, күмелеп калганнар, ахрысы.

Идрисов, шартлау дулкынына эләгеп, нык кына барып төшсә дә тиз исенә килде, әмма башы түмәр кебек булып каткан иде. Җитмәсә күзеннән тоташ яшь агып тора, тавышларны да су астындагы шикелле тонык ишетә. Ул күзәтү пункты блиндажына кайтып керде. Мирхас кырык бишле пушка гильзасыннан эшләнгән лампага ут элдереп маташа иде. Идрисов, бүреген салып, башын ике куллап уарга тотынды. Мирхас ни әйтергә белмичә торганда телефон зуммеры безелдәде. Комбатны сорыйлар иде. Идрисов кулын селтәде.

— Комбатка контузия булды,— диде дә Мирхас трубканы куйды. Ул арада берничә сугышчыны ияртеп, кулына термос тоткан старшина килеп керде. Сугышчыларның өннәре юк, чырайлары җансыз, үлек төсендә иде...

Каракүз Ляшковны эзләп йөрде. Таба алмагач, нигә эзләтмисез, дип старшинага бәйләнде.

Ляшковны юксынып, аны җәлләп күз яшьләре агып чыкты. Мирхас та ул гаярь егетне яратып өлгергән иде. Бигрәк тә комендант часовоена капчык кигертә алуы, акылсыз эшләнгән булса да, кызыгырлык батырлык иде. Госпитальдә яткан комендант начальнигы: күрсәтегез миңа ул куш йөрәкле егетне, кочаклыйсым килә үзен, дип әйткән, имеш.

Иртән Мирхас тәнендә нindидер җиңеллек тоеп уянды, башы да томаннан ачылган сыман иде. Ул автоматын алып блиндаждан чыкты һәм сугыш кырыннан Ляшковны тагы бер мәртәбә эзләп кайтырга уйлады.

Таш юлга чыгып, артына борылып карады. Кичәге сугыш кыры уч төбендәге кебек күренә иде. Җимерелгән, кайсы яндырылган немец танклары кырда чүмәлә сыман булып калганнар. Тукта, ничә танк? Кичә Идрисов унбер диган иде. Берәү, икәү, өчәү... Чынлап та шулай икән. Сытарга, изәргә, кан коярга ыжгырып килгән корыч ташкын туктатылып, асты-өскә китерелгән. Комдив Мостафин мактаулы немец танкларына шәп тозак ясаган икән. Ай-һай! Гаҗәпләнмәслек тә түгел, күл яны һәм юл кырыйлары тәмам танклар каберлегенә әйләнгән.

Мирхас юлдан читкәрәк чыгып, һәрбер снаряд чокырын карап бара башлады. Ляшковның танк десантына кушылып китү ихтималын исенә төшереп, үзенең бу эзләнүен аклый иде. Менә ул бер авиабомба чокыры янына килеп туктады. Ни күрсен, чокыр төбендә саргылт төстәге танксыман нәрсә ята. Тукта, көпшәсе юк икән бит, дип уйлап, Мирхас аяк астындагы зур кантарлар артына тезләнде. Анда немец яшеренеп торуы бар иде. Ләкин беркем дә күренми. Мирхас саклык өчен генә теге машина өстеннән бер очередь бирде. Кинәт брезент өсле кабинка ачылды, аннан кулларын күтәреп бер немец килеп чыкмасынмы. Мирхас йөрәге дөп-дөп килгәнен, тәтедәге бармагының калтыранганын сизде. Немец юка гәүдәле, кечкенә буйлы иде. Килеп ябышса да моны чөеп атарга була, дигән уй килде башына һәм ул тынычланып карап тора башлады. Немецның зәңгәрсу шинеле җиргә тиеп-тиеп килә, йомшак балчык ишелә дә аягы таеп киткәли. Чокырдан менеп җитәрәк ул нәрсәдер әйтергә тотынды. Ара ике-өч метр калгач, Мирхас:

— Хальт! — дип кычкырды. Теге туктады да, күзләрен зур ачып, бер сүзне кабатларга кереште:

— Корошо машино, машино корошо... яволь! — Үзе һаман теге вездеход ягына ияк какты. Мирхас машинаның төзек икәнен аңлап алды. Бу немецның тәмам коты алынып сугышчан рухы сынганлыгын да чамаларга була иде. Мирхас куллары белән: бар, машинаңны алып мен, дип

аңлатырга кереште. Теге башта аңламыйча күзләрен тасрайтып торды, аңлагач йөзендәге сорылык яктырып киткәндәй булды. Ул куштанланып: «Яволь, яволь»,— дип кабатлады, кызу-кызу машинасы янына төшеп китте. Мирхас моның бер-бер хәйләсе бардыр, дип, бик сагаеп, кантар артына тезләнгән көе тегеннән күзен алмады. Менә ул машинаны кабинада килеш кенә кабызды да өскә таба хәрәкәт итә башлады. Бу тәбәнәк кенә, ләкин киң итеп эшләнгән, ачык тимер кузовлы вездеход иде. Мондагы сазлыкларда, пычракларда снаряд ташырга моңардан да җайлырак транспорт булмастыр да. Чокырдан чыгып җиткәч, немец кабинканың икенче ишеген ачты, «Комм, комм...» — дип, Мирхасны чакырып, ниләрдер сөйләнде. Мирхас һаман да шикләнеп торды, тиз генә чамалап алып, кузовка сикереп менде һәм немецның артына автоматын төзәп чүгәләде. Немец аңа борылып команда көткән кебек карады, Мирхас алга барырга күрсәткәч, йөзе тагы яктырды.

— Гут, гут! — дип әйтә-әйтә машинаны шактый кызу алып китте.

## 7

Әнвәрне немецлар машина кузовыннан алып, бер базга китереп ыргыттылар. Ул башы белән барып төште һәм шунда аңына килде. Дөм караңгы, асты лычкылдап торган юеш иде. Борынын бик әче ис ярып керде. Маңгае авыртканга тотып караса, бөтен җире кутыр, кул тигерүгә кан саркый башлады. Нишләде соң ул, ни булды аңа? Әнвәр моннан берничә сәгать элек булган хәлләрне хәтеренә төшерергә азапланды. Ул блиндаж янындагы траншея борылышында басып тора иде, якында гына гранатамы, минамы шартлады, ялкыны күзенә чагылганы хәтерендә, шуннан соң берни белми... Шушы минутта үзенең дошман кулына эләгүе, коточкыч хәлдә икәне аңына барып җитеп, мең-мең энәләре белән миенә кадалды. Бөтен тәне бизгәк тоткан кебек калтырый башлады. Бер кулы белән икенче кул чугын тотмакчы була, дерелди-дерелди бармаклары ычкына иде. Бетүем шушы икән, дигән уй бөтен күңелен кылыч белән телгән кебек итеп узды. Һәм ул бар йөрәге белән әрнеп, кычкырып-кычкырып еларга тотынды. Эчтән бик каты рәнҗү, үз-үзен каһәрләү дулкыны аны тетрәтә иде. Ул тыела алмыйча үкседе. Башында бар кануннар җимерелеп төште, дөньяның асты-өскә килде. «Беттем, беттем», — дип пышылдады ул елый-елый. Газапламый гына атсалар атсыннар иде... Уйларының шул төшендә Әнвәр үз хәленең болай яшь коюдан яхшырмаячагын, хәзер болай өзгәләнү берни дә бирмәячәген исенә китерде. Бик аек акыл, кырыслык белән эш итәргә кирәклеген тойган хәлдә, уйларын әнә шул нәрсәләргә юнәлтте. Сорау ала башласалар нәрсә дип әйтергә? Ни генә белә инде ул? Элемтәче икәнемне әйтергә ярамый. Кичә генә пополнение белән килдем һәм мине снаряд ташырга куйдылар дияргә. Часть номерын кесәдән алган кызылармеец кенәгәсеннән белгәннәрдер инде. Барыбер атачаклар, шуның өчен белмәмешкә салынырга кирәк. Аның русча сөйләшә алмавын үзләре дә күрерләр. Хәрби мәгълүматлар белән генә калмыйча, аның кайдан, нинди семьядан икәнен төпченсәләр, нишләргә?

Әнвәрнең әтисен үз елгылары белән сугышка алмадылар, чөнки аягы бигүк сәламәт түгел иде. Тагын аның бер энесе дә бар иде. Гражданнар сугышы вакытында, аклар чигенгәндә бер бай аңы үзе белән алып киткән. Шулай алар Кореяда бүленеп калганнар. Фин сугышына чаклы аларга еш кына хатлар, ара-тирә посылкалар да килгәләде. Әнә гел үзе белән йөрткән, аксыл сөяк саплы, әллә ничә җәпле кесә пәкесе дә Шәрифҗан абзыйсы бүләге. Сабының ике битенә дә кореячамы-кытайчамы язулар язылган. Кайчак посылкада ситсы-мазар да була иде. Ләкин фин сугышы башланыр алдыннан бер хаты килде дә шуннан

элемтә өзелде. Гарәп хәрефләре белән язган ул хатта нинди хәбәрләр булгандыр инде, әтисе бик уфылдап, сөмсере коелып йөрде. Фронтка алмасалар да әтисен хезмәт армиясенә җибәрделәр. Кайсыдыр шәһәрдә бер заводта эшлим дип яза иде. Аның күптән түгел килгән хатын әнисе Әнвәргә салган, анда әтисе авырып больницага кердем, хәлем әйбәтләнә инде дигән сөенеч белдергән иде...

Боларның барысын да төпченерләр микәнни? Сөйләргәме, юкмы? Барыбер атачаклар бит?.. Ул җәй көне Латвия чигендә яраланып, Великие Лукидан ерак түгел тимер юл буендагы бер авылда госпитальдә ятты. Бик шәп ашаталар, тәрбиялиләр иде. Әнвәр тиз аякка басты. Дөрес, башта бер айлап чамасы сул аягын һич яза алмады, шуңа күрә гел култык таягы белән йөрде. Яраны бәйләтергә дә көчкә-көчкә генә бара иде. Ярадагы көнбагыш төшедәй вак ярчыкларны чүпләп алган саен аягы әйбәтләнә барды. Ядрәләр балтыр сеңерендә утырганга, күбрәк хәрәкәтләнгәндә авырттырып шешәләр һәм үлекләп чыгалар иде... Юк, боларын сөйләтеп тормаслар, синең яраларың нәрсәгә аларга? Ә белмәгән нәрсәләр сорап кыйный башласалар, нишләргә? Түзәргә, түзәргә? Йа хода, чыдамлык бир, чыдамлык бир!

Шул минутта әнисе исенә төште. Әни мине догаңнан ташладыңмы әллә? Мин бит сине бер тапкыр рәнҗеткән идем, сабан туена чыгарга яңа чабата ясап бирә алмадым, киреләндем. Шуңа бик ачуың килгән иде. Әх, нигә киреләндем, үҗәтләндем икән? Шул мизгелләрдә миңа карата күңеленә начар уйлар килгәндер. Нәрсәгә дип сүзеңне тыңламадым соң? Искә төшерә китсәң андый чатаклыклар шактый булгалады бугай.

Ә батареяда минем кисәк югалуымны ничек дип белерләр икән? Менә бит күрәчәгең булса. Һич уйламаганда-нитмәгәндә нинди бәлагә каласың икән? Ярар, бер мин генә түгел, миннән күпкә яхшы кешеләр дә үлеп кала әле. Тик бу фашист-ерткычлар нык газапларлар инде. Асат үлем нинди зур бәхет булыр иде... Түзәргә, түзәргә!..

Кинәт шапылдаган тавыш аның уйларын бүлде. Шунда базга кыштырдап, кайдадыр сыдырыла-сыдырыла нәрсәдер килеп төште. Мине алырга килгәннәр икән дип уйлады Әнвәр, тәне тагы бизгәк тоткандай калтырый башлады. Теше-тешкә бәрелеп шак-шок килә иде. Шул чак җир стенага ышкылган һәм балчык ишелгән тавыш килде һәм мыгырданып сүгенгән аваз ишетелде. Кемдер русча өч-дүрт катлы итеп каргана иде. Әнвәргә кинәт җан кергәндәй булды, аны алырга килгән кеше болай сүгенергә тиеш түгел. Ул терсәкләренә таянып кыймылдап куйды.

— Кем бар монда? — диде сагайган һәм коты очкан тавыш.

Алар бик тиз аңлаштылар.Башка төшкән коточкыч бәла бер-ике сүздән үк берләштерде. Бу латыш солдаты икән. Өч атна гына элек алгы сызыкка килгән булганнар. Әнвәр латышлардан торган полкларның немец белән сугышканын ишеткән иде, шулай да бу егетнең сүзләренә ышанырга да ышанмаска да белмәде. Ул яшь, гайрәтле кеше бугай, сөйләгәндә күз аклары яшен чаткысыдай ялт-йолт килеп торды. Бер төн һәм көне буе траншеяда постта торган, кич алмаш килгәч, черем итәргә блиндажга кергән. Төнлә уянып китсә — немецлар... ике самоходка белән искәрмәстән һөҗүм иткәннәр...

— Барыбер качам,— диде ул, тешләрен шыгырдатып. — Безнекеләр моннан ерак түгел...

Аның сүзләреннән Әнвәргә нindидер өмет чаткысы кайткандай булды, бу егеткә ышанасы килеп, мине дә үзеңә иярт дип ялварасы килде. Ә теле үзенең ничек бу хәлгә таруын гына сөйләп бирде. Шулай да эченә җылы үрләде, карале, мондый мөмкинлек тә бар икән ләбаса, диде эченнән генә шуңа сөенгәндәй. Качып барганда атсалар да үлгәнеңне сизми каласың...

Уйлардан һәм киеренкелектән тәмам ватылып, эттәй арып, нindидер бер минутта оеп кителгән, баз өстендә нәрсәдер дөбердәгәнгә дерт итеп

куйдылар. Базның капкачы ачылган икән, өстән немецча кычкырган тавыш ишетелде. Шул тавышка латыш кузгалып баскычка килде. Әнвәр дә аңа иярде. Сау бул, әни, бәхил бул, эти, син дә исән бул, мине бүтән күрә алмассыз инде, дип, эчтән дога укыган кебек кабатлый-кабатлый өскә үрмәләде ул.

Караңгы иде әле, ләкин таң беленеп килә икән инде, әйберләрне якыннан танып була. Баз авызыннан бераз читтәрәк, юан гына немец, күкрәге турындагы автоматын боларга төбәп, басып тора иде. Тирә-як сирәк урманлык, тегендәрәк поход кухнясы учагыннан ут ялтырап күренә. Латыш егете саргылт чәчле, таза гына түгәрәк битле, буе уртача, әмма җилкәләре киң, көчле икәне күренеп тора. Үзе качканда мине дә алырмы икән, дип шикләнеп, Әнвәр аны күзәтә иде. Латыш немецча да аңлый икән, сакчы нәрсәдер әйткәч, аңа җавап кайтарды. Алар утын кисәргә тиешләр икән, кухня янында маташучысы пычкы һәм балта күтәреп китерде. Ул, аяклары кешәнләнгән шикелле, табаннарын җирдән шудырып-шудырып кына хәрәкәт итә иде. Үзе пош-пош килә, йөрү аңа гаять авыр бугай. Икенче немецның да сул кулында кара перчатка, монысы да инвалид микәнни? Ул урман эченә күрсәтеп, нәрсәдер әйтте, латыш Әнвәргә карады да: әйдә, диде. Урман эченәрәк кереп кисәргә икән дип уйлады ул һәм аягын атлауга «Уф!!» дигәнен сизми дә калды. Сул аягында ботинка юклыгын күреп, аптырап, латышка дәште. Теге аңа таба борылуга эшне тиз аңлап алды һәм, аның аягына иелеп, тубыгын ыштыр белән бәйләшергә булыша башлады. Әнвәр, эче өзелеп, болай ничек качармын, дип уйлады. Латыш мине ияртмәс, үзе генә элдерер, нишләргә соң, нишләргә? Кая төшеп калды икән ул ботинка, шайтан алгыры!.. Әнвәр шулай, эчтән карганып, зарланып үзенә көч бирә, өметен көчәйтә иде.

Урман эченәрәк кереп, җирдә яткан бер бүрәнәне кыска гына түмәр итеп кисәргә тотындылар. Әмма пычкы һич кисми, үтмәсләнеп беткән, аннары разводы да юк иде. Әнвәр бер кечкенә агачка пычкы эзе ясап, шуның белән пычкы тешләрен эләктереп-эләктереп, як-якка каерып-каерып чыкты. Пычкы, начар киссә дә, әйбәт йөри башлады. Әнвәр утын ярырга да бик оста иде, җиргә тезләнеп утырды да кыска түмәрләрне җәһәт кенә ваклап атты. Шул шакмакларны капчыкка тутырдылар һәм кухняга китерделәр. Латыш егете су эчәргә сорап казан янына атлаган иде, аш пешерүче немец эт өргәндәй кычкырып җибәрде һәм боларның өс-башына төртеп күрсәтеп, якын килмә дигәндәй, кулын бутады. Автоматлысы исә тагы нәрсәдер һау-һау килде һәм базга керергә ымлады. Өсләрендә баз капкачы шапылдап ябылгач, латыш егете ачынып төкеренә-төкеренә сүгенде:

— Канэчкечләр, кеше ашаучылар!..

Бераз тынып ятканнан соң Әнвәр әйтте:

— Никтер сорау алыр төсле күренмиләр?

— Без нәрсә беләбез соң! Безнең көзге чебеш икәнне күреп торалар ич алар?

— Нишләтергә уйлыйлар алайса?

— Үлгәнче эшләтергә, аннары озатырга.

— Кая?

— Шуны да белмисеңме? Теге дөньяга.

Шунда җирне дер селкетеп танкмы, чылбырлы трактормы килгәне ишетелде. Кухня янына туктап торды да, бар төшне дерелдәтеп, китеп барды.

— Кухняны передовойга алып китте,— дип, нәтиҗә ясады латыш егете. Әнвәр эндәшмәде, аның җавап кайтарырлык та хәле калмаган иде. Ачлыктан аны әллә нинди йокы баса. Хәл бетү инде бу, дигән зәгыйфь кенә уй килә аның башына һәм шунда ук бу уе томан белән күмелеп югала. Шулай озак кына вакыт үтте бугай, тагы җир дерелдәгәнгә һәм мотор

тавышына ул уянып киткәндәй булды. Латыш егете дә аркасы белән җир стенага ышкынып кыштырдады. Кинәт Әнвәрнең башына тәвәккәл бер уй килде.

— Урманга тагы алып барса, автоматлыга кинәт ташланыйк та, коралын алыйк,— диде Әнвәр пышылдап. — Аның бер кулы гарип бугай.

— Мин дә нәкъ шуны уйлап ята идем,— дип, латыш җанланып китте һәм һөҗүм итә калганда иң элек нишләргә кирәген бик тәфсилләп сөйләп алды. Аннары бу башсызлыкларының уңышлы чыгуына шикләнүен белгертеп: — Монда немецлар мыжлап торадыр шул,— дип өстәде.

— Һәй, барыбер бетәсе бит,— диде Әнвәр, кыюланып, һәм аның күз алдына немецка ничек арттан килеп сугуы, тегенең чайкалып барып төшүе килеп басты. Карале, нәрсәгә куркып торырга? Әнвәр үз уйларыннан үзе кызышып фрицка ни рәвешле һөҗүм итәргә кирәклеген барлы-юклы теле белән латышка аңлатырга тотынды.

Базның өсте дебердәп ачылды, өскә менәргә кушып, теге немецның тавышы ишетелде. Чыгуга автоматлысы аларга зәңгәр төстәге ике немец шинеле ыргытты, кияргә ымлады. Болар бераз аңламаган булып тордылар да, өсләрен салып, чокырга ыргыттылар һәм немец шинелен киеп алдылар. Таза, яңаклары ике яктан асылынып торган бульдог чырайлы аш пешерүче фриц бер фляга китереп бирде. Кораллысы уңга таба автоматын сузып нәрсәдер әйтте. Латыш шул якка башын боргач, Әнвәр дә урман кырыенда кое бурасы күреп алды, ерак түгел генә кызыл чүлмәк түбәләр күзгә чалынды. Инде өйлә узып бара бугай. Әх, караңгы төшкән чак булса, хәзер бер җай китереп бу фрицка барып ябышыр иде, автоматын гына каерып алу җитә, аннары нишләргә кирәген җай үзе күрсәтер иде, дип хыялланды Әнвәр коега таба барганда. Немец исә, аның ниятен сизенгәндәй, еракта ук тора, автоматының тәтесеннән кулын бер дә алмый... Су алып кайткач, латыш ашарга сораган иде, немец бүре улагандай: «Наен!» дип кулын гына бутады һәм аларны тагы базга илтеп яптылар.

— Әх, эңгер-меңгер вакыты булмады,— дип өзгәләнде латыш. Аның да уенда нәкъ Әнвәр нияте булган икән.

Төнлә бик каты җир селкенгәнгә уянып киттеләр. Тирә-юньне төнге самолетлар бомбага тота иде. Бомбаларның бик нечкә сызгырып төшкәне бер секундка гына колакка чалынып китә, шунда дөңк итеп җиргә бәрелгәнен тоясың һәм шартлавын ишетәсең. Нәрсәләрдер бик якында гына шартлыйлар, тукта, бу безнекеләрдер, мөгаен, дигән куанычлы уй Әнвәр башыннан сызылып үтте. Латыш та, күзләре очкынланып, аңа килеп елышты. «Баз өстен ачып булмасмы икән?» — диде ул, өмет белән кыҗрап. Әнвәр аны бер сүздән аңлады: бу мәхшәр вакытында немецның үз хәле хәл, ычкынырга иң уңай чак... Ләкин Әнвәр нидер әйтмәкче булып латышның җиңен тарта башлаган иде, кинәт аларның базы аска убып киткәндәй булды, шартлау дулкыны икесен дә стенага бик каты китереп бәрде. Бер мәл исләрен җыеп, тын ала алмыйча тордылар. Күзләрен ачып карасалар базның бер почмагыннан зәңгәр күк күренә, әйе, күзләре алдамый, йолдызлар чекерәеп карый. Иң элек аңын җыеп латыш сикереп торды, теге почмакка атылды. Аның артыннан Әнвәр иярде. Уе да юк, колаклары да берни ишетми. Бөтен барлыгы белән шул хәрәкәткә йотылган иде. Чокырдан ычкынуга караңгы урман аларны үз кочагына алды. Бер машина тәгәрмәче эзе буйлап чаптылар. Теге хутор күренә торган яктан гел бүтән тарафка төбәлеп йөгергәндә, Әнвәр аягына нәрсәдер кадалганга мәтәлеп җиргә барып төште. Караңгыга күзләре ияләнгән иде инде, кырыйдагы әйберләрне шәйләп була. Латыш егете бик сак икән, шундук Әнвәр янына килеп ауды. Тыннары тәмам беткән, чапкан аттай мышныйлар, сүзләре авыздан чыга алмый. Әнвәр сул аягын күтәрде, ураган ыштыр-чолгаулары каядыр югалган, чалбар балагы да аерылып төшкән иде. Тубыгында бары бер кат оек кына, лычма булып юешләнгән, ә бармаклары өшеп әрнешә иде. Әнвәр хәзер генә җирнең юка рашкы-ярма сыман кар белән капланганын күрде, суыклыкны ул бөтенләй сизмәгән икән. Шунда тиз генә эчке күлмәген изүеннән шытырдатып ертып чыгарды.

Юлны тоткарлаган өчен латыш егете ачуланыр дип, Әнвәр үзен-үзе күрәлмәс дәрәҗәгә җиткән иде. Юк, егет тә чалбар каешын алып, чүпрәк өстеннән шуның белән нығытып бәйләде. Аннары ракета яктысын өйрәнеп тордылар. Әнвәр безнең һәм немец ракеталарын яхшы аера иде. Латышның моңа бик күңеле булды. Биредә оборона сызыгы тоташ түгел икәнен һәм эт эчәгесе кебек чуалып беткәнле ен ракеталар утыннан бераз чамаларга була иде. Әнвәрнең белүенчә, урманлык җирләрдә траншеялар юк, немец бер блиндаж казыган да шуның кырыена бер-ике пулемет куйган. Андый аерым постларның ракеталары һаман бер урыннанрак чөелеп торыр. Ләкин шунысы ымсындыргыч, мондый постларның йә бу, йә теге ягыннан шуышып булса да үтеп китәргә мөмкинлек бар.

Ракеталар күтәрелми торган бер араны чамалап алып, ачык кырдан кояш чыгыш якка таба бара башладылар. Күп кенә җир үттеләр, хәлләре бетсә дә, бүтән булдыра алмыйм, дип авыз да ачмадылар. Инде яктыра да башлады. Яшеренер урын кирәк иде. Алар килеп чыккан урын сирәк урманлык булып, монда һич калырга ярамаганлыгы шунда ук беленде. Ерак түгел бер тирән яр эчендә ешкынлык күренә иде, шунда таба атладылар. Ләкин урман эчендә кинәт немецча кычкырган авазлар яңгырады. Болар икесе берьюлы, чалгы чапкан үләндәй, кинәт җиргә аудылар. Тавышлар якыная бара иде. Әнвәр бер өем чыбык-чабык күреп алды һәм шуның астына үрмәләде. Латыш егете дә аннан калмады. Икесенең дә күзләреннән өн качкан иде. Инде ничәнче тапкыр менә чын үлем белән күзгә күз очрашалар. Чыдаса да чыдый икән адәм баласының җаны! Инде дөп-дөп баскан аяк тавышлары якынга ук килеп җитте. Чәнчелгере, шуны күрмәгәннәр, бу чокыр кырыеннан сукмак үтә икән бит. Фрицлар ашыга-ашыга атлыйлар, табан асларыннан шартлап чәчрәгән коры чыбыклар боларның битләренә килеп тия. Әнвәр киеренкелеккә чыдый алмый, ни булса шул, дип күзләрен йомган иде, бөтен тәне тоташ күзгә әйләнгән кебек булды, ул аркасындагы һәр күзәнәге белән фрицларның хәрәкәтен тоеп ятты. Бар гәүдәсендә ниндидер елдырым ут чабып йөрде, бер минут эчендә манма тиргә төште. Үпкәләрендә кысылган тын, таштай каты булып, бугазына килеп тыгылды. Уф!

Немецларның алгы сызыгын төн караңгылыгыннан файдаланып үткән чакта тагы үлем авызына эләгә язып калдылар. Куе чыршы урманы коткарды, нидер сизенепме, әллә өркепме, күпме генә аларга атсалар да, куелык пуляларны үзенә йотып бара иде. Яктырып килгәндә, ниһаять, урман почмагыннан чыгып, соңгы көч белән үзебезнекеләргә таба шуышып киттеләр. Үргә табарак коры үлән сабаклары каплаган җир. Сабаклар төбендәге юка гына кар бар төшне ала-кола итеп күрсәтә иде. Аларны озак шәйләмәделәр. Килеп җитәрәк кенә автомат очередьлары башларына тияр-тимәс сызып үттеләр. Ату тавышы тынган мәлдә окопта ыгы-зыгы купканлыгы, кемнеңдер бик каты кычкырганы ишетелеп калды. Автомат уты көчәйде. Башны кыймылдату мөмкин түгел иде.

— Үзебезнекеләр! Үзебезнекеләр! — дип кычкырдылар болар, җирдән хор белән кабатлап тордылар. Тончыга-тончыга кычкырдылар. Бераздан ату тынды, болар көчкә-көчкә шуышып барып траншея эченә мәтәлеп төштеләр.

— Власовчылар!! — дип, шәрран ярды бер автоматлы солдат. Шулай уйларлык та иде, өсләрендә немец шинеле, җитмәсә Әнвәр башын урап аяк астына яшел обмотка бәйләп куйган, бер аягына чүпрәк чорнаган. Икесенең дә битләре тырналып, шинельләре сәләмәләнеп беткән иде. Шунда боларга таба траншеядан лейтенант килгәне күренде. Ул миһербанлы кыяфәтле шикелле иде.

— Кемнәр! Кайдан? — диде коры гына. Иң элек Әнвәр үзенең хәлен сөйләп бирде. Часть номерын, командирларның фамилияләрен атады.

— Бар андыйлар,— дип, лейтенант латыш егетенә төбәлде. Аның частен да, командирларын да белмәделәр.

— Ксенофонтов,— дип, дәште лейтенант йокылы, битараф тавыш белән,— бар, КППга илтеп тапшыр. Аннары доложить итәрсең. — Һәм аның өчен болар бөтенләй юк шикелле кыяфәт белән траншея борылышына кереп югалды.

Әнвәр кулга аласыларын белә иде, шуңа бер дә исе китмәде, эчендә куенга куйган мәче баласы шикелле шатлык тыпырчына иде. Хәзер үләргә дә риза, фрицлар тырнагыннан исән-имин ычкынды. Көчкә генә санын өстерәп барса да тирә-якны күзәтте, үзебезнекеләрдән берәрсе очрамасмы? Ләкин кайта-кайта шатлыклы хисләре борчылу, кайгыру белән алмашына башлады. Аны бит болай калдырмаячаклар. Мондый очракларны күрергә туры килде аңа. Идрисовның шулай Маламишкин дигән солдатны бер бәладән йолып йөргәнен аңа сөйләгәннәр иде. Минем мондый хәлгә төшүемне белсә, һичшиксез мәрхәмәте килми калмас иде? Мирхас та аңа ни булса да эшләми калмас иде? Ләкин ничек аларга хәбәр итәргә? Әйе, эшләр шактый кәй әле...

Ниндидер хуторга җитеп килгәндә аларга каршы ак тун, бәрән малахай кигән бер майор очрады. Әнвәр бер карауга аның йөзе бик таныш икәнен шәйләп алды, әмма тиз генә зиһенен туплап өлгерми калды. Майор узып киткәч, капылт уянгандай, башы, гәүдәсе белән калтыранып, хәрәкәткә килде һәм борылып кычкыра башлады.

— Иптәш майор, иптәш замполит! Сез бит Ваһапов, безнең командир идегез! — дип, кулларын бутады, нечкә бугазында тамырлар зәңгәрләнде. Конвой аны тыеп кычкырып җибәрде, ләкин майор боларга таба атлагач, тынды. Туктадылар, Әнвәр, майорның йөзенә төбәлгән килеш, үзенең хәлен кыска-кыска гына сүзләр белән сөйләп бирде. Майор бер сүз дәшмәде, сәерсенеп карап тора иде. Аны хәтерләргә телиме, бер-бер карарга килә алмыйммы, билгесез. Ә Әнвәрнең ике күзеннән дә борчак-борчак яшьләр тәгәрәп төшә, алар аның түшенә бәрелеп, якты тамчылар булып җиргә атылалар иде.

— Алай елама,— диде Ваһапов татарча, йомшак итеп, баланы юатырга теләгән төстә. — Син Фазлыев бит әле. Мин анда шалтыратып карармын, ярар...

Шундый гади итеп әйтте, хәтта Әнвәр аның ярдәм итүенә ышанып та бетмәде. Ләкин бу аз сүзле, һәрчак моңсу йөзле кешенең сүзләрен җилгә очырмавын да белә иде. Кеше бәла-казасына һәрчак ярдәмчел булып истә калган ул. Шуңа күрә эчендә сүнеп барган өмет чаткысы тагы тернәкләнеп, лепердәргә тотынды. Хәлсез буыннарга ниндидер көч өстәлгәндәй булды.

Контроль пунктта аларга бик кырыс тотындылар. Әле теге яктан, әле бу яктан тикшереп җәфалап бетерделәр. Әнвәр тәмам өметен өзде. Ваһаповның сүзләре сүз генә булып калган икән, дип эчтән әрнеде. Нишли генә ала соң ул хәзер? Мәрхәмәтсез язмышка башны бирергә генә кала инде. Әмма билгеләнгән частена урнашырга китерелгәч, Әнвәр тагы бер гаҗәп хәлгә тап булды. Аларны тикшереп кабул итүче кеше Сөенчалин иде. Бүтәннәрдән аерылып, Әнвәр аңа эндәшергә омтылып карады, әмма эчтән моны эшләүдән нидер тыйды аны. Алар фронтка бергә килгәннәр иде, Сөенчалин үзен бик һавалы тотаса килепме, Әнвәргә иске танышы итеп бер сүз дәшмәде. Ә бит ул аның кул астындагы солдат иде, окопта күпме бергә яттылар. Дөрес, күптән инде ул. Шуның хакына булса да: «Ни хәл, ярап төзәлдеме?» — дип, күңел өчен генә булса да сорарга тиеш иде ул. Шуларны искә төшереп, Әнвәр бөтенләй борчуга төште.

Шул арада Сөенчалин бирегә килгәннәрнең «дело»ларын өйрәнеп, кабул итеп ала һәм аларны шул хезмәттәге кораллы сержантларга тапшырып озата торды. Бер мәл болар икәве генә торып калганнар иде.

— Әх, нишләргә соң сезнең белән, ә? — дип, ул өстәл яныннан үз-үзенә елмая-елмая торды да бүлмәдән чыгып китте. Күп тә үтми, әйләнеп тә керде. Аннары боларны коридор аша икенче бүлмәгә алып керде. Анда керпе чәчле, киң җилкәле бер майор утыра иде. Керүчеләр хакында Сөенчалин аңа алдан әйткән булса кирәк, теге сөзеп карап торды да:

— Салып атыгыз бу шинельләрегезне! — дип, бер генә кычкырды һәм, алып кит дигәнне белгертеп, кулын селтәде. Бүлмәдән чыкканда Сөенчалинның йөзендә шатлык чаткылары беленә иде, моның нәрсәдән икәнен Әнвәр аңламады. Өмете аның һаман түбән таба мәтәлә иде әле.

Сөенчалин кушуы буенча якындагы бер складтан киемнәр бирделәр, Әнвәр аягына да ботинкалар табылды. Шушы эшләр белән мәшәләнеп торганда, алар янына тагы Сөенчалин килде һәм боларның кулына кирәкле кәгазьләр тоттырды.

— Ну, котылдыгыз, әмма ышанычны аклагыз! — диде ул, ак тешләрен күрсәтеп елмайды һәм, кырынрак карап, сул кулын козырегына куеп алды. Боларның миңгерәүләнеп беткән башларындагы миләре хәрәкәткә килгәнче, каядыр китеп тә барды. Рәхмәт тә әйтә алмый калдылар. Менә шундый сәер генә холыклы кеше инде ул Сөенчалин. Әнвәр бу хәлне аның яхшылыгынамы, Ваһапов сүзенең хикмәтенәме юрарга да белмәде...

Батареяны Әнвәр байтак эзләп йөрде. Ул яңа урынга күчкән иде. Бу юлы пушкалар алгы сызыктан шактый гына арткарак куелган икән. Ябык позиция, пулялар очып килми инде бирегә.

Ул Идрисов блиндажына кергәндә, анда каты гына сөйләшү бара иде. Әнвәргә игътибар итүче дә булмады. Бер таза гына гәүдәле, өлкәнрәк яшьтәге солдат, Идрисовка һәм Тафтиловка ялт-йолт күзләрен ата-ата, нидер исбатлап маташа иде. Блиндаж зур һәм ярым караңгы, шуңа күрә бер почмакта Мирхас та утырганын, ул да солдатка сүз каткач кына күреп алды.

— Мин секретный объект сагында булдым, шуңа алгы сызыкка куярга хакыгыз юк,— дип, солдат ике кулының да бармакларын тырпайтып алга сузды.

— Бүтәннәргә ярый, ә син әллә алланың кашка тәкәсеме? Без анда чиратлап торабыз, бүген сез барырга тиеш! — диде Мирхас кистереп кенә.

— Димәк, приказга буйсынмыйсыз? — дип Тафтилов ирләрчә карлыккан тавыш белән сүз кушты.

— Юк, буйсынам, тик сезгә соңыннан кыенга килмәсен дип, кисәтеп куярга гына телим. Алгы сызыкта төрле хәл була...

— Отставить! — диде Идрисов урыныннан торып.— Нишләп болай паника куптарасыз? Приказны үтәгез!

— Миндә секрет күп. Мине немецлар эләктерсә? Бу миннән генә тормый.

— Кесәңә граната салып йөр. Бәҗрасын тарттың — бетте.

— Сиңа асат. Алар газаплый башласалар, тәнгә кызган тимер бассалар?

— Тфу! — диде Мирхас ачынып. — Синдә секрет барын немец каян белсен? Секретны әйтсәң, теге дөньяга озатмый калырлар дисеңме?

— Приказны үтәгез! — диде Идрисов нокта куйгандай. Әнвәр шуны аңлады: бу солдатка хәзер күзәтү пунктына, алга барырга кирәк икән, ә ул әнә нинди сәбәпләр китереп маташа. Солдат мыгырдана-мыгырдана ишеккә юнәлде. Мирхас аның артыннан чыгып барганда Әнвәрнең җиңеннән тотып алып, нык кына селкеде, шуның белән аның хәлен белгәнлеген һәм исән-имин котылуына сөенгәнлеген белдерде.

Командирлар Әнвәргә карап тордылар да, бик бетерешкәнен күреп, хәзергә кухняда эшләп тор дип, шунда җибәрделәр...

## 8

Артиллеристлар немецның танк таранын Мостафинның бик оста җимерүе һәм чигендерүе турында күп сөйләделәр. Хәтта Мостафинга герой исеме бирергә кирәк, дип әйтүчеләр дә булган. Бигрәк тә аның бу бәрелештәге тактикасына — танкка каршы пушкаларны гаҗәп оста итеп урнаштыруына сокланганнар һәм уңышны шуңардан күргәннәр, ә кайберәүләр Мостафинның әллә кайчангы бер җыелыштагы чыгышын онытмаганнар икән. Анда ул кыю чыгышы белән кайберәүләргә кагылып узган, имеш. Менә шушы хәлне искә төшергәннәр дә мактау, соклану сүзләре тынган... Боларның барын да аңа шул югары тирәдә кайнашкан әлеге дә баягы Багpаков килеп сөйләде. Теге гайре табигый дигәндәй очрашудан соң алар бик якынаеп, дуслашып киттеләр. Багpаков һаман «давай йолдызны юабыз» дип килә һәм аңа рәхмәтен әйтеп бетерә алмый иде. Тора-бара моның очрашыр өчен бер сылтау гына икәнен аңладылар. Ә асылда исә икесе дә җанны ачып бирердәй дус, күңел таянычы эзлиләр иде. Һәм алар үзләренең өметләрендә алданмадылар, эзләгәннәрен таптылар шикелле. Багpаков төсе-бите, холкы-фигыле белән гади, эчкерсез бер кеше иде. Аны дан-дәрәҗә дә боза алмаган, аңарда ниндидер табигатьтән килгән гамәли акыл көчле иде. Менә шул ягы Мостафинны бик сокландыра, аның белән бер сөйләшсәң, дөньяның сиңа томанлы бер почмагы ачылып киткән кебек була. Аннары Багpаков аның батареялары өчен өр-яңа оптик приборлы һәм ЗИС пушкалары алырга да булышты.

Кайчак бик авыр хәлдә каласың. Күңелеңдә бер-берсенә капма каршы фикерләр, ниятләр тартыша. Нишләргә, нинди карарга килергә белмисең. Менә шундый чакта чын дус кирәк була кешегә. Соңгы вакытларда Мостафин да бик каршылыклы хисләр кичерде. Әле бу якка тартылды, әле теге якка уйлары өстерәп алып китте. Болар барысы да Зитта белән бәйләнгән иде. Ул Мостафинның бөтен вөҗүден зилзилә китереп ташлады. Тиз генә зиһенне җыеп кара син! Моңа үзенең генә көче җитмәслеген сизде Мостафин һәм ул кыз тудырган барча өметләрен, өметсезлекләрен Багpаковка сөйләргә мәҗбүр булды. Әчтән Зиттаны шатлык итеп, бәхет итеп тойса да, ул аны зур кайгы, бәла рәвешендә итеп сурәтләде, үзен шул бәланең корбаны кебегрәк күрсәтәсе килде. Чөнки бу һич тиеш түгел, уставка сыймый торган эш икәнен яхшы аңлаганга күрә, бу хәл Багpаков тарафыннан каты хөкем ителер дип уйлап, үзен мескенрәк итеп тә күрсәтәсе килде. Төскә дә моңсу-җитди иде. Әмма Багpаков аны бик тиз аңлады, үзе дә тормыш кору мәсьәләсендә нык уйланып йөргән кебек иде. Чыннан да бу бер яктан шатлык, икенче яктан бәла, диде ул. Ник икәнен үзең беләсең... Тик ым белән дә ул аңа: әх, ялгышкансың, брат, дип әйтмәде, дусларча ачуланмады да. Киресенчә, аның бу эшендә булачак киртәләрне чыгарга булышачагы турында белдерде. Кимбр минем бу эшемне кара тактага язар инде, дип тагы пошынуын әйтте Мостафин. Багpаков монысын җайлауны да үз өстенә алды. Тиздән кайсы частьларның Владивостокка китәсе ачыкланырга тиеш, диде ул бер килүендә. Әгәр сезнең полкка да приказ була икән, Зиттаны үзең белән алып китә аласың. Әмма эшнең практик ягын хәзердән үк җайлап куярга кирәк, аңа кайда да булса бер хезмәт урыны чамалап куй. Мин дә шуны истә тотып йөрермен...

Әмма бу арада Багpаков нишләптер күренмәде: әллә бер-бер хәл булдымы? — дигән пошаманга төшмичә мөмкин түгел иде. Зиттадан да бер хәбәр-хәтер юк, үзем килеп чыгармын дигән иде, аны да нидер

тоткарлады бугай. Ул үзенең карарын өйдәгеләргә әйтергә, аларның сүзен ишетергә тиеш иде. Ни генә булды икән? Мостафин Зиттаны ниятеннән кире түндерерләр, дип борчыла иде...

Аны элемтәчеләр бүлмәсенә телефонга чакырдылар. Асоев тылдарак урнашкан бер складтан шалтырата, машиналарга запчасть ала алмый азаплана икән. Синең берәр танышың юкмы, дип белеште. Мостафинның анда күз күргән кешесе юк иде, Асоев шуңа бик кәефе кырылып трубканы куйды. Ул Мостафинның латыш хатын-кызы белән бәйләнешен сизеп йөри булса кирәк, ләкин төсе белән белгертми, әмма эштә шулай аңардан канәгать булмаган ишарәләр ясап куя. Нәрсәдән икән бу? — дип, шул хакта уйлый-уйлый үз бүлмәсенә чыгып килгәндә күрде — коридордан Баграков аңа кереп бара. Менә нәкъ кирәк моментта бит. Дусларча кул бирешкәндә үк Баграков сөйли башлады:

— Гитлерны паралич суккан, ди. Швед газетасы язып чыккан.

— Кит әле! Дөмекмәгәнме шунда?

Алар бүлмәгә кереп, Мостафин өстәл артына, ә Баграков кечкенә агач кәнәфигә утырдылар.

— Юк. Тик Геринг күренми башлаган. Аның күздән төшүе бер политика гынамы, әллә союзниклар белән сепарат сөйләшү өчен пәрдәме?

— Бер-берсен ашарга тотынганнар, алайса,— диде Мостафин куанычлы чырай белән.

— Хәзер аларда җан ачуы шулай да көчле әле, имансыз.

— Димәк, Рейх машинасы җимерелеп бара?

— Бу инде ике-икең дүрт шикелле.

— Ә без биредә утырып калырбыз микәнни? — дип, Мостафин уфтанып куйды.

— Шуңа охшый, немец яңа көчләр китерә,— диде Баграков та көрсенеп.

— Нишләп биредә шул чаклы гаскәр тоталар соң?

— Бу сорауны күпләр бирә, әмма җавап таба алмыйлар.

— Яшерен коралга исәп тоталармы?

— Черчилль немецның реактивный самолетлары турында белдерү ясаган. Немец инглизләрне шуның белән тетә икән...

— Реактивный димени? — Мостафин шаккатып сорады, күзләре түгәрәкләнеп китте. Баграков та уйланып утыра башлады. Ул бүген йончылганрак төстә иде. Калку яңак очларына, калын иренле авыз кырыйларына борчылу сызыклары яткан. Турылыгы өчен аны өнәп бетермәүчеләр бар иде, шулар әллә күңеленә шырпы кадаганнармы? Аның эчендәге — тышында. Кайберәүләр дәрәҗәлерәк урынга утырдылармы, дәшмәүчегә әйләнәләр, белмәмешкә-күрмәмешкә салыналар. Баграков алай түгел шул.

— Тафтилов дигән кеше синдәме? — диде ул башын күтәреп һәм изүеннән бер хат алып Мостафинга сузды. Мостафин укый башлауга, йөзенә аптырау билгеләре чыкты, аннары әле ачулы, әле кинаяле көлемсерәү сызыклары беленеп торды. Укып бетергәндә ул чынлап күңелсезләнде, кашлары җыерылып, йөзе чытылды.

— Ниндидер донос шикелле бу,— дип, хатны өстәлгә ыргытты.— Ышанмыйм, булмас, булмас! — Ул башын як-якка селкеде.

— Офицер намусы судына куймакчылар иде, синең кешең булгач, үзем карармын, дип алып калдым.

— Анысы өчен рәхмәт, Петр Петрович. Телгә керүдән баш-аяк. Әмма Тафтилов бик намуслы офицер. Менә бу бәрелештә аныкылар чын батырлык күрсәттеләр.

— Бөтен нәрсә патриотлык белән үлчәнсен иде дә бит, юк,— диде Баграков күңелсез генә.

Батарея ерак түгел иде. Тафтиловны телефон аша чакыртып китерделәр. Ул күңелле чырай белән килеп керде, әмма боларның сүренке-

җитди йөзләрен күргәч, әле Мостафинга, әле Багараковка күз йөртеп, нәрсә бар икәнен белергә теләде, битендәге яктылык сүнде.

— Менә монда синең биографияне язганнар, танышып чык,— диде Мостафин, калын хатны аңа биреп. Тафтилов өстәл янындагы урындыкка утырып, хатны кулына алуга, бөрешеп калгандай булды, башы шинель эченәрәк сеңде. Болар аның йөзендә берәр үзгәреш, борчылу, куркып калу шәйләргә итсәләр дә, Тафтиловның йөзенә берни дә чыкмады. Тик мөгез кебек булып шомарып каткан бармаклары гына аз гына дерелдиләр иде. Ул укып чыкты да, уфылдап, бер сулыш алды, хатның битләрен актарып, анда язганнарны тагы бер кат күздән кичерде.

— Ну, ничек? — диде Мостафин, аның хәленә кергәндәй, йомшак һәм дустанә тавыш белән. Ул монда язганнар чеп-чи ялган булуына ышанып елмая иде.

— Барысы да дөрес,— дип, Тафтилов хатны өстәлгә куйды. Йөзе тәмам сүнеп, сарылык белән капланган иде. Ә тегеләр ни әйтергә белми, бер-берсенә карашып тик торалар.

— Әтиеңнән баш тартуың дамы? — Багараковның муены Тафтиловка таба сузылды.

— Анысы болай, баш тарту дип тә, түгел дип тә әйтергә мөмкин. Минем әти поп иде, нәсел-нәселдән шулай килгән. Мине дә шуңа укытып маташтылар, ләкин ул эштән җирәндем. Унсигездә әти белән бәрелешеп, өйдән чыгып киттем. Безнең Тозлы күл авылыннан ерак түгел Чкалов шәһәре. Шунда китеп эшли башладым. Ләкин минем поп малае булуымны белеп алдылар. Әтиеңнән баш тарт, комсомолга алабыз, диләр. Мин риза булдым. Шуннан бөтенләй араны өздем. Партиягә дә шулай кердем...— дип, Тафтилов моңсу гына тынды.

— Ә хәзер әти-әниең белән ничек? Шикләнмә, без сине батырырга җыенмыйбыз,— диде Мостафин.

— Юк, мин алдаша белмим, бернинди элемтәм юк.

— Хәзер андый эшләр мөмкин бит? — диде Багараков, Тафтиловның каты хөкем көткән йөзенә карап. Ләкин Мостафин да, Багараков та аңа ачуланмыйлар, хәлен аңлаган рәвештә сөйләшәләр иде.

— Әйе, ни гаебе бар аның ул чаклы? Хәзер дә попмы?

— Белмим,— диде Тафтилов икеләнебрәк.

— Әнә, әти-әниең сине эзләтәләр дип язган бит хатта. Син ташласаң да, алар сине ташлый алмыйлар икән?

Мостафинның бу сүзенә Тафтилов берни дә әйтмәде, тагы моңсуланыбрак китте. Бу сөйләшү аның җанына авыр иде шикелле, ул тирән итеп көрсенде дә көрсенде.

— Ә хатны язучы кем? — диде Багараков, кызыксынып, аның күзләрендә очкын беленде.

— Анысының да тарихы бар,— дип, Тафтилов каралган бармаклары белән маңгаен ышкып алды.— Безнең запасной частьта бухгалтер булып эшли иде ул. Лида исемле хатын. Еш очрашырга туры килә иде, бәйрәмнәрне бергә каршы алабыз. Минем бар якны тәмам белеп бетерде бу һәм миңа бик нык ияләште. Мине яратуын бик еш әйтә башлады. Әнисе белән генә торалар. Ул өйдә юкта Лида мине үзенә чакыра. Яз көне тәмам шашынды бу. Мин дә агач түгел, аның яратуына ярату белән кайтарырга тырышам, ләкин бер дә чикне узмыйм. Вакыты да түгел, дим. Лида ирлехатынлы булырга үтереп кыстый. Бала булса, миңа шул җиткән, үзеңне ирекле хис ит, бер сүзем юк, дип ялына. Мин нәкъ шуны теләмим, Лида дим, менә сугыш бетсен, мин әйтәм. Шуннан мөнәсәбәте кинәт үзгәрде аның, миңа үчләнә башлады. Үч тирәнгә китте. Мин фронтка чаклы аның кулы җитмәс дип уйлаган идем, ялгышканмын икән...

— Әй, брат, аны бик каты рәнҗеткәнсең икән бит,— дип, кычкыргандай әйтте Багараков.— Син ирдер ләбаса?!

— Ирен ир дә бит, соңыннан үзем дә үкендем, ә ул хакта...— Тафтилов ишетелер-ишетелмәс тагы нәрсәдер мыгырданды. Аңа бу хакта сөйләп утыруы оят икәне күренеп тора иде. Мостафин аның сүзләреннән шундый нәтиҗә чыгарды: бу Тафтилов бик юаш, артык инсафлы кеше икән. Теге хатын аны тәмам басымчак иткән. Үчкә үч белән кайтара алмавын белеп, бигрәк узынып киткән. Өстеннән жалу язудан да тайчанмаган... Юаш булсаң шулай инде ул. Мостафин аның бу холыкфигылен эштә дә сынап белгән иде, хәзер менә тулысынча ышанды. Ул үзенең замполитын Баграков алдында акларга, яхшы итеп күрсәтергә тели иде.

— Син бик юаш, Николай Петрович,— диде.— Менә шуңа җилкәңә менеп атланмакчы булган ул.

Тафтилов бер сүз дә әйтмәде, бары көрсенеп кенә алды, аның битенә нервы тимгелләре чыккан иде. Мостафин әйткән нәтиҗәгә Баграков та кушылган шикелле итеп кулын селтәде.

— Аңлашылды,— дип, шуның белән бетерик мәгънәсендә ияге белән ым какты.

Мостафин сөйләшү тәмам дигәндәй урыныннан торды, Тафтилов та аягүрә басты, бүреген киде. Командир аңа эш буенча берничә күрсәтмә бирде, ә бу хакта борчылма, дип, дусларча җиңеннән тотып, ишеккә чаклы озата килде.

Баядан бирле кашын җыерып, йөзен чытыбрак утырган Баграков, нәрсәдер аңламагандай, җилкәләрен җыерып куйды.

— Кеше буларак нинди ул Тафтилов? — диде. Чыраенда икеләнү иде.

— Әйтәм бит, мировой кеше, дип. Ләкин сугышта һәрвакыт әйбәт булып бутмый.

— Кешенең табигате юньле булса, аны сугыш хәлләре дә начарлата алмый.

— Юк, әйтмә, ничек кенә начарлата әле!

— Ихтимал,— дип, Баграков урыныннан торды. Сүз шуның белән өзелде, алар бүтән нәрсәләр турында сөйләшә башладылар.

## 9

Әтисе исенә төшкән саен Рифаның йөрәге әрнеп куя, аны җәлләп тамагына төер утыра, күзләрен яшь элпәсе каплый иде. Кайчак одеялына төренеп, бүлмәдәшләреннән яшереп кенә үксеп тә алгалый. Аны ничек бу бәладән коткарырга, дип баш вата. Бер дә булмаса алгы сызыктан әз генә арткарак, икенче эшелонга күчерергә иде үзен. Аның хәлендәге кешегә дә бу мөмкин эш икән, Рифа берничә тиешле начальникка сүз кушып караган иде, монда бернинди хәрәмләшү юк, диделәр. Тик бу аның турыдан-туры командирларыннан тора, дип аңлаттылар.

Бу кайгысы белән кемнәргә барып сыгына ала ул, Рифа шуларны зиһененнән кичерде. Аның таныш-белешләре бик аз иде. Иң элек Мостафин каршына барырга дигән өметле уй туды. Менә ул ичмаса ярдәм итәр, яхшы киңәш биреп кенә калмас. Киңәшне тонналап бирделәр аңа, әмма хәл эшкә барып төртелгәч, төрлечә боргаландылар, кайсы мин кечкенә кеше, дип мескенләнеп калды. Мостафин алай итмәс, өркеп читкә тайпылмас. Әмма ул аңа барып егыла аламы? Рифа кат-кат бу хакта күңелен барлап карады һәм һич тә бара алмаслыгын аңлады. Нәрсә бу? Рәнҗүме аның җанын шул чаклы биздергән? Әллә тагы да үҗәтләнгән горурлыкмы, сер сынатырга теләмәүме? Тик ачык кына берни дә әйтә алмый, әмма бара алмавын төгәл белә, эчтән нидер тота аны, җибәрми. Димәк, бу номер батмый.

Ләкин ниятеннән бер дә чигенергә теләми ул, шуның өстенә тагын әтисенә үзенең булганлыгын күрсәтәсе килү хисе дә эчтән «чыбыклап»

тора аны. Моның кечкенә генә бер сере дә бар иде. Әтисе бик өметләнеп малай көтеп йөргәндә Рифа тугач, аның гаять дәрәҗәдә күңеле кайткан булган. Кулын гына селтәгән. Янәсе, булмады инде. Бала вакытта шул нәрсә күңеленә юшкындай утырып калган һәм менә хәзер һич искәрмәстән калкып чыкты бит. Аннары Рифаның хезмәт урынында абруе бик тиз күтәрелеп китте. Әшли башлавына бер ай үтүгә баш врач аны дәрәҗәлерәк эшкә билгеләде. Герш Исакович аның басынкы-сабыр характерын, рыясыз булуын, үз вазифасына бик намуслы каравын ошатты. Рифа үзе дә эшкә бик иҗтиһатлы иде. Кешене кайда да хезмәт күтәрә бит. Болар барысы да Рифага ниндидер хөрлек тәэмин итәләр һәм әтисенең четерекле язмышына катнашырга кыюлык бирәләр иде. Ул хәзер белә инде, мондый эшкә күзеңне йомыбрак тәвәккәлләмичә дә булмый. Зурга өмет итеп барасың, әмма буш килеш кире борыласың. Санинструктор кызлар аша белешеп, Рифа әтисенең командиры капитан Мамак белән очрашып сөйләште. (Капитанның үзләре урнашкан хуторга киңәшмәгә килгәнен сагалап торды.) Ләкин киң каратут битле, чын украин кыяфәтендәге бу кешене күрүгә каушады да калды. Әллә йөзендә миһербан чаткысы юк идеме? Һәр сүзе рәсми-салкын, ә сынап карый торган күзләре эченә үтеп, синең бар серләреңне белә кебек. Хәбиров сезнең кемегез ул? — дигән соравына да Рифа дөресен генә әйтә алмады. Ул безнең укытучы иде, шундый бәлагә төшкәнен ишеткәч, бик кызгандым, диде. Хәбиров кызганыч кеше түгел, дип куйды Мамак һәм аның матур күзләре сүзнең беткәнен белдереп читкә төбәлделәр.

Әтисе килгәч, Рифа шаккатып башын селки-селки әйтте.

— Ай-ай, ул Мамакның өрәге каты икән! — диде.— Күрүгә әллә гипнозлый тагын, аркам шыбыр су булып чыкты...

Хәбиров кызының сүзләрен, командирын мактауга юрап канәгатьләнеп елмайды.

— Командирыңның, дим, бер күз карашы гел ике көпшәле мылтык төбәлгән кебек менә.

— Ә үзе гадел, простой кеше ул.

— Белмим, белмим.

— Кешене сүзенә карап түгел, эше буенча бәяли.

— Сине үзе янына берәр инструктормы-ниме итеп алсын иде, ичмаса, әз генә булса да тылдарак дигәндәй...

— Андыйга ук кыюлыгы җитмәс, кызым,— диде Хәбиров ничектер моңсу гына.

— Ә гадел дисең?

— Үзе генә баш түгел бит. Син минем уң кулым, дип гел әйтә ул анысы.

— Һәр сүзне чынга аласыңмы, их, эти? — дип өзелеп, шул ук вакытта кистереп әйтте Рифа. Әтисен һаман сүзләргә алданып йөри дип белеп шуңа эчтән әрнеде, шунда ук башына бик тәгаен фикерләр дә килде: димәк, Мамактан өстәрәк торган начальникка барырга кирәк икән...

— Соң нишлим? Миңа ышанган өчен мин барысына да риза, кызым.

— Әй, кызылланып маташмасана һаман, һаман, чисти.— Рифа әтисен кайгыртуы белән бераз гына горурлана һәм акыллы уй йөртүен сиздерәсе килеп тора иде.

Бу ачу китерерлек сүз иде. Хәбиров урындыкта җилкәләрен салындырып утыра торган җиреннән йөзен күтәреп кызына карады. Акшарлы мичкә сөялгән Рифа да катырак ычкындырганын сизеп уңайсызланды, бил каешын бер кулы белән тиз-тиз кырыйга сыпырып гимнастеркасының чабуыннан аска таба тарткалап төзәтенергә тотынды. Тик әтисе берни дә сиздермәде, аның йөзе кызына соклану яктысы белән нурланды.

— Дөрес әйтәсең, кызым,— дип, кызы сүзләренә күңеле булгандай, шат хәрәкәт белән урыныннан торды. Рифа тумбочкасыннан алып

аңа бер зур пачка чәй сузды. Әтисенең авызы колагына җиткән иде, ул, кызына рәхмәт әйтә-әйтә, ишеккә таба атлады.

Юк, кызының болай тырпу торуына ачуы килми аның. Чөнки ул әтисенең хәлен аңласа да, рухын аңлап бетерми. Үзенә ышаныч югалтуның нинди авыр булуын татыганы юк. Кызы чын күңелдән аны кайгырта, ә ата өчен шуны күреп торудан да бәхетлерәк нәрсә бармы? Кем генә үз баласының бер игелеген ун итеп кабул күрми? Ата-ананың иң бәхетле чагы кайчан? Үз кызының яки улының игелеген күргәндә, аларның кайгыртуын тойганда. Хәбиров бүген үзен бәхетле итеп сизде һәм, шул бәхете белән уртаклашырга теләгәндәй, тагы Мирхас янына сугылды. Бик җайлы чак туры килде, блиндажда ул үзе генә, телефон янында нигәдер боегып утыра иде.

— Алма агачыннан ерак төшми, хак сүз,— дип, Хәбиров бик эре генә шинель күкрәгеннән теге чәйне чыгарып Мирхас алдына куйды.— Рифа күчтәнәче! Сиңа!

Мирхасның озын керфекләре аптыраудан еш-еш лепердәп куйды,— шаяра дип белеп, Хәбировка төбәлде.

— Ник шаккаттың? Сине сорашты, бик хәтерли...— диде, Мирхастан күзен читкәрәк алып. Әллә сүзенә ышанычлык төсмере бирү өчен, әллә болай гына Рифаны мактап китте. Хезмәт урынында абруе бик зур икән, майор, подполковниклар Рифа Гасыймовна дип кенә торалар икән... Анысына ышана Мирхас, комсостав арасындагы хатын-кызларга игътибар зур. Тик менә Рифаның мине искә алуы сызгырту гына түгел микән? — дип, ул ышанып бетмичәрәк уйлады, чөнки Хәбировның борчак сибәргә дә күп сорамый торганрак икәнен бу кыска-кыска очрашуларда да төсмерли башлаган иде. Шулай да күңелен нәрсәдер кымырҗытып сызып үтте, күзләрендә очкын кабынды. Теге вакытта Рифа аның йөрәгеннән кан саудырып китте бит, ул моны, билгеле, үзе белмәде. Мирхас үзенең аңардан түбән торуын, укымаган, ярлы булуын аңлап, эчтән генә сызды. Бу нинди дә чир кебек булды аның өчен, чирдән озак сихәтләнә алмады. Авылда чакта Хәбировның сугышта зур бәлагә дучар булуы килеп ишетелгәч, Мирхас әллә нинди рухына ят сөенечкә якын бер хис кичергән иде. Аны ул үз-үзеннән оялып куды. Тик ни генә булса да, башына шундый уй килеп киткәне хәтерендә. Минем белән тиңләштеләр хәзер, дип уйлавы булгандырмы инде? Ә Хәбировны биредә очраткач, аны җәлләп, бөтен йөрәге тетрәде. Ул аңа бик якын кеше булып тоелды. Кызы Рифаны да ниндидер бәхетле очрак бу тирәгә китереп ташлавын белгәч, аның белән бик еракта, томан артында калган чакларын искә төшереп рәхәттә кинәнеп йөргән иде. Ләкин тора-бара кызга карата күңелендә ниндидер ачы көек кенә утырып калганын белде. Ә менә хәзер Рифаның үзен онытмавы хакында ишеткәч, җаны кузгалып китте. Бу тагы аны үзенә тиң итеп күрергә азапланумы? Элек ул хисләрен: мин аңа тиң түгел, тиң түгел, юләр булма, юләр булма! — ди-ди, күңеленнән кырып ташлагандай иткән иде... Ә Хәбиров аны-моны абайламыйча кызын мактый.

— Ну Рифа, молодец, уңса да уңа икән. Кая килеп, әтисенә булыша. Тормыш гадел ул, гадел! Минем нинди газапларым бәрабәренә кызым белән очраштырды, ә?

— Дөнья куласа, әйләнә дә бер баса, диләр.— Мирхас ниндидер кинаяле тавыш белән әйтте. Үзенең Рифа турында төпченеп сорашасы килеп тамагы кычытты. Хәбировка сорау тулы дулкынланган карашын төбәп торды.Теге исә аның бу кызыксынулы күзләрен күрми шикелле иде.

— Рифа безнең Дәвешне онытмаган алайса? — дип, Мирхас сүзне үзе хакында кызның ни әйткәненә бормакчы булды. Хәбировның бу турыда сүз озайтасы килми иде бугай, йөзендә дәртләнгәнлек иде. Мирхасның һаман аңарга сорау тулы караш текәвен сизеп:

— Ярар, үзе янына бер барырбыз әле,— дип, бик ымсындыргыч итеп

әйтеп куйды. Мирхас, кулларын тиз-тиз йөртеп, капчыгыннан соргылт пластмасс стаканнар чыгарды. Термоста чәй кайнар иде. Хәбиров сизелерлек дулкынланган, нигәдер ашыга иде, чәйне дә ашыга-ашыга гына эчте. Мирхас үзенең эчендәген сиздермәскә тырышып, читтән суктырып Рифа турында сораулар бирә торды. Хәбиров исә сүзне бүтән нәрсәгә бора, үзенә каера, әйтеп бетерми генә өзә иде. Мирхас бераз әрсезләнеп тә куйгалады.

Мирхас аңарда ниндидер үзгәреш булуын сизеп калды, бүтән чагында болай тәкъваланмый иде. Рифа турында сөйләтәсе килеп, сүзне тагы шуңа юнәлтергә итте.

— Рифаны әйтәм, үткен кыз булып чыккан, ә? — диде. Үзе хакында кыз нәрсә диде икән, шуны ычкындырмасмы, дип өметләнде. Юк, Хәбиров һаман үзенекен сөрде. Аннары:

— Барсы да шул әтисе аркасында. Кем аны русча укытты?! — диде горур тавыш белән. Йөзенә канәгатьлек һәм бераз масаю чыкты. Ул шул канәгатьлеге, шатлыгы белән ялгыз гына кинәнәсе килгән шикелле, ашыгуын белгертеп, тизрәк кайтырга кирәклеген авыз эчендә ботка пешереп кенә мыгырданды да урыныннан кузгалды, блиндаждан чыга башлады. Мирхас зиһенен җыеп, рәхмәт әйтергә чак өлгереп калды. Бөтен уйлары оялары-ние белән туздырып ташланган шикелле иде. Әллә кайчан башына суга-суга кумгән хисләре кузгалгалап куйды. Йөрәге сулыгып-сулыгып типте. Мирхас нигәдер үзен һәм язмышын тиргәде. Шуннан соң гына аңа аек уйлар кайтты: ахмак, ахмак, диде үз-үзенә. Алданма тагы! Ләкин никадәрле үзен эчтән чыбыкласа да үртәлүе, алданасы килүе бетмәде...

Рифа бер полк штабына сугышчылар белән эш итүче инструкторны күрергә килгән иде, туры китерә алмады. Шулай да аның фамилиясен белде, Сөенчалин дигән капитан икән... Юлы уңмаганга борыны салынып кайтып килә. Бу әтинең нишләп болай бәхете юк икән? — дип уйлый ул. Ә көн шундый матур. Бөтен җирне, агачларны юка гына ак кырпак бәсләгән. Бәйрәм көнне өстәлгә ак эскәтер җәеп куйгандай, сукмакка да ак кәгазь җәйгәнмени, шул кәгазь өстенә аяк эзенне эре-эре хәрефләрдәй тезеп барасың. Урман эче якты, үтәли күренә. Тегендәрәк карасу-яшел чыршылар нәрсәгәдер каш җыерган сыман тоелалар. Шул чак сукмактан каршыга таба килүче күренде. Бер борылыштан кинәт кенә килеп чыкты. Зур чиннар гына кия торган зәңгәрсу-көксел шинельдән, шундый ук тышлы мех бүректән. Ниндидер «шишка» булырга охшый. Рифа аска төбәлгән килеш, перчаткалы көе уң кулын чигәсенә китереп тидерде дә узып китмәкче булды. Ләкин теге кинәт аның сул җиңеннән тотып алды.

— Ай-ай, бәрәңгенең эресен ашагансыз икән,— дигән көр тавышка Рифа борылып караса, фронтка килгәндә очраган лейтенантны танып, туктап калды.

— Танымыйсыз да, ә? — Егет шат елмаеп, үпкәләгән сыман карап тора. Рифа үзен дорфа күрсәтмәс өчен генә елмайды. Бу егетнең тәртипле булуын белгәнгә сөйләшми генә китәргә кыймады.

Сүз өчен генә:

— Ә сез ничек таныдыгыз? — дигән булды.

— Сез гел истән чыкмадыгыз, бәлки шуңадыр? — Егетнең чыраенда көләчлек сызыклары бетеп торды, ул җитдиләнеп, мин шаярып әйтмим дигән кебек әйтте. Кыз аның уйчанлыгына әһәмият итмәде.

— Сез әйтерсез инде!

— Менә бер моңлы көй ишетсәң, шуның моңын гел күңелдән кабатлап йөрисең. Үзе хәтергә кила дә тора, сез дә шулай гел искә төшеп тордыгыз.

Аның сүзләрен шаяруга алмыйча булмый иде, аннары ир-атның бик әрсезләнүеннән дә туйган, шуңа күрә кыю гына төрттереп алды.

— Кызларга кармак салырга тәмам өйрәнеп җиткәнсез икән,— диде.— Кабучылар да бармы?

— Ярар инде ышанмасагыз.

— Шаярып яратма, яратып шаяр, диләр бит.

— Юк, монда шаярып булмый.

— Ярату уенына тагы берәүне кертмәкче буласызмы? — дип, көлеп җибәрде Рифа. Егет тә аңа кушылып көлде, ләкин зәңгәр күзләре нигәдер моңсуланып калды. Рифа китүен белгертеп алга таба борылды, күңел төшермә, егет, дип әйтәсе килде. Шулай әйтеп, үз юлына киткән дә була иде, әмма егет аерылырга теләмичә, аның кырыннан атлап бара башлады. Йөзендә уй иде. Шулай сүзсез генә бардылар. Моның иярүен Рифа бик үк охшатып бетермәде, шулай да һәркемгә итәгатьле һәм ягымлы күңеле җиңелдә: әйдә, сөйләнсен инде, кешенең кәефен җибәрергә ярамый, дип үз-үзен аклагандай әчтән уйлап алды. Аның сүзләрен тирәнгә алмый гына тыңларга кирәктер.

— Хатын-кыз чынга ышанмый, ялганга ышана, диләр иде, хак, ахрысы? — дип, елмайды егет һәм, «бик каты әйтмәдемме?» дигәндәй, кызга сөеп карады.

— Ничек инде ялганга ышансын?

— Менә бит, мин дөресен әйттем, сез ышанмадыгыз?

— Ә мин сезнең ялганмы, чынмы сөйләвегезне каян белим?

— Анысы да хак,— дип, егет кинәт көлеп куйды. Һәм бик кызып-кызып сөйләргә тотынды.— Хатын-кыз алтын таулар вәгъдә иткәнгә мөкиббән китә. Ә дөреслек кырыс, авыр, конкрет нәрсә. Хикмәт шунда: ялган шаян, йомшак, шома, иркәли торганрак...

— Иркәләгәнне мәче дә ярата,— дип кеткелдәде Рифа.

— Менә-менә! Ә ялган ул матуррак, ымсындыргычрак та була...

— Күбәләк тә канаты көясен белмичә якты утка омтыла бит, кызлар да шуның кебек димәкче буласыз...

— Точно! Карале, сез бик акыллы кеше икән! — диде егет ихлас шатланган тавыш белән. Шуңа күзләре очкынланды. Рифага да кызык булып китте. Егетнең хатын-кыз хакында җилбәзәк фикер йөртүен ошатып бетермәде, үз нәүбәтендә бер чәнчеп алмакчы булды.

— Ә ни өчен күбәләк яктыга, утка бара?

— Белмим. Ни өчен?

— Ә үзегез сөйләнәсез. Шул хакта уйласагыз иде?

— Грамотам җитми бит,— дип, егет гаепле сыман көлеп куйды. Рифа сүз катмады. Икесенең дә йөзендә шатлык, бу гәпләшү күңелләренә хуш килүдән туган нур белән яктырган иде. Тынып шактый гына бардылар. Рифаның егеттән: Сөенчалин дигән инструкторны белмисезме? — дип сорыйсы килә, ләкин ниндидер ахмак горурлыгы телен тота.

— Юк, белмим, ни өчен икәнен? — диде егет, сүзне тагын күбәләккә ялгап.

— Әйдәгез, әйдә, үзегез баш ватыгыз,— дип, Рифа аңа тагын күз сирпеп алды.

Егет җавап кайтармады, нечкә озын муенын бөгебрәк, аска төбәлеп барды. Тынлыкны урман артында шартлаган снаряд тавышлары бозды. Ул авазлар агач очларына бәрелеп катлы-катлы булып яңгырый. Бер шартлауны ике-өч мәртәбә ишетәсең.

Урман бетте, кырга килеп чыктылар. Чакрым ярым, ике чакрым чамасы арырак кызыл чирәп түбәле берничә йорт һәм шулар янында лапас кебек озын булып сузылган яшел палаткалар күренде. Рифа үзенең эшли торган җирен егеткә белгертәсе килми иде. Шул ук вакытта шушында гына кал, дип әйтергә дә кыймый. Шуңа күрә сулга таба бераз киткәч туктады. Егет тә, ни әйтергә белмәгәндәй, үзләре төшкән фатир хуҗасын исенә төшерде, аның бик усал фикер йөртүләрен көлә-көлә сөйләп алды. Шул җәһәттән бер-берсенең кайда, ничек урнашуы белән кызыксындылар.

Рифа үзенең бик уңайлы кешеләргә туры килүен аерым бер канәгатьләнү белән сөйләде. Егет тә бер штабка урнашуын, ләкин әшен бер дә өнәмәвен әйтте. Штаб дигәч, Рифаның эчке зиһене эшли башлады, баядан бирле телен кычыттырып торган нәрсәне сорарга булды. Монда штаблар күп күбен бер-бер файдасы тиеп куймасмы, кем белә? — дип уйлады.

— Ә сез Сөенчалин дигән кешене белмисезме? — диде кинәт кенә. Егет ялт итеп аңа карады һәм, нәрсәгә шулай сорый икән дигәндәй, бераз торды да елмайды, күзләре ниндидер сер белән өртелгән сыман булды.

— Беләм,— диде ул көттереп кенә.

— Чынлап әйтәсезме? — дип шатланып, кыз кулларын хәрәкәтләндереп алды.

— Чынлап. Ә нәрсә? — Егет елмайган килеш аска карап тора башлады. Аның нәрсәдер яшергәнлеге сизелеп калды.

— Ул кеше миңа бик-бик кирәк иде.

— Шулаймыни? Тәк-тәк! Нигә шул тикле кирәк?

— Ә ул ниндиерәк кеше, җайлымы, җайсызмы диюем?

— Һмм, шартларга карап инде, һәр кеше шулай... Йә?

— Юк, ни өчен икәнен әйтә алмыйм, шәхси мәсьәлә,— диде кыз һәм аның бит уентыкларындагы нурлары сүнгәндәй булды. Егет кызның йөзендә борчылу шәүләсен күрде.

— Сермени? — ул үзенең фамилиясен бу юлы да әйтмичә генә китәргә уйлаган иде, ләкин кызның сизелерлек боегып калуын күреп, уеннан кире кайтты.

— Түгел дә...— дип, кыз шикләнеп егеткә карап алды. Йөзендә икеләнү, шул ук вакытта серне чишмичә дә мөмкин түгеллеген аңлау иде. Ул барыбер беләчәк инде, дигән нәтиҗәгә килде һәм ничек тәэсир итәр икән дип, күз кырые белән һаман егетне күзәтә-күзәтә, әтисе хәлен сөйләп бирергә мәҗбүр булды. Егет башта бәлагә төшкән кешенең кызы бу үзе булуына ышанмады. Күп кенә сораулар бирде. Шуннан соң гына шиге беткәндәй булды.

— Кһм, ал-ай икә-ән,— дип сузып әйтте һәм шуның белән эш бик җитди булуын аңлата кебек иде.— Сез эзләгән Сөенчалин дигән кеше мин ул!..— Егет горур гына елмаеп кызга карады. Кыз шаяртасыз, ахры, дигән шикелле көлемсерәде, керфек астыннан гына күзләре елтырый иде. «Алдан берни дә вәгъдә итмим»,— дигәч кенә Рифа аңа ышанды һәм карасу-кызгылт битенә кызыллык тибеп чыкты, ул сөенергә тиеш иде югыйсә, әмма нигәдер эчтән уңайсызлык кичерде. Әллә горурлыгына көч килде инде, белмәссең. Егет кайбер нәрсәләрне ачыклагач, аның янына үзе сугылып чыгарга вәгъдә бирде һәм Рифаны әллә нинди каршылыклы уйлар эчендә калдырып кайтып китте.

Ни хикмәттер, аның икеле-микеле уйлары торган саен чуалчыклана гына барды. Ни кирәк соң аңа? Әтисен уңайлырак җиргә урнаштырса, шул җитмәгәнмени? Нәрсәдән ул шулай үртәлеп калган кебек булды? Шул егеткә бар күңелен ачып саласы килдеме? Ә ул аңа әнә нинди битараф, гамьсез карады шикелле. Шуңамы җанында ниндидер канәгатьсезлек юшкыны утырып калды. Егетнең ул, бәлки, горурлыгыннан гына киләдер? Шушы исе китмәү, ниндидер олыларча вәкарьлек астында бик әйбәт йөрәк бардыр? Туктале, аның йөрәге нәрсәгә сиңа? Чынлап та нәрсәгә? Нишләп әле бу кеше синдә шул чаклы кызыксыну кузгатты? Менә тагы үзеңнең хисләреңә ирек бирәсең, юл куясың. Тагы «пешәсең» килә ахырысы? Тагы төнге күбәләктәй утка янарга омтыласың? Ә бит аерата сак булырга кирәген үзең дә бик шәп белеп торасың. Әниең дә хат саен: «Сак бул, балам!» — дип, җан ялварып яза. Командирлар да тәртипле булырга тукып кына торалар. Әйтерсең лә, ул йөри торган юлның ике ягына да: «Саклан, мина!» дип язып куелган. Тоташ миналанган кыр буенча барасың кебек. Нишләп әле бу кешене очраткач кына ул «сакчы»-ларга ачуың кузгалды.

Ул егетнең үзен эре тотуы, кызга артык мөкиббән китмәве күңеленең кай почмагындыр кымырҗытып тора. Ахмаклык бит инде бу! Егетнең шул эрелеге аны берәр ничек үзенә тартасы, буйсындырасы килү хисен уята, нидән икән бу әкәмәт тойгы? Һәрвакыт саклана торган, тыелган «зонага» үтеп керергә омтылудан туган ниятме ул? Әйе, ул тыелган дөнья аны һәрчак ымсындыра, үзенә тарта иде. Күптән инде бу хиснең кыставын тоеп йөри ул... Ә кешенең монда ни катнашы бар? Гаҗәп, әллә нишләде ул, әллә нишләде.

Аларның баш хирурглары Софья Абрамовна, бик тәҗрибәле үткен хатын, кайчак үзенең кызларына эчен ачып, сөйләп ала: кайбер ир-ат, ди, беренче очрашуда ук сине гомергә үзенеке итә дә куя, ә кайберләре синең белән гомер буе яшәсә дә үзенеке итә алмый, имеш. Шуның өчен кызлар үзләренә ишне үзләре сайларга тиешләр, ди. Сине беренче вакыттан ук үзенеке итә алмаган ир-ат белән тормау хәерле, ул сиңа барыбер бәхет бирә алмый икән. Хатын кыз бәхете ир-ат бәхетеннән бик нык аерыла, ди Софья Абрамовна. Ир-ат теләсә нинди хатын-кыз белән бәхетле була ала, ә хатын-кыз — юк! Үзеңне бәхетле итәрдәен сизәргә тиешсең, янәсе. Ә аны каян беләсең? Ирем юк, кайгым юк, диләр кызлар. Мин исә шул кайгыга дучар булырга омтылам түгелме? Юк, әллә нәрсә бу! Очына чыгарлык кына түгел... Тәмам зиһене-акылы чуалып бетте аның.

Бер эш вакытында да аның шул зиһен таркаулыгы үзен сиздерде. Замполит Рифаны бер немец офицерының ярасын бәйләргә урман эчендә урнашкан хуторга алып килде. Немец латыш өенең акшарлы мич кырыендагы топчанда ята иде. Рифаның чибәрлегенәме, әллә ярасын йомшак, бер дә авырттырмыйча, пөхтә бәйләвенәме күңеле булып, немец, куштанлык хәрәкәтләре ясап, һаман елмайды һәм минут саен, «данкё шон» дип кабатлап торды. Даруны бер дә кызганмыйча салып бар җирен китереп бәйләп бетергәч, немец ниндидер бер тизлек белән Рифаның кулын учына тотты да үбеп алды. Рәхмәт әйтеп башын иде. Рифа сизмичә дә калды. Шуны артта күреп торган замполит, җирәнгәндәй йөзен җыерып, читкә карады. Рифа аның ачулануын сизмәде. Ул арада тәрҗемәче килеп, офицердан сорау ала башладылар. Ләкин немец бик масаюлы, үзен безнекеләрдән өстен тоткандай тота иде.

— Ни өчен солдатларыгыз үзләрен үлемгә дучар итәләр, моның мәгънәсез нәрсә икәнен күреп торалар ич? — дип сорады замполит.

— Приказ үтәргә өйрәнгәнгә күрә,— диде теге.— Чигенсәләр дә аларга барыбер үлем яный.

— Ә үзегез фюрерны һаман яратасыз?

— Яратмый кара!

Замполит дошманга эчке ярсуын күрсәтмәс өчен генә елмайды. Рифа аның бармакларының нәфрәттән дерелдәгәнен күрде.

Чыкканда Рифа замполит артыннан ияргән иде, теге йөзен җимереп аска караган килеш әйтте:

— Бу хатын-кыз дигән имансыз — фрицны да ярата алыр!

Рифа бары соңыннан гына бу сүзләрнең үзенә әйтелгәнен аңлады, немец аның кулын үпкәнгә һәм Рифа аны шулай кабул иткәнгә замполитның чиксез ачуы килгән икән. Нинди хурлыклы хәл килеп чыккан булган ләбаса... Менә бит, әллә нәрсә булды аңа соңгы вакытларда...

Рифа башта ниндидер очыну белән Сөенчалинны көтте. Теге озак килмәгәч, сүрелде, уена төрле шикләр килә иде. Мин кем аның өчен? Нишләп ул миңа яхшылык эшләсен? Менә килер дә: булмый, дияр, төрле сәбәпләр китерер. Әх, ул сәбәпләр! Кешегә игелек итәргә кирәк булганда шул сәбәпләр артына качабыз инде. Ярый әле сәбәпләр бар. Ә икенчеләй уйлаганда, ул кеше аның эш тә йокы, йокы да эштән генә гыйбарәт тормышын ничектер кызыклырак итеп җибәрер сыман тоела. Күңеле исә үзе дә аңлап житмәгән ниндидер үзгәреш булуын өмет итеп тора. Нинди үзгәреш ул? Нәрсәгә кирәк соң ул? Юк, юк...

Әле генә сменасын тәмамлап, душта коенып кайтып, тумбочкасындагы көзге каршында чәчләрен рәтләп утыра иде, һич истә юкта Сөенчалин килеп керде. Үзен хуҗаларча тотып, шинелен салып элде, аннары портфеленнән печеньедыр, конфеттыр чыгарып өстәлгә тезде. Рифаның плитәдә чәе кайнап тора иде. Ул чәй янына электән хәстәрләп куйган бер шешә чыгарды. Моны күрүгә Сөенчалин коты алынгандай: юк, юк, диде, йөзен җыерып, куллары белән «ал, күземә күрсәтмә!»— дигән ачулы хәрәкәтләр ясады. Рифа аптырый калды, теге һаман үзенекен иткәч кенә шешәне кире алып яшерде. Шул минутта Рифага бу уңай хәбәр алып килмәгән, шуңа сыйдан да баш тарта, дигән пошаманлы уй килде. Ничектер бит уемтыкларындагы нурлар сүрелеп китте. Егет исә бу уңайсызлыкны сизепме, Рифа аңа чәй ясаган арада шук сүзләр сибәргә, союзниклар турында анекдотлар сөйләргә кереште.

— Бер инглиз полковнигының малае әтисе кул астында адъютант булып хезмәт итә икән. Алгы сызыктагы батальон командирына приказ тапшырырга барган: «Әти әнә шул биеклеккә һөҗүм итәргә һәм алырга кушты!»— дигән. Ярар, дип, честь биргән батальон командиры, ә әниең ни боерды? — ди икән төрттереп. Теге ишарәгә әһәмият итмичә, моны башта әни әтигә боерды, ә әти сезгә боерды,— дигән дә китеп барган, ди. Шуның шикелле, инглизләрнең немецларга каршы сугышуы да хәрби өйрәнүләр кебек кенә.

Рифага бу кызык тоелды, ул көлде дә көлде, егетнең күңелен күрәсе килә иде. Сөенчалинның исә кызны көлдерә алуына кәефе килә иде шикелле. Ул чәен әз генә эчеп алды да тагы сөйләп китте.

— Элеккеге ике дус элемтәче кызлар очрашалар. Берсе бик ягымлы, нурлы йөзле, тулы гәүдәле икән, икенчесе ямьсез икән, ходай кимсеткән үзен. Очрашканда бик шатланышып, бер-берсенә яңалыкларын сөйлиләр. «Син теге сержант белән һаман йөрисеңме?» — дип кызыксына ямьсезе. «И-и, мин аны күптән оныттым инде»,— дигән чибәр кыз. «Ничек?». «Шулай, аны лейтенант оныттырды»,— ди икән. «Хәзер лейтенант белән йөрисезмени?» — «Юк, капитан белән», «Ай-һай бик ансат икән синең?» «Нишлим соң, лейтенантны капитан оныттырды»,— дип көрсенгән чибәр кыз.

Рифа чәйле стаканын кулына тоткан килеш, башын аска ия-ия көлә иде. Аннары кинәт тыелып:

— Бүген көләм дә көләм, хәерлегә булсын,— диде һәм, стаканын куеп, чәчләрен рәтләгән итте. Егет аның аксыл шома, нур бөркеп торган битенә, матур кулларына сокланып карый, үзенең дә авыз кырыйларындагы уемтыкларда нурлар чаткылана иде. Ул мине ошата, ахыры, дигән уй Рифаны рәхәтләндереп узды. Башкаларга ошау — нинди татлы тойгы икән...

— Ә бит мин әтиегезнең эше белән таныштым,— диде Сөенчалин стаканын эчеп бетереп һәм якын иткән рәвештә. — Рифа, аның данныйлары әйбәт, ышанычлы кеше булса кирәк...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, Рифа аны бүлдерде.

— Чынлапмы? — диде һәм җавапны егетнең күзләреннән укып, чиксез шатланып кинәт урыныннан кузгалды да, Сөенчалинга килеп, аның муенын кочып алды, тач-тач итеп ике битеннән үпте. Шунда егетнең тезләренә утырды, ике куллап муенын кочкан килеш, әз генә каерылып, башын артка ташлады, шпилькалары идәнгә төшкәләде, ә эре керфекләре йомылган күзләре нииндидер чәчәкне хәтерләтә иде. Егет кызның биленнән кочкан, бераз каушап калды шикелле, бүтән хәрәкәт ясамады, югыйсә бит, кыз тәненнән ниндидер елдырымнар узып, канын кайнарлатты, күкрәгенең тыгыз йомырыларын сизеп тору аңа рәхәт булды, әмма кулын шаяртмады. Егет кымшанмагач, Рифа да күзләрен ачты, егет күзләре белән очрашмаска тырышып башын турайтты һәм тезләреннән төште. Йөзен егеттән яшерер өчен, тумбочкадагы көзгесе каршына барып басты. Чәчләрен

жыйды, сүтте, каушаганлыгы һәм оялганлыгы күренеп тора иде. Сөенчалин аңа ниндидер мәрхәмәтле елмаю белән караган.

— Зинһар, гафу итегез, шатлыктан әллә нишләп киттем,— диде ул.— Бик зур рәхмәт инде сезгә. Әти дә сөенер...

Сөенчалин нәрсәдер әйтергә тиеш иде, ләкин йөзендә таркаулык, фикерләрен җыйнап бетерә алмаганлык һәм шуны яшерергә теләгән йомшак, яратулы елмаю. Ул шул кыяфәтен җуймаган хәлдә шинелен, бүреген киде, Рифага бик җылы карап әйтте.

— Бу очрашу соңгысы булмас әле, шулай бит?

— Амин, амин,— дип, Рифа көлеп җавап бирде.

— Догагыздан ташламагыз.

— Юк, һәрчак догада булырмын.

Алар шаян сөйләнә-сөйләнә болдырга чыктылар. Сөенчалин кызга: озатып йөрмә, дип ым какты да баскычтан тиз-тиз төшеп китте.

Кайтканда һаман Рифа турында уйлады. Характеры тиз кабынучанмы, әллә сөенеченә эченә сыймаганнан шулай эшләдеме? Шулай да берни булмый калуы нинди әйбәт булды әле. Ара катлауланыр, җанны яңа борчулар-кырчулар килеп басар иде. Ә болай мин беркемгә берни тиеш түгел, ирегемне беркем чикли алмый. Нинди рәхәт бәйсез булу! — дип уйлады ул.

## 10

Елгавага кайтып, Зитта элеккеге квартираларында яши башлады. Әбисе дә шунда күчеп килде. Азык карточкалары бирделәр. Бар төштә совет власте урнашып килә иде инде. Зитта да үз фабрикасына эшкә барды, төрле өндәүләр шулай куша иде. Анда буяу, рәсем ясау кебек эшләр күп булып чыкты. Иртәдән алып кичкә хәтле кулыннан пумала төшмәде. Элек болай дәртләнеп эшләгәнен бер дә хәтерләми. Әллә нинди күңел күтәренкелеге булды аңарда. Хәтта буяу төсләренең тәмен тойгандай итте: кызыл төснең тәме кыркуырак, сары — төчерәк, зәңгәрдә — бөтнек тамчыларындагы авызны салкынайта торганрак тәм...

Бер көнне эштән кайткач, зур көзге каршына басып кофтасын салганда, битенең күздән түбәнрәк җирендә саргылт сипкел нокталары күреп, кинәт аптырап калды. Нидән булыр бу? Шунда ук күпме вакыттан бирле җанын төрле борчулар кимергәне исенә килде. Бигрәк тә Даут турында борчыла иде. Ул хәзер аны уйламыйча тора да алмый. Ашап утырганда кайчак кулыннан кашыгы шалтырап төшеп китә. «Тагы шул майорыңны уйлыйсыңмы? Әй, бала!» — дип, әбисе мыгырданып ала. Бу яратып мыгырдану, майорның әйбәт кеше икәнен үзе дә күрде инде. Мостафин аларга җае чыккан саен шикәрен, консервасын китергәли иде... Теге фаҗигале төннән соң Зитта бөтенләй өмет өзеп тә йөрде. Шул чагында кара кайгы басты аны. Даут мине бүтән күрергә дә теләмәс, бетте, бетте, дип эчтән күңеле сызды. Майорның үз җанына шундый тирән кереп урнашуы гаҗәп иде. Ничек килеп чыкты бу? Нәрсәгә ышанып мин үз-үземне аның иркенә ташладым? Хәзер бит бөтен нәрсә дә вакытлы һәм очраклы. Ул бит бу хакыйкатьне бик яхшы белә, күрә иде. Әмма шулай булуга карамастан, ул майорга беткәнче әсир булды да куйды. Юк, мин бу хискә каршы тора алмыйм, бу — миннән өстен нәрсә, ахрысы...

Шундый борчу белән тулы кичләрнең берсендә Даут үзе килеп кермәсенме. Йөзе тоташ нур гына, сагынганы бөтен кыяфәтенә чыккан... Киңәшмәгә чакырылган булган икән. Юк вакытын тыгызлап булса да, Зиттаны күрмичә түзмәгән... Өч-дүрт сәгать буе гел сөйләшеп кенә утырдылар. Сугыш бетсә, йә көнчыгышка кителсә, дип үзләренчә планнар сызып маташтылар. Хыялда йөзү рәхәт иде. Ләкин планнарның берсе дә очы-очка ялганмый, чөнки икесенең дә язмышларында билгесезлекләр күп иде. Бу билгесезлекләрнең төрлечә чишелүе мөмкин. Икесе дә хыялланган-

ча, Даут Көнчыгышка юнәлсә, Зиттаны үзе белән алып китәчәк. Бу турыда кайбер хәзерлекләр күрә башлады инде ул. Зитта гына: әби мине җибәрә алыр микән соң? — дип уйланып кала... Даут ихлас күңелдән барысын ачык итеп сөйли, Зиттага ике төрле уйланырга җай калдырмый. Нинди әйбәт кеше ул, дип, эчтән сокланып утыра Зитта. Тфү, тфү, күз генә тия күрмәсен... Хисләренә чыдый алмыйча, капылт кына кузгалып, урындык аркасына терәлеп утырган Даутның башын кочып ала һәм бармаклары белән яратып чәчләрен тарый башлый... Даут исә әби килеп керер дип кенә тыелып утыра...

— Син бик арыгансың, минем аучым? — диде Зитта, аны яратып туя алмыйча. Ул шаярып аны «аучым» дип йөртә иде.

— Сине күрү миңа ял була,— дип елмайды Даут. Зиттаның биленнән кочып алды. Зитта тәнендәге ефәкләр нindидер рәхәтлек биреп кыштырдады, кулдан шуышты. Кыз Даутның йөзенә иелде дә, маңгаеннан үбеп, күзләрен сирпеде һәм барысын да аңлады. Менә нинди инсафлы ул, дип сокланды аңа Зитта һәм аның креслосы кырыена утырган килеш сөйләнә башлады.

— Мин бит теге көннән соң бик борчылдым, аңлыйсыңмы шуны, аучым, ә? Ул бандитлар латышлар иде бит? Мине дошман күрер бу, дип бар дөньяны каргадым...

— Шулай уйлый алдыңмы, Зитта? Ә синең моңа ни катнашың? Алар бит адашкан адәмнәр! Аннары мин тәкәббер кеше түгел, хәтта аларга ачуланмыйм да. Үтереп ташласалар да берни эшли алмас идең. Котырганнар ни генә кылмас?! Ә тормышның һәр сәгате газаплы булса да нинди рәхәт! Тиздән бу гаугалар бетәчәк! Шуның өчен генә дә бар нәрсәне кичерергә мөмкин. Тормыш белән чагыштырганда алар чүп кенә. Ә мин үземне әллә кемгә санамыйм, ачу тота белмим...

Даутның һәр сүзе нинди рәхәтлек бирә, күңеленә агыла һәм уена әбисе әйткән фикер килә: тәкәббер кеше белән алма да, бүлмә дә, дип гел әйтә ул. Каян беләсең аны дигәч: кеше кечкенә нәрсәдә дә үзен күрсәтә, шуны тоя бел... дия иде. Әйе, Даут киң күңелле кеше икән, моңа шикләнмәскә мөмкин...

Шул минутта тышта машина кычкыртты, уңган шофер китәргә вакыт дип искәртә иде.

— Тагы кайчан? Тагы кайчан киләсең? — диде Зитта, Даутның кочагыннан чыгып.

— Беләсең, тәгаен генә әйтеп булмый.— Ул моңсу-сагышлы карашын Зиттадан алмады.— Үзем хәбәр салып торырмын! — диде, кузгалып, шинеленә үрелде.

Ул китте, әмма Зитта тагы өметләрен канатландыра һәм пошаманга да төшерә торган уйлар белән калды. Бу кыктан төшкән бәхет минем өченме икән, дип куркып уйлана ул. Озакка барырмы?.. Авыр хәлләр белән тамырдан какшатылган иманы яхшы нәрсәгә дә тиз генә ышанып китә алмый иде. Начар көнкүреш кешенең ышанычын бетерә, ә ышаныч тиз генә килми икән... Башта икеләнүләре болай ук түгел иде, ара якынайган саен төрле шөбһәләр башка килә дә тора. Ә бит аннан да якын кешем юк минем хәзер, дип уйга кала Зитта. Туктале, кайдадыр шундый сүзләр укыганы бар иде: хатын-кыз, имеш, ул туфрак, җир кебегрәк бер зат, аңа, имеш, теләсә нинди орлык сипсәң дә ул аны үстерә, үстерергә мәҗбүр, янәсе... Менә бит, чынлап та, нинди кешене җаныма кертеп урнаштырдым. Кем икәнен белмәсәм дә, бер дә талымланып тормыйча күңелемне ачтым түгелме? Туфрак орлыкка ачылган шикелле? Юк, күңелемнең кай төшедер сизгән һәм миңа эчтән әйткән: «Бу — ул!» — дигән...

Бу бәхетне төрле яктан козгыннар сагалаганын да Зитта аңлый иде. Теге агент аны бер эзләп табачак дип, аңардан ансат кына котылу өчен төрле әмәлләр корып та йөрде. Ләкин ул, гөнаһ шомлыгы, һич көтелмәгән җирдән килеп чыкты. Бер көнне урам буйлап эштән кайтып барганда, әллә

кайдан гына аның янында пәйда булды. Каршы алырга килгән егете сыман итеп култыгыннан тотты да янәшә атлый башлады. Үзе кызын бик сагынган егет кебек елмая, шаян сүзләр әйтеп көлә, рольгә керә иде. Ачудан Зиттаның бөтен тәне кызышты, аксыл битенә нервы тимгелләре типте. Ләкин тынычланырга кирәк иде, ул эчтән үз-үзенә, «тынычлан, тынычлан», дип кабатлады. Ә теге тәмам рольгә кереп җиткәч, сүз арасына гына кыстыргандай:

— Майор сездә булдымы? — дип сорап куйды.

— Нинди майор? — диде Зитта, берни белмәгән чырай белән аңа башын борды.

— Йә, балакай, уен корырга уйлама! — Агентның тавышында янау ишетелде. Зиттаның эчендә ачу күтәрелде.

— Абыйлар утарында аны сезнең бандитлар үтерә яздылар. Мине ничек кенә мәсхәрә итмәделәр! Тфү! Белмәгән булып кыланмагыз, китегез янымнан! — дип, бик зәһәрләнеп әйтеп ташлады Зитта, беләгең кырт кына тартып алды. Агент ни әйтергә белми иде шикелле. Ул йөзендә ригаяле елмаю саклаган хәлдә тын гына атлап бара. Бераздан ниндидер караңгы подъезд турыннан узганда караса — теге юк. Шул караңгылыкта югалды, ахрысы. Бу Зитта өчен әллә ни сәер тоелмады, ул миннән мондый сүзләрне көтмәгән, шуңа күрә телсез калды, дип үзенең кечкенә генә җиңүенә сөенде.

Икенче көнне эштән чыкканда агент аны тагын көтеп тора иде. Күрүгә Зиттаның йөзе тәмам сүнде. Теге игътибарны җәлеп итәргә теләгәндәй елмайды, араны йомшартмакчы булды.

— Ул инцидент безнең эш түгел, ниндидер үтилчеләрдер...— дип сөйли башлаган иде, Зитта аны бүлдерде.

— Мине акылга утырту өчен провокация оештырдыгыз!

— Юк, без түгел, менә кояш!

— Сезнең кул белән эшләнгән әшәкелек ул!

— Кара, ышанмыйсыңмыни? Сиңа чынын әйтәм!

— Шартлаганчы әйтсәң дә ышанмыйм! — Зитта үз ихтыярында нык торырга булды, ул курчак түгел, җебеннән тартып кына аның белән шаярмасыннар. Җитәр! Агент тагы аска караган килеш уйланып барды да төшенке генә тавыш белән:

— Син сатылгансың...— дип әйтеп ташлады.

— Монысы тагы провокация! Сатылмадым да нитмәдем дә! — диде Зитта кимсенгән төстә.

— Юк, читкә тайпылырга уйлама! — Агентның сүзе нык иде.

— Нишләтерсез? Ә? Ә? — Зиттаның озын күз керфекләре очлы энәләр шикелле тырпаеп дәһшәтләнде.

— Мондый көрәштә алиби булмый, Зитта! — диде агент катгый тавыш белән.

— Зинһар, мине бутамагыз, зинһар!? — дип ялварды кыз.

Агент аның сүзләрен ишетмәгән кебек, үзенекен тукыды:

— Турысын гына әйт әле, теге кыйналганнан соң майорниләр сөйләде? Сөйләшкәнсездер бит?

— Юк, аны шунда ук машина килеп алып китте,— диде Зитта, ышандырырга теләп. Үзе эчтән уйлады: менә хәзер нәрсә сөйләшкәнне әйтсәң, ул тагы күбрәк сорый башлаячак, күбрәк тукыначак. Бөтенләй ул чакта телгә дә килмәгән нәрсәләр әйтеп ташларсың. Аннары ул миңа тагы задание бирәчәк. Менә шуннан баткакка суырачак та суырачак. Беләм мин аларның чыгырын. Әгәр тыңламый башласаң, синең «донос»ларыңны фаш итү белән янаячаклар. Җан саклар өчен үзеңнән-үзең аларның колына әйләнәчәксең.

Көн дә диярлек эштән кайтканда агент аның юлын бүлә иде. Зитта аңа каты бәрелергә дә курка, алар берни белән дә санашып тормыйлар. Берсендә ул Зиттаны үз бүлмәсенәме, әллә махсус шуның өчен тотыла торган җиргәме алып керде. Зиттаның коты очты, какча битле, кечкенә

башлы, әмма озын гәүдәле бу егет белән ялгыз гына калырга курка иде. Килеп ябышса, нишләрсең? Зитта бик сагаеп, бөрешеп кенә утырды. Тегенең андый-мондый астыртын мәкере сизелмәде.

— Син аларга ярамаячаксың,— дип башлады ул.— Шуны уйладыңмы? — Тар маңгаендагы купшакланыбрак торган алсу тиресе җыерылып килде.

— Ярарга да җыенмыйм,— диде Зитта исе китмәгән рәвештә. Аңа хәзер бар нәрсәгә дә битараф булып кыланырга кирәк иде.

— Ә айзсорг оешмасында торганыңны белсәләр?

Бу астан эләктерә торган «кармак»лы сорау иде. Зитта кашларын җыерып уйланып торды. Хәзер ул: мин бит гаеп эш эшләмәдем, шуңа күрә нигә миңа куркырга, дип әйтсә, агент аңа: ә-ә, чиста калырга телисеңме? — диячәк һәм тагы да ныграк каныгачак.

— Белсәләр, ни эшлим?

— Сөрәчәкләр бит.

— Ни булса, шул.

— Син яшь әле, үз язмышыңа алай битараф карарга ярамый.

— Ә мин нишли алам инде?

— Менә милләт өчен тырышырга кирәк.

— Фабрикада эшлим, башкага көчем юк.

— Иҗтимагый эш шәхесне югары баскычка күтәрә диләр кызыллар.

— Аның өчен сәләт кирәк.

— Сәләтең җитәрлек, тик теләгең юк. Нигә, ә? — Агент маңгае белән алгатаба сөзеп кызга төбәлде. Зитта җавап урынына җилкәләрен селкетеп куйгач, кайгылы итеп күрсенде, тегенең битенә караңгы чаткылар чыкты. Аннары бер минуттан йөзе яктырды, башына акыллы фикер килгән сыман иде.

— Син үз милләттәшләреңне яратасыңмы соң? — диде ул елмаеп һәм бик төче тавыш белән.

— Яхшыларын яратам, начарларын юк,— дип кисте Зитта, дөрес сөйләгән кебек.

— Үз милләтеңне нык яратырга кирәк. Латышлар, димәк, яхшылар, дип. Бүтән милләтләр үз кешеләрен шулай яраталар.

— Һәр милләттә дә яхшы, яман бар, минемчә,

— Яратсаң, барысы да яхшы була.

— Ничек итеп мин яратып караудан гына начар латыш яхшыга әйләнсен? Аңламыйм? — диде Зитта аптыраган чырай белән. Агент аның сүзләрен колак яныннан уздырды.

— Менә синең, әйтик, балаларың булыр. Син аларның латышча сөйләшеп, латышча җырлап йөрүләрен теләмисеңмени?

— Телим дә соң, бу бит миңа гына бәйләнмәгән.

— Ана кешеләр туган телне беренче саклаучылар була.

— Әгәр бала җаны-күңеле белән әйбәт булса, кайсы телдә сөйләшсә дә барыбер түгелмени?

— Шунда да бөтен хикмәт. Башка телгә күчсә, ул синнән йөрәге белән ераклаша. Менә бит эш нәрсәдә!?

— Белмим. Нинди телдә сөйләшсә дә минем каным ич ул. Юк, бу кешесенә карап тор. Кешенең холык-фигыле нинди? Әнә мин чын латыш дип йөргәннәрнең кайберләре әниләрен, туганнарын ташлап китә. Немецлар килгәч, латыш латыш өстеннән донос язды.

— Ана теленнән дә якын нәрсә юк кешегә! — дип, агент үзенекен каерды, Зиттаның фикерләрен читләтеп үтә иде.— Кызыллар килгәч, ана теле кысыла инде. Әлбәттә, сразы түгел, әкренләп...

— Аны бетерүдән аларга ни файда? — диде Зитта.

— Һәр кеше үз милләтенең күбрәк булуын тели. Хатын-кызларда бу тойгы зур булырга тиеш? Синдә андый изге хисләр юк шикелле? Җәл, җәл!

— Без семьяда шулай тәрбияләндек, кешенең милләтенә түгел, ә начармы, яхшымы булуына карыйбыз. Тормыш иткәндә шул кирәк бит.

— Ә милли горурлык? — дип, агент аны төп башына утыртырга теләгәндәй чәнчеп әйтте.— Хәтта кызыллар да милли горурлыкны хуплыйлар бит.

— Мин кызыл түгел! Тормыштагы гыйбрәтләрдән чыгып кына әйтәм. Аннан соң сез монда милли горурлык дип милләтчелекне күздә тотасыз.

Зиттаның бу сүзләренә бетереп ташларлык дәлилләр китерә алмагангамы, агент җавап бирмәде. Күңеленнән мәсьәлә чишкәндәге кебек, уйланып торды, күз карашы да эчкә төбәлгән иде. Ул өстәл артыннан кузгалды да йөренә башлады.

— Әйе, син сәер генә фикер йөртәсең, җавап та табып булмый,— диде.

Зитта пальто якаларын рәтләде, башын яка эченәрәк батырды. Сүз беткән кебек булды. Зитта кечкенә ридикюлен чыртлатып ачты да, нәрсәдер карап, кире ябып куйды һәм урындыгыннан кузгалды.

— Мине, зинһар, бүтән тарткаламагыз инде? — диде ул мескен, кызгандыргыч тавыш белән. Ул ишеккә килеп җиткәндә агент өстәлдә иягенә таянып уйга чумган иде. Зитта ишетелер-ишетелмәс кенә саубуллашты да, ишекне ачып, чыгып китте. Каушаудан тез буыннары хәлсезләнгән иде, агент берәр нәрсә эшләр, дип бик нык курыкты ул.

Шуннан соң шактый вакыт үтте, Зитта инде бүтән борчымаслар дип өметләнә башлаган иде. Ләкин өмете юкка булган икән. Агент аның эштән кайтканын тагы сагалап торган иде. Ул инде иске танышлардай ничектер бик якын итеп сөйләшә башлады. Бөтенләй элеккегечә түгел, тормыш-көнкүреш турында гына гәп коргандай иде. Аннары гына сүзне туган тел, милләт мәсьәләсенә китереп чыгарды. Патриот кызлар турында сөйләп алды. Ул әкрен-әкрен, гүя сиздерми генә, үз ягына аударырга тырыша иде. Әмма Зиттаның зиһене бик сак, аның яшерен кармакларын күңеленнән генә сизеп ала. Кайсына җавап бирми, кайсы белән бәхәскә кереп, юри фәлсәфәгә өстери һәм шулай итеп җеп очын бүташтырып бетерә иде...

Зитта хәзер ачык бер фикергә килде: аны тынычта калдырмаячаклар бу козгыннар. Һаман ниндидер калҗа чукырга өмет итеп җанына тукыначаклар. Аннары менә бу битенә чыккан сипкелләр дә тикмәгә генә түгелдер, дигән сизенү дә бик борчый иде аны. Миңа Даут янына бармыйча бүтән әмәл юктыр, дип кат-кат уйлый ул. Тик ничек анда барырга? Үзе хәбәр салырмын дигән иде, һаман юк та юк. Мин нишләргә тиеш хәзер? Бер яктан агент кыса, икенче яктан, сипкелләре көннән-көн эрерәк була баруының сәбәбе эчне пошыра...

## 11

Әнвәр һаман элеккеге халәтенә кайта алмыйча, авыр кичереш эчендә йөрде. Күңеле тәмам сынган, рухы изелеп беткән булган, шул гыйфритфрицлар күз алдына килеп газаплый иде аны. Җанына үткен тырнакларын батырганнар да һич җибәрмиләр. Йокларга дип күзен йомды исә, каршына киләләр дә, коточкыч тавышлар белән кычкырырга тотыналар. Һәм ул шабыр тиргә батып уянып китә. Бөтен тәне дер-дер килеп калтырый, йөрәге барабан суккандай дөп-дөп итеп тибә. Бераз хәл җыеп ятканнан соң, йокы күзен йомдырса, тагы шул бастырылу кабатлана. Хәтта көндезләрен дә аңа тынгы юк, фрицларның соры өрәкләре аны сагалап йөриләр шикелле тоела, барган җирдән ул, шикләнеп, артына борылып караштырып ала. Юк, берни дә юк. Куркыныч төш күргәннән соң, уянып, уйлангандай, алар бит чын түгел, бары төш кенә, дигән фикер килә аңа һәм бөтен барлыгы шатлык-куаныч белән тула. Шунда теге какча гына яңаклы, Әнвәрнең үзе кебек юка гына гәүдәле латыш егете исенә төшә. Ул очрамаса, белмим, мәхшәрдән исән-имин котыла алыр иде микән?

Хәзер бер нәрсәне ачык аңлады: куркынычның күзенә керергә кирәк икән, шулай итсәң, аның өркетә торган нәрсәсе бетеп кала. Ул сиңа түгел, син аңа баш буласың. Тәвәккәл таш яра, дигән борынгылар, хак шул, бер дә шүрләп торырга ярамый икән. Йә җан, йә мал, дип кыю хәрәкәт иткәнгә күрә генә котыла алдылар. Элеккеге замполит Ваһаповның очравын гына әйт син. Моны бәхетле очрак димичә ни дисең? Курыкмый торган әйбәт кеше икән. Хәер, аның яхшы булуын Әнвәр элек тә белә иде. Хәзер исә, минем кеше түгел, дип, берни эшләмәсә дә хакы бар иде. Юк, кешелекле кеше бүтәннәрнең баласенә битараф булып кала алмый икән. Үзенә кыенлык китереп булса да ярдәм итә. Ә Сөенчалинны ул каты адәм дип белә иде, хәзер йомшарган, әйбәтләнгән. Ул начальнигы каршына кереп: бу — иреннәреннән сөт кипмәгән пацаннар белән нишлисең инде, балалар тек балалар, дип әйткәндер. Шуңа ул да ригая иткәндер. Әллә аңа Ваһапов шалтыратты микән? Киеменә, төсе-кыяфәтенә караганда нииндидер штабта эшли булса кирәк... Әйе, өлкәннәр аларга чын балаларга карагандай мәрхәмәт белән карадылар.

Повар, ипле генә холыклы әрмән егете Костя да Әнвәрне олыларча: малайка, дип кенә йөртә, артык эш белән теңкәсенә тими, дөрес, үзе дә эшкә иренчәк түгел иде. Тик Әнвәрнең бәрәңгене бик тиз әрчүенә генә гаҗәпсенеп карап тора. «Шул арада бетердеңдәмени?» — дип, ышанып җитмичә әрчелгән бәрәңгеләрне алып-алып карый. Аннары Әнвәрнең үткен пәкесен тотып, үзе әрчеп карый, юк, алай тиз барыбер булдыра алмый, бәрәңгесе шакмак булып чыга. Пәкене кире бирә дә Әнвәрнең кулларыннан күзен алмый. Теге күз ачып йомганчы бәрәңгенең кабыгын, юка гына алып, әрчеп тә куя. Кечкенәдән гел бәрәңге белән үсте ул, аның бәрәңге әрчемәгән, ашамаган көне булмагандыр да...

Кай көнне бүтән төрле эшләр дә күп була. Азык-төлекне олаудан старшина блиндажына ташырга туры килә. Кечкенә ак мичкәләр, бик күп төрле әрҗәләр, кап белән бәрәңге. Ул сүзсез-өнсез генә эшли. Аңа бу эш рәхәт, тансык. Колхозда көн-төн эшләгән чаклары искә төшеп куя. Нинди эштә генә йөрмәде ул! Ике ат белән транспортта, сабанда, көлтә ташуда. Ә армиягә китәсе җәйне бригадир Ситдыйк абый аны борчак сугуга куйды. Сугу дигәч тә, молотилка белән түгел, ә менә болай: чабылып, күбәләрдә кипкән саламлы борчакны зур ындыр табагына калын гына итеп җәяләр. Әнвәр исә, алты тайны икешәр-икешәр бер-бер артлы тезеп, шуның өстеннән чаптырып йөртә. Салам тапталып, юкарып беткәнче йөртә. Аннары тайларны читкә чыгарып тора да, хатыннар борчакны әйләндерәләр. Шунда ук тайларны түгәрәккә кертеп, Әнвәр тагы йөгерттерә, ат тояклары астында коры салам тетелеп бетә. Ичмаса бер бөтен кузак калсынчы. Юк, бик шәп суга тайларның күндәм-елгыр аяклары. Саламны селкеп алалар, җиргә ядрә кебек эре ап-ак борчак калын катлам булып төшә. Тузан эчендә эшләсәң дә, әйбәт ягы бар. Таң белән килгәч тә хатыннар кыр станындагы зур казанга борчак боткасы пешерергә куялар. Өйләгә ул бик шәп булып, тәмле исләр таратып күпереп пешә. Кладовщик тоз да җибәргән булса, ботка инде оҗмах ашыдай тәмле була. Көндез әле аны ашап бетереп булмый, ә кичкә ул куера, каты хәлгә килә. Сабан калагыдай калак ясап, аны казаннан китеп-кисәкләп аласың. Ашъяулыгыңа төреп куясың һәм өйдәгеләргә бик зур кучтәнәч итеп алып кайтасың. Әнвәр ике айга якын тайлар белән борчак суктырды, шунда ул шактый тазарган иде...

Азык-төлек бушатылып беткәч, пар ат җиккән олау китеп барды, Әнвәр ярны чокып кереп эшләгән блиндажы алдына барып утырды. Салкынча булса да көн бик тын, рәхәт иде. Ә текә яр астында куак ышыгына урнашкан кухняда Костя казан асларына ягып җибәрде. Әнвәр утынны бик әйбәтләп ваклап куйган иде. Хәзер Костя күзенә чалынмыйча гына блиндажга кереп ятарга кирәк. Ул исенә килгәләгәнче бераз черем итәргә була, карт солдатлар әйтмешли, балта чапканчы түмәр ял итеп

тора. Ләкин шул чак аның янына ашыга-ашыга Зарипов килеп чыкты. Култыгында ниндидер төенчек бар, бушлат изүе ачык, һәрвакыттагыча чиста итеп кырынган, ак яка теккән.

— Слушай, бер ящик әмәллисе иде, менә өйгә күчтәнәч җибәрергә исәп?— диде ул эш Әнвәрдән торган шикелле гозерле тавыш белән. Әнвәр бик алҗыган иде, кузгаласы килмәде, ягарга хәстәрләп куйган ватык әрҗәләр өелгән утынлыкка күрсәтте. Зарипов төенчеген блиндаж ишеге төбенә куйды да шунда таба китте һәм, кулына балта алып, каккалый-суккалый да башлады. Ул арада Костяның җырлаганы ишетелде. Казан артына, тәгәрмәчкә баскан да озын саплы чүмече белән боткаsucc болгата, үзе бик дәртләнеп җырлый. Һәрвакыт җырлый ул, һаман бер җырны көйли: «Шаланды полные кефали в Одессу Костя привозил. Все биндюжники вставали, когда в пивнушку он входил. Я вам не скажу за всю Одессу, вся Одесса очень велика. Молдаванка из Пересы обожает Костю-моряка...»
Һава бик тын булганга аның җыры радиодан ишетелгәндәй ягымлы яңгырый, аннары чыкылдап торган әрмән акценты бу җырга шуклык өсти һәм үзеннән-үзең елмаясың.
Шул мәл кинәт: «гөрс!» итеп каты шартлау яңгырады. Ярчыкларның выжылдаганы колакка чалынды. Әнвәр яр өстендәге куаклар турында ак мамыктай оешкан төтен болытын шәйләп алды. Немец һавада шартлый торган шрапнель ата икән. Шунда ук тагы «гөрс!» Әнвәр блиндаж эченәрәк шуышты. Әле генә утырган җиргә берничә ярчык төшеп кадалганын күрде. Үткен кырлы, кырлары елык-елык килеп торалар. Тагы да катырак шартлау яңгырады, бусы бик якын һәм нәкъ кухня турында булды. Учак төтене белән шрапнель төтене бергә буталды. Берни аерып булмаслык иде. Тукта, Костяга бер-бер хәл булмадымы?— дигән уй йөгереп узды Әнвәрнең башыннан. Ләкин немец хәзер чираттагы снарядын атачак дип уйлап, ул көтеп торырга булды. Әмма ату бүтән кабатланмады. Әнвәр сагаеп кына кузгалырга иткәндә кухня яныннан:
— Малай-ка-а!— дигән ялварулы тавыш ишетелде. Бу Костя иде. Нәрсәдер булган, ахры, дип, Әнвәр, уктай атылып, кухня янына барды. Ләкин алда төтен, берни аерып булмый иде. Ул кухня арбасы тирәли чапкынлап йөрде, астан уфылдау авазы килгәнгә җиргә чүгәләде. Караса, ни күрсен: Костяның аяклары арткы тәгәрмәчләр арасыннан чыгып тора, ә гәүдәсе нәкъ казаннар астында ята. Ул тәгәрмәчкә шундый итеп шап кереп кысылган, ни алга, ин артка таба чыга алмый азаплана икән. Ах-вах килеп талпынып-талпынып карый, юк кына. Ә чалбары балтырына чаклы сыдырылып төшкән һәм шәрә тәненә ярчык тишкәләгән казан төбеннән кайнар су чәптереп ага икән... Костя хәтәр уфылдый, Нишләргә? Әнвәр исен җыеп, алгы якка үрмәләп килде һәм Костяның култыгыннан эләктерде, бар көченә тарта башлады. Костя үзе дә тырыша иде. Тарта торгач, бер чалбар балагы шытырдап умырылып китте һәм Костя аягын тәгәрмәч арасыннан йолкып алды. Аннары гәүдәсен, казан астыннан суырылып, тартты да тартты. Очасының йомшак җире бик каты кызарган булуын күргәч, Әнвәрнең көләсе килде, ләкин Костяның чытылган һәм күгәреп киткән чыраена карап тыелып калды. Костя уңайсызланып кына торды, чалбарын күтәрде, йөзе тагы да ныграк чытылды. Арт як бик пешкән иде булса кирәк. Шулай да сер бирмәскә теләп, тишкәләнгән казан өстен учы белән сыйпаштырды, аякларын көчкә атлап барып казан астындагы сүнеп бетмәгән кисәүләрне алып аткалады. Хәлсезләнгәндәй казан кырыена таянды да, кухняның эштән чыгуына ышанып, кулын өметсез генә селтәде һәм бер сүз дә әйтмичә, башын игән килеш, блиндажына таба китте. Ул нык бөкрәеп атлый иде.

Әнвәр нишләргә белми, аңа ничек ярдәм итәргә кирәк икән, дип басып торганда, утынлыкта ящиклар арасында Зариповның үлеп ятканын күреп алды. Башта моңа һич ышанмады, әллә авыр яраланганмы дигән

өмет белән янына барды, ләкин аңарда җан әсәре калмаган иде инде. Кулыннан балтасы да төшмәгән, бераз күгәреп калган аксыл йөзе белән янәшәдә генә ята иде. Башына ярчык кергәндер инде. Менә язмыш!

Ул арада кухня тирәсенә командирлар, старшина һәм сугышчылар җыелды. Нәрсә булды да нәрсә булды?— дип, бер-берсеннән сорашалар. Бу хәлнең ничек килеп чыгуын беләселәре килә. Кухня бит алгы сызыктан ике-өч чакрым тылда, аннары яшеренеп тә урнашкан. Берсе әйтә: цельне разведка самолеты күргәндер, ди, икенчесе: бу мөмкин түгел, дип каршы төшә. Ахырда Костяның үзе ярдәмендә мәсьәләне ачыкладылар: җил булмаганга кухнядан төтен торба кебек туп-туры күтәрелгән һәм немец моны күреп алган да шрапнель тондырган...

Тафтилов белән Идрисов басып торган көе хәзер нишләргә кирәклеге турында сөйләшәләр.

— Яким Зиновьевичка барырга туры килә,— диде Идрисов сабыр гына тавыш белән. Тафтиловның алсурак йөзендә эчке уй шәүләләре йөгереште.

— Ул сине ярата, син бар,— дип куйды һәм күзен кысыбрак Идрисовка карады. Теге көлемсерәде, «ярата» дигәнендә киная барлыгын чамалады булса кирәк, Яким Зиновьевичның каты, ләкин шулай да гадел кеше булуын яхшы беләләр иде. Идрисов папиросын ниндидер бер кискен хәрәкәт белән җиргә ташлады да, башын туры гына тотып, китеп барды. Тафтилов янына старшина килде, сугышчыларга «коры паек»ны ничегрәк өләшергә икән, дип кайгыра иде ул.

Әнвәр повар блиндажына керде. Костя йөзтүбән яткан иде, чырае тәмам сүнгән, пешкән җире хәзер тагы да ныграк әрни башлаган булса кирәк. Ул ыңгыраша, авыртуга чыдый алмыйча, башын як-якка боргалый. Санинструктор кыз килгәч, Әнвәр чыгып китте. Ул нигәдер Костяны җәлләмәде, үзенең күңеле салкынлыгына үзе аптырады. Элек ул алай түгел иде, фриц тырнагында булып чykkаннан соң аның җанында ниндидер кыл өзелгән иде, шуннан бирле һәр җан иясенә кызганып карау хисе бетте шикелле. Ләкин үлгән кеше гәүдәсен күрсә, соңыннан шул күз алдына килеп, аны газаплап бетерә. Һич шуңардан арына алмый. Менә Зариповның күкселләнгән аксыл йөзе, янәшәсендә яткан балтасы белән аның күз алдына килеп озак эзәрлекләр әле...

Икенче көнне иртән резина тәгәрмәчле яңа кухня һәм аш пешерүче ике кыз китерделәр. Әнвәргә эш калмады шикелле. Аны Зариповның посылкага дип алып килгән төенчеге борчый иде. Нишләтергә? Ящик ясарга да өенә җибәрергә, дигән гади карарга килде ул. Старшина янына сугылган Мирхаска да шул хакта әйтте һәм теге бик хуплап эшкә үк кереште. Фанеры, планкалар күп иде, пөхтә генә тартма әмәлләп ташладылар. Сугышчан иптәшләренә соңгы хөрмәт күрсәтү — намус бурычы иде. Зариповның үзе әзерләгән һәм калган әйберләрен, кәгазьләрен шунда салдылар. Мирхас аның батырларча һәлак булуы хакында хат та язып куйды. Авыр гына посылканы почтага илтеп тапшырдылар.

Әнвәр батареяга кайтты. Бар төштә дә һөҗүмгә хәзерлек барганы күзгә ташлана иде. Бигрәк тә төннәрен машина һәм солдатлар позициягә урнашып ыгы-зыгы килә иде.

Кинәт кенә җылытып җибәрде. Көне-төне яңгыр ява башлады. Чөнки диңгез бик якын. Кыш монда һәр елны шулай икән. Җир өсте пыяладай шома боз белән капланды. Машиналар йөри алмас булды, кеше дә көчкә-көчкә генә аякланып хәрәкәт итә. Ә пушкаларга снаряд ташырга кирәк. Студебеккерларның тәгәрмәчләренә чылбыр урнаштырып карадылар, юк, булмый, буксовать итеп тик яталар. Менә шул чакта чарасыздан Мирхас плен алып кайткан чылбыр тәгәрмәчле вездеходны искә төшерделәр. Аны бер кирәге чыгар, дип трофей-командадан яшереп калдырганнар иде. Ләкин йөртә белүче юк. Шул муенны кисә. Андыйлар яңа килгәннәр арасыннан да табылмады. Идрисов тагы Яким Зиновьевич

янына йөгерде. Әгәр немецны озатмаган булсалар, алып кайтып, бер-ике тәүлек эшләтергә.

Бәхеткә каршы, немецны озатмаган булганнар. Баш штаб каршында антифашист немецлар күп икән, хәтта генераллары да бар, имеш. Кыскасы, Идрисов, чегәнләнеп һәм Асоевның танышлыкларыннан файдаланып, теге немецны алып кайтты. Юка гына гәүдәле, урта буйлы, зәңгәр мундиры өстеннән безнең соры шинельне һәм шундый ук солдат бүреген киеп алган. Ул да антифашистлыкка язылган булган, ди. Вездеходта эшләргә бик теләп, ризалык белдергән. Ул Мирхас белән бик җылы күреште.

— Тоуариш...— диде сизелерлек акцент белән. Сугышчыларны гаҗәпләндергәне тагы шул булды: русчаны аңлашылырлык итеп сукалый иде. Бер атна эчендә шулай өйрәнеп өлгергәнме?

Солдатлар аңа ерткыч җәнлеккә караган кебек карыйлар! Якын килергә базмыйлар. Мирхас кына алай итми, ул немецка иртәнге аш та алып кайтып бирде һәм кулына чирек буханка икмәк тә тоттырды. Теге башта шул хәтле ризыкка аптырап калды, көне буенамы бу? — дип сорады. Юк, бу иртәнгесе генә дигәч, каерып-каерып ашарга кереште. Ашны да, ипине дә бик шәп ялмап куйды һәм шуннан соң аның теле ачылды. Эшкә тотынырга кирәк, дип Мирхаска әйтә башлады. Юк, көндез мөмкин түгел, диде Мирхас һәм сөйләшеп киттеләр. Немец ремонт мастерскоенда рус әсирләре белән елдан артык эшләгән икән, русчага шунда өйрәнеп калган. Мин бит Цербет шәһәреннән, диде ул. Аны руслар яхшы хәтерлиләрдер, Екатерина II Цербетта туган. Рәсәйгә алып киткәндә аңа уналты яшь булган һәм бер авыз сүз русча белмәгән. Ә нича еллар Россиядә патша булып торган үзе, көчле хатын булган, шайтан алгыры...

— Ни өчен син антифашист булдың? — дип сорыйлар немецтан, аның сүзләренә ышанмыйча, бары кызык өчен генә. Көймә су төбенә китә башлаганын сизгән күсе дип уйлыйлар бугай. Немец бик куштанланып елмая, эре саргылт тешләре күренеп китә, муенын суза-суза сөйли.

— Алар үзләре мине антифашист итте. Башта үзем белән бергә эшләүче иптәшем турында донос ясап торырга куштылар. Мин булдыра алмыйм, дидем. Ай-һай, Ганс, бик нык үкенерсең бит, дип янадылар. Һәм шул сүзләре дөрескә чыкты. Минем эштән гаеп таба башладылар. Әле болай, әле тегеләй итеп кимсетәләр. Өйгә шымчы-провокаторлар җибәрәләр. Теге килә дә, башын исереккә салып, бездәге тәрле кимчелекләрне сүгә, фюрерны тирги. Һәм астан гына минем йөзне күзәтә — тәэсире нинди булыр. Фюрердан риза түгеллегемне йөземдә бер генә тамыр селкенеп белгертсә — мин беттем. Эштә дә шулай җанга тукынып сыныйлар, өйдә дә тынгылык бирмиләр. Түзәр хәлем калмагач, фронтка үзем теләп киттем...

Солдатлар, үз башларында мондый хәлне татыганнары булмаганга күрә, ышанып җитмәгәндәй, башларын як-якка чайкап, гаҗәпкә калалар. Бераз уйланып торганнан соң, булмас дип әйтеп булмый, диләр. Әнә бит газетада беркөн генә укыдык: фашистлар кешеләрне, тере килеш газ камераларына тутырып, агулап үтерәләр икән... Шуларны әйткәч, Ганс расслагандай, ияген кага һәм, йөзен чытып, кулын селти, ишетәсе килми, янәсе...

Кайсыдыр безнең «Катюша» турында немецтан кызыксынып сорап куя:

— Ул залп биргән чакта ыштан төпләрегез юешләнмиме? — ди һәм, теге аңласын өчен, үзенең артына суккалап күрсәтә. Немец бик тиз төшенә.

— О-о! — ди Ганс һәм аның күзләре бәрәңгедәй зурая.— Аны «шварц тод», ягъни кара үлем, дип йөртәләр. Дәһшәтле нәрсә, ну йөрәкне ала инде.

— Сездә аны ник ясамыйлар? — диде блиндаж бусагасында утыручы солдат.

— Серен белмиләрдер,— дип, Ганс Мирхаска таба борылды.

— Аның сере снарядта ди шул. Белергә дип сүтә башласалар шартлый да бетә икән...

Мирхас сәгатенә карап алды, якты көздә машинаны көйләп куярга кирәк, дип Гансны алып чыгып китте. Төнлә алар тупчылар белән таң атканчы снаряд ташыдылар.

Мөслимов телефонда дежур иде. Трубканы бер колагына бинт белән бәйләп куйган да ылыс җәйгән идәнгә сузылган. Аяк сызлый дип бер ботинкасын салып куйган. Линия өзелсә, Әнвәр генә чаба. Ә ул һаман өзелеп кенә тора. Әллә нинди каһәр төшкән чыбык булды бу. Хикмәт чыбыкта түгел билгеле, аның кай төштән сузылуында. Әйтергә кирәк, линия машина, танк бик күп йөри торган җирдән сузылган иде. Немец күзеннән ышык урман буе бу. Монда хәрәкәт тынып тормый. Җирдә яткан кабельне танк, машина, тәгәрмәчләренә эләктереп, өзеп калдыра, кайчак бөтен линиясе-ние белән өстерәп китә. Бүген төнлә андый ук хәтәр хәл булмады булуын, ләкин кабель ярты сәгать саен диярлек өзелеп торды. Әнвәр бер тамчы да черем итә алмады. Артык арыганга күрә иртән ашы да көл чәйнәгәндәй тәмсез булды. Әмма ул сер белгертмәде. Әчтән үзен гаепле тою һәм шул гаебен йоларга тырышу аңа түземлек бирә иде.

Көне буе бозлы яңгыр сибәләде, ә кичтән туңдырып җибәрде, аннары рашкы яварга тотынды. Бу каты бөртекле кар, биткә бәрелә дә чеметтереп ала. Әнвәр йөзен кырыйга борып, линия буенча йөгерә. Хәле бетсә дә бер минут туктап тормый, элемтәсез яшәү мөмкин түгел. Катгый тәртип шундый. Ул караңгыда үзенең кабелен тапты да, шуны күздән югалтмаска тырышып, иелеп, кызу-кызу атлап бара башлады. Бу тирәдәге бүтән частьларның унлаган кабеле бер төштән уза,үзеңнекен танырга, бутамаска тиешсең. Кичә ул ялгышып әллә кем өзеген ялгаган иде, тикшерер өчен порольне әйткәч, әшәке сүз генә ишетте. Аннары үз кабелен эзләп китте. Кабельләр бары да бер төсле булу өстенә, төн дә караңгы, немец ракеталары яктысында шәйләп калырга тырышасың. Менә хәзер дә шул яктыда үзенең линиясен тапты ул һәм өзеген дә күреп алды. Ялгагач, Мөслимов белән бер-ике авыз сүз алышты да, тынычланып, кайтырга борылды. Кыр уртасыннан гына элдерергә булды. Моннан батареяга икеләтә туры иде. Бераз вакытны отса, әз генә йоклап алырга да өмет бар. Бигрәк тә таң алды яман, шул чакта йокыга һич чыдап булмый, бөгә дә сала инде. Таң йокысы бер унбиш-егерме минут кына эләксә дә көне буена җитә... Шулай өмет белән ымсынып тиз-тиз атлап кайта иде, кинәт аяк асты шытырдап ярылды һәм ул бил тиңентен суга чумды. Тәнен ялкындай салкын өтеп алды, шул аны бик тиз исенә китерде. Су тулган зур снаряд чокырының өсте каткан булган һәм ул абайламыйча шунда килеп кергән икән. Бозларны вата-вата чокырдан көчкә чыкты. Чыгу белән суык аны боз сөңгесе итеп катырды. Бар көчкә йөгерүдән башка чара калмады.

Тупчылар блиндажында мич яна иде, Әнвәр шунда атылып барып керде. Бары да йоклаганнар. Учакка чыбык-чабык өстәп, обмотка-ботинкасын чишенеп, сырган чалбарын салды. Эчке ыштаннан гына калып, утка якын ук килеп ятты. Тәнен пешерә-пешерә аякларын җылытты. Ләкин эченә һич җылы үтми, тешләре тешкә бәрелеп шык-шык киләләр иде. Утка аркасын да куеп карады, юк, һаман калтырата.

Бераздан аны Мөслимов эзләп керде.

— Нишләп качып ятасың? — дип, кычкырды ул ачу белән. Йөзе-башы хәтәр дәһшәтле, әйтерсең лә зур бер командир.

— Күрмисеңмени? — диде Әнвәр дә тавышын күтәреп. Ә эчтә ачуы кузгалып тамагына килеп тыгылды, тынын буды. Әнвәр көчкә генә ни булганын әйтә алды, тәне тагы да ныграк калтырый башлады.

— Күзеңне ачыбрак йөрергә кирәк. Чыбык өзелде анда...

— Бар әнә үзең, күзеңне ачыбрак,— дип үчләнде Әнвәр.

— Замполит миңа телефонда гына торырга кушты. Тәк што...— Мөслимов, бүртенеп, кыяфәте белән бик нык янап чыгып китте. Әнвәр, кешеләрнең ояла белмәүләренә эчтән сызып, юеш ботинкасын, судан авырайган чалбарын киде. Яшел аппаратын асты да тагы линия ялгарга кузгалды. Бик кыен иде. Тешен шыгырдатып кысты, әз булса да җылыну өчен атлый-йөгерә барды. Рашкы һаман биткә бәреп ява иде. Ярты төн узып бара түгел микән инде, дип уйлады ул, немец ракеталарының сирәгрәк чөелүен шәйләп.

Кабельне әледән-әле җирдән тартып-тартып карап барса да бер урман борылышында кинәт ул аны югалтты. Караңгыда берни абайлап булмый, ракета яктысы да төшми иде. Бер дә булмагач, җиргә мүкәләп эзләде, кармаланды, барыбер табылмады. Ахырда кире кайтты, кабельне учында шудыра-шудыра тагы килде. Линия шунда өзелгән икән, ләкин икенче очы юк иде. Тагы дүрт аяклап бар тирәне эзләп чыкты, әллә пәри яшергән инде? Биредән үткән линияләрне аппаратына ялгап тикшергән итте. Юк кына. Эшпегә таба бармыйча чара калмады. Ул ялан кырга чыкканда таң беленеп килә иде инде. Сукыр пулялар колак кырыеннан гына сызгырып үткәлиләр. Бу выжылдау җанга эчкәре үтеп керә торган шомны тагы да көчәйтә, ничектер бер бәләкәй генә йомарлам булып кечерәеп каласы килә. Ләкин бернигә карамый барырга кирәк. Эшпегә җитәрәк аны бер күренеш гаҗәпкә калдырды. Бер калкурак җирдә бер-берсенә тоташкан зур-зур ике авиабомба чокырлары. Алар шундый киң һәм тирәннәр, рәхәтләнеп дүртпочмаклы йорт кереп утырышлы. Менә шул чокырның кырыйларына, кечкенә-кечкенә окоп һәм блиндаж шикелле оялар ясап, укчылар урнашканнар. Үзенә күрә түгәрәк оборона. Әмма чокырларның эче үзле кызыл балчык, аякка тышау кебек ябышадыр, ә төптән су күтәрелеп килә. Су өстендә буш консервы калайлары йөзеп йөри. Казырга җир туң булгач, утта янмас, суда батмас солдат монда да югалып калмаган. Адәм баласы тәмугта да әмәлен табар, барыбер яшәр, валлаһи.

Күзәтү пункты теге чокырлардан әз генә сулда, аңа уйсу җирдән киләсе. Әнвәр шунда гына бер очы блиндажда булган кабельне күреп алды. Димәк, биш йөз метрлап чыбык юк дигән сүз. Идрисовның бик каты ачулануын көтеп, ул блиндаж алдына төште. Нәкъ шул мәлдә түбәннән, баш очыннан гына чыжылдап, ут сызыклары, карамчыклар узды. Һәм моннан өч-дүрт йөз метрларда гына торган немец окопларында шартлады.

— Катюшалар залп бирә, фрицлар кыймылдый башлагандыр,— диде Мирхас һәм стереотрубага ташланды. Шунда ук: «Әһә, фрицлар, нашатыр кыстырган кебек чабышасызмы?»— дип, шатланып кычкырды ул. Идрисовның төк үскән иягенә җылы сызыклар чыкты. Ул ачуланмады — карганмады, Әнвәргә запас катушканы тоттырды да тизрәк элемтә сузарга ымлады. Әнвәр аның тиргәмәвенә күңеле булып, теге очка катушканы ялгады һәм сүтә-сүтә тизрәк китеп барды. Өзекне ялгап маташканда «Катюша» икенче төштән залп бирә иде. Әйтергә кирәк, хәзер «Катюша»лар шулай бик еш немецларны ут белән керендерәләр. Ул ату беләнике нче җиргә күчә һәм немецаның койрыгын һич тә тота алмый. Шул ягы белән «Катюша» немецның бик нык җанын корыта...

Әнвәр кайтып ылыс идәнгә ауды. Аяк табаннары ялык-ялык килеп авырта, буыннары «гүли», башы, зиһене томаланган. Эт булып арыган, кулларының җеп өзәр дә хәле юк. Саны кыйнап ташлаган шикелле иде. Әз генә черем итәсе иде, дип күзләрен йомды, әмма йоклап китә алмады, өченче көн якында гына снаряд шартлап сул колагын канаткан иде, шул «атарга», чәнчергә тотынды. Ул арада Мөслимовның сүгенгәне ишетелде:

— Тагы өзделәр, Гитлерның авызын өшкерим!

Карулашырга Әнвәрнең көче юк иде, тешен шыгырдатып кысты

да урыныннан кузгалды. Тегеңә эче тулы ачуын белгертеп, күзенең агы белән кистереп карады. Тик эт каешына әйләнгән Мөслимовның төге дә селкенмәде.

Өч тәүлек шулай чапты ул. Дүртенче көнне тәмам бетте, тамагыннан азык үтмәде. Башы тубал кебек, берни уйлый алмый, исәп йөртә алмый, тилебәрән орлыгы ашагандай миңгерәүләнгән. Авыр кабаклары күзен йомганда уттай пешерә. Ул аягын да, кулларын да сизми шикелле. Кая барганын, нигә барганын да уйламый. Бар эшне аңы белән исәпләп түгел, ә автомат рәвештә генә эшли. Пуля сызгыруларына, мина шартлауларына да исе китми, аңа куркыныч та, үлем дә барыбер. Бары бер нәрсә генә һич ~~нигенмичә~~ миен чүкеп тора: әз генә черем итеп алырга, биш минут кына... Әнә урман эчендә чыбык-чабык өелеп тора, шунда ятып йоклыйсы иде. Бричкага җигелгән ат килеп туктаган, ул рәхәтләнеп йоклый. Тегендә бер ауган бүрәнә нинди тәмле итеп черем итә... Әллә шул бүрәнә кырыена барып авыйм микән?.. Тукта, элемтә өзелсә, оятын кая куярсың? Уф, бүтән булдыра алмыйм, йә яраласын, йә үтерсен, миңа хәзер барыбер... Шундый уй чагылып узды аңыннан, ләкин шунда ук сүнде, соры пәрдә белән капландыргандай булды. Ни булса шул, ике дөнья бер кәнди...

Сызылып таң атып килә, күз керфекләренә йокы гер булып асылынган, атлаганда күзләр йомыла да абынып егылгач кына ачыла. Ул үзләренең студебеккеры торган җирдән узып бара икән. Аяк буыннары чәнчеп-чәнчеп авырта, юк, бүтән атлап булмый... Аны-моны исәпләмәстән машина янына килде һәм бөркәүле кузовка көчкә-көчкә өстерәлеп менә алды. Андагы алам-салам өстенә ауганда берни белми иде инде.

Ләкин озак та тормый аны яңадан килеп таптылар. Мөслимов хәтәр сүгенә, яный иде, Әнвәр аның тавышын ишетә, әмма уяна алмый. Санын кыймылдатырга, башын күтәрергә хәле юк. Бар җиренә мамык тутырылган сыман, бер мускулы да хәрәкәтләнми. Ахырда Мөслимов, бик каты кыҗрап, бортка менеп атланды да Әнвәрне йолкып, өстери башлады. Теге үлгән шикелле ята бирә. Барысын ишетеп, оялып ята, әмма кулын да, аягын да кымшата алмый. Мөслимов юри ятасың дип тирги, мыскыл итә, котырта. Әнвәрнең рәхәт мышнавын күреп, тәмам түземен җуйды, ачу белән каешыннан һәм бер аягыннан элдертеп алды да борт артына шудырып ~~төшереп~~ җибәрде. Башы дыңк итеп җиргә бәрелгәч, Әнвәр уянып, күзләрен ачты. Берни аңлый алмыйча карап ятты. Нәкъ шул моментта энпедән кайтып килүче Мирхас алар янына туктады.

— Нишләтәсең аны?— диде каты гына. Ул Мөслимовның кыланышын тегеннән үк күргән бугай.

— Линия өзелде, панимаешь, ә ул качкан...

— Күрмисеңмени, кеше нишләп беткән?!— дип, ачулы йөз белән тегеңә текәлде һәм җирдә өнсез кебек яткан Әнвәргә күрсәтте.— Харам булмас сиңа да әзрәк тәпиләү!

Мөслимов койрыгын кыскандай тынды, каршы эндәшмәде. Ул сержанттан шүрли иде шикелле. Әнвәр көчкә генә торып басты һәм алар артыннан иярде.

— Бар, бар!— диде Мирхас Мөслимовка боерып. Теге теләр-теләмәс кенә аппаратны Әнвәр иңеннән алды, үзе мәче күзләре белән тирәягына карана, замполит күренмиме, ул очраса сержант приказына буйсынмас, Тафтиловка аркаланырга булыр иде. Юк, шуңа ачудан бүртенеп, кыяфәте белән хәтәр янагандай китте.

Блиндажга кергәч Әнвәр идәнгә егылды, йөзендә үлек төсе, үлек күкселлеге, иреннәре кеөп яргаланган, кан тибеп тора. Мирхас аңа карап алды да бик нык җәлләде. Авырый, ахры дип уйлады. Чемоданыннан баклажка алып, ярты стакан аракы салды һәм Әнвәргә бирде. Теге аңгыра шикелле күзләрен ачалак-томалак китереп торды да стаканны

су урынына авызына койды. Ул аның ачысын да тоймады. Тик бераздан гына тәнендә кан йөгерешкәнен, җан кергән кебек булганын сизде, икенче мәлдә тәмам изрәп төшкәнен белми дә калды.

Мирхасның кәефе әйбәт иде, ылыс түшәлгән идәнгә, телефон кырыена сузылды да уйга талды, ә уйланыр нәрсә бар иде. Өченче көн энпедә Хәбиров очрап сөенечле хәбәр әйтте: Рифаның сине бик күрәсе килә, фәләң көнне килергә кушты, диде. Моны ишетүгә Мирхасның башы күккә тигәндәй булды, эчтән генә бик нык шатланды. Ләкин бераз вакыттан соң башына әллә нинди шикчел уйлар килеп тулды. Чынлап та күрәсе килә микән, болай, кайчандыр күз күргән кеше булганга гына микән? Бу аның өчен бик мөһим иде. Әллә кем булуын, зур абруйга ирешүен күрсәтер өченме? Күпме генә язмыш безгә сукмасын, без, янәсе, төшеп калганнардан түгел. Ул лейтенант булган икән инде. Ухажерлары да капитан да майордыр. Мине күрергә теләве үзенең культуралы, итагать иясенә әверелүен исбатлау өченме? Дәрәҗәгә күтәрелсәк тә иске танышларны онытмыйбыз, дип белгертү өченме? Шулай да кызык, теге вакыттан соң өч ел узган, ә Мирхаска бик озак тоелды. Ул кызны ниндидер өмет белән һаман йөрәгендә саклап, эчтән генә янып, кичереп яшәгәнгә вакыт бик озак, авыр булгандыр. Ул аны йөрәгеннән һәр җепселен берәм-берәм авырттыра-авырттыра йолкып атты, тагы күңеленә кертеп утыртты, хыялый өметләр белән җанын юатты, киңәндерде. Өметен барыбер өзмәде. Инде менә хәзер үзе мең-мең тапкыр теләгән, язмыштан ялварган очрашу алга килеп баскач, күңелен ниндидер курку биләп алды. Әйе, хәзер ул аны күрер дә үзенең аңардан нинди ерак, аңа чит булуын сизәр. Ничә еллар буе яратып-янып йөрүләре бары бер фаҗигале алдану гына булуын тояр. Шунда бар вөҗүде челпәрәмә килеп төшәр. Күңеле кеше ташлап киткән йорттай буш калыр. Хыял белән булса да яшәп торган өмете дә калмас, юкка чыгар... Юк, аны ни генә көтмәсен: барырга, күрергә. Бәлки, ул мин уйлаганча борын чөймәгәндер, артык һавалы түгелдер... Алай дисәң, тылдагы госпиталь ише җирдә хатын-кызлар зур хөрлек белән файдаланалар. Игътибар үзәгендә генә булу бераз кәперәйтсә гаҗәпмени? Тик шулай да аны күрәсе килү бәгырьгә төшкән, нинди икән ул хәзер? Үзгәргәндер инде, таныйрлык та түгелдер. Элеккегедән дә матуррак булып чәчәк аткандыр. Мине күрер дә: нинди картайган, таушалган дияр, сугыш моның өстеннән юл тигезли торган каток булып үткән дип уйлар. Әйе, миңа авыр булды, ә мин исә һаман да шул хыялый авыл малае. Шулай да бирешмәдем шикелле әле. Шуны сиздерер өчен бик яхшы киенеп барырга кирәк. Парадный киемнәре бар аның: күн тужурка, йолдызлы офицер каешы, хром итеге, кубанканы да киеп җибәрергә була. Ә наганны ул һәрвакыт тагып йөри. Тик буш кул белән барып булмас, «Военторгка» сугылып, нәрсә булса да алырга. Кыйбатлы хушбуй күзенә бер чагылган иде шикелле...

Мөслимов кайтып керде дә уйларын бүлдерде. Мирхас телефонны алып карады, ләкин чыбык тагы өзелгән иде. Мөслимов шунда ук моны аңлады һәм йоклап яткан Әнвәр өстенә карады. Ялгарга ул барсын, ди иде аның әрсез күзләре. Мирхас бик катгый итеп кулын селтәде: бар, бар! Тегенең иреннәре кысылды, күзләрен ялт-йолт китерде, әмма бүтән чара юк иде. Һәм мыгырдана-мыгырдана янаулы кыяфәт белән кире китәргә мәҗбүр булды.

Кич булып килә иде инде, якында гына авыр снаряд шартлап җирне селкеткәнгә Әнвәр уянып китте. Гүя җир аның касыгына төртеп уятты. Тәне җиңеләйгән, башы яктырган, аякларының «гүләве» беткән иде. Трубкага тотынды, ләкин анда тынлык, элемтә юк икән. Мирхас стенага башын куеп черем итә бугай. Шунда Әнвәрнең якты миен: бу каһәр суккан линияне бүтән төштән сузарга кирәк, дигән уй сызып узды. Ә кабель каян аласың?— дип, үз-үзеннән сорап куйды ул. Бу линияне җыеп алып, яңа төштән сузганчы байтак вакыт элемтәсез торырга туры килә. Моны рөхсәт итмәячәкләр. Соң нишләргә, запас кабель юк?

Төнлә тагы линия буенча соса кебек әле тегеләйгә, әле болайга йөгерергә туры килде. Бер баруында йөкле олаулар очрады аңа. Ниндидер частьлар алгы сызыктан тылга күченә иде булса кирәк. Бричкаларга нәрсәдер төялгән. Якынрак килгәч, соңгы олауда кабель катушкалары шәйләп алды. Йөрәге дөп-дөп типкәнен ишетмәде, арба кырыеннан тиз-тиз атлавын белде. Кучеры башын игән, йокымсырап кайта — бүтән түгел. Аңа шунда ук уйсыз тәвәккәллек килде, уйлап торсаң, берни дә булдырып булмавын ул үзеннән белә иде. Иплән кенә иң элек бер катушканы йөктән алып җиргә куйды, аннан икенчесен... Вәссәлам. Тылда алар яңасын табарлар әле, дип үзенең намусын да тынычландырды.

Һәм төн караңгылыгыннан файдаланып, энпедән батареяга иң туры юлдан, немецка уч төбендәге кебек күренә торган җирдән, линияне сузып та кайтты. Мөслимов, моны белгәч, күтәрелеп бәрелде.

— Линиягә үзең йөрерсең, минем баш бер генә!— диде. Немец снайперларының кымшанырга да ирек бирмәвенә ишарәләде. Әнвәр кабельне юнәтү дәртенә бирелеп һәм гаҗиз ачудан бу эшне эшләп ташлаган иде, хәзер курка калды. Көндез ул төштән бары үрмәләп кенә үтәргә мөмкин. Карлы-бозлы яңгыр яуган юеш җирдән ике чакрымны түш белән шуып бару ансат булмаячак. Аның эчен таракан кебек чын борчу кыра башлады.

Ләкин, бәхеткә каршы, линия көне буе өзелеп тә карамады. Төнлә дә тыныч булды. Алмашлап йоклап алдылар. Яңа линиядә тавыш та әйбәт, ачык ишетелә иде. Тылдагы дивизион штабы белән рәхәтләнеп хәбәрләш, бернинди тоткарлык юк. Сәхрә. Менә кайдадыр бер кыз белән егет сөйләшә башлады. Әнвәр әз генә тыңлап торгач та аңлады: бу теге повар Костя янына килеп, аны көлдереп, ботка ашап китә торган бик шаян егет, кызлар булып, ниндидер алгы сызыкка яңа гына килгән яшь лейтенант белән сөйләшә иде. Әгәр тавышын үз авызыннан ишетмәгән булсаң, һич танырлык түгел. Нәкъ кызларча инде. Сүзен мәгънәле итеп әйтеп бетермичә җиз кыңгырау кебек чыңлап кителде. Аннары беркатлы рәвештә татлы көрсенеп куя. Шул үзенә тарта торган ымсындыргыч көрсенүе егетләрне ега да сала инде. Үзенә ябыштыра. Егет очрашырга кыстый, «кыз» кыстата, ялындыра, ниндидер бер кызык сөйли: «Вот так случилась, дер киндер получилась», ди. Ахырда «кыз» очрашырга риза була һәм урынын билгеләп, аңлатып маташа...

Бераздан Әнвәр, блиндаждан чыгып, «кыз» күрсәткән төшне күзәтә башлады. Менә шул урында яңа яшькелт шинельдән, мех бүректән яшь кенә кече лейтенант пәйда булды. Сирәк агачлар арасында әрле-бирле йөренә. Ә «кыз» юк та юк. Әнвәрнең көләсе килә, ләкин берүзең генә көлеп булмый икән, шулай да тамаша. Теге шайтан «кыз» да аны качып кына карап, көлеп тора торгандыр әле. Лейтенант йөренә, кыз белән бик очрашасы килә, ахры. Ләкин шул чак һава ярып нечкә сызгырган авазлар ишетелде. Немец миналары сирәк агачлык тирәсендә шартлаганы күренде. Аһ, лейтенант харап була язды бит. Юк, блиндажга посарга өлгерде шикелле. Менә шулай уеннан уймак та чыгуы мөмкин икән бит...

Ну, лейтенант белсә, теге артистның кирәген бирәчәк әле.

Батареяда партиягә һәм комсомолга керү хакында сүзләр йөри башлады. Бу тиздән зур һөҗүм башлану билгесе иде. Мирхас Әнвәрне комсомолга керергә өндәде. Тырышлыгың бар, башың да эшли, диде. Ул аның яңа еузган элемтәсен замполитка да барып мактаган. Замполит бик хуп күргән. Шулай булгач, әллә тәвәккәлләргәме дип уйланды Әнвәр. Аның комсомолга керәсе килә иде. Әмма әсирлектә булуын искә алырлар, дип шүрли ул. Шул гел итәгеннән тарта. Аннары русча гариза яза белмәвенә дә ояла. Мирхас акыллы егет, Әнвәрнең эчендә ниләр сызганын аңлаган бугай, тиз генә гариза язды да, үз кулың белән күчер, дип аңа кәгазь-каләм тоттырды.

Мирхасның тылга барып киләсе бар иде, Әнвәрнең гаризасын юл җаеннан комсоргка кертеп чыгарга алып китте. Комсомолга керү Әнвәрдә куанычлы өмет уяткан иде. Әгәр алсалар, теге фриц өрәкләреннән арынып кебек тоела аңа. Куркыныч кара шәүләләр билгеле сызык аша үтеп чыга алмаслар, югалырлар һәм аның күңеле, курку басымыннан арынып, элеккегечә иркенләп калыр. Аңа кырын караулар да бетәр...

Икенче көнне Мирхас зур сары фетр чемодан күтәреп кайтты. Әнвәргә өйрәнә торырга, уч төбе кадәр генә китапчык — комсомол уставы бирде. Ә үзе, чемоданнан ялтырап торган кара күн тужурка алып, аңа погоннар тегәргә кереште. (Батареяга Тафтилов килгәч, аның бу киемнән йөрүен тыйды., Шуңа күрә Мирхас әйберләрен, үзенчә әйтсәк, парадный киемнәрен шоферларда тота иде.)

— Комбат өч көн ял бирәм диде,— дип, шат тавыш белән сөйләнде Мирхас. Оборонада торганда үзен күрсәткән сугышчыга ял бирү бар иде. Күңеле күтәренке, эчтән ниндидер көй көйли, энә-җепле кулы дәртләнеп хәрәкәтләнә.

— Ни өчен?— Әнвәр бу соравы өчен уңайсызланды, Мирхаска ышанмаган кебек килеп чыга иде. Ләкин ул моңа игътибар итмәде.

— Немецның яшеренгән пушкасын таптым да, шуны катюшникларга әйтеп, бетерттердек. Ишетмәдеңмени, өченче көн иртән шул цельгә залп бирделәр?

— Күрдем. Ну йокыны ишәсең инде, ялда дим.

— Белмим әле. Ял госпитальдә, ә анда таныш кыз эшли икән,— диде Мирхас. Иреннәрендә эчке шатлык нурлары, күзләрендә шул киләчәк бәхет белән өметле кинәнү чагыла.

— Лафа алайса, бәхет?— Әнвәр Мирхасның йөзендә ниндидер моңсу мөлаемлек күрде, ул гүя бу кинәт кенә килгән бәхетне куркытмагаем, дип шикләнгән шикелле иде. Ләкин шул ук вакытта эченә сыймаслык куанычы хакында сөйләмичә дә булдыра алмый кебек.

— Әле тагы шунсы, ул кыз белән авылда чакта ук таныш идек.

— Авылдашыңмыни?— дип гаҗәпләнде Әнвәр, әмма шул минутта ук моның бик мөмкин булуын төшенде. Чөнки үзе дә кухняда эшләгән чагында Салават исемле авылдашын, бергә укыган иптәшен очраткан иде. Күрәсең, ул як кешеләре фронтның шушы төбәгенәрәк җибәрелгәннәр.

Погоннарны теккәч, Мирхас тужуркасын киеп карады. Башына алсу постау түбәле бәрән кубанканы кырынрак салды. Бөтенләй икенче кеше килде дә чыкты. Тансык киемнәрен бер киеп, бер салып һәм кеч-кенә көзгедән караштыргалап, ул байтак кинәнде. Аның йөзендә үз-үзенә соклану да һәм масаю да бар иде. Аннары әйберләрен чемоданга кире салды, ә чемоданны телефон тора торган почмакка ылыслар астына яшереп куйды. Очлы күзләргә чалынмасын.

Өч көн мин аның янында булачакмын, дип уйланды ул, ылыслар өстенә сузылып ятып.

Бераздан аны занятиегә алып чыгып киттеләр. Икенче блиндаждагы яңа килгәннәргә Мирхас стереотруба белән ничек күзәтү алып барырга, ничек ут нокталарын табарга һәм, гомумән, тупчы разведканың үзенчәлекләрен өйрәтә иде.

Әнвәр Мирхасны кичке аштан соң кайтыр дип көткән иде, ләкин теге күренмәде. Төнлә һич көтмәгәндә энпедән үзе шылтыратты.

— Ничек син анда?— дип гаҗәпсенде Әнвәр аның иртәгә ялга барасын белгәнгә.

— Шулай менә, бәхет — хаин, дигәнне ишеткәнең бармы?— диде ул бик моңсу-төшенке тавыш белән һәм бер-ике сүз белән комбатның ашыгыч киңәшмәгә чакырылганын, аның урынына калырга туры килгәнен әйтеп бирде. Әнвәр аны юатырга ашыкты:

— Ялга бер көн соңрак барырсың, ни аерма?!

— Бик ымсынган идем, күңел кителде.
— Һәй, кайгырмасана...
— Кайгырып нишлисең инде,— дип, ул трубканы куйды. Сөйләшәсе килмәгәнлеге сизелеп калды. Аның тавышындагы эрнүле-тиенкылык чалымы Әнвәрнең күңелен тырнады, әмма яңадан шалтыратып сөйләшергә уңайсызланды.
Төнлә линия тыныч булды. Ярты төн узгач, Әнвәр трубканы ял иткән Мөслимовка биреп, йокларга ятты. Күпме вакыт узгандыр, бер заман кычкырып сөйләшкән тавышка уянып китте ул. Ачык ишектән төшкән яктылыктан таң атып килүен шәйләде. Телефонда Тафтилов сөйләшә иде, чырае коточкыч, күзләре аларган.
— Немец разведкасы энпегә һөҗүм иткән, Зәйнуллин югалган,— диде ул ысылдап һәм трубканы Мөслимовка сузды.
— Юк, булмас, нәрсәдер бутыйлар!— дип кычкырды Идрисов, аның йокламаудан йончылган йөзендә кискенлек чалымнары калыкты. Ул Әнвәргә үзе артыннан иярергә ымлап ишеккә атылды.
Алгы сызыкка чаптылар. Аяк асты юеш, тайгак: бозланган җиргә төнлә тагы яңгыр явып узган бугай. Урман кырыеннан энпегә кадәр бер араны түш белән шуып үтәргә мәҗбүр булдылар. Якты иде инде, снайпер пулялары выжылдап кына торалар. Идрисовның ак тун чабулары манма су булып, аяк йөзенә хәтле салынып төшкән, ләкин ул аны сизми иде.

Энпе блиндажында укчы лейтенант белән бер сугышчы комбатны көтеп торалар икән. Барысының да кыяфәтендә әле генә булып узган фаҗиганың соры шаукымы күренә. Бүре куркыткан атлар шикелле киеренке-сак карыйлар. Курку әле чыгып та бетмәгән, аларны һаман үз тырнагында тотканы сизелә. Сүзне дә өзек-өзек кенә сөйлиләр, эзлеклелек юк. Безнекеләр, ягъни Мирхасның алмаш разведчигы һәм телефонист, тик шуны гына беләләр: атышу тавышына Мирхас, пистолетын тотып, блиндаждан чыгып киткән. Бераздан атышлар тынган, тик Зәйнуллин кайтмаган...

Укчы лейтенант та аны абайламаган. Ә эш болай булган: эңгер-меңгер вакытында безнең киемдәге ниндидер солдатлар укчылар окобы янына килеп чыкканнар. Болар уяу икән, тегеләргә туктарга боерып кычкырганнар. Солдатлар исә кинәт җиргә ауганнар да боларга ата башлаганнар. Шунда гына мин аларның немец разведкасы икәнен белдем, ди лейтенант. Дегтяр белән атарга тотынгач, фрицлар чигенә-чигенә энпе тирәсенә авыштылар да үзәнгә төшеп күздән югалдылар. Ике кешеләре үлеп калганы, бер минут буталышып торганнары күзгә чалынды... Нәкъ менә шул моментта Зәйнуллинны эләктергәннәрдер. Ул аларны «тел»дән кайтып килүче безнең разведка дип белгәндер, ә аңлаганда инде эш узган булгандыр...
Лейтенант еш-еш борынын тарта, бу — каушавы һаман бетмәүнең бәласе иде. Ул сөйләп бетергәндә никтер чөгендердәй кызарды. Тынлык урнашты. Идрисов та ни әйтергә белми, бу хәлдән тәмам зиһене таралып, телсез калган. Шул мәл еракта яңгыраган бер тавыш колакка чалынды. Ишек төбендә утырган Әнвәр кинәт хәрәкәткә килде.
— Бу Зәйнуллин тавышы, Мирхас кычкыра,— дип, ул тышка атылды, ышанмаган кыяфәт белән Идрисов та чыкты. Тавыш бик ачык һәм шик калдырмаслык булып кабатланды. Мирхас үрсәләнеп кычкыра иде. Идрисов стереотрубканы боргаларга кереште. Тик моның өметсез эш икәнен шунда ук төшенеп, урманга таба үрмәләп китте. Әнвәр аның артыннан калмады. Комбатның нияте билгеле иде: бер агач башына менеп алып, тавыш килгән җирне күзәтү...
Идрисов бер куе ботаклы чыршыга мәчедәй үрмәләп менеп тә китте. Биноклен күзенә куеп, немец ягын күзәтә башлады. Әнвәр аста комбатны снайперлар чәкемәгәе, дип дер калтырап торды. Агач башыннан немец-

лар ягы әйбәт күренә иде. Идрисов дошманның ут нокталары сөзәктау артына урнашканын шәйләп алды. Әнә бер-берсеннән ерак түгел бер, ике, өч пушка тора. 105 калибрлылар. Тукта, якынрак пушка янына зәңгәр шинельле фрицлар җыелган. Кулларын бутыйлар, түгәрәк эченә таба тибеп-тибеп алалар. Менә берсе кулын бик кискен өскә күтәрде, төркем ике якка аерылды, анда нәрсә булганы күренде.

— Зәйнуллин!— дип, кычкырып җибәрде Идрисов, уртада чайкалыбрак торган гәүдә Мирхас иде. Юк, ялгышмый, ачык күренә: аның кулларын артка каерып, күкрәгеннән кабель белән пушка затворына бәйләп куйганнар. Йөзендәге суккан эзләрдән телем-телем кан тибеп чыккан. Үзе яланбаш, бушлатының җиңе умырылып төшкән дә мамыгы бүселеп тора. Менә берсе нәрсә беләндер кизәнеп аның башына сукты, менә икенчесе...— Ерткычлар!— диде Идрисов тешләрен шыгырдатып.— Вәхшиләр!

Мирхасның башы күкрәгенә бөгелеп төште, аңын җуйды ахры, бичара. Бәйләнгәнгә күрә аягында басып тора әле. Билгеле, ул аларга берни дә әйтмәгән, шуңа ерткычланып җәзалыйлар... Кинәт берсе пистолеттан атты. Мирхасның гәүдәсе бер якка сөрлегеп ауды. Вәхшиләр! Төркем таралды, траншеяга төшеп, шуның буенча хәрәкәтләнүче гәүдәләр күренде. Бетте...

Агач башыннан төшкәндә, Идрисовның төсе-башы имәнгеч, иреннәре калтырый, борын яфраклары тетри, күзләренең агы гына калган кебек, аңа дәшәргә куркыныч иде.

Батареяга кайтып, барысын Тафтиловка сөйләп биргәннән соң, нәтиҗә ясап:

— Бик җәл, бик җәл! Шулай да егет батырларча чиста китте, үземнең күз алдымда,— диде ул Мирхас турында, чөнки особый отделга озын аңлатма язарга туры киләчәген белә иде.

## 12

Мирхасның һәлак булуын ишеткәч, Хәбиров нигәдер кайгыра алмады, бу хәбәр аның җанына тимәде. Моның шулай булуына үзе дә аптырый калды. Бик риясыз егет иде, дип кенә куйды да бетерде. Ут эчендә йөри-йөри бәгыре тәмам катканмы? Аңа хәзер бөтен нәрсә барыбермә? Кичергән авырлыклар җанын кырысландырып бетергәнме? Газаплар кешенең күңелен бүтәннәргә шәфкатьле булырга өйрәтә, диләр иде. Һич тә дөрес түгел икән. Бәлаләр тырнагыннан кемдер миһербанлы булып чыга, ә кемнеңдер йөрәге ташка әйләнә, күрәсең...

Ул термос белән аш, капчык белән ипи алып кайтып кергәндә, Самокат боегып бер почмакта утыра иде. Нәрсәдер булган ахрысы, әллә Ханҗәров белән бәрелешкәнме! Икесе дә калай әтәчләр, тиз кызып китәләр. Хәзерге моментта һич тә ярый торган эш түгел инде дип, Хәбиров борчыла ук башлады. Самокат аштан да, ипидән дә баш тартты. Бу тагы да сәер, һич көтелмәгән нәрсә иде. Хәбиров аңа карамаска, битараф кыяфәт күрсәтергә тырышты. Җанына әз генә тукынганны да яратмый ул. Синең сер алырга, күңеленә керергә һич тә ниятең, теләгең юклыгын белгәч, үзе үк ачылып, нәрсә булганын әйтеп бирәчәк. Хәбиров ашын ашап, котелогын капчыгына салып куйды да, берни юк кыяфәт белән Самокат янына барып ятты. Аңа күз дә төшермәде. Теге тәмәке кабызды һәм, башын түбән игән килеш, тирән-тирән суырып, беркемне дә күрергә теләмәгән караш белән утыра. Ханҗәров аның янына елышты. Хәбировка астан гына күз кысып алды, янәсе, мин хәзер аны «ачам» һәм, шаярткан булып, тезенә төртеп куйды.

— Син нәрсә?— дип, сары тешләрен ыржайтып елмайды.

— Әнкәй үлгән,— диде Самокат карлыккан-хәлсез тавыш белән.

Хәбиров аптырап карап торды, бер сүз дә әйтмәде. Дөньяда бернигә исе китмәүче, бар дип тә белмәүче бу егеткә әнкәсенең үлеме шул чаклы нык тәэсир итүен аңлап җитми иде. Аны бәйли торган җепләр бар икән әле, дип өмет белән уйлады Хәбиров, беткән баш түгел икән әле. Хәнҗәров исә Самокатны үчеклисе килгәндәй:

— Кайгырган буласың, ә үзең бит аны үтердең?— диде. Самокатның башы, киң маңгай астына яшеренгән зәңгәр күзләре чынаяктагы судай чайкалды.

— Нишләп мин аны... кырчын!"

— Әгәр син юньле-рәтле йөрсәң, үлмәгән булыр иде.

— Язмыш-кәнтәй мине шулай итте.

— Синең өчен кайгырып үлгән инде әниең,— диде Хәнҗәров рухсыз тавыш белән. Аның үз әнисе бик нык исенә төшкән шикелле иде.

— Аның ашарына булмаган, син ни беләсең?

— Чын егетләр үз әниләренә ярдәм итәләр. Син акча җибәреп торсаң, үлмәс иде!

— Ә син үзең, кырчын!

— Сүз минем хакта түгел. Сине тапканына үзе дә үкенгәндер, бичара?

— Ник тапкан ул мине, ник баккан?— диде Самокат чын ачынуәрнү белән.

— Билгеле, зур өмет белән тапкан инде, караучым булыр, ярдәмчем булыр дип.

— Ә мин беркем дә була алмадым,— дип, Самокат кулын селтәп төкереп куйды. Үзенең гаебен тануы бөтен чыраена чыккан иде.

— Кем гаепле соң? Кем комачаулады?— диде Хәнҗәров дустанә тавыш белән. Ул бу сорауларны үзенә дә бирә шикелле иде.

Шул мәл, Хәбировны чакырып, Мамак ординарецы килеп керде. Бәхәс ни белән беткәнен ул ишетә алмады. Шулай да Самокатның уйчанланып калуы, үзе турында, әнисе хакында кайгыга төшүе ошады аңа. Бу аның холык-фигылендә борылыш моменты булу ихтималы иде. Яшьләр әти-әнисе вафатыннан соң кинәт балигъ булып, акылга утырып китәләр.

Мамакның блиндажы йөз метр чамасы арттарак, теге бомба чокырларыннан сулда, урманга якынрак төштә иде, килеп кергәч тә күрде, Мамакның чырае төксе, эчке уйлары белән маташкандай, сәер-серле. «Нәрсә булды икән?»— дип уйлады Хәбиров, сак караш белән командирына төбәлеп, һәм уставча доложить итә башлаган иде, Мамак бер ияк кагу белән утырырга кушты. Ул взводның хәлен-кәефен сорашты. Хәлләр шул әүвәлгечә: начар да түгел, яхшы дип тә авыз тутырып әйтеп булмый, бигрәк тә Хәбиров кебек авызы йөз мәртәбә пешкән кешегә...

Хәбиров бу сүзләре белән Мамакны елмайтырга теләгән иде, әмма тегенең йөзендә җитдилек сызыклары җылынмады. Ул карлыган кебек кара, тере күзләрен Хәбировка җете итеп төбәде.

— Карале, сер итеп кенә әйт әле, штаб тирәсендә югарыда әллә синең блатың бармы?— диде Мамак, Хәбировка сорауларның төрлесен ишетергә туры килде, әмма моңа ул ничектер аптырап калды.

— Юк, нинди блат?— дип, ул Мамак йөзенә чекерәеп карады.

— Йә, койрык болгама, мин татарларны хөрмәт итәм, тырыш халык....

— Валлаһи, Остап Петрович, нәрсә соң бу?

— Инструктор сине үзе янына эшкә алырга йөри.

— Ниткән инструктор?

— Сөенчалинны беләсең ич инде?

— Бер-ике мәртәбә эш буенча килеп киткән иде.

— Шул үзенә ярдәмче итмәкче, барасыңмы?— дип, Мамак кырыс кына тагы Хәбировка карады. Ниһаять, Хәбировның башында төрле уй-

лар кузгалып йөгерешә башлады. Шулай да аңа Мамакның төп фикере барып җитми иде әле. Ул һаман мәгънәсез караш белән карады.

— Ничек?

— Ничек әйтсәм шулай...— Мамакның ачуы кузгалганы тавышыннан сизелде. Ул Хәбировны юри белмәмешкә салыша дип уйлый бугай.

— Мин моны аңлап бетермим әле, Остап Петрович,— диде Хәбиров йомшак кына. Мамакның йөзендә ачуы кубәйде, сул кашы маңгаена күтәрелеп урталай сынды.

— Менә иртәгәдән тылгарак, куркынычсызрак урынга күчә аласың. Начальство шулай әйтә. Барып җиттеме?— Мамак кызып китүен йомар өчен планшетыннан ниндидер кәгазьләр алып укырга тотынды. Командирның кырыс, төртмәле карашы Хәбировка шунда ук тәэсир итте һәм аның таркау фикерләрен бер төенгә җыйды. Әллә Рифа берәр өстәге начальник аша эш йөрткәнме? Миңа сюрприз ясамакчы булганмы? Әллә Мамак мине сынар өчен әйтәме? Тукта, нәрсә килеп чыга соң әле? Бүген-иртәгә һөҗүмгә барырга торганда гына? Самокат, Хәнҗәров минем бу эшне ничек кабул итәр?

— Остап Петрович, шаяртмыйсызмы?— диде Хәбиров җитди генә.

— Шаяртырга — син хатын-кыз түгел лә!— дип, Мамак кәгазьләрен кире куя башлады. Хәбировның тамак төере селкенде, сүзен әйтә алмый торды, аннары:

— Шундый моментта ничек мин иптәшләремне калдыра алыйм? Сез бу хакта уйладыгызмы?— диде.

— Мин шул хакта гына уйладым да: китәрме, китмәсме? Ну, брат, ялгышмаганмын, кеше икәнсең!— дип, ул чиксез сөенгән рәвештә урыныннан сикереп торды да Хәбировның беләгеннән тотып алды, күзләренә нур чыкты, йөз сызыклары җылылык белән тулды. Хәбиров та тамагына төер утырганын тойды, йөзен читкәрәк төбәп торып басты.

— Ә бит була кешеләр, җай гына эзләп йөриләр,— дип, Мамак Хәбировның беләген катырак кысты.— Кеше белән кешенең аермасы менә шундый чакта беленә. Ашап-эчеп утырганда түгел!

— Рәхмәт, Остап Петрович!

— Бу һөҗүмнән соң мин сине лейтенант дәрәҗәсенә күтәрәм һәм үземә ярдәмче итеп алам. Шунда партия мәсьәләсен дә карарбыз...

— Ышануыгыз өчен мин барысын эшләргә риза, Остап Петрович,— диде Хәбиров ничек рәхмәт укырга белмичә. Партиягә кире әйләнеп кайту — тәмам акланып калу дигән сүз иде, шуңа күрә ул аның иң мөкатдәс эчке бер хыялы. Һәм Мамакның сүзендә торачагына һич шикләнмәскә мөмкин...

Менә бит аңа тагы бәхет елмая. Һәм ул ачылып китеп, Мамакка үзенең тарихын, ничек бәлагә юлыгуларын сөйләп бирде. Бары биредә врач кызы белән очрашуын гына әйтми калдырды.

— Син көрәшче холыклы,— диде Мамак аның тормышыннан нәтиҗә чыгаргандай.— Ә көрәшчегә авыр була.

Мамак Хәбировның йөрәгендәген әйтте дә бирде. Шуңа күңеле нечкәреп, күзләре юешләнүен сизде ул һәм тизрәк китү ягын карады.

Мамак яныннан чыккач, Хәбиров әле генә булып алган хәлне тагы бер кат күңеленнән кичерде һәм аркасы буйлап елдырым пешереп узып китте, битенә кызыллык та йөгерде. Ә бит теге форсатны эләктереп, шуңа ябышуым да мөмкин иде, әх, ничек акылы җитте, аһ, ничек җитте! Нинди коточкыч хыянәт булган булыр иде! Ничек акылы җитте?! Үземнең взводым алдында бөтен совет җәмгыятенең абруен кинәт төшерә идем бит! Барча ышанычлары бетә иде. Самокат, Хәнҗәров беравыздан: әнә күрдеңме, һәркем үз җаен гына карый, бәләкәй генә шишкага хәтле шкурасын сакларга тырыша, безгә нәрсә кала инде, диярләр иде.

Бу коточкыч булыр иде. Юк, намусым мине тотып калды. Әх, нинди рәхәт миңа хәзер! Күңелем чиста, җаным тыныч! Моңардан татлырак берни дә юк дөньяда!

Рифа миңа яхшылык эшләргә теләгәндер, бу аның кулы. Әллә Сөенчалин белән сөйләште микән? Миңа шул хакта әйтеп куярга өлгерә алмагандыр инде. Алдан искәртеп куйса да карарым барыбер шулай булыр иде. Син, кызым, моны, бәлки, аңлап та бетермәссең. Юк, мин үземнең нинди намуслы икәнемне күрсәтәсем килми. Бүтән вакытта: башкача шартларда мин андый җайны кулдан ычкындырмаган булыр идем, ә хәзер — иңхәлиткеч моментта бу һич мөмкин түгел. Минем дә бик яшисем килә. Ә кемнең генә яшисе килми соң? Биредә әнә ничек булып барысы бер фокуска тупланган бит, мин әгәр ул тәкъдимне кабул итсәм, моңарчы кан-яшь түгеп яулаган барча казанышларны бер минутта пычратып җимереп ташлау булыр иде. Сугышта йөргән кешегә мондый моментлар әз туры килми, шуның өчен сугышта кеше бик тиз сынала дип әйтәләр... Аһ, ничек акылым җитте сынатмаска, ничек җитте?! Миңа рәхәт, иң югары рәхәтлекне кичерәм. Бу бер кечкенә җиңүем! Бәлки, мине эзләп табар, шулай да мин кечкенә генә булса да җиңү яуладым. Яшәүгә тора торган кечкенә генә җиңү...

...Ниһаять, бер иртәдә һөҗүм башланды. Төнлә тагы әз генә кырпак кар явып бар җирне ап-ак иткән булган. «Катюша»ларның дәһшәтле, беренче залпларыннан соң ук дошман ягы кара корым булды. Бу исә шул төшкә атучы меңләгән пушка, минометларга ориентир хезмәтен үтәде. Снарядлар, миналар дошман окопларының астын-өскә китерергә тотындылар. Аяк астында җир кыймылдаган кебек булып селкенә һәм үкчәгә нәрсәдер китереп суккан сыман итә иде..

Идрисов үзенең элемтәче разведчиклары белән энпедә иде. Иң башта ул теге Мирхасны күзәткәндә шәйләгән дошман пушкаларына җиде орудиедән өч залп бирде. Берничә пулемет нокталарына атты. Укчы частьларга юл ачылды шикелле иде. Әмма уңдарак урнашкан дүртенче батарея үз бурычын үти алмаган икән әле. Ни булган соң? Менә аларның комбаты, тыны-өне бетеп, энпегә килеп керде. Элемтәләре юкка чыккан икән, ә Әнвәр сузган линия ник бер өзелеп карасын. Комбат, чибәр генә йөзле капитан, керешкә телефонга ташланды һәм күзәтелгән цельләрен пушкаларына әйтергә тотынды. Байтак маташты ул. Чыгып киткәндә:

— Молодец, элемтәчене бүләкләргә кирәк!— диде. Идрисовка рәхмәтен белдереп. Ул гына чыккан иде, алтынчы батарея комбаты килде. Аны шул ук бәла китергән иде... Линияләрен танкмы, машинамы тәгәрмәченә урап алып киткән. Ул да пушкаларына цельләрен кычкырды — кычкырды да:

— Малайкага рәхмәт! — дип чыгарга ашыкты. Ул Әнвәрне элек тә белә, аны «малайка» дип йөртә иде.

Үз эшенә шундый хуплаулар ишетү Әнвәргә чиксез рәхәт булды. Бар кичергән газаплар бер мәлгә онытылдылар. Бу моментта ул үзен, бөтен йөрәге белән, туган Ватанына ниндидер җепләр аша барып тоташкан кебек хис итте. Авырлыкларны тагы җиңәргә үзендә көч-куәт артуын сизде...

Һавада безнең бомбовозлар, коточкыч гөрелдәп, дошманны дөмбәсләргә үтеп киттеләр...

...Хәбиров, үзенең ышанычлы взводы белән, артхәзерлек вакытында ук барып, дошманның беренче траншеясына бәреп керде. Билгеле булганча, немецлар безнең туплар атканда арттагы траншея — окопларда посып яталар. Хәбиров фрицларның шул хәйләсеннән файдаланды. Шуңа күрә аның взводында югалту булмады. Тик немец үзенең алдануын тиз төшенеп алды һәм якын дистанциягә минометларыннан давыллы ут ачты. Хәбиров: «Ятарга!»— дип команда кычкырды да, паника була күрмәсен өчен, сугышчылар яныннан иелеп үтеп йөрде. Кайсының җил-

кәсенә сукты, кайсына каты сүз әйтте. Әлбәттә, куркуларын җиңәр өчен шулай итми ярамый иде. Беркемнең дә куркуы беленеп тормый, шулай да яңакларында бала йоны кабарганын, мускуллары тартышканын күрергә була. Кайсы курыкмас өчен иң яхшы әмәл тапкан — нәрсәдер эшли, йә атарга әзерләнә, йә немец автоматын табып алып, шуның белән мәшәләнә. Хәбиров моны үзеннән белә, нинди дер эш белән әвәрә булсаң, куркуны уйламыйсың...

Безнең самолетлар өстән пике белән төшеп немецларга бик каты граната сибеп киттеләр. Һәм моның файдасы шунда ук сизелде. Кинәт аларның активлыгы кимеде. Үз ояларыннан сирәк кенә аткалап яталар. Ләкин икенче бәла килеп чыкты. Безнең туплар немец танкларына бик каты ут ачканнар иде. Ә танклар белән дошман пехотасы арасында калган егетләр тирәсендә тупларның кайбер ядрәләре килеп ярылгалый башлады. Шуңардан берничә сугышчы һәлак булды. Ләкин берни эшләр хәл юк иде. Аның каравы артта яндырылган «тигр»лардан күтәрелгән болыттай аксыл төтен күңелләрне сөендерде.

Өйлә җитәрәк ике якның да уты сүрелүен сизәргә була иде. Хәбиров шул минутта ничектер үзе турында уйлап куйды. Менә көрчеккә килеп җителде ахры, якты дөнья йөзен кабат күреп булырмы, юкмы? Тиздән атакага күтәреләчәкбез. Әйе, гомер бик тиз үтеп китте, бер ишегеннән кердем, инде менә икенче ишектән чыгарга барам. Түрендә утырып, хозурлык кылырга вакыт тимәде. Ах, нинди татлы икән бу якты дөнья! Эш, мәшәкать куып, кичәге кәкрене бүген төзәтәм дип йөреп, берни татый алмый каласың. Ни генә булса да, тормышта мин уңышсыз кеше булмадым. Колхоз төзегәндә җиңү сөенече белән рәхәтләнгән чаклар истә. Ләкин бу җиңүләрдә власть көче иде, без аны шәхси җиңү итеп кабул иттек. Бу һәр кешедәге эгоизм булгандыр. Тик шәхси рәхәтлекләрем дә булды. Рифа кызымның үзем кебек яшьтән үк бер кыйбласы булу миңа чиксез бәхет бирде. Менә хәзер әйтә алам, мин аны дөрес тәрбияләгәнмен, иркәләп бозмаганмын. Кызымның шулай кеше арасында абруйлы, горурлыгына тугры булуын биредә үз күзләрем белән күрү бик сирәк бәхет ул... Нишләп бу шулай килеп чыкты? Башта фронт язмышым гел кирегә барган иде, аннары бара торгач барысы да яхшыга булып чыкты. Тормыш миңа җитәрлек бирде дә һәм миннән тиешенчә алды да шикелле.

...Безнең гаубица туплары ата башлады. Аларның снарядлары очканда күренеп киткәли... Шунда ук Мамактан кеше килде, ул атакага әзерләнергә боерган иде. Хәбиров тагы, сугышчыларын дәртләндереп, окоптан окопка кычкырып узды. Шуңа өстәгән кебек «Катюша»ларның утлары озын-озын тасма булып немецлар өстенә сузылды. Самолетлар да алар үрмәлисе биеклек түбәсен теттеләр. Биеклекнең теге ягында шәһәрчек, биеклекне алсаң, дөнья безнеке булачак, дип уйлады Хәбиров. Немец та, сизенеп, бик каты ут белән җавап кайтара. Бигрәк тә алты көпшәле минометына чыдар хәл юк. Үлгән солдатларның кәгазь-документларын Хәбировка китерә торалар. Бар кесәләре бумажник, янчыкише нәрсәләр белән тулды. Һәрберсенең өенә, әти-әнисенә, туганнарына, хатыннарына хат язарга кирәк. Менә шул каһәр суккан түбәне генә алыйк, аннары безнең эш худка китәчәк...

Яшеренгән җирдән утыз дүртле танклар килеп чыктылар. Хәбиров сугышчылары белән шуларга иярде. Дүрт йөз метр араны ничек үткәнлекләрен дә сизмәделәр. Алар түбәгә барып җиткәндә немецлар чигенү ягына әлдерә иде. Танклар һәм сугышчылар, чигенүче фрицлар җилкәсенә атланып дигәндәй, шәһәрчеккә барып керделәр... Сирәк урманлык эчендә икешәр катлы таш йортлар күренде. Бер асфальт җәйгән урамны шәһәрчекнең үзәге дип уйларга мөмкин иде. Урамның теге башында зур гына мәйдан бар, ә мәйдан бер урманга тоташкан икән. Биредәге шәһәрләр буенча фикер йөрткәндә, бу парк булса кирәк.

Мәйданның бер ягында костел булырга тиеш. Кызыл кирпечтән сырлап-матурлап салынган зур бина. Тәрәзәләре бик зурлар һәм витражлы...

Танклар артыннан чапкан чакта шулар Хәбировның күзенә чалынып киттеләр. Машиналар кызу бара иде, сугышчылар бераз артка кала башладылар. Инде шәһәрчекнең икенче ягы да шәйләнә иде шикелле. Бер йорттан аткан пулемет уты безнекеләрне җиргә аварга мәҗбүр итте. Хәбиров асфальт юлның уң канавына ятты. Йөгерүдән эченә кату чыккан, сүзен әйтә алмый, көчкә тын алып, хәл җыя. Шул арада кемдер яраланды. Ул санитарны дәшеп кычкыра, сүгенә башлады. Ләкин немец бик каты атарга тотынды һәм яралы тынып калды. Хәбиров шул мәлдә генә үзеннән бернечә адым алда безнең танкны күреп алды. Ул яндырылган иде бугай, әз генә төтәп тора иде. Ә чылбырлы тәгәрмәче кырыенда бер танкист гәүдәсе ята, ул да янып, күмергә әйләнгән булса кирәк, нәкъ янып бетмәгән кисәү кебек иде. Танкны фауст-патрон белән яндырганнар икәнен шуннан соң гына аңлап алды...

Юк, бу юл буенча алга үтеп булмаячак, дигән карарга килде Хәбиров һәм якындагы ике катлы таш йорт артына керергә боерык бирде. Атыш тыну белән үзе дә шунда шуышып китте.

Өй артында ышык иде. Хәбиров исән калган солдатларын барлады, әмма һич тоткарланырга ярамый иде. Өйне уратып үткәндә агачлар арасыннан йөгерүче зәңгәр шинельләрне күреп алдылар һәм ата-ата шулар артыннан чаптылар. Сул флангтан көчле «ура» тавышы яңгырады. Уңдагылар да аларга кушылды, берьюлы күңелле булып китте. Агачларга бәрелә-сугыла чаптылар. Хәбиров кинәт аягы тайган кебек, бер якка янтаеп, җиргә авып төште. Аны кемдер төртеп җибәргән шикелле булды, ләкин якында берәү дә юк иде. Хәбиров муены буйлап, аркасын пешерә-пешерә, кайнар нәрсә ага башлаганын тойды һәм яраланганын белде. Ул кулларына таянып тормакчы булды, тик шунда көч килеп, күз аллары томаланды, бар нәрсә аның алдыннан каядыр шуып китте. Ул гаҗәп төш күрә башлады. «Әллә өнме бу?»— дип, аңының бер кырые шикләнеп куя иде. Аңардан кемдер сорау ала иде.

— Әйдә әйтеп кал,— диде ниндидер хөкемдар таныш тавыш белән.— Син кемнәргәдер комачаулагансыңдыр, хәзер алар иркенләп калырлар, үлеп яхшы гына итәсең, ягъни дошманнарыңа әйбәт булачак! Ник алар сине күрәлмәделәр, ә?

— Белмим. Артык туры сүзле булгангадыр инде.

— Кемнәр сатты сине, беләсеңме.

— Мәүлиев, Азлай...

— Ни өчен?

— Мине үзләреннән узар дип курыкканга күрә. Көнчелек яман итә кешене, нәфес...

— Үзең донослар язгансыңдыр әле?

— Юк, мин бары гаделлекне генә якладым. Шул исә иптәшләргә ошамады. Мине карьерист кеше дип белделәр һәм читкә тибәрделәр.

— Тагы ни борчый сине.

— Мин Гөсләев белән бик дус идем, ул минем серләремне алды да Мәүлиев, Азлай ягына чыкты... Миңа бары шунысы гына җәл, Гөсләевне бик ярата идем, хәзер дә яратам.

— Ярар, хәзер аларга киртә булмассың инде, чөнки үлгән кешедән дә әйбәт кеше юк...— Хөкемдарның таныш авазы шул төштә ишетелми башлады һәм үзенең барлыгы-юклыгы да беленмәде. Нәрсә булды соң бу?

Хәбиров, аңын җуеп, озак ятты. Куе агачлар арасыннан аны таба алмаганнардыр инде.

Ниндидер ачы ыңгырашу тавышына ул аңына килде, башын күтәрде. Башы чуен кебек авыр, үзенеке түгел кебек тойды. Күзләрен ачса, ни күрсен, якында гына кемдер газапланып ята. Яралыдыр.

Ыңгырашу авазы йөрәккә төшәрлек иде. Хәбиров торырга итте, юк, булдыралмады, лапылдап ауды. Үлем авазы никадәр нык тәэсир итә дип уйлады һәм шул авазга таба шуышты. Күзләре караңгыга иярләнгән, ачык күрә иде. Хәбиров шаккатты: ыңгыраша торган зат фриц икән, канга батып ята. Ул Хәбировтан һич курыкмады: комрад, комрад!— дип ярдәм сорарга тотынды. Хәл эчендә икән. Ике аягы да өзелгән шикелле, белеп тә булырлык түгел, киеме белән кан бергә укмашып беткән. Хәбировка ничектер жәл булып китте, барыбер үлә инде бу дип, үзенең пакетын сүтеп, тегенең яраларын бәйләштергән итте. Теге рәхмәт укый, саташа-ыңгыраша, үзеннән сарымсак исе аңкып тора иде. Бай немецлардан кыйбатлы хушбуй исе килә иде, димәк, бу ярлы-гидай токымыннан диган уй Хәбировның миендә борынлады. Үзенең көчен сынап карамакчы булып, Хәбиров тагы торып басарга итеп карады. Дүртаяклап йөрмәкче булып кулларына таянды, ләкин тагы лапылдап җиргә ауды. Тегенең икенче аягына бинт урарга кереште. Хәбиров бер мәлне кулының көче беткәнен һәм күз алды томаланып калганын сизде. Бер кулы бинт белән немец аягы астына керде дә, тартып чыгара гына алмый бит... Аңа көч килде, ахры, ул тагы аңын җуйды, башы каерылып, агач төбенә төште һәм тынып калды.

Немецча сөйләшкән тавышка ул тагы, аңына килеп, күзләрен ачты, ике терсәгенә таянып күтәрелмәкче булды. Шушы хәрәкәте искәрмәстән аны һәлак итте... Эш шунда, аңардан берничә адымда зәңгәр шинельле ике фриц басып тора иде. Хәбиров берни дә аңламады, алар теге немецны алырга килгәннәр. Менә яралыны икесе ике култыгыннан күтәрделәр дә алып китәргә җыендылар. Ә яралы немец нәрсәдер сөйләнә, Хәбиров өстенә төртеп күрсәтә. Ул мине бәйләде, аны да бәйләгез, дигән кыяфәттә сөйләнә. Ләкин фрицларның берсе аңа автомат тоттырды һәм Хәбировка атарга боерды.

— Шлиссен, шлиссен!— дип, кыҗраган тавыш белән әйтте.

— Наен! Наен! — дип, уфылдады яралы һәм автоматын җиргә атып бәрде. Шунда ук тегеләр яралыны кулларыннан төшерделәр. Яралы нәрсә эшлиләр болар, дип гаҗәпсенеп торганда, бер ач яңаклы, озын борынлы фриц автоматны алды да Хәбиров өстенә очередь бирде, аннары көпшәсен яралы немецка төбәп, тәтесенә басты... һәм китеп барган иптәше артыннан йөгерде.

Ату тавышына килеп, Хәбировны табып алдылар, ул үлгән иде инде. Ничектер рәхәтләнеп йоклап киткәндәй ята иде.

## 13

Һөҗүм уңышлы гына булды. Кечкенә генә булса да бер шәһәрчек азат ителде. Немецның үтә зәһәрләнеп каршы торуын исәпләгәндә, бу аз түгел иде. Моңа да командованиенең бик нык уйлап эш итүе аркасында ирешелде. Мәсәлән, немецлар күз алдында танклар һәм сугыш техникасы алгы сызыкның бер урынына күчерелде. Немецлар, билгеле, чамалап алдылар, димәк, һөҗүм шул төштән булачак икән һәм үзләренең дә көчләрен каршы торыр өчен шунда тупладылар. Әмма безнең һөҗүм һич көтелмәгән бүтән җирдән башланды. Шундый хәйлә белән генә дошман оборонасын өзәргә мөмкин иде. Ул, әлбәттә, шәһәрне калдырып чыгуы белән һич килешмәячәк, контратака ясаячак. Бу ихтималны алдан күреп, командование оборонаны көчле туплар, минометлар белән ныгытты.

Тупчылар төнлә азат ителгән җиргә, яңа позициягә барып урнаштылар. Дөм караңгыда тирә-юньне күреп булмаса да, немец ракеталары яктысында моның урман буе һәм арырак сөзәк үр менеп киткәне шәйләнелә иде. Пушкаларны шул тоташ боз белән капланган үргә куйдылар, лом, кәйләләр чыгарып, туң җирне чаба башладылар.

Шунда ук алгы сызык окопларындагы пехота часте белән элемтәгә керергә кирәк иде. Тимер кагыйдә шулай. Тафтилов бу эшне әле өченче көн генә пополнениегә килгән яшь бер лейтенантка тапшырды, аның белән барырга Әнвәргә кушты.

Киттеләр. Куе караңгы төн. Немец авыр туплардан бертуктаусыз атып тора. Снарядлар кай тарафтанрак килгәнен, кай төштә шартлавын һич абайлап булмый, шуңа күрә сукыр кеше кебек барасың, саклана да алмыйсың. Бик кыен бу берни күрми бару. Ләкин барырга кирәк. Барысын, тәҗрибәле солдаттай, язмышка тапшырып, үлем күзенә атлый бирәсең. Әле бер якка, әле икенче якка сугылып, капшанып дигәндәй эзли торгач, ниһаять, төн урталарында кирәкле частьны таптылар. Пехотачылар немецтан калган бер-ике блиндажга мичкәдәге селедкалардай шыпланып тулганнар иде. Әнә төртер җир юк. Солдатлар чиратлап туң җир чабалар да кереп авалар. Көне буе элемтәне төзек тоту өчен чаба-чаба, Әнвәр эттәй арыган иде, черем итәргә юл буе хыялланып килде, әз генә ял итсә, башы ачылып китәр, тәне җиңеләер. Таң атканда элемтә сузарга ансат булыр. Ничә катушка кабель китәр икән? Юлны бер дә чамалап булмады, мать якасын...

Әнвәр, солдатлар арасына кысылып ятты да йокыга китә башлады. Ләкин бераздан лейтенант аның янына килеп басты, Әнвәрне төрткәләп уятты һәм батареяга кайтып китәргә кушты.

Әнвәр аңгы-миңге килеш дөм караңгыга чыкты. Кай тарафка атлап китәргә белмичә озак кына зиһенен җыеп, немец ракеталарын күзәтеп торды. «Нигә кайтырга кушты икән, минем анда кирәгем юк бит?» — дип, ачынып уйланды ул. Ләкин приказ тикшерелми, үтәлә генә. Әнвәр, җанын учына тотып дигәндәй, тәвәккәлләп китте. Ни булса шул. Һәр адымы упкын эченә атлагандай тоела иде. Шулай да куркынычка да өйрәнәсең, күнегәсең. Ул шактый кызу бара башлады. Бервакыт кинәт: «Туганнар, коткарыгыз!» — дигән көчсез тавыш аны туктатты. Шомлы караңгылык эченнән килгән өметсез ыңгырашу йөрәген телеп-телеп алды. Нindидер бер бәхетсезе минага эләгеп шартлаган, Әнвәр аңа ярдәм итеп булмавы хакында әрнеп уйланды. Хәзер аның янына барсаң, үзең дә минага эләгеп шартлаячаксың, бу көн кебек ачык нәрсә. Шуңа бу бичара яктырганчы ятачак әле, әгәр шуңарчы дөнья куймаса.

Әнвәр килгән төштән кире чапты, гүя аны моннан йөрәккә тия торган ялвару тавышы куа иде. Ракета яктысыннан юлны чамалап, ул тагы алга таба барды да барды, нәкъ ике күзне бәйләп, сукыр тәкәле уйнагандагы кебек. Шул чак кыр уртасындагы бер лапас янына килеп чыкты ул. Килгәндә бу каралтыны ракета яктысында чамалаган иде. Әнвәр шундый сөенде, шатлыктан күзләренә яшь килде. Шулай булмый ни, бу — билгесез җирдә минага эләгеп шартлаудан котылу дигән сүз иде. Әнвәр лапас стенасына сөялеп ял итәргә утырды. Чаба-чаба эчен чәнчү алып, һич атларга ирек бирми башлаган иде. Тик бер-ике минут үтүгә үк авыр снаряд выжылдавын ишетте һәм шунда ук каты шартлау баш түбәсенә күсәк белән суккан кебек итте. Муен сөягө сынгандай чәнчеп авыртты. Колагын нindидер кайнар сыекча пешереп алды. Снаряд лапасның икенче ягында гына шартлап, Әнвәрне контузияләп ташлаган иде. Ул башын селкеп-селкеп карады, анысы тәмам тонган, авыраеп, түмәр кебек булган, шулай да биредә озак юанырга ярамавын зиһене кисәтте аңа һәм ул, торып, бар көченә алга таба йөгерде. Хәзер батарея ерак булмаска тиеш.

Урман эчендә торган бөркәүле студебеккерларны барып тапканда, әз генә яктыра башлаган иде. Машиналар янында бернинди сак юк, барысы да йоклыйлар. Әнвәрне бу хәл шомландырып куйды. Шулай да кыйнап ташланган кебек арыганлыктан кузовка менеп авудан бүтәнне эшли алмады.

Яткач та колагы энә кебек чәнчи башлады. Ул анда укмашып каткан канны бармагы белән тырнаштырды, ләкин бар санын-гәүдәсен йо-

кы басты. Бераздан аны Мөслимов килеп уятты. Тафтилов чакырта икән. Инде яктырган, бар тарафлар ачык күренә иде. Тафтилов блиндажына таба атлаганда бер күренеш Әнвәрне аптыраштa калдырды: пушкалар кырда тырпаеп торалар, ә сугышчылар урманда күренәләр. Пушкалар белән урман арасында булган тар гына җирне немец пулеметы үтәли атып тора. Сул флангтан, тыл ягыннанрак ата. Нәрсә бу? Нишләп болай? Әнә ниндидер атлы тупчылар кырга таба бармакчы булганнар иде, өч ат шунда ук гөрселдәп җиргә барып төште. Бер җайдак та, яраланып, кычкырырга тотынды. Чынлап та, нинди хәл бу? Нигә ул пулеметны туптан атып тончыктырмыйлар? Ләкин Тафтилов шундый тыныч, ышанычлы кыяфәттә иде, Әнвәрнең эченә җылы керде. Димәк, шөбһәләнерлек берни дә юк икән. Ә пулеметның атканы блиндажга ишетелеп тора. Тафтилов Әнвәргә хәзер ни эшләргә кирәген аңлатты:

— Алтынчы батареяга бар, аннан бер элемтәче һәм кабель алып алгы сызыкка элемтә сузыгыз! Шул!..

Әнвәр, блиндаждан чыкканда, бу сәер приказның артында ни ятканын үз-үзенә аңлатырга тырышты: батарея командирлары үлгән иде, димәк, вакытлыча безнең командирлар аларга җитәкчелек итә, шуңа күрә ике батареяга бер линия сузыла...

Алтынчы батарея теге лапас тирәсендәрәк икән, анда барыр өчен бу үтәли атыла торган «коридор» аша чыгарга кирәк иде. Әнвәр урман кырыена килеп, бер нарат кәүсәсе артына посты да пулемет утын күзәтеп тора башлады. Уң флангтанрак берничә солдат иелгән килеш, уктай атылып, коридорны уздылар, тик берсенең кулы яраланды шикелле. Әнвәр ату интервалын чамалап торды һәм бер тыныч моменттан файдаланып, алга ыргылды, нибары 20—30 метр араны үтәргә кирәк иде. Тик өч-дүрт адым атлауга, биленә күсәк белән бик каты китереп суккан кебек булды, ул, аягы өстендә тора алмыйча, җиргә мәтәлеп барып төште. Күз алды кинәт кап-караңгы булып торды. Егылган җирдән ул үзенең җыелып торган бозлы суда ятканлыгын тәне өшүдән искәреп алды. Төнлә яңгыр яуган иде... Миендә кыймылдаган иң соңгы уй шул булды, аннары аңын ниндидер кара пәрдә япкандай итте. Берни белмәде, сизмәде... Аны көне буе ут эченнән ала алмадылар. Пулемет өзлексез атып торды. Кичкә кинәт салкынайтты. Әнвәр киемнәре-ниләре белән бозга ябышып каткан иде, аны көчкә кубарып алдылар. Әле җаны чыгып җитмәгәнен күреп, машина белән санбатка озаттылар.

Ә тагы бер көннән тупчыларга бу каһәр суккан позициядән икенче эшелонга чыгарга приказ килде. Бу үзенә күрә бәхет иде. Чөнки солдатларның безне көнчыгышка җибәрәләр икән дигән юрауларына туры килгән кебек булды. Тик Әнвәргә аны күрергә насыйп булмады.

Тупчы дивизион батареялары төнлә алгы сызыктан чыгып, әлеге азат ителгән, немецча исеме бер төрле, латышча — икенче төрле, ә русча бөтенләй башкача булган шәһәрчек тирәсендә урнаштылар. Бишенче батарея гына ни өчендер шәһәр уртасындагы зур парк янына куелды. Бу бик җыйнак, пөхтә һәм матур шәһәрдә немец бароннары соңгы вакытларга чаклы аерым дәүләт булып яшәгән, диләр. Үз гербы, үз пичәте, үз флагы булган, имеш? Бары 39—40 нчы елларда гына латышларга кушылган, ди. Шуңа күрә биредә немецлар күп икән әле. Чигенгән фрицларның шәһәргә авыр туплардан атмавы, җимертмәве дә фаразның дөреслеген раслый кебек иде.

Ординарецлар Гунар һәм Зангир штаб өчен бер зур гына таш бина таптылар. Бүлмәләр күп һәм җиһазлы булу өстенә, ванналары да эшли иде. Мостафин зур гына бер эчке бүлмәгә телефоннар куйдырды, алдагысына Гунар урнашты. Асоев та үзенә аерым ходлы бүлмә сайлаган иде.

Бу шартлар Мостафинның Зитта хакында уйларын ешайтып һәм өметләндереп җибәрде. «Нигә аны бирегә алып килмәскә?» — дип, бик

тәвәккәл фикер йөртте ул. Гунарны мотосы белән җибәрергә дә Зиттаны алып килергә?! Эшнең соңында уйлый торган кеше буларак, Мостафин бу хакта иң әлек әлеге дусты Баграковка сүз катты. Теге исә Мостафинның бу гамәлен хупламады. Хәлләр ачыклана төшсен әле, сабыр ит, диде дә бетерде. Тавышында ниндидер әйтергә ярамаган сер, борчулы мәгънә ишетелеп калды. Тагы нәрсә бар икән инде? Юк, барыбер берсекөннәргә Гунарны Зитта янына җибәрәм, бераз азык-төлек юнәтеп булса, шуны илтеп кайтыр...

Кичен өстәл артында утырган килеш, әнисеннән килгән хатны ачканда, Мостафинның йөрәге дерт итеп сискәнеп китте. Хатта таныш түгел язу күренде. Укыган саен күзләре яшь белән томаланды. «Лейтенант Мөнир Мостафин Польша җирендә билгесез биеклектә һәлак булды...» Бүтән сүзләрне укый алмады, күзе берни күрми, бармаклары калтырый иде. Ул күзләрен учы белән каплады, икенче кулы белән башын кочаклап, өстәлгә салды да катып калды. Телефон шалтырауларын да ишетмәде. Әйтерсең лә, аның бер кулын снаряд ярчыгы өзеп китте дә, кан чәптереп ага һәм бәйләргә көч тә, әмәл дә юк иде. Бары йөрәкне мең энә белән чәнчегән авырту, сызлану гына бар...

Эш белән кергән Асоев аны шул кыяфәтендә күреп, аптырап китте һәм каршына килеп басты.

— Ни булды? Нишләдең?— дип төпченде. Мостафин күзеннән учын алды. Асоев, куркып, тагы нәрсәдер төпченеп маташты. Чынлап та Мостафинның чырае коточкыч иде. Үзе бер сүз әйтә алмый, иреннәре кыймыл-кыймыл килә, эчтән нидер мыгырдана, ә бер сүзен аңлап булмый иде. Асоев, врач чакырырга итеп, телефонга тотынды, әмма Мостафин, аның беләгеннән бик каты эләктереп, кысты. Асоев аңа төбәлеп карады да нәрсәдер аңлаган кебек булды. Трубканы кире куйды. Мостафин урындыгыннан торды, күрми торган караш белән карады, бугаз төере селкенде, ул нидер әйтмәкче була, ләкин сүзләрен эчкә йота шикелле иде. Асоев аны беләгеннән култыклап, үз бүлмәсенә алып керде.

— Даут, сиңа ни булды?— диде пышылдаган тавыш белән. Мостафин сорауны ишетмәгән кебек итте, аннары гаепле кешедәй ирен очлары белән генә елмайды да кулын селтәде.

Бик озак шулай утырганнан соң гына Мостафинга аек уйлары кайтты. Үзе белән ни булганын ул барыбер Асоевка әйтмәде. Моңа тегенең күңеле бераз тырналды тырналуын, комдивта тулы ышаныч казана алмавына кимсенгән сыман тавыш белән сүз башлады.

— Частьны, мөгаен, Владивостокка җибәрерләр,— диде, авыр гына көрсенеп.— Бәлки мәңгегә аерылырга туры килер?

— Ихтимал,— дип кенә куйды Мостафин үзенекен уйлаган кыяфәттә. Аерылуга бернинди әһәмият бирмәве тагы Асоевның күңеленә барып тиде.

— Син мине нигәдер өнәмисең, Даут, ә?— дип, аңа кистереп карады. Бу фикер Мостафинны уятып җибәргән кебек итте, аның күзләре тиз-тиз йөренде, кашлары фикер туплагандай җыерылды, чыраенда гаптәшенә игътибар итү билгеләре чагылды.

— Нигә алай дип әйтәсең?— диде ул, тагы да сөйкемлеләнеп.

— Миңа майор дәрәҗәсе бирүне якламагансың?

— Ничек якламыйм? Кәгазьне кем язды?

— Син анысы. Үтмәсен белеп язгансың,— диде Асоев, күзен дә йоммыйча.

— Юк. Өстәгеләр безгә доложить итмиләр бит, ә киресенчә.

— Соң, алайса, хикмәт нәрсәдә?

— Үзең беләсеңдер инде, Николай Петрович.

— Юк, чынын гына әйт әле?

— Элек хезмәт иткән җирендә дошманнарың сине онытмаганнар, шулар...

— Дөрес түгел, ышанмыйм,— дип, Асоев тирләгән маңгаен кулъяулыгы белән сөртергә тотынды.

— Бер яман атың чыкса, тиз генә бетми ул. Үлгәч тә кала, ди яман ат...

— Анысына ышанам.

— Күзгә күренмәс фәрештәләр безнең гөнаһларны санап торалар ди бит.

— Кемнәрнекен саныйлар, кемнәрнекен юк,— диде Асоев, мәгънәле генә итеп.

— Анысы инде безгә бәйләнмәгән.

— Юк, бәйләнгән, Даут, бәйләнгән,— дип, Асоев башына килгән фикерләрен, кызара төшеп, тезде генә.— Өстәгеләрнең бер-бер гаделсез эшен кеше күрә дә: безгә ни, әнә начальник үзе дә фәрештә түгел дип, дилбегәдән ычкына. Менә кайда бәланең башы...

Үзенең рәтле адәм икәнен Мостафинга җиткерәсе һәм аны шуңа ышандырасы килә иде. Чөнки асылда бит Асоев үзенең фигыле белән бозык кеше түгел, Мостафин шуны һаман танымый микәнни?

— Аерылабыз, Даут, аерылабыз,— диде Асоев, авыр сулап.

— Әллә бүтән частька күчәсеңме?— диде Мостафин. Аңа аерылу бер тиенгә дә тормагандай җиңел булыр кебек тоела иде. Асоев, уфтанып, сүзне яхшы эшләргә, онытылмас дусларга борырга өмет иткән иде, ләкин Мостафин аны үзенчә аңлады. Шуңа күрә ул, кәефе кырылгандай:

— Анысы да булыр,— дип кенә куйды.

— Синең блат зур инде. Тик синдәй үткен тәэминатчыны мин бүтән таба алмам.

— Һа, кемгә кирәк ул?!— диде Асоев үзен кимсетү рәвешендә, ләкин мактау өметләнеп. Ләкин Мостафин аның уңганлыгын, шәп эшләр башкаруы турында авыз ачмады. Телефонга чакырып, ишек шакуга, моннан чыгуына сөенгәндәй, кызу-кызу атлап китте. Әх, чын күңелдән сөйләшү барып чыкмады, дип ачынды Асоев үзе генә калгач. Аңламыйлар мине, кемгә булса да ярдәм итмичә, нәрсәне булса да күрәшеп алмыйча, кирәкле әйберне дию башы астыннан булса да тапмыйча яши алмыйм мин... Ул үзен аңламауларына, бәяләмәүләренә кимсенгән кыяфәт белән ишекле-түрле йөрергә тотынды.

Төнлә юка гына җепшек кар явып киткән. Көн суык түгел, монда диңгез сулышы сизелә иде. Ләкин пушка лафетына утырып, сугышчыларга матчасть өйрәтүче Идрисов бик өши, эчендә һич җылы тормый. Һаман шул төзәлеп бетмәгән балтыр сөяге эчтән сыкрый, туңа һәм бөтен тәненә шуннан суык тарала. Әллә өйлә вакытында аракы эчеп карыйсы инде, дип уйлый ул, аркасына үрмәләп кымырҗыткан салкыннан бөрешеп. Юк, ярамас, исе килсә, сугышчылардан яхшы түгел. Ярар инде, тагы аспирин гына кабарга туры килер, ахрысы.

Идрисов яңа килгән солдатларны бик җентекләп сынап утыра. Аңа бик мөһим нәрсәне хәл итәргә кирәк: пушкага кемне кем итеп билгеләргә? Төзәүче үткен, зиһене тиз йөри торган кеше булырга тиеш. Ләкин артык каудар да булмасын. Каршыга танк килгәндә, салкын кан белән эш итсен, аек акылын җуймасын. Сынаганы бар, нервлы, чәүчәләк кешеләр каушап калучан. Иң кискен моментта пушка янындагы ике кешенең берсе куркып калмасын, өч-дүрт минутка гына, чирканчык алганчы гына. Шул моментны нормаль үтсә, аннары ул үзен үзе кулга ала һәм эшне бозмый инде. Бәрелештә җиңеп чыгу әнә шундый кечкенә психологик сыйфатлардан барлыкка килә.

Парк кырыендагы йорттан яланөс, яланбаш көе бер солдат йөгереп килде (Тафтилов ординарецы икән) һәм Идрисовны телефонга чакыралар дип, алып кереп китте.

Сугышчылар шунда ук бәйдән ычкынган шикелле шаулашырга, тәмәке тартырга, йөренергә тотындылар. Бигрәк тә һөҗүмнән исән калып чыккан солдатларның кәефе күтәренке. Алар инде үзләрен үлем авызыннан ычкынган исәплиләр. Папирос кабып, аны иреннәреннән алмыйча гына сөйләшәләр. Частьны Владивостокка озатачаклар, дип нык ышаналар. Анда әле сугыш буламы, юкмы анысы суга сәнәк белән язылган. Балта чапканчы түмгәк ял итә. Күбесе туган яклар аша узып булмасмы, бик бәхет ачылса, берәр таныш та очрап куюы бар, дип хыяллана иде.

— Кайсы юлдан алып китәрләр икән?— дип, кызып-кызып бәхәсләшәләр.

— Төньяк юлдан, билгеле, Казаннан...— ди берсе, бик белгән кебек итеп.

— Юк,— ди икенчесе, үз ягын каерып.— Рузаевка аша үтәчәк эшелон. Менә күрерсез...

Сүз шушы юллар белән бәйләнгән нәрсәләргә күчә. Кайсыдыр үз станциясеннән үтүгә бик нык ышанып, калдырырга күчтәнәч әзерләве белән мактанып алып, кесәдән фоторәсемнәр, хатлар чыга. Үкенечле истәлекләр, искә төшерүләр, уфтанулар, сызланулар килеп кушыла. Моңарчы үз эченә генә йомылып, сүзгә-өнгә катнашмаучы Мөслимовның да теле ачылган. Чөнки хәзер үлем куркынычы узган, сагаеп, шүрләп маташуның кирәге калмаган. Ул үзен яңа килгәннәр алдында чослыгы белән үлемнәрне җиңеп чыккан үткен батыр итеп күрсәтәсе килә. Сугышта миңа гел җай килеп кенә торды, ә аңа чаклы бәхетем булмаган иде, дип сөйләнә ул. Иң элек өйләнгәч тә хатыным бетмәс бер чиргә сабышты. Тәне салкын, куены суык булды. Хатынның назы булмаса, ара да салкыная, өзелә башлый икән. Әмма, аның каравы балдыз шәп иде. Ул күкрәкләр, ул бил-сын! Үзе утның да уты. Әз генә тиеп китсәң дә пешереп ала, шуны һич оныта алмыйм. Хәзер апасы яман чир белән авырып ята, ә ул: сине генә үлеп яратам дип, миңа хатлар яудыра. Әллә үз хәле мөшкел булуын сизеп, апасы куштымы икән, дим. Юк, булмас, чирләшкә булса да, хатын бик зәһәр нәрсә иде, андый мәрхәмәтлек күрсәтмәс. Әлифә аңардан качырып кына язадыр. Мин башта ук сине генә сөйдем, дип сайрый наян кыз. Апаның юлын гына кисәсем килмәде, ә теләсәм кисә идем, ди шилма. Булдырыр иде ул яшен уты, анысына ышанам. Хәзер инде, апасы кеше булырлык булмагач, ачыктаначык яза. Яратам, син — минеке! — ди. Аһ, сез аның үзен күрсәгез, һуштан язар идегез!

— Ике умарта балын ашап яткансыңдыр әле син карун аю, юкка шулай үлеп яратмас!— диләр сугышчылар, Мөслимовны үртәп.

— Юк,— ди Мөслимов, кулын селтәп.— Әлифә ул якка каты булды, юк!

— Нәфесеңне сузып карагансың икән, имансыз,— дип, сугышчылар шаркылдыйлар гына. Мөслимов мәгънәле генә елмая һәм, куеныннан Әлифәнең фоторәсемен алып, иптәшләренә suza. Рәсемдә киң маңгай, матур гына кашлар, ихтыярлы, ягымлы гына бит-ияк һәм очкынланып торган зур күзләр.— Әйе, бу кыз үз дигәнен булдырыр. Сөйкемлелеге бар, егетләрнең күзен үзендә туктатырлык бу.

— Моңа йә лейтенант, йә капитан кирәк, ә син? — дип төрттереп куйды бер шаяны.— Синнән бау гына ишәр ул...

— Юк, иштермәбез анысы,— диде Мөслимов, тамагын киереп, җиңүче кыяфәтендә.

— Теге мускулы белән ул, бәлки, майордыр, син каян беләсең? — дип, кистерә икенче бер шаяны. Моның мәгънәсен аңлап, барысы да

шаркылдап җибәрәләр. Кешегә көләргә генә булсын. Үзенең рядовой һәм бер медале дә булмавына Мөслимовның кәефе китә. Ул болар яныннан бер читкәрәк китеп, эчтән генә балдызын күз алдына китереп, уйланып йөри башлый. Димәк, хатын үлә, Әлифә миңа була. Хәзер аны миннән беркем дә тартып ала алмый инде. Әгәр Зөя станцасы аша узсак, телеграмманы ничек сугарга икән? — дип, ул рәхәт уйларга чума, эчтән генә бәйрәм итә...

Гунар шәһәрдән Зиттаны таба алмыйча кайтты. Квартиралары бикле, ә яңа күршеләренең аларны бөтенләй күргәннәре юк икән. Нәрсә булган аларга? Абыйсы утарына кайтып киттеләр микәнни? Алай булса, Зитта хәбәр бирергә тиеш иде. Соңгы очрашуда ул сәер генә елмаеп: сиңа әйтәсе бик мөһим серләрем бар, болай әйтергә оялам, хатка язармын яме, дип әйтеп ташлаган иде. Нинди сер булгандыр инде ул? Тик бу югалу тикмәгә генә түгел. Нәрсәдер булган булса кирәк. Әллә хуторга барып килергәме? Ләкин ничек чыгып китәсең, бер минут юк булып торсаң, бар яктан эзләтәләр. Эш күп. Полк командиры Кимбр да ни өчендер караңгы чырай белән йөри. Берәр күңелсезлек килеп чыккандыр. Янына гозер белән барып булырлык түгел... Әх, хәзер Зитта булса, җан сызлаулары, авыр уйларның башны айкый-айкый авырттыруы бу чаклы ук читен булмас иде. Юк, булмас иде...

Шулай эчтән әрнеп, бер мәлгә гаҗиз булып, үз көчсезлегенә үзе ачуы кузгалып утырганда, баскыч төбенә яшел «виллис» килеп туктады. Берәр начальник, ахрысы, дип Мостафин каешларын рәтләде, гимнастерка итәкләрен тарткалады. Ләкин машинадан төшүче Баграков иде. Мостафинның күңелен шатлык дулкыны тутырды. Ул аякларын да сизмичә, аның каршына атылды. Димәк, көнчыгышка китү хәл ителгән, билгесезлек беткән. Иртәгә үк Зиттаны күрергә барам, теләсә, алып та китәрмен, хәзергә биредә торып торыр... Әмма Баграковның йөзендә шатлык юк иде, кул кысышу да рәсми төстәрәк кенә килеп чыкты. Мостафин, сәерсенеп, аңардан күзен алмады. Бүлмәгә кереп, тирән креслога утыргач та Баграков һаман карашын читкәрәк төбәде, бер учы белән тезенә суккалап-суккалап торды. Аннары дәшми утыруны килештермичә һәм шул ук вакытта шелтә белдергәндәй:

— Зитта Дукатны кулга алганнар,— диде. Мостафинның күзләре зур булып ачылып китте, күзенең аклары гына калып, хәтәр ялтырап алды. Йөзендә, юк, бу мөмкин түгел, алдыйсың, дигән катгыйлык күренде. Ул кинәт урыныннан сикереп торды һәм ышанмаган, гаҗиз мөлдерәгән күзләрен аңа төбәде. Баграков, учы белән: сабыр, сабыр, хәзер аңлатам, дигән хәрәкәт ясады һәм әкрен генә сөйли башлады.

— Баш штабка Елгавага барган идем, шунда махсус бүлек начальнигы чакырып алды да синең фамилияне әйтте. Әйе, мин әйтәм, майор Мостафин безнең штабта. Ул эшнең нидән торганын аңлатты. Бер айзсорг хатын-кыздан сорау алганда синең фамилияңне берничә тапкыр кабатлаган. Сизенәсеңме? Ә ул хатын-кыз Зитта Дукат, синең ниең, латыш буржуазиясе оештырган айзсорглар оешмасында член булып торган...

— Бу ниткән эш?! Чынмы? — дип, кычкырып куйганын Мостафин сизми дә калды.

— Тукта, сабыр гына тыңла,— диде Баграков гаепле кешегә әйткән тавыш белән.— Айзсоргларны син беләсең. Шуларның монда яшеренеп калган бер агенты Зитта Дукатка совет офицеры белән танышырга һәм аңардан хәрби сер алырга задание биргән... Төшенәсеңме, эшләр кая бара?

— Юк,— диде Мостафин юашлана башлаган тавыш белән.— Зитта алай булмас...

— Шул заданиене үтәп, синең белән танышкандырмы ул Дукат, әллә бүтәнчәме, хәзергә билгесез, ди, ачыклауны сорый торган мәсьәлә икән. Әмма шул нәрсә билгеле: Зиттаны ике агент бу эшкә юнәлтеп,

өйрәтеп торган. Алар яшерен генә очрашканнар. Тегеләр хәрби сер таләп иткәннәр, ә Дукат әйтмәгән, имеш, заданиене үтәмәгән. Шулай ук ачыклыйсы бар, ди, моны да. Дукат аларның заданиесен үтәмәгәч, имеш, болар аны юк итмәкче булганнар. Бу хакта Дукатка якын дус кызы айзсорг әйткән, ди. Һәм Дукат чарасызлыктан бик тәвәккәл адым ясаган: НКВДга килгән дә тегеләрнең икесен дә күрсәткән. Кайда яшеренеп ятканнарын белгән булган икән. Башта берсен, аннан икенчесен тотканнар. Ә сорау алганда, агентлар Зиттаны да күрсәткәннәр. Аңлашыла торган хәл. Менә Зитта ничек анда барып эләккән...

Баграковның тавышы дусларча кызганулы иде һәм бу хәл Мостафинга эшнең бик җитди-хәтәр булуын аңлатты.

— Шулай ук булыр микәнни?— диде ул тирән пошынып һәм ике кулы белән башын учлап тотты.— Һични аңламыйм!

— Зитта шпионка булган, сукырлыгыңны таныйсың килмиме?

— Юк, нәрсәдер бүтәнчә монда!— дип, Мостафин маңгаен учы белән ышкыды, гүя каймыккан уйларын турыларга, бер эзгә салырга тели иде.

— Шпионка башыңны әйләндергән, ә син чүпрәк...

— Зинһар, Петр Петрович...— диде иңрәп Мостафин, ул аска караган, иңнәре салынган, нәкъ канатлары имгәтелгән кош кыяфәтенә кергән иде.

— Әгәр Зитта немец шпионкасы булса, эш зурга китә. Бар биографияң пычраначак...

Бу сүзне ишетүгә, Мостафин корт чаккандай тартылып куйды һәм әрле-бирле йөренә башлады. Әгәр шулай булса, коточкыч хәл бит! Мондый очракта кешеләр иң якын кешеләреннән баш тарталар, үз тиреләрен саклар өчен бернидән дә тайчанмыйлар. Багракова та Мостафиннан шундыйрак нәрсә көтте. Менә ул хәзер шул шпионка хатыннан үзен аера, баш тарта башлар. Аңа нәфрәтләнеп кабыныр, үзен алдаган өчен аны өзгәләп ташлар дәрәҗәгә килер...

— Юк, юк,— диде Мостафин, кулларын өшегәндәй угалап.

— Дукатның шундый булуына ышанмыйсыңмы? — дип куйды Багракова, ачулана башлап.— Ә мин ышанам!

— Син аны белмисең бит?

— Үзеңне шундый оста итеп кармакка эләктергәннәр! Ә син: белмисең, имеш! Сиңа хәзер ничек ычкыну әмәлен карарга кирәк...— Багракова минем сүзем бетте, үзең теләсә нишлә, дигән кыяфәт белән портсигарыннан «Казбек» алып кабызып җибәрде. Мостафин креслога барып утырды, ул бөрешеп, кечерәеп калган кебек булды. Бер сүз эндәшә алмады. Башына кинәт китереп суккан бу хәлне ничектер аңга сеңдерергә, аңларга һәм балта белән чапкандай өзгәләнеп, чәбәләнеп беткән уйларының бер очын табарга, шуңа тотынырга кирәк иде. Зитта, Зитта... ничек булып чыга соң әле бу? Ул бит инде минем җанга иң якын кешем, хатыным кебек иде. Ул миңа ышанып, мине үзенең җанына кертте, мин дә, ышанып, аны җаныма кабул иттем. Ул миңа мәхәббәтен бирде, йөрәк серен ачты. Шулар барысы да уен, искиткеч пычрак уен, мине төп башына утырта торган алдау гына булып чыктымы? Зитта ничек шулай юха елан була алды икән? Петр Петрович элекке әңгәмәләрдә сүз арасында әйткәне бар: хатын-кыз хыянәтчел орлыктан яралган ул, дип.

— Ну, нишләргә уйлыйсың? — диде Багракова, тәмәке төпчеген ташлап. Ул Мостафинның һаман үзенең кискен хәлен аңлап җитмәвенә, шуңа күрә үз дәрәҗәсе өчен кайгырмавына гаҗәпләнә иде.

— Петр Петрович, беләсең бит,— дип тотынды Мостафин эчке ачыну белән,— мин һаман ышанып җитмим, кинәт кенә икенчегә борыла алмыйм...

— Бик начар!— диде Багракова киңәш биргән тавыш белән.

— Син үзең дә нәкъ шулай булыр идең... Миңа хәзер Зиттаны күрергә кирәк.

— Юк, бу чаклы ук беркатлы дип белми идем сине, валлаһи...

— Әйе, бу политик мәсьәлә, аңлыйм.

— Аңлагач соң? Ә бу нәрсәдә кичерү юклыгын да төшенәсеңдер шәт?

— Төшенәм! Мин нишләргә тиеш соң?

— Мин сине кисәтергә дип килдем. Бернигә дә катышма!

— Зиттага мин бер хәрби сер дә әйтмәдем. Моны шулай калдырыйммы?

— Әллә ул шпионка түгел, дип исбат итә алырсыңмы? Юк, органнар тикшерсеннәр. Ул тирәгә барма.

— Шулай да ул якын кешем иде бит.

— Бу эшкә беркем дә тыкшына алмый. Анда сиңа эш «текмәкче» булганнар иде әле, мин туктаттым. Икенче атнада эшелоннарга төялеп китәчәкбез, шуны сәбәп итеп сорагач, риза булдылар.

— Минем бер гаебем дә юк,— диде Мостафин, һаман беркатлыланып. «Эшне» туктаттым дигән нәрсә дә аңа тәэсир итмәде шикелле. Ул моның өчен Баграковка мең рәхмәтләр укырга тиеш иде.

— Монда гаеп бармы-юкмы, важны түгел!— дип, ачуланып кычкырды Баграков.— Бөтен эш Дукаттан тора. Әгәр ул тикшерү вакытында бутамаса, артык сүз ычкындырмаса...

— Булмаганны ычкындырмас!

— Даут, әйтим әле, бик начар сыйфатың бар синең: ышансаң артык нык ышанасың, бер ышанмасаң, үлсәң дә ышандырып булмый сине! Артыклык һәрнәрсәдә дә һәлакәткә китергәнен үзең дә беләсең бит!

Ул урыныннан торды. Китәргә җыенуы икән. Мостафин аңа рәхмәт әйтергә дә, әйтмәскә дә белми, күзле бүкән кебек тик катып утыра. Әйе, аның Зиттага ышанычы какшаса да, әле һаман бетеп җитмәгән.

— Ярар, бик үлмә әле,— диде Баграков, ышанычлы рәвештә аңа кулын биреп,— мин шалтыратып торырмын. Шыпырт кына бул!— һәм күзләре белән Мостафин йөзеннән шуып узды да бусагадан атлады.

Теләсәң нишлә, менә шундый хәл. Җитмәсә, бәлагә каршы көрәшер өчен бармак та кыймылдата алмыйсың. Язмыш хөкемен көтәргә генә кала. Ә уйлар һаман, тау елгасыдай, бәргәләнә-суккалана, үзен каплап киткән караңгылыктан чыкмакчы, котылмакчы була, ниндидер юл эзли иде. Зитта белән бергә сөйләнгән сүзләр, эшләнгән эшләр күз алдыннан уза. Аларны зиһене җиз иләктән үткәреп тора. Кадерле минутлар берсе дә истән җуелмаган, ташка уеп язган кебек хәтердә саклангән. Баштарак ниндидер шик күңелдә уянган кебек булган иде? Теге «урман кешеләре» тырнагына эләккәннән соң? Аннары ул бетте. Неужели шул дөрескә чыга?! Яратуның икейөзле булуы мөмкинмени? Юк, Зиттаны мин бер минутка гына булса да күрергә, йөзенә карарга тиеш... Тукта, Баграков: «Берничә көннән эшелоннарга төяләбез»,— диде түгелме соң? Димәк, без китәбез, Зитта кала? Зиттаның йөзенә бер карауга мин барысын да аңлар идем, әйе, аңлар идем. Мин аны тагы кайчан күрермен? Бу инде мәңгегә аерылу? Болай берни дә белмичә китү мине гомер буе газаплап торачак. Кулга кадалган шырпы кебек ул бер минут тынгы бирмәячәк, үлекләп, сулкылдап, җанны кисәчәк. Юк, нәрсәдер эшләргә кирәк...

Берничә көн элек штабтан җентекле белешмә сорадылар: солдатларның сугышка хәтле кем булуы, яралары һәм башкалар турында төгәл мәгълүмат кирәк иде. Элек укытучы булган өлкәнрәк яшьтәгеләрне өйгә җибәрәләр икән, дигән хәбәрләр йөри, бәлки шуның өчендер. Бу эшләрне генә бетерәм дә Кимбрга рөхсәт сорарга керәм, бер тәүлеккә нигек тә җибәрми калмас әле, дигән өметле карарга килде Мостафин.

Төне буе йоклый алмады, кая ул! Иртүк түмәрдәй авыр баш, борчылу тулы күңел белән батареяларга чыгып китте. Гадәттәге ягымлы

чибәр йөзе сүрәнләнеп калган, аяк атлаулары да бик нык салмакланган. Әледән-әле, эче януга чыдый алмыйча, уфылдап куя. Шулай да ул солдатлар янында барын да онытты. Класска дәрес бирергә кергән укытучы кебек, аңа җиңел булып китте. Хәл-әхвәлләрен сорашты, шаян сүзләр дә кыстыргалады. Карале, сез курортка эләккәнсез икән, парк эчендә саф һавалы җирдә яшисез, каршыгызда гына костел да бар, дип көлдереп алды. Үзе гел аларны күзәтте, икешәр-өчәр мәртәбә яраланып, таушалып калган, көлдәй аксыл чырайлы, дөресрәге, чырайсыз солдатлар. Батарея командиры Идрисов та төссез, эчтән ниндидер авыру кимерә ахры үзен. Тукта, ул укытучы булган түгелме соң? Шулай булса, мин аңа кайтып китәргә булышачакмын...



Ул һәрбер солдат каршына тукталып сорашты, ә писарь амбар кенәгәсенә яза барды. Солдатлар үзләре дә дивизион командирын ачык булуын, бернине дә яшереп, куркып тормавын сизделәр, сораулар яудырдылар. Сораулар төрле иде, кемнәргә пособиеләр, бурыч-салымнардан нинди солдатлар коткарыла һәм башкалар. Бер кыю гына чырайлы өлкән солдат бөтенесен кызыксындырган сорау бирде.

— Көнчыгышка китәбезме, юкмы? — диде. Саф бик канәгать булып гүләп алды. Барысы да майорның авызына төбәлделәр. Мостафин елмайды, ә күңелендә, дөресен әйтергәме, юкмы, дигән уй бөтерелде, чөнки әле бернинди дә приказ булмады. Багракoв әйткәнне ычкындырырга ярамас, әйе, ярамас... Ул, ниндидер шаян сүз белән җавап кайтарырга теләп, солдатка таба атлады, ләкин кинәт арттан аткан тавыш ишетелде, Мостафинның куллары як-якка җәелеп китте, гәүдәсе чайкалды, күзләре зур булып ачылган иде. Аның карашы: әх, сезне, нигә мине шулай иттегез, дигән кебек шелтә белән җыерылды да күзләре йомылды һәм тезләре бөгелеп җиргә ава башлады. Гыжылдап сызгырып, авыр сулыш алганы ишетелде... Аны ординарецы Гунар кочагына тотып алды. Кемдер ачы итеп кычкырды. Буталыш китте. Ату тагы кабатланды. Яраланган Гунар шарран ярып чырылдады. Сугышчылар лапылдап җиргә аудылар. Шартлардай булып, кинәт Каракүз тавышы яңгырады: «Әнә костел түбәсеннән аттылар, костелдан гына аттылар!!» Идрисов җирдә яткан килеш кызыл кирпеч костелга күз төшерде һәм ни буласын уйлап-нитеп тормастан:

— Батарея, к бою! — дип, йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып, өскә калыкты һәм пушка артына барып чүгәләде. Бер минутта кискен хәрәкәт булып алды, солдатлар пушкаларына барып ябыштылар. Икенче минутта Идрисов цельне кычкырып әйтте һәм үз пушкасыннан беренче снарядны җибәрде. Шунда ук тагын алты пушка залп бирде. Икенче залп биргәндә кинәт орудиеләр каршында күзләре акаеп маңгаена менгән Тафтилов пәйда булды.

— Отставить! Отставить! — дип, кулларын өскә күтәреп акырды. Ул, әлбәттә, Мостафинның һәлак булганын белми, шуңа күрә шәһәр уртасында пушкадан атуны баш китә торган эш дип, ерткычтай кычкыра. Икенче мәлдә, Идрисов янына атылып килде дә аны пушкадан каерып ташлады.

Теге, хәтәр ярсыган килеш, борын яфракларын калтыратып, эшнең нидән икәнен аңлатмакчы була, кулларын бутый. Шулай тарткалашкан мизгелдә мәйдан кырыендагы ике катлы йорттан, ашыга-ашыга комендант, начальниклар чыгып, болар янына килделәр. Түбәсе тәмам җимерелеп, стеналары ишелгәләгән костел ягына кулларын суза-суза, Идрисовка янап кычкырдылар. Идрисовның ярсуы сүнә төште. Ул Мостафинның һәм тагы бер-ике сугышчының үле гәүдәсен күрсәтте, үзенең туптан атарга мәҗбүр булуын дәлилләде. Комендант бу эшнең ярамаганлыгын әз генә булса да төшендерүдән арып, гаҗиз булып, Мостафин янына тезләнде һәм бик тәҗрибәле врач сыман аның башын Тафтилов кулларыннан алды. Чигәсенә учын нык кына кысып торды, пульсын чамаламакчы булды, күрәсең. Ул арада ак халатлы врач килеп җитте, соквояжын

ачып, аның беләгенә тиз генә укол ясады. Аннары бер кулын Мостафинның йөрәк турына куюга, йөзе үзгәреп калды, өметсез рәвештә кулын кире алды. Мостафинның йөрәге тибүдән туктаган иде инде...

Каракүз башлыгында костел янына йөгергән тупчылар умырылып беткән киемле бер немец снайперы гәүдәсен күтәреп килделәр. Ату дулкынына эләгеп, түбәдән тәгәрәгән, ахрысы, стена төбендә ята иде, диде Каракүз. Атуның кайдан булуын ул ничек шулай дөрес күреп алды икән, шунысы бик гаҗәп иде. Үткен кеше үткен кеше шул инде...

Зур, авыр гәүдәле, симез битле комендантның чырае кырысланып киткәндәй булды, ул немец гәүдәсенә җирәнеп карады да, китәргә таба атлап, Идрисовка коры гына:

— Минем арттан барыгыз!— диде. Тафтилов, эшнең начар якка авышуын сизеп, Идрисов белән бергә атлады. Йөзендә җавап бирергә булса, бергә бирербез, дигән карар бар иде.

Тикшерүдән соң Зиттаны аклап чыгардылар. Хөкем итәрлек гаебе исбатланмады. Дөрес, аңа агентлар яшерен заданиеләр биргәннәр, ул аларның берсен дә үтәмәгән. Мостафиннан хәрби сер алырга уйламаган да, тырышмаган да. Аны беренче күрүдә үк җаны-тәне белән яраткан һәм башка нәрсәне белергә дә теләмәгән.

Сорау алганда Зитта майордан дүрт айлык авыры барлыгын әйтте һәм, врачлар тикшереп раслаганнан соң, теләсә нинди очракта да баласын табарга теләвен белдерде. Бу хәл аны нигездә акларга һәм тизрәк чыгарырга сәбәп булды. Ләкин аңа бирелән китәргә куштылар. Айзсорглар бар икән әле, аның ике зәһәр агентны тоттыруын алар онытмаячаклар.

* * *

Зитта Эрбет шәһәренә килеп, бер заводка художник вазифасына эшкә урнашты. Даутның үлеме турында хәбәр аңа шунда килеп җитте. Баграков Владивостокка эшелонда барышлый аңа открытка язып салган иде.

Сугыш беткән вакытларда Зитта ир бала тапты. Аны күреп: бу кечкенә Даут бит, дип әйтергә була иде. Шул чаклы этисенә охшап туар икән, рәхмәт төшкере.

Мостафинның әнисе Хөсниҗиһан әбинең инде утыздан узган онысы дөньяда яши. Тик ул аны белми генә. Сугышта үлгән улларын исенә төшергәндә, исән калып, әнә шул елны өйләнгән булсалар, фәлән яшьтәге балалары, балаларының балалары булыр иде дип, аларны терелтеп алгалый. Шулай язгандыр инде, ди, йөрәк әрнүен басарга теләп, үзен-үзе тынычландыра.

Зитта Даутның туганнары бармы-юкмы, булсалар — кайда, ничек икәнен дә белми иде. Ул мәгълүматлар аны ничектер бер дә кызыксындырмады. Барча яшьлек табигате, хатын-кызга хас сөю көче белән ул аның үзен генә яратты һәм бу ярату тормышның үзе кебек мәңге дәвам итәр шикелле тоела иде.

## Әхсән Баянов

### Тынлык эше

Көндез бульдозер, динамит
Актарса да ни хәтле,
Җиргә төн, елга сулышы —
Тынлык эше сихәтле.

Кара эшләрне ярлыкау
Хезмәтен башкарганда,
Каргануың, сукрануың
Ишетелми, Җир-ана.

Үсемлекләр бәллүенә
Төшә чык — дога сүзең.
Анда даһилыгың синең,
Сөюең, түземлегең.

Яр өстендә куш мөгезле
Ай да әнә терелгән.
Ишетәм: баса тураеп
Көндез егылган үлән.

*1975*

* * *

Без новатор күзе белән
Бер карыйк әле, күңел.
Җидегән җиргә төште бүген,
Калдырып сөйгән күген.

Экскаваторчы егет
Биргәндер аңа куәт.
Озаттылар көнне бергә
Диңгезләр токымы күрәп.

Калага, өйгә юл ерак,
Яшь йокыга — җылы төн.

Машинасы чылбырына
Менде ятты егетең.

Аста бушлат, өстә бушлат —
Менә диган урын-җир.
Кем өчендер мич башы да
Болай җайлы түгелдер.

Җидегән йолдыз янындагы
Кешенең сулышына
Чуерташлар шыбырдавы,
Океан шавы кушыла...

*1975*

### Таш легенда

Заводлар чамасыз күп сыман,
Заводлар түбәсе — күк томан.
Күперләр — сузылган бетон кул,
«Тотар да адәмне сытар» ул.

Баобаб шикелле торбалар
Галәмгә тәрәлеп торалар.

Башында йөриме кырмыска?
Кешеләр үрмәли тормышка!

Адашып калырлык корылма.
Кодрәтләр сурәте бу дөнья.
Күренә, чыңлый чор турында
Таш белән язылган легенда.

*1975*

## Элекке кебек

Син шул кадәр зирәк идең элек,
Яшәү көче миңа бирерлек.
Якты көчләр куйды бугай кимеп,
Инде киңәш көтмәмдер кебек.

Зирәк идең элек,
Кал шундый булып,
Мине сөйгән чактагы кебек.

Син шул кадәр чибәр идең элек —
Ай-Кояшны көнләштерерлек.
Бөек төсләр куйды бугай кимеп,
Көнләшерлек түгелдер кебек.

Чибәр идең элек,
Кал шундый булып,
Мине сөйгән чактагы кебек.

Шул кадәр дә бәхетле идең элек —
Йөри идең күккә баш чөеп.
Узасың гел хәзер башың иеп,
Узганнардан оялган кебек.

Бәхетле идең элек,
Кал шундый булып,
Мине сөйгән чактагы кебек.

1983

## Ике ләкләк

Күк иркендә гүя — пар ишкәкләр
Талпына киң Идел өстендә.
Тар утрауда ләкләк канатлары
Ишкәкләргә кызыгып җилпенә.

Ике ләкләк камыш арасында:
«Очыйк без дә, күккә тиз җитик!»
Очалганы җилпенеп тиз арый,
Армаганы оча белми тик.

Сабый чактан, шау-шулардан куркып,
Җәяү генә калган ул яшәп.
Балалары күкне сагынмаска
Күнегеп үк бәлки туачак.

Ике ләкләк кешеләргә бәлки
Аваз сала кечкә су аша.—
Ташсыз ярдан камышларга карап,
Кошлар белән кемдер аңлаша.

1983

## Сөйләсеннәр

Сөйләгәннәр сөйләсеннәр,
Аралары якын икән дисеннәр дә,
«Сөю» сүзен кушып безнең исемнәргә,
Гаеп, гөнаһ эзләсеннәр,
Сөйләсеннәр.

Көнләгәннәр көнләсеннәр —
Аралар бит чынлап, ахры, якын безнең,
Яры белән дулкыны күк Агыйделнең.
Тамчы су дип тилмергәндә, дәрьямны син
Бөтен килеш алып килдең —
Көнләсеннәр.

Күрмәгәннәр күрмәсеннәр —
Мин бит синең иреннәргә түгел,
Капландым ла салкын чишмәм ашкынына.
Сөюеңә түгел: ташландым ла ярдан
Узган еллар ташкынына...
Күрмәсеннәр.

Белмәгәннәр белмәсеннәр:
Сине түгел, сөйдем яшьлегемне.
Әллә инде җирсәүне дә яшеримме?
Агыйдел дә, чишмәләр дә калдылар ак,
Сау камышлар кайтардылар имин җавап.—
Белмәсеннәр.

Сөйләгәннәр сөйләсеннәр.
Хәтирәләр хәтәрлеген җиңгән чакта,
Агызса да агым безне аргы якка,
Исән калдык — ташлансак та чакрымнарга,
Адашсак та ят кырларда...
Сөйләсеннәр.

1979

●

Куллар сузып күпме көттем!
Юк, кунмады зәңгәр кош.
Карчыгалар әйткән аңа:
«Ул түгел синең язмыш».

Көтә-көтә аргач куллар,
Калтырангач азакта,
Сизми калдым, алар кинәт
Әйләнделәр канатка.

Очып күкләр иңләдем мин,
Болытларны айкадым.
Ак канатлы күк кошымны
Күкләрдән дә тапмадым.

Ә кауырыйлар ята җирдә...
Күзләрме күрә ялгыш?
Карчыгалар әйтте шунда:
«Ул түгел синең язмыш».

1975

## Ялгыз нарат

Төшкә керә һаман кабат-кабат
Тын утрауда калган карт нарат.
Ялгызлыктан арып, сазлык аша
Яшь көннәргә тора ул карап.

Бер кәүсәле куак, яшел канат,
Яшел болыт — салмак талпына.
Кичтән уза таңга, манчылып гел
Сабыр моңга, сары алтынга.

Кайтырмын дип кемдер биргән вәгъдә,
Нарат калган ядкарь төсле гел.
Ялгыз нарат, айлар-еллар санап,
Кемнәрнеңдер атый исемен.

Тиргисеңме син мине дә, нарат,
Сагынасыңмы әллә хәзер дә?
Өстеңнән бит җилләр төсле шаулап
Узды бугай минем дәвер дә.

Көтә сине зәңгәр, ак заманнар,
Китәчәксең тагын алгарак.
Ишетәмен тавышың: «Сездән ерак
Киткән саен сагышым яңарак».

1969

## Инде бер дә китмә

Мин — әниең, туган җирең синең.
Кайтуыңны сагынып гел көттем.
Көзге җилләр кебек эзләндем гел,
Тын яңгырлар төсле яшь түктем.
Инде бер дә, бер дә, бер дә китмә,
Җир-суыңны җырсыз, көнсез итмә.
Мин бит — туган җирең,
Сиңа мәңге ана,
И бала, бала.

Син, сабыем, яшь үләннәр тапта,
Мин шатланып кына түзәрмен.
Ә егылсаң, йомшак мендәрең мин,
Ярaң сыйпап, түз, түз, диярмен.
Иркәләрмен җил һәм су шикелле,
Чиксезлеге кебек кырларның.
Төш суларга, дулкындай сөярмен,
Ташлап китсәң, кибеп тынармын.
Инде бер дә, бер дә, бер дә китмә,
Җирне җырсыз, мине улсыз итмә.
Мин бит — туган җирең,
Сиңа мәңге ана,
И бала, бала.

1976

## Ай кызы

Кайчандыр ул җирне ташлап киткән.
Су алырга килгәч чишмәсенә,
Мөлдерәмә яшьле күзләр белән
Айга карап, серен чишкән шунда:
«Ал үзеңә, коткар, ай гынам,
Үги анам җәфаларыннан».

Ай, кызганып ятим кыз баланы,
Алган үзенә, булган үзе гашыйк.
Көянтәгә чиләкләрен асып,
Инде Зөһрә айда тора басып:
«Кичерегез, Җирем, чишмәм», — ди.
«Сезгә инде кабат төшмәм»,— ди.

Җир баласы мәңге айга бага,
Җир егете күккә ашмак була.
Ә ай кызы алмый күзен җирдән,
Үкенечле серен ачмак була.
Ай нурыдай сибеп сагышын,
Карый, тыңлый чишмә агышын.

«Һава да юк монда, юк су, яңгыр.
Тавыш та юк, дөнья — җырсыз, өнсез.
Күтәрелми салават күперләре,
Караңгы күк мәңге таңсыз, көнсез.
Айга йолдыз күренә гел генә,
Шәфәкъ янмый ләкин күгендә».

Кайчандыр кыз җирне ташлап киткән...
Тик кабатлый хәзер: «Җирем, бәгърем,
Алчы мине кабат, ал үзеңә,
Барча газап-кайгыңа түзәрмен.
Үкенмәмен арып югалсам,
Чишмәмнән бер чиләк су алсам».

*1985*

## Йокысыз төндә

«Авыр чакта әни искә төшә...»—
Кемдер әйткән гади, даһи сүзне
Кабатладым икән ничә,
Кем белсен...
Күз алдыма бәла, кайгы төсе
Кара төн ябынып килә дә,
Канатларын җәя булмәдә.
Кара шәүлә алып килә миңа,
Алып килә йокысыз төн...

Җанның күгәрмәгән җире калмагандыр,
Ут яндырып әгәр карасаң.

Ал-күк тимгел чамасыздыр анда,
Әгәр санасаң.
Йоклый алмыйм:
Карыйм,
Саныйм,
Ахры, саташам.

Тәнем кыска ыңгырашу авазына бетә сыеп:
— Аһ!—
Бүтән сүз юк.
Үрсәләнеп ята торгач,
Әни килә күз алдына әүвәлгечә.—
Җем-җем итә күздә йокысызлык.

Тән сызлавы, җан сызлавы әкрен-әкрен шунда
Рәхәт җылы белән алмашына.
Күзләремне әни йомдыра да
Башым сыйпап уза: «Йокла, балам».
Мизгел арасында сизәм: тәнем ойый инде,
Мин йокыга талам.

Уяныргa вакыт җиткәч, сизәм: өйдә — якты иртә.
«Тагын бераз йокла әле»,— диеп,
Әни эшкә китә.

*1985*

## Җир ярылмый калган

Нәрсәдәндер җене котырып берәү
Әллә утын, әллә үчен ярган.
Ә бер заман туктап калган — арган.
Мәгәр ачуы басылмаган һаман.

Ачуыннан адәм утын яргыч
Балта белән җиргә китереп орган.
Җирнең үзен ярып атмак булган,
Ярый әле куәт җитми калган.

Усаллыкка киткән бөтен дәрман.

*1985*

## Ринат Мөхәммәдиев

# АК КЫЯЛАР ТУРЫНДА ХЫЯЛ

ПОВЕСТЬ

1



Алсу нигә китә?.. Калдырыгыз Алсуны... Алсу, китмә!— дип кычкыра-кычкыра йөгерде Азат. Җигүле ат басу капкасыннан чыгып күздән югалганчы йөгерде. Башта ул Алсу утырган чананы менә-менә куып җитәм дип йөгерде. Бер як үрәчәгә тотынам. дип үрелгәндә генә, үрәчәгә бармаклары кагылды дигәндә генә, йөзтүбән егылып калды. Ә пар ат җигелгән чана уйнаклап китеп барды. Торып тагын йөгерде, атка тагын якынлашты. Чана түрендә мамык шәлгә төренеп утырган Алсуны да аермачык күрде. Аның: «Әйдә, әйдә, Азат, йөгер...»— дигән сүзләрен дә ишетте. Чанадагылар исә, баш очларында сыек чыбык болгап, көлешә-көлешә атны куаладылар: «На-а-а, юкса, икенче кызыбызны алып калырга да күп сорамас бу Нурлы Алан егетләре. На-а-а... Ха-ха-а...»

Бәлки Азат аларны куып та җиткән булыр иде. Юк, һичшиксез, куып җитәчәк иде ул. Юлның урта бер җирендә абынып егылмасамы... Аяк астындагы бозлы түмгәк бер бадьян алма сыман чәчрәп-таралып китмәгән булсамы... Шуңардан кызык табып, чанадагылар тагы шаркылдап көлмәгән булсамы...

Юлның урта бер җирендә тәгәрәшкән ат алмалары арасында ятып калды ул. Ә чана уйнаклый-уйнаклый китеп барды. Күз төпләрендә, кар бөртекләре эрүдәнме, кайнар тамчылар йөгереште. Шул авыр тамчылар аңар башын калкытырга, торырга ирек бирмәде. Маңгай астыннан гына әрнеп, гарьләнеп карады ул соңгы тапкыр. Алсу да нәкъ шул чакны, чана түрендәге урынынннан кымшанып, аңар нидер дәште, кул болгады төсле.

Азат берни ишетмәде, ишетүдән узган иде. Бөтен ачуын алырга теләп, ялан кулларына эләккән ат алмалары белән карлы юлны төя-төя шыңшыды. Озак ятты шулай. Олыларның үзен аңларга теләмәвенә әрнеде малай күңеле.

Җылы кар өстендә тәгәрәп тынычлана төшкәч кенә аякларына басты. Кесәдән йон бияләйләрен тартып чыгарды. Шап-шоп сугып, карга буялган өстен какты. Бер як җиң очы белән җәлт кенә борынын сөртеп алды. Күз төпләрен уды...

Кодаларның атын чыгарырга дип киереп ачылган капка әле ябылмаган иде. Ишегалдында әле һаман кодаларны озаталар. Тальянга кушылып, әйттерепме-әйттерә туган-тумача. Өй ишегеннән, буран булып бөтерелгән җылыга төренеп, пар стакан һәм шешә тоткан Хуҗа абзый килеп чыкты. Изүләре ачык, күзләр малай өйләндерү шатлыгыннан кысыла төшкән, бәхеткә тулышкан авызы җыеп алалмаслык булып ерылган.

Стаканнарың путалы,
Уң кулыңа тот әле...

— дип жырлый-жырлый, кулындагы кырлы стаканнарны бер-бер артлы кунакларына сузды ул. Эре-эре калҗалар өелгән тум-тутырык тәлинкә тотып, аның артыннан Әминә апа йөри.

— Туй ике килми, кем, «юл аягы» артыннан бер кабып та ал инде... Менә шулай, менә шулай...

— Әй, Әминә апа, кыстап та куясың инде...

— Юк, юк, менә монысын, үзеңә карап торганын, симезрәген, дәүрәген тот әле...

— Әй, Әминә апа...

Кыстау һәм кысташу авазларын тагы Хуҗа абзыйның кәефле жыры күмеп китте:

Ал, күтәреп эчеп җибәр,
Кулыңа килгән стакан...

Гармунчы бию көйләрен аның саен җәһәтрәк тартып җибәрә. Аяклар торган саен ныграк баса. Ишегалды бәйрәм итә, дөнья чайкала. Башка сыеша алмаган бүрекләргә кадәр, биергә теләгәндәй, мәтәлчек атып сикереп төшә. Изүләрдән гайрәт, дәрт бөркелә. Аяк астындагы каты кар такмаклап шыгырдый. Ә Хуҗа абзый — бәхетле, Хуҗа абзый сыйлый:

Аракы арыш мае,
Тот әле, карышма әле...

Кунаклар да биегән җирдән җавап бирә:

Аракыны, винoны
Бик яратам мин аны...

Урам уртасында басып торган Азатта кемнең гаме булсын. Биючеләргә дәрт өстәп зур учларын бер-берсенә шап-шоп сугып торган әтисе дә күрмәде аны хәтта. Бердәнбер улына таба борылып та карамады. Ул арада Мәрьям түтекәй ишегалды тутырып «Баламишкин» көенә җырлап җибәрде. Аның яңгыравыклы калын тавышы берәүнекенә дә охшамаган.

...Менә, малай, мин сиңа әйтим,
Икесен бергә кушып эчсәң,
Ми-тыр я-рым си-и-кертә.

— И-их, әйттерә дә соң безнең Мәрьям түтекәй,— дип, кемдер җыр арасында мактап алырга да өлгерде үзен. Ә ул исә үзенең моңлы керәшен акценты белән тагы да дәртлерәк итеп җырлавын белде.

Кичен өйдә ирләрчә сөйләшү булып алды.

Әтисенең, малларны ашатып-эчертеп, ишегалдыннан керүе, мич каршындагы урындыкка килеп утыруы булды, уңаен көтеп кенә торган Азат шундук аның тезләренә менеп кунаклады.

— Мине дә өйләндер әле, әти!

Ата кеше ирексездән елмаеп җибәрде. Әмма үзен шундук кулга алды. Уйчан кыяфәткә кереп, колак артын кашып куйган булды.

— Ничек була инде бу, сүзең бик җитди икән бит...

— Әйе,— дип, әтисенә охшатырга тырышып, малай да үзенең колагына үрелде.

— Кемгә өйләнергә дисең инде?

— Алсуга, әти, Алсуга!

— Кайсы Алсу? Кем кызы соң ул?

— Исемнәрен белмим. Хуҗа абзыйларның өр-яңа кодасы инде... Миңлегали абый өйләнде бит, шуларның бәләкәй кызы инде...

— Ә-ә, шул буламыни инде Алсу... Соң, бик бәләкәй түгелме соң әле ул? Теге көнне капка келәсенә буе җитми азапланган кызны әйтәсеңме?

— Шул, шул, әти,— дип, уңайрак урын эзләгәндәй, янә бер тез өстеннән икенчесенә күчте Азат. Әтисенең дә Алсуны хәтерләп калуына күңеле булды аның.

— Бәләкәйрәк кыз икән шул.

— Һи-и, әти, үсә ул!— дип тынычландырырга ашыкты малай әтисен.— Туй көнне без Миңлегаяз белән тыңлап тордык, Хуҗа абзый менә болай

җырлады: «Бәләкәй булсын, матур булсын — кочаклагач үсә ул»,— диде. Ишегалдына ук ишетелде. Үзең дә шундаең бит.

Серләшүен ярым пышылдаудан башлаган Азат, инде дөньясын онытып, шар ярып сөйләргә тотынган иде. Авызы да ерылганнан-ерыла барды. Әтисен ышандыра алуына аз гына да шиге калмаган иде инде. Шуңа, тез өстенә генә сыеша алмыйча, идәнгә үк сикереп төшеп, урындык әйләнәсендә бөргәләнә башлады.

Әти кешегә мәзәк иде, билгеле. Шулай да ул сагая төште. Улын иңбашыннан үзенә кыса төшеп, сүзне читләтебрәк икенче очтан башлады.

— Сиңа ничә яшь соң әле, улым?

— Җиде. Көзгә мәктәпкә барам.

— Иртәрәк түгелме соң?

— Түгел! Өйләнергә беркайчан да иртә түгел!

— Кем әйтте?

— Үзем беләм. Җыру да ишеткәнем бар.

Әти кеше тагын бер тын уйга калып торды. Улын рәнҗетми генә аңлатырга иде аның теләге.

— Нәрсә, бик тә ошадымыни соң ул кыз? Кем дидең әле...

— Алсу.

— Алсу бит әле... Исеме матур икән.

— Исеме генә түгел, үзе дә, әти. Шун-дый матур ул... Чанада шундый оста шуа. Малайлардан да болайрак. Беренче көнне үк амбар тавының иң түбәсенә менде дә шуып төшеп китте. Без авызны ачып карап калдык. Ә ул көлә генә. «Таумыни бу,— ди,— моның ише тауны безнең авылда бар дип тә'белмиләр»,— ди. Без ул тауның яртысыннан гына шуа торганыек.

— Башына ук менәргә курыкмадыңмы соң?

— Курка ди. Алсу сизсә... Ул болай да көләргә генә тора.

— Егет икәнсең.

— Егет булмасам, өйләнәм дип тә тормас идем. Егетләр гел өйләнә бит. Әнә, Миңлегали абый да егет иде, өйләнде.

Канат үскәндәй булды Азатка. Әтисен ышандырды ич, һәр сүзенә җавап тапты. Инде кайчан алырга барырлар икән Алсуны?.. Кайсы атларны җигеп барырлар икән... Дугага шөлдерләр дә тагарлармы...

— Һи-и, әти,— дип җанланып китте ул кинәт,— әле мин сиңа Алсуның шәле, бияләйләре турында сөйләмәдем. Аларны күрсәң, исең китәр. Каз бәбкәсе сыман йоп-йомшак һәм күпереп тора. Шәл дисәң дә шәл ул, әти, менә шундый-шундый йомшак инде, гел мамык кына...

— Шәлен дә тотып карадыңмыни?

— Юк! Тотына ди! Күзгә шулай йомшак күренә ул.— Малайның күзләрендә очкын кабынган иде, ул мавыгып сөйләвендә булды.— Аларның бә-ә-әк еракта, бә-ә-әк биек таулар ягында бер туганнары бар икән. Менә шул тауларда шундый дә-әү мөгезле кәҗәләр йөри икән... Шул кәҗәләрдә генә шундый йомшак мамык була икән... Шул туганнары кәҗә тотучылардан шундый кәҗә сатып алган. Шул кәҗәнең мамыгы бик күп була икән. Шуны Алсуларга да җибәрәләр икән.

Улы сөйләгәннәр әтисенә дә кызык булып китте.

— Менә ничек икән,— дип,— гаҗәпсенгәнен сиздереп алды ул.— Боларның барысын да сиңа Алсу сөйләдеме?

— Әйе,— дип, канәгать кенә борын тартып куйды малай. Һәм белгәннәре әле шулар белән генә бетмәгәнлекне аңлатырга ашыгып, янә кабалана-кабалана сөйләп китте:— Алсуның Айсылу апасы бик оста бәйли белә икән. Алсуга каз бәбкәсе сыман бияләйләрне һәм йомшак шәлне Айсылу апасы бәйләгән... Беләсең килсә, әти, шул ерактагы туганнары Алсуларга да бирәр кәҗә алып җибәрербез дип язганнар. Кәҗә аучыларын гына табу кыен икән. Ул аучылар тауларда, кәҗәләрдән болай, кача-поса йөри икән... Тотарга ярамый ди ул кәҗәләрне, закун бар, ди... Ә кәҗәләрне барыбер тоталар икән — анысына да үзенә күрә закун бар, ди...

— Кызык икән,— дип көрсенеп куйды ата.

Малайның кәефе яхшы иде, ул иркенләп сулыш алды. Бераз тын торгач яңадан әтисенә таба үрелде.

— Алсу әйтә, әти, сезнең авыл да матур икән, ди. Нурлы Алан дигән исеме генә ни тора, ди... Аны алырга, пар ат җигеп, бергә барырбыз, яме, әти... Авылларына кергәндә, дилбегәне миңа бирерсең...

Әти кеше улын бүлдермәде. Бәхәсләшмәде, каршы да төшмәде. Күзләре йомыла барган саен малайның хыял офыклары яктырганнан-яктыра барды. Тавышы акрынаеп тоныкланды һәм тәмам пышылдауга күчте. Такыр башын әтисенең култык астына яшергән Азат, татлы хыялларына чумып, изрәгән иде инде. Кымшанырга да уңайсызланып утырды әтисе. Түр бүлмә ишегендә әниләре күренде. Ата-ана бәхетле елмаешып, берберсенә күз кысты.

Малайны өй түрендәге йомшак урынга илтеп салдылар. Икәүләшеп аңа озак кына карап тордылар. Тәмле төшләр күрә иде күрәсең: Азат әледәнәле үзалдына елмаеп куя, тынгысызланып башын боргалап ала. Кыңгыраулы пар атларга утырып, урман аръягындагы Югары Сөн авылына, мамык шәлгә төренгән нәни кыз Алсуны алырга бара иде булса кирәк ул төшендә. Атлар пошкыруы яисә кыңгырау тавышлары уятмаса ярар иде үзен.

## 2

— Хуҗа абзыйның яшь килене суга төшеп бара,— дигән пышылдау уятты Азатны.

— Алай бик күрәсең килсә, урамга чыгып карарга иде, әнә, баланы уяттың,— дип җавап кайтарды әнисе. Әмма үзе дә камыр җәйгән җирдән, укләвын куярга да онытып, ире белән янәшә урам як тәрәзәгә барып капланды.

Азатның да суга төшеп барган Айсылу апасын күрәсе килә иде, ләкин кузгалмады. Юрган астында бик тә рәхәт, җылы иде шул. Тәмле йокыны качырасы килмәде. Баштан ук түренде дә стенага таба борылып күзләрен йомды. Ләкин йокы качкан булып чыкты. Малай сак кына сулыш алып өйдәге һәр аваз, һәр хәрәкәтне тыңлап ята башлады: кече яктагы мичкә якканнар икән, чарт-чорт иткән авазлар чыгарып коры утын янганы, ялкын дөрләгәне ишетелә. Әнисе дучмак пешерергә җыена ахрысы, камыр җәюеннән туктап, куна тактасыннан он сыпырып төшерде. Ә хәзер, әнә, тукмак белән бәрәңге изә башлады. Күпме генә шыпырт булырга тырышмасын, чуендагы кайнар бәрәңгенең тукмак тигән саен пош-пош иткән авазы әллә каян ишетелеп тора. Аннан соң йомырка сытып, шуны тугыларга керешге. Ул арада, кырынудан туктап күрәмсең, әтисе киенә башлаган иде.

— Кая барасың, чәй дә эчмәгән көенчә,— дип тынгысызланды әнисе.

— Кар яуган ич, син җитешкәнче капка алларын көрәп керим, дим.

— Җитешер идең әле.

— Баш та авыртып тора, мин озакка түгел.

— Авыртмый ни...

Ишекнең шыгырдап ачылганы, аннары шап итеп ябылганы ишетелде. Бераздан капка келәсе шалтырады. Әнисе кисәү агачы белән мич тарта башлады.

Беразга тынлык урнашып торды. Аны тоньк кына булып урам яктан әтисенең кемгәдер дәшкән тавышы бүлдерде:

— Саумы, күрше... Су юлын өйрәнәсеңме?

Күрше дигәне кем булгандыр, җавап сүзләрен ишетмәде Азат. Шунда, кече як ишеге ачылып, сак кына атлап аннан әнисе керде, урам як тәрәзәгә үтте.

Тәрәзә янында байтак кына басып торды әнисе. Дәшми-нитми торды, ә үзе ни сәбәпледер тынычсызланды. Кече якка әйләнеп чыккач кына үзалдына сөйләнгәне ишетелде:

— ...Бу ирләрне... Кая ашыга икән дигән идем... Инде утыз биш яшькә җиткән югыйсә, һаман акыл керми... Каршысына чыгып басмаса канә...

Әтисе кар көрәргә керешкән иде инде. Урамда кемдер чаналы атта юыртып узды.

— И алла, нигә йөзе килми соң моның,— дип зарланып алды әнисе.

Азатка рәхәт. Үзе җылы юрган астында, шул ук вакытта барын да белешеп, ишетеп ята. Алгы яктан әнисенең ягымлы тавышы ишетелгәч кенә күзләрен ачты малай, юкса, изрәп китә язган.

— Азат, улым, тор...

Юрган астындагы рәхәтлекне суза төшеп, тагы бераз киерелеп ятарга иде әле. Әнисе генә тынгылык бирмәс. Әнә, иркәләп, яратып кына уята торган иң ягымлы сүзләре ишетелә:

— Тор-тордан хәбәр килгән, тор, улым, тор, тор...

— Ярар, хәзер торам. Тагы әз генә ятыйм да...

— Ул нинди яту инде, үзең үсеп җиткәнсең. Әллә иптәш малайларың тауга таба төшеп тә бара инде...

— Кемнәр, Миңлегаязлармы?— дип идәнгә сикерде һәм урам як тәрәзәгә үрелде Азат. Урамда дус-ишләрен күрмәгәч, тынычланып, киерелә-киерелә кечә якка чыкты.

— Миңлегаяз бу вакытта торамыни...

— Капкалары шыгырдаганые, улым, шуңа әйтүем.

Әнисе һаман мич янында кайнаша. Өйгә дучмак исе таралган. Авыз суларын китереп тора. Җылы һәм рәхәт. Азат әнисе янына ук килде. Үз эше белән әвәрә килгән ана улының иркәләнәсе килеп йөрүен аңламады.

— Миңлегаяз йоклыйдыр әле... Яшь киленнәре суга төшеп бара, ә син тор дисең,— дип сөйләнде малай, кайнар дучмак исен киерелеп сулый-сулый.

Улының сүзләренә ана капылт кына борылып алды.

— Әле тагы яшь килен суга төшеп киттемени?..

— Безнең турдан үтеп барае, мамык шәлләрен уйнатып.

— Уйнатадыр, уйнатадыр... Атаңны да күрдеңме соң?

— Күренде. Кар көри.

— Көриме?

— Аргандыр, ял итә. Көрәккә таянып басып торадырые.

— Бер-бер кеше булмагандыр бит?..

— Әйттем бит инде, мамык шәлләрен уйнатып...

Әнисе, орышкандай, аны ашыктыра башлады:

— Бар инде, бар, торма. Бишмәтеңне ки дә тиз генә чыгып кер. Бер очтан атаңны да чакыр. Чәй өлгерде диген, тизрәк керсен. Әни әйтте диген...

Бер аягы ишегалдында, икенчесе өйдә булды Азатның. Кочагы белән суык ияртеп кереп тә җитте.

— Әә-әх, әни, суык. Кар шыгырдап тора. Чана шәп шуачак бүген.

— Атаң керәме дим?.. Бар тиз генә юын, хәзер чәй ясыйм.

— Әйттем.

— Сабынлап ю, җәлләмә сабынны... Әйттеңме димим бит, керәме, дим?

— Ярар, диде.

— Бит очыңны гына чылаттың бит, колак артларыңнан ук ю... Чәй өлгерде дип әйттеңме соң?

— Әйттем инде. Хәзер керә.

Ул арада, алъяпкычтан көе генә болдырга чыгып, әнисе үзе дә чакыру хәбәре салып керде.

Җылы пар бөркеп, өстәлгә ак самавыр менеп утырды, олы бадьянга өелгән дучмак куелды. Азатның күңел күтәренке иде. Әтисе дә шаяртып кына торды үзе белән. Әле дәү салкын бармаклары белән аның куенына

үрелеп кытыклаган булды, әле өстәл астыннан җиңел генә чеметеп күз кысты. Аннары, житдиләнә төшеп, хатынына дәште:

— Яшь киленнең шәлен күрдеңме?

— Шәленә ни булган...

— Матурлыгын әйтәм. Узып киткәндә урамнарны балкыта шәле.

— Аның яшендә безнеке дә балкыгандыр...

## 3

Сезнең якларда ничектер — безнең Нурлы Аланга килен төшсә, аны каенана гына түгел, бөтен авыл сыный. Килен булып төшкән кызның һәр адымы, һәр хәрәкәте һәм үз-үзен тотышы аерым бер игътибар үзәгендә торып, атна-ун көн дигәндә аңарга хөкем чыгарып та куела. Кеше кадәр кешене, алай гына да түгел, яшь-җилкенчәк хатын-кызны күреп-тану һәм нәтиҗә ясау өчен бу аз вакыт, билгеле. Әмма, нурлы аланлылар бу эшне озакка сузмый. Хөкем, кагыйдә буларак, дөрескә чыга.

Хуҗа абзый белән Әминә апага килен булып төшкән Айсылуның эшен бер атнага да сузып тормадылар, нәтиҗә икенче көнне үк ясалган иде инде.

— Баскан җиреннән ут чыгара, Хуҗаның Миңлегалие иреште бәхеткә,— диделәр, кибеткә кагылып чыккан күршеләре.

— Югары Сөн кызы ич, алар токкан җиреннән умыра торган...

Дөрес, яшь киленнең сылулыгы, килеш-килбәте хакында хатын-кыз артык сүз кузгатып тормады, бу кадәресен һәркайсы үзе генә хәтер сандыгына салып куйды. Тик менә бер вакыйга көне-сәгате белән авылны урап узды. Бусы хакында хатын-кыз аеруча тәмләп сөйләде.

Бу болай булган. Кодаларны озатканның икенче таңында ук яшь килен бәкегә суга төшкән. Су буеннан атка атланып Курай Назыйм үтеп бара икән. Нурлы Аланда егетләрнең үтә чыккан мут һәм кыланчыкларын шулай «курай» дип йөртәләр. Назыйм, билгеле, кызны танымаган, Миңлегалинең яшь бичәсе шулдыр дип башына да китермәгән. Ә инде кызның сылулыгын күрми үтә алмаган Курай Назыйм, хәйран калган. Читләп кенә уза торганнардан түгел инде Назыйм андый чакта. Айсылуны кунак кызга санап, бәке янына юыртып килеп тә җиткән.

— Күз тияр дип курыкмыйсыңмы, апасы?— дип сүз каткан килә-килешкә.

Борылып күз дә салмаган Айсылу. Үтеп-сүтеп йөрүчеләр беткәнмени! Яшь килен чиләкләренә бер-бер артлы чумырып су алган да, көянтәсенә элеп, кузгалырга иткән. Егет атны сукмакка аркылы куеп, аны җибәрми тора икән. Ә көрт тирән.

— Каян килгән карлыгач буласыз, апасы? Кунак кызы дип беликме, ә, апасы?..

— Юлдан китегез,— дип, бер читтән узмакчы булган Айсылу. Әмма ат тагы аның каршысына төшкән.

— Назыйм булырмын мин, апасы! Сез кем атлы? Әллә телен йоткан инде...

— Телең озын икән, аягыңны ялтырат диләр ич. Ал атыңны!— дип тавышын күтәрә төшкән Айсылу.

— Теле дә бар түгелме карлыгачның... И-и-и, апасы!..

Айсылу әйтер сүз таба алмаган. Ә егет дигәнебез тәмам сайрарга ук тотынган:

— Җә инде, җә, апасы, тартынма, үзең дә шәлеңә охшап йомшакмы,— дип сөйләнә-сөйләнә ат сыртында кое генә кызның иңбашына ук үрелә башлаган.— Кичкә чыгарсың бит, ә, апасы...

Ике уйлап-нитеп тормаган яшь килен, егетне изүеннән эләктергән дә тартып ук төшергән. Кар өстенә дә түгел, туп-туры бәкегә башы белән

чумган Курай Назыйм. Ә Айсылу үз юлында булган. Назыйм исә аның кем булуын, кая китеп югалуын да аңышмый калган. Бәлки бу хакта кеше-кара белмәгән дә булыр иде, әлеге дә баягы шул курайлык инде... Өйләдән соң каравыл өе тирәсендә бер төркем ирләр җыелып торган җиргә килгән Назыйм, түзеп гора алмаган, шапырынырга тотынган. Имеш, иртән су буенда шундый-шундый чибәр бер кунак кызын очраткан. Кичен клубта очрашырга сүз дә куешканнар имеш... «Син идеңмени әле ул»,— дип, тыңлап торучылар арасында булган Хуҗа абзый бу эшкә нокта куйган — Курай Назыймның колак төбенә менеп төшкән.

Бу хакта аеруча яратып сөйләгәне хатын-кызлар иде. «Теләсә кемгә нәфесен сузып йөрмәс, шул кирәк Курайга»,— дип кат-кат кабатлады алар. Кайберләре, стратегик максатлардан чыгып булса кирәк, ирләренә бу хакта сөйләгәндә «шул кирәк сезгә» дип тә өстәп җибәргәләгән, имеш. Озын сүзнең кыскасы шул: урман аръягындагы Югары Сөннән килгән киленне беренче көннәрдән үк үз итте нурлы аланлылар.

Азат та үзсүзле малай булып чыкты. «Алсуны алырга кайчан барабыз?»— дип, һаман әтисен йөдәтте. Әти кеше, юк сәбәпне бар итеп, малай зарыгып көткән ул көнне чигерә килде. «Бу арада себереп тә тора, буран чыкмагае»,— диде. «Урманга карны тирән салган, бераз юл төшсен инде»,— диде.

Малай көтә бирде. Бердәнбер юанычы — яңа көн туган саен Айсылу апасын күрү иде. Миңлегаяз янына кергән саен, аның: «Кем дип торам, кияү кергән икән бит. Үзебезнең кияү!»— дип, үз итеп каршылавы бигрәк тә ошый иде Азатка. «Үзебезнең кияү бит ул, мә, Азат!»— дип, аңар Айсылу апасы әллә ничә тапкыр инде кушуч тутырып чикләвек тә бирде. Беркөн, Миңлегаяз югында, кулына күтәреп аркасыннан да сөйде әле ул аны. Күкрәкләренә кысып сөйде, яратып сөйде. Әллә ничек кенә, рәхәт тә, читен дә булып китте аңар шулчакны. Айсылу апасының елтырап торган күзләренә, чыклы үлән сыман балкыган иреннәренә карарга уңайсызланды ул. Оялудан, тизрәк төшәргә итенеп тартынган булды. Ә үзенә, югыйсә, Айсылу апасының йомшак җылылыгын тою бик тә рәхәт иде. Булмаска, Алсуның бертуган апасы ич ул.

Ниһаять, зарыгып көткән көн килеп җитте. Ул кичне әтисе күршеләрдән күтәренке күңел белән чыкты.

— Иртәгә иртүк юлга. Хуҗа абзыйның үзе белән барырга булдык,— диде ул ишектән килеп керешкә.

— Үзе баргач, юлыгыз уңар, шәт... Әйбәт булган,— диде әнисе.— Бирсәләр генә ярар иде инде.

Боларны күреп, ишетеп торган Азат кулларын чәбәкләп мәтәлчек кенә атмады. Бер урында утыра һәм басып тора алмады ул. Әле түр яктагы сиртмәле караватка менеп сикерде, әле күзгә каршына килеп чәчләрен сыпыргалады, бер сәбәпсез борынын тарткалады. Хуҗа абзый белән баргач, алып кайтмыйлармы соң... Алып кайталар болай булгач.

## 4

Берне кунып, икенче көнне төштән соң гына кайтып төште әтиләре. Аларны Азат авыл башына ук чыгып көтеп алды. Иптәшкә Миңлегаяз да бар иде. Юыртып килгән ат алар янына килеп җиткәч атлауга күчте. Азатның күзе чана түренә текәлгән. Тик анда мамык шәлгә төренеп Алсу утырырга тиешле чана башында, толыпка чумган Хуҗа абзый иде. Улының сораулы карашына җавап рәвешендә, әтисе коры гына әйтеп куйды:

— Өйдә булмады, чана шуарга чыгып киткән...

Әтисенең кәефе чынлап та кырылганга ошый, башка берни дәшмичә, дилбегә очы белән атка кизәнеп, юыртып китеп тә бардылар.

Әтиләренә каршы йөгергәндә Миңлегаязны әллә кайда калдырып килгән Азатның аяклары атламас булып торды. Кулына йомарлап килгән кар кисәген бар көченә кизәнеп аяк астындагы каты карга атып бәрде. Ул вак-вак кисәкләргә бүленеп, таралып юкка чыкты.

— Борчылма, Азат! Яз җиткәч, абый белән җиңгәчәйгә ияреп үзебез барабыз аны,— дип тынычландырды Миңлегаяз.

— Әле язга тикле-е...

— Һи-и-и, малай,— дип, кулын шапылдатып дустының җилкәсенә салды Миңлегаяз,— тиз җитә ул. Менә, январьдан соң, февраль генә кала, аннан апрель выжт кына итә, марты сизелми дә узып китә аның. Май җиткәч, җир кипкәч, без аны үзебез генә дә табабыз Югары Сөнне.

Күп калмаган икән калуын. Миңлегаяз белә инде аны, ни дисәң дә ул мәктәптә укый бит инде...

Чана шуган җирдән, эңгер-меңгер җитеп, күктә бер-бер артлы йолдызлар кабына башлагач кына кайтырга чыктылар алар. Итек табаны һәм бияләйләр карлы бозга каткан, бишмәт чабулары гәрбил такта булган, авыз-борын күгәрчен тәпиедәй күшеккән, куллары ут булып кызышкан иде. Хуҗа абзыйларның капка төбендә Миңлегаязның энесе — каеры тун һәм бүре бүрек өстеннән җылы шәл белән уранган төпчекләре Вакыйф көтеп тора иде.

— Адат, Адат,— дип йөгереп килде ул аларның каршына,— беднең әтиләрнең кәҗә бәкәйләре качкан.

— Нинди кәҗә, нәрсә телеңә салынасың,— дип коры гына кистереп куйды Миңлегаяз. Иреннәре күшеккән булуга да карамастан, Вакыйф алдында үзенең абый кеше булуын белгертеп, бер тәкәбберлек белән әйтергә тырыша иде ул һәр сүзен.

— Югары Сөн кодаларга, теге, әллә нәрсәкәй җирдән кайткан кәҗә бәкәе алырга барганнарые, Адатның атасы белән,— диде Вакыйф шуны да белмисезмени дигәндәй. Һәм авыз-борынына уралган шәлен читкә тартып, йөзен ача төште.

— Нигә кәҗә алырга барсын алар. Монда чыгып телеңә салынып торасың,— дип, ачуланып дәште абыйсы.

— Кәҗә инде, кәҗә. Ата кәҗә баласы!— Автоматтан аткан төсле, шундук ачыклык кертергә ашыкты Вакыйф.

Миңлегаязның талканы корылана гына барды. Үзе өчен түгел, Алсуны алып кайтуларын күпме көткән дустының хәлен белә иде ич ул. Әле алга, әле артларына төшеп сөйләнгән энесенә дәү олтанлы итеге белән кизәнгән булыр идемени.

— Бирермен мин сиңа ата кәҗә баласын.

Вакыйф аңа типтермәде, бөтерчек сыман читкә тайпылды һәм йөгереп китте. Барыбер үзенекен итте — тыңларга теләүче булмаса да, дөреслекне ачып салды.

— Кәҗә булгач, кәҗә! Ата кәҗә баласы. Урман буена кайтып җиткәч, чаналарыннан төшеп качкан. Куып караганнар, тоттырмаган. Кар тирән ди...

Миңлегаяз, чанасын калдырып, аны куып китте. Куышудан кызык тапкан Вакыйф, шырык-шырык көлеп, юл читендәге көрткә сикерде һәм җиң очлары белән йөзен каплады. Абыйсы үзен кар белән күмәр дип чамалавы иде бу. Миңлегаяз күмеп азапланмады, энекәшенең муенына бер-ике уч кар алып сипте дә юлында булды. Вакыйфның гына әле һаман уеннан туктыйсы килми иде. Абыйсы артыннан ук аякларына басып, ул яңадан үзенекен кабатларга тотынды: «Ата кәҗә баласы... Ата кәҗә баласы...» Үз сүзеннән үзе кызык табып көлә иде инде ул, муенына тулган карда аның уе да юк.

Тагын ике көннән Югары Сөн кода үзе килеп җитте. Чана башындагы

толып астында кемдер кыймылдаганны күргәч, капка төбендә трай тибеп йөргән Миңлегаяз белән Азат сагаеп калдылар. Ул да түгел, толып астыннан әкрен генә «ми-и-и» дигән тавыш ишетелде. Югары Сөн кода чанадан төште һәм толыпка үрелде. Аның астында, керт-керт солы саламы чәйнәп, нәни генә бер җан иясе — кәҗә бәтие утыра иде. Аяклары киндерә белән ике як үрәчәгә бәйләнгән булуга да карамастан, чана янына ук килеп баскан Миңлегаяз белән Азатка ул бик кәефле булып күренде. Алмаш-тилмәш ул аларның күзләренә текәлеп торды. Исем бер дә китми, дип әйтүе булдымы, үзе һаман, сагыз чәйнәгәндәй, авыз эчендә салам уртлап тора.

Кәҗә бәтиенең маңгаеннан күренер-күренмәс кенә булып нәни мөгезләр төртеп тора. Ә мамыгы, әйтеп аңлатырлык кына түгел, аяз көндәге зәңгәр күк төсендә. Хәтфә кебек кабарып, күпереп тора, Алсуның шәле һәм нәни бияләйләре кебек. Кәҗә бәтие Азатка шундук ошады.

— Аякларын* чишегез, ул сезгә,— диде Югары Сөн кода, атның аркалыгын төшереп торган җирдән.— Ләкин качыра күрмәгез, карагыз аны. Алсуның бүләге — икегезгә дә уртак булсын!

— Кемгә?— дип сорап куйды Азат, үзен дә белешмәстән. Ул бит Миңлегаязларга гына кода. Миңлегаяз белән Вакыйфка диюедер...

Гел уйламаганда кода кеше, астарлы бияләйләрен салып, Азат янына килде.

— Алсуны алып кала язган егет син бит әле,— дип, ул аның муеныннан сыйпап куйды һәм шаяртып уң кулының чәнчә бармагы белән аның борын очына басты.

Үзен олыга санап әйтелгән бу сүзләр Азатка ошап куйды. Тик җавапка гына сүз таба алмады ул, елмаеп башын түбән иде.

— Шул, шул, кода,— дип, җәтрәк раслап куйды Миңлегаяз.— Азат шул була инде.

Миңлегаяз белән Югары Сөн кода бер-беренә карашып елмаеп куйдылар. Азат, аларга күтәрелеп карарга кыймаса да, бу җылы елмаюны әллә каян сизеп, бөтен күңеле белән тоеп торды.

— Кемгә булсын, Миңлегаяз белән сиңа,— диде Югары Сөн кода кабатлап.— Алсу бүләге! Качырасы булмагыз. Мондый кәҗә бәтиен җиде кат җир астына төшеп эзләсәгез дә таба алмассыз бүтән...

Шатлыктанмы, әллә нидән генә Азатның күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. Хуҗа абзыйларның сарай түбәсеннән карап көлгән кояшка таба борылды ул. Күзләре чагылды. Өй кыегыннан борынлап чыккан боз сөңгеләренә карады, аларда да күзне чагылдырган нурлар балкыды. Ишегалдындагы һәр кар бөртеге елык-елык итеп аның белән уйный, шаяра төсле иде.

Кода кеше шап-шоп басып аякларындагы карны кага-кага, өйгә кереп китте. Миңлегаяз белән Азат, бу көтелмәгән яңалыктан нишләргә белмичә, үзара карашып бер тын тик басып тордылар.

Чана башында утырган кәҗә бәтиенә беренче булып Азат якын килде. Бер кулындагы бияләйне салып, сак кына, бармак очлары белән генә, аның муеныннан сыпырмакчы булып үрелде. Кәҗә бәтиенә исә бу ошамады — дертләп китеп, кисәк кенә муенын читкә борды һәм бөтен гәүдәсе белән кагынып куйды. «Тиясе булмагыз, кулыгыз юылганмы?»— дип кисәткәндәй, усал итеп, маңгай аша сөзеп карады ул Азатка.

— Юк инде, малай, син безнеке хәзер,— дип янап куйды аңар, моңарчы читтәрәк торган Миңлегаяз. Һәм кәҗә бәтиенең янына ук килеп сөйләшә-таныша да башлады.— Әнә, ул Азат абыең булыр. Мин Миңлегаяз кодаң. Киртеп куй колагыңа: Гаяз түгел, Миңлегаяз!! Менә, миңем дә бар...

Кәҗә нәкъ шул чакны, ишеттем, аңладым дигәндәй, әкрен генә «ми-и-и» дип тавыш биреп алды. Малайларга бу кызык булып тоелды, үзара карашып, рәхәтләнеп бер көлешеп алдылар.

— Әллә башлы кәҗә инде, малай. Син әйткәннәрне гел аңлап торды бугай ул,— дип җанланып китте, үзенең куанычы белән уртаклашырга ашыкты

Азат.— Билләһи дим, күзенә карап тордым. Эх тә итми тыңлады син сөйләгәнне.

— Башлы булмый... Ул бит сиңа тегенди-мондый гына түгел, әллә каян, биек таулар ягыннан кайткан кәҗә. Пләмәнни, бик beләсең килсә!

Шулай ерактан килдеңмени, дип, гаҗәпләнеп, шаккатып күзәтте аны Азат.

— Вәт, малай,.. Вәт, малай,— дип, үзенең соклануын яшерә алмыйча сузып куйды ул.— Кәҗә дисәң дә кәҗә ичмасам. Бу инде сиңа безнең авылдагы бакча караклары, ристаннар гына түгел, иеме, Миңлегаяз?

Икесе чананың ике ягына чыгып күзәттеләр алар кәҗә бәтиен. Бер тын сүзсез тордылар.

— Моңа күпме булыр икән?— дип кызыксынып куйды Азат.

— Нәрсә күпме?

— Ничә яшь дим...

— Һе, ничә ай диген, әле бер яшь тә тулмаган аңа.

— Исеме бармы икән?

— Кәҗәнең исеме була димени... Үзеннән сора,— дип кырт кисеп куйды Миңлегаяз.

Аның кырыслыгы ошамады Азатка. Ул сүзсез генә һаман чана тирәсендә бөтерелде. Кәҗә бәтиен әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан чыгып күзәтте.

Бер тын ни эшләргә белми аптырап торган Миңлегаяз, Азатны үртәргә булып, үзенчә кызык тапты. Кинәт кенә чанага сузылып ятты да, кәҗә бәтиенә текәлеп, бар көченә дип әйтерлек кычкырып сөйләшә башлады:

— Кәҗә, кәҗә... Исемең синең ничек?— Үзе сорау бирә, үзе үпкәләмиме дигәндәй, борылып-борылып Азатка күз ташлап ала. Үпкәләргә уйламады да Азат. Аңа ни, кызык кына ич. Миңлегаяз исә тагы да җанланыбрак теленә салына башлады.— Ник әйтмисең, әйт инде, кәҗә! Әнә бит, Азат абыең сорый. Әй, юк, Азат абыең түгел, Азат җизнәң!

Гаҗәпсенеп карап торган кәҗә бәтие шунда аваз салмасынмы:

— Ми-и-әй... Ми-и-әй...

— Исемен әйтте, исемен,— дип, шатлыгыннан кычкырып ук җибәрде Миңлегаяз. Ул тантана итә иде. Чанадагы печән өстендә бер кат тәгәрәп әйләнде дә янә кәҗә бәтиенә текәлде.

— Ничек дидең, ничек? Исемеңне тагы кабатла әле?..

Кәҗә бәтие башын күтәреп өй ягына карап алды да тагы кабатлады:

— Ми-и-ә-әй... Ми-и-ә-әй.

Миңлегаяз чанадан сикереп үк торды. Азат белән бер-берсенә төртешә-төртешә сикергәли башлады алар. Куанычларына чик-чама юк иде.

— Исемен белә, исеме бар!

— Башлы кәҗә дип әйттем бит...

— Вәт, малай, исемен әйтә бит. «Ми-әй», ди.

— Кабатлап та әйтте, «Ми-әй» түгел, «Микәй» диде бугай.

Миңлегаяз шатлыгыннан бер-ике мәртәбә бүреген күккә чөеп алды һәм ишегалды тирәли сикергәли башлады. Йөгереп кенә өйгә дә хәбәр салып чыкты.

— Кәҗәнең исеме бар, үзе әйтте. «Микәй» диде. Микәй...

Миңлегаяз белән Азатның шатлыгын уртаклашырга аннан-моннан гына киенгән бәләкәй Вакыйф килеп чыкты. Авыз тутырып нидер чәйни иде үзе. Абыйлары янына килгәч, кесәсеннән берәр уч бавырсак чыгарып, Миңлегаяз белән Азатны да сыйлады.

— Югары Сөн кодагый җибәргән,— диде ул, авыз тутырып чәйнәвеннән туктамыйча,— Сезгә — кәҗә, миңа — төш.

Вакыйфның үзенчә мактануы иде бу. Миңлегаяз белән Азатның гаме аңардамыни... Миңлегаяз кинәт кабаланып куйды һәм чанага таба ашыкты.

— Кода кереп киткәнгә биш былтыр, без әле һаман Микәебезне чишмәгән, әйдә, Азат, торма,— дип, кәҗә бәтиенең аягы бәйләнгән бауга барып тотынды ул.

— Нигә Микәй булсын, тукта,— дип алар артыннан ук җылы оекбаш өстеннән кигән олы галушларын шаптор-шоптыр сөйрәп Вакыйф йөгереп килде.

— Микәй булгач. Микәй инде. Үзе әйтте!

Вакыйфка әйттең ни, әйтмәдең ни, авызына тагы бер бавырсак ыргытты да үҗәтләнүендә булды.

— Ниткән Микәй. Кәҗәнең исеме булмый анын, ул шулай кычкыра гына, беләсегез килсә.

— Телеңә салынып торсаң...— дип, аңар абыйсы йомарланган бияләен күрсәтеп алды.

— Чишмәгез, тагы кача. Кәҗә ич, ристан ич ул,— диде Вакыйф.

Миңлегаяз аңар кулын гына селтәде.

— Синнән сорамыйлар. Әнә, лапас артына барып кил дә, артың катканчы кереп йөгер өйгә.

— Адатның атасы белән безнең этидән качкан кәҗә ул, бик беләсегез килсә...

Вакыйфның әйтеп бетерүе кая, кәҗә бәтие Миңлегаязның култык астыннан сикереп тә чыкты.

— Капканы ябыгыз, бикләп куегыз,— дип боерык бирде Вакыйф.

Азат, шап итеп, капканы бастырык белән бикләп тә куйды.

— Нигә аңа бастырык тыгарга, кулы юк бит кәҗәнең,— дип, Вакыйф тагы үзенчә шелтә ясап куйды.

Бәйдән ычкынган кәҗә бәтие ишегалдының бер почмагыннан икенчесенә ук кебек атылып чабулап йөрүен дәвам итте. Өчәүләшеп үзен тотарга дип йөгергән малайларны бар дип тә белмәде, араларыннан выжт кына үтә дә кире якка торып чаба иде. Бер почмакка кысрыклап, инде тоттылар дигәндә генә, ул тагын Миңлегаязның бот арасыннан чыгып шылырга өлгерде. Артыннан чаба торгач, малайлар хәлдән тайды, карга чумып беттеләр. Сулуларына капты. Итек эчләренә кар тулды, бияләйләрен югалттылар. Вакыйфның бер галушы төшеп калган булып чыкты, койма читендәге көрттән шуны эзләп маташа иде.

Малайларның тынып калуын күреп Микәй дә тукталды. Ишегалдының урта бер җирендә җиңүче сыман тик басып тора. Як-ягына карангалап байтак кына шулай торды да, кинәттән ук кебек атылып, сөяп куйган сөзәк колгалар өстеннән лапас түбәсенә менеп китте. Нәрсә, нәрсә, әмма мондый елгырлыкны аңардан берәү дә көтмәгән иде!

Түбәдәге кар өстеннән эз салып, ул кыек очына ук менеп басты һәм шунда гына тынычлык тапкандай туктап калды. Муенын сузып турайта төште. Кар тузаннарыннан кагынып куйды. Киерелеп, як-ягына карап алды. Ә аста, ишегалдының өч почмагында, карда аунап, әлсерәп беткән өч малай басып тора. Микәйнең аларга исе дә китмәде. Кыек читендә үк басып торуын белде. Әле бакча якка, әле ишегалдына таба карангалап алгач, кукрәген тагы да киерә, муенын турайта төшеп хәрәкәтсез кала. Өй кыегына кадаклап куйган этәч диярсең.

— Урман ягын күзәтә. Югары Сөнгә таба карый ул,— дип пышылдады Вакыйф.

— Югары Сөндә нәрсәсен югалткан, кодаларга ерак таулар ягыннан җибәргәннәр ич аны... Шул таулар күренмиме, дидер.

## 5

Кәҗә бәтиен лапас түбәсеннән төшерү бер олы вакыйгага әйләнде. Өйдәгеләр чыкты. Азат белән Миңлегаяз урамда йөргән малайларны ча-

кырып кертте. Ишегалдында бер дистә чамасы кеше җыелгач, план кору башланды. Малайларның барысын да бакча якка чыгардылар, алар шунда бер рәт булып тезелеп, кәҗәне бакча якка качырмаска тиеш булдылар. Әминә апа тавыкларга дип изгән бер табак кайнар бәрәңге күтәреп чыкты. Ләкин «бәрәч-бәрәч...» дип тә, «кәҗ-кәҗ-кәҗ» дип тә күпме генә дәшеп карамасын, Микәй башын бормады. Хуҗа абзый өр-яңа бәрән себеркесе тотып түбә читенә үк басып чакырып торды. Аның сүзләрен дә колагына алмады кәҗә. Югары Сөн коданың ачуы чыгып, түзәр әмәле калмады — ишегалдыннан бер кисәк каты кар табып, шуны кәҗә бәтиенә тондырды. Кар кисәге «лык» итеп Микәйнең арт санына барып тиде, ләкин ул кыймылдап та карамады. Алай да булмагач, Хуҗа абзый ишегалды себерә торган озын саплы себерке белән түбәгә үрелде. Буе җитмәгәч, ачуыннан, аны болгап торып ыргытып та җибәрде. Себерке, кәҗәгә җитәр-җитмәс, сабы белән түбә өстендәге карга барып кадалды.

— Баскыч бармы, кая, баскыч китерегез,— диде Югары Сөн коданыклы фикергә килеп.

Хуҗа абзый лапас эченнән сәндерәгә менә торган баскычны күтәреп чыкты. Миңлегаязны дәшеп алдылар. Малайның авыз колакка җитте, шундый җаваплы эшне сиңа ышанып тапшырсыннар әле...

Түбәдә кар тирән иде. Миңлегаяз, бата-чума булса да, тиз менеп җитте. Аннары, кыек буйлатып, лапас түбәсендәге кәҗә бәтиенә таба якынлаша башлады.

— Авызыңны ямшәйтер, типмәсен,— дип кычкырды бакча ягындагы малайлардан кемдер.

— Тибәргә, әллә син аны кырыкмыш тай дип белдеңме,— дип җавап кайтарды шундук икенчесе.

— Улым, тотыныбрак бар, егыла күрмә,— дип борчылды әнисе.

— Егылса, карга төшә ич ул, нәрсә булсын,— дип Хуҗа абзый да тавыш биреп алды.

Күпме кешенең күзе Миңлегаязга текәлгән. Шуны тою ничек рәхәт икәнлеген беләләр микән? Ул тагы да кыюлана төшеп, алга омтылды. Кәҗә бәтиенең янына ук барып җитте инде. Астагылар, ни булыр икән дигәндәй, кинәт берьюлы тынып калдылар. Микәйнең үзенә таба борылып та карамыйча басып торуы, аңардан аз гына да шүрләмәве сәер тоелды Миңлегаязга. Әллә бер-бер юньсезлек кылырга җыенамы...

Ул да түгел, бакча ягыннан малайларның берсен-берсе уздырырга тырышып биргән киңәшләре яңгырый башлады:

— Арт саныннан эләктер...
— Нәрсә җебеп торасың...
— Тот инде, тот!

Җаваплылыкны тою рәхәтлегеннән башы әйләндеме, кыймылдамый да тик басып торган кәҗә сихерләдеме, Миңлегаяз нинди карарга килергә белмичә, аякларын як-якка җәеп кар өстенә утырды. Шунда гына Микәй артына борылып, тыныч кына аңар карап куйды. Ләкин куркып түгел, ни эшләп йөрисең монда дигән төсле генә карау иде бу.

— Кочаклап ал, улым,— дип, яратып һәм ышаныч белән дәште Хуҗа абзый. Аның тавышы Миңлегаязга тәвәккәллек өстәде, айнытып җибәрде.

Бер карарга килеп, кулларын сузды да кинәт кенә бөтен гәүдәсе белән алга таба ыргылды Миңлегаяз һәм... әле генә кәҗә бәтие басып торган кар өстенә барып капланды. Ә Микәй күз иярмәс тизлек белән, арт аякларында гына калып үрә басты да, түбәнгә томырылырга өлгерде.

Бакча якта, түземсезлек белән батырлык кылыр минутны көтеп торган малайлар, «урра» кычкырып, бер-берсен төрткәләшеп кәҗәгә таба дәррәү йөгерделәр. Ләкин алар килеп җиткәнче, Микәй инде үз иреге белән көрттән чыгып ишегалдына төшкән иде. Ишегалдының урта бер җиренә чыгып басты да, нигә шаулаша бу малай-шалай дигән сыман,

бакча ягына карап куйды һәм, берни булмаган төсле, тыныч кына өстенә кунган кар тузанын кагарга кереште.

Миңлегаяз әле һаман лапас түбәсендә иде, ишегалдындагылар өчен инде хәзер ул әллә бар, әллә юк. Еларга да, көләргә дә белми бераз басып торгач, малай кәҗә тәкәсенә охшатып ике кулын югары күтәрде дә «урра» кычкырып көрт өстенә сикерде.

Кәҗә бәтие Миңлегаязларның утын лапасындагы җылы почмакта яши башлады. Инде урынлы-урынсызга качам дип куркытмаса да, ул барыбер кулга ияләшергә ашыкмады. Ишегалдына чыгаруга, дөньясын онытып чабулап йөри дә аннан, ни эшләргә белми, бераз тик басып тора. Һәм әллә кай арада гына бер карарга килеп, теге вакыттагы тәвәккәллеге белән, сөяп куелган колгаларга таянып, бер сикерүдә лапас түбәсенә менеп җитә. Иярәнгән урынына — кыекның нәкъ очына ук барып баса, күкрәкләрен киерә төшеп, башын турайта һәм күңеле булганчы урманга карап тора.

Аны инде хәзер һичкем борчымый, куаламый аннан. Урамнан узучылар күрсә, гаҗәпсенеп бер тын карап торалар да, башларын болгап, үз юлларыннан китеп баралар. Белсәң иде: кая карый, нәрсә көтә ул? Кемне эзли икән шулай?..

Каникуллар үтеп, Миңлегаяз мәктәпкә йөри башлагач, Азатка ямансу булып калды. Су буена тау шуарга да төшәсе килмәде. Анда төшсә, авылда Микәй кала. Берөзлексез кеше ишегалдында чуалу да уңайсыз. Төпчекләре Вакыйф күбрәк өйдә — куян мамыгыннан шәлдер, оек-бияләйдер бәйләп утырган әнисе янында бөтерелергә ярата.

Үз өйләрендә бер ялгызы көнозын ничек утырсын, менә тагын ул урамга чыгып бара. Ике кулы кесәдә. Юлда аунап яткан ат алмаларын үзалдына типкәли-типкәли атлый. Сызгырырга тырышып карады, барып чыкмады, төкерек кенә чәчелде. Ичмасам, шундый булдыксызлыгыннан көлүче дә юк бит. Үтеп барышлый гына, гадәтенчә, капка ярыгыннан Хуҗа абзыйларның ишегалларына күз салды. Барча кош-корт ишегалдында: сыердыр, сарыктыр, каздыр, үрдәктер, тавыктыр йөри. Аларның әле Микәйдән тыш тагы ике дәү кәҗәләре дә бар. Шуларның берсе лапас капкасына терәлеп аркасын кашып тора, икенчесе янәшәдә генә, сагыз чәйнәгәндәй, сакалын селкетә, Микәй бер ялгызы ишегалды уртасында басып тора.

Шунда капка ярыгыннан күзәтеп торган Азатны гаҗәпкә калдырган бер тамаша булып алды. Аркаларын кашып алгач, теге ике кәҗә, җәт-җәт атлап, яңа имидән аерылган сабый сыман басып торучы Микәй янына килделәр. Озын йоннары аннан-моннан тузган, асылынган дәү мөгезле, капкорсаклы бу кәҗәләр каршында Микәй әллә каян аерылып тора. Аны бу ишегалдына очраклы рәвештә генә төшеп кунган бер зифа кош диярсең. Бөтен гәүдәсе, күгәрчен канатыдай елык-елык килеп, әллә каян күзләрне камаштырып тора. Түгәрәкләнеп килгән җыйнак гәүдә, үзенә килешеп торган туры аяклар, төз һәм озын муен, текә маңгай — һәммәсе зифалык һәм гайрәт турында сөйли.

Теге ике кәҗә дә шул зифалыкка соклана иде булса кирәк. Ләкин һәр соклану хөрмәт һәм ихтирамга нигез булып тормый. Соклану көнләштерә, эчне пошырып та куя торган була вакыт-вакыт. Әлеге кәҗәләр дә килә-килешкә, борыннарын суза төшеп, гаеп эзләп тикшергәндәй, кәҗә бәтиен бер кат әйләнеп чыктылар. Микәйнең исә аларга исе китмәде, әйтерсең лә алар аның өчен бөтенләй юк иде, колагын да кыймылдатмый тик басып торуында булды. Дәү кәҗәләрнең берсенә шул ошамады бугай: Микәйнең каршына ук килеп туктады да мөгез очлары белән аның муен төбенә төртеп куйды. Кәҗә бәтие башын борды, әмма дүрт аягының берсен кымшатмады. Дәү кәҗә, аның тирәсендә тагы бер тапкыр әйләнеп чыккач, янә Микәйнең каршысына ук килеп басты. Арткы аякларын

җәебрәк куйды, сөзәргә җыенуын белдертеп, урак сыман кәкрәеп килгән мөгезләрен алга суздьг.

Микәй аның саен кымшанмады, моңарчы ничек торган булса, шул хәлендә тора бирде. Күзләрен йома төшеп, кояш нурларында җылынуын белде. Ул арада дәү кәҗә кинәт кенә бер адым артка чигенде һәм бөтен булган гайрәте һәм авырлыгы белән аңа китереп тә бәрде. Мондый явызлыкны бөтенләй көтмәгән бәти гармун күреге сыман кысылып куйды.

Боларны күзәтеп торган Азатның да тәне чымырдап алды. Әйтерсең, аның үзен дә әлеге явыз кәҗә баганага китереп терәгән иде. Шул мур кыргырыны, ишегалдына кереп, таяк белән ярырга иде хәзер. Ул да түгел, авызын ачып катып калды малай: теге мөртәт җан шак-шок басып янә сөзү нияте белән килеп маташканда кәҗә бәтие кинәт кенә үзгәрде дә китте. Күз иярмәс тизлек белән арт аякларына басты да, сорау билгесе сыман кәкерәеп алга ыргылды, теге ристанның муен төбенә китереп тә ямады! Мәтәлчек ата язып, янтаеп ук китте урак мөгезле дәү кәҗә дигәнебез һәм ипле генә кире борылды да, алдына-артына карамыйча, башын болгый-болгый лапас капкасыннан кереп югалды.

Үз күзләренә үзе ышанмыйча, ишегалдына атылып керде Азат. Хуҗа абзыйларның болдырыннан шул мәлдә кисәү агачы күтәргән бәләкәй Вакыйф килеп чыкты.Башына кияргә дә онытып чыккан Вакыйф дәү галошларын өстерәп йөгерергә башлады.

— Үтерәм, кайда ул карт ристан... Кайда? — дип кычкыра үзе бар көченә.

Кош-корт, мал-туар аңардан куркышып, як-якка сибелде.

— Кемне үтерәсең? Нәрсә өчен? — дип кисәү агачыннан читкә тайпылды Азат.

— Микәйне үтерә ич, теге карт ристан. Кая качкан... — дип бәргәләнде Вакыйф.

— Болгама әле шул тимереңне, башны умырасың ич, — дип тынычландырырга керешә аны Азат.

— Болгамаска... Мин бит тәрәзәдән күрдем, Микәйне үтерәе, — дип, берөзлексез як-ягына каранып, эзләнүеннән туктамады Вакыйф. Үзенә күрә генә түгел, төпчек малайның гайрәте чик-чамасыз иде. Әрнүдән, менә-менә күзләреннән мөлдерәп яшь тамчылары чыгарга тора.

— Һи-и, малай, син күрмәгән икән. Микәй аның үзен үтерә язды, бик беләсең килсә, — дип аның җиңеннән тартты Азат.

Ачык калган ишектә Әминә апа күренде.

— Вакыйф дим, Вакыйф, кер тизрәк. Җәй көне дип белдеңме әллә, шәп-шәрә көе нинди тилереп йөрү ул.

— Хәзер, Адат, киенеп кенә чыгыйм да, — дип, галошлары артыннан кисәү агачын өстерәп, Вакыйф кире өйләренә йөгерде.

## 6

Азат белән Вакыйф инде ничә тапкыр ачуланышып, ничә тапкыр дуслашырга өлгерде. Миңлегаяз әле һаман күренми. Абыйсы юклыктан файдаланып, Вакыйф Азатның теңкәсенә тиеп йөдәтте. Микәй белән маңгайны-маңгайга терәп шаярышкан, сөзешле уйнап торганда, менә тагын ул килеп кысылды. «Ат дагалаганда бака ботын кыстырмасыные», — дип, Миңлегаязча читкә генә этәрергә иде дә бит үзен. Булмый,үз ишегалларында икәнлекне Вакыйф яхшы белә. Ә Микәйнең исә аның белән уйныйсы килми, Вакыйф, әрсезләнеп, башын суздымы, шундук читкә тайпыла.

— Микәй сине бар дип тә белми... Күрдеңме, әнә, сиңа маңгай урынына койрык кына селкетә, — дип көлеп җибәрде Азат.

Вакыйфның җен ачулары чыга, шуннан берсен икенчесе узып үчекләшергә тотыналар.

— Ә син, аның каравы — Адат-кадак, бик беләсең килсә.

— Төпчек түгел инде... Хуҗа абзыйның төпчеге ич син. Төпчек! Төпчек!

— Ә син аңа каравы — фифырузы да үзең, төпчеге дә. Төпчеге дә, фифырузы да...

— Мыййайы байайай... Мыййайы байайай...— дип, тантана итеп такмаклый башлый шунда Азат. Үчекләшергә тотынса, Вакыйфны Миңлегаяз абыйсы да «мыййайы байайай» белән генә телсез калдыра. Шулай диденме, гарьлектән Вакыйфның теле тотлыга башлый, шундук үчекләшмәс була.

Гарьләнерсең дә... Күптән түгел мондый хәл булган: Әминә апа түр якларында кер үтүкли икән. Миңлегаяз дәрес әзерләп утыра. Унга кадәр санарга өйрәнеп килгән Вакыйф мич асты тулып уйнап йөргән куян балаларын санап карарга булган. Кышның кыш буена аларның мич астында куян балалары тәгәрәп үсә иде.

Кулына кисәү агачы алган да Вакыйф берәм-берәм куян балаларын мич астыннан өстерәп чыгара башлаган. Тоткан берсен әтисенең иске салам эшләпәсенә сала, ди. Вакыйф җидегә җиткән, сигезенчесен тоткан, ә эшләпәдә бер куян баласы да калмаган — тоткан берсе, аннан чыгып, кире мич астына кереп тая бара икән. Уйлаган, уйлаган да бер әмәлен тапкан бу: тоткан бер куян баласын мич асты капкачы булып хезмәт иткән калын такта астына кыстыра бара икән. Ә үзе шул такта өстенә сузылып ятып, мич астындагы куян балаларының күплегенә сокланып тик такмаклый икән: «мыййайы байайай! мыййайы байайай!..» Бу аның үзенчәләп «мондагы балалар» дип әйтүе булган. Такта астына куян балаларын тезеп чыккач, исәбенә үзе генә чыга алмыйча, абыйсын да чакырган Вакыйф.

— Абый, абый, мыййайы байайай!— ди икән.

Әнисе белән абыйсы йөгерешеп чыкса, нишләргә белмәгәннәр — такта астыннан бер тигез рәткә тезелгән куян балаларының башлары гына күренеп тора икән...

Шуннан тагылып калды аңа бу үчек. Аз гына теленә салына башладымы, малайлар Вакыйфны «мыййайы байайай» белән каплый да куя. Шулай диделәрме, аның күзләренә яшь килә. Куян балаларын әле дә булса кызгана һәм юксына иде ул.

— Әйдә, үчекләшмик, Адат. Бүтән алай әйтмә, җәме,— дип, бу юлы да Вакыйф тизрәк дуслашырга ашыкты.

— Ярар. Син дә «фифырузы да, төпчеге дә» димәс булсаң гына...

— Ярар, малай. Аның каравы, сине кыйнаучы юк. Миңлегаяз кебек абыең булса...

Борынын сызгыртып алды да, бер читтә бәрән себеркесеннән калдыкпостык яфракларны чүпләп торган Микәйне чакырырга кереште Азат.

— Бәрәч, бәрәч... Микәй, кил монда...

— «Бәрәч» дип сарыкка гына әйтәләр,— дип төзәтте аны Вакыйф.— Кәҗәне «кәҗ-кәҗ-кәҗ...» дип чакыралар.

Моңарчы кәҗә асрамагач, Азат каян белсен инде аны. Икәүләшеп, Вакыйф өйрәткәнчә, чакырырга керештеләр. Микәй, аңлаган сыман, борылып карады һәм тып-тып атлап яннарына килде.

Ничек килүен күрсәгез иде сез аның. Ул муен... Ул аяклар... Ул гәүдә... Үзе ашыкмый, ә үзе чабышка әзерләнгән ат сыман бии-бии килә.

— Безнең эти дә язга бер кәҗә алабыз, ди.— Бу сүзләрне Азат Микәйнең үз-үзен тотышына сихерләнеп әйтеп куйды. Вакыйф шундук аңарга каршы төште.

— Нәмәрсәгә соң ул. Микәй булмый бит инде ул...

— Микәйне кунакка алып чыгарбыз, аңарга күңелсез булмас, ди эти.

— Беләм, беләм... Ник апчыкканнарын беләм,— дип, серле елмаеп куйды Вакыйф. Үз елмаюыннан үзе оялгандай, йөзен читкә борырга тырышты, Азаттан күзен яшерде.

— Нәрсә беләсең?

— Беләм. Әйтмим генә,— дип елмайды Вакыйф.

— Әйтмәсәң, әтидән сорыйм — исең киткән...

— Һи, тилебәрән орлыгы ашасаң, сора. Әтидән шундыйны сорыйлармыни...

— Мактанган була, ул гына белә янәсе...

Микәй Азат янына килеп, муенын аның беләгенә салып туктаган иде инде.

— Ишеттеңме? Безгә дә керербез, яме, Микәй, җәй генә җитсен. Син кирүгә безнең үз кәҗәбез дә булыр,— дип сөйләнә башлады Азат.

— Кирә-кирә, керми димени, иеме, Микәй! Чакырсыннар гына, керәбез аны диген... Беләсең килсә, аны Югары Сөн кодадан синең атаң сораган иң элек. Кода сатмаган. Аның бәясе юк, диган. Иң кадерле кодам белән аның якын күршесенә бүләк итсәм генә инде дигән, уртак малыгыз булыр, дигән.

Бу яңалык Азатка ошады. Ул яңадан кәҗә бәтие белән сөйләшергә керешә.

— Микәй, исемеңне әйт әле, Микәй. Исемең ничек синең?..

— Ул сиңа уенчык түгел лә,— дип тагы акыл бирергә ашыкты Вакыйф.

— Түгел шул, акыллы ул, иеме, Микәй!— Йоп-йомшак ул, матур ул...

Вакыйф шунда яңа кызык уйлап чыгарды.

— Адат, Адат, Әйдә, малай, карыйк әле, кода ялгышмады микән...

— Нәрсәне?

Тагы серле итеп елмайды Вакыйф һәм Микәйне аркасыннан кочаклап та алды.

— Кода дөрес әйттеме икән, дим. Әйдә, әйләндерергә булыш әле...

— Һи-и, тиле, барыбер түгелмени,— дип, Азат төшенгәндәй итте.

— Бер булса, тәрәзәдән йөрерләр иде. Тотыш инде...

Яннарында торган кәҗә бәтиен әйләндерә-тулгандыра башлады алар. Кәҗә карышты, тыпырчынды, әмма типмәде, сөзмәде.

— Ялгышамы соң, безнең кода бит ул,— дип куйды Вакыйф.— Дөрес әйткән, ата кәҗә баласы.

Нәкъ шул чакны, баш очларында гына аларга кушылып тагы кемдер, өченче кеше көлгәне ишетелде. Күтәрелеп карасалар, фермадан кайтып килүче Айсылу апалары басып тора икән.

— И-их, син аларны...— диде ул, көлүеннән туктала алмыйча.

— Ә-ә, җиңгәчәй кайткан,— дип, иң элек уңайсызланып Вакыйф сикереп торды.— Менә без монда карап торадырыек әле... Иеме, Адат!..

Аларның кулыннан ычкынырга өлгергән кәҗә бәтие лапаска таба торып йөгерде. Сикергәли-сикергәли, туп-туры тагын иязлангән урыны — түбәгә менеп китте.

Айсылу апалары Вакыйф янында уңайсызланып басып торган оялчан малайны шунда гына күргәндәй итте.

— И-и, күрми дә торам икән, Азат түгелме соң... Азат кияү икән ич,— дип, аркасыннан сөйде.

Айсылу апасы аны күргән саен шулай яратып, үз итеп, «кияү» дия-дия сөя торган иде. Азатка бик тә рәхәт булып китә иде ул сөйгәндә. Тик авызын ачып сүз әйтергә генә өлгерми кала. Гел шулай, көтмәгәндә килеп чыга да шапылдатып сөя һәм, күңеле булгач, көлә-көлә китеп бара. Бу малайның теле юк ахры, дип уйламый микән Айсылу апасы...

Бу юлы инде ул өлгерлек күрсәтте, Айсылу апасы кузгалып киткәнче дәшәргә ашыкты.

— Айсылу апа,— диде һәм ни әйтергә белми кинәт туктап калды... Юк, сүз булмаудан түгел. Айсылу апасы белән сөйләшәсе килгән сүзләр аның күңелендә тулышып, хәтта ташып тора. Шул минутта нәрсәдән башларга, ни диярга белми генә сүзсез калды ул.

Айсылу апасы, иелә төшеп, ялан куллары белән аның башындагы бүрекен рәтләп куйды. Туңмадыңмы дигәндәй, колак яфракларын тоткалап карады һәм тагы бер тапкыр үз итеп сөйде дә болдырга таба юнәлде.

Вакыйф, дөньясын онытып, кыек башына менеп баскан кәҗә бәтиен күзәтә иде.

— Карале, малай, карале, ул түшләрен киереп торуларын гына күр син аның... Питыр патша атланган айгырмыни...

## 7

Түбәгә менгәч дөнья иркенәеп китә...

Кешеләр аркылыга да торкылыга да корып бетергән койма-киртәләр моннан чүп кенә булып кала. Бөтен әйләнә-тирә ап-ак. Урамнар гел актан. Өй түбәләре, каралты-куралар ап-ак юрган астында. Шул ак түбәләрдән ара-тирә ап-ак төтен чыгып тора. Ул төтен ак багана булып ак болытларга барып тоташа. Ак болытларның аръягында да аклык микән?..

Ап-ак бакчаларның аргы башындагы киртәләр дә ак йомшаклыкка чумган. Ак урамнар буйлап тезелеп киткән баганалар арасын ак бәскә төренгән чыбыклар тоташтырган. Урам читенә өелгән кар көртләреннән ак каеннар үсеп чыккан. Нәни генә тармакларыннан исә аклыкларына сыеша алмыйча мөлдерәгән ап-ак чуклар менә тамам, менә тамам дип торалар...

Аклыкта коенган ак каенның иң югарыгы ботагына ап-ак түшле, озын ак койрыклы купшы бер кош килеп кунды. Тармаклардан ак бәс коелды. Шул ак койрыклы кошныкыдай канатлары булса икән Микәйнең дә... Ни эшләргә белер иде ул. Ике дә уйлап тормыйча шушы ак авылның аргы ягыннан башланган чиксез аклыкка таба чыгар да очарые. Шул аклыкның чигенәчә очарые... Ә аклыкның чиге буламы икән?.. Юктыр! Аклыкка ни җиткән...

Күз күреме җитмәс бу аклыкның аргы якларында ап-ак урманнар бардыр. Ак офык читендә ул урман төсмерләнә дә кебек. Ә ул ак урманнарның да аргы ягында ак юллар бардыр. Шул ак юлларның кайсысы бик еракларда калган ак таулар иленә илтә икән? Аклык тантана иткән менә шул тау һәм кыялар илендә аның әнкәсе, туган энесе торып калды. Бу минутта алар да Микәйнең күз алдына ак булып килделәр. Ак болытлар арасыннан ак нурлар сирпегән әнә шул кояш сыман бит аның әнкәсе. Алар да аны юксынамы, сагынамы икән?.. Ак урманнар төбәгеннән килгән ак юллардан күзләрен алмый аны көтәләрме икән?..

Шунда, ак каенның ботакларына елышып менеп килгән ак мәчедән куркып, теге ак койрыклы кош кагынып очып китте. Их шуның кебек канатлы булсаң икән, дип тагы бер кат сокланып, көнләшеп калды аның артыннан Микәй. Нигә канатсыз булып туды икән ул?..

Кинәт, әллә нидән генә аякларына көч, гәүдәсенә дәрт, нәни мөгезләренә гайрәт килә башлавын тойды ул. Бер урында тик кенә басып тора алмыйча, алгы аяклары белән түбәдәге карны тырнарга кереште. Күзләре очкынланды, иңбашларына пар канатлар чыккандай хис итте ул кинәт үзен. Менә хәзер шушы лапас түбәсеннән кушаяклап этенеп китсә, аның иңбашында канатлар җилпенә башлар, һәм ул күз ачып йомганчы урман аръягындагы теге ак юлларга барып җитәр. Шулай итәчәк тә — ике уйлап тормый алга, югарыга томырылды Микәй.

Әмма иңбашларында җилпенергә тиеш булган канатлар хыянәт итте, тыңламады. Ак болытларга күтәреләсе урында, тирән көрткә төшеп чумды Микәй. Ләкин кимсенү, өметсезләнү турындагы уй мөгез очларына да килеп карамады аның. Ничек итеп көрттән чыгуын һәм бакчалар аша бата-чума ничек басуга чыгып чапканын хәтта үзе дә абайламый калды. Күкрәгенә тулган дәрт, аякларын алгысытып торган көч, мөгезләреннән чәчрәп торган гайрәт канатлардан болайрак ашкындырды аны. Чапты да чапты ул. Дүрт аягы берьюлы кар астына төшеп күмелсә дә, көрткә кереп чумган аякларга вакыт-вакыт таяну гел мөмкин булмый башласа да, алга омтылды. Күкрәкләре белән, бөтен гәүдәсе белән этенде ул. Пружина сыман җыерылып килде дә, муеннарын сузып, тагы алга ыргылды — шуып барды, йөзеп барды

кар өстеннән, әмма тукталмады. Ярык тоякларының йомшак кар өстеннән йөрергә гел яраксыз булуын шунда гына аңлады ул, ләкин сукранмады. Алда урман иде... Урман артында үзләренә тартып торган ак юллар. Шул ак юллар аны әнкәсе янына илтер. Шул хактагы уй хәлдән тайган аякларына тагын көч һәм гайрәт бирде. Ташып, ярсып килде гайрәт...

Артка борылып та карамыйча ашкынуын гына белде Микәй. Күзләренә һичбер нәрсә күренмәде. Бөтен тирә-як тоташ кардан гына тора. Күзләрен камаштырып торган шул аклык аны бервзлексез алга, бары алга дәшә.

Дөньясын онытып шулай алга омтылганда, кинәт тояк астындагы карның шуыша башлавын сизде. Ничек дип юрарга белмәде ул моны, ак кар булып ак кар аңар шулай хыянәт итәрме... Читкә сикерергә омтылды, өлгермәде. Соң иде инде... Үзе артыннан ишелгән кар тавына ияреп түбәнгә — ак упкынга тәгәрәвен абайлады Микәй. Аяклары үзенә буйсынмады. Мәтәлчек ата-ата, кая тәгәрәве хәзер үз ихтыярында түгел иде инде. Колак төбендә кар шавы, кар шыгырдавы гына ишетелеп торды.

Озакка сузылгандырмы ул шау, Микәй анысын абайламады. Ниһаять, бары да тынды, туктап калды. Үзенең карга күмелгән хәлдә текә яр астында ятуын аңлады ул. Тояк астында да кар, мөгезләре очында да. Бөтен хыяллары белән бергә ак кар астында калган. Кузгалырлык, кымшанырлык кына түгел. Арыган гәүдәсе, кызышкан аяклары, оеп, рәхәт бер талгынлыкка күмелә барган төсле булды. Күзләре дә йомылырга итте.

Шунда аның бөтен тәнен яшен ташы телеп үткәндәй булды. Тукта, ул шулай хәлсезләнеп кар астында оеп ятса, нәрсә була соң әле бу... Озаккамы ул монда? Ә гел бөтенләйгә булса? Шушы кар астындамы! Ә урман аръягындагы ак хыял булып үзенә тартып торган ак юллар... Ак кыялар иле... Әнисе...

Аякларына кайнар агым булып янә җегәр килгәнен тойды Микәй. Торырга, һич югында тезләнергә омтылды ул. Әмма аяклар буйсынмады, кымшанмады да. Аның саен тәненә, күкрәкләренә дәрт акты... Үз өстенә өелгән карны йолкып атырдай булып кагынырга, җилпенергә итенде ул. Арка өстендәге кар тавы авыр гына ыңгырашып алды. Ләкин җибәрмәде, калын иде кар.

Торырга дигәч, торырга! Кайнар агым акты да акты, иңнәрендә чынчынлап канат талпынгандай тоелды. Мөгез очларыннан гайрәт ташкыны бәреп чыкты. Бу юлы инде аны һични тотып тора алмаячак... Һәм шулай булып чыкты да — кар тавы аның алдында баш иярга мәҗбүр булды.

Ул тагы ак киңлектә! Барыр юлларына ак келәм сузылган. Кире борылу турында уйлыйсы да юк — әле генә мәтәлчекләр ата-ата ишелеп төшкән урында мәһабәт биек яр калыккан. Бөтен гәүдәсен калтыратып кагынып алды Микәй. Аркасына, йоннары арасына кунган салкын кардан да бигрәк, икеләнү һәм шурләүдән котылырга теләп кагынды ул. Ләкин кузгалып ерак китә алмады. Яр читеннән дүрт-биш тапкыр сикерергә өлгердеме-юкмы, аяк астындагы көпшәк кар тагы убылып куйды. Бу юлы да ул читкә сикерергә өлгерә алмады. Ак түшәк кебек кар астында агып яткан инешкә төшкән булып чыкты. Йоннарын чылатып алган салкын су чиркандырып, айнытып җибәрде аны. Бар көчен җыеп яр читендәге кар өстенә сикерде ул. Беренче сикерүендә барып чыкмады — арт аяклары белән кире салкын суга ишелеп төште. Тагы сикерде, алгы аякларын тез турыннан бөгәргә өлгерде бу юлы, яр читендәге кар өеменә иякләрен куйды, бөтен гәүдәсе белән алга омтылып тырмана торгач, инеш читенә исән-аман чыгып басу насыйп булды.

Көн кичкә авышып бара иде инде. Җылы нурлары белән озата килгән, җемелдәшкән кар бөртекләре аша аның күзләренә өмет өстәп торган, гайрәт биргән кояш та алсуланып баерга җыена иде. Шулай да кирегә юл юк — анда салкын инеш, анда текә яр һәм анда ялгызлык. Ә алда алсу шәфәкъ нурларында коенган ап-ак чиксезлек. Шул ак киңлек янә аның күңелендәге ак хыялларны яңартып җибәрде һәм алгысытып үзе артыннан әйдәде.

Шактый озынга сузылган сөзәк үрне мендә башта. Тирән көрт өстеннән шуышып һәм йөзеп барды диярлек. Инешкә чыланудан төшенә һәм бәкәлләренә нәни боз кисәкләре каткан. Көрттән арынып, азга гына каты кар өстенә чыктымы, шул боз кисәкләре бер-берсенә бәрелеп, дистәләгән нәни шөлдерләр сыман, аваз бирә башлый. Йомшак мамыклары чыланган турыда тәнен салкын чеметкәләп ала. Әмма барыбер бирешергә уйламады ул.

Ниһаять, күз алдында ак шәүлә төсле генә булып урман төсмерләнә башлады. Кояш инде офык читендә эленеп торган ак болытларга кереп күмелә язган. Караңгы төшә баруга да карамастан, аклык кимемәде. Ә тагы бераздан, җир белән күк арасындагы төс аермасы кими барып, ак кар һәм ак болытлар үзара тоташып, бер булдылар. Ак кар өстеннән атлый идеме ул, ак томаннар ерып бара идеме, әллә ак болытлар өстеннән йөзепме — аңламассың. Шундый серле билгесезлек халәтендә бара торгач, ак караңгылык арасыннан аермачык булып урман күренә башлады.

Ул урман буена җитеп туктап калды. Аяклары хәлсез, бөтен гәүдә арыган, әлсерәгән. Тәненә карлы боз кисәкләре укмашып каткан. Салкын җил исеп куйды — калтыратырга тотынды. Күзләргә вак кар бөртекләре сибеп җәяүле буран еберә. Шомландырып урман шаулый. Ул да түгел, якында гына нидер сынды һәм шак-шок килеп берничә тапкыр бәрелеп алгач тынып калды — кар эченә чумды.

Нишләргә?.. Хыялындагы ак юлларын эзләп урман эченә кереп китәргәме?.. Әйләнә-тирәне томалап алган дөм караңгылык, җил һәм агачлар шавы күңелгә шом өстәп тора... Урманга керми генә ак юлларны ничек табар соң ул? Күпме ара үтелгән, күпме газап... Хыялындагы ак юллардан хәзер аны бары тик шушы урман гына аерып тора. Тәвәккәлләргәме әллә?.. Тәвәккәлләргә! дип боерды аңа җаны. Көч табылды — урманга таба ыргылды Микәй. Әмма күп китәргә өлгермәде, колакларын сагайтып, туктап калды.

— У-у-у...

Урман эченнән сәер, шомлы аваз ишетелде. Колак төбендә генә сызгырган җил авазы түгел иде бу. Нииндидер шом алып килгән чит-ят аваз.

Башын бер читкә янтайта төшеп, сагаеп кына урман ягына колак салды ул. Ерак түгел генә коры куак сынганы ишетелде. Озак көттермичә, шул ук шомлы аваз кабатланды:

— У-у-у, у-у-у-у...

— Шомлы аваз дигәне бу юлы янәшәдәге куе караңгылык артында гына ишетелде. Якынлашып килгән куркынычны сизүдән Микәйнең муеннары турайды, колаклары үрә торып басты. Ике уйлап торырлык ара юк иде инде, урман читләтеп чабарга тотынды ул. Кар тирәнлеге дә, каршы искән җил дә, ару һәм тәнендәге сызланулар да онытылды. Бары бер уй — тизрәк читкә тайпылу, теге шомлы аваз чыгарган куркыныч җанвардан качып котылу максаты гына иде аңарда.

Дөньясын онытып шулай бер тын чапкач аякларын тыя төшеп, тагын колак салды Микәй. Ул-бу ишетелмәгән төсле үзе. Шулай да аның артындагы ак караңгылык эчендә әледән-әле нидер ялтырап киткән сыман тоела. Бу нәрсә?.. Аермачык күренеп-күренеп ала — ике утлы күмер кисәге диярсең. Әллә курыкканга гына күренәме?.. Башын тагы да бора төшеп, колакларын торгызып күзәтте Микәй. Теге ике утлы күмер һаман да ныграк ялтырый. Алар артында зур гына кара шәүлә дә төсмерләнә иде инде. Тик ул шәүлә шундый ипле килә, шуамы, тәгәриме, һич аңларлык түгел. Бернинди тавышы-авазы юк, ә үзе якынайганнан-якыная бара. Әллә күзенә күренүче берәр шәүлә генә микән ул?..

Башта мөгез очлары, аннан берьюлы бөтен тәне чымырдап куйды кәҗә бәтиенең. Аяклары тыңламас булып туктап калды. Шунда гына үзе артыннан куа килгән әлеге гәүдәдән качып котылу мөмкинлеге чамалы булуны аңлап алды. Башка чара калмаган иде. Ни язса, шул булыр

дигәндәй, бер пар утлы күмергә ияреп килгән шәүләгә каршы борылып басты. Аякларын терәп куйды, башын селкеп, нәни мөгезләрен барлап алды. Күләгә исә, тагы да якынлаша төшкәч, өч-дүрт сикерем ара калдырып туктап калды. Әллә аны да сагаю һәм шом туктатты, табышының инде качып котылыр җае булмауны аңлап, үзенә күрә ләззәтләнүе идеме?.. Соңгы сикереш ясар алдыннан, бераз гайрәт җыеп, теш кайравы гына булдымы?..

Нәрсә булса булды, соры ерткыч та, Микәйгә охшатып, арт аякларына чүгеп карга утырды. Күзләре елтыр-елтыр килә. Ул да түгел, муенын урманга таба янтайта төшеп, югары сузды да кинәт бөтен тирә-юньне уятып, сузып-сузып уларга керешге:

— У-у-у-у...

Микәйгә аның бу авазы өстәмә көч бирде. Ерткычның шөбһәгә калуы һәм урманга ярдәм сорап мөрәҗәгать итүе дип аңлады ул моны үзенчә. Аның каршында басып торган Микәй соры ерткыч өчен, бәлки, тагы да куркынычрак җанвар булып тоелгандыр... Бәлки, Микәйнең күзләре дә кышкы урман буендагы бу караңгылыкта, дошман күңеленә шом салып, куркыныч елтыраша торганнардыр...

Бер-беренә бөтенләй чит-ят булган ике җан иясе, урман читендәге салкын карга чүккән көйгә, байтак кына күзгә-күз карашып тордылар. Әлеге киеренкелеккә күнегә төшкән Микәй як-ягына да күз салырга өлгерде. Үзеннән ун-унбиш сикерем ераклыгында биек итеп өелгән печән кибәне торуын күреп алды ул.

Байтак озынга сузыла башлаган тынлыкны теге соры нәрсә бүлде. Ул аякларына басты, саклык белән генә Микәйгә якыная башлады. Күзләре янә утлы күмер сыман ялтырарга кереште. Мәкерле рәвештә шуышып килүче җанвар аермачык күренә башлады. Үзенә нинди куркыныч янавын кәҗә бәтие шунда гына аңлады булса кирәк. Икеләнер ара калмаган иде, ул кинәт кенә кырт борылды да печән кибәненә таба торып чапты. Дәү ерткыч аңардан мондый елгырлык көтмәгән булса кирәк. Хәтта, үзенә ташланудан шүрләпме, сискәнеп, туктап та калды бугай әле ул бер мизгелгә. Кәҗә бәтиенең качарга җыенуын аңлагач та артык исе китмәде. Мондый төндә, мондый урында аңардан берәүнең дә котыла алганы юк иде әлегә. Кая китсен, ерак китә алмас. Иплә генә атлавында булды бүре. Лап-лоп басып килгән тәпиләренең саллылыгы, шыкыр-шыкыр килгән тешләренең үткенлеге бирде аңар бу ышанычны.

Кибән янына салган кар, ни хикмәттер, каты булып чыкты — аяклары батмады Микәйнең. Әллә ак төснең аны шулай үз итүе идеме — ак кар аны иңнәренә алды. Томырылып килгән җирдән сикерүе булды Микәйнең, бурап салган кар өстеннән тырмана-тырмана печән кибәненең түбәсенә менеп тә басты. Артыннан ишелеп калган кар өемнәреннән елгыррак булып чыкты ул.

Куа килгән соры бүре, киресенчә, бата-чума башлады. Әйтерсең лә, аның авыр гәүдәсен ак кар күтәрергә теләми иде, ул баскан саен шыгырдап торган кар убылып-убылып түбән төшеп китә. Тәпиләрен никадәр иплерәк һәм җайлырак итеп басарга тырышмасын, соры шәүләне барыбер үз итмәде ак кар. Аяк терәп этенергә һәм кибән өстенә сикерергә дип күпме генә талпынмасын, кибән тирәсенә бурап-бурап салган көрттән аерыла алмады бүре. Дәү тәпиләренә басып сикерергә талпынуы була, ул янә түше белән тирән кар эченә кереп чума иде.

Бүре печән кибәнен әйләнеп йөренә башлады, бер-бер хәйлә кору җаен карады. Микәй исә бер урында таптанып, аны берөзлексез күзәтеп торды. Бүре аның саен башын болгый-болгый йөрүендә булды, печән кибәнен аяклары белән тырнады, тешләре белән йолкыды.

Йөреп-йөреп тә рәт чыгара алмагач, печән кибәне итәгенә чүгәләп тешләрен кайрады, иреннәрен ялап, улап та алды. Тагын торып хәйлә эзләде, берни майтара алмый, янадан барып чүкте — кибән өстендә утырып чыккан ялгыз кәҗә бәтиен күзләп, таңга кадәр авыз суын корытты.

Яктырып бетте дигәндә генә, артына борылып карый-карый, башын түбән иеп китеп барды соры ерткыч. Микәй шунда гына иркен сулыш алды һәм, төн буена сузылган киеренкелектән бушанып, печән өстенә сузылып ятты. Ирексездән, күзләре йомылды. Изрәп йокыга талды. Иртәнге салкынны да, басу ягыннан исеп торган ачы җилне дә тоймас хәлгә житкән иде ул.

Татлының да татлысы булган төш керде аңа:

Имеш, таң вакыты. Зур булмаган кәҗә көтүе биек-биек таулар, дәү-дәү ташлар арасында йөри икән. Кәҗәләр арасында аның әнкәсе дә бар. Ягымлы күзләреннән, озын кара мөгезләреннән һәм кояшлы көндә үзеннән берөзлексез көмеш нурлар балкытып торган зифа гәүдәсеннән таныды аны Микәй. Ул кыя читендәге олы бер таш өстенә менеп баскан да еракка-еракларга, офык читендәге мәһабәт ак тауларга карап тора. Шунда алгы аяклары белән ташны тырнап торган әниләре бәтиләрен үзе янына чакырды. Микәй, туган энесе белән икәү, дөньяларын онытып таштан-ташларга сикереп куышлы уйнап йөри иде. Чакырганны күреп, алар шундук, уеннарын ташлап, әнкәләре янына томырылып килделәр һәм, әнкәләренә охшарга тырышып, аның белән янәшәгә кыя читенә килеп бастылар.

— Мә-ә-ә,— дип дәште әнкәләре тыныч кына.— Каршыдагы үзәнлек аръягындагы ак калкулыкны күрәсезме?

— Ми-ә-ә,— дип, бер-берсен бүлдереп җавап кайтарды бәтиләр. — Күрәбез, күрәбез...

— Шул ак калкулыкның да аргы ягында ап-ак болытларга ашкан ак кыялар бар...

— Ә ул ап-ак болытларга җиткән ак кыяларда ни бар?

— Бәхет, бәтиләрем. Бәхет...

— Бәхет ул ни була, әнкәбез?

— Ул — тынычлык һәм ирек дигән сүз... Әнә, ул ак кыяларда сезнең бәхеткә һичкем кул сузмас, бәтиләрем. Шунда гына сез рәхәтләнеп иректә йөри алырсыз.

— Монда да бик тыныч, иркен ич, әнкәбез.

— Тыныч иде...

— Нигә «иде»?

— Кеше эзләре, бәтиләрем!.. Кеше эзләре күренә бу кыяда.

— Ә кеше ул нинди була?

— Кешеме?— дип, ничек әйтергә белми уйга калып торды әнкәләре.

— Әйе, әйе, кеше... Ул нинди була, әйт инде, әйт, әнкәбез?..— дип тынгысызланды алар.

— Ул ике аяклы, бәтиләрем. Һәм мең мәкергә ия! Аю-бүредән качып була, ә кешедән качу кыен, бәтиләрем.

— Әнкәбез, әнкәбез... Ә ул ап-ак болытларга ашкан ак кыяларда юкмы кеше?..

Нәкъ шул чакны, төшнең иң киеренке җирендә генә, көмеш нурларга төренеп балкыган әнкәләре ни әйтергә икән дип уйланып торганда, ниндидер шартлау авазыннан сискәнеп уянып китте Микәй. Шартлау авазы тагы ишетелде. Капылт кына тирә-ягына карангалап алгач, үзенең кайда булуы һәм нинди язмыш белән монда килеп чыгуын хәтерләде кәҗә бәтие. Ә тирә-юнь яңадан тынып калган. Һичкем күренми, шылт иткән аваз да ишетелми. Төш инде өзелгән. Яңадан ялганырмы ул... Нигә нәкъ менә бүген күрде соң әле ул бу төшне? Нигә кичәге явыз бүре түгел, ә әнкәсенең кешеләр турында сөйләгәннәре керде?.. Кешеләрнең аңа нинди явызлык кылганы бар? Юк, кешеләр турында Микәй начар уйлый алмый иде!

Ирексездән күзләре яңадан кысыла башлады Микәйнең. Күзләре кысылды, ә йокы иңмәде. Хәер, йокы кайгысы идемени соң! Өзелеп калган төшнең дәвамын хәтерләргә, барларга керешә ул. Кыядагы зәңгәрсу аклыкны гына таба алмый газапланды, ә башкасы әлегедәй хәтерендә иде.

... Әнкәләренең иркә карашыннан канатланып, таштан-ташка сикергәли, уйный башлаган иде ул туганы белән. Шунда, янәшәдә генә нидер кыштырдап куйды, һәм алар, аны-моны уйлап тормыйча, бер-бер артлы әнкәләренә таба ыргылдылар. Туган энесе алдан сикерде, ә Микәй сикергән җиреннән һавада эленеп калды. Күпме талпынып, тыпырчынып та чыга алмады ул үзен уратып алган ятьмәдән. Ятьмәгә эләккәч тә әле озак кына кыядагы таштан-ташка сикерә-сикерә ераклашып баручы әнкәсен һәм туганын күзәтте ул. Кәҗә төркеменнән беразга калыша төшеп туктадылар алар һәм Микәй калган якка бер тын каерылып-каерылып карап та тордылар әле. Күрделәрме, юкмы — билгесез. Әнкәсенең моңсу итеп кабат-кабат үрсәләнеп кычкырганы әле дә булса аның колак төбендә яңгырап тора.

Юк, явыз түгел кешеләр! Алар аны үзен тоткын иткән ятьмәдән чыгарды. Явыз түгел кешеләр — алар аны сукмый-какмый гына өйләренә алып кайттылар да ерак юлга озаттылар. Алар аны ашатты-эчертте, җылы урында тотты. Кешеләр явыз түгел — аны рәнҗетмәде, алар үз итте, кадерләде. Ничек итеп кешеләр турында начар уйлый алсын соң ул...

Әнкәсенең кешеләргә булган үпкәсен күпме генә ачыкларга тырышмасын, Микәй аңлый алмады. Үзенең ак кыялар иленнән еракта бер ялгызы көн күрүенә кешеләр сәбәпче дигән уйны мөгез очларына да китереп карамады.

Ак кыялар илендә калган әнкәсе һәм туганы хәзер кайда икән? Бәхет вәгъдә иткән ерак кыяларга барып җитә алдылар микән?.. Җитсәләр дә, аңардан башка моңсудыр үзләренә. Әле ярый Микәйнең кайларда булуын, ниләр күрүен белмиләр. Юкса тагы да моңсурак булыр иде. Менә кайтып кына җитсен, әнкәсе белән туганын ул шундый шатландырыр! Үзенең соры ерткычтан ничек итеп качып котылуын сөйләр. Һәм, әлбәттә, кешеләр турында сөйләр. Ул бит аларны бик якыннан белә хәзер, бөтен кәҗәләрдән яхшырак белә. Кешеләрнең яхшылыгын, игелеклелеген бәйнә-бәйнә сөйләр Микәй.

Урман аръягындагы ак юллар турындагы уйлар аны урыныннан кузгатты. Инде үзен саклап калган кибән өстеннән сикерергә әзер иде. Әмма бая соры ерткыч китеп барган юнәлештән ниндидер авазлар ишетелү аны тыелырга мәҗбүр итте. Кибән очында чокыраеп төшкән урынына кереп яшеренергә ашыкты ул.

Тавышлар якынайды. Микәйгә таныш авазлар иде бу. Ул алардан курыкмады.

— Үнә, үнә, кибән өстендә. Колаклары белән мөгезе күренеп тора,— дип, чаңгыда килүчеләрнең берсе таяклары белән этенә-этенә алга чыкты. Азат иде бу. Аның артыннан җан-фәрман Миңлегаяз куалый. Ә өченчесе, аркасына мылтык аскан, Азатның этисе. Ул чана тартып килә.

— Мин беренче күрдем, мин беренче! — дип тантана итте Азат.

— Теге бүре Микәйне сагалап торган,— дип нәтиҗә ясады Миңлегаяз.

— Һавага атма дидем, эти... Ул бит Микәйне кызганмас иде,— дип, Азат этисен шелтәләргә керешге. Ләкин, Миңлегаязның үзен узып барганын күргәч, янә торып чапты.

Кибән төбен өчесе өч яктан урап алган танышлары янына Микәй үз ирөге белән төште. Малайларның шатлыклары эчләренә сыймады. Микәйне инде күптән бүре карынындадыр дип хафаланган иде ич алар. Кәҗә бәтиен исән күрүдән икесенең дә күзләре дымланды, бугазлары тирәсендә нәни төерләр уйнап алды.

Кулларын як-якка ташлап, иртәнге урман-кырларны яңгыратып, шатлыгыннан бар көченә кычкырып җибәрде Азат:

— Микәй исән! Ур-ра, Ми-кәй и-сә-эн...

Аңарга дусты Миңлегаяз да кушылды. Ә бераздан, урман ягыннан пырхылдап очып чыккан кошлар сыман, яңгырап кайтаваз ишетелде...

Көннәр сизелми дә үтә торды. Кыеклардагы сөңге бозлардан тамчы тамды. Тәрәзә төпләрендә яран гөле чәчәк атты. Ишегалды тагы да җанлана төште. Ирекка чыгу шатлыгыннын кош-кортларның котын алып, бозау чабулый башлады. Ак, кара бөдрәләренә тамчы да кар кунмаган сарык бәрәннәре сикерешеп уйнады.

Микәй генә һаман да әлеге җанлы һәм шау-шулы ишегалдында үз-үзенә урын тапмады. Кая барып сугылырга белмичә, арлы-бирле йөрде дә, иялэнгэн гадәте буенча, лапас түбәсенең иң биек ноктасына менеп, күзләре талганчы тирә-якны күзәтте. Уч төбендәгедәй күренеп торган авыл һәм кырлардагы, урман һәм су буйларындагы тоташ аклык инде көннән көн кими бара. Урамдагы юллар чекерәеп күзгә ташланып тора, киртә һәм койма башларындагы, өй кыегындагы аклык та күз алдында эреп югала сыман. Тау битләре ала-кола сыер сыртын хәтерләтә башлады. Үзенең аклыгы белән алгысытып, офык читеннән берөзлексез үзенә таба әйдәп торган урман булып урман да көрән төскә кереп авылга якыная төште. Күз алдында эреп югала барган шушы аклык сыман, кәҗә бәтие күңелендәге ак кыяллар да сүрәнләнә, ерагая бара түгелме соң...

Әкияттәге батырлар сыман ай үсәсен көн үсте, көн үсәсен ай үсте Микәй. Аяк торыклары нык кына калкынды, күкрәге күзгә күренеп киңәя төште. Сакал да үзенекен итте. Аеруча сокландырганы аның мөгезләре иде. Буынтыклы-буынтыклы булып нык тамырдан үсеп чыккан юан кара мөгезләре... Әле кайчан гына үзенә мөгез күтәргән дәү кәҗәләр дә хәзер аның яныннан үткәндә койрыкларын кыса төшеп, көяз генә карангалап уза. Сөзү, куркыту турында уйлап карау түгел, әле теге чактагылары өчен дә үзләрен гаепле санап, гафу үтенгәндәй италәр. Хәтта берсе, син үпкә саклама инде безгә, дуслашыйк әйдә дигәндәй, муенын сузып, аның аркасын кашырга да әзер булуын белгерткән иде. Микәй назланып тормады торуын, шул ук вакытта өйдәш кәҗәләргә ачу-үпкә дә сакламады.

Ул, Азатка ияреп, алар ишегалдына кунакка йөрергә дә күнекте. Тора-бара Миңлегаяз белән Азат Микәйне үзләре белән чана шуган җиргә дә ияртеп төшә башладылар. Малайлардан бигрәк, кәҗә тәкәсенең үзенә ошады бу.

Тау шуарга йөргән малайларның телләрендә хәзер гел Микәй исеме иде. Көннәрдән бер көнне түбән очтан Фаяз да үзенең овчарка токымы дип йөргән Дүрткүзен ияртеп төшкән. Шундый токымлы этен күрсәтеп, аның да үзенчә мактанасы килгәндер инде.

Дүрткүз анда кәҗә тәкәсе йөрүен генә ошатмады. Чанадагы малайлар артыннан дөньясын онытып кушаяклап чабып төшкән кәҗәне күрүгә, эт аяк астындагы карны тырный-тырный өрергә тотынды. Ә Микәйнең аңарда гаме юк — малайлардан алда ук тау өстенә менеп баса да, шунда аларны сабыр гына көтеп тора. Тегеләрнең шау-гөр килеп, этешеп-төртешеп шуып китүе була, алар белән куыша-куыша уйнаклап Микәй дә түбәнгә томырыла.

Һәркем шулай үзенчә кызык табып йөри иде. Тау итәгендә мәтәлешеп яткан малайларны сабыр гына күзәтеп тора иде кәҗә тәкәсе, байтактан инде бәйләнергә җай эзләп йөргән Дүрткүз кинәт, котырынып өрә-өрә, аңарга ташланды.

— Ул бит овчарка, ботарлап ташлый хәзер кәҗәне,— дип кычкырыша башлады малайлар.

— Тый этеңне, бетерә бит кәҗәне,— диделәр Фаязга.

— Дүрткүз... Дүрткүз,— дип кычкырды Фаяз.

Эт, хуҗасын ишетүдән узып, өрүендә булды. Гәүдәгә дә Микәйдән шактый калку күренә иде ул. Ә кәҗә бәтие исә ни эшләргә дә белми тик боргалана тау итәгендә — койрыгыннан эләктерергә чамалап тирәсендә бөтерелгән Дүрткүзгә таба башы белән борыла да, сер бирмичә, сагаеп карап тора. Малайлардан берәве дә якын килергә базмады алар янына, көтмәгәндә килеп чыккан гаугадан югалып калганнар иде.

— Ал этеңне, чакыр...
— Тилергән этеңне ал аннан,— дип, берөзлексез Фаязга кычкырындылар.
Эт, аның саен котыра биреп, хәзер үк ботарлап атарга теләгәндәй, Микәйнең өстенә үк ыргыла башлады. Үзеннән курыкмаска иткән бу кәҗә бәтиенең шулай бер урында таптанып торуы чыгырыннан чыгаргандыр, ахрысы. Эт якынрак килгән саен, Микәй сагая, бер йодрыкка җыелган пружина сыман кысыла барды.
Һәм шунда малайларны шаккатырган бер хәл булып алды. Тешләрен зәһәрле ыржайтып котырынган эт бәтинең арт санынннан каптырып алды дигәндә генә, Микәй күз иярмәс тизлек белән кинәт башын болгап алды да, мөгезләренә эләктереп, этне үзе аша икенче якка чөеп ыргытты. Кар өстенә аркасы белән барып төшкән Дүрткүз, чыйный-чыйный, артына да борылып карамыйча, авылга таба торып йөгерде. Чаналарын онытып бу хәлне күзәтеп торган малайлар үз күзләренә үзләре ышанмадылар.
Инде авылга менеп качкан этнең чинау авазлары басыла төшкәч кенә малайларның берәм-берәм телләре ачылды. Барысы да әле генә күргәннәренә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, шаккатып фикер алышырга тотындылар:
— Малай, күрдеңме, баш аркан ыргытты бит, име...
— Ие булмый, мамык урынына очыртты бит!
— Вәт кәҗә дисәң дә кәҗә, малай!
— Овчаркасын гел бетереп атты.
— Ниткән овчарка токымы булсын ул, кәҗәдән шулай мыскыл иттергәнне...
— Бетерү генәме соң, урамга чыгарлыгын калдырмады.
Нишләргә белми бер урында басып торган Фаяз гына үзенең мактанычы булган овчарка токымы Дүрткүзен кызганды. Ул бер тын мыштым гына борынын тарткалап торды да, бу гарьлеккә артык түзә алмыйча, елый-елый тыкрыкларына таба йөгерде.
— Фаяз, чанаңны ал, чанаңны оныттың,— дип кычкырдылар аңа. Күзендәге яшьне күрсәтергә теләмәде Фаяз, кире борылмады.
— Овчаркасының сөякләрен җыярга төшәсе бар бит әле аның...Капчыкка дип меңүедер,— дип өстәп куйды тагы да усалрак теллесе.

Шулай итеп, Микәй авыл малайлары өчен легендар геройга әверелде дә куйды. Телләрендә хәзер гел ул гына. Теге көнне тау шуганда күргәннәрен әллә ничә тапкыр арттыра-арттыра сөйләде алар. Барый исемле малай икенче көнне озын тәнәфес вакытында бөтен мәктәп алдында кулларын, башларын болгый-болгый сөйләп күрсәткән.
— Башын менә болай итеп, кырын-кырын гына карангалап торды да, малай, менә болай итеп сөзеп эләктереп тә алуы булды, тотып та атуы булды,— дип, башы белән кискен хәрәкәт ясап күрсәткәндә, ишек тоткасына бәреп, әздән генә күзен чыгармаган. Андый чакта күз турында уйлап торалармы! — Малай, беләсегез килсә, Фаязның овчарка токымы каравыл өе өстеннән очып, инешнең теге ягындагы бакчага — кем бакчасы әле... әйе, Гаяз абыйларның бакчасына ук барып төшмәсенме. Ул чинавын аның ишетсәгез... Билләһи газим менә, әнә, Миңлегаяздан сорагыз ышанмасагыз,— дип әйткән, ди. Миңлегаяз, шулай булды ахры дип, үзе де ышанып тыңлап торган боларны. Барый сүзләренең дөреслеген раслап баш та кагып торган әле.
Мәктәптән кайтучы малайлар хәзер Микәйне бер күрер өчен генә дә алар урамыннан урап уза иде. Койма читенә өелгән бүрәнәләргә менеп күзәтәләр, капка-койма ярыкларыннан карыйлар. Кәҗә бәтиенең лапас түбәсендә чагына туры килсәләр, гел телсез калалар, бер-беренә төртешеп пышылдашырга тотыналар:
— Үнә, үнә, күрәсеңме...

— Кәҗә түгелдер бу, малай. Күрәле син аны, канатлы атмыни!

— Син аның мамыгына кара, мамыгына. Бар хикмәте мамыгында ди бит аның.

— Көмеш укадан чиккәннәрмени, малай, ә?

— Түбә тикле түбәгә ничек менә диген...

Хәзер авылдагы бөтен малай Микәйне әллә каян таный, үз итә, аңарга бер генә тапкыр булса да кесәсеннән ипи чыгарып каптырырга дип хыяллана. Миңлегаяз белән Азатның да дәрәҗәсе көне түгел, сәгате белән артты малайлар арасында.

Күрше-тирә малайлар, мәктәптән кайтып, аннан-моннан капкалап алырга өлгерәләрме-юкмы, ничектер җаен чыгарып, Хуҗа абзыйларга таба элдертү ягын карыйлар. Миңлегаязның кәҗә бәтиен ияртеп урамга чыгуы була — китә уен, китә тантана. Микәйнең үзенә дә ошый иде алар белән куышып уйнау. Тора-бара кәҗә бәтиенең холкын, бөтен сәер гадәтләрен белеп бетерде малайлар.

Әйтик, болай була: арадан берәү кар йомарлап Микәйгә таба ата да, кайсы кая йөгерешә, кача башлыйлар. Кар кайсы гына яктан ыргытылмасын, аны атучыны Микәй шундук ачыклап өлгерә һәм сикергәли-уйнаклый куып та китә. Юлдан йөгереп тә, кар эченә кереп тә котылырмын димә инде. Бүрәнәләр өстенә менеп китсәң дә эләктерә, бура-мазар булып, шуның эченә кереп качсаң да — әҗерен кайтармыйча туктамый. Ярсуын тыя төшеп, йомшак урынга ипле генә берне кундырып ала да, ара өзелде дигәнне аңлатып, канәгать кенә кырт борылып китеп тә бара. Микәйнең берәүгә дә җәрәхәт ясаганы, берәүнең дә күзеннән яшь чыгарганы булмагандыр. Үзеннән качып барган малай абынып егыла-нитә калса, түземлек белән аның аякка басканын көтә. «Тәрбия» эшенә ул торганнан соң гына керешә. Ни итсә итә, әмма егылганга тими. Шул көннәрдә телевизордан «Өч мушкетер һәм Д' Артаньян» киносын караган малайларга Микәйнең бу гадәте аеруча мәзәк тоелды.

— Карале, малай, карале, мушкетерлар кебек ич бу...

— Микәй түгел, Д' Артаньяндыр ул.

Аның бу гадәтеннән, усал ният белән файдаланып, кызык чыгаручылар да табылды. Кушаяклап куып килгән Микәйдән качар урын тапмаган малайлар йөзтүбән юлга сузылып ята да кәҗәнең үзенә тими янәшәдә тик таптанып торуыннан кызык ясый иде. Кымшанырга гына ярамый. Ялгыш кымшанып куйсаң — игелек көтмә! Икеләтә эләгәчәк. Көтеп-көтеп тә җирдә ятучы урынынннан кузгалмаса, очратырмын әле бер дип, ул үз җае белән китеп тә бара. Малайларга кызык — әле бер минут элгәре, йөрәге уч төбендә булып, тын алырга да куркып яткан җирдән торганда, авызлар ерылып китә. Күрдегезме, янәсе, минем батырлыкны... Тик бернәрсәне — Микәйнең моны барыбер искә төшерәчәген генә онытып җибәрәләр. Ә Микәй бурычлы калуны яратмый.

Ни генә булмасын, әле кайчан гына ялгыз башын кая куярга белми газап чиккән Микәй тиз арада Нурлы Алан авылы малайлары арасында үз кешегә әверелде. Ишегалдыннан көннең теләсә кайсы вакытында качып чыгып китеп, үз вакыты белән кире әйләнеп кайта торган булды ул.

## 9

Көннәрдән бер көнне мәктәптән кайткач та Миңлегаяз атыла-бәреләазатларга йөгереп керде.

— Микәй сездәме? Микәйне күрмәдеңме? — дип сорады ул кергән уңаена.

— Әле генә лапас түбәгездә кадаклап куелгандай басып торае...

— Анда юк. Киртә аша чыгып качкан.

— Нигә качсын, урамдадыр,— диде Азат дустын тынычландырырга ашыгып. Ләкин үзенең дә күңеленә шом керде. Чынлап торып качкан булса?.. Хәзер кыш көне түгел, эзеннән барып табармын димә. Боз кузгалып, сулар ташыган чак...

Икәүләшеп урамга йөгереп чыктылар. Кая барырга белми икеләнеп торгач, иң элек пожар өе һәм кибет тирәсеннән урап килергә булдылар.

Иртә язда һәм кышын ир-атның җыелып гәпләшә торган урыны — пожар өе янында, ни хикмәттер, кеше юк дип әйтерлек иде бүген. Сугышта бер кулын калдырып кайткан Гаяз абый гына ат җигеп азаплана.

Тагы бераз киткәч, юлда очрашып нидер сөйләшеп торган ике әбигә игътибар итте алар. Дөньяларын онытып, рәхәтләнеп сөйләшкән сүзләре, тыңламыйм дисәң дә, әллә каян ишетелеп, колакка бәрелеп тора.

— Теге нәмәрсә кайткан, шуңа дип менгәнием әле, Маһитап абыстай.

— Минем дә шунда таба теркелдәвем, соңгарак калып ишеткәнем шул, соңгарак калып. Җитсә генә ярар иде канә.

— Җитәр, җитәр. Маһитап абыстай, икешәр шешә генә бирәләр әҗәл дарулары иттеләр инде шул шайтан суын, билләһи.

— Әҗәл даруы булмый ни, безнең ише карт-корының утынын да шул кисә, шул турап өя, бакчасын да сукалый, кoйманы, каралты-кураны рәтлим дисәң дә шул чукынган нәмәрсәкәй кирәк бит.

— Әйтмә дә инде, Маһитап абыстай, әйтмә дә... Чистый бар эшкә дә ярый торган булып китте шул җен каргаган нәрсә. Менә безнеке, сабанга төшкәнче кыш чыккан тәкәне чалам, ди. Сугымы да шунсыз булмый хәзер. Кодалар да киләсе барые... Икене генә бирәләр шул. Ике шешә белән нишләмәк кирәк, кеше алдында оятка калуың бар...

— Ярар, кем, Галимә, ие... җүгерим әле. Мин сузылып менеп җиткәнче бетеп куя күрмәсен.

— Бар, бар, Маһитап абыстай, сүзнең ни, аның бетәсе жук, чиратка баса тор.

Малайларга аларның сүзләреннән бигрәк, үз-үзләрен тотышы кызык тоелды. Хатыннар икесе дә ашыга, кабалана иде. Әмма һич кенә дә берберeннән аерыла алмыйлар. Аяклары икесен ике якка тарта, чигенә-чигенә юлларын дәвам итәргә тырышалар үзләре, ә күңелләре җибәрми. Сөйләшерацлашыр сүзләре күп, ә үзләре рәтле-башлы берни сөйләшми. Инде аерылалар дигәндә генә янәдан бер-беренә тартылалар. Азат белән Миңлегаяз үтеп киткәч тә, алар әле шулай чөркелдәшеп калды.

Кибет урамына борылгач та хәйран калды малайлар. Сирәк була торган җанлылык иде кибет каршында. Берсе керә, берсе чыга — кулларына сумкасетка ише әйбер тоткан авылдашлар арлы-бирле йөгерешә. Кибетнең ишекләре як-якка киереп ачылган, урамга аннан җылы пар бөркелеп тора. Сату-алу гөрләп барган урыннарда гына була торган ыгы-зыгы һәм авазлар яңгырап тора. Шаяру һәм уен-көлке арасында кемнәрнеңдер сукрану сүзләре дә ишетелеп куя.

— Кем чыгарган ул закунны, нигә ике генә шешә? — диде калын тавышлы ир кеше.

— Бүчкәсенә төшерсәң дә туймассыз сез. Җавап бирүченең кибетче Миңнурый апа булуын әллә каян таныды малайлар.

Шунда хатын-кыз затыннан икенче берәүнең тавышы яңгырады:

— Чиратсыз бирмә, алланың кашка тәкәсе түгелдер ләбаса...

— Кырга тирес чыгарасы бар, күзеңә тилчә чыкмагандыр бит, кем апа... Әнә, трактор эшләп тора,— дип җавап кайтарды чиратсыз керүче. Монысы Аю Гаяны тавышы иде, әле ике генә ел элек унны бетергән егет. Чаңгы буенча район чемпионы. Узган елны Сабан туенда батыр асты калды.

Ул арада, кулына ике шешә тотып, Гаян үзе дә килеп чыкты. Өстендә куртка-мазар юк, свитердан, яланбаш. Азат белән Миңлегаязны күргәч, тел очында мөлдерәп торган сүзләрен аларга әйтте: «Вәт, малай, җыен бездельник җыелып ята шунда, эшләгән кешегә: «Чират!..» — дип торган булалар».

Ул борын астыннан тагы ниләрдер мыгырданып, урамның каршы ягында гөрләп эшләп торган тракторына таба җил-җил атлап китеп тә барды. Арбасына тирес төялгән «К-701» кара төтен чыгарып газ бирде дә үкереп урыныннан кузгалды. Кабинаның ярымачык ишегеннән Гаянның канәгать йөзе генә күренеп калды.

Малайлар үзләренең кибет ишеге төбенә үк җиткәнлекләрен дә абайламый калдылар. Ишек төбеннән сузылып киткән чиратның очында уңайсызланып кына басып торган Миңлегали абыйсын күргәч, Миңлегаяз сискәнеп үк куйды. Нигә икәнен ул үзе дә аңламагандыр, мөгаен. Азатның җиңеннән тартып, тизрәк китәргә ашыкты. Микәйне эзләргә чыгуларын онытып язганнар ич...

Шулай да кибет ишегеннән чыккан тагы бер яңалык колакларын торгызды аларның.

— Аракысын алалар, ә шешәсен тапшыру дигәндә — юк,— дип зарлана иде кибетче.

— Тапшырмый нишләтәсең, ул буш шешә кемгә кирәк... — дип, ыгызыгы килде бернича кеше.

— Үзем дә аңламыйм, гомер булмаган хәл. Кая куялардыр буш шешәне, әллә шешә ашаучылар килеп чыккан инде...

Миңлегаязның карашы янә абыйсына юнәлде — ул тәмам коелып төшкән, үз якасы эченә яртылаш кереп чумган иде инде. Абыйсын шундый хәлдә күрмәс өчен генә булса да китәргә ашыкты ул.

Урамның аргы ягына чыгып, күп тә китмәделәр, аларны чыр-чу килгән бала-чага авазлары артларына борылып карарга мәҗбүр итте. «Микәй сөзә, Микәй...» — дип кычкырыша иде алар. Күзләре маңгайда, ә авызлары колакка җиткән. Чынлап та кибет ишегалдыннан, канатлы ат сыман очып диярлек, Микәй килеп чыкты. Әмма җан-фәрман йөгерешкән ыбыр-чыбыр әниләренең итәк астыннан кибет эченә кереп шылырга өлгергән иде инде.

Микәй туктап калды. Кая барырга белмичә, бер тирәдә таптана башлады. Үзен рәнҗетүченең арт сабагын укыта алмауга кәефе кырылган иде аның. Аннары, башын ия төшеп, бер читкә китте дә, кибет каршында тау сыман өелеп торган буш аракы тартмаларына сөялеп, муенын кашырга керешә. Үзен яратып һәм үз итеп читтә күзәтеп торучы Азат белән Миңлегаязны ул әле абайлап өлгермәгән иде.

Шунда кибет каршына килеп туктаган мотоцикл тавышыннан тирә-юнь кинәт сискәнеп алгандай булды. Кояш нурларында җылынып басып торган Микәй койрыгына ук килеп терәлә язган мотоциклны вакытында чамаламый калдымы, сискәнеп, икенче бер читкә сикерде. Мотоциклда килүчеләргә шул җитә калды — эчләрен тотып бөгелә-сыгыла рәхәтләнеп көлделәр дә, күңелләре булгач, зур эш майтарган кыяфәт белән кибеткә кереп юк булдылар. Ул да түгел, кабаланып урыныннан кузгалган Микәйнең каршысына, музыкаль сигнал биреп, кызыл «Жигули» килеп туктады. Ул янә сискәнеп алды, башы белән һава сөзеп, арт аякларында гына торып калган көе гәүдәсен читкә борды. Ләкин бер-ике адым китәргә дә өлгермәде, кинәт газ биреп урыныннан кузгалган авыр йөк машинасы астында кала язды. Тагы арт аякларына ташлады гәүдәсен, үрсәләнеп читкә сикерде. Әмма кай якка борылырга һәм кайсы юнәлештә китеп, бу мәхшәрдән ничек качып котылырга да белми иза чигә иде Микәй. Машина, трактор һәм мотоцикллар берөзлексез тукталып һәм кузгалып торалар иде кибет каршында. Бу шомлы ыгы-зыгы ошамады аңар, ул бер тын гаҗәпсенгән сыман башын кагып, мөгезләрен як-якка айкап, чайкалдырып торды. Һәм бары шуннан соң гына, кинәт бер карарга килеп, машина-тракторлар ыгы-зыгысы арасыннан атылып чыгып йөгерде. Каршына йөгереп чыккан Азат белән Миңлегаязны да абайламады. Алдына-артына карамыйча туп-туры чапты да чапты ул су буена таба сузылган озын урам буйлап — тояклары астыннан язгы пычрак кына чәчелеп калды. Микәйнең шундый тизлек белән йөгерүен авылда бу көнгәчә берәүнең дә күргәне юк иде әле.

Малайлар әлсерәп су буена төшеп җиткәндә, Микәй ярсып, кабаланып аккан язгы ташу читендә тын гына бер ялгызы басып тора иде. Әлеге ташуның кыш буе күңелен һәм карашын иркәләгән аклыкны урлап качуын уена да кертеп карамады ул.

## 10

Үзенең эчкерсез көләчлеге һәм яшьлеге белән өйне балкытып йөргән Айсылу җиңгәсенең йөзендә Миңлегаяз шул кичне беренче тапкыр борчылу чаткылары күрде. Кичке ашка алар Миңлегали абыйларыннан башка гына утырдылар, җиңгәсе белән янәшәдәге урын буш торды. Ә Миңлегали мич артындагы итек киптерә торган сәке өстенә яткан да ыңгырашуын белә.

— Ярар, исегез киткән икән, бүтән әчмәс,— дип кенә куйды Хуҗа абзый.

Айсылу дәшмәде. Миңлегали ягына карангалап ала да тик башын иеп утыруын белә. Әминә апа башына чөйгән яулык чите белән башкаларга күрсәтми генә күз төпләрен сөртеп-сөртеп ала иде.

— Әрмиягә киткәндә салып биргән рүмкәсен дә иптәшләреннән яшереп, өстәл читенә куеп киткән бала бит ул. Кайткач та күпме гомер иснәп карамаган бала,— дип сукранды үзалдына.— Кемнең генә күзләре тиде икән, и-и бала...

— Дөньяның асты-өскә килмәгәндер ләбаса. Җитәр, балавыз сыкмагыз!— дип, сүзгә тагын Хуҗа абзый кушылды. Ул үзе дә борчыла иде, әлбәттә. Шулай да сүзне, үзенчә шаяртмакчы булып, бүтәнгә борырга итте.— Анда әнә шешә ашаучылар күренә башлаган ди авылда...

Урынсыз шаяру итеп кенә кабул иттеләр бу яңалыкны. Берәү дә дәшмәде, Миңлегаяз гына, кая куялар икән ул шешәне дип, үзалдына уйлап куйды.

Утлар сүнде. Өй тынып калды. Миңлегаязның күзләренә йокы кермәде. Бүген көндез кибет янында күргәннәре бер-бер артлы хәтерендә яңарып торды. Урамда сөйләшеп торган ике апаның һәр сүзе күңеленнән узды. Кибет ишегеннән бүселеп чыккан чират... Шул чиратның очында кыяркыймас басып торган Миңлегали абыйсы... Кибеттән кош тоткандай атылып чыккан Аю Гаяны... Урамдагы машина-трактор ыгы-зыгысы... һәм шул ыгызыгы уртасында югалып, ни эшләргә белми аптырап калган Микәй...

Әйтерсең лә боларның берсен дә ул бүген үзе күрмәгән, ә хәзер генә йокы аралаш күз алдына китереп ята. Әмма хәтерне алдап булмый — барысын да күрде һәм ишетте алар. Бәлки шул минутта Азат та шул ук хакта уйлап ята торгандыр әле...

Яр читендә язгы ташуга карап торган Микәй нинди уйларга бирелеп тора иде икән?.. Кибетче Миңнурый апасы сүзләре тагы... Ул буш шешәне нишләтәләр икән, кая куялар — монысы инде бөтенләй башка сыймаслык яңалык...

Аның күңелен аеруча телгәләгәне — Миңлегали абыйсы иде билгеле. Кибет эчендәге чиратның иң очында түзем генә посып торган абыйсы ниләр кичерә иде икән?.. Ул гомер булмаганча кызганыч бер кыяфәттә иде. Иң өсләре басылган, кая куярга белмәгән озын куллары салынып төшкән, бүреге булып бүреге башында чит кешенеке сыман эленеп торган кебек иде. Шуның өстенә, Миңлегаяз белән Азатны күргәч сәер бер кыяфәткә кереп, тагы да куырыла төште һәм энеләрен күрмәмешкә сабышты бит әле...

Ә хәзер, әнә, мич артындагы сәкедә ята, нәкъ шул чакны абыйсы авыр гына кымшанып куйды, икенче ягына әйләнеп ятты булса кирәк. Сәке шыгырдап алгач, яңадан гырылдап йокыга китте. Вакыйфка рәхәт, ул Миңлегаязның янәшәсендә, «мес-мес» килеп, тик йоклавын белә. Кече якта, инде күптән ут сүнгән булуга да карамастан, әтисе белән әнисе

нидер пышылдашып алды. Ул да түгел, өйнең түрендәге чаршау артыннан оекбаш очларына гына басып Айсылу җиңгәсе чыкты. Өйгә төшеп торган ай нурларында аның сылу шәүләсе аермачык булып күренә иде.

— Миңлегали, җаным, тор,— дип пышылдаганы ишетелде аның мич артыннан.— Әйдә, урыныңа барып ят... Итекләреңне сал һич булмаса...

Абыйсы нидер мыгырданды төсле, әмма кеше аңларлык сүз әйтә алмады. Сәке тактасын шыгырдатып боргаланды да янә гырылдый башлады.

— Тор инде, Миңлегали...— дип, тагы да ягымлырак һәм акрынрак итепниләрдер пышылдады Айсылу җиңгәсе.

Миңлегаяз аны кызганып куйды.

— Миңлегали дим, куркам...

Бу юлы инде елар-еламас эндәште Айсылу җиңгәсе. Ә абыйсы аны ишетмәде. Ул, өметен өзеп, кире өй түрендәге үз чаршауларына таба узды. Миңлегаязга хушбуй исләре бөркеп торган эчке күлмәк җиле кагылып үтте. Шунда, кулын суза төшеп кенә, җиңгәсенең иңбашларына таратып салынган озын чәчләренә кагыласы, «курыкма, җиңги, мин йокламыйм, курыкма!»— дип әйтәсе килде Миңлегаязның. Кыймады... Шушы вакыткача уяу булып, олыларны күзәтеп ята дип әйтер җиңгәсе. Уңайсызланды.

Күзләрен четердәтеп йомарга тырышты Миңлегаяз. Ләкин алар йомылырга теләмәде. Бер чите генә булса да ачык кала иде күзләренең. Йокларга, дип сүз бирде үз-үзенә, йокы читләп узды. Чаршауга таба карамаска тырышты, ә баш, үзеннән-үзе күтәрелә төшеп, шул якка үрелде.

Җиңгәсе бераздан чаршау артында тонык кына ут кабызды. Кулына эш алып бәйләргә тотынды. Микәйнең беренче мамыгыннан Миңлегали абыйсына шарф бәйли ул. Аннары Миңлегаязга, Вакыйфка һәм Азатка да бәйләячәк. Тизрәк бәйләсен иде инде. Нинди шарф дигәндә, Микәй мамыгыннан дип, горурланып йөрисе килә иде аның тизрәк. Үч иткәндәй, җиңгәсенең кулындагы энәләр дә бүген теләр-теләмәс кенә кыймылдый. Озак-озак тукташтырып та тора әле. Уйланадыр... Ниләр уйлый икән, белсәң иде. Ник кылен булып төштем боларга, ди микән?.. Юк, алай димәс. Тизрәк шушы төн генә узсын, иртәгәдән үк янә абыйсы белән гөрләшеп тора башларлар. Төне генә озын...

Айсылу җиңгәсенең теләсә нинди үтенечен, йомышын үтәргә әзер иде Миңлегаяз. Аның шул минутта ук җиңгәсенә ниндидер зур яхшылык эшлисе килде. Ләкин нинди? Ничек ярдәм итә ала соң ул?.. Югары Сөннең иң уңган савымчысы булган диләр бит аның җиңгәсен... Безнең авылда да шул гадәтен куа дип сөйлиләр. Миңлегаязның әнә нинди уңган һәм матур җиңгәсе бар... Ул булмаса бик күңелсез булыр иде аңарга. Абыйсы да төшеп калганнардан түгел. Сабан туенда батыр калды. Менә дигән шофер. Армиядән кайтканда түше тулы значок иде. Теләсә кемгә бирәләр ди ул тиклене!..

Малайның уйларын бүлеп, яңадан мич артындагы сәке шыгырдап куйды.

— Су... — дип ыңгыраша иде абыйсы.

Миңлегаяз торырга өлгермәде. Өйнең ике почмагында берьюлы кымшанган авазлар ишетелде — кече яктан әнисе һәм олы якның түрендәге Айсылу җиңгәсе.

Айсылу никадәрле сак булырга тырышмасын, су чиләк төбендә генә булгандыр күрәмсең, ул чүмеч тиюдән шалтырап куйды. Бераздан абыйсының комсызланып эчкәне ишетелеп торды. Һичкем берни дәшмәде.

Юрганына чумып яткан Миңлегаязны яңадан хушбуй исе килеп торган ягымлы җиләслек иркәләп узды. Бу юлы инде кулына эшен алмады җиңгәсе. Чаршау артындагы урыннарын рәтләде, ипле генә бер-бер артлы мендәрләрен кабартып алды. Аннары, кулларын аркасына таба сузып, таратып салынган чәчләре арасыннан нидер эзләгәндәй итте — ике тапкыр әрбет чикләвеге ваткан сыман «черт»ләтеп куйды. Чаршаудагы шәүләдән

карашын ала алмаган Миңлегаяз Айсылу апасының бөтен килеш-килбәтен бер дулкынга, гел алга ашкынган ярсу дулкынга охшатты. Ут сүнеп, өй эче тынып калгач та шул дулкын сурәте озак кына Миңлегаязның күз алдыннан китми торды.

Язгы кояш нурлары бөтен өйгә тулып балкый башлагач кына уянды ул. Шылт иткән аваз да ишетелми. Янәшәсендә яткан Вакыйфтан да җилләр искән. Кабаланып сикереп торды Миңлегаяз. Айсылу апасы фермага киткән булса кирәк. Әтисе дә эштә. Әнисе ишегалдында маллар карап йөри. Вакыйф аның тирәсендә чуала. Миңлегали абыйсы кече якта икән, өстәл артына бер ялгызы утырган да дәү куллары белән маңгаен кочаклап уйга чумган.

Миңлегаяз җиңелчә киенеп ишегалдына чыкты. Вакыйф аңа каршы йөгереп килде.

— Бәләкәй абый, бәләкәй абый...

— Кем тия?!

— Дәү абыйга, беләсең килсә, өр-яңа машина биргәннәр. Үзбушаткыч, беләсең килсә... Бөтен шуфир кызыккан... Ә Мөдир яңа машинаны дәү абыйга биргән. Аңладыңмы?!.

## 11

Нурлы Аланда ул көнне гадәттәгедән күпкә иртәрәк уяндылар. Лапас капкалары шыгырдап ачылуга, нигә болай иртә? дигән сыман, кычкырыша-кычкырыша ишегалларына беренче булып сарыклар йөгерешеп чыкты. Йокылы күзләрен челт-мелт йомып, кәҗәләр кузгалды. Сыер мөгрәп алды. Күрше ишегалларында сыер савып утырган апалар һәм җиңгиләр, сөтле бикәләрен тынычландырырга теләп, әледән-әле билләрен турайтты. Түгелмәсен дигәндәй, сөт тулы чиләкләрен сак кына алъяпкычларына таба елыштырып куйдылар. Җылы сөт исен сизенгән яшь бозаулар сузып-сузып тавыш бирде. Бүгенгә җитәр дигәндәй, соңгы тапкыр әтәчләр хәбәрләшеп алды. Кетәклектән, пырхылдашып, берәм-берәм тавыклар коелды. Каз-үрдәк капка астыннан урамга чыгу җаен эзләде. Йокылы күзләрен уа-уа, ишегалды һәм капка тирәләрендә сыек чыбык тоткан малайлар кайнашты... Көтү чыккан беренче көн иртәсе шулай башланды.

Бераздан бер-бер артлы капкалар ачылып, урамга төркем-төркем мал-туар чыга башлады. Әле төнге талгынлыктан арынып та җитмәгән урамнар кинәт җанланып китте. Шул арада бәрәннәрен күздән югалтып өлгергән сарыклар шар ярып кычкырырга тотынды. Сыерлар, бозауларын юксынудан, әле генә ябылган капкаларга муеннарын сузып мөгрәде. Мал куарга чыккан апалар, ярты гомер күрешмәгән кешеләр сыман, берберсе белән бик тәмләп гәпләшергә, хәл-әхвәл белешергә кереште. Бөтен авылга, озакка сузылган кышкы йокыдан уянган табигать сыман, бер җилпенүдә кинәт җан керде. Һәммә урам һәм тыкрыклар бергә килеп кушылган чатта, көтүнең кайда җыелуын белгертеп, чыбыркы шартлады. Кыш буе бер-береbelән күрергә зар-интизар булган сыерлар шунда төркем-төркем булып җыйнала башлады. Дәү мөгезлеләрнең аяк арасында буталып, кая барып бәрелергә белмичә арлы-бирле сугылган дулкын сыман, сарыклар төркеме хәрәкәт итте. Кәҗәләр исә, үз урыннарын һәм дәрәҗәләрен белеп, каралты-кура тирәсендә өелгән бүрәнәләр янында кайнашты, усак каезлады. Икенче берәүләре яңа каезланган бүрәнәләрнең сусыл тәненә үз келәймәләрен суга барды.

Микәйнең шул тикле мал-туарның бергә туплануын әлегәчә күргәне юк иде. Шуңа гаҗәпләнеп торган арада, урамнардан һаман саен төркем-төркем килә торган дәү мөгезле һәм бөдрә йонлылар аны төрле яктан уратып та алган. Кысынкылыкта калу, билгеле, ошамады аңа, әмма ул бөҗрадан чыгу да җиңел түгел иде. Атлап китү түгел, урыныңнан кымшанырга да өлгермисең, «бә-ә-әй, күзең чыкканмы әллә-ә-ә, кая төрте-

нәсең» дигәндәй, бөдрә йонлылардан я тегесе, я монысы дөнья бетереп кычкырырга керешә.

Көтү кузгалып авыл башына җиткәч кенә төркемнең бер читенә килеп чыгу җаен тапты Микәй. Һәм шунда ук үзенең әйләнә-тирәсендә, җанга рәхәт биреп, тамак төпләрен кытыклап торган җылы төс, ягымлы төскә төренгән киңлекне күреп хәйран калды. Бу кадәр мул җылы һәм ягымлы төсне әле аның күргәне юк иде. Күрү генә түгел, ул хакта хыялланганы да булмады. Аны алгысытып торган якты, матур дөнья төшләренә әлегәчә гел ак төстә булып кына керә иде бит. Тоташ бер ташкын сыман алга таба аккан көтүдән аерыласы — дәү мөгезлеләрне һәм көдрә йонлыларны ташлап качасы, иксез-чиксез яшеллек эченә кереп адашасы, бәкәлләре талганчы шушы җылы һәм ягымлы тау читләре, үзәннәр буйлап йөгерәсе, чабасы килде аның. Күңеленә килгән ният аны шундук читкә каера башлады. Әмма гел уйламаганда борын төбендә генә иләмсез озын чыбыркы шартлады. Борылып караса, ни күрсен — кеше. Дәү-дәү атлап аның артыннан ук җитеп килә иде инде ул. Микәй шундук әнкәсе кисәтүен хәтерләде һәм сискәнеп куйды: «Кешедән сак булыгыз, бәтиләрем... Кешедән!» Ашыгакабалана ул киредән бөдрә йонлылар төркеменә елышаң төште һәм, башын игән булып, тын гына баруын белде — шартлый торган чыбыркы тоткан кешенең узып китүен көтте.

Кеше, аның ниятен каян белгән диярсең, узмый да узмый гына бит, авызыннан әче төтен өреп тик йөренә аның тирәсендә. Тагылган сыман, янәшәсеннән Микәйне күзәтеп бара. Хәтта, мин монда дигәндәй, иелә төшеп берничә тапкыр аның аркасыннан да сыпырып алды. Ә бөтен әйләнә-тирәне уратып алган теге ягымлы төс, җылы төс һаман саен үзенә чакырып, әйдәп тора. Күзләрне камаштырып кызыктыра. Микәйнең түзәр хәле калмады, йөгерә-чабасы килүдән бәкәл очлары сызлагандай итеп, тынгылык бирмәде. Мөгезләреннән бәреп торган гайрәт очкыны артканнан-арта барды. Һәм ул кинәт кенә, арт санына бөтен авырлыгын ташлап, кушаяклап этенде дә, шул җылы һәм ягымлы яшеллек кочагына ташланырга теләп, алга ыргылды. Янәшәсендәге көдрә йонлылар аның бу сәрсәнлегеннән сискәнеп читкә тайпылды, дәү мөгезлеләрнең аяклары буталып алды. Кеше кулындагы озын чыбыркы да хәрәкәткә килде. Ләкин, муен турында гына шартлау авазы чыгарып, бер ягын көйдереп алган чыбыркы усаллыгы гына туктатырлык идеме соң аның бу ашкынуын...

Микәй, алны-артны, уңны-сулны белми, аяклары кая илтсә, шунда томырылды. Тоякларын иртәнге сусыл үлән иркәләде, күкрәкләренә салкын рәхәтлек алып килгән җил сарылды. Күзләрен җылы да ягымлы да булган яшел чиксезлек берөзлексез алгысытып торды. Үзәнлеккә чабып төште ул, аннары, аяклары ярсуын басарга теләгәндәй, янә сөзәк үргә томырылып менеп китте. Югарыга менеп җиткәч, тагын түбәндәге яшел киңлекләргә ашкынды. Үз күләгәсен узарга теләп, тау битеннән чабып үтте Микәй. Аннары үзән буйлап җитез җилне куып китте. Дөньяның ягымлылыгы һәм җылылыгы тәмам исәрләндергән иде аны. Әгәр кай якта икәнен белсә, ул хәзер урман аръягындагы ак юлларга гына түгел, әнкәсе белән туганы калган ак кыялар иленә дә «эх» дигәнче барып җитәр — ак нур булып үзенә әйдәп торган бәхетне куып тотар иде. Аның аякларында җегәр, күкрәкләрендә көч һәм мөгезләрендә гайрәт ташып торганда куып тотмыймы соң...

«Аю-бүредән качып була, кешедән качу гына кыен, бәтиләрем»,— дигән иде әнкәсе. Ә ул әнә бүредән дә качты, кешедән дә. Аны тотып торырлык, аны ирексез итәрлек көч бармы соң! Йөгергән саен йөгерәсе, берөзлексез томырылып чабасы, шушы җылы яшеллекнең чигенәчә барып җитәсе килде Микәйнең. Ул да түгел, бу уеннан кайтып, кырт борылып кире йөгерде. Бу яшел иркенлекнең һәм ирекнең чиге булмасын иде... Юк, кирәкми аңар андый чик һәм чикләүләр. Шушы җылы һәм ягымлы яшеллек буйлап туйганчы уйнап йөгерәсе килә аның.

Әйләнә-тирәдә һичбер җан иясе юк. Тынлык... Иркенлек... Чап та чап кына, бернинди тыю һәм чикләүләр юк. Әнкәсе күрергә теләгән бәхет тә бәлки шундый була торгандыр әле. Ул ашкынган ак кыяларның итәгендә дә шундый ук киңлекләр җәйрәп ятадыр.

Үз күләгәсен куып, җил белән узышып чабудан бераз күңеле булгач, тау итәгендә үскән үләнлеккә туктап ашап алды Микәй. Челтерәп аккан инешкә төшеп сусавын басты. Һәм су эчеп туйгач, инеш аркылы салынган асылмалы күпер өстенә менеп, бер тын тирә-юньне күзәтеп торды. Дөнья һаман саен матурая гына бара иде. Үзәнлек һәм тау итәкләре тагы да җылырак һәм ягымлырак булып киткән. Мөгез очларында балкып кояш көлә, күпер астындагы су өстендә дә шул ук кояш аның күзләрен чагылдырып-чагылдырып уйный. Һәм шул нурлар аны яңадан су янына әйдәде.

Янә инеш читенә төшеп басты Микәй. Вак ташлар һәм ком бөртекләрен уйнатып челтерәгән суга карап торды. Борынын төртеп эчим дигәндә генә ул, бая кояш нурлары балкып көлгән төштә, үз шәүләсен күреп хәйран калды. Судан аңар гайрәтле дәү тәкә карап тора иде. Шулай зур булып үскәнлеген үзе дә абайламый йөргән икән ич. Киң булып алга чыккан күкрәкләр, куе сакал, таза сыйраклар — һәммәсе анык ич. Ә мөгезләре, мөгезләре ни тора!.. Мондый нык һәм таза мөгезләрне әле берәүдә дә күргәне юк иде аның, ерак тауларда калган әнкәсендә булса гына... Шулай әле бер яны, әле икенче яны белән борылып-борылып сокланды ул мөгезләреннән инешкә төшкән шәүләгә карап. Башын югары чөеп, күкрәкләрен киереп, сыйракларын турайтып карап торды — үзен иң зифа һәм мәһабәт кәҗә тәкәсе дип хис итте. Үз-үзенә сокланып бер тын торгач, мөгезләрен түбәнгә төбәп, судагы күләгәсен сөзәргә иткән булды. Үзеннән дә гайрәтле һәм җегәрле кәҗә тәкәсе юктыр төсле тоелды. Шул җегәрне кая куярга белмәүдән, тояклары белән чәчрәтеп, суны кыйный башлады.

Янә ике иңбашына канат чыккандай булды Микәйнең. Кушаяклап су читенә сикерде дә, бәкәлләре ашкынуын тыя алмыйча, инеш агышына каршы чабып китте. Киң күкрәкләре белән җылы, рәхәт һава дулкынын сөзеп барды, мөгезләре белән җилне ярды. Дүрт тоягы алмаш-тилмәш кушаяклап җир шарын какты. Тирә-яктагы яшел чиксезлек үзенең җылы назы белән аңа берөзлексез гайрәт һәм көч өстәп торды. Ул чапты да чапты. Мондагы ирек һәм иркенлеккә хәйран калып чапты. Язгы бәхетеннән, яшеллектән, яшьлегеннән айный алмый чапты...

Онытылып тагы күпме шулай чапкан булыр иде Микәй... Инеш кискен борылыш ясаган турыда, үги ана яфраклары гына үскән кызыл яр читендә, аны бер төркем кардәшләрен күрү генә тыелырга мәҗбүр итте. Үзе кебек үк көтүдән качкан «кәҗә взводы» иде бу. Микәйнең шулай тилереп чабуына гаҗәпләнгән идеме алар, аның сәер кыяфәтенә, көмеш ука сыман елкылдап торган мамыгынамы? Төптән юан чыгып, шактый саллы күренгән мөгезләренә киттеме исләре? Һәрхәлдә, тау читендә дөньяларын онытып йөргән кардәшләре, шым булып, карашларын аңарга текәгән иде.

Микәйнең ашкынып, берөзлексез алга ыргылып торган аяклары туктап калды. Нindидер сәер, үзенә дә ачык кына аңлашылып җитмәгән инстинкт туктатты бугай аны. Ул кызыл яр читенә текәлде. Кызыл яр читендәгеләр аны күзәтте. Шулай күпме үткәндер һәм тагы күпмегә сузылган булыр иде әле бу карашып тору... Кәҗә төркеменнән берсе — иң дәү гәүдәлесе — кузгалып куйды һәм үзе артыннан башкаларны да әйдәп, читкә борылды.

— Ме-е-е,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә тонык аваз чыгарып.— Бер дә харап инде, исегез киткән...

Башка кәҗәләр, буйсыну белдереп, шундук аңар иярделәр. Ләкин дәү кәҗә артыннан кызыл яр читен калдырып киткәндә, арадан берсе, иң соңгы булып кузгалганы, кабат-кабат каерылып Микәйгә таба моңсу караш ташлады. Ул җыйнак гәүдәле нәфис кәҗәгә Микәй баштук игътибар

иткән иде. Ә менә тау сыртына күмелер алдыннан соңгы мәртәбә каравында ул кәҗә аңарга әллә нидән генә үз һәм якын булып китте. Аның күзләрендә чагылып киткән якты нур Микәйнең күз карашын өтеп узды, бәгыренә кадалды.

Кәҗәләр китеп барды, күздән югалды. Инеш читендә ул тагы берьялгызы торып калды. Моңсу булып китте аңарга шунда. Тирә-юньдәге җылы яшеллек тә тоныклана төште. Иркенлек белән тынычлык та онытылды. Микәйнең җаны тынгысызлана башлады. Ялгызлыкны аз татымады югыйсә, моңарчы да бу илдә ул япа-ялгызы иде. Әмма бу дәрәҗәдәге ялыктыргыч һәм кинәт басып киткән ялгызлыкка беренче кат юлыгуы. Үз-үзен белешмичә, инешне аркылы сикереп чыкты да әле генә кардәшләре китеп югалган сырт өстенә менеп басты.

Кәҗә төркеме ерак китәргә өлгермәгән иде әле. Әмма бу сәер тәкәнең әрсезлеген сизеп алган теге иң дәү кәҗә аны күргәч яңадан кабалана башлады. Башкаларны да үзе артыннан калышмаска әйдәп, башын болгый-болгый тизрәк читләшергә ашыкты ул. Тау читендә берьялгызы торган Микәй моңсу гына күзәтүендә булды. Аларның үзен читләтүенә кәефе кырылды аның.

Шунда, теге җыйнак гәүдәле нәфис кәҗә, тукталып, янә Микәйгә таба борылды. Бер тын икәүдән-икәү карашып торды алар. Әйләнә-тирәнең яктыра баруын, дөньяның баягы җылы яшеллеккә кайтуын тойды Микәй. Әлеге караштан аның күкрәкләренә кайнар агым, бәкәлләренә көч, мөгезләренә гайрәт ташыды. Үзенә дәрт һәм куаныч алып килгән кәҗәгә таба сак адымнар белән якынлаша башлады Микәй. Хәер, ул якынлашмады, аны нәфис кәҗәнең сихерле күз карашы тартып китерде.

Үзенең яңа танышына сокланып туймады Микәй. Муеннарын турайтып, мөгезләрен күккә чөеп, аны чит-читләп әйләнеп чыкты. Бер урында гына басып тора алмады. Ул кәҗәгә тыныч кына карау мөмкин түгел иде шул. Җыйнак кына мөгезләр, тар маңгай, туры аяклар һәм бигрәк тә шомырт сыман кара күзләр һәм кара туны аны моңарчы ул күргән һәммә тереклектән аерып тора иде. Микәйнең аңарга җылы итеп дәшәсе килде. Башын аның муенына салып, һич булмаса мөгезләре белән аның аркасын тарап, озак-озак янәшәсендә торырга иде. Ләкин кабалана-кабалана ары китеп барган кәҗәләр Шомырткараны калдырырга теләмәделәр. Тагы шул әлеге дә баягы алдан элдерткән дәү мөгезле кәҗә тынгысызланды.

— Мә-ә-ә, Шомырткара, сине көтәбез...— диде ул кырыс кына.

Шомырткара бер Микәйгә, бер дәү мөгезле кәҗә ягына карады. Шулай икеләнеп, ни эшләргә белми торгач, теләр-теләмәс кенә урыннан кузгалды. Аяклары кардәшләренә таба тартты, ә күзләрен Микәйнең көмеш ука сыман елык-елык килеп торган гайрәтле гәүдәсеннән аера алмады.

Микәйнең дә шушы япан кыр читендә берьялгызы торып каласы килми иде. Китмә, дип әйтәсе килеп, ул Шомырткараның каршысына чыгып басты. Тату һәм ягымлы карашлары очрашып, янә алар икәү генә торып калды. Ләкин бу бер мизгел генә иде. Шак-шок килгән тояк тавышлары Микәйне артына борылырга мәҗбүр итте. Аның өстенә аткан ук кебек ыргылып, мөгезләре белән сытып китәргә әзер булган теге дәү тәкә килә иде. Күңелендә явызлыкка һәм сөзешүгә һичбер урын булмаган Микәй бу көтелмәгән хәлдән югалып, каушап калды. Дәү кәҗәнең ярсуына каршы торырга әзер түгел иде ул. Кире борылып чабар чак та түгел. Бер читкә тайпылып, күзләрен аңарга текәп торган Шомырткара алдында сынатырга ярыймы соң?.. Шуның өстенә әле тагы күпме кәҗә күзәтеп тора. Билгеле инде, ул кәҗәләр һәммәсе дәү тәкә яклы, аның җиңүен телиләр, һәм шуңарга аз гына да шикләнмиләр.

Тик менә Микәйнең яңа танышы Шомырткара ни уйлый, ул кемнең җиңүен тели икән?.. Шуны белергә теләгәндәй, берьялгызы читтә посып торган Шомырткарага күз салды ул. Үзе өчен түгел. Микәйне кызганудан шулай бөрешеп, мескенләнеп калган иде булса кирәк Шомырткара. Һәрхәлдә, Микәй шулай дип аңлады.

Ә дәү тәкә күптән инде аның каршысына килеп баскан, үзе белән көч сынашырга чакырып, аны көтә иде. Алгы аяклары белән җир тырнап, муен өстендәге йоннарын кабартып, очлы мөгезләрен аңарга төбәп куйган бу иләмсез һәм шыксыз тәкәнең кан сауган күзләреннән генә дә куркып качарлык... Ләкин качарга ярамый! Арт аякларын ипләбрәк куяр өчен җайлы урын эзләде Микәй. Сөзешәсе килми иде аның, ә сөзешергә кирәк. Ни кадәрле генә иләмсез һәм шыксыз булмасын, әлеге дәү тәкәдә бер ачуы юк иде бит аның. Ашыкмады, бәлки тынычланыр, дип көтте Микәй. Тик ул уйлаганча барып чыкмады. Аның шулай икеләнеп торуын куркуы дип белдеме, качарга ният итүе дипме, нәфрәтен басарга ярсып атлыккан дәү тәкә аңар җан-фәрман китереп төртте. Гел көтмәгәндә, уйламаганда булды. Микәй үзенең зур хата ясаганлыгын аңлады — артында текә кызыл яр булуын хәтердән чыгарган икән бит ул. Дәү тәкәнең авырлыгыннан аяклары, ирексездән, артка чигеп куйды, ул үзенең кызыл ярдан тәгәрәп төшеп китүен сизми дә калды.

Инеш читендәге вак ташлар өстенә әүмәкләнеп барып төшкәч тә бераз аңыша алмый торды әле. Аяклары, яңаклары сыдырылган, йомшак мамыгы арасына һәм колакларына кызыл балчык, ком тулган. Күзләрендә, менә-менә тамарга әзер булып, кайнар тамчылар мөлдери. Ә югарыда, кызыл яр читендә, күкрәкләрен киереп, ике япьле сәнәк сыман мөгезләрен күккә чөеп дәү тәкә басып тора. Ул да түгел, яр читеннән кәҗә көлкесенә калган сәер яшь тәкәне күрергә килгән башлар күренде. Алар берсен икенчесе уздырышып мәэлдәшә — җиңүчене мактый, җиңүче тирәсендә көязләнеп боргалана. Күз читләре белән генә түбәнгә дә мыскыллы караш ташлап алырга өлгерделәр. Җиңүче тантана итә иде.

— Мә-ә-ә,— дип алды ул, күкрәген тагы да киерә төшеп вәкарь белән генә. — Бер дә харап икән! Исегез киткән иде...

Ә Микәй — текә кызыл ярдан әле генә тәгәрәп төшкән Микәй — кагынырга да онытып тик басып торуын белә. Мәңге шулай дәвам итәр кебек иде, хурлык һәм гарьлекнең чиге-чамасы юк. Бу кызганыч халәтеннән ул котылыр идеме икән?.. Әгәр шунда кызыл яр читеннән Шомырткараның нәфис маңгае, җыйнак мөгезләре күренмәгән булса...

Чарасыз калган Микәй Шомырткараның карашын тотып алды. Мизгел эчендә елкылдап киткән ул караш кызгану түгел, ышаныч белән тулы иде. Шул караш аның тән авыртуларын оныттырды, шул караш аның әрнүләрен юкка чыгарды. Шул караш аның монда берьялгызы гына түгел икәнлеген искәртеп, Микәйнең оеп барган канына яңадан кайнар учак якты. Бөтен тәненә һәм мөгезләренә ташып-ташып, актарылып гайрәт тулганны тойды ул шунда. Иңнәренә тагын канат үсте. Һәм бар гарьлек, кимсенүләрен берьюлы онытып, кире кызыл яр өстенә менеп басты ул.

Күзләренә ак-кара күренмәде. Аяклары басып торган туфракны тоймады. Аның өчен башка һәммә кәҗәләр аерым шәүлә булып кына калдылар. Шомырткара булып Шомырткараның да кайдалыгын белмәс хәлдә иде. Күз алмаларының үзәгендә бары аны — үзен хыянәтчел төстә кызыл яр түбәсеннән тәгәрәткән дәү тәкәне генә тотты.

Дәү тәкә көч сынашырга әзер иде. Арт аякларын җәя төшеп терәгән дә, әле сиңа аз булдымыни дигәндәй, мөгезләрен тырпайткан да тик тора.

Бу юлы да, беренче булып, ярсуын тыя алмаган дәү тәкә китереп төртте. Микәй аның бу сөзүеннән кымшанмады да, ул әзер иде инде. Ник шунда аяк астындагы җир убылмый яисә өстенә тау ишелми — ул җиңәргә тиеш! Хәлиткеч сикереш ясау нияте белән Микәй бөтен гәүдәсен пружина сыман җыерып китерде һәм үзен кыерсытучыга ташланды. Дәү тәкәнең сеңере нык булып чыкты, ул да бирешмәде, аякларында басып калды. Алар маңгайны-маңгайга, мөгезләрне мөгезгә терәп сөзешергә керештеләр. Шак та шок бәрелүдән мөгезләр, аварга җыенган агач сыман, шыгырдап, сыкрап-сыкрап куйды. Мөгезләрдән очкын чәчрәде, күз төпләрендә ут

күренде, күкрәкләрендә ялкын дөрләде. Тояк асларында җир актарылды, зәңгәр күктә нурлар чайкалып торды...

Гомерендә үзенә мөгез күтәрүчене күрмәгән дәү тәкә бу сәер җан иясеннән болай ук көтмәгән иде, әлбәттә. Тәмам әлсерәде, аякларын тоймый, мөгезләрен буйсындыра алмый башлады. Тик бирешергә уйламады. Үзенә каршы торырга сәләтле тәкә табылуга ышанмады. Ярсыганнан-ярсый барып, Микәйне янә кызыл яр читенә таба кысрыклый башлады. Әмма бу юлы яшь тәкә аңардан елгыррак булып чыкты, бер ыргылуда читкә тайпылды да, аның үзен шул кызыл ярга таба төрткәләргә тотынды. Кабаланды дәү тәкә, боргаланды, әмма берни кыла алмады — арт аяклары инде кызыл яр читендә иде. Башын тотарлык, мөгезләрен күтәрерлек хәле дә калмаган иде үзенең. Кан баскан күзләрен күтәрә төшеп, чарасыз карашын Микәйгә төбәде ул.

Аны кызыл ярдан тәгәрәтү өчен хәзер гайрәте артканнан-арта барган Микәйгә җиңелчә хәрәкәт ясап тагы бер кизәнү җитә. Ләкин алай итмәде Микәй, артка чигеп, дәү тәкәнең яңадан уртага чыгуын көтте. Бу изгелекне бөтенләй көтмәгән тәкә бер тын аңыша алмый торды. Кызыл яр астына тәгәрәүдән исән-сау котылу куанычыннан кәҗәләренә күз төшереп алды. Алар янында сынатырга ярамый, дигән уй ярып үтте аның мөгез төпләрен. Әмма бөтен гәүдәсе белән җыелып, башын югары чөйгән, мөгезләрен сөзешергә әзерләп куйган Микәйне күрүгә яңадан бәкәлләре калтыранып куйды. Юк, булмый, күпме генә тырышмасын, бу хикмәтле тәкә затына каршы торырлык җегәр калмаган иде инде аңарда. Шуны яхшы аңлаган дәү тәкә кире борылды, һәм башын түбән салындырып теләр-теләмәс кенә авыл ягына таба китеп барды.

Ул көнне авылга шактый соң, эңгер-меңгер вакыт җиткәч кенә кайтырга чыкты Микәй. Башын горур тотып, вак-вак кына адымнар белән нык басып, иң алдан ул кайтты. Аңардан алга чыгарга берәү дә кыймады. Артыннан кәҗәләр төркеме ияргән иде. Янәшәсеннән, аз гына калыша төшеп, Шомырткара атлады.

## 12

Җил исте, сулар акты — вакыт үзенекен итте. Ай үсәсен көн үскән Микәй иң дәү кардәшләреннән дә калкурак, гайрәтле бер тәкә булып үсеп җитте. Нык, калын сыйраклар өстендә торган тыгыз тән, туры муен һәм текә маңгай, елык-елык килеп күзләрне камаштырып торган көмешсу мамык дисеңме, бер пар чалгы сыман һава ертып торган туры озын мөгезләрме — болар бары да тик аңарда, Микәйдә генә. Көтү җыелган урынга ул төшми торып, кәҗәләрне урыннарыннан кузгатырмын димә. Авылдагы барлык кәҗә көннән-көн буена аның тирәсендә. Көтүчеләр дә, авыл кешеләре дә күнекте моңа. Микәй күренә икән, димәк көтүдән бер кәҗә дә качмаган дигән сүз. Микәй кая китсен, болай да һәрчак иректә ич. Иртәнге тынлыкны ертып, көтүнең ук очы сыман, беренче ул атлый. Чыкта коенган ямь-яшел үзәнгә беренче булып ул аяк баса. Чыклы үләндә беренче булып аның дүрт тоягы эзе кала. Һәр иртәнең сусыл үләннәрен иң элек ул татып карый. Инеш аркылы чыкканда аз гына да болганмаган йөгерек шарламага сакал очын тидереп, көмештәй саф суны да башкалардан элегрәк ул эчә.

Микәйнең инде тынгылык белмәс җаны да тынычланып килә. Алай гына да түгел, үзен тулы бәхеткә ия тәкә итеп хис итә ул хәзер. Шундый тыныч һәм якты көннәрне тоташтырган гадәти бер төндә, татлы йокысыннан бүленми генә, төш күрде ул. Микәйнең хәтерендә җуела барган үткәнне, тәмам онытылган бер хыялны яңартып, яңадан балкытып, дөрләтеп җибәргән төш булды бу.

Имеш, ул үзенең кәҗәләре белән, ерак аралар үтеп, Ак кыялар илендәге ап-ак киңлекләргә барып чыккан. Бөтен әйләнә-тирә ап-ак нурда коена икән. Тавыш-тын юк. Янәшәсендәге кәҗәләрнең андый аклыкны беренче

генә күрүләре икән — исләре китте, һәммәсе берьюлы телдән язды. Бу нинди аклык, диләр. Бу нинди матурлык, диләр. Син булмасаң, без бу ак кыяларны әле кайчан һәм ничек күргән булыр идек, диләр. Син үзең дә безнең шул кыялар сыман нурланып балкыйсың, шул кыялар кебек горур, шул кыялардай тәкәбберсең, Микәй, диләр. Мактап һәм олылап туймыйлар аны.

Микәйнең мактауларга исе китми. Әнә хәзер дә зур булмаган кыяташ өстенә менеп баскан да, карашларын еракка төбәп, тик басып тора. Янәшәсендә торган Шомырткарага гына ишетелерлек итеп дәште ул шунда.

— Шомырткара, син шушы ак таулар илендә калырга теләр идеңме?..

— Белмим шул,— дип җавап кайтара Шомырткара һәм бераз уйга чумып торганнан соң өстәп куя: — Монда яшел хәтфә сыман иңкүлекләр, урман-кырлар, челтерәп аккан шаян инешләр дә бармы соң?

— Монда ак кыялар, мәһабәт шарлавыклар, иркен һәм тыныч ак киңлекләр бар, Шомырткара...

— Иркенлек ул яшел була... Сусыл чирәм үскән инеш буйларына җитәме соң...

— Мондагыдай аклык бер кайда юк. Ак төс — бәхет төсе, Шомырткара.

— Ак төс матур анысы... Ә яшел төс ашата һәм җылыта да...

— Яшел үләннәр дә булса, шушы Ак кыялар илендә генә калыр идеңме, Шомырткара?

— Тоякларны иркәләгән йомшак туфрак сагындырыр. Монда гел ком, монда гел таш, Микәй...

— Кыя очларындагы салкын рәхәтлек һәм сафлыкны белмисең әле син, Шомырткара.

— Яшел тугайларның җылылыгы сагындырыр, дим...

— Әгәр мин шушында калсам, син ни сайлар идең, Шомырткара?

— Синең белән бергә җылы туфраклы яшел тугайларны, йомшак сулы инешләрне эзләп китәр идек, Микәй.

... Төшнең шул урынында, кинәт, лапас капкасы шыгырдап ачылды. Ике ут арасында чарасыз калган Микәй уянып китте. Ишегалдында иртәнге ыгы-зыгы башланган. Өй каршындагы ак каеннарның бөдрә тармакларыннан мөлдерәп торган яшел нурлар коела. Микәй әле генә игътибар итте: җанына аеруча үз булган, аклыклары белән берөзлексез аның карашын иркәләп торган каеннар дөньяга яшел нур чәчә икән бит. Ак каеннар дөньяга яшел нур булып тама икән. Шомырткара, яшеллек дип, юкка гына өзгәләнми, димәк. Ак төс һәм яшел төс алар бербөтен түгелме соң?... Бер үк иркенлек, хөрлек һәм бәхет төсләре ич! Ак һәм яшел — Микәй белән Шомырткара дигән сүз. Аларны бер-берсенә каршы куеп Микәй ялгышкан икән ич... Кышын ап-ак булган урман-кырлар да җәйгә очраклы рәвештә генә ямьяшел төскә кермәгән булса кирәк. Дөньяда ак белән яшел һәрчак бергә, һәрчак янәшә. Микәй белән Шомырткара да шулай.

Шулай итеп, урман аръягындагы ак юллар һәм шул юлларның очындагы ак кыялар турындагы ак хыял аның хәтерендә янә калкынып алды. Шул ак дөнья торган саен ешрак искә төшеп, билгесез ераклыкларга алгысытып, ашкындырып торды. Микәй түзде, үзенең ни өчен һәм ниләр уйлап өзгәләнүен берәүгә дә, хәтта Шомырткарага да сөйләмәде. Ул вакыт-вакыт әйләнәтирәдәге яшеллекне, яшел үлән өстендә көязләнеп терт-терт басып йөргән кәҗәләрне дә күрмәс хәлгә килә иде. Мөгез очлары сыкрый, тояклары кымырҗый, күзләренә мөлдерәмә бөртекләр тула иде кайчак. Микәй барыбер түзде.

Түзде. Әмма бу халәтнең дә чиге булырга тиештер бит. Көннәрдән бер көн, көтү авылны чыгып барганда, кинәт кенә борылып ындыр ягына каерды ул. Аның алабута һәм тигәнәкләр арасына кереп шылганын янәшәсендәге кәҗәләр дә абайламый калды. Әмма күзләре күрмәсә дә, күңелләре сизде — башка кәҗәләр дә бер-бер артлы Микәй артыннан юк булдылар.

Көтү үз юлы белән китеп барды. Аның койрыгында йокымсырап барган көтүче берни күрмәде, берни сизенмәде. Кәҗәләрне җир упты диярсең... Әле

генә көтү башында иделәр, күз ачып йомган арада үзләреннән җилләр исте. һич югында берсе адашып калса икән...

Бакчалар артыннан бер тын баргач, зур булмаган уязлык башлана. Шунда җиткәч кенә артына борылып күз салды Микәй. Тыннары бетеп, үзе артыннан чабып килгән кәҗәләрне күргәч, күкрәген киерә төште, муенын турайтты, мөгезләрен югары чөйде. Барысы да ул уйлаганча барып чыккан иде, димәк. Канәгатьләнү кичереп, җәт-җәт атлап китте Микәй. Офыкта беленер-беленмәс кенә күренеп торган урманга төбәп барды. Барды да барды... Бәкәлләрен иркәләгән сусыл үләннәргә, ак башларын моңсу тибрәндергән ромашка һәм әнисләргә исе дә китмәде, уенда урманга барып җитү генә иде. Туяклары тигән җирдә тия, тимәгән җирдә — юк. Шул урманга җитсә, аның ярсуы һәм ашкынулары бераз басыла төшәр, ул тынычланыр, аяклары аны тыңлый башлар кебек иде. Чөнки үзен ак юллар һәм ак кыялардан аерып торган бердәнбер нәрсә — шул урман булып тоела иде аңар. Тизрәк җитәргә дә шул урманга, аннан инде хыялындагы ак дөньяга ничек бару юлын ул һичшиксез табачак!

Микәй шул дәрәҗәдә ашкынып бара иде ки, урманга төбәп кузгалганнан бирле әле артына борылып та караганы юк. Аның җитез һәм дәү адымнарына өлгерә алмаган кәҗә көтүе инде шактый сузыла, таркаулана төшкән. Кая бару, максатларының нидән гыйбарәт булуы хакында кызыксыну түгел, күкрәк тутырып сулыш алырга да аралары булмады. Кая барудамыни соң хикмәт — кем артыннан баруларын яхшы беләә ич алар. Карашларын нурландырып, тәннәрен җилкендереп үзе артыннан әйдәүчеләре бар. Ул — Микәй! Аннан калышу бу җылы һәм нурлы җәйге көннең иң зур матурлыгыннан, куанычыннан һәм назыннан калышу дигән сүз.

Ераклардан ук чакырып, алгысытып торган урман читенә җиткәч, Микәй туктап калды. Кая таба хәрәкәт итәргә икән дигән сыман, як-ягына карангалап торды. Ул арада күз күреме ераклыкта калган кәҗәләр дә берәм-берәм куып җитте.

Кәҗәләрнең барысы да куып җитте. Кайчандыр дәү тәкә дигән мәртәбәле исеме булган кәҗә генә күренмәде. Соңгы араларда гел боекты, мескенләнеп калды ул. Дәү тәкәнең тигәнәк һәм шырданга батып, асылынып төшкән озын йоннарын күргән саен Микәйнең күңелендә кызгану хисе уянып куя иде. Теге чакта үзен кызыл ярдан төртеп төшергән өчен ул бит аңарга һичнинди ачу-фәлән сакламый иде. Алай гына да түгел, ут уйнатып йөрергә тиешле тәкәнең шулай кинәт кенә сула баруында үзен гаепле итеп тоя. Дәү тәкә бүген дә кәҗә көтүеннән аерылып калган. Димәк, ул бүген дә берьялгызы. Ялгызлыктан авыр ни бар?!. Микәй моны яхшы белә.

Берәүне дә рәнҗетәсе, берәүгә дә кайгы китерәсе килми иде аның. Ә Дәү тәкә, Микәй аркасында, кимсенергә, ялгызлыктан җәфа чигәргә мәҗбүр. Аның ни гаебе бар?! Һәр кәҗәнең бәхетле буласы килгән кебек, ул да бәхеткә лаек ич. Ул да үзенә текәлгән елтыр күзләрнең кадерен белергә тели торгандыр. Берсеннән икенчесе нәзакәтлерәк кәҗәләр белән иңне иңгә терәп янәшә торасы — иркәләнәсе, назланасы килә торгандыр. Ләкин, әнә, кәҗә көтүеннән аерылып ул бер ялгызы калырга мәҗбүр. Үзеннән гайрәтлерәк һәм көчлерәк яшь тәкә алдында буйсыну белдерүе бу аның. Микәй булган җирдә миңа урын юк, дип әйтүе. Нигә көчкә, гайрәткә карап бүленә икән бу бәхет?.. Әгәр мөмкин булса, Микәй аңар һич икеләнүсез ярты шатлыгын, ярты бәхетен бүлеп биргән булыр иде. Кәҗә көтүеннән бер ялгызы аерылып калган тәкә бик тә кызганыч тоелды аңар.

Әмма аерылып калган Дәү тәкә язмышын кичерергә теләр идеме икән ул? Һич югында аның язмышын уртаклашырга үзен көндерә алыр идеме икән?.. Юк! Юк, әлбәттә! Көчсез булуга караганда, көчле булу меңкабат артык... Каршылыклы уйларыннан арынырга ашыгып, бөтен гәүдәсе белән җилпенеп куйды ул. Сыйракларын турайтты, күкрәкләрен киерә төште. Мөгезләрен күккә чөйде. Микәйнең җилкенүен күреп, кәҗәләр җанланып

китте, хәрәкәткә килде. Урыннарында гына тора алмый, аның бер алдына, бер артына чыктылар. Кузгалырга кыенсынганнары да гел таптанып торды, көязлектәнме, койрыклар җыела төште. Кара янып пешкән пар-пар чиясыман күзләр берөзлексез мөлдерәде. Микәйнең болай да ташып торган гайрәтен ярсытып мөлдерәде күзләр. Бәхетләре ут булып янды, су булып ташыды, урман булып шаулады. Бергәлекнең, тазалыкның һәм сәламәтлекнең, табигый инстинктларның олылыгы һәм гүзәллеге турында лепердәшеп серләште урмандагы һәр яфрак.

Урман читендәге ямьле бер аланда көннең ничек узып киткәнен дә сизми калды алар. Татлы төштә генә булып узды, ахры, мизгелгә тиң ул бәхетле сәгатьләр. Вакыт узуын Микәй эңгер-меңгер җитеп, караңгы эленгәч кенә тоеп алды. Көн чынлап та үтеп киткән. Ак юлларны табып, ерак-ераклардан хыялны әйдәп торган ак кыяларга барып җитәрлек кадерле вакыт узган... Көн озынлыгына сузылган бетмәс наз һәм ярсудан айнып, кинәт кабалана, арлы-бирле тартыла-сугыла башлады Микәй. Ә кәҗәләргә аның күңелендәге тойгыларны тиз генә аңлату мөмкин идеме соң?.. Аларның дөньялары бөтен. Җылы көн, җиләс урман һавасы, хуш исле үлән һәм агач яфраклары... Күзләрен нурландырып торган Микәй дә, тып-тып басып, янәшәләрендә таптана.

— Җанкайлар,— дип мәэлдәде аларга Микәй.— Көн узып та киткән.

— Көн узмады, Микәй. Бәхет китергән көн узмый,— дип, бер-берсен бүлдереп җавап кайтарды кәҗәләр. Аның күкрәкләренә, иңбашларына сыенып сырпаланды алар.

— Кузгалырга кирәк, соңга калабыз,— дип ашыктырды Микәй.

— Син кемнедер юксынасың...— дип, колак төбендә генә тавыш биреп алды берәү. Шомырткара иде бу.

— Миңа күңелле һәм рәхәт, Шомырткара.

— Күңелле һәм рәхәт булган җирдән качмыйлар,— дип каршы төште икенче бер кәҗә.

— Ни эзлисең, нәрсә җитми? — дип дәште Шомырткара.

— Бәхет, Шомырткара, бәхет...

— Үзең күңелле дисең, рәхәт дисең — бәхет шул түгелме соң?

— Бәхет, Шомырткара, ул — ак була. Бәхет — туган җирдә, Ак кыялар илендә генә.

— Бергә-бергә булу бәхет түгелмени, Микәй?..

— Бергә-бергә туган илдә булу — бәхет, Шомырткара!

Ул арада урман буен кичке караңгылык урап алды. Салкынча җил исеп, агачлар шомлы гына шаулашырга кереште. Танауларны ярып һава дулкыны тибрәнә башлады. Бәкәлләрне беренче чык бөртекләре чылатты. Әмма ак кыялар турындагы хыял арта һәм көчәя генә барды. Шул хыял аны урманга әйдәде, ак дөнья һәм ак киңлекләргә шул урманны аркылы чыкмый торып җиту мөмкин түгел дип ышанган иде ич ул.

Икеләнүләргә урын калдырмаска тырышып, Микәй караңгы һәм шомлы урманга таба җәт-җәт атлап китте. Кәҗәләр дә урыннарыннан кузгалды. Ләкин алар теләр-теләмәс кенә атлады, атлаган саен кире борылып, сыек зәңгәрлек эчендәге офык читенә таба каерылып-каерылып текәлеп тордылар. Дөм караңгы урманнан курку идеме бу, әллә шул сыек зәңгәрлек итәгендә калган авылларын юксынумы...

Алай гына да түгел, кәҗәләр бер-бер артлы тукталып, баскан җирләрендә торып кала башладылар. Авылга таба башларын суза төшеп, үрелеп-үрелеп мәэлдәргә керештеләр.

— Курыкмагыз, сез бит минем белән,— диде, адымнарын тыярга мәҗбүр булган кәҗә тәкәсе.

— Курыкмыйбыз, Нурлы Алан кала,— диде аңарга якынрак торган Шомырткара.

— Тиздән ак кыяларга барып җитәрбез...

— Нурлы Алан кала. Нурлы Алан кала-а-а,— дип мәэлдәште башка кәҗәләр бертавыштан.

— Анда дөнья ап-ак, анда киңлек, ак иркенлек,— дип тынычландырырга ашыкты аяклары урман аръягындагы серле дөньяга ашкынып торган Микәй.

— Күрче, безнең авылның офыгы нинди якты! Нәкъ синең туның төсендә, Микәй... Урман — шомлы, урман — караңгы...

Аны ак хыялларыннан аерырлык көч, гомумән, юктыр ул. Микәй ниятеннән кире кайтырга җыенмады, билгеле. Кәҗәләрнең үзенә тугрылыгына ышанычы зур иде. Ияреләр дип ышанды. Яңадан урман эченә таба омтылды. Инде агачлар арасыннан шәүләсе дә күренмәс булды... Шунда, бөтенләй уйламаган-көтмәгәндә кинәт кенә туган бер хис аны тукталырга һәм кире борылырга мәҗбүр итте. Урман читеннән кузгалырга теләми җәфа чиккән кәҗәләр кызганыч тоелды. Кәҗәләрен ул шулай дөм-караңгы урман читендә калдырып китсә, яхшы булмас ич.

Төнне авылга илтә торган юл читендәге каенлыкта уздырды алар. Ә таң беленү белән, яңадан урман куенына елышкан аланлыкка әйләнеп кайттылар. Бу көн дә бәхетле, бу көн дә мәңгелек булып тоелды... Әмма аны да шомлы төн алыштырды. Тагын таң беленде... Һәм тагын караңгы төште.

Бу бәхетле тәүлекләрнең инде чиге-ахыры булмас төсле тоела башлаган бер вакытта аларны иләмсез озын чыбыркы тоткан көтүче эзләп тапты. Качмадылар, буйсыну белдереп, авылга таба теркелдәде кәҗәләр. Гайрәте һәм ярсуы басыла төшкән Микәй дә кәҗәләре артыннан иярде. Авылга ашкынып чапкан кәҗәләрне куып җитә алмый иза чикте ул. Аяклары талган, күкрәкләре кысылган, авыр мөгезләре горур башын түбән иелергә мәҗбүр иткән. Көтүче, шуңардан файдаланып, бөтен ачуын Микәйдән алды. Озын чыбыркысы белән кизәнә дә сыдыра, кизәнә дә сыдыра... Чыбыркы аның ике як арт санын көйдереп алды, иңбашларын телеп үтте, колак төбендә генә шартлап, яңакларын яндырды, күзләреннән ут чыгарды. Әмма Микәйнең түзү һәм буйсынудан башка чарасы юк иде. Зарланмады, тавыш-тын да чыгармады хәтта — болай да сызланып торган, авырайган, хәлсезләнгән гәүдәсен өстерәп, кәҗәләр артыннан калышмаска тырышып алга атлады. Ә көтүче аның саен усалланды, Микәйне кыйнавын белде. Чыбыркы, иләмсез озын елан сыман, аның баш очында сызгырып ала да, әле аякларына, әле мөгезләренә килеп урала, тигән саен тәннәрен көйдереп, телеп-телеп ала. Микәй түзде. Микәй сер бирмәде. Хәтта көтүчегә ачуланмады, аңар таба борылып күз дә салмады ул.

## 13

Аклыгы белән куандырып кыш килде... Кышны яңа язлар алыштырды, табигатьтә яшел төс тантана итте. Көтү чыккан беренче көнне зарыгып каршы алды Микәй. Койма читендә җыелып торган кәҗәләрне күрү аңарга чиксез дәрт һәм шатлык китерде. Тагы да үсеп, тазарып киткән Микәйне дә кәҗәләр зарыгып сагынган иде. Аны абайлап алу белән, кәҗә төркеме өстеннән җиңелчә дулкын үткән сыман булды. Тыкрык башы җанланып китте. Килә-килешкә иң элек Шомырткараны эзләде ул.

Берсеннән икенчесе купшырак нәфис туннарга төренгән ике бәти иярткән Шомырткара киртә буенда тыйнак кына аны көтеп тора иде. Микәй, шундук, әнисе янында уйнаклап йөргән ул бәтиләрнең кара төстә түгел, көмеш сыман мамыкка төренгән булуларына игътибар итте. Иртәнге яктылыкта үзләреннән шундый ук көмеш нурлар тараткан сылу бәтиләр башка кәҗәләр тирәсендә дә күренә иде. Килә-килешкә бер кат күздән кичерде дә, мөгезләрен югары чөеп, аякларын нык-нык басып, күкрәген

киерә төшеп, туп-туры кәҗәләр җыелган почмакка үтте Микәй. Ул үткәндә, сарыклар читкә тайпылып юл бирде, сыер булып сыерлар да, аның озын һәм нык мөгезләрен күргәч, сагаеп калдылар.

Ниһаять, көтүче чыбыркысы шартлады. Кузгалдылар... Микәй алга узды. Микәйгә ияргән бердәм һәм тату кәҗәләр төркеменә сыерлар һәм сарыклар, алдан ук килешеп куйган сыман, юл бирделәр. Яңа җәйнең әле яңа яшәреп килгән беренче үләннәренә иң элек Микәй тояклары эз салды...

Көтүдә бер хәл. Хәзер Микәй авылда да иң хөрмәтле затларның берсе булып китте. Малай-шалай турында әйтеп тә торасы юк, аның исемен ишетүгә үк колаклары үрә тора иде инде аларның. Аның белән элеккечә үк уйнарга, шаярырга яратсалар да, инде хәзер ялгышып та аны оскыртучы яисә котыртучы юк. Янәшәсендә басып тору, күпереп торган мамыгыннан, юан муеннарыннан бер сыйпап алу малайлар өчен зур бәхет һәм дәрәҗә иде. Шулай сокланып торганда карашлар киң маңгай өстендә тырпаеп торган ике япьле иләмсез озын мөгезләргә төшми мөмкин түгел. Шул мөгезләрне күрү белән иң этәч малайларның да аркасыннан бер уч кырмыска чабышып уза.

Соңгы кыш эчендә олыгаеп киткән иде Микәй. Малай-шалай белән куышып чабуларга, уйнакларга бер дә атлыгып тормый ул хәзер. Күбрәк зурлар тирәсендә, ир-ат булган җирдә чуалырга ярата. Иртә язда һәм көз көннәрендә, кышкы суыкларда булсын, лапаста ябылуда яисә ишегалдында бикләнеп ятудан кызык тапмыйча, берөзлексез урамга, Нурлы Аланның ыгы-зыгылырак урыннарына тартыла. Үз көе белән чыгып, үз вакытында кире кайтырга күнеккәч, аның авыл буйлап сәяхәтенә хәзер Хуҗа абзыйлар да каршы килми башлады. «Нәселе шундыйдыр, башка маллар кебек алдына салганга риза булып, ишегалдында чемченеп йөри белми шул... Җанына урын тапмый, ямансулый торган мал булып чыкты»,— дип, кәҗә тәкәсен урамда үз ирече белән йөрүдән тыймадылар.

Әле ат абзарына барып чыкты Микәй, әле каравыл өе янында җыелып тәмәке көйрәткән ирләр тирәсендә чуалды. Ат чанасына килеп, керт-керт печән ашады, урамда коелган тукранбаш чәчәкләрен җыештырды. Аны һичкем кумады, һичкем селтәнмәде аңар. Зур хөрмәткә лаек ирекле бер сәяхәтче булып, үз көенә тик йөри иде авыл буйлап. Ләкин кайда гына булмасын, ул берөзлексез кешеләрне күзәтте. Трактор һәм машина тавышларына да тәмам ияләште хәзер. Авылның машина һәм тракторлар паркында ремонт эшләре белән мәш килгән ирләр тирәсендә чуалырга күнекте. Машина-тракторлар паркы тора-бара аның аеруча үз иткән урынына әверелде. Шундагы тимер-томыр арасында йөрүдән үзенчә бер хикмәт таба кебек иде ул.

Ир-атлар да аны үз иттеләр. Ара-тирә кесәләренә кыстырып килгән ипи кисәкләре белән сыйладылар, әлеге дустанә мөнәсәбәттән ике як та үзенә бер ямь таба иде. Аяк астындагы карны шыгырдатып, эшлекле бер кыяфәт белән Микәйнең фырт-фырт атлап машина паркына килеп чыгуын зарыгып көтеп ала торган булды ирләр.

— Адәм акыллары бар бугай бу тәкәдә,— дип сокланды ирләр.

— Карап торуын гына күр, кәҗә генә димәссең,— дип яраттылар үзен.

— Нindидер сагыш, моң бар моның күзләрендә,— дип тә гаҗәпсенделәр.

Ә Микәй аның саен ияләшә барып, тимер-томыр арасында тын гына, уйчан гына чуалып йөргән кешеләрне күзәтте. Шул кешеләрнең явызлыгы турында әнкәсе әйткән сүзләр китми иде аның хәтереннән. Шул кешеләр аны ак кыялар иленнән аерды, шул кешеләр аны Әнкәсе һәм бердәнбер туганыннан аерды. Шулай да, ни генә булмасын, кешеләр хакында әнкәсе ялгышкандыр төсле тоела иде аңар. Кешеләргә бернинди нәфрәт, ачу саклый алмады Микәй. Аларны яратты ул. Кешеләрдән

башка яшәүне күз алдына да китерә алмый башлады. Шул дәрәҗәдә юмарт, шул дәрәҗәдә көчле кешеләрнең кәҗәләргә нинди дә булса зыян салу ихтималын мөгез очына да китереп карамады. Кешеләр — бөтен табигатькә, бөтен әйләнә-тирәгә бары тик игелек кылучы. Кешеләр — бар тереклекне бер дәрәҗәдә якын итүче һәм тәрбияләүче. Кешеләр — кәҗәлекле. Шуңа да яратты, шуңа да үз итте ул кешеләрне.

Кышкы озын кичләрдә Нурлы Алан авылының урамнары гел балкып торды. Тәрәзәләрдәге утлар төнлә дә сүнәргә ашыкмады. Нурлы Алан шәл бәйләде. Яшь киленнәр һәм җиткән кызлар йокыларын оныттылар, Нурлы Алан кызларының толымнарына көмешсу йөгерткәндәй балкып, үзенә тартып торган мамык шәлләр уралды. Иләк-иләк йолдыз сибелгән кышкы зәңгәр кичнең күзләрне камаштырып торган гөмбәзе Нурлы Алан хатыннарының иңнәренә сарылды. Нурлы Алан кызларының уңганлыгы көне-сәгате белән дигәндәй тирә-як авылларны урап узды. Нурлы Аланда бәйләнгән шәлнең даны урман аръягындагы авылларга җитеп, торган саен ераккарак тарала барды. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән төбәкләрдән Нурлы Алан шәлен эзләп килүчеләр ешайды.

Нурлы Алан шәле дисәң, сатып алучылар телсез калды. Шәл белән бергә кәҗәләрнең дә дәрәҗәсе үсте. Нурлы Алан шәлчеләренә дан һәм шөһрәт китергән кәҗәләрне күрер өчен генә дә килеп чыктылар. Микәй турында исә берсеннән икенчесе хикмәтлерәк тарихлар сөйләнде, легендалар йөрде.

...Имеш, Микәй аргыяк күперенә аркылы басып кәҗәләргә юл бирми маташкан сөзгәк сыерны күпердән очырган. Сыеры бер аягын өстерәп кайтып кергәч, хуҗасы — Шәһәр Рәфәгате кызмача баштан сәнәк эләктереп авыл буенча Микәйне эзләп йөргән. Очраган бер кешене тинтерәтеп бетергән, имеш. «Кая ул теге килмешәк? Чәнчәм! Бәреп үтерәм!» — дип, әйтеп әйткән, имеш. Эзли торгач Микәйне тапкан бу, әмма кулы күтәрелмәгән. «Кәефең юк ахры, башың авыртамы әллә, Рәфәгать абый, дигән сыман күзләрен мөлдерәтеп карап торган җанга ничек итеп кул күтәрелмәк кирәк?» — дип сөйләгән имеш.

...Имеш, Хуҗа абзыйлар чәй эчкәндә табын янына үзләре белән Микәйне дә утырталар икән. Ашап туйгач, Микәй тастымал алып авызын сөртә икән. Моны, имеш, аларга йомыш белән кергән кемдер үзе күреп торган.

...Имеш, беркөн Хуҗа абзыйларга Микәйне сорап бер юлаучы килгән. Өйләрендә Миңлегали генә булган. Мөдир белән өченче «борын»ны көтеп утырган чаклары туры килгән.

Юлчы кеше мәсьәләне шундук мөгезеннән алган, килү максатын, йомышын әйтеп салган.

— Бәясе бер ярты,— дигән төшерергә күнегеп барган Миңлегали, ике дә уйлап тормастан.

Юлаучы ышанмаган, шаярта дип уйлаган.

— Җаным да җәл түгел, сатыгыз шул тәкәне,— дип ялварган.— Хатын тынгылык бирми. Нурлы Алан кызларындагы күк шәл тапмасаң, ди...

— Булмый! Җан башны тәзәтми!.. Бер яшник! — дигән шунда хәйләкәр генә бу юлаучыны күзәтеп торган Мөдир.

Бер ярты белән бер ящик арасындагы аерманы чамалап алган Миңлегалинең дә нәфесе үсә төшкән.

— Әйе, бер яшник, — дип кабатлаган, Мөдиргә кушылып.

Юлаучы, бармакларын бөгеп, колак яфракларын сыпыргалап торгач, ризалашкан. Ризалашмый соң нишләсен, хатыны бит өзеп әйткән...

— Микәй өчен бер яшник чүп кенә, шалкан бәясе генә бит ул,— дип, Мөдир аның күңелен күтәргән.— Бер елда ул синең бөтен авылыңны шәлгә, үзеңне озын берлеккә күмә...

— Әйе, әйе, мамыгы да шәп, җегете дә... Бер дә яман, адәм гыйбрәте,— дип җөпләгән Миңлегали.

«Яшник» алынган, «Җигули»ны ишегалдына ук керткәннәр. Тик Микәй тоттырмаган. Өчесен өч якка чөеп бакча капкасыннан чыгып качкан.

— Кайта ул...— дигән Миңлегали.

Болар Микәйнең тәпиен юарга керешкәннәр. Бер тәпиен юганнар, икенчесен, аннан өченчесен... Соңгы тәпиен юып маташканда Хуҗа абзый кайтып кергән һәм өчесен дә өйдән сөреп чыгарган.

Бу хәлләр булгандырмы-юктырмы, ләкин шунысы хак: ике-өч ел дигәндә Микәй бөтен авылны көмешсыман елык-елык килеп торган җылы, йомшак мамыкка төрде. Кышкы суыкларда тезелешеп клубка килүче Нурлы Алан кызларын хәзер зәңгәр нурлар озатып бара, аларны үзләренә килешеп торган шул мамык шәлдән башка күз алдына китерү дә кыен. Егетләр муенында да шундый ук җылы мамык шарф, кулларда мамык перчатка. Сабыйларда җылы башмак, оекбаш һәм бияләй — болар һәммәсе нурлы аланлыларга Микәйнең бүләге.

## 14

Микәйнең яшәү рәвеше һәркем тарафыннан шулай тиеш сыман кабул ителде. Җәйнең җәй буена кәҗәләре белән табигать кочагында — көтүдә, тау битләрендә, урман һәм су буйларында. Кыш җиттеме — урамда, ремонт мастерскоенда, каравыл өе янында, кибет янсә ат абзары тирәсендә.

Март урталары иде булса кирәк. Көннәрдән бер көнне, колхозның ремонт мастерскоеннан кайтып барышлый, кибет каршында җыелып торган ирләрне күреп, Микәй алар янында да тукталып алды. Ирләрнең кызып-кызып нидер сөйләшүен, әледән-әле, җанлана төшеп, шаркылдышып көлешеп алуларын күзәтеп тору мәзәк иде аңа.

Янәшәдә генә җигүле ат тора. Шуның чанасы артына барып басты Микәй. Чанада хуш исле солы саламы — ара-тирә чемченеп алырга да була. Мөгезләре очында гына кояш эленеп тора. Аның җылы нурлары күзләрне чагылдырып ала, тәннәрне иркәли, күкрәкләрдәге ярсуны кузгата. Ничек ташлап китмәк кирәк...

— Егетләр, әнә, Микәй дә килеп чыккан,— диде ирләрнең берсе, сүз арасында аңарга күрсәтеп.

— Егетләрнең асыллары кайда, Микәй шунда,— дип, чертләтеп бер читкә төкереп куйды шунда Курай Назыйм.

— Микәйгә җиткән егет булырга кирәк әле,— диде икенче берәве.

Кыз артыннан кыз сайлап, өйләнә алмый, кулны кесәгә тыгып, фуражканы кыңгыр салып йөрүендә булган Назыймга карап көлеп җибәрделәр. Шулай да Назыйм сер бирә торганнардан түгел.

— Безнең язмышлар Микәй белән бер чама инде,— дип, кәперәеп тә алды.

Ул үзенә күрә шактый мәгънәле итеп әйтергә теләгән иде, әмма аның сүзләренә булган игътибарны Мөдир бүлдерде. (Ул трактор-машиналар паркындагы мөдирлегеннән чыгарылса да, төшеп калмаган иде. Төшемле җирдә эшли — колхозның склад мөдире. Мөдир булып тугандыр, күрәмсең, мөдир булып калды.)

— Әйдә, Рәфәгать, чыгар әле фильтрлыңны, булгач-булгач шәһәрчә булсын, бер тартып җибәрик,— дип дәште Мөдир.

Шәһәр Рәфәгате сигарет таратты. Кесәсеннән шырпы чыгарды. Ирләр борыннары белән берәм-берәм ут кабызучының кушуч арасына кереп чыктылар.

— Саранланма инде, Микәйгә дә чыгар өлеш,— дип дәште Мөдир, сигарет тартмасын кесәсенә тыгып торган Рәфәгатьне ярты юлда туктатып.

Рәфәгать һәм башкалар бер мәлгә сискәнеп куйды һәм югалып калдылар. Әмма сискәнергә мәҗбүр иткән ул сүзләрне Мөдир үзе әйтте ич. Ә аның сүзләрен кире кагып яисә искә алмый калып кара. Мөдир Мөдир инде ул!.. Авыз читләре белән теләр-теләмәс кенә елмаерга иттеләр. Һәм чынлап та кызык булып китте. Шәһәр Рәфәгате, сигаретын сузып, Микәйгә таба атлады. Хуш исле солы саламы чемченеп торган Микәй шундук башын читкә борды.

— Синнән ник алсын... Әнә, Миңлегалигә бир,— диде Мөдир.— Ул үз кеше.

Миңлегалинең күңеле тартмады. Әмма, правосын алдыргач, соңгы көннәрдә генә Мөдир үзе янына эшкә алган иде аны — Мөдирнең сүзен аяк астына салып таптый алмады. Микәйне үзе янына чакырды Миңлегали. Тәкә хуҗасын таныды, теләр-теләмәс кенә булса да килергә мәҗбүр булды. Үзенә таба сузылган кулга карап торды, андагы әйбернең ни икәнлеген чамалап өлгергән иде инде. Исе борынын ярып керде. Юка кәгазьгә төрелгән ул сасы нәрсәгә ничәмә-ничә мәртәбәләр тап булганы бар иде бит аның. Авыл әйләнәсендә, койма читләрендә үскән үләнгә үрелим дигән саен шул ис килеп бәрелә иде борынына. Теңкәсенә тигән, күңелләрне болгаткан ис. Бер нәрсәне аңлый алмады ул — нигә әле аңар һәрчак сөеп, үз итеп караган хуҗасы шул сасы нәрсәне тәкъдим итә? Микәйгә начарлык телиме ул?.. Алай дисәң, үз авызыннан да әче төтен исе бөркелеп тора. Үз-үзенә дошман булмас кеше... Кеше кадәр кеше ничек итеп шундый ахмаклык эшләргә мөмкин?..

Берни аңыша алмады Микәй. Хуҗасының күзләренә текәлде. Карашларын мөлдерәтеп, зур ышаныч белән карап торды ул аңарга.

— Кабызып бир, дип әйтә бит... Әнә, көтеп тора,— дип пышылдады арадан берәү.

— Ширпы китер. Шырпыңны сыз,— дигән сүзләр ишетелеп алды.

Тамаша итеп торучыларның кызыксынуы Миңлегалигә дә күчте, аны да мавыктырды. Бер кулы белән тәкәнең муен астыннан сыпырып торды ул, икенче кулы белән, ипле генә итеп, сигаретның фильтрлы башын Микәйнең иреннәренә тидерде.

Берни аңламады кәҗә тәкәсе. Нарасыйларча мөлдерәп, әле хуҗасының күзләренә, әле аның кулындагы сасы нәрсәгә тик карап торды. Кеше кадәр кеше аңар начарлык теләмәс. Кеше кадәр кеше начар әйбер тәкъдим итмәс бит... Шуның өстенә әле монысы хуҗа кеше. Аны көн саен диярлек үз итеп, аркаларыннан сөеп, иркәләп киткән хуҗасы. Юк, кешеләр ихтыярына каршы бара алмады ул. Кешегә булган ышанычы бар нәрсәдән югарырак иде. Микәй сак кына иреннәрен кыймылдатты...

Ирләргә шул җитә калды. Кешеләр һәммәсе берьюлы җанланып куйды, шаккаттылар. Баш түбәсендәге бүрекләр колак читенә шуышып төште, күзләр маңгайга кунаклады. Берсен-берсе бүлдереп гөрләшергә тотынды ирләр.

— Капты бит, капты...

— Микәй тәмәке тарта!

— Вәт, кәҗә дисәң дә кәҗә ичмасам...

— Егетләр, хәтерегезгә киртләп куегыз — 19 ...нчы елның 13 нче марты бу көн, ул тарихка кереп калыр: кәҗәләрдән беренче булып Микәй тәмәке тарта башлаган көн, дип искә алырлар аны,— дип, кулларын кесәдән чыгарган Курай Назыйм мавыгып сөйләргә тотынды.

Аның әле дәвам итәргә дә исәбе юк түгел иде. Сүзен Мөдир бүлдерде.

— Тарих ул шәп нәрсә, кураем, тик аның белән баш төзәтеп булмый. Билгеләп узыйк булмаса...— Мөдир тәкъдимен хуплап, чара күрү җаен карадылар. Ә ул дәвам итте.— Син, кураем, тарих дисең, ә беләсеңме бу

тарихның нәрсә эшләп куюы бар, әгәренки Микәй сыман барлык кәҗәләр дә тартырга өйрәнеп китсә, безгә ни калыр?!

Әйтер сүз тапмады Назыйм, иңбашларын тарткалап елмаеп кына куйды. Мөдир шәп утырткан иде үзен, рәхәтләнеп көлеп алдылар.

Миңлегалинең күңеле аеруча булган иде. Зур канәгатьлек белән тагы бер тапкыр тәкәнең аркасыннан сөйде дә Мөдиргә карады. Мөдир аңардан шулай ук канәгать иде.

— Әйттем ич, егетнең асылы ул Микәй,— дип куйды Курай Назыйм, сүзсез каласы килмичә. Шул арада сул колагы өстеннән чертләтеп тәкереп алырга да өлгерде.

— Сигәрите нинди, сигәрите...— дип, куанычыннан нишләргә белмәгән Шәһәр Рәфәгате тагы кесәсенә тыгылды.

... Ирен арасына кыстырылган сигаретны нишләтергә белмәде Микәй. Бәхетле гөрләшкән кешеләргә карап торды. Тел очын гына тидереп, авызындагы әйбернең тәмен белеп карарга булды — иреннәре һәм теле әчетә башлады. Авыз эченә кергән ис күңелен болгатты, күзләреннән мөлдерәп яшь бәреп чыкты. Артык түзә алмады ул, сасы нәрсәне кире төкереп, дымлы күзләрен яшерергә теләгәндәй ирләр яныннан китеп барды. Кычкырып-кычкырып сөйләшкән, көлешкән кешеләр шунда торып калды.

«Микәй тәмәке тарта»,— дигән хәбәр авылны аркылыга да, буйга да гизде. Күпләр ышанмады — бу хәбәр бер колакларыннан ничек кергән булса, икенчесеннән шундый ук тизлектә чыгып та китте. Ләкин, хикмәтле яңалыкка исләре китеп, аның хакмы-түгелме икәнлегенә үз күзләре белән ышанасы килүчеләр дә булмады түгел. Сенсацияне ишетү бер хәл, ә аны үз күзләрең белән күрү бөтенләй башка инде... Микәй көндәгечә урамга чыгу белән, аның авызына әле сигарет, әле папирос яисә махорка тыгарга ашкынып тордылар. Башын борып карады, торып читкә чапты Микәй. Ләкин кая гына барып чыкмасын, кешеләргә юлыкты. Ә кешенең кулында, әлеге дә баягы әрем сабагы юанлыгы шул ук сасы әйбер була. Кешедән качмады ул, исе үк үзенә чит-ят булган шул әйбердән качты. Бу кешеләргә ни булды?.. Кеше кадәр кеше нигә шундый юк-бар белән мавыга?.. Шулай да тора-бара кешегә булган ышанычы көчлерәк булып чыкты аның. Бертуктамый борынына, ирен очларына сузылып торган бу искә инде ул күнегә дә башлады. Һәм әледән-әле, үзен яратып сыйлаган, кадерләгән кешеләр хакына гына дип, аларның күңеле булсын өчен генә ул нәрсәне авызына да кабып торды.

— Күр әле, күр... капты.

— Микәй тәмәке тарта, билләһи дим, тарта...

— Әнә, әнә, авызында ич,— дип, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә куана иде олысы-кечесе.

Шул тәмәке дигәннәрен ирен очларында бераз тотып торгач, тагы да ныграк үз итә, кадерләбрәк сөя иде аны кешеләр. Микәй дә әллә ни югалтмый, кешеләрнең дә күңеле була. Кешеләр канәгать!

Тора-бара тәмәке сузган кулларга ияләшеп, алардан качмый да башлады ул. Тәмәке булган җирдә аны ныграк үз иттеләр. Тәмәке булган җирдә карашлар гел аңарга текәлде. Тәмәке булган җирдә Микәй беркайчан да ялгыз хис итмәде үзен. Барысы да аңарга сокланып карады, гаҗәпләнде, сөйде.

Микәйнең яңа шөгыле турындагы хәбәр Азат белән Миңлегаязга да килеп җитте. Озак кына ышанмый да йөрделәр. Шулай да көннәрдән беркөнне үзләре сынап карарга булдылар.

— Тәмәкесен каян табыйк?— диде Миңлегаяз, сынауга тәмам әзерләнеп беткәч.

Сынау көнен түземсезлек белән көтеп алган Азат җавабын, хәрбиләрчә килештереп, кыска тотты.

— Табылган,— диде кистереп.

— Катысы түгелме?— дип, Миңлегаяз үзенең белдеклелеген күрсәтте. Берочтан Микәйне дә кайгыртуы иде, билгеле.

— Кәнфит күеге — фильтрлысы!

— Табылу урыны?

— Әти запасыннан.

— Табу юлы?

— Чәлдерү...

Миңлегаяз дустына шелтәле караш ташлап алды: шулай ярыймы, янәсе...

— Сорамыйча алу, иптәш Миңлегаяз генерал! Башка чара юк иде.

— Ике көн бәдрәф чистартырсың солдат Азат!

— Есть, иптәш Миңлегаяз генерал!

— Тәмәкене китер!

Азат, бомба чыгаргандай саклык белән, кесәсеннән сигарет чыгарды. Күңелләре күтәренке иде, тыела алмыйча, үзара карашып, көлеп алдылар. Әнә, ничек килештерәләр ич... Чын солдатлар кебек.

Микәйнең әле яңа гына чираттагы биләменнән кайтып төшкән чагы иде. Ишегалдының урта бер җиренә баскан да, башын бер якка янтайтып, мөгез очы белән аркасын кашып тора. Малайларны бөтенләй күрмәмешкә салыша, күзләрен йома төшкән дә кояшка таба борган.

— Ничек бирәбез, шул көе генәме?— дип кызыксынды Азат.

— Тәмәкене ничек тарталар, солдат?

— Ут төртеп, иптәш Миңлегаяз генерал.

— Ут төртмиләр, солдат, кабызалар!

— Мә алайса, кабыз.

— Юк, син кабыз, солдат!

— Авызга капсаң, исе килә. Син тотып тор, мин кабызам!

Ничәмә-ничә шырпы сызып, сигарет башын күпме генә көйдерсәләр дә, аның башыннан төтен чыкмады. Миңлегаяз, тәвәккәлләп, авызына алды. Һәм әче төтенгә буылып шундук ютәлләргә дә кереште.

— Фу, сас-сылы-гы моның. Үскәч ничек тартырсың?!.

Микәй, иреннәрен ялый-ялый, байтактан инде аларның кулындагы сигаретны күзәтә иде. Миңлегаязның кулына ул үзе үк үрелде һәм сигаретны иреннәренә алды. Суырмады ул аны, эвәләде-эвәләде дә, уты сүнгәч комсызланып чәйни үк башлады.

Малайларның исе китте. Ни куанырга, ни борчылырга белмәде алар. Микәйдән моны көтмәгәннәр иде, бөтенләй югалып калдылар. Кәҗә тәкәсе исә, авызына тәмәке керүгә, аларның барлыгын да онытты, ләззәтләнеп чәйнәвен генә белде.

— Тартмый ич, ашый ул аны, ашый,— дип тагы буылып-буылып ютәлләргә тотынды Миңлегаяз.

— Микәй, кире чыгар! Ашама! Бир монда!..— дип ялварырга кереште куркуга калган Азат.

Кәҗә башын читкә борды. Һәм кырт борылып китеп үк барырга җыенды.

— Генерал, дим... Авызын ачтыр! Тәмәкесен алыйк... Мин тотып торам,— дип кычкыра-кычкыра Азат кәҗә тәкәсенең мөгезенә барып ябышты. Миңлегаяз ике куллап аның иреннәренә үрелде. Яңакларын каерырга итте. Сакалыннан тартып карады. Ләкин Микәйне көч белән җиңәрлек түгел иде, ул рәхәтләнеп чәйнәвендә булды. Мөгезләренә ябышкан Азат белән Миңлегаязны ишегалды буйлап өстерәп китте. Болай өстерәлеп барудан ни файда, Микәй башын селтәп алырга да өлгермәде, ике малай аның ике ягында тәгәрәшеп ятып калды... Кәҗә тәкәсе урам буйлап кибет ягына таба торып чапты.

## 15

Беренче көнне үк көтүдән качты Микәй...

Елдагыча, зарыгып көтелгән җәй башы иде югыйсә. Үләннәрдә чык бөртекләре җемелдәшкән якты иртә. Сулышларны иркәләп, күкрәкләрне кытыклап, мамыкларны тарап талгын җил исә. Тояклар астында җылы йомшак балчык. Бөтен әйләнә-тирәдә күзләрне чагылдырырлык дәрәҗәдә саф яшеллек тантана иткән чак.

Кышның кыш буена лапас һәм ишегалларында бикләнеп яткан, әлеге иртәне зарыгып көткән кәҗәләр дә биредә. Язны тизрәк җиткерергә теләп, тояклары белән ишегалдындагы каты карны күпме тырнаганнарын үзләре генә белә алар. Килеш-килбәте белән карашларын гына түгел, хыялларын да билән алган Микәйне бер күрергә ничек зарыгуларын әйтеп аңлатырлык түгел. Мактаулы һәм киң күңелле тәкә турында әлегә ишетеп кенә белгән көмешсу бәтиләр дә шунда. Кайсының гына Микәй сыман гайрәтле һәм данлы булып үсәсе килми иде икән...

Шуларның һәммәсен белсә дә, качты Микәй. Хыянәтчел төстә калдырып качты. Аның юкка чыгуын, тигәнәк һәм алабута баскан ташландык нигез турына җиткәч үк ни арада күздән югалуын янәшәсендә барган Шомырткара да абайламый калды.

Көтүнең иң алдыннан барган кәҗәләр төркеме үз юлында булды. Көмеш ука сыман тоташ бер агымны хәтерләткән кәҗә көтүе әле берни аңышмады һәм сизенмәде. Әле кайчан гына Микәйнең бар шатлыгын һәм куанычын тәшкил иткән көтү иде бит бу. Ә бүген ул әнә шул көтүне хыянәтчел төстә ташлап качты.

Юк, ак юллар һәм ак кыялар турындагы хыяллары сәбәпче түгел бу качуга. Кая(?) һәм ни өчен(?) дигән сорауларга, мөгаен, үзе дә җавап бирә алмаган булыр иде ул. Зур хата ясавын да аңлады үзенең. Әмма кире борылмады. Юлбашчысыз калган көтү турында уйламаска тырышты, ашыкты, кабаланды Микәй. Койма һәм читән ярыкларында тырмалып уч-уч мамыклары әләгеп калды. Бәкәлләрен тимер-томыр һәм калай кисәкләренә бәрде, пыяла ватыклары тояк читләрен китеп-китеп алды. Сакал һәм түшләренә тигәнәк уралды, сыйракларына сырлан ябышты. Бернигә карамый бакча артлатып авылга ашыкты ул. Аяк астындагы үләннәрне, хуш исле эре-эре яфракларны тоймады, күрмәде. Аларда бөтенләй гаме юк иде аның. Исләрен дә тоймады, сиземләмәде хәтта, үләннәрнең кайчандыр аңар дәрт һәм җылылык китергән сыек яшел төсләре үк саруын кайнатты. Янәшәдә генә агып яткан инешкә ачуы чыкты, чишмә тавышы да борчыды аны. Үз күләгәсе булып, үз күләгәсен читкә куасы килде. Маңгаенда тырпаеп торган иләмсез зур мөгезләренә җен ачуы чыкты. Шул дәү мөгезләре булмаса, бәлки, болай качып йөрү әллә ни кыен да булмастыр кебек тоелды.

Урамнар иртәнге ыгы-зыгыдан тынычланып, бушанып калган. Ул туп-туры кибет каршына үтте. Анда берәү дә күренми иде әлегә. Моңарга да исе китмәде. Түмгәк-түмгәк булып кипкән көл балчык өстеннән комсызланып тәмәке төпчекләре чүпләргә кереште. Авызына җыйды да, башын күтәрә төшеп, озак кына ләззәтләнеп чәйнәп торды. Акрын гына күз аллары ачыла төшкәндәй булып китте, тынгысыз җаны изри башлады. Кибет янында берүзе чемченеп байтак йөрде ул. Кояш мөгезләре очына менеп җиткәч кенә, ирләрне юксынып, ремонт мастерскоена таба китте.

Ара-тирә аркасыннан сыйпап үтүчеләр булса да, кешеләрнең Микәйдә гаме юк иде. Һәркем үз эше белән мәшгуль, арлы-бирле йөрделәр, ашыктылар. Кыш буе бер урында йокымсырап чыккан трактор һәм машиналарга хәтле урыннарыннан кузгалып, кайсы кая таралышып бетте.

Күңеленә ятышлы ис сизеп, тимерче алачыгы ишеге төбенә килде Микәй. Анда ике ир-ат тәмәке тарткан көйгә тимер чүкеп маташа иде. Тукталды. Һәм моңлы гына итеп аларның әле кулларына, әле авызларына карап тора башлады. Күзләрен мөлдерәтеп озак торды шулай. Тимерче-

ләрдән күзен бер генә мизгелгә дә читләштермәде. Авызыннан сулар килде, тамак төбе янды, күзләре эренләп чыкты. Ләкин аны никтер аңламадылар һәм аңларга теләмәделәр. Ул гына да түгел, яннарыннан ук кудылар. Микәйнең китәсе килмәде. Борын тишекләрен иркәләп торган шул төтен исе өчен генә дә торырга риза иде ул. Төпчекләрен ташлаганны көтте. Үч иткәндәй, анысын да аяк астына түгел, утлы күмер өстенә аттылар. Микәйгә күз читләрен генә төшереп үзара сөйләшеп алды кешеләр.

— Күр инде, бичара, әнә ничек газаплана. Бирикме соң әллә берне генә...

— Бирәсе түгел!

— Соңгысы итеп кенә, кызгандыра ич...

— Ә болай кызганыч түгелме?

Кешеләр сөйләшүендә булды. Күзләреннән сизеп, күреп торды — усаллык белән карамыйлар иде, элеккечә үк яратып, үз итеп карыйлар, югыйсә. Ә сигаретларын кызганалар.

Көтеп-көтеп тә бер эш чыгара алмагач, ул тагы бер мәртәбә гараж алдыннан урап узды, рәткә тезелеп торган комбайннар каршыннан үтте. Бара торгач ремонт мастерскоеның түр почмагында аунап яткан тимер-томыр ватыклары өеме өстенә менеп туктап калды. Мөгезләре тагы да авыраеп китте кебек, бөркүлеккә түзәрлек түгел. Аяклары да талган. Бераз хәл алырга исәпләп, көн кызуын җыйган кара калай кисәге өстенә, кояшка арка куеп сузылып ятты Микәй. Йоклыйсы килде аның, йоклый алмады. Башын аркасына салып изрисе, онытылып торасы килде, барып чыкмады. Бер сәбәпсезгә тынычсызланды, берөзлексез кыбырсынып торды. Үз-үзен кая куярга белмәде. Бер читтә өелеп яткан күгәргән тимер кисәкләренә карап ятты. Озак ятты шулай, күгәргән тимер ватыкларының да төсе нәкъ тәмәкенеке кебек икән. Күзләре оедымы, әллә чынлап та шулай идеме: тора-бара әйләнә-тирәдәге туфракның да күгәргән тимер төсенә керә баруын искәрде. Ремонт мастерскоен уратып алган тимер рәшәткәне дә тоташ тутык баскан. Комбайннар, каралты-кура түбәләре дә тутык булып тоелды... Ара-тирә үскән кычыткан һәм алабутага кадәр шул ук тутык төсенә кергән. Койма аръягындагы басулар, кояш нурлары һәм хәтта күк йөзе булып күк йөзе дә тоташтан күгәргән калай белән төреп алган сыман иде.

Күзләренә ышанмыйча, мөгезләреннән төшеп торган бер пар күләгәгә игътибар итте — алар да тутык төсенә кергән. Бөтен әйләнә-тирәне тоташ бер төс — тутык баскан. Тутыккан дөнья аның күз алдында болганатулгана башлады. Тирә-ягыннан ак төстә булган хет бер генә әйбер булса да табарга теләп эзләнде — таба алмады. Яшел төсне күрергә зарыкты — анысы да кай арада юкка чыккан... Тутыктан башка берни күренмәде аның күзләренә. Дөньяны тутык баскан. Урамдагы каеннар да, аклыкларын җуеп, тутык төсенә кергәннәр. Дөньяга әле яңа каш сирпегән яшел яфракларына да тутык кунган. Бу төсне башка күрәсе килмәде, күзләрен йомды.

Күзләрен йомуга, күз алдына ап-ак киңлек, ак карга төренгән биек-биек таулар, кыялар килде. Имеш, ак кыялар илендә ул туган энесе белән таштан-ташка сикереп уйнап йөри икән. Шунда кыя читендәге зур бер таш өстендә торган әнкәләре дәште аларны. Көмешсыман нурлар чәчеп торган әнкәләре янына ук кебек атылып, томырылып килде алар. Аңарга охшатырга тырышып, башны күккә чөеп, күкрәкләрне киерә төшеп, икесе ике ягына чыгып бастылар.

— Күрәсезме,— диде әнкәләре,— әнә анда, бик еракта, ап-ак киңлекләр аръягында ак калкулыклар башлана...

— Күрәбез, күрәбез,— диеште алар.

— Шул якларга барып, шундагы ак киңлек һәм иреккә тиенсәң иде, балалар.

— Монда да иркен һәм бар дөнья ак ич, әнкәбез,— диеште алар.

— Кеше исе килә, кеше...— диде хафаланган әнкәләре.

Туганы дәшмәде. Ә Микәй дәшми калудан курыккандай, ашыгып-кабаланып әнкәсенә каршы төште.

— Кеше яманлык итмәс, әнкәбез. Кешеләр юмарт һәм ягымлы, үзем беләм.

— Юк, бала, ялгышасың! — дип бүлдерде әнкәләре.— Аю-бүредән качып котыла алсак та, без кешедән кача алмыйбыз...

— Юк, әнкәбез, юк! Качмыйк! Кешеләр безгә гел игелек кенә кылыр. Алар безгә тимәс...

— Ялгышасың, бала! Игелек табигатьтән. Кешедән — бәла-каза!

— Әнкәбез, сөйләмә алай! Кеше — юмарт, кешеләрсез дөнья ямьсез... Сөйләмә, кирәкми, әнкәбез! Кешеләр табигатьнең үзе кебек. Кеше кадәр кеше, әнкәбез, без нарасыйларны рәнҗетмәс! Алар, әнкәбез... шундый...

— И-и-и, бала,— диде дә әнкәсе, аңарга таба башын бора төшеп күз салды.

Шундый да нурлы, шундый да җылы, шундый да ак караш иде аның әнкәсендә... Микәйнең ул караштан күзләре чагылды, җаны кузгалды, бәгыре өзгәләнде. Бәкәлләренә көч, күкрәкләренә җегәр, мөгезләренә гайрәт ага башлады кинәт. Яткан җиренә сыеша алмый, сикереп үк торды Микәй һәм күзләрен ачты.

Белгән булса, күзләрен ачар идемени... Тоташ аклыкның төштә генә булуын оныткан ич ул. Тирә-юнь күз алдында чайкалып куйды. Әнкәсе дә, аның нурлы карашы һәм ак хыяллар берьюлы юк булды, аклык күгәрек төсендәге куе томан артында эленеп калды. Кай ягына күз төшермәсен, тутыккан калай һәм тутыккан тимер кисәкләреннән тыш берни күрмәде ул.

Аргы почмакка урнашкан тимерчелек ягыннан шулчак:

— Микәй, Микә-ә-әй...— дип кычкырган калын тавыш ишетелде.

Колакларьт үрә торды. Микәй, кабалана-кабалана, тавыш килгән якка таба китеп барды.

## 16

Микәйне ул җәйдә көтүгә чыгара алмадылар. Ни итсә итте, авыл читеннән үк башланып киткән чыклы үләнгә һәм яшел чирәмгә аяк бастыра алмадылар аны. Баштанаяк тигәнәк һәм сырланга, тузан һәм балчыкка батып, көннең-көн буена авылны аркылыга да, буйга да гизеп тик йөрүендә булды. Кәҗәләрен искә дә төшереп карамады. Көтү киткән һәм көтү кайткан чакларда, күзгә чалынып йөрүдән тайчынып, я нинди дә булса бер бура эченә поса, я ташландык нигез урыннарындагы тузанлы чокырга кереп ята. Әйтерсең, берәүдә дә гаме юк иде аның.

Гаме юк иде югын... Әмма көтүгә җыелган яисә көтүдән кайткан кәҗәләрнең авазына колаклары һәрчак сак булды. Сузып-сузып кәҗә кычкырганны ишеткәндә, муенындагы йоннары үрә тора, эсселе-суыклы булып, бөтен тәне калтыранып китә иде.

Көннәрдән бер көнне көтү кайтканны аеруча зарыгып көтте ул. Түзәр әмәле калмагач, авыл башына ук чыгып каршы алырга булды. Таныш авазлар ишетелә башлагач кына кыюлыгы юкка чыкты, түзмәде, бакча артындагы таллыкка кереп качты. Тояк тавышларыннан, сулышларыннан танып, тоеп торды ул юлдан узган кәҗәләрне. Ул поскан таллыкка җиткәч, бер кәҗә гел туктап калды. Шомырткара иде бу. Бер-берсен күрмәсәләр-дә, исләрен тоеп, әллә каян сизенеп тордылар. Шомырткара сузып-сузып аваз салды:

— Ми-и-кәй, Ми-и-кәй! Ник качасың, нәрсә булды, Ми-и-кәй?— диде.

«Шомырткара-а»,— дип җавап кайтарасы килде Микәйнең. Әмма дәшмәде, чак тыелып калды. Бик тә, бик тә кыен иде җавапсыз калу...

— Ми-и-и-кәй, дөньяның иң матур чагы, качма инде, Ми-кә-әй,— дигән ягымлы иркә аваз ишетелде тагын.

«Дөньяда ни ямь...» — дип дәшәсе килде Микәйнең. Шомырткараны борчуга салудан куркып тыелып калды.

— Быелгы яшеллеккә исең китәр. Яшел төс — безнең төс ич, Ми-и-кә-әй...

«Тояк очындагы үләнне тутык баскан. Тал чыбыкларына кадәр тутык. Сине дә тоташ тутык итеп күрәсе килми, Шомырткара»,— дип дәшәргә җыенганда, күз төпләренең дымыгуын тоеп, тагын тыелырга мәҗбүр булды Микәй. Шул хәлендә Шомырткара каршына чыгып басудан уңайсызланды.

Шомырткара, инде тәмам өметен югалтып, тагы берничә кабат сузып тавыш бирде дә башын салындырып көтү артыннан иярде.

Тирә-як тынып калды. Тузан басылырга өлгермәгән иде әле. Юлга чыгып баскан Микәй Шомырткараның тояк эзләрен барлады. Шул эзләрне тапса, иң матур һәм бәхетле көннәрен дә кире кайтара алыр төсле иде. Әмма юлда тоташ тутыкны хәтерләткән тузаннан башка берни күрмәде һәм тоймады ул. Баеп барган кояшның нурлары тутык сыман бөтен әйләнә-тирәне каплап, басып киткән иде.

## 17

...Офык читендә кара болытлар күренеп-күренеп алды. Алсуланып кояш баеганда, дымсу, салкын җил исте. Төннәрен берөзлексез әллә яшен, әллә аҗаган уйнады. Яңгыр булуы бар, яңгырга китмәгәе, дип хафаланды нурлы аланлылар. Басуда әле сугылмаган иген — сабан бодае бетмәгән, арпа коела, солы чират көтеп ята. Ачык ындыр табагында орлыкка дигән борчак, арыш чистартылмаган. Салам күбәләре җыеп алганны көтеп ята. Авылда кылны кырыкка ярыр вакыт... Шундый чакта ничек кул кушырып утырырга мөмкин. Инде бишенчегә күчкән Азат та, Миңлегаяз кебек үзеннән өлкәнрәк дус-ишләре белән бергә, ындыр табагыннан кайтып керми, өлкәннәргә булыштылар. Көрәк тотып,* үзтөягечләргә ашлык этеп тордылар. Капчык өстерәделәр-төяделәр, бушаттылар. Капчыкларның баш-башыннан тотып, хатын-кызлар кайнашты, картлар кыймылдады, яшь-җилкенчәк хәрәкәтләнде.

Ир-атлар да кул кушырып тормады, билгеле. Комбайннар көнне төнгә ялгап эшләде, икмәк төягән машиналар тыз да быз йөреп торды. Салам җыйды, жир тырмалады, җир сөрде ирләр. Колхозның ындыр табагында да аз түгел ирләр. Бер ишеләре янып-көеп эшләп йөрде. Ә икенчеләре...

Икенчеләре дә бар иде. Таза-таза ирләр, колак артына карандаш кыстырып, күпме икмәк кайтканны, киткәнне хисаплап торды. Амбарда, каравыл өендә, үлчәүдә, һәр көшел янында кәгазь тотырып торды ирләр. Сырлап-боргалап көннең-көн буена кәгазьләргә кул куйдылар, тамга ясадылар, чут төймәсе тарттылар. Һәр склад ишеген, һәр чистарткычның, һәр бушаткычның ничек эшләвен күзәтеп торды ирләр. Арлы-бирле йөрде алар, эшлекле йөрделәр. Үткән-сүткәндә капчык өстерәгән яшь киленнәргә шаян сүзләр әйтеп уздылар, куллары сузылгалап алды.

Ындыр табагының түрендәге каравыл өе турында җыелып әңгәмә корырга да өлгерде ирләр. Пышын-пышын гына мәзәк хәлләр сөйләргә дә вакыт чыкты. Каравыл өенә эшлекле генә кереп чыккаладылар. Кайберәүләрне аяклары гел шунда каерып торды: мыштым гына кереп киттеләр дә кош туткандай очынып чыктылар. Шунда кереп, биелгы уңыш өчен, исәнлек-саулык өчен, йөзгә байлар төсе чыксын өчен, көннәр матур торсын өчен, кәеф яхшы булсын өчен, ди-ди күтәрде алар.

Гәүдәгә нык кына калкынып киткән Азатка да күз кыстылар хәтта.

— Нишләп анда, җыен хатын-кыз тирәсендә капчык ташып йөрисең, ирләр янына да килеп киткәлә,— диделәр.

Килде Азат, ялындырмады. Аның колагына Мөдир үзе пышылдады. Дөрес, ул хәзер гаражда да, складта да мөдир түгел инде, ул эшләреннән соң кырыкмаса-кырык эш алыштырды. Әмма кая гына бармасын, Мөдир булып калды. Хәзер — ремонтка туктап онытылган орлык киптерү корылмасы мөдире. Миңлегалине дә үзеннән калдырмады Мөдир — аны ул үз янына капчык хисаплаучы итеп алдырды.

— Әйдә,—диде,— печтик кенә кәгәсеңме? — диде Мөдир үз итеп.
Азат уңайсызланып калды. Ни әйтергә белми югалудан, елмайды. Елап булмый бит. Әтисе яшендәге кешегә тавыш күтәреп тә булмый. Ярамый, дигәнне аңлатып, башын какты.
— Яңгыр килсә — икмәк кала бит, чылана,— дип дәште малай. Юкса, телен йоткан диярләр.
— Калганы юк әле,— диде Мөдир, тәҗрибәле кеше буларак.
— Хатын-кызларга булышыйк, капчыклар авыр ич...—диде Азат, тавышын калынрак итеп чыгарырга тырышып.
— Хатын-кыз ирләрдән ныграк, гәҗит укырга кирәк,— диде алар янына килеп баскан Йөк үлчәүче.
— Ягез, кем барып кайта? — дип эндәште Капчык хисаплаучы, монда җитдирәк мәсьәлә бар әле дигән сыман. Өч-дүрт ир бер-берсенә карашты, һәркайсы урындагы кеше, хөрмәтле кеше икән шул. Басудан арпа төяп кайткан үзбушаткыч шоферына ымладылар.
— Юк,— диде шофер, кабинадан башын чыгарып,— комбайннар көтә. Эш кала.
Ирләр Мөдиргә кушылып, аның җавабыннан дәррәү көлешеп алды.
— Эш качмый ул, үлгәч тә өч көнлек кала,— дип елмайды Мөдир белән янәшәдә ук торган Капчык хисаплаучы.
— Син яшь кеше, бер аягың анда, икенчесе монда булыр,— дип Азатка борылдылар.
— Капчык ташыйсы бар. Персидәтел абый күрсә, бирер кирәгегезне,— дип карады Азат.
— Куркыттың! — диде Йөк үлчәүче, бәхетле елмаеп.
— Персидәтел белән партург районда,— диде Мөдир, «аны гына беләбез инде, энекәш» дигән сыман елмаеп.

Азат, ни әйтергә дә белмичә, йөкче хатын-кыз һәм яшүсмерләр янына китеп барды. Каршысына үтә дә эшлекле бер кыяфәт белән килгән Микәй очрады. Ашыга-кабалана килә иде Микәй — ни алдына, ни артына каранмады, як-яктагы икмәк көшелләренә дә күз төшермәде. Хәтта Азатны бар дип тә белмәде. Туп-туры ирләргә табан узып китте.

Мөдир һаман дәрәҗәле кеше. Сүзе үтә, кулыннан эш килә. Әле дә аңар берөзлексез гозер белән килеп торалар. Килгән кешене ул җылы каршылый белә. Килмәсәләр — чакырып ала. Мөдир вакытны бушка уздырмый.
— Фатимәттәй...— дип, әнә хәзер дә тол хатынны чакырып алды.
— Әү, Мөдир, әү,— дип алъяпкычларын кага-кага килде үлчәүгә капчык өю белән мәшгуль булган өлкән яшьләрдәге бер апа.
— Сиңа ни кирәк, Фатимәттәй?..
Мондый шәфкатьлелектән тол хатын югалып торды бераз. Күңеле булды, Мөдир үзе аның хәлен тиктомалдан гына сорашсын инде...
— И-и, рәхмәт инде, улым Мөдир! Ни кирәк дип, кирәкнең бетеп торганы юк инде аның...
— Конкрет, Фатимәттәй, конкрет!
— Печән кайтартасы бар иде шул...
— Печән кайтарту өчен ни кирәк, Фатимәттәй?
— Машина, улым Мөдир, машина.
— Машина табу өчен ни кирәк, Фатимәттәй?
— Беләм, улым, беләм... Бар ул... Булыр, хәстәрләп куйганы да бар.
— Печәнең кайсы диләнкедә?.. Әйтеп торма, Фатимәттәй, ул онытыла. Үзем барасы түгел ич, язып китер. Шешәнең дим, нәрәт язу өчен аның үзенә үк бланкасы да ябыштырылган. Онытылмый да, төшеп тә калмый. Шулай бит, Фатимәттәй!..
— Беләм, улым Мөдир, беләм — андый нәрәтләрне язган бар,— дип, алъяпкычларын кага-кага, ничек килгән булса, шулай ук китеп тә барды Фатимәттәй.

Мөдир, ышанычлы кешеләре белән, үзенең эш урынына — ремонттагы орлык киптерү корылмасына таба үтте. Бу корылма ындыр табагында үзенең биеклеге, серлелеге һәм тыныч почмакта урнашкан булуы белән башка һәммә корылмалардан аерылып тора. Мөдир рөхсәтеннән башка анда керү катгый тыела. Тәртип куелган. Ишекләр бикле була, теләсә кемгә ачылмый. Пароль — шешә чыңы!

Корылманың ишеге ачылу белән иң алдан Мөдир үзе узды. Баскан саен челтер-челтер килеп, җаннарына рәхәт һәм сихәт биреп, шешәләр шалтырады. Ул да түгел, көчәя барган шешә чыңы астында ул югары күтәрелә башлады. Ни җитте баскычтан гына түгел, шешәләрдән өелгән баскычтан. Исең-акылың китәрлек — корылманың түшәменә җитәр-җитмәс биеклектә әрдәнәләп шешә тавы өелгән иде. Мөдирнең осталыгына хәйран калырлык, шешәләрне ул шундый итеп өйгән, цементсыз-кадаксыз дигәндәй пирамида корган да куйган. Горурланмаслык та түгел, әнә ничек югарыда утыра ул. Бишеккә чумган диярсең, шешәләре җай гына тирбәлеп, атынып тора. Ияреп кергән ышанычлы кешеләренә шуннан торып кына вәкарь белән дәште ул:

— Шешәдән дә әйбәтрәк нигез юк ул, егетләр! Греклар төзегән пирамиданы да, Сөембикә манарасын да эшереп сала безнең шешә! Пирамидаларың җансыз катып калган, диләр. Ә Сөембикәсе бөтенләй авыша бара анда. Ә безнең шешәләр, менә, чылтырап тора. Авышмый да, җансыз катып та калмый, тик тибрәнә һәм үз аягында нык тора! Шешә — безнең нигез, егетләр! Аны аракы тутырган посуда гына дип уйлаучылар ялгыша һәм ничек кенә ялгыша әле! Шешә барысын таба — бу бер! Аяк астындагы шешәләрдәге язулар шаһит, монысына ышану кыен түгел, укып карый аласыз... Бүгенге авылның әлегедәй елъязмасы бары монда гына теркәлә... Кирәксә, кош сөтен дә табабыз анысы. Шешә — дуслаштыра! Ике булдымы, бәхәссезме?.. Шешә — югары күтәрә, өчме?! Боларын теләсә кайсы ахмак белә... Ә хәзер мине тыңлагыз, монысы дүртенче, һәм аны Мөдир генә белә: шешә — алыштыргысыз төзү материалы! Нигезгә аеруча шәп була... Колагызга киртеп куегыз, материаль нигез турында гына түгел сүз — рухи нигезне дә шешә белән ныгытканда әйбәт. Шешә ныгыткан нигез авышмый да, янтаймый да, егетләр. Үз тәҗрибәмнән беләм. Яшәсен шешә!..

— Яшәсен шешә!.. Яшәсен безнең Мөдир!..

Бәхетле авазларның, шешә чыңына кушылып, кайтавазы озак яңгырап торды.

Офыкта адашып йөргән болытлар, бергә укмашып, тәмам куерып килә иде. Әллә каян гына көчле җил исеп куйды. Хатын-кыз ашыгырга, кабаланырга тотынды. Ачык яткан көшелләрне берәм-берәм капларга керештеләр. Орлыкка дигән борчакны чылатудан куркып, агроном егет гел ашыктырып торды. Ни итсә иттеләр, җиргә беренче яңгыр тамчылары төшкәндә, борчак көшеле ябык амбарга кертеп бетерелгән иде.

Ул да түгел, пәри туе уйнатып, давыллап җил исә башлады. Көшелләр өстенә капланган җәймәләрне дер селкетте, чит-читкә өелгән кибәкләрне тузгытты. Күк күкрәде, яшен яшьнәде. Коеп яңгыр ява да башлады. Чыр-чу килеп, ябулы урыннарга йөгереште халык. Кулындагы себеркесен ташлап, туксан белән барган Сөләйман карт та амбар алдына теркелдәде. Микәй булып Микәй кабаланды, ындыр табагының ерак почмагында торган орлык киптерү корылмасына таба чабып үтте.

Малайлар түбә астындагы көшелләр өстенә менеп мәтәлчек атып уйнарга керешге. Азат исә каравыл өе кыегы астында ышыкланып калган иде. Бер җай табып, малайлар янына элдерим дип торганда, авылдан ындыр табагына таба кемнеңдер ашыгып-кабаланып йөгергәнен күреп алды ул. Ашыгыч һәм әһәмиятле эше бар, күрәмсең, җилгә, яшенгә, яңгырга да карамый йөгерүендә булды кеше. Йөк үлчәүче икән. Ярым бөкрәйгән хәлдә йөгереп килеп җитте ул аның янына. Еш-еш сулыш ала, манма суга баткан... Ә кәефе күтәренке!

— Өлгердем...— диде ул, килеп җитәр-җитмәс үк үзенең куанычын уртаклашып.

— Чылангансың ич,— диде Азат, сулышына буылып торган Йөк үлчәүчене кызганып.

— Юк, ул турыда түгел, ягъни мәсәлән, кибеткә өлгердем,— дип ачыклык кертте тегесе.

Аңладым, дип баш какты Азат.

— Безнекеләрне күрмәдеңме? — дип сорады сулуы һаман да басылмаган Йөк үлчәүче.

— Кемнәр?

— Мөдир белән Капчык хисаплаучы, ягъни мәсәлән.

— Юк, күрмәдем.

— Ә Микәйне?..

— Микәй әнә теге якка чапты,— диде Азат, кулы белән орлык киптерү корылмасына күрсәтеп.

Йөк үлчәүче, бөкшәя төшеп, ике дә уйламый Микәй чабып үткән якка элдерде. Шундый ашыгыч иде эше, хәтта күлдәвекләрне дә урап тормады ул, турыдан бәрде.

Яңгыр чиләкләп коюын белде. Кара-кучкылланып килгән болыт бер якка да авышырга теләмәде, нәкъ авыл өстендә эленеп торды. Баш түбәсендә торган түбәтәй диярсең, як-ягыннан чал чәчләр сыман кояш нурлары чәчелгән. Шул тамашага сокланып озак кына карап торды Азат. Ә күңелен сорау бимазалады: «Нигә эле Микәй артыннан йөгерде бу Йөк үлчәүче?.. Микәй бит бер ялгызы чабып үтте...» Сорау кызыксынуга әверелеп, кызыксыну аның үзен дә шул якка тартты. Күлдәвекләрне ерып, нәни-нәни гөрләвекләр аша сикереп, ул да ындыр табагының аргы почмагына таба йөгерде. Коеп яуган яңгыр суы чәчләрдән борынга, борыннан ияккә күчеп акты.

Ачык калган ишектән эчкә үтте Азат һәм күзләре чагылып куйды. Каршыда түбәгә җитеп килгән шешә тавы өелгән — үз күзләренә ышана алмый торды малай. Бу кадәр шешә каян килгән монда?.. Һәм аны кем ташыган, кем өйгән?.. Ничек итеп өйгән? Башка сыя торган түгел.

Алар өчәү иде — Мөдир, Йөк үлчәүче һәм Капчык хисаплаучы. Шешә тавының түбәсенә үк менеп кунаклаганнар да иркенләп кәеф-сафа сөреп утыралар. Өстәлләре дә, дөньялары да түгәрәкләнгән. Алларында әле бушарга өлгермәгән өч шешә һәм бер стакан. Ботарлап куелган какланган каз, кыерчыгы сындырып алынган түгәрәк икмәк. Егет шулай гаҗәпләнеп торганда, «әле монда мин дә бар» дигән сыман, янәшәдә генә Микәй башын болгап алды һәм бар гәүдәсе белән калтыранып куйды. Кышын салкын җилдә сыкраган агач кәүсәләре сыман аның дәү кара мөгезләре шыгырдап куйды. Микәй чаптыр-чоптыр итеп алдындагы консерва банкасын ялый иде. Бар дөньясын онытып ялый...

Яңгыр шыбырдавы астында урнашып алган тынлыкны шунда Йөк үлчәүченең карлыккан тавышы бүлдерде:

— Шеф дим, Шеф... Ничек дидең, тагы кабатла әле, Шеф...

— Хәтереңне әйтер идем... Бу хәтер белән, аракы эчәргә түгел, мич башында утырырга сиңа,— дип җавап кайтарды Мөдирнең калын тавышы.

— Соңгы тапкыр дим... Шеф, ә, Шеф?..

Һәр сүзенә, һәр иҗегенә басым ясап кабатлады Мөдир.

— Аракы алдырсаң — ара калдырып булмый, ара калдырсаң — аракы алдырып булмый. Бу — заман әйтеме булыр! Төшендеңме?..

— Төшендем,— дип, башын какты Йөк үлчәүче һәм тырышып кабатларга кереште.— Ара калдырсаң... аракы алдырсаң...

Күпме генә тырышмасын, иple-башлы хәтерләп калмаган иде барыбер.

— Ахмак! — дип туктатты аны Мөдир.— Синең белән эчкән мин җүләр. Әйдә, сал да, синең хәтер өчен чөңкәйтеп куябыз.

— Хәтер нәрсә!.. Аны эчеп тә, ашап та булмый. Яшәсен шешә! Шешә яшәсен.

Беразга тынлык урнашып алды. Ишек төбендә торган Азатны шунда гына күреп алдылар.

— Кем бу? — дип сорап куйды Йөк үлчәүче, баланаяк бармагын малайга төбәп.

Тегеләр икесе берьюлы урта төяк бармаклары белән авызларын сыпырып, үзара карашып куйдылар.

— Үзе! — диде Мөдир.

— Ничек үзе, ягъни мәсәлән...— дип гаҗәпләнде Йөк үлчәүче, күзләрен челт-мелт йомып.

— Үзе дигәч, үзе! — дип кабатлады Мөдир. Йөк үлчәүченең ризалашмый чарасы юк иде. Аңлаганын белдереп, башын кагып куйды да, аркасына янтая төшеп, авызын зур итеп ачкан килеш түбә астында гөлдер-гөлдер килгән күгәрченнәрне күзәтә башлады. Бер очтан озонлы яңгыр һавасын да иснәве иде булса кирәк.

— Шеф дим, ә, Шеф... Соңгы тапкыр гына кабатла әле?

— Нәрсә тагы? — дип аңышмады Мөдир.

— Аракыны алдыру турындагыны...

— Ахмак! — диде Мөдир, ачуы чыгып. Башка берни дәшмәде.

— Үзе, ягъни мәсәлән,— дип мыгырданды, аларның барлыгын онытkан Капчык хисаплаучы һәм янәшәдә яткан шешә этикеткаларына теркәлгән «нәрәт»ләрне укырга кереште: «Әтәмән планы урманыннан утын кайтартырга иде. Габдерәхим абзаң...» «Ат сикерткән тау астыннан — нигезгә таш. Фәйрүзә кодачаң...»

Мөдир кешегә күп сөйләшү килешми. Ул эш белән мәшгуль булды: бушап калган ике шешәне ипле генә үзе төзегән пирамидага тоташтырып куйды. һәм шешәләрнең шулай ипле торуына куанып, тулар-тулмас бер стаканны янә бушатып алды. Какланган казның бер ботын авызына тыкты... Бераздан тагы кабатлады.

— Синең чират, көттермә,— дип, Капчык хисаплаучы Йөк үлчәүченең иңбашына төртте. Тегесе һаман түбә астындагы күгәрченнәрне күзәтеп, ачык авыз белән озон сөзә иде.

— Көтмим, чиратсыз эчәм,— дип түнтәрде Капчык хисаплаучы. Моңарчы тын гына ялмануында булган кәҗә тәкәсе, үзенең монда икәнлеген белдереп, кымшанып куйды һәм шешәтау итәгенә үк килеп, мөлдерәмә күзләре белән югарыга текәлде. Аны күрмәделәр. Ал аягының тояк очы белән нигездәге шешәләргә шак-шок бәреп хәбәр салды Микәй, үзенә игътибар сорады, акрын гына «мәэлдәп» алды.

— Тутырып сал,— дип, Мөдир шешәне Капчык хисаплаучыга төртте.— Көттермә Үзен.

Шешәтау түбәсеннән алпан-тилпән түбән төшеп, консерва банкасына өч-дүрт «буль-буль» агызды Капчык хисаплаучы. Азат сискәнеп китте, һәм үзен-үзе белешмичә кычкырып җибәрде:

— Нишлисез, шайтаннар!

Аны, әйтерсең, бөтенләй ишетмәделәр. Ул монда, гомумән, юк иде сыман. Капчык хисаплаучы шешәләрдән өелгән баскыч буенча ничек төшкән булса, челтер-челтер иткән чың астында шулай ук ипле генә кире менеп тә китте. Ә кәҗә тәкәсе почтыр-почтыр килеп банканы яларга кереште. Азат, банкага үрелеп, аракыны түгәргә иткән иде, Микәй аңар шундый итеп карады... «Башың ике булса гына кил» — дип әйтә иде булса кирәк — кан баскан күзләрен акайтты, иләмсез зур мөгезләрен сөзәргә әзерләде. Чигенми булдыра алмады Азат.

— Мин сине күргәнем бар,— дип, Азатка әби-чеби бармагын төбәде шешәтау түбәсенә менеп утырган Капчык хисаплаучы.— Күргәнем бар...

«Миңлегали абый, туктатыгыз, нишлисез... Миңлегали абый...» —

дип кычкырырга ачылган авызыннан сүз чыкмады Азатның. Текәлеп карап торган Капчык хисаплаучы аны чынлап та танымый иде.

— Үзе! — диде Мөдир, тагын берне төшереп алгач.

— Тьфу, тьфу,— дип, әлегәчә ачык авыз белән түбә астындагы күгәрченнәрне санап утырган Йөк үлчәүче тик торганнан төкеренә башлады.

— Үзе түгел, үзле...— дип, гомерендә беренче тапкыр Мөдир белән килешмәде ул, күгәрченнәргә йодрык болгый-болгый төкеренде.

— Үзлемени...— дип, Капчык хисаплаучы кычкырып көлеп җибәрде.— Үзлемени?..

Башта авызын каплый-каплый көлде ул. Аннан мөлдерәп төшкән күз яшьләрен сөртә-сөртә көлде. Сулышына буылып, Йөк үлчәүчегә төртеп күрсәтә-күрсәтә көлде. Эчен тотып та көлде. Шешә баскычлардан тәгәри-тәгәри көлде...

Мөдир көлмәде. Мөдир кешегә көлү килешми — ул елмайды гына. Йөк үлчәүче һаман төкеренүендә булды, күгәрчен кучтәнәче чынлап та үзле булып чыккан иде, ахры...

Ә Микәй, шешәтау итәгенә килеп, алгы тояклары белән шак-шок итеп янә хәбәр бирә башлаган иде. Мөдир белән Йөк үлчәүче аңар игътибар итмәде. Микәй тагын шакылдатты, тагын... Аны ишетмәделәр. Азат Микәйне куарга итеп карады, ничек кенә булса да ярдәм итәсе, бу куркыныч корылма астыннан аны исән-сау коткарасы килде малайның. Зур мөгезләр каршы төште, кан баскан акайган күзләр... Аны һичкем күрергә дә, ишетергә дә теләми иде бугай монда. Шифер түбәгә шыбырдап яуган яңгыр тавышы көчәйгәннән-көчәя барып, аның колагын, зиһенен томалады. Торган саен ныграк шаулый барган колакларын учлап, каралтыдан чыгып китми чарасы юк иде малайның.

Ишекне ачып чыгуга, саф һава килеп бәрелде. Әмма куллары ишеккә ябышкан диярсең, Азат бер тын бусага төбендә тоткарланды. Эчке яктан яңгырап ишетелгән мөдир тавышы тоткарлады аны.

— Егетләр... Микәй исәнлеге өчен эчтекме соң әле без?..

— Эчтек,— дигән тавышы ишетелде Йөк үлчәүченең.

— Эчсәк, тагы берне!..

— Ике булды инде...

— Өч фарыз! Өч!.. Үзенә дә салыгыз, җанкисәккәйнең. Онытырга ярамый бәгырьне... Әйдә, Микәй исәнлеге өчен!

Үзе җиңел генә күтәреп куйды да, янәшәсендәге Йөк үлчәүчегә бәйләнергә тотынды Мөдир.

— Син нәрсә, Микәйгә исәнлек теләмисеңмени?.. Болай булмый, юк, юк, калдырма... Сезнең ишеләрнең бишенә тора ул Микәй-бәгырь...

Баш очында түбәтәй сыман эленеп торган болыт акрынлап булса да офыкка авышты. Кояш чыкты. Нурлы Аланның бер башыннан икенчесенә Салават күпере сузылды. Шул мәһабәт күпер астыннан ындыр табагына авылдашлар йөгерешеп чыкты. Күкрәк тутырып яңгыр һавасын сулый-сулый эш урыннарына таралыштылар. Чырык-чырык көлештеләр, шаулаштылар, яңалыкларын бүлештеләр — һәркемнең күңеле күтәренке иде.

Микәй тагы бер банканы ялтыратып куйды. Аңа тагы шайтан каргаган шул эчемлек җитми башлады. Ләкин аны кайгыртучы, аңарга эчемлек салырга җыенучы юк иде. Аның дөньяда барын онытканнар. Җен ачуы чыкты кәҗә тәкәсенең. Кан сауган күзләре акайганнан-акая барды, бөтен гәүдәсе калтыранырга тотынды, дөнья айкала-чайкала башлады. Тутык төсендәге калай банкага, тутык төсендәге шешәләргә һәм шешәтауга чыкты аның ачуы. Аннан тутыкка чумган кешеләргә текәлде. Тутыккан кешеләр кайсы-кайда түнеп ыңгыраша, үрмәли, тәгәрәшә башлаган иде. Ул да түгел, көтмәгәндә, әле генә тутык сыман тоелган

әйләнә-тирә аның күз алдында ялкын төсенә кереп яна башлады. Каршындагы калай банкадан ут күтәрелде. Тау булып өелгән һәр шешәдән ялкын бәреп чыкты. Шешәтауны тоташ ут ялмап алды. Тау гына түгел, тутыккан кешеләр тәгәрәшеп янырга кереште. Шул ук ут аның үзен дә чорнап алды, үзе дә яна — ялкынланып, дөрләп яна... Януын яна, әмма торган саен суыграк була барып, тәмам калтырата, туңдыра.

Үзе яну бер хәл, дөрләп, ыңгырашып янган кешеләр кызганыч тоелды аңарга. Яналар, көяләр, харап булалар ич... Кешеләр яна! Кеше дип әйтерлекләре калмый. Чара күрергә, ярдәм итәргә кирәк... Уятырга теләп, мөгез очлары белән тәрткәләде ул күз алдында дөрләп торган кешеләргә. Уянмадылар. Шешәтау итәгендә ятуларын гына беләләр. Кузгатырга теләп, ул аларны төртеп-төртеп җибәрде — шешәләр белән бергә тәгәрәштеләр, әмма уянмадылар... Яналар, дөрләп яналар ич. Алардан чыккан ут дөньяга капмасын... Дөньяны коткарырга иде ул уттан. Дөнья бер генә, ул янмаска тиеш! Янмаска! Дөньяда яшел төс — яшәү һәм яшьлек бар! Дөньяда аклык — ак юллар, ак кыялар, ак кыялар турындагы ак хыял бар! Уттан сакларга кирәк үзләрен, уттан...

Дөрләп януларында дәвам иткән кешеләрне әвәләргә, төрткәләп тәгәрәтергә кереште ул. Мөгезләрен кызганмады — ялкыннары гына сүнсен...

Орлык киптерү корылмасы эченнән ярдәм сорап кычкырган авазлар ишетелде. «Каравыл» кычкыру һәм ыңгырашуга күчте ул авазлар. Яңгыр үтеп көннең шулай аязуына куанып эшкә керешкән нурлы аланлылар, берни аңышмады, ни дияргә белмәделәр. Югалып калдылар. Ялвару катыш хәвефле тавышлар көчәйгәннән-көчәя генә барды.

— Шайтаннармы әллә? — дип гаҗәпкә калды Сөләйман карт булып Сөләйман карт. Күпме гомер кичеп, күргән-ишеткәне юк иде мондый авазларны.

— Шайтаннар...— дип җөпләде башын күңелсез генә түбән иеп, чарасыз калган Азат.

— Шайтаннар... Шайтаннар...— дип кабатлады хатын-кызлар, әледән-әле орлык киптерү корылмасына таба шикле караш ташладылар.

Ул да түгел, корылма эчендә кинәт әйтеп аңлату мөмкин булмаган шау-шу һәм гүләү авазлары яңгырарга тотынды. Җир тетрәдеме, яшен суктымы, тау ишелдеме — һич аңларлык түгел иде. Күз алдында корылманың капкалары як-якка ачылып китте. Ташкын булып тәгәрәшкән шешәләр арасыннан җан-фәрман чабып зур кара шәүлә атылып чыкты. Анда-монда борылмады шәүлә, туп-турыга чапты һәм горбил тактадан тотылган биек койма өстенә ташланды. Кинәт яшен суккандагыдай тавыш ишетелде — имән баганалар урыннарыннан кузгалды, калын горбилләр, урталай сынып, йомычкадай як-якка чәчелде, пыран-заран килде. Ә койманың аргы ягында упкын сыман тирән чокыр — кара шәүләне Ай күрде, Кояш алды...

— Шайтан...— дип ухылдады бөтен ындыр табагы.

Аларның ухылдавын ташкын булып ындыр табагына, ындыр табагыннан авылга таба тәгәрәшкән-аккан шешә шавы күмеп китте. Шешәләр, әрсезләнеп, этешеп-төртешеп, бер-берсен сытып тәгәрәште. Йөзәрләгән, меңәрләгән шешә берьюлы челпәрәмә килде. Ташкын булып аккан пыяла ватыклары дулкын-дулкын югары күтәрелеп тау итәгендә утырган авылга, өй түбәләренә, бакчаларга, урамнарга чәчрәде. Юллар һәм сукмаклар яшькелт-зәңгәр пыяла кабырчыклар белән тулды.

— Шайтан түгел, Микәй ул,— дип, җан авазы чыгарып, шешә ватыкларын ера-ера торып йөгерде Азат. Көрәк һәм себеркеләрен эләктереп, аның артыннан сак кына башкалар кузгалды. Пыяла өстеннән йөрергә күнекмәгән халык «ух-ах» килде.

Тимер-томыр кисәкләре, пыяла ватыклары белән тулган тирән чокыр төбендә ятучы Микәй тынып калган иде инде. Чәрдәкләнгән койма такталарына тотынып, пыяла ватыкларына киселгән аяклары әрнүгә дә

игътибар итми озак карап торды Азат. Бер ялгызы калгач та байтак басып торды. Микәйнең бөтен язмышы күз алдыннан узды. Чана башындагы толып астыннан әле генә көмеш нурлар сирпеп башын калкыткан бер нарасый иде ич ул. Ә хәзер әнә — чокыр төбендә... Аның һавада эленеп калган зур мөгезләре сорау билгеләре булып тоелды малайга. Эре-эре сорау билгеләре...

Кичен, берьялгызы ындыр артына чыгып, озак кына уйга бирелеп йөрде Азат. Микәй белән бергә үткән борчу-хәсрәтсез елларын, хыялый бала чагын да мәңгегә җуя түгелме ул?.. Ничек болай килеп чыкты? Табигатьнең шундый камил һәм риясыз җан иясе нигә әле шундый аянычлы язмышка дучар булды?.. Кем гаепле моңар? Кем?.. Кешеләргә бит Микәй һичнинди зыян китермәде. Кешеләрне үз итте һәм яратты Микәй. Ул кешеләргә ышанды. Бөтен авыл җылы мамык шәлгә төренде. Мамыгын гына түгел, җанын да бирергә риза иде бит ул кеше өчен. Нәтиҗәдә, әнә ничек килеп чыкты... Кешеләр дә начарлык теләмәде бит югыйсә...

Сораулар бәгырен телгәләде үсмер малайның. Тамак төбенә төер булып тыгылды, ике чигәсен китереп кысты шул ук сораулар.

Шунда Азат бакча ягыннан кемнеңдер үзенә якынлашып килүен абайлап, сискәнеп куйды. Айсылу апасы икән.

— Азат...— дип гаҗәпләнде ул, көтелмәгән бу очрашудан каушый калып.— Нишләп йөрисең монда?

— Болай гына, Айсылу апа... Ә син кая?

— Югары Сөнгә...— диде ул, кулындагы төенчеген кая яшерергә белмичә уңайсызланып.

— Нурлы Аланны күрәсең дә килмәс инде... Шулаймы, Айсылу апа?

— Нурлы Алан — үз авылым кебек, Азат,— диде Айсылу, малайга якын ук килеп. Күрәмсең, аны аркасыннан гына булса да сөясе килгәндер. Азатның инде гәүдәгә шактый калкынган булуын искә алып кына ниятеннән кире кайтты.

— Айсылу апа,— дип дәште малай, күзләрен аңардан яшерергә тырышып.— Башка беркайчан да күрешмәбез инде...

Малайның кәефен күтәрәсе килепме, Айсылу апасы җанлана төште.

— Әле Алсуны алырга киләсең бар бит...— дип, елмаерга итте ул. Һәм бертын күзләрен тутырып Азатка карап торды.

Айсылу ашыга-кабалана китеп барды... Күбәләк кар явып торган бер көндә кыңгыраулар таккан пар атта килен булып төшкән Айсылу шулай тын гына караңгы сукмак эченә кереп югалды. Авылга илткән тыкрыктан кемнеңдер адашып өйгә кайтмый калган ялгыз кәҗә бәтие сузып-сузып кычкырырга кереште...

# Мөдәррис Әгъләмов

## Синең кулда каләм

Үзең!
Үз теләгең белән
Үз тамгаңны киртләгән —
Тукталып калмаска тиеш
Халкың тапшырган каләм.

Үз сукмагың!
Үзең салдың,
Беркем көчләп кертмәгән.
Карасы бетсә, каның бар,
Халкың тапшырган каләм!

Ата-бабаң беркайчан да
Уракка кичекмәгән,
Син дә кырда. Синең кулда
Халкың тапшырган каләм.

Җырны чикләмәгән вакыт,
Ә гомерне чикләгән...
Рәнҗеп туктамасын
Сиңа
Халкың тапшырган каләм.

## Мин дөньяга багам

Авызын ачкан итектән,
Бармак борын тәрткән,
Чалбар балаклары күптән,
Теткәләнеп беткән,
Ыңгырашып турая тез
Иңгә ҭөшкән йөктән...
Кинәт башымны күтәреп
Киң дөньяга багам.

Кырмыска күтәреп алган
Бер зур гына салам,
«Алла ярдәм бирсен, балам»,—
Сәлам биреп калам.
Ташны ярып юлын алган,
Бер кечкенә чаган,
Күзәтәм дә баш күтәреп
Бу дөньяга багам.

Орлык чәчәр өчен чәчкә
Башын түбән иган,
Карт имән, дәвамын күреп,
Башын күккә чөйгән,

Яңгыр ява, карлар ява
Йолдыз ява түбән.
...һәммәсе җиргә карый дип,
Киң дөньяга багам.

Күтәрелсәң чиксезлек бар —
Аера болыт... томан...
Җирдә яшәү — галәмдәге
Билгесезлек сыман.
Нинди бәхет, шуны аңлап
Җирдә басып торам,
Шул хәлемдә, горурланып,
Бу дөньяга багам.

Бабамнар алла тудырган,
Ә мин — инкарь итәм...
Рухи туган юлга чыккан
Ерак чиксезлектән...
Тәрәз төбендәге гөлнең
Иреннәре кипкән,
Аңа сибәргә су алып,
Киң дөньяга багам.

## Үзе бәхет бит ул

Тыңлап кына кара: күпме аваз,
Күпме тибрәнүләр, күпме моң...
Һәм тоясың сулыш белән бергә
Күкрәгеңә тормыш тулуын.

Юк, түгел бу яфрак шавы гына,
Түгел урман гүләве генә...
Актарылып,
Катлам-катлам булып
Чорның үткән көннәре менә.

Юк, түгел бу кошлар җыры гына,
Түгел кәккүк авазы гына.
Сине җиргә, күккә, тереләккә
Бәйли торган җепләр сузыла.

Юк, түгел бу җил хезмәте генә,
Түгел чишмә агышы гына.
Баксаң, табигатьнең хәрәкәткә
Дәшеп торган тавышы була.

Юк, түгел бу карлар төшү генә,
Түгел яңгыр коюы гына.
Баксаң, чистарырга кирәклеген
Сискәндереп куюы була.

Шулар аша сиңа планетаның,
Кешелекнең намусы дәшә.
Үз-үзенә кеше кабер казый,
Әгәр шуны аңлый белмәсә.

Тыңлап кына кара: күпме аваз,
Күпме тибрәнүләр, күпме моң...—
Үзе бәхет бит ул тереклектә
Шул хикмәтнең берсе булуың.

## Тәрәзәгез булса

### I

Яңа урам булыр монда,
Бетә иске йортлар.
Кич җитүгә, сокландырып,
Кабыныр төсле утлар.

Каударланып, әйтә алмый
Саубуллашу сүзен
Күбекләнеп чәчәк аткан
Соңгы тапкыр сирень.

Тупыллар ап-ак кәфендә,
Хушлашалар кебек;
Каралып калган йортларны
Ак мамыкка төреп.

Уяныгыз!
Бар тирә-як
Киемен алыша.
Ачыгыз тәрәзәләрне,
Тәрәзәгез булса!

### II

Пәрдәләрне сискәндереп,
Керсен язгы һава,
Бүлмә болай да кешене
Кан чыкканчы сава.
Шагыйрь такыр басу кебек
Шып-шыр бушап кала,
Өстәлендә торган агач
Сынга охшап кала.

Иң кадерле вакытыңны
Ашый комсыз йокы —
Үзең белән фикерең дә
Инде йокыныкы.
Дөнья яшәр, күкрәгеңә
Язгы һава тулса.
Ачыгыз тәрәзәләрне —
Тәрәзәгез булса!

III

Түшәмнәрдә «куян» бии,
Кояш чакыра тышка.
Хәрәкәткә дәшә заман
Һәрбер тукталышта.
Бүлмәгә куылган суда
Бит чылату? Җиткән!
Язгы сулар, ташкын булып,
Төшә биеклектән.

Бар тереклек хәрәкәттә
Ява, ага, бара.
Күтәрелсәң, кояш белән
Якынaя ара.
Таш булып таш та тарала
Суламыйча торса.
Ачыгыз тәрәзәләрне,
Тәрәзәгез булса!

IV

Язгы һава шундый тәмле,
Шалкан кебек сусыл.
Яшәү ул — шул: син илеңнең
Авазына кушыл!
Күр, әнә тынычлык кошы
Ак күгәрчен куна.
Бөеклекне эзләп ятма
Китаплардан гына.

Шаккатырмасын бөекнең
Даны, көче, яше...
Ул — илеңдә, хәрәкәттә
Ул — үзеңдә яши.
Киләчәккә барасы бар,
Саубуллашыйк, ягез.
Ачыгыз тәрәзәләрне,
Булса тәрәзәгез!

## Бер барырмын әле...

Әнкәй, әнкәй, мин бит һаман исән,
Син киткән бу авыр дөньяда
Бөтен нәрсә үзгәргәндер дисәң,
Ялгышасың, алай уйлама.

Аналарда һаман бер үк хәсрәт,
Алар һаман куркып уяна.
Стенадан карый тоныкк сурәт —
Хәсрәт-кайгы бетсә, ни кала?

Балаларың сабый имезәләр,
Чыр елатып көлмәк кигезәләр,—
Тәгәрмәчле бишекләр генә...
Варисларын көтә еллар буе
Туган йортта ишекләр генә.

Оныкларың кәнфит кимерәләр,
Асфальт юлдан чыр-чу йөгерәләр —
Табаннарын камыл кадамый...
Бишек тә юк, әлли-бәлли дә юк,
Чөнки хәзер әби карамый.

Бернәрсә дә үзгәрмәгән дисәм,
Дөрес, кайбер нәрсә үзгәрә.
Көлтә кую бетте, шуңа хәзер
Кырда калса кала тезмәләр.

Үзгәрешләр алай күп тә түгел,
Кайтасыбыз да юк үткәнгә.

Көрәк кирәк түгел, бәрәңгеләр
Калса кала җирдә — түтәлдә.

«Уфалла»ны күптән онyттылар,
Ташу да юк хәзер симәнә.
Буш басу да калмый, һич югында
Рәхәтләнеп үлән сибәләр...

«Тик бер генә телем ак ипине
Авыз итсәм әгәр бу көнне,
Өр-яңадан терелеп китәр идем,
Йөгереп китәр идем шикелле».

Синең сүзләр. Зәйдән ул хикмәтне
Табып кайтты әткәй ахырда...
Син юк идең инде... Бу вакыйга
Булгандыр күк ерак гасырда.

Сугыш әтиләрне — янган утта,
Сезне бозлы суда сынады.
Сугыштан соң, җирдә тәмуг диеп
Сөйләдегез Хиросиманы.

Ә уйласаң, үзгәрешләр бик күп,
Җиңеләйде дөнья халыкка.
Җиңеләйгән саен, якынайдык
Хиросима дигән тәмугка.

Үзгәрешләр бик күп, сез сугышны
Җиңгән кебек, без дә ахырда
Бу афәтне кичеп чыкса идек
Алда торган яңа гасырга.

...Әнкәй, әнкәй, ә мин һаман исән,
Инде байтак юллар тапталган.
Синең янга бер барырмын әле,
Барырмын да кабат кайталмам.

Үзе килмәгән шул, тик хат кына
Яза икән бу дип уйлама...
Улым, кызым тыныч дөньялыктан
Хат язсалар иде миңа да.

## Ике алма...

Алмагач ул нигә кирәк, диләр,
Алмаларын өзеп алмагач.
...Беренче ел ике алма өздем.
Ике алма... ике алмагач.

Кеп-кечкенә сабый иде алар,
Ялгыш тисәң, сына торганнар.

Еллар үтте... инде бага-бага
Алма бирә алыр булганнар.

Әгәр саклый белсәң, җилләргә дә,
Давылларга да дим түзәрләр...
Ике алма... миңа иң зур бәхет,
Калганнарын инде өзәрләр.

## Тукта, мизгел

Кабат-кабат
кабат кабатланмас,
Үзәк өзелер дә үзгәрелер.
Тукта, тукта бары бер минутка,
Миңа кайгы алып килгән мизгел!

Вакыт ага, әмма мизгелләрен
Хәтер җыеп кала сайлап кына.
Тояк тавышы килә. Шулай чаба
Шатлык алып килер җайдак кына.

Кеше була бик шатлыклы хәлдә,
Кеше була бик кайгылы хәлдә.
Көнлек мәшәкатьләр арасында
Кеше кабына — яна мизгелләрдә.

Хәсрәт китердем, дип син курыкма!
Тукта, тукта, мизгел, бер минутка!

## Үзгә моң

Д. Г.

Актанышның һәйбәт туфрагында
Томырылып үскән ак каен
Көтмәгәндә юл чатына чыгып
Күкрәгемә салды башкаен.

Юлларым гел бер тирәдән үткән,
Күп мәртәбә күрми узганым.
Агылып керде җанга үзгә язмыш,
Назлап китте җанны үзгә моң.

Коелмасын дигән кебек кенә
Кагылып алам алкаларыңа,
Без гаеплемени күңелләрнең
Үз-үзләрен тапмаганына.

Юатырга теләп йөрәгемне
Башны салам ябалдашыңа,
Әллә инде үзебез ашыгабыз,
Әллә инде вакыт ашыга.

Тик соң бугай инде, юлдашыма
Ак каеным минем, дияргә,
Йөрәгемне учларыма кысып
Кала бары башны ияргә.

Миңа юлны дәвам итү кирәк,
Кузгаламын... чыккан юл озын...
Кала каен җиде юл чатында,
Калдырасым килми ялгызын.

Ак каеным кулын болгар иде,—
Ис инде, җил, зинһар ис инде...
Ак каеным,
Синдә кала моңым...
Алга чакыра юлым, хуш инде!

## Соңгы чиктә

Ахыргача!
Ахыргача барам,
Үз язмышым үз язмышын табар.
Бал кортлары әнә соңгы чиктә
Канатлары тузып капланалар.

Ахыргача!
Ахыргача барам,
Җырланмаган җырым кирәк әле.
Былбыллар да әнә соңгы чиктә
Туктап кала ярылып йөрәкләре.

Ахыргача!
Ахыргача барам,
Сөенә-сөенә дөнья чистартуга —
Тукраннарның мигә, соңгы чиктә,
Тукылдауларыннан кан савыла.

Ахыргача!
Ахыргача барам,
Юк, калмады көчне саклар чама,
Чорлар аша хәбәр китерергә
Янып егылачак атлар чаба.

Яңа гасыр, әнә, капка ача —
Ахыргача барам,
Ахыргача!

*Быел август аенда татар халкының күренекле улы, революционер-ленинчы Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тула. Г. Ибраһимов тарафыннан «Шәрыкның бөек революционеры» дип олыланган М. Вахитов Бөек Октябрь революциясенең җиңүенә һәм илебездә социалистик җәмгыять төзү эшенә үзеннән зур өлеш кертте. Журналыбызның бу санынннан башлап күренекле революционерның тормышы һәм эшчәнлеге турында материаллар тәкъдим итела башлый.*

**Рәфыйк Нәфиков,**
тарих фәннәре докторы,
профессор.

# ЛЕНИННЫҢ КӨРӘШТӘШЕ

Мулланур Вахитов Беренче рус революциясе көннәреннән үк язмышын эшчеләр сыйныфына бәйли. В. Тихомирнов, В. Скрябин, А. Аросев, Н. Чепурных, С. Рахманкулов кебек иптәшләре белән бергә ул гектографта большевистик листовкалар һәм прокламацияләр бастыра, В. И. Ленинның «Нәрсә эшләргә?»сен чыгара.

Мулланур Вахитов революцион сходкаларда һәм демонстрацияләрдә актив катнаша. 1906 елның мартында ул укыган класс бөтен реаль училищены аякка бастыра һәм алар шәһәрдә лейтенант Шмидтны яклап күтәрелгән студентлар, эшчеләр демонстрациясенә килеп кушылалар.

М. Вахитов 1903 елдан башлап большевик Хөсәен Ямашев белән бергә «Шимбә» исемле әдәби түгәрәк утырышларында катнаша. Бирегә Идел буе һәм Урал төбәкләреннән, шулай ук Азербәйҗан, Казахстан, Урта Азия якларыннан килгән укымышлылар да йөри торган була. Түгәрәк татарча спектакльләр дә куя. Ул көннәрне искә алып М. Вахитов соңрак болай дип яза: «Тарих агышының якты, бәхетле сәгатьләрендә, яңа идеяләрнең куәтле тавышы көчле океан корабы сыман рус чынбарлыгының йокыга чумган ярларын уяткан вакытта, азатлык алуның шат авазы белән хис-кичереш чишмәләре ачылган чорда һәм яшьләрнең каһарманнарча тырышлыгы белән туды татар театры. Караңгылык көчләре куәтле һәм явыз иде, яшь бу омтылыш алдында бик зур каршылыклар ята иде, ләкин яшьлек — рус интеллигенциясенең иң яхшы вәкилләре чакыруы авазын бөтен йөрәге белән дәртләнеп кабул иткән яшьлек — ул киртәләрне үтеп чыга алды һәм үз байрагын саф килеш безнең көннәргә җиткерә алды» [1].

Мулланур Вахитов марксистик түгәрәк төзи, аның бернечә утырышын үткәрә. Ул үзе һәм аның дуслары большевистик «Урал» газетасы белән, аның фактик редакторы Хөсәен Ямашев белән даими элемтә тоталар.

Мулланур Вахитов шулай ук Казан сәнгать училищесы укучылары һәм учительская семинариядә белем алучы казах, башкорт, чуваш, мари, удмурт, мордвалар белән дә дус була. Ә Петербургка килгәч ул Л. Рейснер, С. Габиев, У. Алиев, У. Буйнакский кебек яңа дуслар таба. Алар белән бергә матбугатта карагруһчыларны тәнкыйтьләп чыга. Ул фәнни социализм идеяләрен һәм төрле милләт эшчеләренең дуслыгын ныгыту буенча Х. Ямашев эшчәнлеген дәвам итә. Үзенең бер мәкаләсендә М. Вахитов караңгылык диварлары җимереләчәк һәм яңа, бәхетле тормышның яшь үрентеләре шатланышып үсеп китәчәк көннәр турында яза, кешеләрнең ул көнгә ашкынуларын әйтә.

Большевиклар белән тыгыз элемтәдә торган һәм РСДРП(б) Үзәк Комитеты белән хат алышкан М. Вахитов татар эшчеләрен уртак революцион көрәшкә тарту буенча эзлекле эш алып бара. Ул редактор булган «Кызыл байрак» газетасында, шулай ук эшче клубларында һәм завод-фабрикаларда үткән митингларда Мулланур Вахитов һәм Мөселман социалистлар комитетының аның тирәсенә тупланган революцион канаты эзлекле рәвештә ленинчыл фикер үткәрәләр. Алар милләтчеләрне, милләт берлеге хакындагы «теорияләр»-

[1] Вахитов М. Избранное. Казань, 1967, 32—33 бб.

не фаш итәләр, большевиклар белән бергә Кызыл Гвардия отрядлары оештыралар, социалистик революциягә, Советлар властена таба барырга чакыралар.

Татар буржуазиясе милли-азатлык хәрәкәтен үз кулына ала алмады һәм бу эш аның хәленнән дә килми иде. Әлбәттә, биредә милләтчеләрнең чын йөзен фаш итүче Мөселман социалистлар комитеты да шактый роль уйнады. М. Вахитов хезмәттәшлек иткән «Аваз» демократик газетасы (1917, 15 июль саны), мәсәлән, болай дип язды: «Изелгән милләтләр өчен бер генә юл бар — ул рус социалистлары белән бергәләп эшләү». «Тарихның җаваплы сәгатендә,— дип язды М. Вахитов,— халыкның нәфрәт дулкыны, иске стройны җимереп ташлап, яңа тормыш төзегән вакытта, без үзебезнең «Кызыл байрагыбыз»ны күтәрәбез һәм бик шатланып изге максат өчен көрәшүче бөтендөнья пролетариаты сафына басабыз» («Кызыл байрак», 1917, 28 июнь саны). 1917 елның 2 августында шул ук газетада «Бөтен дөнья пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг нәрсә аңлата?» исемле зур редакцион мәкалә урнаштырыла. Бу язма төрле илләр пролетариатының интернациональ берләшүен пропагандалый, бөек марксистик принципның асылын аңлата. Газетада шулай ук фәнни социализм турында мәкаләләр, РСДРП(б) тарихы буенча материаллар, «Правда» газетасыннан алынган язмалар да еш басыла. М. Вахитов җитәкчелегендә А. М. Коллонтайның В. И. Ленин тарафыннан хупланган «Сугыш кемгә кирәк?» исемле брошюрасы да татарчага тәрҗемә ителә.

Митингларда чыгыш ясаган вакытта М. Вахитов «Бөтен дөнья пролетариатының юлбашчысы Ленин яшәсен!» дигән чакыруны кыю рәвештә әйтә. Аның практик эшчәнлеге дә сүздән аерылмый. 1917 елның маенда Кронштадт Советы Казан земская управасын үз кулларына алган М. Вахитов һәм аның иптәшләренең революцион хәрәкәтен бер дә юкка гына яклап чыкмый. «Иптәшләр, нык торыгыз. Буржуаз хөкүмәткә буйсынмагыз!»— дип язалар алар («Камско-волжская речь», 1917, 28 май саны). Менә шушы үтә җаваплы чорда М. Вахитов большевиклар партиясе Үзәк Комитеты белән турыдан-туры элемтәдә тора, хат алыша [1].

1917 елның 9 августында Казан большевиклары органы булган «Эшче» ябылгач, «Кызыл байрак» газетасында үзәк большевистик басмалардан мәкаләләр күчереп басыла башлый, бу орган татар хезмәт ияләрен илдәге хәл белән таныштырып тора. Ә шовинистик кадетлар газетасы «Камско-волжская речь» большевиклар погром оештыра дигән уйдырма белән чыккач, «Кызыл байрак» аңа үтергеч җавап бирә (1917, 23 октябрь саны). 1917 елның 11 сентябрендә газета «Демократик киңәшмә» дигән мәкалә урнаштыра һәм РСДРП(б) Үзәк Комитетының 31 августта булган утырышында кабул ителгән «Власть турында» резолюциясен тәфсилләп аңлата. 21 июньдә газета «Правда»дан «Латышлар арасында» исемле мәкалә күчереп баса. Ә бу мәкаләнең исә В. И. Ленин күрсәтмәсе буенча язылуы билгеле. Латышлар арасында большевистик идеяләрнең киң таралу фактын пролетариат юлбашчысы бик тә хуплый һәм аны бөтен илгә белгертергә кирәк дип саный.

1917 елның тарихи Октябрь көннәрендә М. Вахитов үзенең каләме белән дә, корал белән дә турыдан-туры пролетариат көрәшендә катнаша. Ул Кызыл Гвардия отрядларын оештыручылардан берсе була, аларны Казан Кремленә һөҗүмгә алып бара.

Ә Казанда Совет властен урнаштыру һәм ныгытуның үтә авыр чагында — меньшевиклар, эсерлар, буржуаз милләтчеләр һәм бүтән дошманнар, милли хисләрдә уйнап, рус булмаган халык эшчеләрен Россия пролетариатына каршы куярга маташканда — М. Вахитовның 11 декабрьда Алафузов завод-фабрикалары эшчеләре алдындагы чыгышы принципиаль әһәмияткә ия. Биредә ул Мөселман социалистлар комитеты исеменнән чыгыш ясый һәм комитетның резолюциясен укый. Казанга мөселман гаскәрләре килү һәм шәһәрдә яңа мөселман буржуаз автономиясе төзелү хакындагы уйдырманы юкка чыгара. Чын революционер-интернационалистка хас булганча, ул татар пролетариатының Бөтенроссия пролетариаты белән бер юлда икәнлеген белдерә. Үзенең сыйнфый позициясен ачык күрсәтеп, М. Вахитов болай ди: «Мөселман эшчеләренең дә, бөтен эшчеләрнең дә дошманы бер. Ул — буржуазия!»

В. И. Ленинның Тулы Әсәрләр җыелмасының утыз бишенче томында, 571 биттә «В. И. Ленин тормышы һәм эшчәнлегенең төп даталары» дигән рубрикада мондый юллар бар: «Январь, 7 (20) Ленин Сталин, М. Вахитов, Ш. Манатов белән татар һәм башкортларның милли азатлык хәрәкәте турында сөйләшә, Учредительный собраниенең совет власте яклы мөселман депутатларына үзәк мөселман учреждениесе оештырырга һәм мөселман халкына кагылган декретлар эшли башларга киңәш итә».

Бу М. Вахитовның беренче мәртәбә В. И. Ленин белән шәхси очрашуы була. Әсәрләрнең шул ук томында берничә биттән соң икенче очрашуның да датасы китерелә. 1918 елның 17 (30) январенда В. И. Ленин тагын М. Вахитовны һәм аның иптәшләрен кабул итә, алар белән Мөселман эшләре буенча Комиссариат членнары буларак сөйләшә, аларның Сөембикә манарасын һәм Кәрван сарайны мөселманнарга кайтару турындагы декрет проектларын хуплый.

[1] «Исторический архив», 1956, 6 сан, 38 б.

Бер сәгатькә сузылган әңгәмә вакытында В. И. Ленин М. Вахитовта дәүләт масштабындагы эшлеклене күреп өлгерә, аның мөмкинлекләренә тиешле бәя биреп һәм мөселман дөньясындагы абруен искә алып, М. Вахитовны хөкүмәт комиссары итеп билгели [1].

В. И. Ленин белән беренче очрашу ук М. Вахитовка һәм аның иптәшләренә онытылмаслык тәэсир ясый. Соңыннан М. Вахитов С. Сәетгалиевкә бу хакта кат-кат сөйли, Үзәк мөселман комиссариаты әзерләгән мәсьәләләрне хәл иткән вакытта В. И. Ленинның турыдан-туры катнашуын әйтә. Ә туганы Н. Вахитовка ул Ленинның ягымлылыгы, аның гаиләсендә дусларча җылы мөгамәлә булу турында сөйли [2].

Яңа постта М. Вахитов, дәүләт эшлеклесе буларак, зур сәләткә ия икәнен күрсәтә, большевиклар партиясе курсын ныклы тормышка ашыра, буржуаз милләтчеләрне принципиаль төстә фаш итә. Ул Болак арты республикасы, Хәрби Шура, Милли идарәише буржуаз милләтчеләр, контрреволюционерлар оешмаларын тар-мар итүне оештыра.

М. Вахитов җитәкләгән Комиссариат Россиянең мөселман халыклары арасында марксизм-ленинизм идеяләрен таратуда, халыклар арасында дуслыкны ныгытуда, хезмәт ияләрен империализмга каршы көрәшкә туплауда зур роль уйный.

Яңа тормыш төзүдә М. Вахитов зур өлеш кертә. Ул бик күп мәртәбәләр хөкүмәтнең җаваплы заданиеләрен үти. 1918 елның 25 июлендә, революция язмышы хәл ителә торган Көнчыгыш фронтка китәр алдыннан, В. И. Ленин М. Вахитовка, «Нинди генә өлкәгә карамастан, җитәкчелекнең бөтен тармакларында күрсәтмәләр бирү» хокукын ышанып тапшыра [3].

М. Вахитовка бирелгән таныклыкларның берсендә В. И. Ленин болай дип яза: «Барлык Совет революцион комитетларына, тимер юлларгa, пароходчылыкларга һәм шулай ук Совет республикасының бөтен власть органнарына һәм оешмаларына иптәш Вахитовка ярдәм итәргә тәкъдим ителә һәм аңа үзенә кирәкле юлда тиз йөрү мөмкинлеге тудырырга» («Дружба народов» журналы, 1957, 11 сан).

Элек изелгән халыкларның тормышын һәм көнкүрешен яхшырту мәсьәләләре белән дә, төрле декретлар һәм карар проектлары эшләп тә, докладлар белән дә Халык Комиссарлары Советына һәм В. И. Ленинның үзе янына бер генә мәртәбә керми Вахитов. Мисал өчен, ул Төркстанга автономия бирү хакында махсус доклад әзерли [4], динне дәүләттән аеру турындагы мәсьәләнең мөселманнарга кагылган өлешен әзерләшә [5].

В. И. Ленин Мөселман комиссариатының һәм М. Вахитовның эшчәнлеген игътибар белән күзәтә, аңа ярдәм итә, абруен күтәрергә тырыша. Туганы Н. Вахитов истәлекләренә караганда, М. Вахитов В. И. Ленинның квартирасында да бер генә мәртәбә булмаган. («Совет әдәбияты», 1957, 8 сан).

Урыннарда Мөселман комиссариатлары оештыру хакындагы Халык Комиссарлары Советы карарына В. И. Ленин һәм М. Вахитов тарафыннан кул куелган. Партия матбугатында, «Правда» һәм «Известия» газеталарында аларның бүтән уртак чыгышлары да яхшы билгеле [6].

1918 елның 26 февралендә М. Вахитов «Известия» газетасында «Революцион татар халкына» дигән ялкынлы өндәмәсен бастыра. Революция бишеге булган Петроград шәһәре куркыныч астында калган көннәрдә ул татар хезмәт ияләрен «стеналарында килер буыннар бәхете өчен көрәштә һәлак булган эшчеләр һәм солдатлар каны алланып торган шәһәрне — революция крепостен — саклаучылар сафына басарга» өнди («Известия ВЦИК», 1918, 26 февраль).

Үзенең эш-хәрәкәтләрендә М. Вахитов Ленин идеяләрен һәм революция интересын төп кулланма итә. Мәсәлән, аның мөрәҗәгатьләренең күбесе Ленинның «Социалистик Ватан куркыныч астында» дигән декреты белән аваздаш.

М. Вахитовның Үзәк Мөселман комиссариаты җитәкчесе, аның халыкара бүлеге председателе, Наркомвоенморе каршындагы хәрби коллегия члены, Наркомнац баш коллегиясе члены, Идел буенда азык мәсьәләсе белән шөгыльләнүче гадәттән тыш комиссар һәм Ленин вәкиле булып эшләүләре дә һич онытылырга тиеш түгел.

М. Вахитов җитәкләгән Комиссариат һәм Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе интернациональ отрядлар төзеп, Кызыл Армия частьларын булдыруга да нык булыштылар. Руслардан, татарлардан, казахлардан, үзбәкләрдән, башкортлардан һәм таҗиклардан торган мондый частьлар Петроградта һәм Мәскәүдә, Саратовта һәм Әстерханда, Уфада һәм

---

[1] Октябрь революциясенең Үзәк Дәүләт архивы. 1318 ф., 1 тасв., 383 эш, 169 б.

[2] Сәетгалиев С. Татреспублика и тов. Ленин.—«Пролетарская революция», 1925, № 9 (44), 110 б.

[3] Марксизм-ленинизм институтының үзәк партия архивы, 2 ф., 6715 эш. 1—2 бб.

[4] Октябрь революциясенең Үзәк дәүләт архивы. 1333 ф., 2 эш, 96 б.

[5] Марксизм-ленинизм институтының үзәк партия архивы, 2 ф., 1 тасв., 6785 эш, 1—2 бб.

[6] В. И. Ленин и Татария. Казань, 1964, 50—51 бб.

Донбасста төзелә. Алар Совет властен яклап Гражданнар сугышының төрле фронтларында көрәшәләр.

М. Вахитов Үзәк мөселман комиссариатының халыкара пропаганда бүлеген җитәкли, чит илләрдән килгән вәкилләр белән дипломатик сөйләшүләр алып бара һәм социалистик идеяләр җиңсен өчен биредә дә күп хезмәт куя. Төркия коммунистлар партиясенә нигез салучы Мостафа Сөбхи, күренекле татар әдибе һәм галиме Галимҗан Ибраһимов — аның дуслары була.

Мулланур Вахитовка милләтчеләр, шовинистлар, меньшевиклар һәм бүтән төрле ревизионистларга каршы кискен көрәш шартларында эшләргә туры килә. Мөселман комиссариаты төзелүне татар буржуазиясе ачу белән каршылый. 1918 елның 31 январенда «Корылтай» газетасы: «Мөселманнар үз эшләренең большевик хөкүмәте төзегән комиссариатта каралуына юл куймаслар»,— дип белдерә. Милләтчеләр «ата большевик» М. Вахитовка үч алу белән ачыктан-ачык яныйлар.

М. Вахитов исеме массаларга яхшы таныш була. Дәүләт аппаратында эшләүчеләр арасында да ул абруй казана. Партия Үзәк Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы аны Наркомнац коллегиясенең даими составына член итеп раслыйлар. М. Вахитовның 1918 ел, 2 мартында Верныйга (хәзерге Алма-Ата) җибәргән телеграммасында да патшага каршы кораллы восстаниедә катнашучылар турында зур кайгырту чагыла.

1918 елның 4 августында М. Вахитов Ленин кушуы буенча Көнчыгыш фронтка, Казанга — иң авыр урынга килә. Бу вакытта юлбашчы кискен хәлне тасвирлап болай дип язды: «Хәзер барысы да Казан — Урал — Самара фронтында чехословакларны тиз җиңүгә бәйле, революциянең бөтен язмышы әнә шуннан тора» (Военная переписка. 1917—1920 гг. М., 1957, 57 б.). М. Вахитов та үз эшчәнлегендә шушы күрсәтмәләргә нык таяна. Ул җитәкләгән Комиссариат һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Кызыл Армия частьлары, шулай ук интернациональ отрядлар төзү буенча зур эш башкара.

4 һәм 5 август көннәрендә М. Вахитов Казан губком вәкилләре белән берлектә дошман уты астында коммунистларны һәм эшчеләрне шәһәр өчен көрәшкә туплап йөри. Ләкин көчләр һич тә тигез булмый һәм август аенда Казанга дошман керә. Байлар һәм буржуаз милләтчеләр әйтүе буенча М. Вахитов кулга алына. Аны аталар. «Җиңү безнең якта булыр! Коммунизмны үтереп булмый!»— Мулланур Вахитовның соңгы сүзләре бу.

Августның дәһшәтле көннәрен яктыртып большевиклар партиясенең үзәк органы «Правда» газетасы М. Вахитов һәм Үзәк мөселман комиссариаты эшчәнлегенә югары бәя бирә. 1918 ел 17 август санында газета аларны «Октябрь һәм дөнья революциясе тантана итсен өчен» көрәшәләр дип бәһали.

М. Вахитов җитәкләгән Мөселман комиссариаты Россиядәге изелгән халыкларга яңа тормыш төзүдә генә түгел, ә бәлки элек колония яки бәйле булган илләр халыкларының милли-азатлык хәрәкәтен үстерүгә дә, көрәшнең бу мөһим тармагын эшчеләр сыйныфының гомумпролетар көрәшенә китереп кушу буенча да бәя биреп бетергесез зур эш эшләде.

Талантлы оештыручы һәм дәүләт эшлеклесе буларак М. Вахитов чын революцион, интернационалист кадрлар әзерләүгә зур шәхси өлеш кертте. Ленинчыл милли политика нигезендә ул урыннарда социалистик төзелеш практикасын һәм теориясен үстерештә. Аның кайнап торган революцион эшчәнлеге, эштәге фидакарьлеге һәм көрәштәге кыюлыгы — бик күпләр өчен үрнәк булып торырлык.

Күренекле революционер, Ленинның көрәштәше булган М. Вахитов истәлеген мәңгеләштерү инде ул елларда ук башлана. 1922 елда мәгариф эшләре буенча халык комиссары А. В. Луначарский революционер-интернационалист М. Вахитов турында бик җылы итеп сөйли. ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы көнчыгыш халыкларының коммунистик оешмалары Үзәк бюросының III Интернационалга отчетында М. Вахитов исеме ак интервентлар тарафыннан үтерелгән С. Шаумян һәм П. Джапаридзе белән янәшә телгә алына.

Ул елларда Гражданнар сугышы фронтларында комиссар Мулланур Вахитов исемендәге Кызыл Армия полкы уңышлы сугыша. 1922 елда Казанда атаклы революционерга һәйкәл куела. Ә 1943 елда «Мулланур Вахитов» исемендәге пароход легендар Сталинградка бүләкләр, азык-төлек, китаплар, төзү материаллары китерә.

Бүгенге көндә Мулланур Вахитов исеме халык күңелендә яши. Аның хакында җырлар, поэмалар иҗат ителә. Аның исеме белән колхозлар һәм совхозлар, завод-фабрикалар аталган. Республикабызның Ленин орденлы башкаласы Казанда Вахитов исемендәге район бар.

Мулланур Вахитов татар хезмәт ияләрен һәрвакыт башка халыклар белән дуслыкка чакырды, ул уртак Ватаныбызның кайнар йөрәкле патриоты иде. Социализмның бөек эше өчен көрәштә һәлак булган большевик Мулланур Вахитов бүген дә безнең белән бер сафта!

Тукайның 100 еллыгына

# УРАЛЬСКИДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ



**Шәһәрнең Ленин һәм Чапаев урамнары чатындагы йорт. Биредә 1905 елда корректор булып Г. Тукай эшләгән «Уралец» газетасы типографиясе урнашкан була.**

*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

# ТУКАЙ КЛУБЫ

Еллар хәтерендә күпме вакыйгалар тәеннәнгән, күпме истәлекләр калган. Татар әдәбиятының гыйбрәтле көндәлеге булып та калган ул хатирәләр. Газета хәбәрләренә, журнал хроникасындагы гадәти юлларга еллар буе бер үк сүзләр үрелеп барган: «Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында...» дип башланганнар алар. Бу сүзләр әдәбият язмышы турындагы кызу бәхәсләрне дә, дәртле һәм моңлы шагыйранә сүзне дә, акыллы киңәшне дә, ачы тәнкыйтьне дә сыйдыргандыр сыман... Ниләр генә ишетмәгәндер дә бу диварлар, нинди генә вакыйганың шаһиты булмагандыр?!

Еллар чылбырына төеннәр төйнәлгән дә төйнәлгән...

Алдымда газета тегелмәләре, китаплар, истәлекләр... Алар аша мин үткән көннәргә сәяхәт ясыйм, инде якты дөнья белән хушлашкан әдәбият-сәнгать эшлеклеләребез белән кабаттан очрашам, хатирәләрне яңартам.

1935 елда элекке сөт базары урынында архитектор Пэн проекты буенча конструктивизм стилендәге яңа һәм заманча биш катлы бина калкып чыга. Бауман урамындагы бу йорт әле салынып беткәнче үк Матбугат йорты дигән исем ала. Язучылар, журналистлар, нәширләр, полиграфистлар аның өлгерүен түземсезлек белән көтәләр, ай саен, атна саен өмәләр оештыралар. Һәм менә «Кызыл Татарстан» газетасының 20 июнь саны хәбәр сала: «Шушы көннәрдә Казан матбугат йортының төп корпусы ачыла». Шунда ук яңа мәһабәт бинаның рәсеме урнаштырылган. Таш урамның ике ягында яшь юкәләр, ә Матбугат йорты тәрәзәләре кунакчыл тәс белән елмаеп торалар сыман.

1935 ел — язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубы эшли башлаган ел да ул. Биредә газета хроникасына теркәлгән иң беренче вакыйга 1935 елның 27 июнь датасы белән билгеләнгән. Бу көнне Татарстан язучылары республикабызның XV еллык бәйрәменә килгән кунаклар белән очрашалар. ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Кави Нәҗми аларга «инде индустриаль илгә әйләнгән Татарстанда социалистик культура һәм аның мөһим кисәге — Татар совет әдәбиятының чәчәк атуы турында» сөйли. Башкортстан хөкүмәте һәм башкорт совет язучылары исеменнән чыгыш ясаган Афзал Таһиров ике республика арасындагы туганлык мөнәсәбәтләрен тагын да ныгытырга чакыра. Дуслык кичәсендә Ш. Камал, Г. Толымбай, Г. Гали, Ш. Усманов, С. Баттал һәм Мәскәүдән килгән иптәшләр чыгып сөйли, кунаклар республика нәшриятында чыккан китаплар күргәзмәсе белән танышалар.

Бу гадәти вакыйганың үзенә бер символик мәгънәсе бар. Язучылар клубының беренче эше дуслыкка, туганлыкка, хезмәттәшлеккә барып тоташа. Милләтләр дуслыгы, әдәбиятлар дуслыгы, төрле музалар дуслыгы шулай башлана биредә.

Тукайлар яшьлеге шаулаган Шәрык клубы, Тукташлар, Кутуйлар гөрләткән Татар мәдәнияты йорты эстафетаны яңа бинага тапшыра — әдәби-музыкаль кичәләр, кызыклы очрашулар инде моннан соң биредә үтәчәк. Язучылар союзы, китап нәшрияты, газета-журналлар редакцияләре бөтенесе бер җиргә туплангач иллә дә күңелле икән! Атна саен я яңа әсәр тикшерү, я берәр композитор һәм җырчының иҗат отчеты, я көн кадагына суга торган доклад, я мавыктыргыч әңгәмә. Клуб үзе әлегә «язучылар залы», «язучылар союзы кабинеты» дигән исемнәр белән генә аталып йөри. Ә менә 1938 елның 14 апрелендә... Бу көнне Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы Г. Тукай исемен мәңгеләштерү мәсьәләсен карый. Язучылар союзы клубына бөек шагыйребез исеме бирелә.

Сугыш алды еллары әдәби хроникасыннан кайбер фактлар гына китерик.

1936 елның 17 январе. Шагыйрьләр секциясенең киңәйтелгән утырышында «Маяковский иҗаты һәм татар совет поэзиясе» дигән мәсьәлә тикшерелә.

1937 елның 7 январе. Матбугат йортының язучылар залында А. С. Пушкинның «Таш кунак» әсәре тәрҗемәсе тикшерелә. (Н. Исәнбәт тәрҗемәсе).

1938 елның 31 марты. М. Горькийның 70 еллыгына багышланган кичә үткәрелә.

1939 елның 29 марты. Халык иҗаты кичәсе. 21, 24 апрельләр — Татарстан совет Язучылары союзы идарәсенең отчет-сайлау җыелышы. Яңа идарәнең җаваплы секретаре итеп М. Җәлил сайлана. 25 апрель — Салих Сәйдәшев иҗатына багышланган кичә. М. Җәлил, Ф. Бурнаш, Х. Туфан, җырчы Г. Кайбицкая композитор иҗатының татар музыкасын үстерүдәге зур роле турында сөйлиләр.

1940 елның 13 апреле. Язучы Мәхмүт Максудның иҗат кичәсе. Анда М. Җәлил, Г. Кашшаф, Ш. Камал, Н. Исәнбәт, М. Гали, Г. Кутуй чыгып сөйлиләр...

Һәм кинәт... Бөек Ватан сугышы җилләре Г. Тукай исемендәге клуб диварларына да килеп кагыла. Мәскәүдән, Украинадан, Белоруссиядән эвакуацияләнгән язучылар биредә беренче сыену урыны табалар. 1941 елның көз-кыш айларында эвакуацияләнгән 800 ләп язучы гаиләсе Г. Тукай исемендәге клубта урнашкан шушы үзенчәлекле штаб аша

уза. Язмыш җилләре белән бергә А. Толстой, А. Фадеев, А. Сурков, Д. Бедный, М. Алигер, М. Танк, Я. Купала, Л. Ошанин һ. б.лар килә. Бирегә Италиянең антифашист шагыйре Джованни Джерманетто иң беренче тапкыр Тукай шигырьләре белән очраша, француз коммунисты Жан-Ришар Блок «41 нче елның Октябре» дигән ялкынлы шигырен иҗат итә.

Авыр сынау көннәрендә төрле милләт шагыйрьләре бер үк аваздан җиңү тантана итәчәге турында җырладылар, ялкынлы сүз белән халыкны хәлиткеч һөҗүмнәргә рухландырдылар. Татарстан Язучылар союзы каршындагы барлык иҗат секцияләре бер агитпроп бүлегенә берләшә. Аңа Ш. Маннур, Р. Ишморат, К. Нәҗми, Л. Җәләй, Г. Кутуй, Т. Гыйззәт кебек күренекле язучылар җитәкчелек итә. Тукай исемендәге клубта Татарстан Язучылар союзы композиторлар белән бергәләп сугышчыларга җылы киемнәр җыю файдасына түләүле әдәби-музыкаль кичәләр үткәрә. Матбугат йорты түбәсенә, балконнарга әледән-әле ПВХО группалары күтәрелә. Язучыларның күбесе берәм-берәм аяусыз сугыш барган җиргә — ут сызыгына юл тота. 1942 елның 8 январенда дуслары Муса Җәлилне дә фронтка озату мәҗлесе уздыралар. Г. Тукай исемендәге клубта оештырылган бу кичәдә рус һәм чит ил язучыларыннан А. Сурков, Дж. Джерманетто, Араконда, В. Бахметьев, С. Липкин бар иде, дип искә ала тәнкыйтьче Г. Кашшаф.

Андый озатулар байтак булган. Ләкин кайберләрен каршыларга гына туры килмәгән. Аларның исемнәре хәзер мәрмәр тактага уелып язылган. Әле хәзер дә исән булырдай ничәмә-ничә ир-егет! Һәркайсы олы язмыш, һәркайсы поэмага, җырга лаек. Алар безне һәр кичә саен ишек төбенә үк чыгып каршылыйлардыр сыман.

Тагын саран сүзле хроникага күз салыйк. «1943 елның март ахыры — апрель башы. Ф. Кәрим, М. Максуд, Х. Госман фронттан кайтып киттеләр. Язучыларның Г. Тукай клубында уздырылган очрашу кичәсендә Ф. Кәрим «Разведчик язмалары»н, Х. Госман «Яшь егет» исемле повестен, М. Максуд яңа шигырьләрен укыдылар. «1944 елның 1 феврале. Г. Тукай исемендәге клубта язучыларның гомуми җыелышы булды. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре Г. Шәфиковның «Сугыш чорында совет язучыларының бурычлары», Г. Кашшафның «Ватан сугышы чорында татар совет әдәбияты» дигән докладлары тыңланды».

Һәм менә җиңү таңы ата. Дәһшәтле көннәрдә дә тынып тормаган музалар яңа көч белән яңгырый башлый. «Әдәби җомга»ларда фронтовик язучыларның яңарган дөнья, тыныч хезмәт симфониясе турындагы әсәрләре укыла, өзелеп, бүленеп калган җыр дәвам итә, ветераннарның көр, ышанычлы тавышына яшь авазлар кушыла.

Илле ел эшләве дәверендә биредә күркәм традицияләр урнашкан. Гадәттә, язучының яңа әсәре белән укучы беренче булып монда очраша. Язучы исә иң беренче хөкемне монда ишетә. Клуб советы үз эшендә төрле формаларга мөрәҗәгать итә. «Әдәби җомга»лар, юбилей кичәләре, иҗат отчетлары, яңа әсәр турында фикер алышулар, очрашулар, шигъри сабантуйлар — боларның һәммәсе культурабыз казанышларын пропагандалауга, әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт, ирешкән казанышларыбыз белән горурлану хисе тәрбияләүгә юнәлтелгән. Биредән сөйгән халкына классик язучыларыбыз Ш. Камал, К. Тинчурин, Х. Туфан, композиторларыбыз С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, СССРның халык артистлары Х. Әбҗәлилов, Н. Якушенко, Г. Шамуков, Ф. Халитов, Ш. Биктимеров, А. Аббасов, тугандаш әдәбиятлар вәкилләре М. Кәрим, С. Михалков, К. Кулиев һәм башкалар мөрәҗәгать иткән. Космонавт В. Терешкова, атаклы юмор остасы А. Райкин, Тын океан баһадиры Ә. Җиһаншин, итальян әкиятчесе Дж. Родари, композитор А. Хачатурян белән булган истәлекле очрашулар да хәтердә. Хәер, бөтен бәйрәмнәрне, бар исемнәрне санап чыгу мөмкинмени?! Аларны искә төшергәндә, Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң олы юлга чыккан әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезнең бүген нинди югарылыкка ирешүенә чын күңелдән сөенәсең.

Традиция буенча клубның һәр сезонын әдәбиятыбыз аксакаллары ачып җибәрә. Гадәттә алар инде сагынып сөйләргә калган күптәнге бер кичәне, кызыклы очрашуны искә төшерәләр. Бу чыгышлар тамашачыларга билгеле бер рухи юнәлеш бирә, иҗади буыннар арасындагы бәйләнешләрне ныгыта. Яшьләр иҗатына багышланган кичәләрдә авторларның беренче китабы турында, «Идел» альманахы турында сүз бара.

Кайбер «җомга»лар культурабыз тарихындагы мөһим вакыйгаларга, әдәби мирас мәсьәләләренә, аз өйрәнелгән мәдәни чыганаклар белән танышуга багышлана, Г. Тукай клубына кунакка театр коллективлары, концерт оешмалары, иҗат союзлары, үзешчәннәр чакырыла. «Ленинчыл сәнгать фестивале», «Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал», «Мөнәҗәтләргә нигезләнгән хор концерты», «Истәлекләр ни сөйли» дип исемләнгән кичәләр республикабыз матбугатында да киң яңгыраш алды.

...Менә шулай — кичә арты кичә уза. Ә зал түрендәге Тукай, безнең таләпчән остазыбыз, гүя, сынап һәм уйланып, бүгенге әдипләрнең сүзләрен, моңнарын тыңлап утыра.

**Әхмәт РӘШИТОВ,**
язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы директоры.

# ӘДӘБИЯТКА ОЛЫ МӘХӘББӘТ

ГАЛИ ХАЛИТКА 70 ЯШЬ

РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Гали Халит күп еллар дәвамында әдәбиятка һәм әдәбият фәненә олы мәхәббәт, тугрылык белән хезмәт итеп килә.

Гали Халит мәктәптә укыган елларында ук әдәбият белән кызыксына башлый. Ә 1930 елны Казанга килеп, педагогия техникумына укырга керә. Әдәбияттан Әминә Халит, татар теленнән Җамал Вәлиди кебек укытучыларның дәресләре, техникумда М. Гафури һәм С. Сәйдәшев белән очрашулары Гали Халитның хәтер дәфтәрендә бик истәлекле булып язылып калган. Аның биредә язган беренче шигырьләре Буа газетасында басылып чыга.

Педагогия институтының тел-әдәбият факультетына кереп укуы Гали Халитны әдәбият дөньясына тагы да якынайта. Анда ул Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, Х. Бәдигый, Г. Алпаров, Н. Хәким кебек күренекле тел-әдәбият белгечләренең лекцияләрен тыңлый, татар, рус һәм дөнья әдәбияты классикларының мирасы белән якыннан таныша. Институтта укыганда шигырьләр язуын дәвам итсә дә һәм аларның кайберләре өлкә матбугатында күренсәләр дә, соңгы курсларда укыганда Гали Халит инде үзендә, шагыйрьлектән бигрәк, тәнкыйтьчелек сәләте барлыгын ачыклый. Шуңа да ул төп кызыксынуын тәнкыйть өлкәсенә юнәлтә, Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Писарев хезмәтләрен аеруча мавыгып өйрәнә. Институтны тәмамлар алдыннан язган мөстәкыйль иҗади эшен ул Такташ иҗатына багышлый. Укытучысы Г. Нигъмәти аңа югары бәя бирә.

Гали Халитның тәнкыйтьче буларак танылуы Арча педагогия техникумында татар әдәбияты укыткан елларына (1936—1942) туры килә. Аның беренче тәнкыйть мәкаләләре 1937 елны — аңа нибары 22 яшь тулган чакта — күренә башлый. Шул елда Тукай иҗатын өйрәнүнең торышына караган һәм Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасы турындагы мәкаләләре басыла. Беренче адымнарыннан ук инде яшь тәнкыйтьченең әдәби әсәрләрне нечкә зәвык белән сиземләве, әдәбиятны ныклап өйрәнүе, Тукай һәм Такташка булган олы мәхәббәте ачык чагыла. Татар әдәбиятының төрле чорында яшәгән ике классик шагыйрьгә мәхәббәтен ул гомере буена саклый, аларның иҗатларына даими рәвештә мөрәҗәгать итә.

Әнә шуннан соң Гали Халитның газета-журналларда әдәби хәрәкәтнең актуаль мәсьәләләрен күтәргән, татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен анализлаган, аерым язучыларның иҗатын тикшерүгә багышланган әдәби тәнкыйть мәкаләләре бер-бер артлы күренә башлый.

Язучылар җыелышында ул татар әдәбиятының гомуми торышына яки аерым жанрлар үсешенә караган докладлар ясый. Үсеш юлындагы кимчелекләрне ачып салган аның фикерләре тирәсендә еш кына җанлы бәхәсләр кабынып китә. Шулай итеп, әдәбият дөньясында ул үткен күзле, туры сүзле тәнкыйтьче буларак танылa. 1939 елны Г. Халит СССР Язучылар союзы члены итеп алына. 1942 елны Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә керүе аның тормыш юлын тулысы белән әдәбият һәм әдәбият фәне белән бәйли, бар көчен, сәләтен әдәбиятка багышларга мөмкинлек тудыра.

Утызынчы елларның ахырларында ук Г. Халитның иҗаты тематик-проблематик яктан киң диапазонлы һәм төрле жанрларга бай булуы белән игътибарны җәлеп итә. Шул елларның җанлы әдәби хәрәкәтенә актив катнашу белән бергә ул татар әдәбияты тарихын өйрәнү буенча да системалы эш алып бара. Шулай да галимне аеруча кызыксындырган һәм фәнни өйрәнә башлаган чорны ачык билгеләргә мөмкин: бу — XX йөз башы татар әдәбияты. Г. Халит төп игътибарын әлеге чор татар әдәбиятының классик язучыларына — Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, М. Фәйзи иҗатларына юнәлтә.

XX гасыр башы татар әдәбияты безнең әдәбият белемендә иң нык өйрәнелгән өлкәләрдән санала. Шушы чор әдәбиятының идея-эстетик үзенчәлекләрен, үсеш закончалыкларын, иҗат методларының һәм әдәби стильләрнең хәрәкәтен ачкан нигезле һәм теоретик характердагы тикшеренүләре белән Г. Халит әдәбият фәнен үстерүгә кыйммәтле өлеш кертте. Галимнең XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүдәге аерым күзәтүләре «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре» (1948) исемле китабында дөнья күрде. «XX йөз башында татар әдәбияты» (1954) исемле коллектив хезмәттә дә Гали Халит — төп авторларның берсе.

Әдәбият белеменең бүгенге ирешкән югарылыгыннан караганда, галимнең бу чор хезмәтләрендә XX йөз башындагы әдәби хәрәкәтне катлаулы һәм бөтен бер процесс буларак яктыртуда системалылыкның җитмәве дә, аерым әдәби күренешләрне һәм язучыларны бәяләүдә дөрес үк булмаган карашларның урын алганлыгы да күренә, әдәбифактик материалның тулы ук булмаганлыгы да күзгә ташлана. Әмма бу кимчелекләрнең байтагы шул чор әдәбият белеменең һәм әдәби атмосфераның гомуми торышы белән билгеләнә иде.

Тарихилык принцибын әдәбиятны тикшерүдә төп маяк, төп нигез итеп алуы галимгә XX йөз башы әдәбиятының идея-эстетик үсешендәге байтак үзенчәлекле хасиятләрне күрергә, үсү баскычларын ачыкларга ярдәм итте. Шушы нигездә Гали Халит XX йөз башы татар әдәбиятының иҗтимагый-идея колачы киңәюен, милли әдәбиятның электә булмаганча күтәрелешен һәм эчке яктан катлауланууын, төрләнүен күрсәтте, әдәбияттагы тирән үзгәрешләрне җәмгыятьтәге иҗтимагый-политик һәм милли азатлык хәрәкәтләре белән бәйләнештә һәм шулар яктылыгында карады. Г. Халит хаклы рәвештә халыкка мөнәсәбәт һәм аның белән бәйләнеш мәсьәләсен милли әдәбиятның нинди юлдан барышын һәм язмышын хәл иткән факторларның берсе дип санап, халыкчанлык һәм реализм мәсьәләсен тикшерүгә җитди игътибар юнәлтте. Татар әдәбиятының демократик нигезе ныгуын, халыкчанлык һәм реализм өчен көрәшнең аңлы юнәлеш алуын күрүе дә, бу процессның үзәгенә халык шагыйре Г. Тукайны куеп каравы да галим хезмәтләренең отышлы ягы иде. Һәм болар һәммәсе бергә Г. Халитның киләчәк тикшеренүләре өчен ныклы нигез булып ятты.

Гали Халит XX йөз башы әдәбияты турындагы тикшеренүләрен соңгы елларда да дәвам итеп, шул чор әдәбиятының идея-эстетик байлыгын тагын да тирәнрәк, күпьяклырак яктыртуга иреште, үзенең элекке карашларын тагы да тулыландырды һәм үстерде, иҗат методлары турындагы концепциясен яңа күзәтүләр белән баетты. Хәзер дә ул, мәсәлән, реализмны татар демократик әдәбиятының бөек казанышы һәм төп юлы буларак карый. Әмма, шул ук вакытта, галим башка иҗат методларының һәм агымюнәлешләрнең әдәби хәрәкәттәге урынын, әһәмиятен читкә какмый яки кире яктан гына билгеләп узмый, ә аларның тарихи-социаль, милли җирлекләрен, тарихи зарурилыкләрен ачарга омтыла. Аеруча романтизмның татар әдәбиятындагы мөстәкыйль юлын һәм реализм белән мөнәсәбәтен билгеләү буенча яңа фикерләр кузгатуын билгеләп үтәргә кирәк.

Г. Халит, күренекле рус әдәбиятчыларының (М. Храпченко, У. Фохт) фикерләренә таянып, реализм һәм романтизм синтезы турында игътибарга лаек яңа концепция тәкъдим итте. Реализм һәм романтизм иҗат методларының бер-берсенә үзара тәэсире нигезендә XX йөз башы татар әдәбиятының сәнгатьчә зур яңарыш кичерүе турындагы фикерне Г. Халит моңарчы да әйтә килә иде. «Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары» (1971) исемле мәкаләсендә ул әлеге фикерне тагын да үстереп, шушы синтез өченче бер башлангычның, әдәби юнәлешнең — романтик реализм агымының тууына нигез булуы турында язып чыкты.

Г. Халит XX йөз башы татар әдипләренең иҗат индивидуальлеген өйрәнү буенча да әһәмиятле хезмәтләр иҗат итте. Аның озак еллар дәвамында аеруча яратып өйрәнгән әдибе — Габдулла Тукай. Бөек шагыйрьгә багышланган монографияләрендә[1] ул Г. Тукайның XX гасыр башы татар әдәбиятында тоткан урынын, аның дөньяга карашы һәм фикерләре үсешен, халыкчанлык һәм реализм өчен көрәшен, шагыйрь үткән юлның тарихи-әдәби фонын мөмкин кадәр тулы һәм киң итеп күрсәтүгә ирешә. Г. Халит соңгы елларда шагыйрьнең образлы фикерләү дөньясына тирәнрәк үтеп керергә омтыла, иҗатындагы новаторлыкны, поэтикасындагы үзенчәлекләрне ачу буенча уңышлы эзләнүләр алып бара.

Г. Халит татар совет әдәбияты тарихын өйрәнү буенча да озак еллар дәвамында нәтиҗәле эш алып бара. Татар совет әдәбиятының үсеш этапларын гомуми пландарак күрсәткән беренче мәкаләләрендәге күзәтүләрен дәвам итеп, ул төп игътибарын совет әдәбиятының егерменче елларын тикшерүгә юнәлтте. Илленче елларда әдәбиятчыларга

[1] Халит Г. Тукай үткән юл. Казан, 1962; Тукай и его современники. Казань, 1966; Тукай и татарское литературное движение начала XX века. Казань, 1956.

яңа бурыч — татар совет әдәбияты тарихын язу эше йөкләтелде. Моңа Г. Халит та тартылды. Тикшерү өлкәсе итеп егерменче еллар әдәбиятының сайлануы исә галимнең фәнни кызыксынуы белән дә турыдан-туры бәйле иде. Мәгълүм булганча, XX йөз башы әдәбияты Октябрь революциясенә кадәрге вакытны эченә ала. XX йөз башында иҗат итеп килгән күп кенә әдипләрнең иҗаты Октябрь революциясеннән соң да дәвам итә һәм яңа сыйфатлар белән баый. Галим өчен бер үк язучының ике тарихи чордагы иҗатын өйрәнү, жанр, стиль, иҗат методларының яңа дәвердәге үсеш тенденцияләрен күзәтү кызыклы да, отышлы да иде.

Г. Халитның бу чор әдәби хәрәкәтенә караган хезмәтләрендә күп мәсьәләләр күтәрелә, татар әдәбиятындагы гуманистик һәм халыкчанлык традицияләренең Октябрьдан соң нинди яңа хасиятләр белән баюы, язучылар иҗатында нинди яңа сыйфатлар тууы, кыскасы — яңа чор әдәбиятының новаторлыгы, социалистик реализм методының тууы һәм үсеше, аның башка әдәби методлар белән бәйләнеше кебек гаять җитди һәм катлаулы мәсьәләләр яктыртыла. Яңа иҗат методының тууын катлаулы һәм каршылыклы процесс буларак аңлатуны шулай ук галимнең хезмәтләрендәге отышлы як итеп күрсәтергә кирәк. Егерменче еллар әдәбиятында күп төрле эстетик тенденцияләр хәрәкәт итә, күп төрле эстетик платформалар мәйданга чыга. Г. Халит хаклы күрсәткәнчә, яңа методның формалашуы төрле төркемнәрнең алдан тәкъдим иткән әзер рецептлары һәм сукмаклары буенча бармый. Яңа метод чынбарлыкның каршылыклары һәм әдәбияттагы идея-эстетик фикерләрнең катлаулылыгы эченнән үзенә юл сала, көрәшкә туа һәм көрәштә сынала.

Татар әдәбият фәне теория мәсьәләләренә һаман ныграк игътибар итә, союз күләмендә кузгатылган сөйләшүләргә илтифатлырак була бара, әдәби иҗатның, әдәби процессның үзенчәлекләрен ачуга кыюрак омтылыш ясый. Шушы тенденцияләр Г. Халитның татар совет әдәбиятының егерменче еллардагы үсеш юлын яктырткан хезмәтләренә дә хас.

Такташ турында әдәбият фәнендә җитди сүз әйтүче галимнәрнең берсе Гали Халит булды. Ул соңгы елларда шагыйрь иҗаты турында ике монография бастырды. (Шагыйрь, чор, герой. Казан. 1971; Поэзия дерзаний. Казан, 1980.) Такташ иҗаты бу хезмәтләрдә бер мәсьәлә — әдәби метод һәм герой проблемаларына бәйләнештә яктыртыла. Шагыйрь иҗатын әнә шулай әдәбиятның үзәк проблемасы яктылыгында һәм бер фокус тирәсендәрәк карау авторга әһәмиятле күзәтүләр ясарга ярдәм иткән. Монографиядә Такташ иҗатында барган идея-эстетик үсеш, иҗат методында туган үзгәрешләр, герой эзләүдә һәм табудагы үзенчәлекләр һәм каршылыклар үзләренең калку нокталарында, киң һәм бай әдәби фонда ачылалар.

Ул шагыйрь иҗатына бәйләп гыйсъянчылыкның татар әдәбиятына хас әдәби-тарихи җирлеген, образлы фикерләүдәге үзенчәлекләрен ача, егерменче елларда «революцион шәхеснең формалашу тарихында зарури бер буын» булуын күрсәтә. Г. Халит гыйсъянчылыкның татар әдәбиятында туган үзенчәлекле бер күренеш булуына нык акцент ясау белән бергә, аның каршылыклы һәм йомшак якларын да билгеләп уза.

Г. Халит язучыларның идея-эстетик үсеше белән аларның иҗат методы арасына тигезлек билгесе куюга, романтик типтагы фикерләүне «кимчелекле» итеп санауга хаклы рәвештә каршы чыга һәм Такташның иҗат методындагы эволюциясен, романтик рухтагы үсешен конкрет мисалларда күрсәтә.

Такташның егерменче еллар ахырына таба яңа герой эзләвендәге үзенчәлекләре хезмәттә аеруча бер тулылык белән тикшерелә. Герой характерының үзгәрүе — космик төшенчәләрдән акрынлап читләшә барып, көндәлек тормышка якынаюы, настроениеләрендә элекке романтик контрастлар кими башлавы, ярым тоннар һәм психологик нюанслар көчәюе кебек хасиятләр шактый дәлилле ачылган.

Г. Халитның Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллардагы татар әдәбияты, әдәбият белеме турында да әһәмиятле тикшеренүләре бар. «Җиңү тойгысы» исемле мәкаләсендә (1945) Г. Халит, әдәбиятчылардан беренче буларак, сугыш чоры татар әдәбиятын яңа бер этап итеп карады, бу чорның үзенә хас идея-эстетик хасиятләрен билгеләргә омтылды. Ул татар язучыларының иҗатында электә күренеп калган бертөрлелектән, абстрактлыктан, схематизмнан арына барып, реалистик тулылыкка таба борылыш ясауларын әһәмиятле момент итеп билгеләп үтте. Шул ук вакытта бу мәкалә язучылар алдында торган яңа бурычларны дөрес тотып алуы һәм аларның игътибарын сугышчының эчке дөньясын эпик колач, психологик тирәнлек белән сурәтләүгә юнәлтүе белән дә — әдәбиятның киләчәк юлын кайгыртуы белән дә әһәмиятле.

Г. Халитның тәнкыйть мәкаләләре киң колачлы һәм кыю булулары белән аерылып торалар. Мондый сәләтен без аның Тукай, Такташ турындагы монографияләрендә күреп үткән идек инде. Хәзерге әдәби процесс турында да Г. Халит төпле итеп, фәнни итеп, үзе дә ышанып, укучыларны да ышандырып яза. Мисал өчен, «Кешеләр һәм язмышлар»

исемле мәкаләсе (1968) аның тәнкыйтьче буларак кыюлыгын һәм үткенлеген тагын бер кат раслады. Әлеге хезмәттә сүз Әмирхан Еникинең иҗаты турында бара. Әдип әсәрләре турында безнең тәнкыйтьтә аз язылмаган. Әмма, дөресен әйткәндә, Г. Халитның әлеге мәкаләсенә кадәр Ә. Еникинең иҗаты һәрьяклап һәм тирән анализланганы, шундый дөрес бәяне алганы юк иде. Аның хикәя-повестьлары тирәсендә матбугатта бәхәсләр һәрчак була торды, тик аларның күпчелегенә объективлык җитеп бетмәде, күп кенә тәнкыйтьчеләр Ә. Еники әсәрләренең үзенчәлекле сюжет юллары эчендә адашып калдылар, бу әсәрләргә салынган идея-эстетик мәгънәне укучыларга җиткерә алмадылар. Г. Халитның әлеге мәкаләсе Ә. Еники иҗаты тирәсендә байтак еллар барган догматик бәхәскә нокта куйды, язучы әсәрләренең чын идея-эстетик кыйммәтен ачып бирде.

Соңгы елларда Г. Халит әдәбиятны тарихи-теоретик планда тикшерү белән бергә, әдәбият теориясенә караган хезмәтләр дә язды. «Бездә ирекле шигырь бармы?» (1970—1972), «Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары»(1971), «Иҗат методы һәм стиль» (1974), «Романтизм һәм реализмның төп сызыклары» (1975) кебек мәкаләләрдә теоретик гомумиләштерүнең тирәнәя баруы күзгә ачык ташлана.

Соңгы елларда рус әдәбият белемендә (М. Храпченко, Л. Тимофеев, Г. Поспелов, А. Соколов, Н. Конрад һ. б. хезмәтләрендә) метод һәм стильгә караган күп кенә бәхәсле мәсьәләләр ачыкланды. Гали Халит үзенең мәкаләләрендә әнә шундый абруйлы галимнәрнең хезмәтләренә таяна, рус совет әдәбият фәне ирешкән казанышларны ачып сала. Гали Халит шушы концепцияләр яктылыгында татар әдәбиятына да күз ташлый, методларның, стильләрнең үсеш-хәрәкәтенә, үзара мөнәсәбәтләренә кагылышлы яңа фикерләр кузгата.

«Иҗат методы һәм стиль» мәкаләсендә, мәсәлән, автор төп игътибарын стиль мәсьәләләренә юнәлтә. Стильнең әдәбият фәнендә ничек билгеләнүенә, аның метод, дөньяга караш, эстетик идеал белән катлаулы бәйләнешләренә, стильнең нинди компонентлардан торуына туктала. Стильне телгә генә кайтарып калдыру концепциясе белән хаклы рәвештә килешми. Автор, стильне билгеләүче фактор буларак, объектив һәм субъектив башлангычларның ролена да әһәмият итә: индивидуаль стильләрнең иҗат методы белән бәйләнешләренә кагылышлы кызыклы күзәтүләр китерә, рус һәм татар әдәбиятыннан алынган мисалларда тотрыклы, хәрәкәтчән синтетик стильләрнең үзенчәлеген күрсәтә. Чор стиле, стиль аныклыгы, милли стиль, психологизм, җан диалектикасы кебек мәсьәләләрне дә ул рус һәм татар әдәбиятыннан алынган мисаллар нигезендә яктырта; социалистик реализм методында романтик агымнарның төрле традицион төсмерләре дәвам итүенә дә тукталa; эпиклык, психологизм кебек традицияләрнең социалистик реализм методында үстерелү үзенчәлекләрен ачыклый.

Г. Халит турында сөйләгәндә һич тә аның фәнни-оештыру эшчәнлеген читләтеп узып булмый. Безнең чор — коллектив хезмәтләрнең әһәмияте күтәрелгән, әдәбият фәнен оештыруның зарурилыгы ачык күренгән вакыт. Г. Халитның бу өлкәдә дә эшләгән эшләре шактый. Моңа, әлбәттә, аның эш урыны да сәбәпче булгандыр — ул озак еллар Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әдәбият секторы мөдире булып эшләде, хәзер дә шунда фәнни консультант булып эшли. «XX гасыр башында татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1965) кебек зур, коллектив хезмәтләр турыдан-туры Г. Халит җитәкчелегендә язылдылар. Г. Халит күп томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның өченче томына җитәкчелек итте. Ул әдәбият фәненә кадрлар хәзерләүгә, урта мәктәп өчен дәреслекләр язуга, классикларның әсәрләр җыелмасын чыгаруга якыннан катнашып килә.

Гали Халитның әдәбият фәнендә үз сукмагы, үз юлы бар. Бу юл татар совет әдәбият фәненең төп үсеш юлыннан аерылгысыз. Үзенең күп санлы фәнни хезмәтләре белән, туры сүзле, таләпчән тәнкыйть мәкаләләре белән ул әле һаман әдәбиятыбыз үсеше өчен тырышып хезмәт итә.

**Нил ЮЗИЕВ.**

**Мәхмүт Хәсәнов**

# ИКМӘК — ТОРМЫШ УЛ

Безнең телдә һәрвакытта да янәшә торган ике сүз бар: «Җир» һәм «Икмәк». Бу сүзләр шулкадәр якын, бер-берсенә шул дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгәннәр ки, аларны хәтта ана һәм бала белән тиңләргә мөмкин.

«Җир» сүзен без бик киң мәгънәдә аңлыйбыз. Бер караганда, ул иксез-чиксез галәм киңлегендә йөзүче зәңгәр планета булып күз алдына килә. Ә Җирнең космостан төшереп алынган рәсеме миңа һәрвакыт әле яңа гына мичтән чыккан икмәкне хәтерләтә.

Иелеп учка алган кара-кучкыл, көрән-сары, кызгылт-сары төстәге туфрак та — җир. Әмма, беренче карашка, төсе белән дә, исе белән дә ул кадәр шаккатырырлык булмаган шул туфрактан дөньяда иң газиз, иң татлы, хуш исле икмәк барлыкка килә.

Аңа бәйле рәвештә исә, ирексездән, үзәкләргә үтә торган ачы җилләр, күз ачкысыз бураннар һәм чатнама суыкларда, түзә алмаслык җәйге челләләрдә басу киңлекләрендә эшләүче игенче күз алдына килеп баса. Ул бөтен хезмәтен, тырышлыгын һәм осталыгын ашлык үстерүгә бирә, тормышының мәгънәсен шуңарда күрә. Нәкъ менә шунлыктан безнең Ватан игенчегә иң олы хөрмәтен күрсәтә.

Халык тикмәгә генә: «Икмәк — дөнья тоткасы, ил куәте», дими торгандыр. Әйе, икмәк, чын мәгънәсендә — безнең куәт, иң зур байлыгыбыз ул.

Ай-һай, авырлык белән табыла икмәк дигән бәһасез бу байлык! Ул тулысынча киләчәккә, өметләнеп көтүгә бәйле. Халыкта: «Көтү белән куып җитүдән дә авыр нәрсә юк»,— дигән әйтем бар. Көткәндә, иң яманы — билгесезлек. Бәлки шуңадыр, игенче һәр туар көнне дулкынланып каршылый, чөнки һәр туар көн аның хезмәтенә, тырышлыгы нәтиҗәсенә тәэсир итә. Көзнең ничек килүен чамалап тора: үстергән ашлыкны хәвеф-хәтәрсез җыеп алып булырмы, арышын-фәләнен вакытында чәчеп өлгерерме, уҗымнар матур тишелерме? Аннан кышны көтә ул. Явым-төшемне күзәтә: кар катламы ничек? Уҗымнар зарарланырлык түгелме?

Инде көннәр озаеп, кояш чак кына туры карый башлады исә, игенче, нәкъ сабан туйлары якынлашуын сизенгән чабыш аты кебек, тәмам тынычлыгын җуя, бөтен барлыгын эчке бер ашкыну биләп ала. Андый чакта бер игенче генә түгел, бөтен авыл икенче ритм белән яши башлагандай була: амбарлар, машиналар тирәсендә ыгы-зыгы, зур җанлылык башлана. Бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр мотор тавышлары тынмый, күңелләрне урыныннан кузгатып дәртле гөрелте яңгырап тора. Игенче өчен иң җаваплы вакытларның берсе — язгы чәчү җитә...

Чәчүләр тәмамлангач, игенче, маңгай сыпырырга вакыт табуына куангандай, бер мәлгә күкрәген тутырып иркен сулыш ала. Әмма бу әле тынычлану түгел, ул һаман көтә, аның күзләре офыкларга барып тоташкан иксез-чиксез басу киңлекләрендә...

Ул көтә, җирләрне тетрәтеп, күкләр күкрәп, шифалы яңгыр яумасмы? Яңгырлардан соң җылы көннәр утырып китмәсме? Андый вакытта игеннәр күзгә күренеп, буынга сикерә, басулар киңлегенә берни белән дә чагыштыргысыз хозурлык иңә...

Әкренләп урак өсте якынлаша. Таңнар атканда, басу киңлекләрендә, учына чыңлап торган алтын башак салып, дөньясын оныткандай тын гына торган кеше күрсәң, гаҗәпләнмә, бу игенче булыр...

Дөньяда бердәнбер бәһа белмәс нәрсә бар: ул — Җир. Игенченең эш урыны да, өмет-хыялы да, ният-максаты да шул Җир-анага бәйле. Икмәк һичкайчан да кешегә җиңел генә бирелмәгән. Мисал өчен Совет властеның беренче елларына мөрәҗәгать

иту дә җитә. Шул уңай белән Кокушкино һәм Апакай авыллары крестьяннарының 1922 елның 22 декабрендә В. И. Ленинга язган хатларыннан бер өзек китерәсе килә:

«Безнең элекке авылдашыбыз Владимир Ильич Ленин-Ульяновка.

Кокушкино һәм Апакай авылы гражданнарыннан.

Безнең кадерле иптәшебез Владимир Ильич, иң беренче Сине кузна, качыш уеннары уйнау һәм урамнарда бергә атлар саклау буенча белүче авыл картларыннан Сиңа сәлам җибәрәбез. Ул вакытлардан соң күп еллар үтте, бик күп үзгәрешләр булды инде.

1917 елның Октябрендә Совет властеның беренче кушуы буенча бөтен алпавытларыбызның, шул исәптән үзебезнең авыл кулагы Н. Фадеевның да, тетмәләрен теттек. 1918 елда барыбыз да бердәм рәвештә Кызыл Армиягә язылып, Советлар Россиясен өстебезгә килүче дошманнардан — алпавытлардан, генераллардан һәм капиталистлардан сакладык.

Шуннан соңгы елларда безнең якларда иген уңмады, ачлык булды, кешеләр һәм терлекләр чума вакытындагыдан да күбрәк кырылдылар.

Шуның нәтиҗәсендә безнең хуҗалыкларыбыз коточкыч бөлделәр, аларны хәзер бу хәлдән бары тик бөтен җәмәгать белән генә чыгарырга мөмкин.

Таза, исән бер генә семья да, бер генә төзек йорт та калмады. Ачлык барысын да ялап алгандай итте.

Без Сиңа, үзебезне изелүдән коткаручыга, бик шатланып нинди дә булса бүләк җибәрер идек, тик бернәрсәбез дә юк...»

Икмәк турында сөйләгәндә җир-анага, табигатькә, икмәккә мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә кагылмый үтеп булмый. Җир кадерен, икмәк тәмен белү кешедә бик яшьли тәрбияләнергә, тагын да үтемлерәк итеп әйтсәк, ана сөте белән керергә тиеш. Югыйсә бит әле ипине әрәм-шәрәм итү, шәһәр җирләрендә аны урамнарда аунату яки чүплеккә чыгарып ташлау кебек күренешләр дә очраштыргалый.

Мондый очракларда, ирексездән, шагыйрә Саҗидә Сөләймановaның «Икмәк» дигән шигъри әсәре искә төшә.

> Оныттык та мыни —
> Сыер җигеп,
> безме кырда иген икмәдек?
> Бер сыныгы өчен ирсез, атсыз,
> бил сындырып, михнәт чикмәдек?
>
> Оныттык та мыни —
> валчыгы да
> Әҗәл даруыдай елларны?
> Дөнья базарында ул хәзер дә
> алтын бәясеннән югары!..

Әйе, икмәк — ил тоткасы. Кояштай кадерле ул. Аны әрәм-шәрәм итүчеләр бик борынгы заманнардан бирле иң каты җәзага тартыла торган булган. Икмәк салучыларның да дәрәҗәсе бик югары булган. Борынгы Грециядә, мәсәлән, икмәк сала белүчеләр дәүләтнең югары җаваплы урыннарына да утыра алганнар. Борынгы герман дәүләтләрендә күмәч пешерүчене үтергән җинаятьче башка һөнәр иясен үтерүгә караганда өч тапкыр катырак җәзаланган. Ә борынгы Римда икмәк салучы кол гладиаторлардан да югарырак бәяләнгән.

Күп гасырлар үткән, барлык ризыкларның башы булган икмәккә карата хөрмәт һич кимеми. Икмәккә, җир-анага мөнәсәбәт турында сүз чыкканда, минем күз алдыма ике төрле күренеш килә: берсендә, чал сакалы биленә җиткән йөзьяшәр карт, җир-ана өстенә иелеп, алмагач үсентеләре утыртып йөри. Ул белә: үзе утырткан бу агачларның җимешен бәлки аңа авыз итәргә дә туры килмәс. Әмма ул үзе өчен түгел, аңардан соң киләсе буынны күздә тотып бил бөгә. Икенче бер күренештә дә бер бәндә. Монысы инде үзе утыртмаган, хезмәтен куймаган агачларның җимешен җыеп кына калмый, агачның ботакларына кадәр ботарлый. Тик аның карыны тук булсын, башкаларда аның эше юк. Элек-электән, кешене әхлакый яктан бәяләгәндә, аның җир-анага, икмәккә булган мөнәсәбәтенә караганнар. Юньле кеше үзен бар иткән табигатькә, аның иң кадерле ризыгы икмәккә карата мәрхәмәтсез була алмый.

Бу мәкаләне язарга утырганчы, өлкән буын язучыбыз Нәкый ага Исәнбәт төзегән татар халык мәкальләре томнарын алып, икмәк турындагы бүлекләргә күз йөртеп чыктым. «Икмәктән олы аш юк», «Икмәк һәрнәрсәгә баш» дигән мәкальләре белән бергә «Ипинең бер валчыгы да мәчеттән олы» яки «Икмәк корьәннән олырак» дигән мәкальләрне укып, тирән уйга чумдым. Күргәнебезчә, икмәкне үзенең маңгай тире белән сугарып

тапкан гади халык элек-электән ук инде ипине диннән өстен күргән. Элекке этика кагыйдәләре буенча, икмәк өстенә коръән кую да тыела торган булган.

Әбиемнең бер хикәятен гомерем буена да онытасым юк. Имештер, бер фәкыйрь мосафир, юл читенә утырып, тамак ялгап алырга булган. Ашаганда, ялгышлык белән, бер валчык икмәген җиргә төшергән. Күпме генә эзләсә дә, таба алмаган. Ахыр чиктә мосафир, валчыгы аяк астында калмасын, башкалар аны таптап мәсхәрәләмәсен өчен, шул урынны киртәләп куйган, ди. Бераздан соң бу фәкыйрь кинәт кенә баеп киткән.

Әбием авызыннан ишетелгән бу әкиятнең мәгънәсенә төшенү әллә ни кыен түгел. Сүз икмәк валчыгын алтын бөртегеннән өстен күрү турында бара.

Халык икмәкне изге ризыктан санаган. Аны сыңар кул белән тоту, аны ямьсезләп сындырып алу зур гаептән саналган. Ипине кайнар йөрәк тибеп торган күкрәккә терәп кисәргә өйрәткәннәр. Бу — икмәк йөрәк белән, җан белән берүк дигән сүз шикелле.

Икмәккә кадер-хөрмәт бүгенге көннәрдә тагын да артырга тиеш. Бездә, җир-су, табигатьнең бөтен байлыгы халыкныкына әверелгән илдә, башкача булуы мөмкин дә түгел. Шул ук вакытта җирнең сокланып туймаслык могҗизасы булган икмәк өчен җәмгыятебезнең һәрбер шәхесе җаваплылык та тоярга тиеш.

Шушы урынга җиткәч, янә бер хатка мөрәҗәгать итәсе килә. Атаклы педагог В. Сухомлинскийның әтисе язган хат ул. Аны әти кеше улына яңа уңыш онынннан пешерелгән беренче икмәк янына тыгып җибәргән. Анда мондый сүзләр бар: «Көндәлек ризыгың булган икмәк турында онытма, улым. Мин аллага ышанмыйм, әмма икмәкне изге, дип атыйм. Синең өчен дә ул гомереӊ буена изге булып калсын. Икмәкнең нинди кыенлыклар, авырлыклар белән табылуы турында бер генә минутка да онытма. Минем әтием, синең бабаң Омельконың крепостной булуын һәм аның, җир сукалаганда, буразнага капланып үлеп калуын онытма. Хәзергә, син укып йөргәндә, кемнәрнеңдер, кара тир түгеп, сиңа көндәлек ризык-икмәк хәзерләвен онытма. Укуыңны тәмамлап, укытучы булгач та, икмәк турында онытма. Икмәк — ул кешенең хезмәт җимеше, киләчәккә өмет, синең һәм синең балаларыңның намусын үлчи торган өлге икәнлеген онытма. Безнең буынның тамыры — хезмәт халкы, Җир-ана һәм икмәк икәнлеген һичкайчан да онытма».

Каенның яме — яфрак белән туз, өстәлнең яме — ипи белән тоз, ди халык. Әйе, халкыбызның бик күп әкият-хыяллары, җыр-моңнары, табышмаклары, риваять-сынамышлары җиргә һәм аның иң бөек җимеше булган икмәккә тоташа. Халкыбыз борынборыннан үзенең өметләрен җиргә, икмәккә бәйләгән. Ул икмәкне кадерләп, кызыл ашъяулыкка төреп, иң кадерле урында саклаган. Аның валчыгын да әрәм-шәрәм итмәгән, чөнки икмәк өчен күпме хезмәт куярга, нихәтле маңгай тире түгәргә кирәклеген һәм икмәктән дә олырак аш юклыкны тирәннән аңлаган ул.

Хәзер заманнар үзгәрде, авыл хуҗалыгы эшләре тагын да катлауланды. Җир эшкәртү ысуллары үзгәрде, игенче кулына көчле машиналар тапшырылды. Әле дә хәтеремдә: колхоз һәм совхоз җитәкчеләре, игенчелек белгечләре җыелышында берәү колхозчы хезмәтен симфоник музыка белән чагыштырган иде. Урынлы һәм бик тапкыр чагыштыру. Белгәнебезчә, симфоник музыка — иң четерекле, иң катлаулы музыка. Дистәләрчә кешеләрдән торган оркестрдагы бер генә музыка коралы чак кына ялгышса да, симфония үзенең камиллеген югалта, ямьсез яңгырый. Авыл хуҗалыгының да бер генә тармагы чатакланса да, шунда ук аның гомум эшкә начар тәэсире сизеләчәк.

Бүгенге сүзебезне игенче хезмәтенә багышлауның сере дә бар. Аның өчен тагын җаваплы чор җитте. Ил табышының нинди булуы игенче фидакарьлегенә, бу чорда ни дәрәҗәдә оста эшләвенә бәйле. Хәер, игенче осталыгы һәрвакыт кирәк: кышын да, язын да, чилләләрдә дә, уракка төшкәч тә. Ул һәрвакыт икмәк өчен тырыша. Күз алдымда — игенченең мәһабәт гәүдәсе. Кулында тәмам җитлеккән, эре орлыклы тук башак...

Юк, аның өчен гади башак кына түгел бу. Ул аңа — җирдән җегәр, кояштан нур алып үскән бу салмак башакка — рәссам яңа гына ясап бетергән үз әсәренә карагандай сокланып, онытылып текәлгән. Кулындагы зыңлап торган тулы башакка горурлык хисе кичереп карый ул.

Республикабыз игенчеләре алдында быел гаять зур, гаять катлаулы бурычлар тора. Партиянең XXVI съезды, КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнары карарларын тормышка ашыра барып, ил алдындагы изге бурычларын намус белән үтәргә тырышалар алар. «Азык-төлек программасы — бөтен халык эше», дибез икән, бу да авыл эшчәннәренең бурычын арттырганнан-арттыра. Шунлыктан алар елның һәр фасылына зур әзерлек белән килләр. Мул уңыш алу өчен таңны таңга ялгап эшләргә дә ризалар. Җитлеккән игеннең һәр башагы шуңа күрә бик кадерле. Һәм һәркем аны олыларга тиеш.

# КАҺАРМАННАР ЕЛГАСЫ

Күптән түгел Украинаның политик әдәбият нәшрияты «Днепр — каһарманнар елгасы» исемле китап чыгарды. Тышлыгында өстәмә бер аңлатма да бар: «Бөтенхалык батырлыгының дәлилләре». Авторлар коллективы бу уникаль җыентыкка Совет Армиясенең 1943—1944 елларда Днепр өчен алып барган тиңдәшсез сугышына кагылышлы документларны туплаган.

Күз алдыннан бер-бер артлы хәлиткеч вакыйгаларны тасвирлаучы эпизодлар үтә. Кыска-кыска язмалар, күпсанлы фоторәсемнәр, архивлардан эзләп-эзләп тә таба алмаслык кадерле белешмәләр. Нәтиҗәдә бу көрәшнең бөтен колачы, анда катнашучыларның батырлыгы, Совет Кораллы Көчләрен җитәкләүчеләрнең осталыгы, Коммунистлар партиясенең юлбашчылык роле бер бөтен булып гәүдәләнә.

Китапта китерелгән аерым эпизодлар безнең сугышчыларның гаҗәеп кыюлыгын, тапкырлыгын һәм ил хакына җаннарын да аямауларын раслыйлар. Менә «Правда» газетасының 1943 елгы 17 октябрь санынннан алынган берничә юл: «...Чал Днепр Туган ил өчен барган күп яуларга шаһит. Аның тарихы могҗизалы риваять кебек. Әмма Кызыл Армия сугышчылары күрсәткән батырлыклар алдында моңа кадәр булып үткән вакыйгаларның даны тоныкланып калды. Днепр ярларының мондый ук каһарманлык үрнәкләрен күргәне юк иде әле».

Җыентыкка кертелгән донесениеләр, фронт газеталарыннан алынган хәбәрләр елганы штурмлаучы сугышчыларны, вакыйгалар агышын ап-ачык күз алдына китереп бастыралар. Мәсәлән, 65 нче армия политбүлегенең 106 нчы Байкал укчы дивизиясенең 236 нчы штурм отряды тулысынча сугышка үз теләге белән килгән егетләрдән тора. Алар елганы Лоев районында беренчеләрдән кичеп чыгып фронтка юл ачалар. Отряд командиры Хохлов, көймәләргә утырыр алдыннан: «Кем, аргы якка чыккач, Кызыл байракны беркетеп куярга тели?»— дип сорый. Егетләрнең барысы да бу җаваплы бурычны өсләренә алырга әзер икән. Байрак рядовой С. А. Поповка тапшырыла. Егетне беренче көймәгә утырталар. Дошманның яудырып торган уты астында көймә аргы ярга иң беренче чыгып җитә. Попов, яраланган булуына карамастан, алга йөгерә, иң калку урынга җитеп, байракны кадап куя. Нәкъ шул мизгелдә дошман пулясы егетне аяктан ега. Поповның иптәшләре, байрак тирәсенә тупланып, яралы килеш, дошманнарга каршы торалар һәм икенче-өченче көймәдәгеләр килеп җиткәнче, шул урыннан кузгалмыйлар. Плацдарм мәйданы зурая, Кызыл байракның җилфердәве исә сугышчыларга көч өсти.

Шуңа охшаш донесениеләрдә Татарстан егетләре күрсәткән каһарманлыклар турында да укырга мөмкин. Мәсәлән, 53 нче армиянең 375 нче Харьков укчы дивизиясеннән 1243 нче укчы полкы элемтә ротасы радисты комсомол Исхуҗин тиңдәшсез батырлык үрнәге күрсәтә. Полкның командалык итү пункты өстенә дошманның автоматчылар төягән өч танкы килеп чыккач, Исхуҗин яңа гына яулап алынган плацдармдагы пушка янына йөгереп бара. Пушканың расчетындагылар барысы да һәлак булган. Тик тора. Исхуҗин берүзе пушкага «җан өрә», иң алдан килүче танкка төзәп атып җибәрә. Танк яна башлый. Дошман офицеры, танктан сикереп төшә дә, Исхуҗинга ташлана, тик егет аңа атып өлгерә. Әле моннан соң да фашистларның җиде солдатын үтерә ул. Калган ике танк кире борылырга мәҗбүр була. Шул кадәр дә тигезсез сугышта

җиңеп чыгуына Исхуҗин хәтта үзе дә гаҗәпләнә. 84 нче Кызыл Байраклы укчы дивизиянең 201 нче полкында артиллерия батареясының разведка отделениесе командиры сержант Абзай Гыйзетдиновның кыюлыгын телдән-телгә сөйләп йөртәләр. Ул дошман урнашкан җиргә үтеп керә дә, безнең артиллериягә хәбәр салып, үз өстенә ут сиптерергә куша. Аның шул алым белән дошманга салган зыянын исәпләп тә бетерерлек түгел.

Китапта генерал-майор Гани Сафиуллин җитәкләгән 25 нче укчы корпус күрсәткән батырлыкларга аерым урын бирелгән.

Сугышчыларны берсеннән-берсе кыюрак адымнар ясарга чакырып, шәхси үрнәк күрсәтеп торучыларның күпчелеге — коммунистлар. Солдатлар армиядәге коммунистларның бары тик яхшы сыйфатларын гына, партиягә һәм Ватанга ихластан бирелгәнлекләрен генә күреп торалар.

60 нчы армия политбүлегенең 1943 ел 31 октябрь донесениесендә (бу документ әлеге китапта беренче тапкыр файдаланылган) 248 нче Кызыл Байраклы аерым укчы бригадасының бер коммунисты турында болай язылган: «...3 нче укчы батальон парторгы сержант Хатип Хәсәенович Хәсәнов, милләте — татар, Нехаевка авылы өчен барган кискен көрәш вакытында пулемет расчеты белән бергә дошман тылына үтеп керде һәм һич көтелмәгән яктан ут ачты...Фашистларның ут сиптерүче ноктасы һәм 40 сугышчысы юкка чыгарылды.Батальон хәлиткеч һөҗүмгә күчәргә мөмкинлек тапты. Әмма пулемет расчетындагылар үзләре дә һәлак булган, Хәсәнов, берүзе калган иде. Яралы килеш, аңын җуйганчы, ул пулеметтан ут чәчүен дәвам иттерде. Үлем хәлендәге сержантны немецлар әсир итеп алалар һәм, күзләрен ачу белән, безнең частьларның урынын, сан-исәбен сораштыра башлыйлар. Хәсәнов: «Коммунистлар Ватанны сатмыйлар»,— дип бер генә җөмлә белән җавап кайтара. Егетне ерткычларча җәзаларга тотыналар. Башка бер сүз дә әйттерә алмаячакларына төшенгәч, Хатипның башын чабып өзәләр. Безнең частьлар авылга килеп кергәч, авыл халкы командирга батыр йөрәкле бу коммунистның гәүдәсен күрсәтә. Хатип Хәсәновка вафатыннан соң Советлар Союзы Герое исеме бирелә».

Совет Армиясенең Днепр буенда күрсәткән каһарманлыгы күпмилләтле булуы ягыннан да сокландыргыч. Мондагы җиңүләрдән соң Советлар Союзы Герое исеменә лаек дип табылган 2569 сугышчы арасында гына да илнең 37 милләт вәкиле бар. Җыентыкта раслап күрсәтелгәнчә, аларның 1850 се — рус, 435 е — украинлы, 56 сы — татар, 45 е — белорус һәм тагын 33 башка милләт кешеләре. Геройларның күпчелеге — коммунистлар һәм комсомоллар. Мәсәлән, Герой исеменә лаек дип табылган 56 татарның 33 е коммунист, 6 сы комсомол булган.

Китапның йомгаклау өлешендә Днепр кичкәндә Советлар Союзы Герое исемен алган сугышчыларның тулы исемлеге, кайбер бүләкләү кәгазьләренең күчермәләре дә теркәлгән. Анда биографик белешмәләр дә бар. Тик, кызганычка каршы, сугышчының нинди шартларда, кайда, ничек Геройлыкка лаек каһарманлык күрсәтүе генә юк. Исемлектә кыскача гына шушындый мәгълүмат та булса, «Днепр — каһарманнар елгасы» китабының кыйммәте тагын да зураер иде.

**Владимир СКОРОБОГАТОВ.**

Киев шәһәре.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## БӨЕК ҖИҢҮНЕ КАРШЫЛАП

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының 15 мартта узган ачык җыелышы Бөек Җиңүнең 40 еллыгына әзерлек мәсьәләләренә багышланды. Партоешма секретаре язучы Р. Мөхәммәдиев докладыннан соң фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар Н. Дәүли, Ш. Рәкыйпов, Р. Мостафин, Р. Харис, Р. Кәрамиев һ. б. иптәшләр катнашты. Алар хәрби-патриотик темага югары художестволы әсәрләрне күбрәк иҗат итү кирәклегенә тукталдылар, гаять мөһим бу теманың вакытлы бер кампания генә булмыйча, даими дәвам иттерелергә тиешлеген ассызыклап әйттеләр.

Куелган мәсьәлә буенча җыелышта конкрет чаралар билгеләнде.

Язучыларның 23 апрельдә узган ачык партия җыелышы «Бөек Ватан сугышы һәм татар әдәбияты» дигән темага багышланган иде.

Докладлар белән Ф. Миңнуллин (проза), С. Маннапов (поэзия), Н. Ханзафаров (драматургия) чыкты. Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Ә. Еники, Р. Мостафин, Ф. Мусин, Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б. катнашты.

Чыгыш ясаучылар Бөек Ватан сугышы турында язылган яңа әсәрләргә төпле анализ ясадылар, бу темага әсәрләр язучыларга үзләренең теләк һәм тәкъдимнәрен әйттеләр.

## ФРОНТОВИК ЯЗУЧЫЛАРНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ

6 майда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында фронтовик язучыларны Бөек Җиңүнең 40 еллыгы белән тәбрикләү тантанасы булды.

Тантаналы җыелышны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты һәм алып барды. Күкрәкләрен орден-медальләр бизәгән 26 язучыга Бауман районы хәрби комиссариаты вәкиле майор Б. П. Юрченко «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 40 ел» юбилей медальләре тапшырды.

Медальләр белән бергә фронтовик язучыларга КПССның Бауман район комитетының Почет грамоталары, истәлекле бүләкләр тапшырылды.

РСФСРның халык артисты А. Арсланов сугышта һәлак булган шагыйрьләрнең шигырьләрен укыды. Ветеран язучыларны яшь буын әдипләр котлады.

Язучылар Совет власте өчен көрәшләрдә һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәл һәм Мәңгелек ут янына чәчәкләр куйдылар.

## ФРОНТОВИК ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

29 мартта Казанның Актерлар йортында күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең Бөек Ватан сугышында һәлак булуына 40 ел тулуга багышланган кичә булып узды. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән Р. Гатауллин чыкты. Шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Миңнуллин, М. Әгъләмов һ. б. үзләренең Фатих Кәримгә багышланган шигырьләрен укыдылар. Фронтовик шагыйрьнең полкташы Габделхак ага Кафиатуллин һәм кызы Ләйлә Кәримова истәлекләр сөйләделәр.

## МУСА ҖӘЛИЛ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

23 апрельдә Минзәлә шәһәренең педагогия училищесы бинасында герой-шагыйрь Муса Җәлил музееен ачу тантанасы булды. 1941 елның ноябрь-декабрь айларында шагыйрь биредә хәрби-политик курсларда укыган. Бу вакыйгага багышланган тантанада КПСС райкомының беренче секретаре Р. Хәмадиев, «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Р. Харис, язучы Г. Ахунов, журналист Ш. Хамматов, Муса Җәлилнең курсташлары Х. Галимов, Х. Әхмәтов, шагыйрьне белгән башка кешеләр, партия, совет оешмалары вәкилләре чыгыш ясады. Тантанада катнашучылар Муса Җәлил һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре куйдылар.

## ҖӘЛИЛЧЕНЕҢ ТУГАН ЯГЫНДА

8—9 майда Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең хатыны Әминә ханым республикабызның Сарман районында булып, Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышлап уздырылган җыелышларда һәм митингларда катнашты. Әминә Җәлил, тәнкыйтьче Р. Мостафин һәм шагыйрь Р. Харис М. Җәлилнең көрәштәше Зиннәт Хәсәновның туган авылы Иске Кәшердә бәйрәм тантанасында булдылар, батыр җәлилченең һәйкәленә чәчәкләр куйдылар һәм аның музеен карадылар.

## ХУДОЖНИКЛАР — ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕНӘ

19 апрельдә Татарстан Художниклар союзының Күргәзмәләр залында Татарстан рәссамнарының Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган әсәрләре күргәзмәсен тантаналы ачу булды. Күргәзмәне ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСР-

ның атказанган художнигы Ә. И. Тумашев ачты. Бу күргәзмәдә төрле жанрларда иҗат ителгән 300 дән артык экспонат куелган.

Күргәзмәне ачу тантанасында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## «ЗУР ИДЕЛ» КҮРГӘЗМӘСЕ

25 апрельдә Чабаксар шәһәрендә «Зур Идел» VI зона художество күргәзмәсен ачу тантанасы булды. Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган бу күргәзмә Чувашия дәүләт художество музееның яңа бинасында ачылды. Анда 2 меңнән артык рәсем сәнгате, монументаль һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәре бар.

Күргәзмәне кереш сүз белән Чувашия АССР Верховный Советы Президиумы Председателе, «Зур Идел-85» күргәзмәсенең оештыру комитеты председателе А. П. Петров ачты.

Татарстанның бүгенге рәсем сәнгате әсәрләре күргәзмәдә иң зур бүлекләрнең берсен алып тора.

## КАЗАНДА ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Быел Бөек Җиңүнең 40 еллык юбилее илебез тормышының бар якларына да үзенең шифалы сулышын өрде. Шул исәптән, халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукай туган көнгә багышлап уздырыла торган традицион шигырь бәйрәме дә әлеге зур вакыйгага багышланды. «Казан язы» исеме белән клубларда, культура сарайларында, хезмәт коллективларында фронтовик әдипләр белән очрашулар, әдәби-музыкаль кичәләр уздырылды. Сарман, Арча районнарында, Г. Тукайның балачагы узган Тукай-Кырлайда, Әлмәт, Брежнев шәһәрләрендә шигырь бәйрәмнәре булды.

26 апрельдә шигырь бәйрәме республикабыз башкаласында уздырылды. Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре юлбашчыбыз В. И. Ленин һәйкәленә, А. Пушкин, М. Горький, Г. Тукай, М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәк бәйләмнәре куйганнан соң, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Г. Тукай һәйкәле алдында шигъри митинг башланды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзының шигъри бәйрәмнәр уздыру комиссиясе председателе шагыйрь Р. Харис ачты.

1985 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары шагыйрь Н. Арсланов һәм музыка белгече М. Нигъмәтҗанов чыгыш ясадылар.

Аннары фронтовик шагыйрьләрдән М. Садри, З. Нури, Н. Дәүли, Г. Паушкин, М. Хөсәен, М. Мазунов, К. Латыйпов, М. Саттаров һ. б. үзләренең шигырьләрен укыдылар, күренекле артистлар һәм мәктәп укучылары башкаруында Бөек Ватан сугышы кырларында һәлак булган шагыйрьләрнең әсәрләре һәм Г. Тукай шигырьләре яңгырады.

## ОТЧЕТ-САЙЛАУ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

16 апрельдә Казанның Актерлар йортында Бөтенроссия тарих һәм культура истәлекләрен саклау җәмгыяте Татарстан бүлегенең IX отчет-сайлау конференциясе булды.

Җәмгыятьнең Татарстан бүлеге Советы президиумы председателе урынбасары, тарих фәннәре докторы, профессор А. Х. Халиков отчет доклады белән чыкты.

Бөтенроссия тарих һәм культура истәлекләрен саклау җәмгыятенең Татарстан бүлеге Советы президиумы председателе итеп ТАССР Министлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов сайланды.

Отчет-сайлау конференциясендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова чыгыш ясады.

## ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

28 февральдә Кама Аланының культура сараенда «Казан утлары» журналы һәм Татарстан атом электр станциясе төзелеше коллективларының «Иҗади хезмәттәшлек килешүе» буенча 1984 елгы эшләрне йомгаклау утырышы булды. Төзелеш коллективы иң яхшы очерклар өчен бирелә торган премияләргә Х. Гайнетдиновның «Кеше кадере» (№ 1, 1984) һәм М. Әһлиуллинның «Яныгызга кайтыр идем!» (№ 7, 1984) очеркларын лаек дип тапты. АЭСтагы әдәби пост штабы исә «Казан утлары»ның 1985 еллык саннарын алдынгы төзүчеләр Харис Гәрәев, Дамир Сабиров, Сания Мифтахова, Фәһим Шәрифуллин һәм Нәфис Мәүлетовка бүләк итте.

Гадәттәгечә, язучылар АЭС төзелеше китапханәсенә китапларының яңа томнарын алып килгәннәр иде. Алар арасында Г. Ахунов, Г. Афзал, М. Елизарова, Н. Гайсин, Ә. Маликов, Г. Латыйп, М. Хәсәнов, Р. Нәфиков һ. б. иптәшләр бүләк иткән китаплар бар.

Утырышта журналның баш редакторы Р. Харис, Брежневтагы йортлар төзү комбинаты начальнигы М. Бибишев, 12 нче идарә начальнигы Р. Сәләхов катнаштылар.

Кичәнең музыкаль бүлегендә Татарстан АЭСын төзүчеләргә багышлап махсус иҗат ителгән «Кама Аланы» исемле яңа җыр яңгырады. Аның сүзләрен шагыйрь Р. Харис, көен композитор Р. Абдуллин язган.

25 апрельдә Кама Аланында Бөек Җиңүнең 40 еллыгына һәм Г. Тукайның туган көненә багышланган шигъри митинг булды. Аны 12 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы Р. Сәләхов ачып җибәрде. Митингта Г. Кашапов, К. Тимбикова, Р. Низамиев һ. б. катнашты.

1 майда Кама Аланында Татарстан атом электр станциясен һәм яңа шәһәр төзүчеләрнең бәйрәм демонстрациясе булды. Бу — энергетиклар каласында рәсми төстә зурлап уздырылган беренче демонстрация иде.

# ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ

Һәрбер рәссамның кабатланмас мизгеле — иҗат дөньясы күгенең «җиденче катына» күтәрелгән бәхетле очышы буладыр. РСФСРның халык художнигы, СССР һәм ТАССР Дәүләт премияләре лауреаты Лотфулла Фәттаховның мондый бәхетле мизгеле «Сабан туе» исемле картинасын иҗат итүгә бәйләнгән. Татар халкының борынгыдан килгән милли бәйрәмен күтәренке рухта, күңелгә хуш килерлек төсләр белән гәүдәләндергән әлеге полотнода рәссамның гомере буе тупланган иҗат тәҗрибәсе һәм осталыгы чагыла шикелле.

Иҗат биографиясендәге аерым этапны билгеләүче «Сабан туе» картинасы өстендә эшләү ике елдан артык дәвам итә. Үзенең сабан туйлары белән дан тоткан Әтнә якларында йөздән артык эскиз, шул исәптән карандаш рәсемнәре ясала. Натурадан алынган шушы күзәтүләрне бер бөтен картинага күчерү җиңел генә башкарылмый. Кызыклы милли типаж сайлау, геройларның бирелешен бербөтен композицион схемага берләштерү, максатка ярашлы төсләр гаммасын табу... Кыскасы, рәссамнан гаять зур тырышлык һәм түземлек таләп ителә.

Шактый озак эшләнүенә карамастан, «Сабан туе» бер сулышта тудырылган әсәр буларак кабул ителә. Композициясенең табигый һәм шул ук вакытта динамикалы булуы сокландыра. Моның сере нидә? Күренеш һәм бизәкләргә гаять бай булган бәйрәмнең бары тик бер тамашасы — сабан туеның җанын тәшкил итүче татарча көрәш мәйданы картинаның композицион үзәге итеп сайланган. Мәйданда ике батыр көрәшә. Түбәтәй кигән көрәк сакаллы карт, «Хәрәмләшмәгез!» дигәндәй, ирексездән көрәшчеләр тирәсендә бөтерелә. Мәйдан читендәге чатыр өстендә чигүле сөлгеләр җилферди. Халык шау-гөр килә. Бөдрә ябалдашлы агач төбендә басып торучы кызның карашында бил алышучыларның берсен аерата якын итүе сизелә шикелле. Көрәшкә чыгарга әзерләнеп торган иргә, әнә, янындагы хатыны соңгы «күрсәтмәләр»ен бирә. Икенче бер якта утыручы малай көрәшне шулкадәр кызыксынып күзәтә, әйтерсең, мәйдан уртасына атылып чыгарга әзерләнгәндә аны кемдер тотып калган. Киләчәк сабан туйлары батыры!.. Сабан туе, хезмәт туе... Мәйданны уратып алган хезмәт халкы вәкилләре йөзләрендә бәйрәмнең бөтен рухы көзгедәгечә чагыла. Полотнода төп герой итеп нәкъ менә алар сурәтләнгән.

Татар халкының тормыш-көнкүрешен тирәнтен белгән, кабатланмас милли характерларны сокландыргыч осталык белән бирә алган рәссамның «Сабан туе» картинасы Лотфулла Фәттахов иҗатында гына түгел, бөтен милли сынлы сәнгатебездә күренекле казаныш буларак кабул ителде, һәм әлеге әсәр Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (Мәскәү, 1957 ел) хаклы рәвештә югары бәя алды.


**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның
бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә**: Минзәлә драма театры артистлары Ә. Гаффарның «Язлар моңы» спектаклендә.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)